Дибәҗә
Каюмова

Буранлы юллар

Дибәҗә Каюмова

Буранлы юллар

Повестьлар, хикәяләр

Казан
«Рухият»
2004

ББК 84 - (2Рос-Тат) - 4
К35

Мөхәррире
Асия Юнысова

Илья Максимов
рәсемнәре

Каюмова Дибәҗә.
К35 Буранлы юллар: Повестьлар, хикәяләр. — Казан: Рухият, 2004. — 384 бит.

Дибәҗә Каюмованың бу китабына соңгы елларда иҗат иткән проза әсәрләре керде. Авторның, һәрвакыттагыча, геройларының холык-фигыльләрен, кичерешләрен үз күңеле аша кичереп, йөрәге аша уздырып язган бу әсәрләрен укучы яратып каршылар дип уйлыйбыз.

ISBN 5-89706-079-7

© Дибәҗә Каюмова.
© «Рухият» нәшрияты, 2004 ел.

РӘЙХАН

Аның фатиры шәһәр читендәге йортның дүртенче катында. Кухня тәрәзәсеннән еракларга сузылган такыр басу күренә. Рәйхан, еш кына өстәл янындагы артсыз урындыгына утырып, еракларга күз сала. Өй янына кайчандыр кемнәрдер утырткан бөдрә каеннар саргайганнар. Җир өстендә көз дигән матур да, моңсу да чор. Әле яңгыр ява, әле кургаш болытлар кызу-кызу каядыр агылалар да ялтырап кояш чыга, тайгак юллар кала... Менә кинәт җил күтәрелә, тәрәзә артындагы каеннарның сары яфракларын йолкып алып, каядыр очыртып алып китә. Ә каеннар, җилгә буйсынып, әле уңга, әле сулга чайкалалар. Кайчак көзге җил шул кадәр шәфкатьсез кылана — зифа каен, бөтен ябалдашы белән җиргә авып, харап булыр төсле тоела. Аумый үзе. Нык. Бөгелә генә, сыгыла, сынмый.

Рәйхан ялгызы. Тәрәзә янындагы тимер бәтәрәйләрдән бөркелгән җылыга оеп, җайлабрак утыра да, үткәннәрен исенә төшерә башлый. Үткән гомер — аккан су...

Менә ничә көннәр инде ул берәүне көтә. Берәү дигәне беренче яратканы, тугры булырга антлар итешкән, әмма язмыш ераклаштырган, нәкъ илле ел инде күз карашы, кыяфәте, гәүдәсе, күкрәк җылысы онытыла, күңеленнән җуела алмаган Мулланур.

Кинәт ишек шакыдылар. Рәйхан сискәнеп куйды. Кер, дигәнне көтмәде, ишектә Мулланур күренде. Ишекне ачкач, артка таба борылып, ул кемнедер чакырды.

— Әйдә, әйдә, ул өйдә.

Мулланур артыннан Рәйханга таныш булмаган берәү атлады.

— Утыңны кабыз, нишләп берүзең караңгыда утырасың?

— Мин берүзем түгел, гадәтемчә, гел синең белән,—дип шаяртты Рәйхан, урыныннан кубып аларга таба атлады.

Рәйхан куанычын яшермәде. Көткәне килде, җанына нур өрде.

Ул, чыннан да, ялгыз калганда да, җаны гаҗәеп киеренке халәттә дә аны көтә, татлы да, ачы да, шатлыклы да, хәсрәтле дә тойгылар дулкынында чайкала.

— Мин инде әллә кайчаннан бирле синең яныңа җыенып йөрим... Әллә нәрсә тоткарлый шунда,— дип сөйләнде Мулланур, аклангандай.

Рәйханга бу сүзләр күптән таныш: нидер тоткарлый, киртә була. Рәйхан аны аңлый, ул фәкать шатлыгын кая яшерергә белми, сөрмәле күзләрен очкынландырып, Муллануга карый. Бу — аның бердәнбере, аның илле ел буе сөйгәне, кадерлесе. Аларның әле сөйләшер сүзләре бетмәгән. Сирәк булса да, алар Рәйханның оҗмахтай якты, матур, җылы, аулак өендә очрашалар, сөйләшәләр, көлешәләр. Нәкъ яшьлектәгечә, нәкъ теге илле ел элек очрашкандагы, танышкандагы кебек. Әллә кайда яшеренеп яткан хисләр уяна, яңгыр булмаудан кипшенә, яргалана башлаган җирне, туфракны манчыган шифалы тамчылар кебек, бер-берсеннән бөркелгән җылы нур аларның җанын ләззәтли. Көтү минутларындагы газаплар, эч пошу, ялгызлыктан иза чигүләрнең эзе дә калмый. Бу очрашу минутларында Рәйхан үзен саф һавалы нарат урманында сәйран кичкән кебек хис итә, яшьлегенә кайта.

Мулланур Рәйханга авыр гына сумка сузды, плащын салып чөйгә элде.

— Үтегез, рәхим итегез,— диде Рәйхан елмаеп.

— Менә шушы иеде минем табыныр дәрәҗәдә гашыйк булган беренче һәм бердәнбер гомерлек мәхәббәтем, — диде Мулланур танышына. — Әйе, әйе, табыныр... кемем, дим соң? Аллам, дисәм, ярамас...

— Фәрештәм, диген, —диде танышы.

— Әйе, гомерем буе табынган фәрештәм — Рәйханым. Мулланур Рәйханга таба атлады, аның җилкәсе аша гына сузылып, нигъмәтләр тезелгән өстәлгә күз салды.

Әле дә җыйнаклыгын югалтмаган ыспай гәүдәле Рәйхан, алкаланып-алкаланып торган чал бөдрәләрен җилпеп җибәреп, Мулланурга таба борылды.

— Мин нинди фәрештә булыйм, ди. Күрмисезме, чәчемне дә яулык астына яшерергә онытып утырганмын, — дип, шкафтан пәрәвездәй юка ефәк ак яулыгын алып, чәчләрен каплап артка бәйләп куйды.

— Фәрештәм булмасаң, җырланмаган җырым, уйналмаган скрипкам син, — дип, Мулланур аны җилкәләреннән сак кына кочып алды.

***

Яз. Алма агачлары, чияләр ап-ак мамык шәл ябынган чак. Авыл уртасындагы бакчада, агачлар арасында түп-түгәрәк уен мәйданы яшьләр белән тулы. Күктә, нәкъ мәйдан өстендә тулган ай эленеп тора. Яшьләр, ай яктысында бер-берсен чак төсмерләп, үзара әңгәмә коралар. Заманы өчен ыспай киемле, ак якалы егетләр бер читтә төркем-төркем булып җыелган. Мулланурның әле андый ак якалы күлмәге дә, фырт чалбары да юк. Ул егетләр тирәсендә әрле-бирле йөрде дә, киеменең ташка үлчим булуыннан кыенсынып, китәргә ниятләде. Шул арада бер төркем кызлар яланга якынлашты. Алар, чыр-чу килеп, Мулланурны урап алдылар.

— Кайттыңмы, Мулланур?

— Кайчан кайттың?

— Трактор хисапчысы булып эшләү авыр түгелме? Мулланур, унны бетергәч, ерак бер урыс авылында трактор хисапчысы булып эшли иде. Эше күп, көн-төн басуда.

Нурулла, тирә-якны яңгыратып, гармунын тартып җибәрде һәм дәртле бию көе уйный башлады. Арадан бер кыюрак егет атылган ук кебек уртага чыкты, ике кулын кош канатларыдай җәеп җибәреп, тыпыр-тыпыр бии башлады.

Мулланурның шушы егет кебек кыюланып, уртага чыгып дәртләнеп биисе килде, әмма булдыра алмады, бер кырыйда басып карап торудан узмады.

Чыр-чу килүче кызлар арасында зифа талдай нәфис гәүдәле, ак кофта, кара итәк кигән бер кыздан да килештеребрәк биегәне булмады.

Мулланур кыздан күзен алмады, биеп туктагач та, түгәрәкнең теге ягында, нәкъ Мулланурга каршы басып торучы ул кыз аның күңелен яулады. Менә кызны тагын бер егет биергә чакырды. Кыз ялындырып тормады, башын аска ия төшеп, аякларын тиз генә тыпырдатып алды да, нечкә билен уйната-уйната, суда йөзгән аккоштай, талгын гына егеткә таба юнәлде. Аяклары белән йомшак үләннән шуып кына бара, ә куллары килешле итеп ике якка җәелгән, гүя ул, шәльяулыгын чукларыннан гына тотып, уртада әйләнә.

Ялгыз биюләрдән соң парлы, өчле, сигезле биюләр берберсен алыштырды. Егетләр, кызлар парлап-парлап биеделәр, озак-озак бөтерелделәр. Ялан дәртле яшьләр шаушуыннан гөрләп торды. Мулланур да баскан җирендә җыр көенә чайкалгалады. Менә ул, ниһаять, бөтен кыюлыгын җигеп, ак кофталы кыз янына килде, сүз катмакчы булды. Кыз кинәт кенә аңа таба борылып карады. Ай яктысында кызның күзләреннән очкын чәчрәгәндәй булды.

Ниндидер шаянлык, чаялык, серлелек бар иде ул күзләрдә. Таныш булмаган бу кыз бөтен барлыгы белән уен, шаяру, ташып торган шатлык, бәхеттән гыйбарәт сыман иде.

Аларның күзләре очрашты. Мулланурның йөрәге күкрәк читлегендә бәргәләнде. Их, шушы ак кофталы кыз кебек шат та, кыю да, чая да булсаң иде! Барлык оялчанлыгыңны, тыйнаклыгыңны онытып, очып уртага чыксаң һәм биергә фәкать шушы кызны гына чакырып, аның белән озак-озак бөтерелсәң иде. Берничә мәртәбә кызга дәшергә талпынып караса да, булдыра алмады, каушады, кирәкле сүзләр табылмады. Ул фәкать кызның тагын бер мәртәбә аккош кебек мәйдан уртасына таба йөзеп китүен теләде.

Кем соң ул? Кунак кызымы? Кайсы авылныкы? Кем исемле? Бу сораулар Мулланурның миен бораулады.

Аларга тиз генә танышу насыйп булмады...

***

Рәйхан район үзгенә, кияүдәге апаыына кунакка килгән иде.

Ләмига апасының ике айлык улы, бик елак. Юу, җыю, ашау-эчү хәстәре — барысы да Ләмига өстендә. Болай да эш сөймәгән яшь хатын тәмам пычракка баткан. Кая карама юылмаган савыт-саба, пычрак бала чүпрәкләре, чүпчар. Кызы белән бергә кунакка дип килгән анасы Хәтирә, икенче көнне үк су җылытып, көне буе бала чүпрәкләре юды, каткан табак-савыт, сөттән бушаган чүлмәк, төбе көйгән кәстрүлләр, ботка каткан кашыкларны төнгә суга салып куйды. Урын-җирнең тузанын какты, ишек-тәрәзәләрне сабынлап юды, идәннәрне комлап ышкыды. Ана бит, кызының шапшаклыгына, торган өенең бу кадәр рәттән

чыгуына сәбәбен тапты: баласы елак, кулын бәйләгән, дип фикер йөртте. Чистартты, юды, сөртте, үтүкләде.

— Ярый әле, килдегез, әни, мин бит ялгыз, ярдәмчем юк,—дип сөйләнде Ләмига караватка ятып бала имезгәндә. — Өй җыештырырга килгән хатыннарны кудым. Берсе бер рәтле итеп эш белми, яратмадым.

Берничә көнгә Казанга командировкага киткән кияве, райком секретаре Фазыл Саматов кайтып төште. Ул, капкадан керү белән үк, өйдәге үзгәрешләрне күреп алды. Тәрәзәләр киерелеп ачылган, ишегалды тутырып кер эленгән, бар җирдә тәртип күзгә ташлана.

— Оҗмахка әйләнгән түгелме соң безнең өй?!— дия-дия, Фазыл өйгә керде. — Минем оҗмах кошым, Ләмигам, йомшак кулларын чылатканмы әллә дисәм, әби килгән икән. Исән-сау килдегезме? Һо-о, Рәйхан нинди зур кыз булган. Әллә сине бөдрә чәчләреңнән тартып үстерделәрме?

Рәйхан җизнәсенең бу сүзләреннән комачтай кызарды.

— Кара әле, әби, безнең баһадирны! Малай үстерәбез бит без. Егет! — диде Фазыл көр тавыш белән.

Әни кеше һаман да үзенә эш тапты. Самавыр куеп җибәрде, өстәл әзерләде. Фазыл сүзен дәвам итте:

— Тик менә Ләмига гына өйдә эшләргә, бала карарга кеше тап, мин эшкә чыгам, дип куркыта. Ләмига эшли башласа, баланы кая куярбыз, кемгә каратырбыз?

Кияүнең сүзләре Хәтирәне борчуга салды: чыннан да, балаларын кем карар? Өй эшләрен кем эшләр? Һай, үз яннарында гына булсалар! Көн димәс иде, төн димәс иде, эшләр иде, ярдәм итәр иде. Аралар бик ерак шул. Хәтирә шул уйлар белән баш ватты.

Икенче көнне Ләмига болай дип сүз башлады:

— Карап-карап торам да куанып бетә алмыйм, Рәйхан бигрәк уңган кыз булып үсеп килә икән, кулы эшкә ятышып тора.

— Әйе, җитезлеге дә, уңганлыгы да Аллага шөкер.

— Сиңа унбер яшьме инде, Рәйхан?

— Әйе, уникенче китте.

— Дүртенчегә күчтеңме, бишенчегәме?

— Дүртенчегә.

— Әллә бездә генә каласыңмы соң? Бездә зур яңа мәктәп,

укытучылар бик яхшы. Укуыңны бездә дәвам итәрсең. Миңа да ярдәмче булырсың.

Рәйхан дәшмәде. Ул эченнән бик риза иде, чөнки олы апасын бик ярата, җизнәсен әтисе кебек күрә.

— Әни, —диде Ләмига, — калдыр безгә Рәйханны. Үзеңә дә җиңелгә килер. Дүрт кашык күтәрәсе урынга — өч кашык, диюем. Бездә яшәр Рәйхан, киендерербез, укытырбыз, ким-хур булмас.

Шулай итеп, Рәйхан олы апасы белән җизнәсендә бала карый башлады.

Башта эшләр уңай гына барды. Ул кечкенә Марсельне кулыннан төшермәде, ашатты, йоклатты. Апасы да йомшак кына эндәште, күп эш кушмады. Тора-бара апасы бик тупасланды, кычкырды, юк кына нәрсәләрдә гаепләде, хәтта кыйный башлады.

— Нәрсә терәлеп каттың? Су алып кайт! Идән ю!

Рәйхан зур-зур чиләкләр белән су ташыды, идән юды. Инде хәзер усал итеп кычкыручы апасы аңа Алмалыдагы күрше карчыгы булып күренә башлады. Сафура карчык килене Рәшидәгә нинди генә сүзләр әйтми иде, Рәйхан хәйран кала иде. «Каян килә кешеләргә мондый явызлык?!» — дип уйлый иде. Менә үзе хәзер Рәшидә хәлендә. Марсель елый башласа, апасы аңа:

— Ишетмисеңме әллә, бала елый! — дип кычкыра.

Рәйханның апасына: «Минем балам түгел, синеке бит ул»,— диясе бик килсә дә, әйтми, түзә.

Кайбер көннәрдә Рәйхан Марсельне күтәреп Каргалының югары очына, әнисе киткән юлга килә һәм озак-озак елый. Әнием, ник син мине монда калдырдың? Мин сине бик сагынам бит. Апам бик усал, ул мине җәберли, кыйный...

Ләмига үзе эшкә киткәндә, тегене эшлә, болай ит, дип, Рәйханга көн буена җитәрлек эш калдыра.

— Әнә, шулпасы әзер, җизнәң кайтыр алдыннан утка утыртып, менә бу макаронны салырсың, — диде беркөнне Ләмига.

Рәйхан сәгатькә карап кына торды. Унбер тулып, уникенче китү белән Марсельне караватына бастырды да, керосинкага ут кабызып, олы апасы тәлинкәгә салып калдырган макаронны шулпага салды. Кайнап чыкканчы

яныннан китмәде, кайнап чыккач, онытылып Марсель белән уйный башлады.

Ләмига кайтып кергәндә кәстрүлдәге аш кайнап, куерып беткән иде.

— Нәрсә бу? — дип җикерде Ләмига. — Нәрсә бу? Ник ашны карамадың?

— Үзең әйттең бит, салырсың, дидең, салдым, кайнаттым...

Рәйхан куркып каушап калды. Ул да булмады, апасы пыр тузып тәрәзә янына омтылды, тәрәзә кашагасыннан уклауны йолкып алды һәм Рәйханга ташланды. Юан уклау баланың әле җилкәсендә, әле билендә, әле башында дөпелдәде. Рәйхан, суксаң сук инде, дигән сыман, иелә төшеп, сулкылдап елады да елады.

— Нәрсә булган? Ник сугасың син аңа? Үтерәсең бит!

Бу — эштән кайтып кергән Фазыл иде.

— Әнә, ашка салган токмачы укмашып, кәстрүл төбенә утырган, аш быгыр-боламык булган, — дип шәрран ярды Ләмига.

— Пычагым да булмас, ашарбыз, ашаудан башкага ярамас, — диде җизнәсе, — ник син аны кыйныйсың? Ул синең бөтен эшеңне эшли, балаңны карый.

— Үтерәм мин аны, тагын болай эшләсә. Үтерәм!

— Синең, Ләмига, бозык каның кайный. Тынычлан. Син — бай, ул хезмәтче түгел бит. Ул синең бертуган сеңлең ләбаса.

— Бертуган, бертуган!.. — дип кычкырды Ләмига.

Ул шунда, чыннан да, үзенең кан тамырларында затлы кан, байлар каны агуын исенә төшерде.

Әйе, Ләмига Хәтирәнең беренче ире, бай малае Гыйрфаннан туган кызы иде. Гыйрфан каты куллы, саран кеше иде. Тау чаклы вәгъдәләр биреп тә, берсен дә үтәмәде. Кызы Ләмига тугач, миңа ир бала кирәк, дип, яшь хатын алып кайтты. Бай кызы Мөхтәрәмә бик иркә, көйсез, үзсүзле булып чыкты. Я, Хода, нинди генә сүзләр ишетмәде Хәтирә бу каһәрләнгән өйдә. Көн дә ызгыш, көн дә җәнҗал булды. Түзде-түзде дә Хәтирә авылдан качып китте...

***

Менә шушы «бай кызы»нда яши иде Рәйхан. Яшәү авыр

булса да, үсә төшкәч, кичке уеннарга чыга башлады. Анда ул гармунчы егет Рамил белән танышты. Мулланурга ул башта, нишләптер, күз дә салмады. Хәер, бигрәк кыюсыз иде шул Мулланур...

Рамил көн дә кичләрен кызны капка төпләренә чаклы озатып куя. Ул гармун уйный, Рәйхан җырлый.

Бер кичне алар озак кына урамда йөргәннән соң, бер эскәмиягә килеп утырдылар. Рамил гадәтенчә гармун уйнады, Рәйхан әкрен генә җырлады:

Аргы яктан бирге якка
Басма салдым киң итеп...

Шулчак алар каршысына яшел күзен ялтыратып, зур бүре килеп туктады. Уттай янып торган күзләрен әле Рамилгә, әле Рәйханга текәп, гармун тавышын тыңлагандай тын калып, арт аякларына чүкте. Аларның нәкъ каршыларына утырды.

— Ай, әллә бүре инде?!

Рәйхан шулай диде дә Рамилнең муенына ташланды, күзләрен чытырдатып йомды.

— Курыкма, бүре бу, карт бүре, — дип пышылдады Рамил, үзе гармунын уйнады да уйнады.

— Киттеме әле, Рамил?

Ә бүре аларга карап һаман утыра бирде.

— Китмәдеме әле, Рамил? — дип кабат пышылдады Рәйхан.

— Юк, китмәде. Курыкма, кыймылдама.

Рамил Рәйханның куллары калтыравын тойды, әмма аңа сөйгәненең бу халәте дә тиңсез ләззәт бирә иде.

— Китмәде әле, китмәде.

Кинәт Рамил гармунының барлык төймәләренә басып, бар көченә күреген сузып җибәрде, бүре сикереп куйды һәм, урыныннан кузгалып, авыр гына атлап, басу капкасына таба юнәлде.

— Китте, китте, ач күзләреңне, Рәйхан, җырлап бетер инде җырыңны.

Рамил тагын бик моңлы бер көй уйный башлады һәм җырлап җибәрде:

Төнгә каршы берәү моңлы итеп,
Рамай,
Аерылышу көен җырлады...

— Бу нинди җыр, Рамил?

— Бу «Рамай» дигән яңа җыр. Матурмы?

— Матур, ләкин...

Рәйханның күңеленә ниндидер шом үрмәләп, суык булып китте.

— Йә, Рамил, мин туңдым, керәм инде, — диде.

Чыннан да, май төне суык идеме, башка сәбәптәнме, Рәйхан кереп китәргә ашыкты.

Әйе, бу ак чырайлы, какча гәүдәле, бик акыллы карашлы гармунчы егетне никтер Рәйхан үз итә алмады.

***

Икенче көнне алар тагын очраштылар.

— ...Китәм инде бик еракка, Рамай,

Сөйгән ярым, синнән аерылып...

Рамил бик кәефсез иде, ул Рәйханга карамый гына җырлады да җырлады, гармунын гадәттәгедән катырак тартты, катырак кычкыртты.

— Ни булды сиңа, Рамил? — диде Рәйхан. — Бигрәк моңлы җырлыйсың, кем белән аерыласың, кемне калдырып китәсең? Нәрсә булды?

— Булмады...

— Булган инде, булган. Әллә авырыйсыңмы?

Рамил дәшмәде. Читкә карап бик озак торганнан соң, эченнән сыгып чыгарган кебек:

— Әйе, мин авырыйм. Шуңа күрә, син дә атна саен рингиткә йөрисең икән бит, — диде.

— Рингиткә?! Кем әйтте? Юк сүз ул. Безне, балалар белән эшләүчеләрне, елга ике тапкыр мәҗбүриләп рингит белән тикшерәләр. Кем әйтте? Әйт, кем әйтте?

Рамил тураебрак баскандай итте, баскан җирендә бераз гына таптанып алды һәм киң итеп сулыш алып, бөтен кыюлыгын җыеп берьюлы әйтеп салды:

— Әйе, Рәйхан. Дөресен әйтим. Миндә — туберкулез. Мин шуңа да сине хәтта үбәргә дә куркам. Сизмәдеңмени? Син мине гаепләгәнсеңдер, бәлки, шуңа да ярата алмыйсыңдыр.

Шушы сөйләшүдән соң, Рамил Рәйханны чакырып, турларында башка бер дә гармун уйнамады.

Кичен уенга чыккач, Рәйханның дусты Рәсимә аңа бер дәфтәр тоттырды.

— Мә, Рамил бирде, сиңа истәлеккә бирергә кушты. Укып кара.

Рәйхан дулкынланып дәфтәрне кулына алды: — Ә син укыдыңмы? — Юк, укымадым.

— Әйдә, бергә укыйбыз, әйдә, әйдә. Кайтабыз да укыйбыз. Бу Рамилнең көндәлек дәфтәре иде. Шигырьләр, җырлар, күз яшьләре аша язылган әрнешле сүзләр. Башта Рәйхан үзе укыды. Дәфтәр шул кадәр пөхтә, чиста. Рамилнең язуы шундый матур. Рамил генә шушылай энҗе бөртекләре кебек тезеп, матур итеп яза ала, ул гына шушындый әчкерсез шигырьләр чыгара ала икәненә ул ышанды.

«Быел ураклар урмадым
Карурман буйларында.
Синең белән аерылышу
Юк иде уйларымда...»

Рәсимә елап җибәрде. Рәйхан исә теге көнне булган сөйләшүне искә төшерде.

— Ул дәваланырга санаторийга китәм, диде, — дип күз яшьләрен сөртте Рәсимә.

«Биек тауның башларында
Куйбышев дигән кала.
Минем башка бүләгем юк,
Шушы истәлек кала.»

Кызлар озак кына Рамилне кызганып еладылар. Рәйханда бу егеткә карата олы ихтирам, хөрмәт хисе уянды. Ләкин ул мәхәббәт түгел иде.

Көннәр үтте. Рамил инде онытылды. Бары дәртле яшьлек калды һәм уен-көлке, көн дә бию, җыр, кичке уеннар дәвам итте. Яшьлек ул — үзе матурлык, диләр. Ә чибәр булсаң? Кашларың кыйгач, күзләрең сөрмәле, билең нечкә, гәүдәң килешле булса? Моны ничек дип атыйлар? Рәйхан инде үзенең үтә дә чибәр икәнен чамалый иде бугай. Бу авыл кызлары арасында ул иң чибәр, иң килешле дигән абруй казанды, егетләрнең күзләрен яндырды. Кайсы гына егет аның белән парлап биергә, кайнар кулларын тотарга, нечкә биленә бармак очы белән генә кагылырга хыялланмады икән? Тик Рәйхан барысы арасыннан бер генә егетне ошатты...

Шулай да Рәйхан бу егет белән бик сак сөйләште, кызлар табигатенә хас тыйнаклыкны саклады.

***

Рәйхан ул көнне гадәттәгедән иртәрәк уянды. Сабан туен, Мулланурны исенә төшерде, күңеле шатлык хисе белән тулды. Аның тәрәзә пәрдәләрен аерып, тәрәзәләрне ике якка ачып, өй каршындагы шомыртларга карап кычкырып җырлап җибәрәсе килде.

Көне буе шул җилкенү, җиңеллек һәм шатлык хисләре белән йөрде: җитезрәк атлады, кызурак сөйләште. Үзе эшли торган балалар бакчасының кысан бүлмәләре аңа киңрәк, чыр-чу килеп уйнаучы балалар да матуррак күренде. Әйе, бүген ул — башка кеше, бүген аңа әллә ни булды.

— Апа, — диде Рәйхан кич уенга чыгар алдыннан, — теге чигешле маркизет кофтаңны бүген дә уенга киеп чыгыйм әле.

— Киярсең, тик егетләрнең пычрак кулы тимәсен.

— Уенга егетләр пычрак кул белән чыкмас инде...

— Төрлесе була аларның. Кулы сабынлап юылса да, күңеле пычраклары булуы мөмкин.

Рәйханның кер кунмаган күңеленә бу сүзләр бик сәер тоелды. Күңел ничек пычрак булсын инде? — дип уйлады кыз. Күңел ул — иң саф, иң чиста нәрсәдер.

Кара бөдрә чәчен тарап, апасының маркизет кофтасын кигәч, Рәйхан түрдәге ике тәрәзә арасына эленгән зур көзге каршына килде, бөтерелеп алды, үз-үзеннән канәгать булып, йөгереп урамга чыкты. Җил капкадан чыгу белән, ул көчле ташкын булып авыл өстен каплаган гармун тавышына әсәрләнде, гармун аның җырын суза иде. Кызның күңел халәте белән гармунның моңлы тавышы шул кадәр тәңгәл ки, ул атлаган җиреннән йөгерә үк башлады. Җыр аны еракларга чакыра, алгысыта иде. Ирексездән ул җырлый ук башлады:

Аклы ситсы күлмәгеңнең
Якаларын кем уйган?

Ул җыр иркенә бирелде. Җыр аңа атап язылган кебек тоелды. Ул гүя гади Рәйхан, ятим кыз түгел, ә әкияти чибәр, күккә ашып бара, гүя ул бөтенләй икенче, серле дөньяга

күчкән. Ул йөгерде, дулкынланып, соңга калудан, җырның өзелүеннән куркып йөгерде...

***

Мулланур яңа чалбар, ак күлмәк киеп, бүген кичке уенга тагын Рәйхан белән очрашасына нык ышанып килде.

***

Рәйхан мәйданчыкка якынлашканда, җыр тынган иде инде. Гармунчы ниндидер кыска көй уйный. Мулланур Рәйхан киләсе юлны бертуктаусыз күзәтте.

Ниһаять, ерактан караңгы урамда ак кофта ялтырап күренде. Мулланур ашкынып аңа таба атлады.

— Хәерле кич, Рәйхан.

Алар туктадылар.

— Хәерле кич, Мулланур.

— Инде бүген «син» дип кенә дәшәм, ярыймы, Рәйхан?

Чая кыз шаяртып алырга уйлады:

— Юк, ярамый, миңа һәрвакыт «сез» дип дәшәрсең?— дигән булды, башын югарырак чөеп.

Ул урам буйлап атлавын дәвам итте.

— Без бит инде танышлар, дуслар, — диде Мулланур кыюсыз гына, аның белән рәттән атларга тырышып.

— Әйе, әллә кайчаннан бирле, — дип үртәде кыз.

— Менә ике көн инде минем күңелем тынгылык тапмый.

— Ник? Ни булды?

— Синең белән танышканнан бирле тынычлыгым бетте... Сине кичә озатып куйганнан соң, төне буе йокламадым. Таң алдыннан гына онытылып алганмын. Синең күзләреңне төшемдә күреп уянып киттем. Бу күзләр, бу керфекләр минем йөрәгемне тишкәләделәр.

— Ә син тынычлан, аларга ашардай булып карама. Ник карыйсың?

— Мин синең күзләреңә бертуктаусыз карап торыр идем...

Мулланур кыюланып аңа таба омтылды һәм ике кулы белән аның беләкләрен кысып тотты, үзенә таба борып, Рәйханның кайнар иреннәрен үзенең кипшенгән салкын иреннәре эченә алып, бик каты суырып үпте.

Рәйхан бу көтелмәгән шашкын үбүдән тын ала алмый торды. Мулланурның иреннәреннән котылгач, никтер уфтанып:

— Уф! — диде.

Бу Рәйханның беренче тапкыр егетләр белән үбешүе иде. Ул коелып төште, ни эшләргә белмәде, тәне буйлап ниндидер кайнар дулкын үтте. Мулланур тагын Рәйханны кочаклап алды.

— Кем соң син? Минем юлыма каян килеп чыктың? Ходай бирдеме миңа сине? Шайтанмы? — Мулланур тагынниләрдер сөйләнде, аның кайнар тыны Рәйханның битен яндырды.

— Йә, җибәр әле, артык әрсез булма, бигрәк куркыныч сүзләр сөйли башладың тагын...

— Рәйхан, минем сиңа бер үтенечем бар.

— Нинди?

— Әйдә, көн дә кичләрен күрешәбез. Мин сине бик яратам.

— Яратам, дисеңме? Син бит мине бөтенләй белмисең. Белмәгән кешене ярталармыни? Ярату өчен аның кем булуын, холкын-фигылен белү кирәк.

— Белмәсәм дә, аңлыйм, күңелем белән сизәм — син миңа булырга тиеш, мәңгегә.

— Миңа?! Миңа, дисеңме? Ул ни дигән сүз? Мин бит әйбер түгел, уенчык түгел. Безнең бакчада балалар, «миңа! миңа!» дип, уенчыклар өчен тарткалашалар.

— Йә, йә. Ачуланма, мин матур итеп әйтә алмадым бугай. Ничек итеп әйтим соң? Без бергә булырга тиеш.

— Бергә? Монысын ничек аңларга?

— Йә инде, син бик усалланма әле. Мин дә усал була беләм.

— Йә, йә, усаллан.

— Карале, Рәйхан! Усалланганда синең күзләрең тагы да сөрмәлерәк булып күренә икән, очкынланып китә хәтта.

— Бәйләндең инде шул күзләргә: «серле», «сихерле», «очкынлы». Тагын нинди?

— Тагынмы? Тагын, тагын... — Мулланур үтемлерәк сүзләр эзләде, — беләсеңме, синең күзләр — иң матур, иң матур күзләр.

— Йә, җитте! Бернинди дә матур түгел, гап-гади коңгырт күзләр. Кайберәүләрнеке кебек зәп-зәңгәр яки чем-кара булса, матур, дияр идең.

— Димәк, без икебез дә гап-гади. Ә мин сине Ходай тарафыннан миңа җибәрелгән фәрештә дип белгән идем.

Рәйхан Мулланурның күкрәгенә башын куйды. Шунда кыз күкрәк эченнән дөп-дөп иткән тавыш ишетеп, тынып калды. Абау! Агач келәт эчендә дулаган ат кебек, ашкынып-ашкынып, талпынып-талпынып тибә икән йөрәк дигәнең! Мулланурда гынадыр мондый кайнар йөрәк, шашкын йөрәк.

Моңарчы Рәйханның йөрәк тавышын ишеткәне юк иде. Йөрәкне шулай ук көчле тибәдер дип уйламый иде ул. Кара, менә шушы йөрәк бит инде сөю һәм сөелү әгъзасы, дип уйлады кыз. Күзләр күрә, куллар тота, колак ишетә, ә йөрәк... Ә йөрәк йә ярата, йә яратмый. Әйе, әйе. Нәкъ шулай. Йә ярата, йә яратмый.

Йөрәкне зур түгел, кешенең үз йодрыгы кадәр генә, диләр.

Шушы уйлар белән Мулланурның йөрәк тибешен тыңлап бераз тын гына торган кыз, егетнең күкрәгеннән башын алып, аның кулына үрелде.

— Йодрыгыңны күрсәт әле, Мулланур.

— Йодрык татыйсың киләме әллә?

Егет көлеп җибәрде.

— Юк ла, мин йодрыкны күп татыдым инде, мин синең йөрәкнең ни зурлыкта икәнен күрәсем килә.

Мулланур эре сөякле бармакларын бергә төйнәп, Рәйханның күзләренә якын ук китерде.

— Менә күр. Зурмы?

— Зур да түгел икән, югыйсә, ә шундый дулый үзе, шашып-шашып тибә.

— Зур түгел, дисеңме? Минем йөрәк йодрыгым кадәр генә түгел, беләсең килсә, йодрык чаклы ике...

***

Рәйхан дус кызы Санияләргә керә. Кызлар — кызлар инде, бертуктаусыз көләләр, шаяралар, көзге тирәсендә бөтереләләр. Сания кашларын каралта, сөрмә тарта.

Саниянең әнисе кызлардан күзен алмый, һай, яшь чаклар, колын чаклар, тай чаклар! —дип уйлый. Ул кызларның ялгыз йөрмәгәнен белә.

— Килегез әле, икегезгә дә бер нәрсә сөртәм. Тәмле исле булыгыз, егетләрегез үзегезне үбеп туймасын, — дип көлә.

Ул, сугышта ятып калган ирен исенә төшереп, яшьлегенә кайткандай була.

— Нәрсә соң ул? — дип чыркылдаша кызлар.

— Менә, сөрткәч белерсез. — Ул кызларның битенә, иреннәренә гөлсирин сөртә.

— Гөлсирин, гөлсирин! — дип куана Сания. Алар хуш исле гөлсиринне иреннәренә сөртеп, кичке уенга китәләр.

Айлы төннәрдә Рәйхан белән Мулланур урам буйлап сүзсез генә озак-озак йөриләр.

— Телисеңме, Рәйхан, мин сиңа безнең авылның иң матур урыннарын күрсәтәм. Син әле безнең авылның су буйларында йөргәнең, тау башына менеп, авыл өстенә күз салганың юктыр, — диде Мулланур кич кызны озата барганда.

— Юк шул, берүзем нишләп йөрим инде.

Айлы кичләрдә Мулланур кызны үзенең туган авылының чишмә буйларына, киң аланнарына алып барды. Еш кына авыл турында халык телендә йөргән төрле риваятьләр, гыйбрәтле хәлләр турында сөйләде.

Беркөнне кич алар авылның елга аръягындагы текә тавына таба, сөзәкләп, борылып-борылып тауга күтәрелә торган киң юлдан салмак кына атладылар. Куллар — кулда, иңнәр — иңдә иде. Бәхет, мәхәббәт канатлары җилкендереп-җилкендереп аларның адымын җиңеләйтте.

Тау башына менеп җиткәч, Рәйхан егетнең кулыннан кулын алып, артка таба борылып басты һәм хәйран калды. Биек тау башыннан караганда, авыл уч төбендәге кебек ап-ачык булып күренеп тора иде. Әле шәфәкъ кызыллыгы сүнмәгән, шулай да тәрәзәләрдә балкыган утлар тычкан уты кебек бер-беренә күз кысыша.

— Кара, кара, Мулланур! Нинди матур икән бит сезнең авыл. Агачлар ничек күп. Авыл ямь-яшел, урман диярсең!

Алар озак кына авыл өстенә сокланып карап тордылар. Нindidер рәхәтлек, нindidер җиңеллек белән, авыл чаклы авылдан өстә, күккә якынлашып басып торалар бит алар, мәхәббәттән җилкенгән бу ике яшь йөрәк. Ул арада тауның төн ягыннан колач җитмәслек алтын шар булып, әкрен генә

ай күтәрелеп килә иде. Йа Хода! Аймы соң бу? Күкне һәм җирне тоташтырып берничә генә мизгел җиргә терәлеп торды да, ай җирдән аерылып, күзгә күренеп өскә күтәрелә башлады. Җир йөзендә шушы сары шардан башка берни юк кебек тоелды кызга. Ә ул шул кадәр якын кебек иде, гүя тау башында торган килеш кул сузсаң, аның салкынын тоеп чирканырлык иде кебек. Рәйхан кинәт бу зур җәлпәк айга таба кулын сузды.

— Кара, кара, Мулланур! Ай ничек якын. Кул белән тотарга була.

Айның мондый зур булып калыкканын Рәйханның әле күргәне юк иде бугай. Ул бу могҗизага хәйран калып, карап торды, айдагы барлык сурәтләр зурайганнар иде. Аның тыны кысылгандай булды.

Шунда Мулланур киң сулыш алып җырлап җибәрде:

Ай югары, ай югары,
Айга менәсем килә...

— Әйдә, Мулланур, айга туры карап тын алмый торыйк, кем озаграк тора алыр икән?—ди Рәйхан.

— Һәй, ай нәрсә ул? Менә син кояшка карап кара. Мин кояшка да озак-озак карап тора алам, — ди Мулланур.

— Булмас ла, кояшка карасаң, күзең сукыраер, карама, юләр, ник аңа карыйсың?

— Кояшта таплар бар, беләсеңме?

— Булмаганны! — ди Рәйхан беркатлы ышану белән, Мулланурның тел төбен аңламыйча.

— Кояшта да айдагы кебек таплар бар.

— Булмаганны!

Мулланур ай яктысында Рәйханның янып торган күзләренә туры карый.

— Керфекләреңне нәрсә белән бөгәсең син?

— Юләр, керфекне бөгәләрмени? Алар тумыштан шундый.

— Сөрмә тарткансың син, каләм беләнме, корым сөрттеңме?

— Сөрмә?! — Рәйхан кулъяулык алып төкерек белән юешләп, күзләрен ышкый һәм Мулланурга суза:

— Менә кара, берәр нәрсә буялганмы?!

— Йә инде, йә, мин сине сөрмә тартып йөрисең дип уйлаган идем... Җырлыйммы бер җыр?

— Җырла соң, җырлыйсың килгәч...
Кулымдагы йөзегемнең
Исемкәйләре Рәйхан.
Синең матурлыкларыңа
Бөтен табигать хәйран.

— Үзең чыгардыңмы?

Рәйханның күзләре моңсуланып ала.

— Нигә синең күзләрең бер караганда бик моңсу, бер караганда бик усал, үтәли тишә, очкынлы, очлы?

— Белмим.

Егет кыздан күзләрен алмый, ул гашыйк, ул сөя. Ул тагын кызны кочып үбеп ала.

— Нәрсә сөрттең син ирененә?

— Гөлсирин.

— Нигә?

— Син үбеп туймасын дип, — ди дә Рәйхан, кыр кәҗәсе кебек сикерә-сикерә йөгереп китә.

Мулланур аның артыннан омтыла, тотып ала һәм тагын суырып үбә.

— Йә, юләрләнмә, син нәрсә? — дип Рәйхан үпкәләгән була.

— Яратам мин сине, Рәйхан, үлеп яратам, гомерем буе яратачакмын.

— Булмас ла!—ди Рәйхан һәм чая тавыш белән көлеп җибәрә.

Аның көлгән тавышы урамнар буйлап үтеп, тәрәзәләргә барып кагыла...

***

Июнь аеның матур бер иртәсе. Сабан туе. Ап-ак күлмәк, кара чалбар кигән Мулланур Рәйханны капка төбендә озак кына көтте. Алар сабан туе буласы мәйданга беренчеләрдән булып барырга сүз куешканнар иде, икәү генә барырга, иртәрәк барырга.

Рәйхан өрфиядәй юка, үтә күренмәле зәңгәр ефәк күлмәген, биек үкчәле күксел туфлиен киеп, көзге алдында бөтерелеп алды да, үз-үзеннән канәгать булып, тау кәҗәседәй керт-керт атлап капка төбенә чыкты. Мулланурның әле Рәйханның бу күлмәген беренче күрүе. Йа Хода!

Нинди нәфислек, зифа буй. Кызны үз куенында бер ел буе иркәләсә дә, аның бу кадәрле дә чибәр, гүзәл икәнен белмәгән икән, ләбаса.

— Сиңа зәңгәр күлмәк бигрәк килешә икән, зәңгәр күк йөзе төсле булгансың, күзләрең дә үзгәргән, зәп-зәңгәр, күлмәгең төсле, — диде егет, соклануын яшерә алмыйча.

— Юкны сөйләмә, Мулланур, күз үзгәрә димени? — ди беркатлы кыз.

— Синме соң бу, Рәйханыммы?—дип читкәрәк тайпылгандай итеп, бер адым артка атлады да, кинәт кызның нәзек биленнән кочып, күтәреп алды һәм әйләндерә башлады.

— Нишлисең, юләр? Кеше күрер бит, кеше ни әйтер? — дип чәбәләнде кыз.

— Әллә ниләр әйтсеннәр, Мулланур шашкан, юләрләнгән, дисеннәр. Көнләшсеннәр, үртәлсеннәр. Миңа барыбер. Мин бик яратам. Ярата икән, дисеннәр, шашып ярата, дисеннәр.

Сабан туе була торган мәйданга барып җиткәндә урман, су буйлары аты туарылып бәйләнгән арбалар, аллы-гөлле бизәкле чуар киемле хатын-кызлар, ирләр белән тулы иде инде. Әле сабан туе башланмаган.

Биек колгаларга эленгән эре-эре бизәкле шәльяулыклар, чүпләм сөлгеләр, озын-озын тукымалар җилдә җилферди. Урман кырыенда, агач күләгәсендә чабышка барасы атлар койрыкларын әрле-бирле болгап, бертуктаусыз кигәвен куа.

Гармун тавышы, халык гөрелтесе белән ялан шыплап тулган кырмыска оясын хәтерләтә.

Менә бәйрәмнең башлануын белдереп, сабан туен алып баручы халыкка мөрәҗәгать итә, нидер сөйләп бераз халыкны тынычландыра һәм аннан халык шаулатып кул чаба. Бәйрәм тантанасы башлана.

Бер урында җирдән аз гына калку ыбыр-чыбыр бала-чаганы көрәштерәләр, түгәрәк мәйданның икенче башында йомырка салынган кашык кабып йөгерә башлыйлар, чүлмәк ваталар. Халык гөж килә, кул чаба, көлә.

Сабыйлар, үсмерләр бил алышып, бүләкләргә куаныша. Ниһаять, аларны юан беләкле таза егетләр алыштыра.

Мулланур белән Рәйхан җитәкләшеп мәйдан читендә әрле-бирле йөриләр, кемнәр беләндер күрешәләр, сөйләшәләр.

— Мулланур, сабый чакларны искә төшереп, әллә бер көрәшеп чыгабызмы? — ди күрше Шамил.

Шулчак кинәт кенә егетнең сөйгәне алдында гайрәтен күрсәтәсе килү хисе уяна:

— Телисеңме, мин дә көрәшкә керәм.

— Әйдә, әйдә, күрсәт кем икәнеңне, — ди чая кыз, — күтәреп ал, җиргә сал авыл батырларын.

Мулланур кыздан бу сүзне көтмәгән иде. «Кирәкми, ватылма!» — дияр кебек иде. Юк, алай димәде Рәйхан, «күрсәт кем икәнеңне», диде, үзе хәйләкәр генә елмайды. Кызның сүзләреннән Мулланур бер буынга үсеп киткәндәй тойды үзен: сөйгәне аңа ышана, аның көч-куәтен тоемлый, горурлана.

***

Мулланур сабый чакларында, унбиш-уналты яшьләрендә яшьтәшләре арасында көрәштә беренчелекне беркемгә дә бирми иде. Әмма берничә ел элек көрәшүдән туктады. Әтисе Гали ага улының Сабантуйларда көрәшергә теләвен өнәмәде.

Гали төптән юан чыккан, тыгыз тәнле улы Мулланурны бик яшьли такта ярырга өйрәтте. Ике сыртын тигезләп юнгач, бүрәнәләрне ике метр биеклектәге станок өстенә күтәргәндә, улы атасына юан башын тоттырмый, үзе башлапябыша. Беләкләре нык, күкрәкләре киң аның. Мулланур станның өстендә, ә әтисе аста. Буй пычкының аркылы тоткасына кулы тию белән егеткә дәрт керә. Әйе, көчле, гайрәтле егет булып үсеп җитте Мулланур.

...Беркөнне Мулланур белән Нурәхмәт абыйсы шаярып кына бил алыша, көрәшә башладылар. Гали ага горурланып улларына читтән озак кына карап торды. Менә Мулланур Нурәхмәтне җиңел генә күтәреп җиргә орды. Читтән карап торган ата алар янына килеп басты.

— Кая, үзем, үзем салыйм әле сыртына шул бożырны, борынын бик чөймәсен, кикриген төшерим әле, — дип Нурәхмәткә күз кысты.

Гали авылның күптәнге данлыклы көрәшчесе иде. Биле каты, беләкләре нык булды. Аны Сабантуйларда җиңүчеләр табылмады. Уллары үсә төшкәч, ул үз һөнәренә аларны өйрәтте, көрәшнең күп кенә серләренә төшендерә килде:

сөлгене ничек тотсаң уңайлырак, көндәшеңнең билен ничек кинәт кенә үзеңә тартырга һ.б.

Менә ата белән кече ул бил алыша башладылар. Озак тартышырга туры килмәде. Мулланур атасын җирдән йолкып кына алды да күкрәгенә күтәрде һәм, бөтереп, җай гына җиргә салды.

Ата җирдә озак ятмады, яшьләрчә җитез генә сикереп торды да кулындагы сөлгесен җиргә ыргытып:

— Булдырдың, улым, — диде. — Көч күрсәтү яхшы эш, әмма аның илдә бәһасе бик түбән. Син көчеңне-куәтеңне файдалырак эшкә сарыф итәргә тырыш, чүпрәк-чапрак бәрабәренә түгел, — диде.

***

Мулланурның бу яшенә җитеп беркем алдында да сер биргәне булмады. Бүген, сабан туе көнне, сөйгән кызы алдында булдыксыз, көчсез, гайрәтсез булып күренсенме?

Ул озак уйлап тормады, башын түбән иеп, эре-эре адымнар белән мәйдан уртасына бил алышырга кереп китте.

Көрәш кызды. Кемдер батыр калды, кемнәрдер сырты белән төште. Мулланур исә көрәштә җиңеп беренче урынны алмаса да, кочак-кочак бүләкләр алып, Рәйхан янына килеп туктады һәм кызның зәңгәр ефәк күлмәге өстеннән аның җилкәсенә эре-эре чәчәкләр төшерелгән озын чуклы, чия төсле зур шәльяулык салды.

— Бу безнең мәхәббәтнең бер еллык юбилеена миннән бүләк булсын, — дип пышылдады.

Ул арада мәйдан тышында кемдер:

— Атлар килә! — дип сөрән салды. Халык атлар килгән якка ашыкты.

***

Мәхәббәт хисеннән яшь кыз үзен күкләргә ашкандай хис итте. Гүя ул җирдә яшәми, кулларын кош канатлары кебек җәя дә, җирдән аерылып китеп, һава дулкыннары иркендә кала, оча, күтәрелә, бер түбәнәя, бер югары омтыла. Аның Мулланурга булган кайнар хисләре болытларның картлылыгын җиңәрдәй көч белән бәргәләнә.

Аның мәхәббәте айлы төндә йолдызлар балкуы кебек,

гүзәл чишмә чыңы, иртәнге чык тамчылары кебек саф. Бүген аңардан, нәрсә ул мәхәббәт? — дип сорасалар, ул җавап таба алмас иде.

Мәхәббәт бу яшь кызның тынгысыз җанының изге бер илаһи халәте. Мәхәббәтне, усал, диләр, аяусыз, диләр, мәрхәмәтсез, диләр. Дөрестер дә.

Рәйхан Мулланурга башын югалтыр дәрәҗәдә гашыйк булды. Ул, егет белән бергә тирән чоңгылга чум, дисәләр, чумарга күккә аш та, югарыдан түбәнгә ташлан, дисәләр, ташланырга әзер иде. Ул Мулланурның ярсу йөрәкле булуын да, теленең әче икәнен дә, кулларының катылыгын да белмәде, сизмәде. Мулланур янында булганда аңа гүя бәхет канатлары чыга, ул үз-үзен белештермәс дәрәҗәдә үзгәрә, үсә, көлә. Кызга чын мәхәббәт килде, өермә булып бөтереп, яшен булып көйдереп килде. Ул хәзер генә мәхәббәтнең тылсымлы нәрсә икәнен аңлады.

Җәйнең иң кыска төннәре, иң озын көннәре. Кыска төннәрне ямьләп, авыл җыр-моңга күмелеп яши. Кыска төн сизелмичә үтә дә китә, яңа көн башлануын хәбәр итеп, беренче әтәчләр аваз сала. Күрешеп, сөйләшеп туймас көннәр шулай үтә дә үтә. Мулланур белән Рәйхан еш очрашмыйлар, әмма очрашу-сөйләшүләр — гомергә истә калырлык матур мизгелләр.

Эштән бушый алмаган җир баласы өчен сөю-сөелү — зур бәхет. Мулланур сөя. Ул шашып сөя, Рәйханны сөя. Барлык егетләрдән көнләшә-көнләшә сөя. Ул көнчел күңелне ни эшләтергә? Ничек тыярга? Көнләшү хисе чыгырыннан чыгар дәрәҗәдә борчый Мулланурны. Аның сөйгәне кем беләндер кайдадыр сөйләшеп торадыр кебек, аңа кемдер елмая, күңелен яулый, үбә, коча кебек тоела. Ул бит көн-төн эштә чит-ят авылда.

***

Мулланур көнозын кырда булып, бик арып, кыр станында кичке аш ашап утыра иде. Шулчак шушы авылда тракторчы булып эшләүче авылдашы, җирән чәчле Самат кыр станы янына килеп, тракторын туктатты, кабинасыннан сикереп төште дә, эре тешләрен күрсәтеп, киң елмаеп Мулланурга дәште:

— Мулланур, сөенче әйтәм, тыңлыйсыңмы? Бер кикерәм, җырлыйсыңмы? Рәйханыңны бер егет белән күргәннәр, син монда тузанга гарык булып йөр әйдә, ә ул анда...

— Кем әйтте? Алдашма!

— Кем, кем... Сүз иясе белән йөрми, очлы күзләр күргәннәр.

Мулланур авызына алган кайнар бәрәңгесен аннан-моннан чәйнәп, көч-хәл белән йотып җибәрде дә, калай җамаягын этеп куеп, өстәл яныннан кузгалды...

Җәйнең төне — бары бер тотам. Инде кояш баеп бара, шәфәкъ сүнә. Мулланурның күңелен кинәт яшен кебек бер уй чәнчеп алды. Кайтырга! Авылга кайтып килергә! Йөгерергә!

Озак уйланып торырга вакыт юк, Мулланур авылга чапты. Караңгы да төште, ул юлда очраган чокыр-чакырда йөзтүбән каплангалап та төште, сикереп торып, тагын чапты, тагын капланды, тагын йөгерде, алга ыргылды. Аның башында бары бер уй, бер борчу: Рәйхан кем белән? Кем кочагында?

Авылга якынлашканда ул тәмам хәлдән тайган иде инде, кара тиргә батып, авылга килеп керде. Адымын бераз әкренәйтеп олы урамны үтте, тыкрык аша чыгып, бераз суына төшеп, Рәйхан яшәгән өйгә якынлашты. Җылы көннәрдә Рәйхан дус кызлары белән келәттә йоклый, анда җиләс, тыныч. Мулланур сак кына капкага кагылды, капка эчтән бикле иде. Ул капка астындагы тактаны алып куйды да җиргә ятып, капка такталарына сыдырыла-сыдырыла эчкә, ишегалдына үрмәләде, шылт иткән тавыш та чыгармый гына, мәче кебек йомшак басып кына келәт ишегенә якынлашты. Келәт ишеге бераз ачык, ул колак салып келәт эчен тыңлады, анда йоклаучыларның мышнаган тавышы гына ишетелде.

Ишекне ача төшеп эчкә үтте. Дөм караңгы, стенадагы кечкенә тәрәзәдән генә бераз яктылык сирпелә.

— Рәйхан! Рәйхан! — дип пышылдады егет. Рәйхан уянмады.

— Ә! Нәрсә! Кем бар? — карлыккан ирләр тавышы ишетелде.

— Ә син кем? — дип кычкырып җибәрде Мулланур, тирән тынлыкны бозып.

Бу тавышка берничә кыз уянып, чыр-чу килештеләр.

— Кем син? — дим мин сиңа, кем син?

Мулланур тавыш килгән якка омтылды һәм түрдәге агач караватта ятучының өстендәге җәймәсен йолкып алды.

— Кем син? Ник син кызлар янында?

Рәйхан, Мулланурның тавышын танып, хәлне ачыкларга ашыкты.

— Мулланур! Кычкырма! Ярсыма! Ул бит Марат, минем энем, кунакка килгән.

Көнчел кеше арысланнан яман, диләр бит. Бу минутта Мулланур бу «кунак»ны өзгәләп ташларга әзер иде, тик Рәйханның йомшак тавышы аны бераз тынычландырды. Ул куллары белән йөзен каплап бераз гына исен җыеп утырды да:

— Йә, ярый, ач миңа капканы, чыгар мине, — диде Рәйханга тупас кына.

Мулланур үзен-үзе белештерми, каплана-түнә ничек чабып кайткан булса, шулай каударланып җил-җил китеп тә барды. Рәйхан исә капка төбендә басып калды. Таң сызылып, яктыра башлаган иде инде.

***

Рәйхан берничә көн кичке уенга чыга алмады. Балалар бакчасында эш күп, ул икешәр смена эшләде. Кичләрен план төзеде, дәресләргә әзерләнде.

Бу хәлгә аптырап, дус кызы Сания Рәйхан янына килде.

— Ни булды? Ник уенда күренмисең?

— Эш күп әле. Вакыт юк, — диде Рәйхан кәефсез генә.

— Эш күп! — дип кычкырды Сания. — Эш качмас! Ә Мулланурыңны югалтуың бар.

— Мулланурга нәрсә булган? Әллә авырыймы?

— Авырый, авырый. Башкалар белән авырый башлаган.

— Тукта, тукта. Аңлаешлы итеп сөйлә әле.

— Аңлыйсы килгән кешегә бик аңлаешлы. Кичә үз күзләрем белән күрдем, Мулланур Мөнирәне озата китте.

— Булмас. Ышанмыйм. Юкны сөйләмә.

— Ышанмасаң, кич чык. Үз күзләрең белән күрерсең.

Бу сүзләрдән Рәйханның күңеленә салкын шом үрмәләде.

Ул Саниянең сүзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмәде, икеләнде. Шулай да, үз күзләре белән күрергә теләп, кич клубка ашыкты. Урам буйлап барганда тирә-ягына карамаска тырышты. Бәхетенә, аңа каршы беркем дә очрамады. Кибет яныннан узды, анда да кеше күренмәде. Клубка якынлашканда гына тынычлана башлаган йөрәге яңадан ярсып тибә башлады.

Аңа барлык тәрәзәләрдән кешеләр карап тора кебек, барысы да, Мулланурыңны югалттың, дип көлә, шаркылдый кебек тоелды. Ни булса — шул, тизрәк барып җитәргә, Мулланурны күреп сөйләшергә, барысын ачыкларга һәм бу борчулардан котылырга кирәк иде аңа.

Ул клуб эченә килеп керде, бөтен кеше аңа борылып карады. Аңа гына шулай тоелдымы, әллә чыннан да шулай булдымы, ул югалып калды. Клубның аргы башында Мулланур егетләр белән нәрсәдәндер шаркылдап көлә иде. Рәйхан аны күрде. Әнә кара костюмының якасы өстеннән ак күлмәк якасын чыгарып салган. Чәчен шома итеп артка тарап куйган. Ике кулын чалбар кесәсенә тыгып, башын артка ташлап, нидәндер эче катып көлә. Ул көлә, ә Рәйхан яна. Дөресме? Дөресме?

Менә Мулланур көлүдән туктап, Рәйханга таба караш ташлап алды, Рәйханны күрде, ләкин карашын туктатмады, күрмәмешкә салышты, тиз генә егетләргә борылып, көлүен дәвам итте. Дөрес икән! Дөрес икән! Ул бүгенге көннән аныкы түгел, башканыкы. Мөнирәнекеме, башка берәүнекеме — ул бүгеннән аңа ят, башка иде.

Рәйхан Сания белән Дәимә янына килде, аларның артына чыгып, Мулланурны күзәтте. Ул аны таныды да, танымады да. Ул Рәйханга дорфарак, тупасрак һәм ярсурак булып күренде. Аның сөйгәнеме соң бу?! Әллә бөтенләй чит кешеме? Ул чак кына елап җибәрмәде.

— Мин кайтып китәм, кызлар, — диде Рәйхан.

— Иртә бит әле, кая ашыгасың? — диде Дәимә.

— Син нәрсә, минем сүзләремә ышанмыйсыңмыни? Үз күзләрең белән күрерсең, бераз гына тор инде, — диде Сания.

Түгәрәк уен башланды. Кызлар, егетләр түгәрәккә басып җыр җырладылар. Рәйхан ул җырларны ишетмәде дә, кушылып җырламады да. Аның күңелен фәкать бер гамь биләгән иде. Дөресме? Дөресме?

Түгәрәктә әйләнгәндә, ул Мулланурга карамаска тырышты, күзләрен идән такталарына төбәп, ниндидер эчке бер салкын битарафлык белән атлады да атлады. Бүген ул үзен бөтен дөньядан читләшкән, канаты сынган ялгыз чәүкә итеп тойды.

Аны кемдер уртага чакырды... елмайды... алар әйләнделәр...

Ул уртага чыгу белән кемдер җыр башлады. Ул җырны барысы да белә, дәррәү күтәреп алдылар:

Әнә килә автомобиль,
Алмалар төягәннәр.
Бигрәк матур үстергәннәр,
Күз тияр, димәгәннәр.

Ул үз нәүбәтендә уртага тагын кемнедер чакырды. Бераздан, уен-көлке иң югары ноктасына җитеп, клуб эче гөр килеп торганда, Мөнирә утырган җиреннән әкрен генә кузгалды да, ишеккә таба юнәлде. Сания Рәйханның кабыргасына төртте:

— Кара, кара! Мөнирә кузгалды, озакламый Мулланурың да аның артыннан шылачак, — диде.

Чыннан да, берничә минут үттеме-юкмы, Мулланур егетләр арасыннан аерылып, башын аска иеп, тирә-ягындагыларны этә-төртә, алпан-тилпән ишеккә таба атлады.

Рәйхан борылып Мулланурга таба карамады, горур кыз эчтән янды, эчтән көйде. Әнисе гел әйтә иде: авызыңда кара кан булса да, кеше алдында төкермә.

***

Рәйхан өчен иң авыр көннәр башланды. Ул яшәдеме, юкмы, җирдәме, әллә һавага ашып, болытлар арасында адашып йөрдеме, сорасаң да, ул әйтә алмас иде. Ул үзен юкка чыккан, тормыштан ваз кичкән кешедәй хис итте. Нигә яшәргә? Рәйханның башына әллә нинди чуалчык, коточкыч уйлар килде.

Һәркөн иртән ул җан өшетерлек уйлар белән, кеше күзенә чалынмас өчен кычытканлы тыкрыклар аша елый-елый эшкә килә...

— Ни булды, Рәйхан? Тагын еладыңмы? — дип каршы алды аны бакча мөдире Әнисә апа.

Рәйхан күзләрен яшерде. Әнисә апа сизгер, күрде, аңлады.

— Әйдә әле, кызым, чыгыйк әле, сөйләшик.

Алар балалар бакчасының буяулы тәбәнәк эскәмияләренең берсенә утырдылар.

— Сөйлә, яшермә, кызым, эчеңне бушат, ни булды тагын? Шул Мулланур өчен яшь түгәсеңме?

— Әй, Әнисә апа! — диде Рәйхан. Башка бер сүз дә әйтә алмады.

— Шул шалапай өченме, балакаем? Әле син бик яшь, бөтен тормышың алда, ул зур тормыш океанын йөзеп чыгар өчен көч тә, түземлек, сабырлык та бик кирәк. Сабырлык — кешенең алтын сыйфаты. Дус бар, дошман бар. Яшьләреңне кешеләргә күрсәтмә, әллә ниләр сөйли башларлар. Башыңны югары тот.

Рәйхан, башын түбән иеп, Әнисә апасының сүзләрен тыңлап утырды. Күзләрендә яшь кипте, йөрәге тынычлангандай булды.

— Егет башка белән йөри башлаган дип, күз яшьләре түгә калсаң... Егетләр ил өстендә илле була, сөйгәне, гомерлеге бер генә. Гомерлеге әле очрамый калмас.

Рәйхан бу минутларда ачы күз яшьләренең әле юкка гына түгелгәнен белә алмады, әле ишетәсе сүзләр, җанны телгәләрлек гайбәтләр ишетү көннәре алда икәнен башына да китермәде.

Кеше язмышының тоташ сынаулардан торганын яшь кыз каян белсен соң?

Шулай да, эченә бикләнеп, үзенең бәләкәй генә дөньясы белән, Мулланурны онытырга тырышып яшәгәндә, Рәйхан күптән түгел генә солдат хезмәтенә киткән Фәгыйль исемле егеттән хат алды. Ул кызга җылы хат язган иде.

«Миннән хат көтмәгәнсеңдер, Рәйхан. Менә минем кем икәнемне бел. Мин ничәмә-ничә айлар синең янда гына тавыш-тынсыз басып торырга, синең сулавыңны гына ишетергә теләп, матур күзләреңә бер генә карап алсам да, җан рәхәте тоеп, куанып яшәргә дучар булган Фәгыйль.»

Хат озын иде. Рәйхан хатны укып чыкты, Фәгыйльне күз алдына китерергә тырышты. Әйе, ул да барлык авыл егетләре кебек ак күлмәкле, оялчан гына чандыр егет. Ул,

чыннан да, Рәйханны бик еш парлы биюгә чакыра, янында гына басып тора иде. Күптән булган бу кичләрне исенә төшереп, Рәйханның йөрәге бертөрле әрнү белән сулкылдап алды. Фәгыйльне ул күрми иде, аның күзләре, күңеле гел Мулланурда гына. Ул фәкать аны гына өзелеп ярата.

Фәгыйльнең бу хаты Рәйханга зур шатлык китермәде, шулай да ул аңа якты уйлар, фикерләр тулы хат юллады. Солдат авылын, өен сагына торгандыр, чит җирдә кош теле хәтле генә хәбәр дә аны канатландырып җибәрер, авыр хезмәтен җиңеләйтер, дип уйлады...

***

Әнисә апасы белән сөйләшеп бераз тынычланып, үз халәтенә ияләшеп килгәндә, беркөнне Рәйхан Мулланурны очратты. Уйламаганда-көтмәгәндә, урамнан алар бер-берсенә каршы атладылар. Мулланур Рәйханның җитез, җыйнак гәүдәсен әллә каян күреп алды һәм адымын кызулатты. Ә Рәйхан аны күрү белән коелып төште, берәр капкага кереп качар өчен тирә-ягына каранды. Тик качар капка тапмый, чарасыз, адымнарын акрынайтып, башын түбән иеп, атлады да атлады.

Ул Мулланурны күрмәмешкә салышып үтеп китәргә теләде. Мулланур әрсезләнеп, берни булмагандай, киң елмаеп, ашыгып, Рәйханның каршысына килеп туктады һәм беләкләреннән тотып алды.

— Рәйхан! — диде ул үзенә генә хас калын карлыккан тавыш белән. — Авылда әллә нинди гайбәтләр йөри, син шуларга ышанасың икән, имеш, мин...

— Җитте, Мулланур, дәвам итмәсәң дә була. Син... Син икейөзле, хыянәтче бәндә.

— Тукта, тукта! Ни дидең? Нинди хыянәт? Кемгә хыянәт? Син бит үзең миңа хыянәт иттең. Син Фәгыйль белән мәхәббәт хатлары алышасың, аңа сөям, бәгърем, дип хатлар язасың.

— Җибәр, Мулланур, минем сине күрәсем дә, синең белән сөйләшәсем дә килми.

— Килмәс шул, берсе белән хат алышасың, икенчесе белән үбешәсең.

— Нахал! Бу сүзләрнең дөрес түгеллеген үзең дә беләсең, шулай да оятсыз рәвештә мине үртисең.

— Үртәмим, Рәйхан, яратам бит мин сине, башкалар белән бергә күрәсем килми.

— Ялганлама. Мөнирәне озатуың, аның белән йөрүеңне нәрсә диярсең?

— Мөнирә ул — болай гына. Син чыкмаган көннәрдә култыкларга кеше булсын, дип кенә.

— Ялган, ялган! Мин сине бу кадәр ялганчы дип белми идем.

Рәйхан егетнең кулыннан ычкынып йөгереп үк китеп барды. Онытырга, онытырга, уйламаска, исемен дә башка телгә алмаска!

***

Аларның көпә-көндез урамда сөйләшеп торуларын күреп, тәрәзәдән күзәтеп торучылар һәм Мөнирәгә җиткерүчеләр дә табылды. Мөнирә исә, көнләшү һәм ачу катыш, үзенең ни әйткәнен белештерми:

— Мулланур әллә кайчан аның төбен төшергән инде. Мулланур минеке, ул мине генә ярата, — диде.

Бу сүз бөтен авылга таралды, зурайды, үсте һәм, ниһаять, Рәйханга да килеп җитте.

— Ник син аны судка бирмисең, Рәйхан? — диде дус кызы Сания. —Аларның икесен дә җавапка тартырга кирәк. Минме? Мин болай гына калдырмас идем. Син нәрсә?

— Судлашып йөрү — түбәнлек. Минем саф икәнемне судлашмыйча да үзем сайлап барган ирем белер әле.

Сания тынып уйга калды. Чыннан да, шулай бит.

***

— Чыгып кит, теләсә кайда яшә, ана эт! — дип каршы алды эштән кайтып кергән Рәйханны олы апасы. — Әнә әйберләрең, теләсә кая олак. Үз өемдә сөйрәлчек асрый алмыйм. Ояты гына нинди бит! Чыгып кит! Чыгып кит!

Рәйхан дәшмәде, бөреште, куырылды, аклану, аңлашу — аның өчен түбәнлек. Ә ничек итеп аңлатасың? Кыз баланың мондый хәлдә күрсәтер өчен уен тузы бармыни? Ул җирәнгеч гайбәтләрнең кызганыч корбаны гына була ала. Бер юл — тизрәк тормышка чыгып, пычракны юу кала.

Рәйханның кирәк-ярагы, киемнәре бер чемоданнан

артмады. Ул дусты Саниялəр күршесе, ялгыз хатын Әсмабикəгə күчте. Ләкин олы апасының «сөйрəлчек» дигəн сүзе аның колагыннан озак китмəде. Апасы булып апасы аны аңларга, авыр хəлен җиңелəйтергə телəмəде.

Бакча мөдире Әнисə апа Рəйханның хəлен аңлап, аның күкрəгенə каткан төерне эретерлек йомшак тавыш белəн сүз башлый:

— Йə, кызым, бүген тагын елагансың бугай, сөрмəлəрең юылып төшкəн, — дип шаярта.

Рəйхан аның сүзлəреннəн тагын йомшап китə, агып төшмəгəн бер тамчы яше күз төбендə мөлдерəп кала.

— Әйдə, чыгыйк əле, сөйлəшик, минем сиңа бирəсе бик җитди соравым бар.

Алар тагын аулакка чыгып утырдылар.

— Дөресме шул сүзлəр? — ди Әнисə апа катгый тавыш белəн, Рəйханның күзлəренə туры карап.

— Дөрес түгел, дөрес түгел, Әнисə апа, валлаһи.

— Ант итмə, бала, Алла исемен юкка-барга искə алырга ярамый. Менə нəрсə, кызым, син телəк телə. Кыз чагында телəгəн телəк кабул була. Тулган ай яктысында, айга туры карап, чын күңелеңнəн, нинди телəгең бар — шуны телə.

Рəйхан бу сөйлəшүдəн соң бик җитди уйланды. Нинди телəклəр телəргə? Телəк — тели белсəң — телəк, тели белмəсəң — имгəк, дилəр түгелме соң? Мулланур капланып үлсен, күзлəре чəчрəп чыксын, аяк-кулы тартышсын, дипме? Юк, юк. Мең кат юк! Рəйханның Мулланурга карата гомерендə дə андый телəк телисе юк. Ходай кушмаганны. Бу бит телəк түгел, каргыш була. Каргау яшь кызлар эше түгел, каргау ул карчык-корчык эше. Ул Мулланурны хыянəтче дип атаса да, нинди генə сүзлəр белəн хурларга телəсə дə, аңа яман телəк телəргə күңеле, йөрəге кушмады. Ул шуны белə: мəхəббəткə хыянəт иткəн кеше бервакытта да бəхетле була алмый.

Иң яхшысы — ул үзе өчен телəк телəргə булды. Ул төне буе тəрəзəгə карап уйланып ятты. Тулган ай нəкъ тəрəзə турысында үтə күренмəле сихри шар булып эленеп тора, үзе əкрен генə селкенгəндəй итə. Шул айга туры карап, Рəйхан күз алмаларын яшьлəндерде дə Әнисə апасының əйткəн сүзлəрен исенə төшерде. Телəк телə... Кыз вакытта

теләгән теләк кабул була ул, диде бит аның шәфкатьле Әнисә апасы. Ул өстеннән юрганын алып атты, тәрәзә буена килеп басты да, ияген алга суза төшеп, теләк тели башлады:

— И, Ходаем! Ишетәсеңме минем ялваруларымны...

Аның теләкләре бик гади иде: тизрәк кияүгә чыксын, сайлаганы Мулланурдан чибәррәк булсын, чибәр булса, Рәйхан яратыр. Тик тизрәк аның гөнаһсызлыгын, «сөйрәлчек» түгел икәнен ачыкласын, пычрак гайбәтләр юкка чыксын...

***

Менә шундый, башын кая куярга, ни уйларга белми, иләсмиләс йөргән көннәрендә клубта таныш түгел бер чибәр егет аның янына килеп сүз катты:

— Исәнмесез, Рәйхан!

Кем ул? Каян белә ул минем исемемне, дип уйлап алды кыз. Гадәте буенча, елмаеп, ачык йөз белән аның сәламен алды, сорауларына җавап бирде, әкрен-әкрен аның кем булуын ачыклады.

Ул шушы авыл егете икән. Шәһәрдә кибет директоры. Киеме шәп, өстендә куе зәңгәр бостон костюм, галстук. Сөйләгән сүзе дә болай уңайлы, еш кына урыс сүзләре кыстырып, туры карамый гына, бераз үзенең өстенлегенә басым ясагандай, вәкарь белән генә сөйләшә.

— Минем исемем — Габделхак. Дус егетләр Гена диләр, — диде ул елмаеп.

Аның Рәйханга ошарга, акыллы булып күренергә тырышуы читтән күзәтеп торган кешегә акка тамган кара тап кебек күзгә ташлана иде.

***

Габделхак бу очрашуга озак әзерләнде. Туганнан туган энесе Рамил белән сөйләшүдән соң, ул кискен карарга килде: Рәйханны очратырга, сөйләшергә, озакка сузмый тәкъдим ясарга, өйләнергә.

— Син, абый, кызларны бик күп сайладың, җитәр, тот та шуңа өйлән. Яхшы кыз, чибәр, акыллы, — диде Рамил.

— Син бит аның белән үзең йөргән идең. Үзең ник өйләнмисең?

— Мин аңа өйләнә алмыйм, абый. Үзең беләсең, минем бик җитди сәбәбем бар, мин авыру. Ул синең белән бәхетле булыр. Рәйхан бәхетле булырга лаеклы кыз...

***

Җанын кая куярга белми йөргән Рәйханга бу сөйләшү эссе чүлдә суга тилмереп иреннәре кипкән юлчыга хәл кертүче бер йотым су кебек булды. Аның күңеле күтәрелде, яшәргә өмете тернәкләнде. Әгәр тәкъдим ясаса, тотам да риза булам, дип уйлады кыз. Күп тә үтмәде, Габделхак аңа, чыннан да, тәкъдим ясады.

— Чык миңа, Рәйхан, фатирым бар, эшем яхшы, кимхур итмәм, курчак кебек итеп киендерермен,—диде.

***

Бөтен авыл халкын хәйран калдырып, Рәйхан, уйламаганда-көтмәгәндә, шаукымлы, иләс-миләс дигән даны чыккан Фаягөл малае Габделхакка кияүгә чыкты.

Дусты Саниягә ул ачынып:

— «Саф» кызлар утырып калсын, мин чыгыйм әле. Чәйнәр сагызлары бетәр, тынарлар, — диде.

Әсма апаның капка төбенә җиңел машина килеп туктады. Әсма апа бу машинаның нигә килеп туктавын аңлады.

— Килделәр бит, Рәйхан, самавыр куеп җибәр, — диде каушый төшеп.

Рәйхан ашыга-ашыга самавырны мич каршысына утыртып күмер салды, чыра яндырып самавыр торбасы эченә ташлады, кәкре торбаның башын тишеккә тыкты. Үзе:

—Их, Әсма апа, әллә идән астына төшеп качыйм микән? Яратмыйм бит мин аны, — дип өзгәләнде.

— Кызым, ризалык биргәч, алай итәргә ярамый бит инде.

Ул арада ике егет ияртеп Габделхак үзе килеп керде. Авылда иң чибәр кызны үзенә хатынлыкка алу куанычыннан үзен герой итеп сизеп, кулларын уа-уа:

— Менә мин сине алырга килдем, киен, киттек, — диде ашыктырып.

Рәйхан җиңел пәлтәсен чөйдән алып, тиз генә өстенә киде дә, берсүзсез ашыгып ишектән чыгып китте, аның артыннан егетләр иярде.

Сентябрь урталары иде. Коеп яңгыр яуды, күк күкрәде. Галәмдә ниндидер ялгышлык, бу соңга калган көзге яшен — күпләрне хафага салды. Көзге яшен — күз яше, диләр бит. Рәйхан моны белә, әмма белсә дә, әлләни әһәмият бирмәслек хәлдә иде.

Мич каршында сусыз куелган самавыр яшелле-зәңгәрле тавышлар чыгарып утырды да, сул якка кыйгаеп төште. Яшьләрне озатырга чыккан җиреннән Әсма ашыкмый гына өйгә атлады. Зәңгәрләнеп идәнгә төшкән самавырын күреп, артына ава язды:

— И, Ходаем, хараплар булды бит, хараплар булды бит,— дип өзгәләнде.

***

Хатын-кыз кочагын күп татыган бу шома кияү егетенең куены Рәйханны җылытмады. Беренче төн аның өчен авыр сагыш, пычрану, каралу, яшьлеге белән аерылу булып, күз яшьләренә сәбәп булды. Ул илереп-илереп елады.

— Нигә елыйсың, юләр. Елама, сөен. Миңа кияүгә чыгып, син тапланган исемеңне чистарттың. Мин синең турыдагы гайбәтләргә ышана язган идем, бәхетең, дөрес булмаган икән,—диде Габделхак.

Ләкин бу сүзләр Рәйханны куандырмады. Ул бу төннән соң үзен яфраклары саргаеп коелган, шәрә калган каенга тиңләде. Яфраклары булмагач, агачлар да кояшка куанмый, көзге җилләр аларны үтәли иләсли, ботакларын талкый, кайрыларын сыбызгы итеп сызгырта, борчый.

***

Рәйхан ашык-пошык Фаягөл малае Габделхакка кияүгә чыккач, Мулланур үзен сүнеп бара торган учакка охшатты. Пыскый, дөрләми, көле арта, суына.

Ул хәзер клубка чыкса да, уйнамый, көлми, бию-җырга катнашмый, бары бертуктаусыз тәмәке пыскыта. Парлыларга кызыгып карый, кызлар белән ваемсыз гына сөйләшә. Мөнирә инде аның өчен йолкып ташланган чәчәк, шиңеп, саргаеп бара. Мулланурны күрү белән елый башлый,

авырлы. Булган эш булган. Мулланур аның белән артык сөйләшми, берничек тә үткән эшне кайтарып булмый. Әллә күкрәк турысында, әллә йөрәк уртасында яра сыкрый. Рәйхан белән үткәргән матур көннәр үзәкне өзеп искә төшә. Аның үлеп Рәйханны күрәсе, сөйләшәсе килә. Ул анда ничек икән? Рәйхан Фаягөл малае Габделхакны ярата алды микән? Аның авылны, Мөниръне ташлап күз күрмәгән, колак ишетмәгән җирләргә китәсе килә. Читтә бит беркем беркемне белми, анда, ерак җирдә, өр-яңадан яши башларга, барысын онытырга мөмкин.

***

Ул, Рәйхан кияүгә чыгып берничә ай үткәч, түзмәде, Алмалыга юл алды. Йомышы да юк кебек иде. Бәлки аны очратыр, сөйләшер, күңелен тынычландырыр.

Алмалының үзәк урамнарыннан үтте, кибетләргә сугылды, аннан Габделхак яшәгән урамга чыкты. Таш йортлар күләгәсеннән, кардан чистартылган тротуардан бераз баргач, ул үзеннән берничә генә метр ераклыкта аңа таба атлаучы Рәйханны күреп алды. Кышкы пәлтәсенең якасын торгызган, башында мамык шәл, йөзе тартылган, күзләре эчкә баткан.

Мулланур ашкынып Рәйханга таба атлады, кочакларын җәеп, йөгереп барып кочаклап аласы килде, тик ул бу юләрлектән үзен тыеп калды. Ул хәзер ир хатыны, ярамый.

— Рәйхан! Саумы?

Рәйхан Мулланурны урамда очратырмын дип башына да китермәгән иде. Аның үз хәле хәл. Кайгысы эченә сыймас дәрәҗәдә зур.

Рәйхан комачтай кызарды, Мулланурның сәламенә җавап бирмәде.

— Рәйхан! Сау гынамы? Хәлләрең ничек?

— Синекеннән яхшырак, — диде Рәйхан сер бирергә теләмичә, җебеп төшүеннән куркып. — Син... Син бит озакламый эти булырга җыенасың икән. Шул дөресме?

— Юк сүз ул,— диде Мулланур, ваемсыз булырга тырышып, бик каты тамагын кырды, барыбер тавышы карлыгып, каркылдап чыкты,—ышанма син аңа...

Мулланур сүзсез калды, аннан исенә килеп:

— Син соң, Рәйхан, бәхетлеме?

Рәйхан дәшмәде. Бәхетлеме? Бәхет нәрсә соң ул? Бармы соң ул бәхет дигән кош? Әллә күктә, әллә кайда ай тирәли, кояш тирәли очып, кешеләрне ымсындырып, алдап йөриме? Кем генә бәхетле икән бу дөньяда?

Мулланур җавапны озак көтте, үзе Рәйханнан күзен алмады. Рәйханы, аның Рәйханы бүген үзеннән бәхетлеме, юкмы икәне турында баш вата, җавабы юк. Ул мондый катлаулы һәм тупас сорау биреп сөйгәнен борчуы өчен үз-үзен битәрли үк башлады.

Калтыранган куллары белән ашыга-ашыга кесәсеннән папирус чыгарды, шырпы сызды, учлары белән шырпы башындагы зәгыйфь утны җилдән саклап, авызындагы тәмәкесенә ут кабызды. Рәйханнан читкәрәк борыла төшеп, берничә мәртәбә тирән итеп эченә төтен суырып, озак итеп аны өрде дә:

— Кем өчен сакладым мин сине?!— диде, һәр сүзен аерым-аерым сыгып чыгарып.

Көн салкын, коры иде.

Рәйхан декабрь аеның салкын кояшының күкшел урман артына таба тәгәрәвен күзәтте. Аның зәңгәрсу пәлтәсенә кичке шәфәкъ нуры кызгылт-көрән төс биргән иде.

— Бәхетлеме, дисең син, Мулланур, кем өчен сакладым, дисең,—дип телгә килде, ниһаять, Рәйхан һәм дәртсез, хиссез генә үзенең тормышын сөйләп бирде.

Кибеткә эшкә урнашкан, бергә эшләүчеләр бик яхшы, сату итү, кешеләр белән аралашу Рәйханга ошый. Фатирлары зур, тәрәзәләре урамга карап тора, якты. Күршеләре киң күңелле. Ә башкача...

Ул ире Габделхак турында ләм-мим бер сүз дә әйтмәде. Декабрьнең өзек-өзек җиле җирдә яткан коры карны арыбире кугалый, Рәйханның битенә салкын кар бөртекләрен китереп сылый. Хатын бер кулы белән чәчләренә кунган кар бөртекләрен сыпырып куйды да:

— Я, Мулланур, күрештек, сөйләштек. Бүтән бу тирәдә йөрмә, яме,— диде дә китәргә кузгалды.

Ул урам буйлап тиз-тиз атлады. Артына борылып карамады. Ә Мулланур баскан җиреннән кымшанмады, гүя аны шушында кадаклап куйганнар иде. Сөйгәненең кечкенә

җиңел гәүдәсе күздән югалганчы аннан күзләрен алмады. Югалтты ул Рәйханны, югалтты, башка бервакытта да кире кайтарып алмаска югалтты.

Рәйхан исә әллә атлады, әллә йөгерде. Ул Мулланурның күз карашын тоеп, әллә сөенечтән, әллә тирән сагыштан күз яшьләренә төелә-төелә җил-җил атлады. Күз яшьләрен тыймады, аксыннар, аксыннар! Әле күпме күз яшьләре агызасы барын ул башына да китермәде.

Ул Мулланурны яратудан туктамады. Йөрәккә әмер биреп буламыни? Ләкин ул аның белән сөйләшергә тиеш түгел иде. Нигә ул аның янына туктады? Ник үтеп китмәде? Мулланур аны кулыннан тотып туктатмады лабаса. Ник туктады? Ул бит ир хатыны. Эченә сыймаган бөтен серләрен, ирен яратмавын, ярата алмавын, хәтта күралмавын әйтеп сала язды. Ярый әле, Ходай сабырлык биреп, күп сөйләмәде. Ире турында бер-ике кәлимә сүз ычкындырса, күзләре мөлдерәмә яшь белән тулыр иде.

Ул ир белән яши, иркәләү, назлау күргәне юк. Кушылганнарына ике ай дигәндә, Габделхак аны бик нык җәберләде.

Солдат хезмәтеннән кайткан Фәгыйль, чыбык очы туган дип, кайтуын белдерү өчен Габделхак эшли торган кибеткә керде.

— Абый, саумы, мин кайттым, дип, ялтырап, сипкелле битләрен нурландырып, Габделхак белән сөйләшеп чыгып китте. Ләкин Габделхак куанмады. Ул аның Рәйханга хатлар язуын белә иде.

Габделхак кич эштән кара янып кайтып керде. Рәйхан исә ир дигәненең ишекне ничек ачып керүеннән үк нинди кәеф белән кайтканын абайларга өйрәнеп бара. Әнә, ул ишекне кирәгеннән артык каерып ачты да, кирәгеннән артык шапылдатып япты. Киеменең төймәләрен өзеп атардай булып ашыга-ашыга ычкындырды, элгечкә элмәде, ишек төбенә генә атып бәрде.

— Әнә, Фәгыйлең кайткан, сине сагынуына чыдый алмый, минем янга кергән. Элек аяк та басканы юк иде. Килгән! Абый, дигән була, кайттым, дигән була. Сине күрергә дип килгән ул!

Рәйхан иренең дуамаллыгын, юкка шикләнүен эчке бер

рәнҗеш һәм сагаю белән тыңлап, ни әйтергә белми торганнан соң:

— Син шундый юләрләрчә көнләшәсең дәмени әле?— диде.

Тагын нидер әйтергә теләгән иде, Габделхакның тәрәзә янына барып басуын күзәтеп туктап калды. Габделхак тәрәзә төбендәге гөл савытын кулына алды, тупас йодрыгы белән бәреп тәрәзәне ачты да, чүлмәкне чәчәк аткан гөлие белән урамга атып бәрде. Рәйхан исә:

— Нишлисең? Ни кыланышың бу? Кеше башына төшсә?— дип кенә кычкырып алды.

Шул арада Габделхак өстәл янына килеп, аны идәнгә каплады. Үзе:

— Кырам, ватам, сөйгәннәреңне каршыларга тәрәзә төбенә гөлләр куйдыңмы? Өстәлгә матур чүпрәк җәйдеңме? Кил, үзеңне дә...—дип акырды.

Рәйхан телен тешләп, почмаккарак елышты. Аның тормышы шулай тәмугка әйләнде. Кич булдымы, кара тавыш, кычкырыш. Шундый бик күп көннәр артта калды! Җаны газаплануга түзә алмый, башка бу бәндә белән тора алмам, дип, Рәйхан беркөнне елый-елый әнисенә килде:

— Булмый, әни, тормыйм,—дип елады әнисенең күкрәгенә капланып.

— И, балам,— диде ана. — Уйламыйчарак чыктың бугай, ашыгыбрак чыктың.

— Кеше түгел ул, әни, әллә юләр, әллә шаукымлы. Бер сәбәпсез кул уйната, кыйный, эчемә тибә.

Кызның төеремләнеп килгән күмәненә күз төшереп, ана:

— Балаңны харап итә күрмәсен, каһәр суккан җан!— дип әрнеде.

Ул арада Габделхак үзе килеп керде. Ул Рәйханга ничектер бәләкәйләнеп калган сыман тоелды. Керә-керешкә турыдан-туры:

— Әйдә, Рәйхан, җаным, кайтыйк!— дип ялынды.

— Юк, мин беркая да бармыйм. Мин синең белән тормыйм.

— Рәйхан, дим, кеше көлдермик, әйдә кайт. Мин сиңа тырнак белән дә чиртмәм. Кайт, әйдә. Озакламый улыбыз туар. Әйдә, әйдә,— дип юхаланды Габделхак.

— Балам, Рәйхан, әллә соң кайтасыңмы? Тимим, ди бит.

Бер болганмый су да тонмый, болганып алдыгыз, тынычланырсыз,— диде ана, әрнүле тавыш белән.

— Юк, әни, тормыйм мин аның белән!— дип елады Рәйхан.

Хәтирә, катгыйрак тавыш белән:

— Башта уйларга иде, кем икәнен белергә, сынарга иде. Чыккансың икән, тор инде син. Ничек тә рәтен тап. Кеше көлдермә. Син дә, кияү, нигә аны кыйныйсың? Ни гаебе бар аның?

— Кем кыйный аны?! Минем аңа кул күтәргәнем юк,— дип алдады ананы Габделхак.

Туачак бала хакы дип, кеше көлмәсен дип Рәйхан Габделхак белән кайтып китте. Бу кайгыдан Хәтирә урын өстенә ауды һәм озак авырып ятмый гына гүр иясе булды.

***

Габделхак соң гына эштән кайтты. Таныш-белеш ирсәк хатыннар белән кәеф-сафа корып, миенә үрмәләгән хәмер парыннан томаланган күзләрен ачалы-йомалы баскычтан күтәрелеп ишек шакыды.

Рәйхан янында авылдан килгән дусты Рәсимә бар иде. Габделхакның бу кыяфәттә кайтып керүеннәнме, ул бераз кыенсынгандай булды. Тик үзенең нинди максат белән килгәнен исенә төшереп, бик тиз үзен кулга алды. Габделхак өйгә кереп өстен салырга өлгермәде, Рәсимә гадәттәгедән каты кычкырып:

— И-и, оныта язганмын, әйтми дә торам, Мулланурның малае туды бит.

Рәйхан Рәсимәгә карап күзләрен дә кыскалады, янәсе, сөйләмә, дәшмә, кулы белән дә ишарә ясады, янәсе, ул өйдә бит, аның алдында сөйләмә. Ә тегесе әллә сизмәде, әллә сизсә дә, юри күрмәмешкә салынды, такылдады да такылдады.

— Мөнирә бәбәйләгәч, Мулланур аның янына бармаган, ди! Ә авылда әллә ниләр сөйлиләр. Мулланурны бит аны кыстап кына, куркытып кына өйләндерделәр...

Габделхак дәшми-нитми генә залга үтте, лап итеп диванга егылды һәм колагын торгызып тегеләрнең сөйләшкәнен тыңлап ятты.

Рәсимә дәвам итте:

— Өйләнешкәндә көмәне биш айлык булган. Дүрт ай тулар-тулмас Мөнирә сарык кебек... Рәсимә кычкырып көлеп җибәрде.

— Карале, Рәсимә! Син безгә шушыны сөйләргә дип килдеңме?—дип кычкырды Габделхак яткан җиреннән.

Бик озак ни әйтергә белми торганнан соң, Рәсимә:

— Йә, дускаем, мин киттем. Сау булыгыз,— дип китәргә ашыкты.

Рәсимә артыннан ишек ябылу белән башланды коточкыч гарасат. Өйдә аумаган чиләк, ватылмаган савыт-саба калмады.

Исерек Габделхак кырды, җимерде. Ватар нәрсә калмагач, ул Рәйханга ташланды. Рәйхан бик җайсыз диван кырыена барып төште. Габделхак аны ике кулы белән муеныннан буып алды:

— Үтерәм, үз кулларым белән буып үтерәм, менә шушында мәче кебек җан бирерсең.

Габделхакның акайган күзләре коточкыч иде, кан баскан күзләре белән Рәйханга төбәлеп дәвам итте:

— Авызыңны җәеп, селәгәеңне агызып, Мулланурыңның мажараларын тыңлап утырасың. Сөйгәннәрең сагынып утыралар минем өемдә,— дип җикерде.

Рәйхан аның кулыннан ычкынып, хәлсезләнеп идәнгә егылды, тыны кысылды, борынына җиткән корсагы таш кебек катты, бугазына менгәндәй булды.

Ике көннән Рәйханны «Ашыгыч ярдәм» машинасы бала тудыру йортына алып китте. Ул үле бала тапты.

***

Авыр булса да, тормыш дәвам итте. Рәйхан шәһәрнең үзәк урамында урнашкан «Галантерея» кибетенә эшкә урнашты. Ул хәзер бөтенләй башка кешегә әйләнде. Матур җыр ишетсә дә, нәфис чәчәк күрсә дә, кошлар сайраса да, күңеле тулып, күзләренә яшь тула. Андый минутларда ул Мулланур белән булган көннәренә кайта. Ул аны оныта да, күңеленнән җуя да алмады. Онытырга, исемен искә алмаска дип ант итсә дә, яшь йөрәк үзенекен итте. Аңа әмер биреп буламыни? Кайвакыт әллә каян, күңел түреннән айкалып хәтта шигъри юллар да чыга:

Бакчадагы гөлләрем — син,
Яшьлегемнең ямьнәре.
Тормышымның хыялы — син,
Язмышымның бәйрәме...

Шигырьме ул, юкмы, аңа барыбер. Ул шигырь Мулланур турында, алар йөрәк тибешеннән туган сүзләр.

Эшкә барганда да, кайтканда да Рәйхан ялгыз атлый, ә күңеле белән гүя Мулланур янәшә, гүя ул аның белән сөйләшә, кайгыларын уртаклаша.

— Менә, Мулланур, син дә өйләндең, улың туган... Бәхетледер инде син...

— Белмим, Рәйхан... Нәрсә соң ул — бәхет?

— Бәхет — сөю, сөелүдер ул.

— Мин, димәк, бик бәхетсез...

— Ник алай дисең? Мөнирәне яратасыңдыр бит.

— Минем күңелемдә, йөрәгемнең иң тирән урынында син, бары син генә, мин сине генә яратам.

— Юкны сөйләмә. Хыянәтеңне ничек аңлатырсың?

— Рәйхан, син елыйсың түгелме соң?

— Елыйм, кан-яшь түгәм. Барысын да сиңа сөйләр идем, син ерак. Син аңлар идең.

— Сөйлә, Рәйхан, бушат күңелеңне.

Рәйхан уйчан гына гүя сүз башлый.

— Тыңла, алайса. Кичә генә булган хәлне сөйлим. Нурсыз, ямьсез тормышымны бераз бизәмәсме дип, тәрәзәм төбенә роза гөле утырткан идем. Ул шундый тиз тамырланып, җете кызыл чәчәк атты. Һәр көн иртән хуш исен исним, күңелемә нур тулгандай була, күзләремә сөенеч яшьләре килә, шул гөлдән үземә көч ала идем. Габделхак шул роза чәчәгеннән дә көнләште. Кичә эштән кайтсам, ни күрим, гөлемнең коры төпсәсе генә тырпаеп калган. Артыма ава яздым. Чәчәге бер якта, яфраклары икенче якта идәндә аунап ята. Күзләремә ышанмадым, аптырадым, хәйран калдым. Гөлнең соң ни гаебе бар?! Яфракларын, чәчәген учыма алып, үксеп-үксеп еладым. Әй, гөлкәем, нинди гаепләрең өчен болай рәнҗетте ул сине?— дидем. Менә шундый минем тормышым, Мулланур...

***

Тагын бер елдан Рәйхан кыз тапты. Ике тамчы су кебек

үзенә охшаган кызын Габделхак та яратты, сөйде, учларына утыртып сикертте, матур-матур киемнәр алып кайтты. Ата булу хисе тудымы, ул ничектер басынкырак, тынычрак кешегә әйләнде, гүя аны алыштырып куйдылар.

Тик бу озакка бармады. Еш кына ул төнге бер, икеләрдә генә кайта башлады. Берсеннән-берсе яхшырак костюмнар тектерде. «Майский костюм», июнь, июль айлары өчен костюмнар булдырды. Эшкә китә башласа, «майский костюм»ны бир, тегене бир, моны китер, дип ваклана, көйсезләнә. Кабат ул элекке Габделхак булды да куйды.

Рәйхан, бала караучы табып, эшкә чыкты. Эштә күңеле күтәрелә, күңелдәге төерләр чишелә, кайгы-хәсрәт онытылып тора.

Беркөнне кибеткә посылка белән товар кайтып төште.

— Кызлар, карагыз әле нинди матур мендәр япмалары!— диде кибет мөдире посылканы ачып. — Карагыз әле, күз явын алырлык бит.

Рәйхан ике мендәр япмасы алды да бәхет кошы тоткандай сөенә-сөенә өенә алып кайтты. Урын-җирне өр-яңадан җәеп, мендәрләрен кабартып, нейлон япмаларны ябып куйды. Өй яктырып, ямьләнеп киткәндәй булды. Ул ике кулын кушырып, бөтен күңелсезлекләрне онытып, сокланып үзенең караватына карап торды...

***

Эш сәгате тәмамлангач, үз уйларына чумып, ул урам буйлап тагын ялгыз гына атлады. Биек баскычтан күтәрелеп, өйгә керде. Чәй куеп җибәрде. Әллә ничек күңеле шомланып куйды, аңа никтер өй эче караңгырак сыман күренде. Нидер җитми, нидер урыныннан кузгалган кебек тоелды. Нәрсә юк соң? Өстәл урынында, тәрәзәләр, пәрдәләр... шкаф... урын-җир... Мендәрләр. Ә мендәр япмалары кая соң? Кая булганнар? Аларны мендәр өстеннән кем алган? Кая куйган?

Рәйхан мендәр япмаларын эзли башлады, карават астына иелеп карады, комод тартмаларын тартып-тартып, андагы чүпрәк-чапракны кузгатты. Бер җирдә дә нейлон япмалар юк иде. Кара коелып Габделхак кайтып керде.

— Мендәр япмалары юкка чыккан. Син алып каядыр куйдыңмы әллә?— диде Рәйхан тыныч кына.

— Утка яктым, мичкә ыргыттым,—диде Габделхак дорфа гына.

— Мине дә утка ташлыйсың калды инде,— диде Рәйхан үрсәләнеп һәм караватка капланып елый башлады.

Габделхак ашык-пошык киенеп, каядыр чыгып китте. Рәйхан бераз тынычлангач, кызы Энҗене алып кайтты. Су җылытып, бала күлмәкләрен юып элде. Бишек җырлары җырлап, кызын йоклатты. Утны сүндереп үзе дә урынга ятты. Күзенә йокы кермәде. Тәрәзәдән мөлдерәмә тулып, балкып ай карап тора иде. Кинәт Рәйхан сикереп торды. Тагын Әнисә апасының сүзләре исенә төште. Тулган айга карап...

Гүя ул яшьлегенә кайтты. Муллануpны ул каргый алмаган иде. Каргарга теләмәде, йөрәге кушмады.

Ул тәрәзә янына килеп, тулган айга карады. Бернинди икеләнүсез, йөрәген сыкрата-сыкрата, тирән рәнҗеш белән күз яшьләре аша каргый башлады.

— И, Ходаем, ишет ялваруларымны... Кара каргышым иясен тапсын, ул Габделхак дигән явыз булсын. Матурлыкка бәя бирә белмәгән, хәтта күралмаган бу мокытны каргыйм, күр, ишет, Ходаем. Мин барыбер аның белән яшәмәячәкмен, килер бер көн, мин аннан котылырмын. Ул башка минем чәч бөртегемне дә, керфегемне дә күрә алмас, бер күрергә тилмерер. Теләгем шул: миннән соң матурлыкны аңламаган, сукыр, чукрак, аксак, бөкре хатын белән гомере үтсен! Бар байлыгы җилгә очсын! Соңгы көне хәерчелектә үтсен!

***

Беркөнне Рәйхан эштән кайтышлый Һәдия апасы янына керде. Апасы кичке өстәл әзерли иде, тәлинкәләргә салып, мичтән яңа чыккан вак бәлешләр китереп куйды.

— Әйдә, сеңлем, утыр, өеңдә әле пешкән ризыгың юктыр,— диде.

Рәйхан апасына үзенең сөенечен сөйләргә ашыкты. Бәлеш ашый-ашый алар бераз серләштеләр.

—Трюмо алдым, апа, кредитка, өй эче яктырып, матурланып киткәндәй булды. Тумбочкалы, калын пыяласының читләре сырлап эшләнгән, бик матур.

— Куанычлы әйбер булсын. Кияү ошаттымы соң?

— Аңа нәрсә? Ул әйбер алганны бик яратмый, акча җыя, кием тектерә. Мин үз акчама алдым, кредитка, үзем түләячәкмен. Энҗегә бик ошады. Яныннан да китми, мәктәпкә китәр алдыннан бөтерелә генә. Әйдә, апа, безгә, күреп китәрсең.

Һәдия яңа алган трюмоны барып карарга булды.

Капка төбендә күз яшьләренә манчылып, үксеп, Энҗе басып тора. Ул әнисен күрү белән, ашыгып, аңа таба йөгерде.

— Әйдә, әни, тизрәк, өйдә что творится!— дип әнисенең кулына килеп ябышты.

— Тагын нәрсә булды?

— Кергәч күрерсең, анда папа котыра.

Биек баскычны йөгереп менеп, Рәйхан ишекне ачып җибәрде. Ни күрсен: идән тулы көзге ватыклары, Габделхак котырган ерткыч җанвар кебек, тешләрен шыгырдата-шыгырдата, ах-вах килеп, көчәнә-көчәнә, калын табанлы итекләре белән көзге пыялаларын таптый, сыта, тибеп-тибеп җибәрә. Пыяла ярчыклары әле өстәл өстенә, әле урын-җиргә барып төшә, стенага барып бәрелә.

— Син нишлисең, Габделхак!— дип кычкырды Рәйхан. — Нишләвең бу? Әллә котырдыңмы?

Габделхак шашкан күзләрен акайтып Рәйханга карап алды да, тагы да кызуланыбрак көзге ватыкларын изә башлады. Үзе бертуктаусыз:

— Менә сиңа! Менә сиңа! Менә сиңа көзге! Менә сиңа чибәрлек!— дип акырды.

Рәйхан, ишектән өй эченә узарга теләп, бусаганы атламакчы булды. Ул арада бу мәхшәрдән коты очкан Һәдия Рәйханның кулыннан тотып алды һәм артка сөйрәде.

— Син нәрсә? Юләрләндеңме? Кая керәсең? Ул хәзер синең башыңны өзәчәк, шушы пыялалар кебек сытачак бит!— дип өзгәләнде.

Чыннан да, бу тетрәндергеч күренеш эченә керү үзе зур хата, төзәлмәслек фаҗига белән бетү мөмкинлеге көн кебек ачык иде.

Һәдия Энҗе белән Рәйханны үзенә ияртте.

— Тизрәк, тизрәк, әйдәгез, китик,— дип кабатлады.

Рәйханның Габделхак белән яшәгән елларда күргән җәбер һәм кыйналулардан елап инде күз яшьләре гүя агып беткән, бу юлы ул еламады, аның бәгыре каткан иде.

***

Ул китәргә, мөмкин кадәрераграк китәргә, дигән фикергә килде.

— Апа,— диде Рәйхан, — мин Казанга китәргә уйлыйм. Бер баланы ничек тә туйдырырмын.

— Казанга?—дип гаҗәпләнде апасы. — Казаннан барып тапмас дисеңме? Ул икенче көнне үк артыңнан килеп җитәчәк, юхаланачак, ялыначак. Син тагын җебеп төшәчәксең. Ничә мәртәбә тасма теленә ышанып кайттың, гомереңне саттың. Китсәң, ераграк кит.

— Әнием, әйдә, еракка, еракка китик,—дип, анасының муенына асылынып елады Энҗе.

Рәйхан уйга калды. Кая китәргә? Кеме бар соң аның? Канаты астына сыендырырлык беркеме дә юк. Ул атасыз ятим үскән, бала карап җәберләнгән, кан-яшь тулы үсмер елларын исенә төшерде.

Олы апасында бала караганда булды бу хәл. Көз иде, сулар чираган чак. Ишегалдында таста түгелми калган су туңган иде. Олы апасы Рәйханны гаепләде:

— Су калган таста! Тасның төбе төшсә! Ник түкмәдең? Ник калдырдың?— дип Рәйханның аягына бик каты китереп типте. Рәйхан аягы авыртуга түзә алмыйча, елый-елый икенче аягында сикергәләде дә, баскычка барып утырды.

— Тор, нишләп утырасың?— дип апасы тагын башына китереп сукты.

Кечкә Рәйханның аягы гөбе кебек шешеп чыкты. Авыртулардан елау авыр, әмма рәнҗетелүдән күз яшьләре бигрәк ачы икән...

***

Рәйхан, кайчандыр Урта Азиягә китеп, берничә ел аннан хатлар, котлаулар җибәреп яткан Мәһирә исемле бер танышын исенә төшерде. Ул хатларында җылы якларны бик мактап яза иде: эш күп, тормыш яхшы, урамнарда җимеш агачлары үсә...

Дөрес, бу хатлар, котлаулар туктаган иде инде. Шулай да Рәйхан кәгазьләр арасыннан Мәһирәнең адресын табып, аны сөйләшүгә чакырып, телеграмма сукты...

***

— Алло, Фирганә, Фирганә!

— Әйе, бу мин — Маһирә. Телефонда кем? Рәйхан, синме? Син кайдан?

Рәйхан сүзен әйтә алмады, яшьләренә тыгылды, теле тотлыкты. Һәдия Рәйханның кулыннан телефон трубкасын алды да кыскача гына Рәйханның хәлен аңлатты, Фирганәгә, аның янына юлга чыгарга ниятләвен әйтте.

Фирганәгә поезд бик иртә килеп җитте. Энҗене житәкләп, икенче кулына зур чемодан тотып, Рәйхан Лиза Чайкина урамын эзләп тапты.

Маһирә әле эшкә китмәгән иде. Алар бик җылы күрештеләр, кочаклаштылар, елаштылар.

Менә шулай яшьлеген, Мулланурын, авыр кайгыларын туган якларында калдырып, Рәйхан бер таныш түгел җиргә килеп чыкты. Ун-унбиш көн дигәндә, авырлыклар белән эшкә урнашты, ниндидер яңача җилкенү белән эшли башлады. Яңа шөгыль, яңа кешеләр, яңа танышлар.

Башта аңа монда бик кызык кебек тоелды. Ул үзендә өлгерлек, кыюлык, хәтта бераз хәйләкәрлек, әрсезлек сыйфатларын да ачты. Эчтән генә горурланып та куйгалады. Дуслары күбәйде, мактау сүзләре ишетте. Ул бүтән бервакытта да үткәннәрне искә төшермәскә, Мулланурны да бөтенләйгә онытырга булды. Әмма бу халәт озакка бармады. Рәйхан бик еш үзендә эчке сызлану, өзгәләнү сизә башлады, кайвакыт аны коточкыч сагыш яулап ала, ә бу күз яшьләренә сәбәп була. Бу хәлдән котылу өчен ул әлләниләр кылырга әзер иде. Күңел бушлыгыннан, ризасызлыктан ул мондагы матурлыкны күрми, җимешләрнең хуш исен тоймый, җылысында туңа, кичләрен моңая, көндезләрен сыкрана, төннәрен саташа башлады. Ул бернигә гаҗәпләнми, аны бер нәрсә дә сөендерми. Кайчак үзенең бу халәтне җиңәрлек көче калмаганын тоеп, куркуга кала, бушлык сөремен берни дә юкка чыгара алмас кебек тоела башлый.

Иртәләрен уй-теләксез генә уяна, ашык-пошык чәй капкалап эшкә чаба, эшен теләр-теләмәс кенә башкарып көн уздыра. Ярый, кызы, Энҗесе бар. Ул аның белән кичләрен китап укып, дәрес хәзерләп, бераз күңелен тынычландыра.

Илдә чакта ул юк-юк та Мулланурны очрата, берничә генә минут сөйләшеп тора, шушы минутлар да аның өчен зур юаныч була иде. Ул өзелеп Мулланурны сагына, аны бик еш төшләрендә күрә.

...Мулланур аның янына килгән, имеш.

— Гафу ит, Рәйхан, күптән синең яныңа килергә җыенам, тик нидер тота, нидер җибәрми,— ди.

Рәйхан аны куа:

— Бар, кит, күземнән югал. Минем бу көнгә калуыма син генә гаепле,— дип кычкыра.

— Кума, Рәйхан, кума. Син бит мине әле дә яратасың, сагынасың. Кума, ялгышма, үкенерсең. Яратасың бит, яратасың...

Мулланур аны үбә, имеш.

— Яратам, яратам!..

Рәйхан елый башлый, имеш...

Рәйхан уянып китте. Күзләре яшьләнгән, йөрәге дөп-дөп тибә, үзе шыбыр тиргә баткан. Ул кызы Энҗегә таба борылып, йоклаган баланы кочаклап, төшендә түгел, өнендә, төн караңгысында яшеренеп, бик озак елап ятты. Байтак кына күз яше түккәч, тагын йоклап китте.

Ул уянып, өйдәге тынлыкны тыңлап, йөрәк тибешен ишетеп, кузгалмыйча бераз ятып торды. Тәне һәм җаны искиткеч киеренке халәттә, тагын нигәдер борчыла башлады. Менә хәзер өй ишеге ачылыр да, кояш нурларына уралып иң якын кешесе — Муллануры килеп керер сыман тоелды.

Тукта, төшендә ул аны күрде бит. Ничек итеп күрде әле ул аны? Менә шушында гына басып тора иде түгелме? Әйе, әйе. Ул аны куды, кит, күземә күренмә, диде, хәтта кычкырды.

Әллә кайда, күңеленең иң тирән җирендә яшеренеп яткан хис-тойгылары уянды да, сусызлыктан шиңә башлаган чәчәккә су бөркегәндәй, аның бөтен барлыгын ниндидер йомшак дулкын биләп алды. Ул да булмады, соңгы көннәрдә аны газаплаган әч пошу, күңел җилкенү, өметсезлекнең эзе дә калмады. Ул яткан көе генә башын борып, кояш төшкән тәрәзәгә карады. Анда да елмаеп кояш чыккандыр, бәлки

кояшлы яңгыр явадыр. Аның инде бер ел рәтле-башлы яңгыр күргәне юк.

Әллә соң, барысын ташлап, туган илгә кайтып китәргәме?

Туган туфракка аяк тидерсә, Рәйханга һичшиксез яңа җан иңәр иде. Китәргә! Китәргә!

***

Поездан төшеп, алар Казан пристанендә пароход көттеләр. Ташбака кебек әкрен йөрүче пароходта егерме сәгать буе зарыгып, ниһаять, Рәйхан кызы Энҗе белән Алмалы пристанена якынлашты.

Бер ел вакыт узып та киткән, тик аның туган яклары нәкъ ул киткәндәге кебек, үзгәрмәгән, гүя ул кичә генә шушы җирдән узган. Үзгәрмәсә дә үзгәрмәс икән бу текә ярлар! Җил-яңгырларда түбә калайлары уңып, ян-яклары чәрдәкләнеп беткән дебаркадер һаман шул ук икән. Кыя ташка язылган «Саша+Маша» дигән язуны да яңгырлар юып төшермәгән, әллә кайлардан күренеп тора. Яр өстендәге тәртипсез сибелгән ярымҗимерек корылмалар, сарайлар, өем-өем бүрәнәләр, утын әрдәнәләре — барысы да нәкъ ул киткәндәге кебек моңсу һәм кызганыч.

Тик аның бер ел гомерен генә чит-ят җир үзенә йоткан, сызып ташлаган.

Бу җирдә һаман үзгәрмәс моңсу тормыш, анда аның ачы яшьлеге калган.

Ярга чыгып бастылар. Рәйхан үзенең йөрәгендә күптән онытылган җилкенү хисе, тәнендә җиңеләю сизгәндәй булды. Әллә ул үткәннәренә кабат җилкенәме?

Пароходтан төшүчеләр бик аз булды, төштеләр дә кайсы кая сибелделәр.

Пристаньга йөри торган кечкенә автобуска этешә-төртешә кереп утыргач, Рәйхан тәрәзәдән карап тирә-якны күзәтте, болын, түгәрәк-түгәрәк таллыклар, ватык көзге ярчыклары кебек сибелгән вак-вак күлләр, Чулман буендагы киң комлыклар аның күңелен дәртләндерде. Нинди хозурлык аның туган ягында! Ул моннан соң беркая да китмәскә, гомергә туган-үскән җирендә калырга дип күңеленә беркетте. Ул арада әллә каян болыт чыгып, автобусның тузанлы тәрәзәсен юа башлады.

— Әнием, нинди яңгыр!— диде Энҗе.

Ул теге якларда яңгырны да сагынган, күрәсең.

— Әйе, кызым, туган якның хәтта яңгырларын да сагындык шул без.

***

Рәйхан туган-үскән җиреннән беркая да китмәскә ничек кенә антлар эчмәсен, барыбер анда озак яши алмады. Яхшы гына фатирга урнашып, кыш өчен утын әзерләп, кистереп өйдә, эше якын гына иде. Тик ул кайту белән бер генә көн дә тынычлык күрмәде.

Габделхак һаман өйләнмәгән. Беркөнне Рәйхан янына кибеткә Габделхакның сеңлесе килеп керде. Аны-моны караштырып йөргән, хаклар сорашкан булды, аннан Рәйхан эшли торган бүлеккә килеп, аның сатып алучылардан бераз арынуын көтеп, сүз башлады:

— Күптән кайткансың икән, Рәйхан. Күзгә-башка чалынмадың. Кереп чыгар идең. Хәл-әхвәл сорар идең.

— Сорашкан, белгән кадәресе дә хәттин ашкан, Әминә.

— Абый элеп киптергәндәй булды инде, син димәгән сәгате, сине искә алмаган көне юк. Эчә башлады.

— Эчә башлады?! Эчүен ташлаганы булдымы соң аның? Сүз сөйлим дип сөйлисеңме, Әминә?

— И, Рәйхан, син аны күрсәң, жәлләр идең. Саташа хәзер, ялгыша башлады. Гел синең исемеңне атый: «Рәйхан!»— дип кычкырып җибәрә, «Син кайда? Китәрмен дә кискән тырнагымны да күрмәссең, дигән идең, син кайда?»—дип сөйләнә, саташа. Кайт аның янына, бөтенләй юләрләнмәгәе, үзенә кул салыр, үләр дип куркабыз.

— Андый кешенең яшәмәве яхшырак, Әминә. Минем аны күрәсем дә, беләсем дә килми. Соңгы сүзем шул: миңа андый сүзләр сөйләргә башка килеп йөрмә,— диде дә, Рәйхан эчке якка кереп китте.

Габделхак үзе дә әле Рәйхан эшли торган кибеткә, әле кичләрен аның фатирына килеп, аны акылына килергә, баланы ятим итмәскә өнди, ялына-ялвара.

— Ялынма, Габделхак, ялынма, юхаланма. Мин синең сүзләреңә, ялган вәгъдәләреңә күп ышандым. Ышандым да күпме гомеремне синең белән саттым, сәламәтлегемне бетердем. Менә бу экземалар — син канечкечнең бүләкләре.

— Бала хакына, Рәйхан!

— Бала ятим булмас, мин аны ятимлеген сизмәслек итеп үстерермен, бөтен көчемне биреп укытырмын, кеше итәрмен. Беләсеңме, ул синнән киткәннән бирле бер мәртәбә дә сине искә алмады. Аңа син кирәк түгел, ерткыч ата түгел, чын ата кирәк.

Рәйхан инде нигә кайтканына үкенә башлады. Ул туган җир дип аһ итүенең, яшьлек хисләренең мираж гына булуын аңлады. Ә Габделхак белән бер шәһәрдә яшәп, аның Рәйханны тынычлыкта калдыруына исәп тоту мөмкин түгел. Ул булган юк-барны бер чемоданга тутырды да, кызы Энҗене алып, тагын озын юлга чыкты. Китәргә, башка кайтмаска! Ул тагын дүңгәләк кебек җил-давыл шаукымы белән җылы якларга китеп барды.

***

Рәйхан кабат Фирганә шәһәренә килде, тагын зур авырлыклар белән кибеткә урнашты. Аның тормышы җиңеләймәде, сагыш-кайгылары бетмәде, күз яшьләре кипмәде. Ул үзенең үткән гомерен тагын искә төшерә. Кечкенә утраучык булып калган Мулланур белән булган көннәр искә төшә. Ул әле елмая, әле ерак-еракларга күзен текәп, уйга чума. Ялгыз калуының сәбәпләрен эзли, кайда, кайчан язмыш хатасы җибәрелгән? Ул шул сорауга җавап эзли. Сагыш, әрнү, кемгәдер үпкә — барысы бергә буталып, күз яшьләренә сәбәп була. Ул мендәренә капланып, үксеп-үксеп елый башлый. Ул үзенең яшьлек хаталары өчен, Габделхак белән язмышын бәйләгән өчен ачы үкенү хисе белән бәргәләнә. Ул фәкать Мулланурны сагына, аның белән бергә булса, мәхәббәт тулы тормышта яшәр иде кебек тоела.

Менә бүген дә шулай булды. Ул эштән кайтты, өстен алыштырды, яраткан җиңел зәңгәр чәчәкле халатын киде һәм чәй куеп җибәрде. Энҗесен кочаклап үпте, ашатты, дәрес хәзерләтте, йоклатты да Рәйхан озын караңгы төн белән ялгыз калды. Фотоальбомын кулына алып, тагын Мулланурның рәсеменә карады. Ул яшь каен күләгәсендә, каядыр уйчан караш ташлап, басып тора. Тере кебек, менә кузгалыр да Рәйханга таба атлар кебек. Их, Мулланур!Ниләр эшлисең икән хәзер? Рәйханны оныткансыңдыр инде

син. Кайтты, бер генә мәртәбә дә күрә алмады бит. Син кайда идең соң?

Гомере буе ул хатирәләр белән генә яшәр микәнни? Үткәннәре исенә төшеп, бертуктаусыз аны әзәрлекләп, тынычлыгын алырмы? Рәйхан җансыз рәсемгә үзенең коры иреннәрен тидереп алды. Аның шушы минутта Мулланурның күкрәгенә сыенасы килде. Тик ничек кенә теләк көчле булмасын, гомер арбасын кире борып, язмышны үзгәртеп булмавын аңласа да, ул шул хисләрнең аның көннәрен матурлавына сөенде. Әле ярый, аның юлында кыска гына вакытка булса да ул очраган. Югыйсә, нәрсәгә куаныр иде, нәрсәне җылы итеп исенә алыр иде? Аның күңеле йомшап китте, йөрәге тагын әрни башлады. Еллар уза, ә аның киләчәге билгесез. Өметсезлек шундый чиккә җитте, ул үз-үзен белештерми тагын үксеп елап җибәрде...

***

Рәйхан эшли торган кибеттә эшләүче җыйнак гәүдәле, бик өлгер, сөйләшергә ярата торган җыештыручы хатын Сания менә ничә көннәр инде Рәйханга сүзката алмый йөрде. Бу беркемдә дә кабатланмаган сөрмәле, уйчан, серле күзләрне аның кайдадыр күргәне бар, күргәне бар, тик кайда, кайчан? Шуны искә төшерергә теләп, ул бөтен гомер юлын күз алдына китерде. Кайда гына соң? Кайчан? Шул сорау бер генә минутка да аңа тынычлык бирмәде. Күргәне бар! Менә бүгенгедәй, якында гына күргәне бар.

Сания таяк башына чорнаган чүпрәген арлы-бирле таш идәннән сөйрәп, башын иеп әле бер, әле икенче якка таба үтте дә, түзмәде, Рәйханга якын ук килеп сүз башлады:

— Карале, сеңлем, мин сине моңарчы кайдадыр күргәнем бар бит,— диде.

— Белмим шул, Сания апа,—диде Рәйхан уңайсызланып.

— Кайда гына күрдем соң мин сине? Һич исемә төшерә алмыйм бит.

— Безнең Алмалы шәһәрендә булганың юкмы соң?

— Юк, булганым юк. Ул якларга аяк та басканым юк.

— Минем дә бу якларга беренче килүем.

— Карале, сеңлем, этиең, әниең кайсы яклардан соң синең?

— Әтием Алмалыдан ерак түгел авылдан, әнием Кайбыч дигән районнан. Синең ул якта булганың юктыр шул, Сания апа.

Саниянең күзләре очкынланып китте, ул ашыга-кабалана:

— Кайбычтан, дисеңме? Кайсы авылдан?— дип кычкырып җибәрде.

— Кошман дигән авылдан.

— Соң аны нигә әллә кайчан әйтмәдең? Мин дә Кошманнан бит. Кемнәрең бар анда? Кайтканың бармы ул якларга?

— Туганнар бар. Әнинең энесе Миргалим абый...

— Миргалим, дисеңме? Укытучы Миргалимме?

— Әйе, Миргалим абый укытучы булган, Кошманда укыткан.

— Менә, менә. Синең күзләрең нәкъ менә Миргалим абый күзләре. Шундый ук очкынлы, якты, сөрмәле. Ул шул күзләре белән керфекләрен сирпеп бер караса, кызлар һуштан язалар иде. — Сания кеткелдәп көлеп җибәрде... — Мин бит Миргалим абыйда укыдым, җаным. Миргалим абый күзләре инде, бәгырькәем.

— Ә син үзең бу якларга ничек килеп эләктең, Сания апа?— дип сорады Рәйхан.

— Мин күптән инде монда, җаным. Ирем сугышта һәлак булды. Җанымны кая куярга белми йөргәндә, бу яклардан Кошманга туганнар кайттылар. Кызым Гөлсинәне ияртеп, ике дә уйламый, шулар белән авылдан чыктым да киттем.

Бу сөйләшүдән соң Сания Рәйханны туганы кебек якын итте.

Беркөнне ул Рәйханга тагын сүз кушты:

— Карале, сеңлем Рәйхан, карап-карап торам да, сине җәлләп куям. Кибеткә кергән һәр ир синең яныңда туктала, ашардай булып карый, җаныңа тия, селәгәен агыза, кайчак шушы таяк белән сылыйсым килә. Чибәр булу да бик читен икән, дип куям. Шул шакшы ирләрнең корбанына әйләнүеңнән куркам, җаным. Кара инде теге «Волга» йөртүчене. Килмәгән көне юк, кабып йотардай булып сиңа карап тора, менә гел юлбарыс инде, күзләре яна, йөзе комачтай кызарып бүртенә.

Рәйхан үзе дә моны күрә. Ул мондагы мут күзләрне, ыржаеп торган озын сары тешләрне, елык-елык иткән кап-кара чәчләрне, тир белән керләнгән сырлы муеннарны күралмый, җене котыра, ачуы чыга.

Әмма ул сатып алучыга елмаергә тиеш, кара коелырга ярамый. Эшләргә кирәк, яшәргә, бала үстерергә, фатирга түләргә акча кирәк.

Кай көннәрдә, бер дә уйламаганда, күңеленең әллә кайсы киртәләре эченә яшеренгән, инде онытылып, югалып бара торган уй-хисләре тагын баш калкыта. Ул кешеләрнең йөзендә Мулланур чалымнарын эзләп иза чигә. Сагыну, саргаю аны соңгы чигенә җитеп газаплый.

Беркөнне шулай, арып эштән кайтканда, ул алда бара торган бер кешене Мулланурга охшатып, үзе дә сизмәстән, «Мулланур!» дип дәште. Ир борылып карамады. Мулланур булса, сискәнеп борылыр иде, елмаер иде. Ул түгел. Шуңа да карамастан, Рәйхан, аруларын онытып, аның артыннан атлады да атлады. Нәкъ шундый ук базык гәүдә, киң җилкә, юанча нык муен, тырпаеп торган колаклар. Атлавы да нәкъ аныңча, салмак, ышанычлы, ныклы, горур адымнар. Ул үзен Мулланур артыннан баргандай хис итте, тик теге ир тукталышта автобуска кереп күздән югалды...

***

Сания Рәйханны туганы кебек күреп, еш кына кызы Энҗе белән үзенә кунакка чакыра. Алар төннәр буе серләшәләр, кайгы-хәсрәтләрен уртаклашалар.

Шундый очрашуларның берсендә Сания белән Рәйхан ничектер озак кына сүзсез утырдылар, һәркайсының башында үз уе иде. Шулай да Рәйхан бүген үзен бик бәхетле хис итте. Сания апа аңа чын дус, якташ, сердәш, туган якның бер якты шәме сыман тоелды. Еш кына аның күңелен уйлар шундый итеп чорный, икеләнүләр, борчылулардан ул шундый арый, алардан ничек котылырга, бушанырга белми газаплана.

Кайчакта кем беләндер парлап урамнар урыйсы яки менә бүгенге кебек сүзсез генә утырасы килә.

Ә Сания үзенең сүзен ничек башларга белми: үпкәләтмәмме, рәнҗетмәмме, ачуланып кайтып ук китмәсме? Ул сүзен башлый, уйларга чумган җиреннән Рәйхан сискәнеп китеп, аңа туры карый.

— Карале, Рәйхан җаный, тыңла әле мине, рәнҗемә, үпкәләмә, күрәм: үзең чибәр, үзең акыллы, җитез, эшчән, ни гомер инде япа-ялгыз гомер сөрәсең. Яраткан кешең юк, сердәшең, дустың, димме.

— Син, Сания апа, минем турыда әле бик аз беләсең, йөрәгемнең кем дип тибүен дә, кемгә гомерлеккә табынып дәрәҗәдә гашыйк икәнемне дә белмисең.

Шунда Рәйхан үзенең бердәнбер тыңлаучысына берни дә яшермичә үзенең Мулланурны, фәкать Мулланурны гына яратуын һәм аның белән булып үткән катлаулы мөнәсәбәтләрен сөйләп бирде, бөтен күңелен ачып салды.

— Менә, җаным, Мулланурыңны оныту өчен сиңа кияүгә чыгарга кирәк,—диде Сания.

— Кияүгә? Кемгә? — дип кычкырып көлде Рәйхан. — Үзбәккәме? Теге «Волга» йөртүчегәме? Кемгә? Юк инде, Сания апа, мин сөю, мәхәббәтсез, күземне йомып бер мәртәбә упкынга ташландым. Мин ул хатамны башка кабатларга теләмим. Сөймәгән кеше белән яшәүнең нәрсә икәнен мин бик яхшы беләм. Сөткә пешкән, суны да өреп каба, диләр бит.

Сания әле серне чишәргә ашыкмады. Ул әллә кайчан инде Ташкент шәһәрендә яшәүче туганы Шәмседохага хат юллаган иде. Хатында ул Татарстаннан баласы белән бик яхшы бер хатын килүе, үзе эшли торган кибеттә эшләве турында язган иде.

Шәмседоха Корбан гаете уңаеннан Сания белән Рәйханны үзләренә кунакка чакырды. Белмәгән кешегә тора салып кунакка бару әллә ничек кыенрак тоелса да, туган якларны сагыну, ямансылау, эч пошулар бераз онытылып тормасмы, дип, Рәйхан риза булды.

Аларны поездан төшүгә бер егет каршылады. Ул такси белән килгән. Рәйхан егетнең аксыл-күрән төстәге ыспай джемперы аша күзгә ташланып торган киң җилкәләрен һәм тыгыз мускулларын чамалады. Туры бәдәнле, куе кара чәчле, кара күзле бу егет Рәйханга үзен артык нык кызыксыну белән күзәтә сыман тоелды. Егет Рәйханга кулын сузды:

— Күрешик, минем исемем — Шәүкәт,— диде.

Рәйхан кыенсынып кына аңа кулын бирде:

— Рәхмәт, мин — Рәйхан.

Шәүкәт кечкенә Энҗене иң беренче итеп таксига кертеп утырттты, аннан хатыннарга дәште:

— Уңайлап, жайлап утырыгыз, юл ерак...

Сания белән Рәйхан Ташкентта өч көн булдылар. Иксез-чиксез, гөрләп торган Ташкент базарын карадылар, бер кичне циркка бардылар. Корбан гаете үткәч, кабат Фирганәгә юл тоттылар.

Уйламаганда, көтмәгәндә Рәйхан Ташкенттан, Шәүкәттән хат алды. Вак кына хәрефләр белән язылган тулы бер дәфтәр бите. Рәйхан бу хатны зур кызыксыну белән укып чыкты да кычкырып көлеп җибәрде. Нәрсә дигән бу:

«Бәхетсез язмышымда бер бүләк», «кызың да бик ягымлы», «үзең дә бик чибәр»...

Хатны кабат укып тормады, чөнки хаттагы күп кенә сүзләр аның ачуын чыгарды: «кайчан очрашабыз», «зинһар, кире какма», «без бергә булырга тиеш»...

Рәйхан яшь вакытта Мулланурдан алган беренче хатын искә төшерде. Аның хаты гел шигырьләр, җырлардан гына иде. Нинди җырлар иде соң әле ул? Рәйхан озак уйлады. Мулланурның бер генә җыры хәтерендә калган булып чыкты:

Биек тау башына менеп
Чәчең тарасаң иде.
Йөрәгемнең янган җирен
Ярып карасаң иде...

Их, Мулланур! Менә син бүген Рәйханның йөрәгенең янган җирен ярып карасаң иде. Күрер идең анда нинди ялкын, нинди яра барын. Сине бер генә күреп сөйләшер иде, серләшер иде. Сорар иде: Шәүкәтнең хатына ни дип җавап бирим? Әйт, Мулланур, дияр иде...

Ул кичке тынлыкны тыңлап бик озак утырды да моңлы итеп әкрен генә җырлап җибәрде:

Өй алдындагы бакчадан
Өзеп алдым бер йөзем.
Өзеп алган йөзем кебек
Чит җирләрдә берүзем...

Шәүкәткә җавап хаты язасы урынга, ул кайчандыр эче пошкан минутларда күңел нурын, сагышларын тапшыра торган көндәлек дәфтәрен кулына алды. Ул бу дәфтәргә күбрәк өзелеп юксынган мизгелләрдә теленә килгән сүзләрне язып куя иде. Дәфтәр битләрен актарып укый башлады:

«Көндезләрен сагынып уйланам,
Төннәремдә күреп уянам,
Сагынам юлларда барганда,
Сагынам ялгызым калганда.
Сагынам, чөнки бик яратам.
Сагынмый булмый шул яратсаң...»

Менә берничә генә көн элек язылган юллар:

«Минем күңелдә көчле мәхәббәт канат кага, Мулланурым, мин сине генә яратам. Җаныма никадәр сөю сыйса, шулкадәр яратам. Син минем күңелемә яшен уты булып, күкрәгемне яндырып кердең. Без бер-беребез өчен генә яратылган.

Яшем узды инде, диеп
Ник әле көенергә?
Беркайчан да соң түгел бит
Сөяргә, сөелергә.»

Шушы юлларны укыгач, ул тагын каләм алды һәм дәвам итте:

«Синнән еракларга китүемә инде ничә еллар. Тик тормышымдагы үзгәрешләр сиңа булган мәхәббәтемне үзгәртә алмады. Мин кайда — син шунда булдың. Шәүлә булып түгел, нур булып, җылылык, ялкын булып син минем гел янәшәмдә яшисең. Мин сине тоям, сиземлим. Миңа башка кеше кирәкми.»

Әллә каян шигыре дә телгә килде:

«Үкенечле мәхәббәтем —
Әрнүләрем ачысы.
Бик еракларга аерган
Безне язмыш кайчысы.»

***

Көн әллә нишләп бик озак үткән кебек тоелды. Рәйхан төштән соң бөтен рухын ашкындырып торган яшьлек

көннәрен хәтеренә төшерә-төшерә бер елмаеп, бер моңаеп, кибеткә керүчеләргә теләр-теләмәс кенә хезмәт күрсәтте. Аларның әрсез күз карашлары аны тәмам туйдырган, гүя ул берни күрми, исе дә китми.

Кинәт ул бөтен күзәнәкләре белән еractан очкынлы, үтәли тишә торган карашны тойды. Тойды, ләкин күзен күтәрмәде, борылып карамады. Әмма шул карашны күтәрә алмыйча, тәне чымырдап, кулы калтыранып куйды. Битарафлык күрсәтеп, озак кына үз-үзе белән тарткалаша торгач, түзмәде, теге якка борылды. Аңа ниндидер таныш күзләр текәлгән иде.

Рәйханга куркыныч булып китте. Кем соң әле ул? Кайда күрде ул бу коңгырт моңсу күзләрне?..

Ул эшләвендә булды. Тик аны алыштырып куйганнар иде. Уйлап-нитеп тормый гына әйбер үлчәде, акча алды, санамый гына тартмага салды. Гүя ул бу минутта кибет сатучысы түгел, дрессировщик кулындагы кечкенә җәнлек, аңсыз рәвештә ул кушкан әмерне үти, хәрәкәтләнә, хәрәкәтләр төгәлме, түгелме — анда аның эше юк.

Рәйхан тагын борылып карады. Бу юлы ул күзләрне генә түгел, елмайган иреннәрне дә шәйләде. Кара каш һәм куе кара чәчләр аны аңына китерде. Бу бит —Ташкенттагы танышы, аңа хат язган Шәүкәт. Аңа, чыннан да, томырылып, гашыйк күзләре белән Шәүкәт карап тора иде.

Рәйхан тирәсендә сатып алучыларның азаюын көтеп торды да, Шәүкәт бөтен кыюлыгын җигеп аның янына килде.

— Саумы, Рәйхан...

Рәйхан аңа елмаеп җавап бирде.

— Әйдә, Рәйхан, яп кибетеңне. Мин сине алырга килдем,— диде.

Рәйхан тиз генә кулындагы сәгатенә карап алды, кибетне ябарга иртәрәк иде әле.

— Юк, Шәүкәт, мин кибетне иртә яба алмыйм, әле егерме минут вакыт бар.

— Безне көтәләр.

— Кем көтә, кайда көтә?

Шәүкәт вакыт уздыра алмый бик озак таптанды, урамга

чыгып тәмәке пыскытты, тагын кереп Рәйханны ашыктырды, бертуктаусыз сәгатенә карады. Ә сәгать уклары үч иткәндәй бик әкрен кыймылдадылар.

Була бит шулай: кайберәүләр үзенең килеш-килбәте, күз карашы, елмаюы белән әсир итә. Шәүкәт тә акыллы коңгырт күзләре, уйчан карашы белән Рәйханны үзенә буйсындырып, үзе белән ияртте. Рәйхан карышмады.

— Кая барабыз?—дип кенә сорады.

— Сания апаларга.

Рәйхан Санияләргә керү белән, ишек төбендә туктап калды, өйдәгеләр сөйләшүләреннән туктап, барысы Рәйханга карадылар, аның затлы күлмәге, күлмәгеннән дә затлырак нәфис йөзе, кашы-күзе өстәл тирәли утыручыларны битараф калдырмады. Кемдер хәтта яшь хатынны күреп:

— Аh!—дип куйды.

Ә Шәүкәт үзен бик иркен тотты. Рәйханны кулыннан тотып, түргә таба әйдәде.

— Менә, диде,— мулла белән абыстайны алып килдем. Шаhитлар бар, безгә никах укыячаклар.

Рәйхан көтелмәгән бу күренешкә нинди бәя бирергә белмәде, чыгып та китмәде. Ул Шәмседохага таба атлады:

— Мин бер нәрсә дә аңламыйм, Шәмседоха апа, нинди кәмит соң бу?—диде.

Шәмседоха аптырап калмады:

— Аңлыйсы-нитәсе юк, бу бернинди кәмит түгел, үзебезнең мөселман йоласы. Шәүкәт белән сиңа мулла никах укыячак, Аллаhы боерса. Бик пар килгәнсез. Улым эчми, бәхетле булырсыз. Ул ялгыз, син ялгыз, каңгырап йөрмәгез.

Рәйхан берәүгә дә күтәрелеп карамады, берәүне дә күрмәде. Өйдә бик эссе hәм тынчу иде.

Бу инде Рәйханның чын-чынлап кармакка эләгүе булды...

***

Менә шулай Рәйханның яңа тормышы башланды. Ул ир канаты астына керде. Әмма аның күңеле гел Мулланурда булды. Ул аны hаман төшләрендә күрде. Мулланурны оныта алмады. Аның өчен якты кояш, меңәрләгән чакрым арадан үзенең җылы энергиясен җибәреп, яктысы белән Рәйханны

куандырып тора. Ә Шәүкәт Рәйхан өчен төннәрен генә күзгә күренә торган салкын ай булды. Ай да бит бер караганда сызылып кына киткән урак булып, күзгә чалыныр-чалынмас, икенче караганда нур сипкәндәй тоелса да, кояш яктысыннан гына ялтырап торган күк җисеме.

— Ярата алмыйм, Сания апа, җылысы җылытмый, ялкыны салкын,—диде Рәйхан беркөнне Саниягә, күзләрендәге кайнар яшьләрен яшермичә.

— Ияләнерсең әле, җаным. Бик уңган бит ул Шәүкәт, кулыннан килмәгәне юк, бар эшкә оста. Яратырсың, яратырсың. Ирле гомер — иркә гомер ул. Ирле кеше — чинлы кеше.

Рәйхан дәшмәде, үзбәкләр бәйләнүеннән туеп, башын үзе бәйләде бит бу иргә, беркемгә дә үпкәләр, рәнҗерлеге юк. Язмышка күнәргә, яшәргә, гомер итәргә туры килер. Сания дәвам итте:

— Чибәрлеге бар, баһадирдай гәүдәсе, дисеңме, килешкилбәте, дисеңме. Аның кай җире яратмаслык? Ир — ир инде ул. Менә бәбкәчләрегез булыр, уртак куанычлар бәйләр үзегезне.

***

Шәүкәт Шәмседоханың бердәнбер улы булып, иркә үсте. Укуны өнәмәде, яхшы укымады. Ике сыйныфтан соң мәктәпкә башка бармады. Аның каравы бик иртә кулына балта, чүкеч алды.

Шәүкәт, чыннан да, эшкә оста, нәрсәгә генә тотынса да, җиренә җиткереп, пөхтә итеп эшли, өлгер. Балта эше, дисеңме, тимер-томырмы — барысын да булдыра. Ике ел кеше өстендә фатирда яшәгәннән соң, алар Фирганә читендә йорт сатып алдылар, аны адәм рәтенә кертеп, каралты-кураны яңартып, мунча салып, җай гына яши башладылар.

***

Рәйханның беренче баласы үле туды.

— Авыр тартмалар күтәреп, баланы харап иттең,—диде Шәүкәт һәм эшен ташлап, Рәйхан эшли торган кибеткә йөк ташучы булып керде.

Берсе балта эшенә, икенчесе аш-суга оста. Алар шулай килешеп кенә тормыш итә башладылар. Тагын бер елдан Рәйхан кыз тапты.

Бергә яши башлагач, икесе бергә сатып алган кыйммәтле зур әйбер —телевизор булды. Аны Шәүкәт тиз генә рәтләп, антеннасын урнаштырды. Бу көнне алар үзенә күрә бер бәйрәм ясадылар. Балалар түземсезлек белән зәңгәр утның кабынуын көттеләр. Рәйханга ни өчендер экраннан Алмалы урамнары күренер сыман тоелды.

Шәүкәт телевизорның кабызгычын борды, бүлмәгә матур гына үзбәк музыкасы таралды. Шулчак Рәйханның күңелендә көчле сагыну хисе кабынды. Аның «Рәйхан» көен ишетәсе килде. Бу — татлы бер сагыну иде. Рәйхан телевизор каршысына утырмады, өстәлгә самавыр, касәләр һәм кайнар пәрәмәчләр куйды. Үзе күңеле белән еракта калган Алмалы урамнарында, су буйларында йөрде.

Эштән арып кайткач, кичләрен алар дүртәүләп зәңгәр ут каршысында уздыра башладылар. Балаларга кызык, төрле тамашалар, цирк, концертлар. Ләкин Шәүкәт белән Рәйхан арасындагы суык бушлыкны берни белән дә тутырып булмады. Араларындагы бу суыкны Шәүкәт күптән сизде. Кайчандыр шат күңелле Шәүкәт тора-бара сүзгә саранланды, кызып китүчән булып китте. Салып та кайткалый башлады. Андый көннәрдә Рәйхан аны бөтенләй танымый. Шәүкәт мактана, мин герой, дип күкрәк кага, түрәләрне, әллә кемнәрне сүгә, хатын-кызга булган нәфрәтен төрле тәмсез сүзләр белән бизәкләп аңлата.

Андый көннәрдә Рәйханның кемнәрдәндер ярдәм сорап кычкырасы килә. Аның йөрәген үкенү яндырып ала. Болай яшәп булмый. Нишләргә?..

***

Еллар шулай үтә торды. Бер караганда уңай гына барган тормыш икенче караганда кара тавыш, сугыш-талашка әйләнде. Шәүкәт көн-төн эчә, сугыша. Рәйханның тормышы тагын тәмугка әверелде. Җил-давыл үтә, тагын көйле генә тормыш дәвам итә.

Рәйханның бар куанычы — балалары. Энҗе урта мәктәпне тәмамлап, Казанда югары уку йортында, Эльвирасы Алмалыда медучилищеда укый. Ялгыз калган вакытларда Рәйхан балаларын юксына. Аларны күреп сөйләшү теләге үзәкне өзә.

Ләкин иң аяныччы — Шәүкәтнең түбән тәгәрәве. Ул кешелек сыйфатларын югалтып, яшәүнең тәмен, ямен югалтып бара. Аны ничек бу халәтеннән коткарырга?

Ул көнне Шәүкәт айнык иде. Рәйхан аның белән сөйләшергә булды.

— Шәүкәт, Алмалыда зур төзелешләр башланган икән. Төпләнеп эшләр эшең юк, әллә без дә шунда кайтабызмы? Эшләрбез, фатир алырбыз.

***

Алар, өйләрендә кеше калдырып, Алмалыга кайттылар. Шәүкәт яңа төзелешкә балта остасы булып эшкә керде, Рәйхан кибеткә урнашты.

Алмалы урамнары һәрвакыттагыча тып-тын, ара-тирә таш йортлар күләгәсеннән бер-ике кеше үтеп китә. Әллә җәйге тынчу һава аларны таш пулатларына куып керткән?

Менә кайнар кояш астында йомшара төшкән асфальттан кәс-кәс атлап, таш диварларда яңгыраган аяк тавышын тыңлый-тыңлый, урам буйлап Рәйхан бара. Әле бер, әле икенче якка карангалап ала. Сагынылган. Ул өрфия челтәрләр эленгән зур-зур тәрәзәләрдә үзенең гәүдәсен күреп елмая.

Көтмәгәндә ул ерактан җил-җил атлап килүче Мулланурны күреп алды. Күксел чалбар, кыска җиңле шакмаклы күлмәктән, култык астында кара папка. Ул хәзер зур начальник, күрәсең.

Рәйханның йөрәге бер мизгелгә тибүдән туктады, тыны кысылды. Каршы барыргамы, юкмы? Юк, Рәйхан, син аның белән очрашырга тиеш түгел, диде аның аек акылы. Берни уйлап тормый Рәйхан ачык капка эченә омтылды. Мулланурның үтеп киткәнен капка артында көтеп карап калды. Рәйхан бу юлы үзенең тиле йөрәге белән көрәштә җиңеп чыккан аек акылына куанды.

Ничә еллар инде алар күзгә-күз очрашмадылар. Икесенең дә гаиләләре бар. Мулланурның өч улы тупырдап үсә, Рәйханның ике кызы.

***

Очрашу көтмәгәндә булды. Шәүкәт юк-бар эш белән өйдә

калды. Рәйхан кибетләргә чыкты. Сеңлесенең кызы кияүгә чыга, бүләкләр кирәк. Ул уйчан гына үзәк урам буйлап атлады. Бер өйнең тәрәзәсеннән үзәкне өзеп татарча көй яңгырый:

«...Әй, исемең матур, кемнәр куйган?..»

Рәйхан әллә нишләп китте, аның җыры, яшьлек җыры. Аңа кайчандыр канатлар куйган, күкләргә ашырган җыр.

Рәйхан кибеттән бүләкләр алып урамга чыкты, кулында зур гына төргәк. Шулвакыт аның янына ук юл кырыена бер җиңел машина килеп туктады. Машинадан теге көнне күргән шул ук шакмаклы кыска җиңле күлмәк кигән Мулланур килеп чыкты.

Ул! Рәйхан бер мәлгә каушап калды, туктады. Күңелен ниндидер шатлыклы иләс бер хис биләп алды.

Мулланур туп-туры Рәйханга таба атлады.

— Рәйхан! Синме соң бу?

Рәйхан оялчан гына елмаеп аңа карады, колагы шаулады, күз алды караңгыланып китте.

— Ничә еллар сине күрмәгәнгә! Кайчан кайттың?

— Кайттыгыз, диген, мин берүзем генә түгел, ирем Шәүкәт белән.

— Кая соң Шәүкәтең? Машинага утыр, өеңә илтеп куябыз.

— Юк, юк, рәхмәт, утырмыйм.

— Әллә куркасыңмы?

— Яхшы түгел бит, Мулланур.

Рәйхан Мулланурның машинасына утырмады.

— Көт, мин килермен.

— Килмә, кирәкми.

Берничә көннән, чыннан да, Мулланур аларга килде. Шәүкәт белән Мулланур таныштылар, сөйләштеләр. Яшерен сер юк иде. Мулланур аларны ял көнгә табигать кочагына чыгарга чакырды.

***

Көннәр бер-бер артлы шулай агылдылар да агылдылар. Бер көн икенчесенә охшамады. Кышкы көннәр бигрәк күңелсез булып тоелды Шәүкәткә. Бу да булдымы тормыш?—дип уйлап ята иде ул төннәрен. Еш кына аның күз алдына киң урамнары, парклары, чәчәкле бакчалары белән

Ташкент килеп баса. Анда калган дуслары исенә төшә. Мәрхүмә беренче хатыны, аерып җибәргән икенче хатыны күңеленә килә. Аны кыйнаган, җәберләгән чаклары исенә төшә. Ә Рәйхан? Рәйхан аны яратмый, түзә генә. Ул чибәр, уңган, үткен һәм шаян. Ташкентта яшәгәндә, мәҗлесләрдә Рәйхан аның турында җыр җырлый иде. Шәүкәт ул җырны исенә төшереп, елмаеп куя.

Аклы ситсы күлмәгенең
Якалары бумажный.
Үзе болай ничава да,
Характеры неважный...

Төнге тынлыкта комод өстендәге будильникның бертуктаусыз текелдәгәне ишетелә. Шәүкәт бик озак йоклый алмый, уйланып ята. Тамагы кытыкланып, аракы эчәсе килеп куя. Кем белән эчсен соң ул? Дуслары еракта калды, Мулланур белән әллә ничек.

Ул әкрен генә урыныннан торып, ишегалдына чыкты, тәмәке кабызды. Ул соңгы вакытларда үзен читлектәге кош кебек хис итте. Талпынасы иде, очып китәсе иде Ташкентка...

Табигатьтә инде яз. Күкне томалап шыксыз болытлар йөзә, йолдызлар күренми. Әллә шуңа, әллә башка сәбәптән аңа тагын да күңелсезрәк булып китте. Әллә соң, чыннан да, хыялларда гына була торган матур тормыш аны читләтеп үткәнме? Ул үзен бик ялгыз, беркемгә кирәкмәс кеше итеп хис итте.

Аларга сирәк кенә булса да Мулланур килгәли.

Рәйханның туган көне иде. Мулланур, зур гына сумка тотып, аларга килеп керде. Исәнлек-саулык сораштщы. Шәүкәт белән кул биреп күреште. Ни өчендер өйдә бәйрәмчә ямь юк иде.

— Сез нәрсә, әллә ызгыштыгызмы?— диде шаяртып.

— Бездә көн дә ызгыш, көн дә талаш,— диде Рәйхан кыенсынып кына.

— Ник? Ни бүлешәсез?

— Бүлешер нәрсә безнең һаман да шул Ташкент инде.

— Ташкент?

— Шәүкәтнең Ташкент, Ташкент диюләре минем үпкәбавырга таш булып утыра инде.

Иелгән башын ике кулы белән учлап утырган Шәүкәт шунда телгә килде:

— Мин, Мулланур, Ташкентка кайтып китәм. Рәйхан теләсә нишләсен, мин монда калмыйм, китәм. Рәйхан сүзе белән монда килеп, кыш буе каткан сырма кидем, олтанлы ката сөйрәдем. Туйдым, җитте. Ул тюремщик киемнәрен бүтән өстемә саласым юк. Китәм булгач, китәм.

— Я, ярар, Шәүкәт, уйлашырбыз, сөйләшербез. Тик бүген Рәйханның туган көне бит. Бераз гына шәраб исе чыгарыйк, тәбриклик.

— Рәхмәт, Мулланур, алай да син килеп кердең әле. Югыйсә, кая барып бәрелергә белми йөри идем. Шәүкәткә аңа Ташкенттан башка берни кирәкми.

Шул арада Рәйхан мичтән кайнар бәлеш чыгарып куйды, өстәлгә тәлинкәләр китерде. Мулланур сумкасыннан колбаса, балык консервасы һәм бер шешә шампан шәрабы алды.

— Шәүкәт, сал әле эш киемнәреңне, ки әнә яңа күлмәгеңне,— дип елмайды Рәйхан иренә. Шәүкәтнең дә йөзе яктырып китте.

— Ягез өстәл янына! — тиз генә Рәйхан өстәлгә бәллүр бокаллар куйды, Мулланур аларга чемердәп торган шәраб койды.

— Шәүкәт,—дип башлады Мулланур басып, кулына шәраблы бокалны тотып, — минем сезгә беренче килүем түгел, бер-беребезне яхшы аңлыйбыз, сүзләремне гаепкә алмассың. Мин бүген үземнең яшьлек дустым Рәйханны туган көне белән котларга дип монда ашкынып килдем. Син, Шәүкәт, бик бәхетле кеше, син... — Мулланур матуррак сүзләр эзләде, малайларча каушады. — Гомер юлдашы булырлык менә дигән кеше тапкансың — Рәйханның керсез күңеле, кайнар олы йөрәге бар. Ул аны сиңа бүләк иткән. Сакла син бу изге хатынны. Ярат. Мин Рәйханны туган көне белән, ә сине бәхетле булуың белән котлыйм.

— Рәхмәт, Мулланур,—диделәр Шәүкәт белән Рәйхан беравыздан.

Озак кына сүзсез торганнан соң, Шәүкәт телгә килде:

— Без Фирганәдә бераз яшәгәннән соң, Рәйхан белән Ташкентка күчтек. Ташкент зур, матур шәһәр генә түгел,

ул минем туган шәһәрем. Сагынам мин, Мулланур, Ташкентны. Үзең уйлап кара, оҗмах кебек җирне шушы йолкыш, ярымҗимерек Алмалыга алыштыр инде. Монда тормыш бик авыр бит, ярый инде, кышны ничек кирәк — алай чыктык. Яз килде. Тик яз да монда Ташкенттагыдай түгел. Ямь юк миңа монда, мин монда саргаеп үләчәкмен.

Бу көннән соң алар озак та тормый китәргә җыендылар. Әйберләрен контейнер белән озаттылар. Мулланур аларны ерак юлга якын дусларча озатып калды. Саубуллашканда шатлыгы эченә сыймаган Шәүкәт Мулланурга:

— Ярый, дус, без синең изгелекләреңне беркайчан да онытмабыз. Җәй саен кайтырбыз. Киләсе елда күрешкәнгә кадәр хуш!— диде һәм алар ирләрчә кысып кочаклаштылар.

— Кайтыгыз, ел да кайтыгыз!

— Кайтырбыз, һичшиксез, кайтырбыз,— диде Шәүкәт, — шулай бит, Рәйхан.

Әмма Шәүкәткә кабат Алмалыга кайту насыйп булмады. Ул Ташкентка кайткач, озак яшәмәде. Башына кан савып вафат булды. Аны соңгы юлга озатканда Рәйхан:

— Ташкент, Ташкент, диде, җирседе. Әҗәле тартып кайтарган икән,—дип елады.

***

Югалтулар — табу түгел шул. Кешене югалту сары сагыш, кара кайгы тудыра. Рәйхан да, Шәүкәт вафат булгач, аны җирләгәч, бик ямансулады, йөрәге сулкылдады. Кулы эшкә бармады. Ул үз-үзенә урын таба алмас дәрәҗәдә авыр кичерешләр белән яшәде. Шәүкәт бик яшь иде бит әле. Яшәргә дә яшәргә иде. Юк шул, тыңламады. Сөенечтән дә эчте, эше аз гына кире китсә дә эчте, кан басымы күтәрелде, тыны кысылды. Тора-бара күзләре күрмәс булды, аяк-куллары хәрәкәтсез калды. ЙаХода! Нинди аяныч үлем! Ходай биргән гомереңне яшәп бетерергә теләмичә, үз теләгең белән үлем тырнагына барып кер инде. Рәйхан шундый уйлар белән газапланды.

Уйлар, уйлар... Хәзер ул япа-ялгыз, бары уйлары гына тынычлык бирми. Шәүкәт белән яшәгән елларны, балаларның кечкенә чагын, кызы тугач Шәүкәтнең куануларын исенә төшерде. Ничек кенә күз алдына китерсә дә, бер генә

яман гадәте дә, әйткән начар сүзе дә килмәде аның күңеленә. Бары тик яхшы якларын, сирәк кенә булса да әйткән ягымлы сүзләрен исенә төшерде. Яратам бит мин сине, дия иде, кадерлем, дия иде. Әллә соң Рәйхан үзе аның кадерен белмәдеме? Ник бик яшьли китте соң ул дөньядан?

Шәүкәттән башка аңа бик ямансу иде. Рәйхан үзенең йомшак мендәрендә бераз уйланып ятты. Аннан торып утырды, сузылып кына радионы ачты. Шунда, ни гаҗәп, яшьлеген, туган ягын искә төшереп, аның өчен бик тә кадерле булган көй яңгырады. Ул тын да алмый җырны тыңлады:

«...Әй, исемең матур, кемнәр куйган?..»

Бу көнне Ташкент эфиры татар җырларын яңгырата иде. Рәйханның бераз гына күңеле күтәрелеп китте. Бөтен кайгыларын таратып җибәреп, җилгә очырып, яңадан яши башлау хисе биләп алды аны. Исәннәргә яшәргә кирәк!

Алдагы тормыш Шәүкәтсез генә дәвам итәчәгенә күнегергә кирәк иде аңа.

Эчпошыргыч иртәләр, шундый ук көн, кич, төннәр кабатланды. Нинди аяныч тормыш! Шундый көннәрнең берсендә тагын туган як дигән үзәк өзгеч хис дулкын булып Рәйханның күкрәген ярып керде. Арып-талып, эсседән әлсерәп ул эштән кайтты. Йомшак урынына башын төртүе булды, инде күзенә йокы эленә дигәндә генә, күкрәк эчендәге йөрәге убылып киткәндәй булып, калтыранып алды. Ул урыныннан сикереп торды һәм ачык тәрәзәдән караңгыга төбәлде. Җылы якның йомшак киче аны әллә нишләтте.

Җир исе, агачлар, җимешләрнең хуш исе аны исертеп җибәрде. Ул төнге йолдызлы күккә карады һәм кинәт, күңеле җилкенеп, аның очар кош буласы килеп китте, бу хистән аның йөрәге кысылып куйды. Еракта калган туган җире, яшьлек кичләре, дуслары, Муллануры тагын искә төште. Тора-бара мондый әсәрләнүләр ешайганнан -ешайды. Әллә кайчан булып узган хәлләр, шулар белән бәйле кичерешләр, кайгы-хәсрәтләр, күз яшьләре күңелендә яңарды.

Муллануp Шәүкәтнең вафат булуын белми бит, хәбәр итәргә кирәк, дип уйлады Рәйхан, күңеле түренә җыелган

әрнүләрдән бушанасы килеп. Әгәр телефон аша сөйләшергә заказ бирсәм, сөйләшеп булырмы?

***

—Алло!— телефон мембранасын калтыратып, Мулланурның карлыккан тавышы яңгырады.

Рәйханның телефон трубкасын тоткан кулы калтырады, тез буыннары йомшарды, менә авам, менә авам дигәндәй, ул бераз чайкалып алды да, урындыкка утырды.

— Алло! Алмалы! Алмалы!

— Алло! Рәйхан! Синме соң бу?

— Мин бу, Рәйхан. Мин, алло, алло!

— Саумы? Син кайдан, Рәйхан?

— Ташкенттан.

— Үзең генәме?

— Үзем генә. Шәүкәт... — Рәйхан сүзен дәвам итә алмады, кычкырып елап җибәрде.

— Елама, Рәйхан. Нәрсә булды?

Рәйхан Шәүкәтнең кайчан һәм нинди хәлләрдә вафат булуын сөйләде, үзе елады, үзе ничек тә үзен кулга алырга тырышып, бераз тынычлангач:

— Нишлим, Мулланур? Киңәш бир,— диде.

— Бирешмә, Рәйхан, син нык кеше. Булдыра алсаң, илгә кайт, ташламабыз,—диде Мулланур.

Озак уйланды Рәйхан. Кайт, дисең син, Мулланур. Бу кадәр әйберне, өйне нишләтергә? Ул өй эчен күздән кичерде. Менә Шәүкәт белән бергә сатып алган әйберләр: комод, шкаф, диван, карават, суыткыч, телевизор. Аларны Шәүкәт уенчык әйберләр кебек кенә кузгатып төягән иде. Шәүкәттән башка аларны ул ничек йөртер.

Кайгырма, диде шунда күңеле, төяүчеләр табылыр. Бөгелеп төшмә, син нык кеше, диде бит Мулланур да. Никадәр кайгылар күрдең, никадәр күңел авыртуларын җиңдең бит. Монысын да җиңәрсең.

Бу уйлар Рәйханның күңелен юып җибәргәндәй булды, аңа бераз җиңелрәк булып китте. Күңелендә якты, ныклы хис — үз-үзенә ышаныч хисе уянды.

Шәүкәт вафатыннан соң ел ярымнан Рәйхан, чыннан да, Алмалыга күченеп кайтты.

***

...Мулланурның танышы Таһир Шакирович Рәйханның кечкенә фатирының матурлыгына хәйран калды. Оҗмахтай җылы, якты бүлмә, дип уйлады ул, тәрәзә пәрдәләре, өстәл, карават җәймәләре, вазадагы чәчәкләрне күздән кичергәч.

— Кунаклар, ник сүзсез калдыгыз? Әйдәгез өстәл тирәсенә,— диде Рәйхан җиңелчә каушый төшеп. — Менә кәнәфи, урындык. Мулланур, кая утырасың?

— Мин кая утырсам да ярар. Ә олы кунакны — кәнәфигә. Алар өчәүләп түгәрәк өстәл тирәли утырдылар.

— Рәйхан, мин сезне таныштырмадым бит әле. Бу — Таһир Шакирович, Казаннан. Без Казанда бергә укыган идек. Ул Казанда хәзер, зур кеше. Менә безнең районга газ җибәрү тантанасына килгән, шунда очраштык. Ул синең минем өчен кем икәнеңне белә, минем аңардан яшерен серем булмады. Яшь чак, сине сагынып, саргайган еллар иде... Менә безнең мәхәббәткә быел сабан туе көннәрендә илле ел тулды. Белгән кебек ул да Алмалыга килгән. Нинди кызыклы очрашу. Бу газ җибәрү тантанасы гына түгел, бу — юбилей! Шулаймы, Рәйхан?

Мулланур Рәйханның күзләренә карап елмайды. Ул караштa яшьләрчә шашып сөю дә, бәхетле куаныч та, үткән гомер өчен үкенү, барысы өчен гафу үтенү хисләре — барысы да бар иде.

Дуслар ипле генә гәп кордылар.

— Без, Таһир Шакирович, шул еллардан бирле Сак белән Сок кебек бер-беребезне бер күрергә зар-интизар булып, сагынышып яшәдек. Мин бик күп төрле эшләрдә эшләдем. Без танышканда мин трактор хисапчысы гына идем. Шулай бит, матурым?

— Әйе, шулай иде бугай.

— Исеңдәме, егерме чакрым араны кичләрен синең белән бер күрешү өчен чабып кайта идем.

— Исемдә, исемдә...

— Аннан кара таңнан торып, тагын шул араны чабып үтә идем. Яшь чакта йөрәк кайнар иде минем...

Рәйхан ипле генә елмаеп куйды.

— Көнче идең, усал идең...

— Йә, йә, аларны искә төшермә, шул көнләшү дигән явыз аерды да бугай безне.

Мулланур бераз уйланып утырды.

— Хисапчыдан бригадирга, бригадирдан колхоз рәисенә күтәрелдем. Аннан институт, менә хәзер зур хуҗа,— диде дә Мулланур, затлы текә маңгаен сыпырып алды. — Әле ялга чыгарга уйламыйм, көчем, гайрәтем бар.

— Ярар, ярар, мактанып та җибәрдең инде. Мактанмый булмыймы?

— Юк, Рәйхан, бу минем тормыш юлым, мин үткән гади дә, катлаулы да юл.

Мулланур тагын сүзсез калды һәм, тирән сулыш алып, сүзен дәвам итте.

— Сине уйлап, сиңа омтылып, синсез җанны кая куярга белми йөргән еллар... Әйе, мин гомерем буе мәхәббәт эзләдем. — Мулланур кунакка таба борыла төшеп сүзен дәвам итте. — Рәйханны югалткач, аңа аз гына булса да охшаган кеше эзләдем мин. Күп хатыннар күрдем, яшермим. Берсе дә Рәйханны алыштыра алмады. Мәхәббәт бер генә мәртәбә була икән ул, мин шуны аңладым.

— Ә хатының?— дип сүзгә кушылды тыныч кына тыңлап утырган кунак.

— Хатын? Хатын — хатын инде ул. Яратсаң да — хатын, яратмасаң да —хатын. Балалар анасы. Зарланмыйм, минем хатын сабыр, эшчән, йорт хуҗасы... димме? Ул — башка.

Мулланур озак кына башын иеп сүзсез утырды. Дулкынлануданмы, аның бите буйлап тире агып төште. Ул кесәсеннән кулъяулык алып битен озак-озак сөртте һәм ярымпышылдап кына тагын сөйли башлады.

— Без Рәйхан белән бик күп еллар бер-беребездән ерак идек. Ул Үзбәкстанда, мин — монда. Ә күңелләребез белән без гел бергә булганбыз. Ул да мине уйлаган, сагынган, мин дә гомерем буе аны юксындым. Без бер-беребез өчен яратылган булганбыз, тик язмыш дигән усал өермә безне рәхимсез рәвештә аерган...

— Йә, ярый, дуслар, үткәннәрне иске төшерү — изге эш. Сезне юбилей белән котларга кирәктер бит,— диде Таһир Шакирович.

Мулланур шампан шешәсен ачып бәллүр бокалларга шәраб койды.

— Я, фәрештәм! Я, матурым, — дип Мулланур бер бокалны Рәйханга сузды.

Таһир Шакирович кулына шәраблы бокалны алып аягүрә басты:

— Дөресен әйтим, ничә еллар яшәп, нинди тантаналарда булып, мин беренче мәртәбә мондый юбилейда сүз әйтәм. Бу — гадәттән тыш күренеш. Нинди генә сүзләр табарга соң олы мәхәббәткә мәдхия җырлар өчен?

Кунак күңел дәфтәреннән актарып чыгарып, күп кенә күренекле затларның, философларның мәхәббәт турындагы искиткеч матур, тирән мәгънәле сүзләрен мисал итеп китерде. Чемердәп торган шампан шәрабы аларның күңелен ачты, йөзләрен нурландырды.

Рәйхан бераздан комод өстендә торган магнитофон төймәсенә басты. Бик матур көй яңгырый башлады һәм искиткеч йомшак тавыш белән яшь җырчы җыр сузды:

Ничә еллар үткәч,
Онытылып беткәч,
Очраштырдың нигә
Син, язмыш?
Ул төзәлгән яра
Инде тагын яңа,
Күзләреңдә бары тик
Сагыш...

Рәйхан җырчыга кушылып җырлый башлады:

Эзлим, сүзләр эзлим,
Ни дип җавап бирим?
Язмыш, моны
Ничек аңларга?..

Калын матур тавыш белән Мулланур да җырга кушылды. Аларның тавышлары шулкадәр бер-берсенә тәңгәл килә, гүя алар гомер буе шулай җырлап кына яшәгәннәр!

Инде гомер үткән,
Без бүтәннәр икән.
Син бит минем
Яшьлек хатам ла...

Җыр дәвам итте. Алдагы сүзләргә Мулланур үзе генә кушылды.

Син бик төрле, язмыш,
Син бик серле, язмыш.
Синдә минем
Керсез үткәннәр...

Аннан Рәйхан кушылды. Кунак җыр сүзләренең тирән эчтәлеген, нәкъ алар язмышы турында булуын уйлап тын гына утыра иде.

...Олы хисләр сүнми,
Онытуны белми.
Бер очраша икән көткәннәр...

БУРАНЛЫ ЮЛЛАР

Быел Фәһимә туган авылына озакка кайтты. Сагынып, туган ягының һавасын тансыклап кайтты. Агыйдел буйларын буйларга, комнарында кызынырга...

Таң атып, ерактагы таулардан яшел үзәнгә кояш үзенең беренче нурларын сибә башлау белән, Фәһимә яланаяк таныш сукмактан Агыйделенә атлады. Учма-учма сакалларын тирбәндереп ярдан томан күтәрелә, кәҗә талы ботакларына кагылып-кагылып, ак кисия шәл кебек яр буйлап шуыша. Тирә-юньдә җан әсәре күренми, Агыйделнең теге ягындагы йөгәнсез тайлар гына экияти җанварлар булып тоела.

Агыйделкәй элеккечә тоныктүгел икән... Яр буенда да гәрәбәдәй сары ком түгел, ниндидер ят кара балчык, сыланчык баткак. Кая соң мондагы киң-киң комлыклар? Фәһимә бала чакта йомшак кайнар комга бата-бата чабулый торган иде. Кая соң монда чи-чи килеп бертуктаусыз әрлебирле оча торган керәшәләр? Боларның барысы юкка чыккан. Агыйдел дә элекке Агыйдел түгел, ул Фәһимәгә киңрәк тә, шомлырак та булып күренде.

— Нишләдең, Агыйделем? Ник син бик үзгәрдең?

— Син дә үзгәргәнсең. Калынайгансың, чәчләреңә чал төшкән, күзләрең дә начар күрә башлаган — борын өстеңдә күзлек. Әйе, заман җилләре елгаларны гына түгел, кешеләрне дә үзгәртә. Күпме еллар үткән бит! Йә, сөйләп җибәр, син соң ничек гомер иттең? Минем яннан киткәч ничек яшәдең? Хисап бир!..

—Ничек яшәвем турында хисап, дисең инде син...

...Фәһимәнең үз гомерендә, кемнәр алдында ничәмә-ничә мәртәбәләр хисап тотканын бер Ходай үзе генә беләдер инде. Әмма туган җире, сөекле Агыйделе алдында хисап тоту, ай-һай, җиңел булыр микән?Ниләр генә баштан узмаган да, нинди генә кешеләр белән очрашылмаган!

Укыган елларында ачлыктан тилмергән көннәрнең, бер кыерчык ипекәй өчен учына акча йомарлап, чиратларда басып торган сәгатьләрнең санын кем исәпкә алган?!

Шәһәр белән туган авылы арасын ничә тапкыр чабата киеп җәяүләп үтүләрне кем санаган?! Ничә китап укылган, ничәсе укылмый калган, ничә инша язылган, шигырь ятланган, җыр җырланган, ничә мәртәбә сөю, мәхәббәт килгән, хат язылган, ничәсе күз яшьләренә манчылган? Аларны кем санап барган соң?!

Болары — яшьлектә...

Ә эш, хезмәт юлы — үзе ярты гасырлык чор гаять сикәлтәле, авыр булып, сырлы-сырлы каршылыклар, уңышлар һәм уңышсызлыклар, үтереп макталулар һәм кара гайбәтләр, биек-биек тауларга авырлыклар белән менүләр һәм мәтәлеп төшүләр, җиңүләр һәм җиңелүләр, агарулар һәм кызарулар, горурлану һәм рәнҗешләр — берберсен туктаусыз алыштырып торган.

Анысы — тормыш дип аталган, Ходай язган, беркемненә дә охшамаган олы юл.

Аңа тулы хисапны ничек бирергә?

Фәһимә күзләрен йомды. Шунда кемнеңдер бик моңлы итеп җырлаганы ишетелде:

Агыйделкәй алкын,
Суы салкын,
Каз-үрдәкләр каршы йөзалмый...

Агыйдел өстендә дулкыннар шаулаштылар, ярга килеп-килеп бәрелделәр.

— Бу синең әнкәң җыры. Хәтерлим, синең газиз әнкәң дә, газиз әткәң дә миндә, шушы дулкыннарда тибрәлеп үстеләр. Тормыш юллары минем күз алдымда үтте. Язмышлары минем белән бәйле булды. Мин аларны ач үлемнән коткардым, балыгымны бирдем, маллары өчен печәнне мул үстердем. Синең дә балачагың шушы дулкыннар кочагында үтте. Ничә мәртәбә миндә су коендың, әткәң көймәсендә ничә мәртәбә минем дулкыннарны ярып үттең — бары да исемдә. Синең җырлаган җырларыңны да хәтерлим:

Аклы күлмәк бик күп кидем,
Кимәдем айлыларын.
Агыйделгә салыйм микән
Башымның кайгыларын?..

Бу җырны син әнкәң Бибиәсмадан отып алган идең. Ул бик күп мөнәҗәтләр, җырлар белә иде, яратып, моңланып җырлый иде. Шуңа да ул бик озын гомерле булды...

***

Күпне күрде Бибиәсма. Уртача гына тормышлы, күп балалы гаиләдә баш бала булып дөньяга килде. Тукмак буе

булу белән энеләрен, сеңелләрен карады, бишек тибрәтте. Чиләк биеклеге булу белән, иңенә көянтә салып су ташыды. Унҗидесе тулар-тулмас, Агыйдел аръягындагы бер авылга, күрмәгән-белмәгән, колга озынлыгы ябык бер егеткә димләп кияүгә бирделәр. Яратмады, ярата алмады Бибиәсма аны.

Ачлык иде, авыр еллар иде. Ире Герман сугышында юкка чыкты, хаты-хәбәре булмады. Бибиәсма ике баласы белән ятим калды. Яшьлектә алган аз-маз белемен җигеп, ул кышның озын кичләрендә кыз балаларга сабак бирде. Биата-биана белән яшәде, аларга хезмәт итте.

1920 елның җәе иде. Кызу урак өсте. Бик озак арыш урып, ял итәргә утырган җирендә, Бибиәсма көлтәгә башын куеп, йокыга талды. Кызу кояш аның битен иркәләде, күз төбендәге яшен киптерде. Җиткән арыш исе белән талгын җил аның ак яулыгы астыннан маңгаена төшкән чәченә кагылды. Шулчак битендә кемнеңдер җылы бармакларын тоеп, Бибиәсма уянып китте, ләкин күзләрен ачарга ашыкмады. Гомерендә беренче тапкыр үз битендә тойган ул җылы бармакларның рәхәтенә, тын алудан туктап, ыңгырашып куйды, кулларын күзенә китереп, кояшны каплады.

— Кояш бәрмәсен үзеңне, Бибиәсма...

Бу күршесе Сәрвиҗамал тавышы иде.

Бибиәсма, күзләрен ачып, зәп-зәңгәр күк йөзенә карады. Биектә-биектә кабарышкан ап-ак болытлар сибелгән. Бибиәсма бу матурлыкны күреп шаккатты. Йа Хода! Нинди матурлык, нинди биеклек! Ул сүзсез генә урыныннан торды, күлмәк итәген, оегын каккалады.

— Нәрсә бар, күрше?

— Кояш суга күрмәсен, дим.

Сәрвиҗамал тирә-ягына каранып алды. Беркем дә юклыгына ышангач, ул Бибиәсмага якынрак килеп, бик мөһим сүзе булуын сиздереп, күзләренә карады.

— Бибиәсма,—диде хатын пышылдап һәм серле итеп. — Сиңа әйтәсе сүзем бар иде. Якын итеп, сердәш итеп кенә. Ачуланмасаң... Үпкәләмәсәң... Сине яратып... Кызганып...

— Йә, нәрсә, сузма, күрше, әйт сүзеңне.

— Сине кияүгә сораучы бар...

Бу көтелмәгән сүздән Бибиәсманың чигәләре тартышып куйды, тәне чымырдады! Ялгыш ишетмимме, дигәндәй, күршесенә бер сүз дә әйтә алмыйча, туп-туры аңа карады. Өндәме бу, әллә төштәме?

...Сөйләшү, димләү, киңәшләшүләр озакка сузылды. Бибиәсма кисәк кенә кире дә какмады, ашык-пошык ризалыгын да бирмәде. Чигәсен ярырдай булып, башында уйлар чайпалды. Аның авыр язмышында юлдаш булырга теләүче — кем ул? Акылы? Фигыле? Йөзе-кыяфәте? Нәселнәсәбе? Олымы-яшьме? Бибиәсма аны ярата, үз итә алырмы? Балалары ни әйтер? Биана-биата бу хәбәрне ничек кабул итәр? Каргамасლармы? Рәнҗемәсләрме? Яңа җирдә җәберзолымга дучар булмасмы? Сораулар, сораулар...

Бибиәсманы тормыш юлдашы итәргә теләүче ир аңардан ерак булмаган Наратлы авылыннан икән. Үзе солдат хезмәтендә чакта хатыны вафат булып, ике баласы ятим калган, егерме тугыз яшьлек, холкы-фигыле яхшы, куркәм генә кеше икән. Сәрбиҗамал ирне шулай бәян итте. Тик бер генә кимчелеге бар — гражданнар сугышында контузия алып, колагы катыланган.

***

Озакламый, кайната-кайнана ризалыгы белән, өч җанга тияр өлешен алып, Бибиәсма туган өенә, ата-анасы куышына кайтып төште. Атасы Каһирның болай да зур гаиләсе тагын ишәйде. Артык кашыклар да, мәшәкатьләр дә артты.

Ятимнәр бик ябык, сөякчел балалар иде. Кәҗә сөте эчереп, мунчада мәтрүшкәле каен себеркесе белән чабып, балаларны бераз аякка бастырдылар.

Ел башында, олы кырлачта, Бибиәсма, ике ятимен ияртеп, Наратлы авылына, Гыймалелисламга кияүгә чыкты. Анда аны, күзләрен ятимлек пәрдәсе каплаган, юаш һәм хәлсез өч-дүрт яшьлек ике ир бала каршылады. Аларның моңсу күзләре, мөлдерәмә яшь аша, булачак әниләренә илереп төбәлгәннәр иде. Ике малай — Мәхиян һәм Барый. Үзенекеләр бер-ике яшькә олырак — Сәлимҗан һәм Хәсәнҗан.

Бибиәсма яңа йортка бик тиз ияләште. Көче-куәте җитәрлек, Ходай биргән сәламәтлеге, эре сөякле гәүдәсе, юан беләкләре — ким-хур булырлык түгел. Ул себерде, юды,

кырды — Гыймалелисламның дөньясын берничә көндә гөл итеп куйды. Балалар да өстәл тирәли утырып, берсеннән икенчесе көнләшеп, ярыша-ярыша, кысыр умач ашадылар, чамалап кына киселгән арыш ипекәен валчыгын да калдырмый ашап бетерә башладылар. Баш калкыттылар, үсеп, исәеп киткәндәй булдылар.

Егерме бернең язы бик иртә башланды, гаять кызу көннәр торды. Кояш бертуктаусыз кыздырганлыктан, кар бик тиз эреп бетте. Апрель урталарында ук агачлар яфрак ярды, җир өсте яшеллеккә күмелде. Моңарчы күрелмәгән, бик иртә килгән яз гаять аянычлы булды. Ачлык килде. Амбарда чәчүлек орлыктан башка берни калмады. Юа, кузгалак, ат кузгалагы сабыйларның эченә ярамады. Эч китүен туктату өчен Бибиәсма нинди генә әмәлләр күрсә дә, тәмам хәлсезләнеп, сөяккә калып, малайлар берсе артыннан берсе дөнья куйдылар.

Бер-берсенә ияләшеп тә өлгермәгән ир белән хатын арасы бераз суына төште. Бибиәсма үзен бик бәхетсез тойды, балаларның болай булуына үзен гаепле санады: карый алмады, саклый алмады, балаларны кара гүргә тыкты. Гыймалелислам да үзенә урын тапмады, ишегалдына чыкса, кулы эшкә ятмады. Җитмәсә, ничә айлар инде бер тамчы яңгыр төшми. Чәчкән икмәге борын төртү белән кипте, көйде. Ажгырып ачлык килүен сизде ирнең күңеле.

Ул еш кына үзенең беренче хатыны Мәдинәне искә алды, аны исенә төшереп торучы һәрбер әйберне тотып-тотып карый торган булды, тузаннарын сөрткәләп яхшырак урынга куйды. Менә лапас почмагына кадап куелган урак. Ул Мәдинәнең йөгерек кулларында бик җитез иде. Менә читәнгә сөялгән кул тырмасы, Мәдинәнең утырып сөс эрли торган кабасы. Каба төбе икегә ярылган, почмакта аунап ята. Гыймалелислам ярылган каба төбен кулына алды. Бер-берсенә якын китереп карады. Ярылган агачны ялгап булмый шул. Ул үзенең язмышын шушы икегә ярылган агач кисәгенә охшатты. Ачу белән аларны атып бәрде.

Татар өе кабасыз булмас, Бибиәсманың кулы эшкә ятышып тора, эрләсен, бәйләсен, киндер суксын, бәлки күңеле ачылып китәр, җиңеллек алыр, дип уйлады Гыймалелислам. Яңа каба төбе ясарга кирәк, дип, агачлар

арасыннан элмә агачы табып, кулына үткен балтасын алды. Утын түмәре янына җай гына чүгәләп, агачны юнырга, тасларга тотынды. Эч пошуның дәвасы — эш. Ул, бу эше белән мавыгып, бераз тынычлана төште. Тәрәш таягы тыгу өчен борау алып, тишеген тиште, тагын бераз матурлады, шомартты. Аннан кулында әйләндергәләп, эшеннән канәгать калып, иске кабаның тәрәш тарагын яңа каба төбенә сыйдыру өчен бер суккан иде, яңа каба төбе кинәт ярылып китте. Ярылган каба төбенә карап озак кына утырганнан соң, Гыймалелислам аны өйгә алып кереп китте. Хатынының күңелен күтәрерлек сүз әйтә алмады, шулай да елмаеп эндәште:

— Менә, хатын, сиңа каба төбе ясадым,—дип шаяртты һәм каба төбен Бибиәсмага сузды.

Бибиәсманың үзен-үзе кая куярга белми, күңеле бәргәләнгән, балаларын искә төшереп, елап та алган, бик авыр хисләр белән өй эшләрен караштырып йөргән чагы иде.

Ярык каба төбен күреп, ул шашына язды:

— Һәй, чукрак! Мыскыл итеп торган буласың! Көлмә, яме! Энеләремә әйтеп, эчеңне издерермен,—дип кычкырды.

— Нәрсә дидең? Издерермен, дидеңме?

Гыймалелислам, ярык каба төбе белән нык кына кизәнеп, Бибиәсманың җилкәсенә тондырды һәм кызулап өйдән чыгып китте. Утынлык янына барды, җирдә аунап яткан балтасын алып ачу белән утын түмәренә чапты. Арлы-бирле йөреп, күңелен тынычландырырга тырышты. Анда сугылды, монда сугылды.

Юк, кулы кычытмаган иде Гыймалелисламның. Талашу, хатынына кул күтәрү, ара бозу түгел иде аның уенда. Балалар вафатыннан соң ике арада хасыйл булган салкынлыктан котылып булмасмы, дип шаяртып алмакчы булган иде. Мәдинәсе булса, шаяруын аңлар иде, кочаклап көлгән булыр иде, күзенә карап: синкәем, шаяртма! дип, оялчан гына кызарыр иде. Юк шул, мөлаемлыгын да, йомшак табигатен дә үзе белән кара җир астына алып китте аның сөйгән хатыны. Бусы көйсезрәк тә, теллерәк тә булыр, ахры, дип уйлады Гыймалелислам. Бу утлы кисәүне беренче кабынуында ук сүндерүенә үзе дә куанып куйды, югыйсә, йөз кызыллыгы булуы бар, дип уйлады.

Каты агач төшкән җилкәнең авыртуыннанмы, булып алган көтелмәгән җәнҗалдан айный алмыйчамы, Бибиәсма кайнар күз яшьләренә төелеп, бик озак елады. Тәрәзәдән урамга карап та, сәке йөзлегенә утырып та, үзен-үзе кая куярга белми авыр язмышына ачынып елады ул, йөрәге калтырады. Бераз тынычлана төшкәч, үзенең кызулык белән иренә әйткән сүзләрен кабат-кабат исенә төшерде һәм бу гаугага үзенең төп гаепле кеше икәнен аңлады. И Ходаем, нигә бу минутта минем сабырлыгымны алдың, дип ачыргаланды. Орыш-талаш өчен килдемени ул бу йортка? Хәсрәтен уртаклашыр кеше булыр дип, тату гаилә кору өчен, тыйнак, сабыр кеше булганга ризалашты бит ул.

Бибиәсма түр сәкенең йөзлегенә утырып, башын түбән иде. Башка бервакытта да иренең чукраклыгын телгә алмаска, дип күңеленә киртләп куйды. Гомер буе тату яшәгән ата-анасын күз алдына китерде. Ир хакы —Тәңре хакы, дия иде бит әнисе Гайникамал, ирне түбәнсетмәскә, аның ирлек дәрәҗәсен саклый белергә, олыларга, дия иде. Әгәр Гыймалелислам аның бу дуамаллыгын гафу итсә, башка беркайчан да тавыш чыгармаска үз-үзенә ант итте, нәзер әйтте.

Өйлә җитеп килә иде. Комганга җылы су салып, тәһарәтләнеп керде, ап-ак намазлыгын җәеп, өйлә намазын ниятләде.

Ул арада Гыймалелислам арт бакчадан әйләнеп килде, аңа-моңа кагылып йөри торгач, бераз тынычлана төште. Шулай да Мәдинәсен һич кенә күңеленнән җибәрә алмады. Сигез ел бергә гомер иттеләр бит, яратышып яшәделәр. Тик тормыш дигән иске бизмән генә Гыймалелислам белән Мәдинәне ике тәлинкәсенә салып селкетте, гомерлеккә аерды. Гыймалелислам сөйгәненең соңгы минутларын күз алдына китерергә тырышты. Менә аның Мәдинәсе череп таркалган үпкәләренә тын ала алмый газап чигә. Аның шомырт кара күзләреннән үлем ачысы белән соңгы күз яшьләре тәгәрәгәндер, ул аларны хәлсез куллары белән сөртеп алгандыр. Шунда да ул Гыймалелисламның исемен кабатлагандыр. Бәхил бул, җаным, балаларымның газиз әткәсе. Соңгы сулышымда сине күрә алмый китәм. Балаларымны ятим итмә, сакла, дигәндер. Өйләнерсең, үзеңә

тиңне табарга тырыш, дигәндер. Теле белән әйтә алмаса, күңеле белән әйткәндер. Саклый алмады шул ул сөйгән хатыныннан туган балаларын, саклый алмады.

Гыймалелислам өйгә таба атлады. Ул өй ишеген ачып кергәндә, Бибиәсма сәке уртасында, намазлыгын җәеп, оеп дисбе тартып утыра иде. Бибиәсма озак кына дога укыды һәм, намазын тәмамлап, намазлыгын җыеп алды.

— Чәй кайнаткан идем, син, чәй эчәбезме?—диде Бибиәсма иренә карап, гүя алар арасында берни булмаган, гүя аңа ире ярык каба төбе белән сукмаган.

Ул җитез генә йон оекларын киеп алды, өстәл өстенә самавырны китереп куйды, агач җамаяк белән бәрәңге, телем-телем кисеп ипекәй куйды.

Гыймалелислам өстәлгә якынлашып, күңеленнән: «Өстәлдәге ризык караңгы көнне дә яктырта»,—дип уйлады һәм хатынына карап елмайды.

Гыймалелисламның өе, Бибиәсма килгәч, көлеп тора торган җәннәткә әверелде. Өй эче чип-чиста, җыйнак, өй бүрәнәләре кырылып юылган, гәрәбәдәй сап-сары, озын сәкегә кулдан сугылган җаймә җәелгән, түр почмакта биек итеп түшәк-ястык, мендәрләр өеп куелган. Авыл өенең бар байлыгы, матурлыгы — шул. Тәрәзә кашагаларына Бибиәсма алып килгән киҗеле сөлгеләр эленгән. Өстәл өстендә җиз самавыр.

Гыймалелислам сүзне авырдан башлады.

— Булган эш булган, үткән эшкә салават, син миңа рәнҗемә инде, телеңне озайтмасаң, мин беркайчан да кул күтәрмәм,—диде.

Бибиәсма дәшмәде.

Икенче көнне Гыймалелислам башка көндәгедән иртәрәк уянды. Бибиәсма күз камаштырырлык итеп чистартылган җиз комганга җылы су салып, ирен юындырды. Сүз күп булмады.

— Ни генә дисәң дә, хатын, тату яшәүгә берни дә җитми, ачуланышмыйк, авыр сүз әйтешмик. Дөньялар җиңел түгел, яңгырлар юк, басуда ком бураны уйный, уҗымнар корып бара. Ниләр күрәсе бардыр? Сүзле өйдә җил уйнар, диләр бит,—диде Гыймалелислам.

Бибиәсма тагын дәшмәде. Оятыннан бит очлары уттай

януын тойды һәм әткәсенең: «Тавышлы йорттан фәрештәләр качар»,—дигән сүзләрен исенә төшерде. Ире хаклы, һичшиксез, хаклы иде.

***

...Әйе, бу җәйдә Агыйдел дә — кайчан гына мул сулы елга иде — бик саекты, азык җитмәгәннән ябыккан ятим бала кебек, нәүмизләнеп, мескенләнеп калгандай булды. Печәнлек болыннар саргайды, җир өсте яргаланып бетте, кошлар сайрамас булды. Авыллар үлек чыккан өйне хәтерләтте, урам буйлап хәсрәт җиле йөрде. Халык мунча ягарга курыкты. Шырпы сызмасаң да, кабынырга торган җимерек каралты-кура, мал-туар — барысы да һавага карап яңгыр өмет итте, Ходайның мәрхәмәтеннән ташламавын сорады. Черек баганалы кое сиртмәләре тынып калды, коеларда су бетте. Йа, Хода! Яңгыр бир! Бир! Бир! Бир!

Яшь-җилкенчәк көн саен авыл читендәге буадан чиләк белән су алып кайтып, урамнан үткән һәр кешегә су сипте, борынгыдан калган халык йоласын үтәп, яңгырга өмет баглады. Ул да ярдәм итмәде. Корылыктан гаҗиз булган халыкның тынычлыгы китте.

Бер көнне авыл картлары мәчет янына җыелды, яңгыр сорап намаз укырга кирәк, дип киңәш иттеләр. Икенче көнне иртә таңнан тәһарәтләнеп, картлар авыл белән буа арасындагы яланга җыелдылар. Аларга бала-чага иярде.

Хәзрәт озак кына вәгазь укыды.

— Агайлар! Шушында истиска намазы укырбыз, һәркайсыгыз уңайлы урын сайлап урнашыгыз, сабыйларны үз яныгызга алыгыз,—дип башлады ул сүзен.

— Аллаһы тәгалә үзенең иң яраткан вә өстен күргән колларына гына бәла җибәрә, диелгән Коръән кәримдә, бу бәладән чыгу юллары күрсәтелгән. Аллаһы тәгаләгә сыенырга, ялварырга, теләкләр теләргә тиешбез. Без һәркаюсыбыз беләбез: дөньялыкта бирелгән авырлыклар Ахирәттәгедән җиңелрәктер. Гөнаһларыбыз күп, җәмәгать, илдә никадәр кан коелды, бәндә бәндәгә дошман булды. Шул гөнаһларыбыздан арыну өчен бирелгән җәзадыр бу. Шунлыктан, адәм баласы, бәла килсә, аны сабырлык белән каршы алырга, Аллаһы тәгаләдән ярдәм көтәргә, өмет өзмәскә

тиеш. «Хәсәбелләһу вә нигъмәл—вәкил» дияргә тиеш. Гөнаһларыбыздан тәүбә вә истигъфар кылыйк. Дошманлашкан бәндәләр, менә шушында мөнәсәбәтләрегезне ачыклагыз, бер-берегез белән бәхилләшегез, татуланышыгыз!

Ул арада картлар арасында бераз гүләшеп алу булды. Кайсылары урыннарыннан кубып, низаглы күршесе яки ачуланышкан туганы янына килеп, туры карашып, гафу сорадылар, куллар бирештелер.

— Җәмәгать!— диде хәзрәт, — башлыйбыз. Изге, чиста күңелегезне намазга багышлап, кыйбла тарафка карап басыгыз! Ике рәкәгать истиска намазы укырбыз.

Намаз уку озак булмады. Агайлар җирдән күтәрелеп бастылар һәм хәзрәтнең сүзен көттеләр.

— Менә, Ходай кушып, барыбыз бердәм намаз укыдык. Ходай, иншалла, рәхмәтеннән ташламас. Инде дога!

Хәзрәт матур моңлы мәкаме белән гадәттәгедән бераз кычкырыбрак:

«Аллаһумә әски гыйбәдәкә...» дип дога укый башлады.

Картлар һәм балалар кулларын күкрәкләренә кушырып, башларын түбән иеп, хәзрәтнең сүзен тыңладылар.

— Йә Рабби, колларыңны сугаргыл, хайваннарга рәхмәт кыйлгыл. Йә Рабби, безгә дога кыйлмак илә боердың вә һәм кабул итмәкне вәгъдә кыйлдың. Инде без Сиңа Үзең боерганча дога кылабыз. Бәс, имди, Син, вәгъдәң буенча, безнең догаларыбызны кабул кыйлгыл. Йә Рабби, әгәр дә гөнаһларыбыз күплеге сәбәпле үземезгә рәхмәт кыйлмасаң, гөнаһсыз сабыйларымызга вә хайваннарыңа рәхмәт кыйлгыл...

Әмма яңгыр яумады.

Кояш рәхимсез кыздырды.

Икенче һәм өченче көнне авыл картлары истиска намазын чәчү җиренә, кырга чыгып укыдылар.

Өченче көнне, барысын гаҗәп-хәйран итеп, зәп-зәңгәр болытсыз күк йөзеннән кечкенә генә болыт хасыйл булып, берничә тамчы яңгыр сибәләде.

Картлар башларыннан кәләпүшләрен салып яңгыр тамчыларын кабул иттеләр. Ходайга рәхмәт сүзләре әйтеп, тәкбир әйтеп авылга таба атладылар. Булдымы ул өч-дүрт

тамчы яңгыр, әллә юкмы. Картлар хыялында ул бар иде... Әмма җирне туендырырлык яңгыр ул язда да, җәйдә дә бер генә мәртәбә дә яумады.

***

Утызынчы еллар иде.

Колхозлашу башлангач, Гыймалелислам каршылык күрсәтми генә, бердәнбер кола биясен һәм камыт-ыңгырчагы белән арбасын тапшырып, колхозга керде, яңа тәртипләрдә яңача, баш иеп, кая кушсалар, шунда эшли башлады. Язын сабан сөрде, муенына тубал асып, сөргән җиргә ашлык чәчте, печән өстендә печән чапты, кибән куйды, урак өстендә ашлык сукты, эскерт өйде, кышын балык тоту бригадасында катып-калчаеп боз тиште, җылым тартты.

Бибиәсма да эшне батырып эшли торганнардан иде.

Колхоз оешуның икенче елында каерылып арыш уңды. Авылның яше-карты таңнан кичке шәфәкъка чаклы басуда булды. Яшь баласы булса, баланы кабык арбага салып, тәпи киткәннәрен тәпиләтеп, үзләре белән алып, хатыннар кырда урак урдылар.

Бибиәсма ул елны буйга узган иде. Кишәрлекләп бүленгән арыш җирендә хатыннар, берсен-берсе күрә-күрә, ашыкмый-кабаланмый гына урак уралар, көлтә бәйләп сослан куялар.

— Авыл яна түгелме соң?—дип кычкырып җибәрде кинәт бер хатын.

Бибиәсма сызлаган биленә кулын куеп, авыртынып кына турайды да авыл ягына борылды.

— И Ходаем, өйләр яна бит!—дип кычкырды һәм урагын җиргә ташлап, аны-моны карамый, йөгерә-атлый олы юлга чыкты.

Уракчылар камыл ерып, кайсы каян авылга таба ыргылдылар. Бибиәсма йөгерә алмады, алтынчы аен тутырып килгән көмәнле хатын ике-өч адым атлап карады да туктап калды, тыны кысылды, корсагы касыгына килеп тыгылды. Бик авырлык белән булса да, кабына язып, атлады, ашкынды, үзе бертуктаусыз кабатлады:

— И Ходаем, и Ходаем! Өебез яна бит! Харап кына булабыз бит!

Күк йөзен коточкыч куе кара төтен каплап алган, кызыл ут ялкыннары күккә үрмәли. Бибиәсма авылга якынлашты. Коры бүрәнәләрнең шарт та шорт яну тавышы аерым-ачык ишетелде.

Янгын сүндерүчеләр күптәннән эшсез ятып үшәнләнеп беткән атларын урыннарыннан кузгата алмый, кузгаткач тәртә арасына кертә алмый азапландылар, каушаудан һәм ашыгудан тузанлы камыт-дилбегәләрнең рәтенә чыга алмый әвәрә килгән арада, ялкын инде җиде-сигез өйне ялмап алган иде.

Бибиәсма тыкрык аша урамга төште. Урамның алар өенә каршы ягында берничә өй ут эчендә, кече урам аша тыкрыктагы Солтангәрәйләрнең салам түбәсенә ут капкан. Ялкын сикерә-сикерә, күз ачып йомганчы тагын берничә лапас, мунча һәм йорт түбәсенә күчте.

Янгынны күреп, күрше авыллардан янгын мичкәләре белән атлар килеп җиткән. Ут-ялкынга чыдый алмыйча атлар чыгымчылый, бер урында таптана, күзләрен акайтып кешнәп җибәрә. Су мичкәләре ныгытылган арбалар өстендә ирләр су насосын эшләтәләр, кычкырышу, чыр-чу, күзләр шашынган, беркем-беркемне аңламый.

Кое сиртмәләре, ашыгып су алган кешеләр кулында, урыныннан йолкынып чыгардай булып шыгырдый, чыелдый, сиртмә баганалары чайкала, коедан күтәрелгән чиләкнең яртысы чәчрәп җиргә түгелә. Ялкынга сибелгән су тәкерек кебек чыжлап юкка чыга. Ут шашынганнан-шашына бара. Калган өйләргә ут капмасын өчен ашыга-кабалана аларга да су сиптерәләр. Шулай да бу көнне авылның унбер өе каралты-курасы белән утырып янды, кара күмергә әйләнде.

***

Көз җитте. Алмалар өлгерде. Бакчалар тулы алма. Алмагач ботаклары алма күплектән сыгылып-сыгылып тора. Ботаклары сына күрмәсен дип, Гыймалелислам терәүләр куеп йөри.

Бибиәсма вакыт җиткәнен сизеп, сигез яшьлек кызы Зәйнәпне авылда танылган кендекче Камилә карчыкка йөгертте.

— Әни тиз генә килеп җитәргә кушты, диген, әбекәең үзе аңлар. Аңа бирерсең,— дип ярты такта чәй тоттырды. Бибиәсма кыз тапты.

— Бисмиллаһир-рахманир-рахим!—дип Камилә әби баланы кулына алды. Баланың беренче авазын ишетеп иреннәрен очлайтып, «Әт-тә-нә-нә-не!» дип, җыерчыклы иреннәрен бөреп, гөргелдәп алды.

— Сөбханалла! Җәннәт исләре белән туды сабыең, дөньяңа яңа нур өстәсен, аталы-аналы, алтын канатлы, бай, шәфкатьле, иманлы бала булсын!

Кулындагы ак чүпрәккә салган баланы җылы су белән юындырды, аннан сак кына йөзтүбән әйләндереп, чүпрәк белән бик әйбәтләп сөртте һәм:

— Суы сарыксын, үзе калыксын! Бәхетле, тәүфыйклы булсын!— дип, ак биләүгә биләде һәм Бибиәсманың уң ягына, кечкенә мендәргә салды.

Аннары тәрәзәгә килеп:

— Гыймалелислам!—дип кычкырды.

Колагы каты булганлыктан, ир карчыкның тавышын ишетмәде.

Ул инде күптән хатынының баладан котылуын көтеп йөри иде. Күңеле сизенеп, ишеккә таба якынлашты. Карчык исә тәрәзәдән кул изәде:

— Гыймалелислам! Кызың бар! Сөенче!

Ата дулкынланып, ашыга-ашыга өйгә керде. Хатынының хәлсезләнгән гәүдәсен, каны качкан ябык йөзен күреп, каушый төште. Аның йөзенә якын ук килеп:

— Ходай рәхмәте белән бушануың өчен мин бик шат, тәбрик итәм!—дип пышылдады.

Бибиәсма аңа карап елмайды һәм тәбрикләвенә ымлап кына рәхмәтен белдерде.

Гыймалелислам сабые янына килеп, уң колагына сак кына пышылдап азан әйтте, сул колагына «Кад-камәт-ис-салават!»— диде. Сәке йөзлегенә утырып, «Аллаһумә әҗгалһү бәрран...» дип дога укыды.

Ир белән хатын, балалары вафатыннан соң дөньяга килгән һәр баланы халыкның борынгы йолаларыннан берсе булган «сатып алу» йоласын үтәргә сүз куешканнар иде.

Алдан сөйләшү буенча, Камилә әби баланы биләү

өстеннән шакмаклы кәшмир шәлгә төрде дә ишегалдына чыгып китте. Өйнең ян тәрәзәсен ачып:

— Бала сатам! Кыз бала сатам! Алучылар юкмы?—дип дәште.

Аның тавышы яшьләрчә шаян, җыерчыклар тулы йөзе, яшәреп, алсуланып киткән иде.

Гыймалелислам тәрәзәгә таба сузылып:

— Миңа нәни кыз кирәк! Күпмегә сатасың, әбекәем? Сатып алам!—диде шаян тавыш белән.

— Биргәнеңне аз диген, алганыңны зур диген. Күпме бирсәң, шуңа риза!

Карчык тәрәзәдән төенне Гыймалелисламга сузды. Ата кеше сабыен сак кына уң кулына алды да Бибиәсманың ал кәшмир күлмәген карчыкның беләгенә салды.

— Алыш-биреш тәмам, биргәнеңне алам, котлы булсын балаң, тәрәзәне ябам,—дип такмаклый-такмаклый, карчык тәрәзәне ябып куйды һәм, йөгерә-атлый өйгә кереп, кечкенә калакка бал һәм май элеп, «Әгузе-бисмилла»сын әйтеп, сак кына баланың иреннәренә тигезде.

Балдай ширбәтле булсын,
Сүзе хикмәтле булсын,
Дусларына чордаш булсын,
Хозер Ильяс юлдаш булсын.

Тагын изге догалар укылды, теләкләр теләнде. Шулчак сабый аваз салды, әкрен генә кыз балаларга хас нәзек тавыш белән елап җибәрде.

— Сөбханалла!—дип шатланды кендек әби. — Сабый Аллаһы тәгаләне искә төшерде, ишетәсеңме, Гыймалелислам, «Лә илаһа илаллаһи!»— диде, тәһлил әйтте, гомере озын булыр, Аллаһы боерса, сабыең Хак тәгаләне мактап аваз салды.

Баланың җиденче көне алдыннан Гыймалелислам, дин кушканча, җиренә җиткереп, корбан чалдырды. Ике яктан ике күршесен һәм туганнарын мәҗлескә җыйды. Коръән укытты, сөенеч сәдакалары өләште. Җиденче көнне сабыйның чәчен кайчы белән сак кына кыркып, утка якты.

Исем сайлау, исем кушу да озакка сузылмады. Кызына ата исемне үзе тапты.

— Улым булса, Мөхәммәт дип атармын дигән идем,

кызыма фәһемле, аңлы-белемле булуын теләп, Фәһимә дип куярбыз,—диде.

Бибиәсма да моңа бик куанды.

Гыймалелислам, ашъяулыкка төреп куелган китаплар арасыннан берсен алды да, каләм алып, «193... нчы елның өченче сентябрендә Фәһимә исемле кызым дөньяга килде. Бәхете белән үссен» дип язып куйды.

***

Фәһимә бик иртә тәпи китте, теле иртә ачылды. Теле ачылыр-ачылмастан, әнисенә кушылып көйләр көйләде, җырлагандай кыланды.

— Төпчегебез җырчы булмагае,—диде Бибиәсма иренә.

— Бирсен Ходай, бирсен Ходай. Җыр да бик кирәк, кешегә гел эш белән черү генә димәгән.

— Мөнәҗәтләрне бик ярата, миңа кушылып җырлый.

Кечкенә Фәһимәнең күңеле бик нечкә. Әнисенең китап укыганын тын да алмый тыңлап утыра.

— Муллаҗиңги, китап укымассың микән?—дип кич утырырга кайчак күршеләре дә керә.

Бар эшне ташлап, Бибиәсма китап укырга әзерләнә. Иң элек сабынлап кулларын юа, бисмилласын әйтеп, бик кадерле әйбер кебек, киштә өстеннән ак киндергә төрелгән китапларны ала.

— Яхшылап утырыгыз. Бисмиллаһир-рәхманир-рахим,—дип бик җайлап изге китапны кулына ала.

Күзлеген киеп, матур мәкам белән укый башлый. Кызлары Зәйнәп белән уллары Габделхәй бу китапны инде ничәнче тапкыр тыңласалар да, һаман алар өчен ул шундый кызык. Чөнки әниләре көйләп укый, аның тавышында табигатьнең бөтен бизәкләре чагыла.

Кечкенә Фәһимәнең күңеле тула. Ул әнисенең әкрен генә кыймылдаган иреннәренә яшьле күзләрен төбәгән, күңеле белән бик ерак җирләргә киткән. Менә ул Йосыф исемле бәләкәй малайны күз алдына китерә. Аны әтисе тезләренә утыртып сөя, аның төшен тыңлый, аны үбә-үбә, бик зур кеше булырсың, дип әйтә. Ә абыйлары бик усаллар, явызлар икән. Алар аны каядыр алып китеп, коега салалар.

Биленә бер бау тагып китерделәр,
Йосыфны шул тар коега төшерделәр,
Шәфкать итми, йөзен читкә чөерделәр,—
Урак белән берсе бауны кисәр имди.

Өстәл өстендә җиделе лампа тоньк кына яктылык сибә. Гыймалелислам, җайлап утырып, тавышсыз-тынсыз гына җәтмә үрә. Ә Фәһимә Йосыф белән бергә кагыла, сугыла, алҗып хәлдән тая, абыйларына ялвара, елый, коега төшеп китә...

Изге китаплар ак киндергә төрелеп кабат киштәгә куела — кояштан саргаймасын, тузан кунмасын.

— Китап — изге нәрсә ул, — ди Фәһимәнең әнисе.

***

Җиде яше тулар-тулмас Фәһимә беренче сыйныфка укырга керде. Ул күптән укырга һәм язарга, санарга өйрәнде. Еш кына аңа дәрестә күңелсез булып китә иде. Язуын тиз генә язып, эшен бетерә дә тирә-ягына каранып тик утыра бирә.

Беркөнне, ничектер, дәрестә аңа бик күңелсез булып китте, тик утыру ялкытты, җырлыйсы килә башлады. Сөйләшер иде — ярамый, укытучы ачулана. Ул әкрен генә шуышып парта астына төшеп китте, идәнгә утырып, дусты Сәгыйрәнең чабатасына күз төшерде. Кызык берни дә тапмагач, җырлап җибәрде:

Иман белмәгән кеше,
Хараптыр барча эше,
Кабул булмас һич эше,
«Аллаһ!»—дигел Бәдәвам.

Укытучы Җиһан апа урыныннан торып басты.

— Кем җырлый?

Балалар кычкырып көлеп җибәрделәр.

— Фәһимә ул! Әнә, парта астында!

Фәһимә әкрен генә парта астыннан чыкты, урынына утырып, башын түбән иде.

Җиһан апа аның янына килеп басты.

— Нәрсә дип җырладың, Фәһимә? Тагын җырлап күрсәт әле.

— Юк, апа, бүтән җырламыйм.

— Җырла инде, Фәһимә.

— Җыр түгел лә ул — мөнәҗәт.

— Кемнән өйрәндең?

— Өйрәнмәдем, әни җырлый бит аны.

— Тагын берне генә җырла инде.

Иман белмәгән — үләр,
Шәйлә имансыз китәр,
Тәмугта урынын күрер,
«Аллаһ!»—дигел Бәдәвам.

— Бу мөнәҗәтеңне башка беркем алдында да җырлама, яме,— дип, укытучы Фәһимәнең башыннан сыйпады.

***

Икенче сыйныфка күчеп, укый башлаган көннәр иде.

— Фәһимә! Нәрсә булды, ник елыйсың?

Укытучы апа Фәһимә янына килеп, аптырап калды. Баланың күлмәгенә, түшеннән итәгенә кадәр, хәтта аякларына да шәмәхә кара чәчрәп беткән иде.

— Нәрсә булды, үскәнем? Ничек болай карага манчылдың?

Баланың сул кулы да карага буялган, ватылган пыяла кара савыты идәндә аунап ята иде.

— Фәвәсим этеп җибәрде дә кулымдагы кара савытым менә монда бәрелеп ватылды-ы-ы.

Бала «монда» дип өстәл почмагын күрсәтте. Үзе тагы да катырак итеп, сулкылдап елап җибәрде.

— Нәрсә белән язармын инде мин? Апам апкайткан иде бит аны. Бүтән калмады. Мин нәрсә белән язармын инде? Кара савыты каян алырмын? — дип такмаклады, бер-бер артлы сабый башына төшкән кайгысын тезде. — Әнигә ни дип җавап бирермен? Нәрсә киярмен? Күлмәгем дә әрәм булды. Бүтән күлмәгем юк бит минем.

Кызлар, Фәһимәне кызганып, әле укытучы апага, әле Фәһимәнең кызганыч кыяфәтенә карап, үзләре дә менә-менә елап җибәрердәй булып, берсүзсез басып тордылар. Дус кызы Сәгыйрә Фәһимәгә якын ук килеп, аның кара түгелгән күлмәгенә кагылырга куркып, дустына балаларча беркатлылык белән:

— Елама инде, әниең юар әле, карасы да бетәр,—дип юатырга тырышты.

Баланың күлмәген Бибиәсма каен селтесе белән казанда да кайнатып карады, әмма аксыл зәңгәр күлмәкнең үз төсе тагы да сыегайды, ә шәмәхә кара киҗе-мамыкка шулкадәр сеңгән иде, юылып төшү түгел, аның җете шәмәхә төсе үзгәреп тә карамады.

Сугышның икенче елы иде. Кибетләрдә сатып алырга әйбер юк, хәерчелекнең чиге чамасыз. Бибиәсма кызын юатты:

— Кайгырма, балам, бераз шушы бизәкле күлмәгеңне киеп йөрергә туры килер, эшләр бераз җиңеләйсен, сүс эрләрбез, киндер сугып, үзеңә өр-яңа җылы күлмәк тегеп бирермен.

Бераз эшләр саеккач, көн саен кичләрен Бибиәсма аркау җеплек эрләде. Фәһимә орчыктан җепне йомгакларга урады.

— Селте белән кайнатып агартырбыз, бик яхшылап буада чайкарбыз,—дип кызын куандыра торды.

Гыймалелислам базардан киндер туку өчен буйлык җеп сатып алып кайтты.

— Менә нинди нәзек, ап-ак җеп алдым. Төпчегебезгә бик матур күлмәк булыр,—диде, кайтып җепләрне сәкегә салгач, сакалын сыпырып. Киләпле буйлык җепләрне тагын йомгакка чорнадылар.

— Син миңа йомгак ясарга ярдәм итәрсең,—дип, Бибиәсма киләпне Фәһимәнең кулларына кидерде,— менә шулай ике куллап, тартыбрак тот.

Бибиәсма җепнең очын эзләп табып, йомгак ясый башлады. Фәһимә кулларына эленгән җеп киләбен әле уңга, әле сулга таба йөртә-йөртә, әнисенә ярдәм итте. Шулай, әни белән кыз сукыр лампа яктысында төн уртасына кадәр җеп чорнадылар, һәр йомгак Фәһимә өчен өр-яңа җылы күлмәк булып күренде. Ул аларны кулларында сикертеп алды, авырлыгын үлчәгәндәй, кечкенә нәзек бармакларында селкеткәләде. Куана-куана әтисе үргән кәрҗингә сала барды. Җеп йомгакларга уралып беткәч, ишекле-түрле сузып, бик озын киләп ясадылар, аннан әнисе аны урта бер җиреннән тигез генә итеп кисеп, ат койрыгын төйнәгән кебек төенләп куйды.

Берничә көннән киндер сугу өчен әзерлек башланды. Әтисе өй түрендәге сәкенең берничә тактасын алып, озын-озын агач җайланмалар ныгытып куйды.

— Бусы киндер сугу станогы булыр, — диде, төпчегенә күз кысып.

Бибиәсма, чолан диварында озак эленеп торып, тузанланып беткән көреле кылычны каккалап өйгә алып керде. Көреләрне бер-берсенә казның бот сөяге белән тоташтырып, түшәмгә беркетелгән бауга элеп, станга тигезләде.

Аннан кызына көре аша җепне алгы якка ничек суырып чыгарырга өйрәтте. Фәһимә кечкенә бармаклары белән көренең элмәкләре аша әнисе биргән җепне берәм-берәм алып торды. Бу катлаулы эш кызга бик кызык, мавыктыргыч булды. Ул аны дәртләнеп, бөтен игътибарын җигеп, әнисе белән шаян сүзләр әйтешә-әйтешә, җырлый-җырлый башкарды.

— Җебеңне бераз тарта төш, салпыланып тормасын,— ди әнисе.

— Менә шулаймы? Булдымы?

— Булды, булды. Йә, тартма, тигез булсын. Өзә күрмә.

— Юк, юк, иплэп кенә тартам.

Тешле кылычны көренең алгы ягына элделәр. Тешле кылыч аша җепне суыру бик ансат булды. Җепләр тешләр арасыннан гына чыгарылды.

Эш беткәч, әнисе җепләрнең барысын бергә җыеп төенләде дә, станның алгы агачына беркетеп куйды.

— Менә хәзер суга башларга да була,—диде. — Аллаһ боерса, минем төпчек кызыма матур күлмәк тегәрбез. Түгәрәк якалы, бөрмә билле итеп тегәрмен, яме.

— Путасы да булырмы, әни?

— Путасы да булыр, кызым, зур кызларныкы кебек биленңне буып торыр. Түшенә матур сәдәф тагармын.

— Озын җиңле, беләзекле итәрсеңме, әнием?

— Әйе, беләзекле итеп тегәрмен, җылы булыр.

Фәһимә бөрмә итәкле, матур сәдәфле күлмәкне төшләрендә күреп куанды. Кыз әнисенең киндер сукканын сәке йөзлегенә утырып бик озак күзәтте. Шоп-шома агач соса эчендә аркау җебе уралган шүре келтер-келтер әйләнә. Икегә аерылып киткән җепләр тасмасы арасыннан әнисе

сосаны әле бер, әле икенче якка шудырып җибәрә. Келтер-келтер, келтер-келтер. Шундый кызык! Соса бер якка үтү белән әнисе аягы белән астагы тактага басуы була, җепләр тагын икегә аерылып китәләр. Әнисе тешле кылычны үзенә таба тартып, киндергә шап итеп бәрә, тагын бер мәртәбә җиңелчә генә кагып куя. Аннан тагын шүреле сосаны җепләр арасыннан йөгертеп җибәрә. Келтер-келтер!

Фәһимә, киндер станогына таянып, әнисенең эшләвен, җитез хәрәкәтләрен бик озак күзәтте. Аның күз алдында ак тукыма үсте дә үсте. Әнисе, станок эченнән чыгып, самавыр куярга киткәч, үзе дә әнисе урынына утырып, теге тактаваларга басмакчы булып карады — аягы гына җитмәде.

Шулай, Фәһимәнең әнисе әллә ничә кич утырып киндер сукты. Өй эчендә бертуктаусыз келтер-келтер, шап-шоп иткән тавыш ишетелеп торды. Бик озын тигез ак тукыма барлыкка килде...

***

Фәһимә бишектән үк моңлы җырлар, мөнәҗәтләр, Коръән сүрәләре тыңлап үсте. Сөйләшә башлаганчы ук ул матур моңлы тавыш чыгара башлады, җырлагандай итте.

Үсә төшкәч, моңлы җыр, аның яшеренеп яткан хисләренең илаһи сере булып, йөрәге түрендә яшәде. Аның җырын ишетеп, әнисе Бибиәсма, бер яктан үзе кебек матур тавышлы булыр, дип куанса, икенче яктан, моңлы кеше бәхетсез була ул, дип хәсрәтләнде.

Сугыш беткән ел иде. Бибиәсма белән Гыймалелислам көн-төн колхоз эшендә. Ун яшьлек Фәһимә үзе генә, өй җыештыра. Өй эчендә таяк болгасаң, берни эләкмәс, шыр-ялангач. Агач карават өстендә киндер җәймә, мендәр, ястык. Фәһимә җырлый-җырлый тәрәзә пыялаларын юа, өй шыңгырдап яңгырап тора:

Өй артымда шомыртым ла,

Яннарында чияләр...

Чия куаклары артында коймага ышыкланып, ике хатын-кыз аның җырын тыңлый. Фәһимәнең моңлы тавышын ишетеп, хатыннар сихерләнгәннәр. «Шомыртым» җырыннан соң ул «Рамай»га күчә:

...Кемнәр безгә теләк теләде икән,
Аерылышып гомер итсен, дип...

Күрше Кәшифә апа җырдан әсәрләнеп, яулык очы белән күзләрен сөртеп ала. Аның ире сугышта башын салган, җыр аның иң нечкә кылларын тибрәткән.

Фәһимәнең тавышында тәрәзә каршындагы чия куакларының кыштырдавы да, зифа камышлар серләшүе дә, йолдызларның җем-җем итүе дә — барысы да бар.

Фәһимә җырлаганда аның күңеле күбәләккә әйләнеп, каядыр очып китәрдәй була. Туган авылы Наратлының күл буйлары яланнарын иңләп-буйлап бозау эзләгәндә дә, бөрлегән җитешкәч, Агыйделнең текә ярына аякларын салындырып утырып, дуслары белән ял иткәндә дә җыр суза. Дуслары аның тавышын бозарга теләмиләр, аңа кушылмыйлар, хискә бирелеп бары тыңлыйлар гына.

...Китәм инде, китәм инде,
Талдан күпер салырсыз.
Тал күперләр бик тар булыр,
Сагынсагыз, барырсыз...

Бу җырны да дусларына Агыйдел буенда печән җыйганда җырлады. Ул быел Минзәләгә укырга китәчәк. Укытучы булырга укыячак.

Авыл баласының бар күргәне — шул укытучы инде. Авылда укытучыдан да ыспайрак, укытучыдан да матуррак, чистарак киенеп йөрүчене күрмәгәнгәме, ул мәктәптә укыганда ук укытучы булырга хыялланды. Әнә, Галия апа кебек, Сәхия апа кебек. Куллары нинди нәфис, ап-ак, чәчләрен генә күр: ничек матур аларның. Фәһимә дә укытучы булырга дип күңелен ныгытты. Укытучылыкка укырга. Минзәләгә китәргә, педагогия училищесына...

***

— Рәхмәт, Агыйделем! Син минем турыда да, изге атам-анам турында да бик күп нәрсәләр бәян иттең. Рәхмәт сиңа! Тагын ниләр сөйлисең бар? Көтәм.

Агыйдел дулкыннары тын калдылар, һәм пышылдап диярлек ярга иркә тыннарын өрделәр. Чал Агыйдел тагын телгә килде:

— Юк, бала, син җиргә килдең, табигать кочагында үстең. Ә табигать ул — елга, күлләр генә түгел, ул җир өстендәге

борма-борма юллар, җиләкле яланнар, кара урманнар, ничә мәртәбәләр сине адаштырган бураннар. Кулларыңны яргалаган җилләр, ул синең йөзеңә нур биргән, алсулык бүләк иткән кояш. Гомерең буе алар синңа юлдаш булырлар. Алар сөйләсеннәр, алар үткәнеңне исеңә төшерсеннәр. Аларны тыңла.

Шунда ерак-еракта бер илаһи тавыш ишетелде:

Агачларның башын киссәң, төбе кала,
Кыз балакай үзе китсә, моңы кала...

Бу моңлы тавышны Агыйдел генә түгел, таллар, күлләр, күл өстендәге кыр казлары, камышлар — бөтен дөнья тын калып тыңлады. Бу мөнәҗәтне әллә Фәһимәнең әнисе, әллә Җир-ана үзе әйтте, бу таныш аһәң Фәһимәнең сагыш һәм аяныч катыш күз яшьләренә сәбәп булды.

Сикәлтәле дә, биек-биек киртәләре дә булган, авыр һәм озын гыйлем юллары сүз алды, алар сөйләде.

***

Җиде сыйныфны гел «биш»кә генә тәмамлап, кулга «Мактау кәгазе» алгач, җәй буе Фәһимә болында печән өстендә күбә төбе җыйды. Тырманың кытыршы сабыннан алга-артка тарткалап — куллары, кояшның рәхимсез кыздыруыннан янып-пешеп, иреннәре ярылып, ул тәмам хәлдән тайды. Ә август урталарында күрше кызы Җәмилә белән Минзәләгә җәяүләп юл тоттылар. Аларны Җәмиләнең бертуган апасы—укытучы Язилә апа озата барды. Тапшырылачак документларны да ул тотты.

Әле бер кул яссуы гына күтәрелгән кояш нурлары җир өстен кып-кызыл төскә күмгән. Фәһимә беренче тапкыр туган авылыннан каядыр, моңарчы күрмәгән-белмәгән җирләргә китеп бара. Аңа унөч яшь. Кичә генә эткәсе белән әнкәсе арасында, алар җылысына изрәп йоклаган сабый бүген әллә кайларга сәфәр чыга.

— Юлыгыз уң булсын, балалар, исән-имин йөреп кайтыгыз!— дип калдылар этисе белән әнисе, авыл башындагы буа янында.

Өч кыз җил-җил атлап китеп бардылар. Фәһимәгә бу аерылышу әнисе укыган «Йосыф кыйссасы»ндагы Якубның сөйгән улы белән аерылышу вакытындагы газаплы

минутлар кебек тоелды. Фәһимәнең тамак төбенә каты төер тыгылды, күзләреннән атылып яшь чыкты. Яшьләрен күрсәтмәс өчен, ул башын иеп арттанрак атлады. Кулында чүпрәк букча, букча эчендә бер кыерчык ипекәй. Аягында өр-яңа чабата, өстендә бер кат күлмәк һәм кечерәеп бара торган бишмәт. (Бишмәтне апасы Зәйнәп теккән иде.) Ике толымга үрелгән калын чәчен артка җибәреп, ак яулык бәйләгән.

Күтәрелгән ташлы юлдан үз күләгәсенә баса-баса атлау башта Фәһимәгә бик кызык тоелды. Юл такыр, аякта шыгырдавык сап-сары чабаталар. Менә бер-бер артлы эрелеваклы авыллар үттеләр. Бер авылга кергәндә, Язилә кызларны кисәтергә кирәк тапты:

— Унике чакрым килдек. Артык чабуламагыз, арырсыз, юл бик озын, салмак кына атлагыз, — диде, бераз шаярышып йөгерешеп алган кызларга.

Иртәнге җиләс һавада унике чакрым юл әлләни авыр тоелмады. Авыл урамын үткәндә, Фәһимә үзләренең өенә охшаган өй эзләде, уңга-сулга каранды. Аларныкы кебек ике тәрәзәсе белән урамга караган иске өйләр күп-күбен, тик ул үстергән алсу чәчәкле кына гөлләре дә, ак пәрдәләре дә юк шул. Иске булса да, Фәһимәләрнең өе биек, тәрәзә каршысында рәшәткәле бакча, чия куаклары. Ул туган елны әтисе өч төп чия утырткан. Алар ел саен Фәһимәгә әчкелтем җимеш бирәләр.

— Бу авылда өйләр бик тәбәнәк икән, тәрәзәләре башын түбән игән кеше кебек, җиргә төбәлгәннәр, гөлләре дә юк,— диде Фәһимә телгә килеп.

Фәһимә үзләренең тәрәзәләрен дә, шыгырдап ачыла торган, кайчандыр әткәсе үз куллары белән ясаган «урыс капка»ларын сагынып өлгерде. Суыксу авылын чыгып, тузанлы йомшак басу юлыннан бара башлагач, апалары:

— Әллә аяк киемнәрен салабызмы?— диде.

Фәһимә оек-чабатасын тиз генә салып, киндерәләрен бергә бәйләп, аллы-артлы җилкәсенә элде. Язилә апа белән Җәмилә дә чүәкләрен салып кулларына тоттылар. Бу юлдан атлау рәхәт, адымнар да озынрак, аяклар җитезрәк булып китте.

Фәһимә тирә-ягына карана-карана арттан атлады. Сул якта сөзәк тау, арыш басуы, көлтәләр тезелеп киткән, ә уң якта еракларга сузылган иксез-чиксез урман. Юл туп-туры ниндидер авылга алып бара.

— Менә бусы Адай була, тагын сигез чакрым үттек.

— Барысы егерме булды, — ди тиз генә Җәмилә.

— Тагын утыз биш чакрым гына калдымыни? — ди гаҗәпләнеп Фәһимә, куангандай итеп.

Авылга кереп бер-ике тыкрык үткәч, алар кечкенә инеш агып сазлыкланган урам аша авыл артындагы урманга юл тоттылар. Саркып торган вак-вак чишмәләрне сикереп үтә-үтә, юкә, карама, шомырт, өянке кебек вак агачлы әрәмәлекләр белән бүлгәләнгән болын аша атладылар.

Инде кояш төшлеккә авышкан, бик нык кыздыра, җилнең әсәре дә юк. Көзгә таба атлаучы кояш җәйнең соңгы көннәрендә кыздырып калыйм, дип тырыша, ахры, Фәһимәнең иреннәре чатнап ярылды, тамагы кипте, ашыйсы килә башлады.

— Балалар, арыгансыздыр, бераз баргач, чишмә булыр, шуның янында утырып, тамак ялгарбыз, туйганчы чишмә суы эчәрбез,— дип юатты Язилә апа кызларны, аларның хәлдән тая баруларын чамалап.

Фәһимә, аңкавына берекккән телен әйләндереп, канәгатьлек белдереп баш какты, сүз әйтергә хәле җитмәде. Ак май яккан ипиен ашыйсы килеп, иреннәрен ялап алды. Сагыну бер хәл, карын ачып, тамак кибү хәлләре бик авыр икән шул.

Арба тәгәрмәчләре эзендә җыелган су күреп Фәһимә, килеп җитәбез, ахры, дип уйлады, ял итәрбез, ипекәй ашарбыз, дип куанды.

— Менә чишмәгә килеп җиттек, үләннән, юл читеннән атлагыз,— дип киңәш бирде Язилә апа.

Кызлар, чабып алынган болынның ямь-яшел курпысына басып, бер чокырдан тибеп чыккан көмештәй саф сулы чишмә янына килеп тукталдылар.

Болын тып-тын. Кибәннәрне санап, яланнарны айкап, талларын иркәләп, көмеш чишмәдән чыккан сулы чокыр эченнән кояш елмаеп тора. Ник бер кош тавышы ишетелсен. Чишмә генә шул тынлыкка сихри бер моң өстәп челтер-челтер ага.

— Исеме бармы бу чишмәнең?—дип сорады Фәһимә Язилә апасыннан.

— Исемен мин белмим, болын чишмәседер.

— Юк, әйдәгез, бу чишмәне Кояшлы чишмә дип атыйк,— диде Фәһимә.

— Юлда башка чишмә юк, туйганчы суын эчәрбез, ял итәрбез,—диде укытучы апа һәм күзгедә үзен күргән кебек, Кояшлы чишмәнең суына бераз карап торды да, тигез өслекне ватып, учлары белән чумырып су алды, тәмле итеп суын эчеп җибәрде.

Кызлар да теш сындырырлык салкын суны озаклап, йотымлап-йотымлап, тәмләп кенә эчтеләр.

— Бу кадәр тәмле сулы чишмә бу болын уртасында ничек хасыйл булды икән?

— Юлчылар өчен, болынчылар өчен, безнең өчен Ходай тәгалә бүләгедер,— диде Фәһимә.

— Эчегез, рәхәтләнегез.

Кызлар чишмә суын туйганчы эчеп, салкын суны битләренә сиптеләр, көлештеләр. Тәннәре рәхәтләнеп, җаннары сафланып китте, хәл керде, яңадан тугандай булдылар. Аннан яшел куе курпы өстенә аякларын сузып утырдылар, бик тәмләп майлы ипи ашадылар. Укытучы апа чишмәләр, җир асты сулары турында нидер сөйләп алды. Аннан кызларның балчык каткан аяк бармакларына карап:

— Болын юлы бик каты, табаныбыз кабарыр, аякларны юып, киенербез,— диде.

Фәһимә курпы өстенә чалкан төшеп, бераз зәңгәр күк йөзенә карап ятты. Күкне бизәп кауркый болытлар әкрен генә селкенгәләп тора, ара-тирә кабарынкы болытлар күренгәли. Алар бүген гел Фәһимәнең авылына таба агылалар. Әнә теге куянга охшаганын аның әнисе күрер микән? Кызының бу болытка карап калуын аңлар микән? Әнисенең ак күлмәге менә шушы болытлар шикелле ап-ак иде, җилфер-җилфер итә иде. Ул кызына юл догаларын укыды.

«Болытлар! Минем әнием белән әтиемә сәлам әйтегез! Авылыбыз өстенә берничә генә тамчы яңгыр сибегез!»— дип уйлады Фәһимә. Кычкырып әйтер иде, көлерләр, аны аңламаслар.

— Ял итү, утырып тору бик рәхәт, ягез аякларыгызны юыгыз, киенегез, юлыбыз әле ерак,—диде укытучы апа.

Алар юлны дәвам иттеләр. Әле уңга, әле сулга боргаланып, тал куакларын әйләнеп үткән болын юлыннан бик озак атлагач, тагын бер авылга якынлаштылар.

«Барам әле Минзәләгә, юллары такыр диләр»,—дип җырлыйлар, юлы бер дә такыр түгел икән, болын юлы, кара балчыгы каты. Шул уйлар белән Фәһимә башын түбән иеп атлады да атлады.

Игезәк балалар кебек бер-берсенә охшаган кечкенә-кечкенә авылларны үтеп бераз баргач, Язилә апа:

— Менә бу — Ык елгасы,— диде.

Алар киң генә бер елга ярына якынлаштылар. Елга буенда суга салынып төшкән куе таллык, камышлык. Елгада арба көч-хәл белән үтеп китәрлек агач түшәлгән тар гына озын күпер. Агачлары йомычкаланып, суелып, ашалып беткән, кайберсе хәтта сынган. Агачтан-агачка баса-баса, азапланып аргы якка якынлаштылар.

Җитез генә юртып, күпергә таба атлы арба узып китте. Тик ат күпер алдында кинәт туктап калды. Арбадагы агай, чыбыркысын баш өстендә бер кат әйләндереп, атка бик каты сыдырып җибәрде. Атның күзләре киерелеп ачылды, ул урынында бераз гына тыпырдап алды да, ыргылып күпергә барып керде. Арба тәгәрмәчләре аркылы агачларда озак кына доңгыр-доңгыр килделәр. Фәһимә, артына әйләнеп, күпер аша сикерә-атлый, титаклап атлаучы атны кызганып, бераз туктап торды. Әле сиңа аргы яктан арбаңны тутырып йә печән, йә утын сөйрисең бар, бахыркаем, дип уйлады. Күңеле тулды, елыйсы килде.

Сөзәк таудан кызлар авылга күтәрелделәр. Авыл уртасында озын манаралы, алар авылыныкы кебек җыйнак кына агач мәчет. Урамнары тар, ямь-яшел чирәм, анда-монда кое сиртмәләре.

— Бу Дусай авылы дип атала, алдагысы — Мәлкән, керәшен авылы,—диде Язилә апа.

Фәһимә аңламады, нинди авыл ул керәшен авылы? Кемнәр алар —керәшеннәр? Моңарчы аңа бу турыда беркемнең дә әйткәне булмады.

— Керәшеннәр кемнәр алар, Язилә апа?—дип сорады Фәһимә, кыенсынып кына.

Гүя аңа кемдер, җиде класс тәмамлап, шуны да белмисеңме, дияр төсле тоелды.

— Берничә гасырлар элек татарларны урыслар көчләп чукындырганнар, муеннарына тәре такканнар. Чукындырылган татарларны «крещен», ягъни чукындырылган дип атаганнар. Шулай безнең халык икегә бүленгән. Чукындырылган һәм чукындырылмаган. Әнә шул «крещен» дигәннәренә керәшен атамасы тагылган. Алар татарча сөйләшәләр, урыс кебек чукыналар.

Фәһимәгә бик куркыныч булып китте, аның тәне чымырдады, күз алды караңгыланды.

Бу ике авыл арасындагы иләмсез тирән чокырларны үрмәли-үрмәли, берничә чакрымга сузылган Мәлкән урамнарын үттеләр. Чирәме корыган яланнар аша чыгып, игене җыелган басу юлыннан атладылар. Инде тәмам хәлсезләнеп, аякларын көчкә сөйрәп, тузанлы юлдан бардылар да бардылар. Бераз гына утырып ял итәсе, калган ипине ашап аласы иде, тамак та кипте. Юк шул, бу болын түгел, чишмә дә юк, җиләс күләгәле куаклар да.

— Инде, матурларым, күп калмады, бары уникe чакрым атлыйсыбыз бар,—диде Язилә апа. — Менә бу басу беткәч, Минзәлә күренеп кенә тора.

Кемнәрдер бу юлдан атка утырып кына җилдергәннәр. Әнә тәгәрмәч эзләренә әле тузан да кунмаган, дип уйлады Фәһимә.

Юл үргә таба күтәрелә иде, атлавы тагын да авырлашты. Бара торгач, еракларга сузылган гүзәл бер манзара алдында хәйран булып, Фәһимә туктап калды. Гүя ул биек тау башына менгән дә еракларга күзен текәп, җир өстен күзәтә.

Баеп баручы кояшның сүлпән нурларына коенып, сибеп ташлаган терекөмеш бөртекләре кебек күлләр, кибәнле болыннар, бормаланып-бормаланып аккан тар гына елга һәм ап-ак таш өйләре белән шәһәр алсу-кызгылт нурга чумган иде.

Шулар уртасында елга аша салынган салават күпере кебек тимер күпер ниндидер сихри бер могҗиза булып күренде.

Ходаем! Нинди гүзәллек! Нәрсә бу? Өнме? Төшме? Фәһимә йокысыннан уянып киткәндәй булды. Аруын онытып, йотылып карап торды.

— Ә-әнә, күрәсезме? Минзәлә шул инде. Барасы өч чакрым юлыбыз калды, — диде Язилә апа.

Фәһимә җиңел сулап куйды: җиттек бит! Тәки җиттек бит!

Белем чишмәләренең башы шундадыр. Минзәләдәдер.

Алар, юл кырыена утырып, калган ипи кыерчыгын вак-вак кына тешләп, тамак ялгадылар.

***

Сентябрьдә укулар башланды. Минзәлә педучилищесы кызыл кирпечтән төзелгән мәһабәт йортка урнашкан. Нигәдер ул Фәһимәгә беренче күрүдә ошамады. Чыраен сыткан караңгы йөзле кеше төсле, кашын җыерып каршы алды. Эченә кергәч, бу фикере тагын да куәтләнде. Таш суыгы Фәһимәнең тәнен генә түгел, җанын өшеткәндәй булды.

Әмма, укулар башланып, анда укыта торган затлар белән якыннан аралаша торгач, Фәһимәнең фикерләре үзгәрде, училищеның бинасы да кояшка елмаеп дустанә каршылый башлады. Авыл баласы өчен андагы белем ияләре гүя гади кешеләр түгел, ә әнисе укый торган изге китаптагы фәрештәләр булып тоелды.

Фатирда Сылуҗан исемле хатында яши башладылар. Ике тәрәзәсе урамга карап торган кечкенә өй. Ишегалды чирәм, капкадан ишеккә чаклы сузылган тар сукмак, абзар-кура юк, бары такталардан корамалап ясалган бәдрәф.

Ишектән керү белән сул якта зур мич, түр башында озын сәке, ишегалдына караган тәрәзә каршында өстәл, ишек катында тактадан ясалган караватт.

Өйнең бар җиһазы шул.

Кичләрен өстәл уртасына сукыр лампа куеп, шуның яктысында дәрес әзерләделәр. Сөреме чыкмасын өчен ут теле өстенә кәкре кадак атландырып куйдылар. Лампа ике телле булып яктырак яна.

Укулар авыр, таләпләр зур. Укуның беренче көннәреннән үк диктантлар, контроль эшләр белән белемнәрен тикшерделәр.

Күпләр коелып төшеп калды һәм сөзелеп калган төпле белемле укучылар белән октябрь аеннан ныклы укулар башланды.

Дәреслекләр, язу әсбаплары аз булса да, Фәһимә дәрес вакытында укытучыларны тыңлап утырып, белемне үзләштерә барды, ул укытучыларның мөлаемлыгына, кыяфәтенә сокланып, дәртләнеп һәм яратып дәресләргә йөрде.

Менә Фәһимәнең иң яраткан урыс теле укытучысы Галина Федотовна Князева, аккош кебек нәзакәтле генә атлап, сыйныф бүлмәсенә килеп керә, бүлмәгә җиңелчә генә хушбуй исе тарала. Ул балаларга күз ташлап елмая да, бөтен барлыгыннан затлылык бөркеп торган искиткеч килешле гәүдәсен туры тотып, укытучы өстәленә якынлаша. Аның тавышы йомшак, сүзләре җайлы. Чибәр битен бизәп, кашы-күзе нурлана, ап-ак батист кульъяулыгын нәфис борыны астына юри генә тидереп ала да:

— Так, ребята, начнем,— ди.

Бүлмәдә чебен очкан тавыш та юк. Фәһимәнең урыс теле чамалы. Укытучы сөйләгәнен аңлар-аңламас. Аның ягымлы, йомшак тавышына, сөйләгәндә иннек сөрткән нәзек ирене өстендәге энҗе бөртегедәй кечкенә миңенең җай гына кыймылдавына, ак ефәк кофтасы астында калку күкрәгенең тын алганда күтәрелеп-күтәрелеп куюына сокланып, Фәһимә дөньяда яшәвен оныта. Сәгать үтүе сизелми дә кала. Оеп тыңлап утырганда чылтыраган кыңгырау сискәндереп җибәрә.

Кызу-кызу адымнар белән җыйнак гәүдәле география укытучысы Сәет Маликович Сәүбәнов дәрескә керә. Күрсәткеч таягын өстәл кырыена куеп, журналдан укучыларны барлый, йылт кына ике кулы белән чалбарын күтәреп алгандай бер хәрәкәт ясап ала.

— Фәһимә, карта янына бүген сине чакырам,— дип, аңа карап елмая. Күрсәткеч таягын аңа сузып: — Мурманскидан Камчаткага кадәр «сәяхәт итәрсең»,— ди.

Бу — Мурманскидан Камчаткага кадәр шул арада очраган диңгезләр, утраулар, ярымутраулар, бугазларны атау һәм аларның табигате, флора-фаунасы һ.б. турында сөйләп чыгу, дигән сүз.

Укучысының түкми-чәчми бу маршрутны сөйләп чыгачагын укытучы белә. Фәһимә аның иң яраткан укучысы. Ул аның белән горурлана.

Аннан укытучы тагын башка берәүне чакыра. Картага арты белән бастыра.

— Скагеррак һәм Каттегат бугазларын күрсәт, — ди.

Укучы, картага арт белән басып, ул атаган бугазларны якынча күрсәтергә тиеш.

— Алар турында сөйлә. Кая урнашканнар? Урынын ачыкла.

Укучы җавап бирә:

— Скагеррак һәм Каттегат бугазлары Төньяк һәм Балтыйк диңгезен аерып, Ютландия һәм Скандинавия ярымутрауларын аерып торалар,—ди һәм таягы белән төртеп күрсәтә.

— Аермасы нәрсәдә?

— Скагеррак төньяктарак, Каттегат көньяктарак.

— Дөрес түгел. Кем дөресли?

— Скагеррак Ютландиянең төньяк-көнбатыш ярында, ә Каттегат Ютландиянең көнчыгыш ярында.

Укытучы канәгать.

— Суматра, Борнео утрауларын күрсәт.

Укучылар сәгатьләр буе картада «сәяхәт» ясыйлар. География —аларның иң яраткан фәне.

Аннан тарих укытучысы Нәгыймә Габдрахмановна Чурмантаева керә. Кыска итеп киселгән шомырт-кара чәчен кәкре тарагы белән тарап, артка кадап куя да, тыңкышрак тавышы белән укучыларны барлый, китек тешен күрсәтеп, киң итеп елмая. Ул дәрес алдыннан сорау биргәнне бик ярата. Шул сорауга җәелеп китеп сөйли башлый, дәрес узып китә, звонок була. Укучылар кайвакыт укытучының бу йомшак ягыннан бик оста файдаланалар.

Менә какча озын гәүдәле физика укытучысы Гыйззәт Рәхмәтуллович Галиев дәрескә керә. Ул барыннан да картрак күренсә дә, шаян сүзе белән яшәрә дә куя. Кайвакыт балаларча самими, кайвакыт вакланучан, усал. Аны кызларның чибәрлеге дә, егетләрнең киң җилкәсе дә кызыксындырмый. Белем давай! Белем!

Физика дәресе бара. Такта янында килешле генә киемле, зур зәңгәр күзле, чибәр Фәния җавап бирә. Нидер сөйли.

Кинәт укытучы аны туктата.

— Мыштыд-мыштыд кителдең, утыд, икеле!—ди

укытучы. (Ул «Р» авазын теле белән өске иреннәрен ялап алган кебек итеп әйтә.)

— Сөйләдем бит инде, абый!—дип суза Фәния елардай булып.

— Утыд, утыд, авызыңда тады боткасы пешедден, мин бедни аңламадым. Икеле, яхшылап укып кил, ядыймы.

Аннан, укучылар өстеннән шаян күзләре белән тиз генә карашын йөртеп ала:

— Йә, кем ачык итеп, булачак укытучыладча, аңлаешлы итеп сөйләп бидә?

Куллар күтәрелә.

— Күдәсезме, нинди галимнәд үсә бездә!—дип куя укытучы.

Физика укытучысының укучы халкы яратмый торган бер шаян гадәте бар: дүртлеме, бишлеме алсаң, икенче дәрестә яки өченчесендә тагын сорый, бастырып сорый, белмәсәң, икеле чәпи.

Тыйнак, чибәр һәм егетләрчә җиңел гәүдәле математика укытучысы Ясәви Һадиевич Һадиев Фәһимәнең аеруча яраткан укытучысы. Шуңа күрә, ул бу фәннән гел бишлегә генә укый һәм, училищены тәмамлагач, математика укытучысы булып юллама алу турында хыяллана.

Ә Сания Гомәровна Гобәйдуллина — маңгай өстендә дулкын-дулкын булып яткан ефәктәй җирән чәчле, сирәгрәк вак тешле, бик таләпчән химия укытучысы. Ул күз карашы белән гипнозлагандай, укучыларны бик тиз тынычландыра һәм үзенең бик матур сөйләм теле белән әсир итә.

Менә тәрбия дәресләренә класс җитәкчесе, логика фәне укытучысы Нурвисан Ибраһимовна Тәлдәева керә. Ярты битен алып торган зур соры күзләрен укучылар өстеннән йөртеп чыга да, елмая төшеп, гадәти булмаган сөйләм теле белән (ул урысча укыган, шуңа татарча начаррак сөйләшә иде бугай) кызлар теге яки бу урында үзләрен ничек тотарга тиеш, ничек утырырга, сөйләшергә, көләргә кирәк икәнен мисалларда аңлата.

— Син, Фәһимә, башыңны түбән иеп, артыңны суза төшеп йөрисең, алай йөргәч, кызлар картрак булып күренәләр, менә болай, менә болай йөрергә кирәк,—дип, йөреп күрсәтә.

— Ә син, Рәмзия, артык кычкырып, авызыңны ерып

көләсең, ярамый, ярамый. Укытучы кеше үз дәрәҗәсен белеп кенә көләргә тиеш. Укытучының алай чәчелеп түгеләргә хакы юк...

***

Юллар әле истәлекләр сөйләүдән туктамады, ярдәмгә буранны чакырды.

— Буран, буран! Фәһимәнең бу юлында без икәү идек. Син дә мин. У-у! Ул озын юллар! Анда баланы зур сынау көтә иде. Булу яки булмау, яшәү яки яшәүдән туктау, исәнлек яки үлем арасында көрәш барды. Син, буран, аңа каршы истең, аның юлын бутарга тырыштың. Ул көрәштә бу кечкенә буйлы, көчсез бала җиңеп чыкты.

— Юк, мин аны киләчәккә әзерләдем. Әле алда бураннар булыр, берсе артыннан берсен җиңәргә тырыш, сынма, каушама, нык тор,—дидем.

***

Ул елны авылдашы Җәмилә укуын дәвам итә алмады, сынауларда җиңелде.

Ә хуҗа хатын яшь, чибәр Сылуҗан үзенә йортка өйдәш итеп бер ирне кертте. Торыр урын калмады. Фәһимә дусты Ләзидә белән икенче фатирда яши башлады. Дуслары күбәйде, белем ныгыды, кышкы сынауларны бик яхшы бирде.

Фәһимәне Ләзидә кышкы каникулга үзләренә, ягъни авылларына кайтырга өнди башлады. Фәһимәнең әтисенең олы абыйсы — дүрәткәсе дүрәнкәсе белән шул авылда яшиләр. Ләзидә артыннан күчтәнәчләр җибәрәләр. Кунакка чакыралар. Фәһимәнең аларны да бик күрәсе килә, өйгә дә күңеле тарта. Хатлар аша әтисе белән әнисе аның бу теләген үз ихтыярына куйдылар.

Шулай итеп, Фәһимә каникулда кунакка барырга карар кылды. Кызлар юлга таң алдыннан кузгалдылар. Ике телем кара ипине Фәһимә туңмасын өчен сырма түшенә тыкты, кирәк-яракны кара сумкага салып тотты. Көнчыгыштан искән таң җиле җылы өйдән кузгалган бу ике сабыйга әлләни куркыныч түгел иде. Кызу-кызу атладылар.

— Чулман ярына кадәр егерме бер чакрым,— диде Ләзидә.

— Егерме бер күп түгел,— диде Фәһимә.

— Аннан Исәнбай, аннан... Брак түгел, илле генә чакрым. Барысы җитмеш.

— Җитмеш! Кичкә барып җитеп булырмы?

— Кичкә җитәрбез, төнгә калмасак...

Алар әле култыклашып, әле аллы-артлы атладылар. Сызылып таң ата башлады. Алланып кына килүче таң яктысына таба атлау Фәһимәгә бик кызык тоелды. Аның әле бер дә таңга таба болай әсәрләнеп, дәртләнеп атлаганы юк иде. Әллә шул уңышлы тапшырылган имтиханнар куанычы, дүртле-бишле билгеләре җанга рәхәт, тәнгә куәт бирде. Стипендия булачак, әткәсе-әнкәсе куаначак. Шуңамы, атлау җиңел, күңелле иде. Аяк астында коры кар шыгыр-шыгыр килеп, адымга куәт өсти, битне салкын җил чеметә. Җырлап та җибәрәсе килә, кар шыгырдавына кушылып, Фәһимә эченнән генә җырлагандай итә:

Китәм инде, китәм инде,
Күренеп тора юлларым.
Таулар аша, сулар аша
Сузсаң, җитмәс кулларың...

Бу аның әнисе җырлый торган җыр.

Чулман янына килеп җиткәндә, кояш җир өстеннән өч илле чамасы күтәрелгән иде. Чулман өстендә җиллерәк тә, салкынрак та тоелды. Кызлар урыны белән шома бозда шуа-шуа, урыны белән йөгерә-атлый уздылар. Аннан тигез чана юлы башланды. Илле чакрым калды, дип уйлады Фәһимә, Ләзидәнең сүзен исенә төшереп. Атларга да атларга. Түштәге ипекәйнең бер кисәген ашап, кар капкалап тамак ялгадылар.

Исәнбай авылы дигәннәре карга күмелгән, җиргә иңгән тәбәнәк өйләре, морҗалардан күккә ашкан төтеннәре белән уң якта калды. Юл авыл читеннән генә узды.

Фәһимә әтисенең сүзләрен исенә төшерде: суык көнне төтен һавага туры күтәрелә, ә җылырак көннәрдә җиргә сарыла, дия иде. Төтеннәр туры һавага күтәрелә, димәк, көн суык. Җәяүләп кызу атлаганга гына әлләни сизелми.

Ник бер юлчы очрасын! Булганы да, кая баралардыр, гел каршыга очрый. Арттан берәр атлы куып җитсә, бәлки, атына утыртыр иде. Аз гына булса да аякларга ял булыр иде.

Кичкә таба кинәт кенә буран башланды. Уң яңакка бәреп кар ява, җил юка шәл аша муенга, итәк астыннан билгә, аркага үрмәли. Атлау авырая, аякларның хәле бетә башлады. Көн караңгылана барды. Кышкы кыска көн сизелми узды да китте.

Юантык гәүдәле Ләзидә әллә чыннан да нык арыды, арттан бара, еш-еш сулыш ала, «уф!» дип куя. Бара торгач:

— Фәһимә! Күрәсеңме, сул якта салам эскерте! Әйдә, шунда кереп бураннан ышыкланып утырабыз, бераз ял итәрбез!—диде.

—Юк!—дип кычкырды ашыгып Фәһимә, буран тавышын җиңәрлек көчле тавыш белән. — Юк! Юк!! Анда кереп утырсак, катып үләбез без.

Шунда Фәһимәнең күз алдына кайсыдыр елны буранда туңып үлгән туганнан туган Рауза исемле апасы килде. Ул унике генә чакрым ераклыктагы авылда укыган. Кайтканда адашып, салам эскертендә катып үлгән иде.

— Юк, уйлама да ул турыда! Ныграк бул! Атларга! Атларга! Туктарга ярамый!

Җил тагы да катырак сызгырды, биткә бәреп яуган кар үзәккә үтте.

Кинәт Фәһимәгә каяндыр нәзек кенә тавыш, җыр ишетелгәндәй булды. Әллә әнисенең моңлы тавышы, әллә җил сызгыра, әллә кемдер мөнәҗәт әйтә. Нинди моң!

Балам синең ераклыгың
Яндыра сагыш-утларда.
Алам каләм, язам сәлам
Өзгәләнгән минутларда...

Бу әнисенең язган хатындагы җыры икән бит. Шунда котырынган буран эченнән әнисенең йөзе пәйда булды. Гадәтенчә яратып елмаймады, ә бәлки шелтәләгән кебек туп-туры кызның күзләренә карады. Кулларын сузды.

— Балам, бигрәкләр дә ерак сәфәргә чыккансың бит! Адашмассыңмы? Авылга гына кайтырга киңәш биргән идек бит. Әткәң бик сагынды үзеңне, дус кызларың да кереп, кайтмадымы, дип сорыйлар.

— Юк, әнием, мин дүрәткәйләрдә озак тормам, аларны да бик күрәсем килде. Сәгадәт апаны, Мәдинә апаны. Алар бит безнең бик якын туганнар. Рәнҗемәгез миңа, изге

теләктә торыгыз. Кәтегез. Мин кайтырмын,—диде Фәһимә күңеленнән.

— Сагындык бит, кызым, бик сагындык. Сыерыбыз да бозаулады. Угыз эремчекләрен сиңа да куйдым. Авыз итәргә тизрәк кайт.

Фәһимә әнисе язган хаттагы сүзләрне искә төшерде. Үзе буранга каршы, аруын җиңәргә тырышып, атлады да атлады. Ярый юл такыр, күтәрелгән таш юлны буран артык капламаган. Мондый юлда кеше адашамыни?

Бара торгач, Ләзидә тагын телгә килде:

— Безнең авыл олы юлдан ике чакрым эчтә. Авылга кергән юлны таба алсак ярар иде,—диде.

Такыр юлда берәзлексез шуышып торган җәяүле буран башны әйләндергәндәй итте. Җилгә бирешмәскә тырышып, кызлар атладылар да атладылар.

Кинәт бик еракта, алда тычкан күзедәй генә ике яктылык пәйда булды. Ул ике күз бер балкып алды, бер юкка чыкты, тагын калкулык артыннан кинәт кенә хасыйл булды, озак кына балкып торды. «Сүнә күрмәсен! Сүнә күрмәсен! Шул утларда безнең язмыш», — дип уйлады Фәһимә.

— Фәһимә! Күрәсеңме? Бу йә трактор, йә машина, — диде Ләзидә куанып.

— Ур-ра!—дип кычкырды Фәһимә һәм соңгы көчен җыеп, алга ыргылды. Тынына кабынды, йөрәге дөп-дөп итте. Балкысын, югалмасын, югалмасын! Кышкы ачы буранда, җанга үткән бу суыкта әлеге яктылык аңа җан өрде, көч кертеп җибәрде. Күңеле тынычлангандай булды.

Тиздән бу көчле яктылык, дөбер-шатыр ажгырып алар каршысына килеп туктады. Ике яктан яктылык астыннан күкләргә ашкан ике кара шәүлә килеп чыкты, аннан ике кеше гәүдәсе күренде.

— Сез кемнәр? Шайтан балаларымы әллә? Урыс өеннән этен чыгармас буранда кая барасыз? Нишләп йөрисез?

Ләзидә, кыюланып, сырган чалбарлы, фуфайкалы бу ирләр янына якын килде һәм үзләренең кем булуын, кая баруын аңлатты.

— Әнә, бераз баргач, тегендәрәк, Торнага керә торган юл булыр. Чит-читенә нарат ботаклары кадалган, күрерсез. Шул маяклар арасыннан читкә тайпылмагыз. Кайтып җитәсез инде, — диде берсе, кызларны юаткандай.

Юл дәвам итте. Трактор үтеп киткәч, бөтен дөнья дөм-караңгы булып калды. Бераз баргач:

— Менә, менә маяклар! — дип кычкырып җибәрде Ләзидә.

Гүя ул инде үзенең җылы өенең ишеген ачып, кадерле әнисен күрде.

Алар маяклар уртасыннан тез тиңелте тирән кар ерып атлый башладылар. Юлга буран шыплап кар тутырган иде. Кар ярып бару бик авыр, тәмам хәлне алды, ә атларга кирәк. Монда инде юл хуҗасы булып Ләзидә алдан атлады. Фәһимә аның артыннан, эзенә баса-баса, башын түбән иеп, соңгы көчен җыеп кар ерды.

Кинәт Фәһимәнең җилкәсенә гүя кемдер китереп орды һәм ул юл кырына чалкан барып төште. Каршында коточкыч зур, күкләргә ашкан бер нәрсә: әллә кибән, әллә морҗа, әллә машина — Фәһимә аңлый алмады. Чытырдатып күзен йомды, тагын ачты: әллә җенме, өрәкме, албастымы? Ул урыныннан кузгалырга курыкты. Нәрсә соң бу? Кая башы? Кая койрыгы? Ниндидер торба сыман нәрсә абайлады кыз.

— Тпру! Тпру!

«Атлы кеше бугай»,— дип уйлады Фәһимә.

Чаналы ат. Юк, чана түгел, биек кошевка, аның өстендә толыплы кеше. Толып якасын торгызып кигән. Ята торгач, Фәһимә үз-үзенә шуны ачыклады. Ат тыпырчынды, пошкырды, ни өчендер алгы аякларын күтәреп алды.

— Тпру! Тпру!— диде аттагы кеше һәм кар өстендә яткан Фәһимәгә эндәште. — Кем син? Ник тормыйсың? Әллә имгәндеңме?

Фәһимә әкрен генә торып басты, бил тиңелте карга чумды һәм каты гына:

— Ләзидә!— дип кычкырды.

Ләзидә исә, аны-моны абайламый, буранга каршы атлап, бераз алга киткән иде. Фәһимәнең тавышына борылып, үз күзләренә ышанмый торды, аннан кирегә, ат янына килде.

— Гали абый? Әллә синме?— дип дәште.

Бу, чыннан да, колхоз рәисе Гали Кадыйров иде.

Авылга чаклы чакрым ярым юлны кызлар кошевкага утырып кайттылар.

Фәһимәнең дүрәткәсе Габдрахман карт какча озын гәүдәле, сирәк ак сакаллы намазлык карты иде. Ул Фәһимәнең әткәсенә һич тә охшамаган, куллары көрәктәй зур, аркасы бераз бөкрәя төшкән, карашы кырыс. Бөкрәя төшүнең сәбәбен Фәһимә тиз аңлады: өйләре кечкенә, ишекләре бик тәбәнәк икән, дүрәткәсе, мескен, ишектән кергәндә дә, чыкканда да башын бәрмәс өчен бик нык бөкрәергә мәҗбүр. Өй эче Фәһимәнең моңарчы кергән бик күп өйләрнең игезәге кебек: өй түрендә бер стенадан икенчесенә озын сәке, түрдә ике тәрәзә, бер почмакта мендәрястык өеме. Мич каршында ләгән белән җиз комган.

Дүрәткәсе бик аз сүзле кешедер, ахры, күп сөйләшми, эндәшми-нитми бик озак бер ноктага карап утыра. Шулай да ул икенче көнне иртән:

— Әткәңнәр сау-сәламәтме соң, олан? — дип сүз башлады.

— Күптән кайтканым юк, — диде Фәһимә,—хатларында исән-сау, дип язалар.

— Нигә кайтмадың? Каян кайтмадың? Ата-ана янына еш кайтырга кирәк, — диде карт бераз моңсуланган кыяфәт белән.

— Мин бит укыйм. Минзәләдә. Имтиханнар бирдем.

— Укыйсың?! Мәдрәсәдә укыйсыңмыни? Нинди ханнар белән?

— Ханнар түгел, имтихан. Мәдрәсәдә түгел, училищеда.

— Ә-ә, нинди чөпшедә?

— Чөпше түгел, училище.

— Йә, ярар, синеңчә инде, олан, синеңчә. Сиңа соң — ничә яшь?

— Ундүрт тулды, унбишенче.

— Унбишенче, дисең инде син. Мин авылдан киткәндә әле син булмагансың икән... Апаң Зәйнәпне хәтерләем, бик шаян бала иде... Әткәң балык тота торгандыр инде.

— Әйе.

— Һәй, безнең авылның күлләре! Балыкны кул белән тота идек без яшь чакларда!— дип бик тирән көрсенде Габдрахман карт.

— Хәзер ау белән, җәтмә белән тоталар.

— Без дә ау белән дә, җәтмә белән дә сөзә идек, кармакка да каптыра идек, мурдага да эләктерә идек. Һай, үлгәнче бер туган илкәйләргә кайтып булырмы?

Картның нуры сүнеп бара торган кечкенә күзләреннән бер-ике генә тамчы яшь тәгәрәде. Ул кул аркасы белән генә яшен сөртеп алды да тагын сүзен дәвам итте:

— Гыймалелислам бәхетле ул, туган илдә яшәй, яшьләй аунап үскән яланнарда мин йөрмәс идемме?—диде ул үз-үзенә сөйләнгәндәй. —Күлләрдән балык тота, урманнан утын ташый торгандыр...

— Урманнан утын ташымыйлар,—дип куйды Фәһимә, — утынга күл буеннан кәҗә талы гына кисәргә рөхсәт итәләр.

— Кем рөхсәт итмәй?

— Авыл советы.

— Авыл сәвите кем соң ул?

— Кем булсын, председатель инде.

— Һәй! Шул күл буеның кәҗә талын гына ягарга да риза булыр идем әле мин, сыер тизәге ягып булса да яшәр идем. Юк шул, картайдым... Туфрагым да шушында, чит-ят җирдә булыр кебек...— дип көрсенде карт.

Фәһимәгә бик ямансу булып китте. Ул дүрәткәсен болай ук карттыр дип белми иде шул.

Ул аны үзенең әткәсе кебек шаян сүзле, уенчак кеше дип уйлый иде. Әтисен күз алдына китерде. Ничә яшьтә булгандыр Фәһимә, бик кечкенә иде, әтисе аңа куырган борчак чәйнәп ашата иде. Кич җитсә, җиделе лампа яктысында алар кич утыралар. Әнисе лампа яктысында китап укый, Зәйнәп апасы, Габделхәй абыйсы һәм Фәһимә өстәл тирәсендә утыралар.

Габдрахман картның карчыгы да аның әнисе кебек түгел. Юан һәм зур гәүдәле тупас карчык, йөзе бик җыерчыклы, кайчандыр сөрмәле булган яшькелт күзләре инде моңсуланган, менә-менә күз яшьләре тәгәрәп китәр төсле, сагышлы. Дүрәнкәсе дә туган ягын бик сагынадыр.

Ул шулай уйлады.

— Кортка, сиңа әйтәм, самавыр куеп җибәр, чәйләп алаек, кунак кызын сыйлаек әле, нәрсәң бар анда?— ди дүрәткәсе.

Күп тә үтми, бу кечкенә өйнең дә эче зураеп, яктырып киткәндәй булды. Мич эченнән дүрәнкәсе бәлеш тартып алды. Сый дигәне арыш камыры эчендә пешкән балан икән. Балан бәлеше. Ул төн буе җылы мичтә мәмрәгән. Баланның

төше дә йомшап беткән. Фәһимә бик тәмләп балан бәлеше ашап, тышы белән чәй эчте.

Шикәр шакмагын теш арасында китеп кенә алып, сөтле чәй чөмергәндә, Фәһимәгә бик тә күңелле булып китте. Кунак шулай була икән ул. Аңа кыстый-кыстый чәй эчерделәр, аның акыллы, зур үскән кыз булуы турында әллә ничә тапкыр әйттеләр. Мактадылар...

***

Габдрахман Наратлы авылында хәлле генә крәстиян Галләмнең олы улы була. Өйләнгәч, атасыннан бары бер җигүле ат-арба алып, ташландык бер йортка башка чыга. Берничә ел ул җәй буе удмурт якларында байларга бил бөгеп, урак урып, бер ат йөге бодай алып, күпмедер өлешен шунда ук сатып, хатынына кием-салым алып кайта. Берничә елдан, шулай ат кебек эшләп, яңа өй салырга агач-таш юнәтә. Ниһаять, өйләнүенә биш-алты ел дигәндә кыш буе бура бурап, язга кеше көнләшерлек итеп, урамга өч тәрәзәсе белән ялт итеп торган өй салып чыга. Шул елны туган дүртенче кызына Сәгадәт (бәхет) исеме куя. Тагын удмурт якларында кара тиргә батып эшләп, көзгә олау-олау икмәк төяп кайта. Тик тир түгеп тапкан икмәк аларга ризык булмый. Күрше Фәтхелбаян хатыны Мәрфуга икмәк төяп төнлә кайтып кергән Габдрахманны ян тәрәзәсеннән күзәтеп тора. Эче күбә, күлмәгенә сыя алмый, аскы ирене чабырып чыга, колагы чыңлый, теле авызы эчендә үскәндәй була. Таң атар-атмас ул авыл советына барып, түкми-чәчми Габдрахманның ишегалдына күпме икмәк кайтканын сөйләп бирә.

— Каян алган? Амбарын ашлык белән тутырды.

Шул көнне үк ниндидер комиссия килә. Тентиләр, амбарларның ишеге шәрран ачып ташлана. Икмәкне атларга төяп, алып чыгып китәләр. Дүрт балалы гаиләне өеннән куып чыгаралар. Берничә көннән өйне сүтеп, каядыр алып китәләр.

Габдрахман дүрт балалы гаиләсе белән кара мунчада яши. Язга таба читкә чыгып китә. Удмурт якларында күптәнге бер танышын очратып, үз язмышыннан зарлана. Танышы аңа үз авылына күчеп килергә киңәш бирә. Шулай

итеп, Габдрахман Торна авылына килеп төпләнә. Колхозлашу башлангач, колхозга керә, гомере буе ат караучы булып эшли. Кызларын кияүгә биреп, өйдә карт белән карчык кына гомер итәләр икән...

***

Берничә көн кунак иткәннән соң, картлар Фәһимәне әтиәнисенә илтеп тапшырырга дип киңәш иттеләр.

Ул көнне Фәһимә таң белән уянды. Караңгыдан ук торып, мичкә утын тутырып, мич кабызырга җыенган дүрәнкәсе белән олы кешеләрчә саубуллашты, кунакчыллыгы өчен рәхмәт әйтте.

— Рәхмәт сезгә, дүрәнкәй, кунак иттегез,— диде.

— Кунак, дип, балам, каян килсен инде кунак итү! Нәрсә белән кунак итмәк кирәк?! Картайдык. Әткәң белән әнкәңә бездән күптин-күп сәламнәр әйтерсең. Сине Мәдинә апаң озатып куяр, — диде.

Ул арада мичнең күмере төшеп, дүрәнкәсе табада карабодай коймагы пешереп алды. Чәй эчеп, Мәдинә апасы белән юлга кузгалдылар. Мәдинә җиңел чана алды.

— Арысаң, утыртып тартырмын,— диде.

Фәһимә башта җәяү теркелдәде.

Авылга! Авылга! Әнкәсе-әткәсе янына! Йөгереп тә алды. Бара-бара Мәдинә апасы аны, арыгансыңдыр, дип, чанага утыртып та тартты. Шулай көне буе тагын җәяүләп Фәһимә туган авылына кайтты...

***

Фәһимәнең туган авылы белән Минзәлә арасы артык та түгел, ким дә түгел — илле биш чакрым. Атна саен булмаса да, ул бик еш авылына кайта. Сагынуын басар өчен яки әнкәсе пешергән коймакны ашар өчен генә түгел, ә бәлки хөкүмәт биргән акча җитмәгәнгә, өйдән күтәрә алганча киптерелгән бәрәңге, он, ярма, май кебек ризык алып китәр өчен кайта Фәһимә.

Шимбә көннәрдә якташлар бергә җыелып, юлга чыгалар. Юл авыр, озын булса да, өйгә кайту бик күңелле. Фәһимә базардан ике кием чабата сатып ала. Бер киеме юлның яртысында «чәчәк ата», утырып ял иткәндә, искесен салып

ташлап, өр-яңасын киеп ала. Язларын юлга җәелгән ташу суын, көзге яңгырларда уйсу җиргә җыелган, өсте юка боз белән капланган суны аркылы чыкканда, оек-чабатаны салып кулына тота. Ялан аяк боз вата-вата суны ерып икенче якка чыгалар. Суыкны куар өчен аяк кызышканчы, узыша-узыша, барысы бергә йөгерәләр. Зурраклар эре-эре адымнар белән алдан элдерә. Фәһимәнең бик еш хәле бетә, артта кала. Башкалар утырып ял иткән арада ул да куып җитә, тик аңа ял итәргә вакыт калмый, тегеләр дәррәү кузгалалар. Кайвакыт Фәһимәне ике яктан култыклап алып кайталар. Алай җиңелрәк, тик ул бәхет еш эләкми.

Өченче елны Фәһимәнең дусты, авылдашы Зифа да училищега укырга керде. Август ахырында Зифаның әтисе Асылгәрәй, колхоздан ат сорап алып, аларны ат белән алып барды. Урыны-урыны белән кызлар атка утырып та бардылар, арба артыннан да җәяүләделәр. Арбада ике капчык бәрәңге, бераз азык-төлек, кирәк-яраклар. Ыкны чыгып, Дусай авылын үткәч, урман аша узганда, кола бия атламас булды.

— На, малкай, уникe генә чакрым калды, барып җитик,— дип, Асылгәрәй ничек кенә атны әйдәкләп караса да, ат барырга теләмәде, башын түбән иеп, чыбыркы очы тигән саен тәне тартышып, баскан җиреннән купмады.

— Килеп җиттек, балалар, шушында кунарга туры килер, ат арыды,—диде Зифаның әтисе.

— Ат арыды,—дип кабатлады Фәһимә, бу сүзгә тирән мәгънә биреп.

Үзе эченнән: «Мин аттан ныграк микәнни? Мин арысам да, һаман атлый идем. Ат акыллы хайван шул ул, үз хәлен үзе белә. Ә кеше үзен саклый, яклый белмидер. Кеше эт каешыннандыр, ныктыр, чыдам, чырыштыр»,—дип уйлады.

Алар урман эчендә, юлдан читтәрәк бер агач төбендә кунарга туктадылар, Асылгәрәй атны арканлап, урман эчендәге сирәк кенә үлән эченә җибәрде. Көзге караңгы төндә урман эчендә калу Фәһимәгә бик куркыныч тоелса да, арбага утырып, андагы әйберләргә башны төртү белән ул тирән йокыга талды. Кояш чыгар-чыкмас, салкын таң һавасыннан ул туңып уянып китте...

***

Фәһимә музыка дәресләренә аеруча яратып йөрде. Мандолинада, думбрада уйнарга өйрәнде. Җыр дәресләрендә укытучы еш кына аны класс алдында ялгызын җырлата, өйрәнелгән һәрбер җырны Фәһимә бөтен нечкәлекләре белән кабул итә һәм башкарып чыга.

Укытучы еш кына:

— Сиңа, күгәрченкәем, музыкаль белем алырга, укуыңны Казандагы музыка уку йортында дәвам итәргә кирәк. Синдә сирәк очрый торган музыкаль нәфис сиземләү, ишетү һәм матур моңлы тавыш,— дия иде.

Фәһимәне укытучы кыллы музыка кораллары оркестрында альт партиясенә утыртты. Камил исемле малай белән алар үз партияләрен бик тиз өйрәнделәр. Үзәк өзгеч татар музыкасы аны һәрчак бала чагына, авылына кайтара. Әнә, ул туган авылның су буйларында, томан баскан киң яланнарда, Агыйдел буйларында йөри...

Оркестрда беренче аккордлар яңгырау белән, кызны дәртле бер хис биләп ала, чәч бөртекләре арасында ниндидер аңлатып булмый торган кымырҗу хасыйл була, күзләре дәртле яна башлый. Ул альт-думбраның муенын сул кулы белән тотып, нота битләреннән үзләре уйнаячак ноталарга килеп җитә. Дирижер күзләре белән генә Фәһимәгә карап ала. Башла, янәсе. Фәһимә музыканың дәртле дулкыны белән калкынып, канатланып куя һәм кул бармаклары медиатрны җайлабрак тота, уйнап җибәрә.

Тоныграк, куе, йомшак тавышлы альт-думбра телгә килә. Минут эчендә Фәһимә гади кыз түгел, ә музыкант Фәһимәгә әйләнә. Оркестр гөр килеп залны яңгырата. Их, әнисе күрсен иде! Дуслар күрсен иде!

Думбра кызның кулларында җырлый, моңлана. Оркестрга аның думбрасы үзенә бер төрле куе, лирик тавышы белән моң, җылылык өсти. Их күрсеннәр иде авылдашлары! Килеп карасыннар иде бер генә!

Оркестрның соңгы тантаналы авазларыннан соң зал гөр килеп кул чаба, укытучы, кулындагы нечкә таякчыгы белән ымлап, оркестрда уйнаучыларны аяк өсте басарга куша. Кечкенә гәүдәле, ябык Фәһимә башкалар арасында югалып кала, күренми. Ә аның барысына да күренәсе, елмаеп баш

иясе килә. Алкышлар тәмам булгач, алар урыннарына утыралар. Дирижер, дикъкать дигәнне аңлатып, таяк тоткан уң кулын күтәрә, таякны селтәп җибәрә, оркестр дәррәү яңа көй башлый.

Аһ, бу музыка дөньясы! Моң дәрьясы! Фәһимә кебек үк эчке бер киеренкелек белән, хис белән аны кабул итүче тагын бар микән? Мөгаен, юктыр.

***

Педучилищеның соңгы курсында Фәһимә Мисбах исемле кешеләрдә яшәде. Мисбах бронхлар астмасы белән җәфалана. Хатыны исә бик чибәр. Ап-ак йөзле, түп-түгәрәк кырык биш яшьлек хатын. Аларда Фәһимә олы балалары кебек, үз кеше булды. Атна саен пычак белән кырып, кайнар су белән идән юды, көн саен ике тапкыр көянтә-чиләк белән колонкадан су кайтарды. Балалар белән уйнады, шаярды, җырлар җырлады. Мисбах белән Камилә аның җырлавын бик яраталар, кунак булып танышлары килсә:

— Тыңлагыз әле, бездә нинди сандугач яши, — дияргә яраталар иде.

Гөрләвекле апрель иде. Урамнар тулып шарлап су ага. Фәһимә сулар ера-ера укуга йөрде. Аягында базардан сатып алган үкчәле резин бутый, тик никтер көн дә уң аягы дымлана. Ул, үзе дә сизмәстән, бер көнне авырый башлады. Башы авыртып, Фәһимә ике дәрестән соң өйгә кайтып китте.

— Ни булды? Ник иртә кайттың?—дип каршылады фатир хуҗасы Камилә, Фәһимәнең хәлсезләнеп кайтып керүен күргәч.

— Авырыйм бугай, апа, башым ярыла.

Камилә Фәһимәнең башына кулын тидерде, күзләренә карады. Фәһимәнең күзләрен тонык пәрдә каплаган, бите уттай яна иде.

— Син бит янасың, бала. Кая, ят, әнә урыныңа ят, хәзер температураңны үлчим.

Фәһимәнең култык астына градусникны тыкты.

— Янасың, бала, температураң кырык градус,— диде. — Кайда салкын тидердең син, бала? Аягыңда йон оек югыйсә, бутыеңны да яңа алган идең бит.

— Тишек булган ул, Камилә апа, ничә көн инде аягым манма су була.

—Каһәр генә икән, алдап сатканнармыни? Карап алмаган идеңмени?—дип ачыргаланды хуҗа хатын.

Фәһимәнең уң аягындагы оекбашы лыч су, аягы боз кебек салкын иде. Камилә грелка алып, аңа җылы су агызды, одеял астына кызның аяклары янына куйды, кайнар чәй ясап эчертте.

Әмма Фәһимәнең хәле авырайганнан-авырая барды, ул саташа башлады.

— Хәле начар, хастаханәгә алып барырга кирәк, — диде фатир хуҗасы Мисбах.

Ул арада тугызынчыда укучы уллары Рамил кайтып керде. Камилә аны борчылып каршы алды:

— Фәһимә бик каты авырый, улым, без аны икәү хастаханәгә алып барырбыз, өйдә калдырырга ярамый, яна, кырык градус.

Алар Фәһимәне балалар чанасына яткырып, икәүләп тартып хастаханәгә алып киттеләр.

Фәһимәнең ике ягыннан култыклап табиб бүлмәсенә алып керделәр. Табиб аның хәлен тиз аңлады, палатага кертергә кушты. Палатага кереп караватка яту белән, Фәһимә аңын югалтты.

Күпме яткандыр, аңына килеп күзен ачуы булды, бик каты укшып, косып җибәрде. Аның койкасын ак халатлы ханымнар әйләндереп алган иде.

— Кан басымы түбән, тын алуы авыр, үпкәсе ике яклап та шешкән,— дигән сүзләрен ишетте.

Ул тагын һушын югалтты. Беләгенә кадаган укол авыртуыннан бераздан тагын күзләрен ачты.

Олы яшьләрдәге ак халатлы шәфкать туташы аның баш астындагы мендәрен рәтли-рәтли:

— Уяндыңмы?— диде бик йомшак ягымлы тавыш белән.
— Кайда болай салкын тидердең соң син, кызым?

— Белмим.

Дуслары, укытучылары Фәһимәнең сәламәтлеге өчен борчылып, хастаханә юлын таптадылар, табиблар кулдан килгәннең барын да эшләделәр. Яхшы ук терелә башлагач, инде Фәһимә аякка басам дип торганда, аның күңелен тетрәндергән бер хәл булды.

Аның янына бер укытучы килде. Майда гына кыздырып коймак алып килгән. Фәһимәнең нечкә ябык бармакларын тотып-тотып карый, үзе сөйләнә:

— Бигрәк ябык шул син. Яхшырак тукланырга кирәк, — ди.

Башта җайлы гына сөйләшсә дә, укытучы чәрелдәп аны ачулана башлады.

— Кайда бу кадәр суык тидерергә мөмкин? Егетләр белән төнката урамда тордыңмы? Үпкә шеше — туберкулезның башы инде ул. Син үзеңә гомерлек чир алдың...

Укытучысы киткәч, Фәһимә һушын җыя алмый бик озак утырды. Бу сүзләрне әйткәнче, мылтыктан атып үтергән булса соң, җиңелрәк булыр иде. Йөрәкнең дә ярасы берьюлы юкка чыгар иде. Ул аның алып килгән бик тәмле төсле, сап-сары, тишекле-тишекле коймакларына кагылмады, кулын да сузмады.

— Кайгырма, кызым, — диде шунда күрше караваттагы апа, — үпкә шешен хәзер бик яхшы төзәтәләр. Яңа дарулар, антибиотиклар бар хәзер. Тыңлама, оныт ул апаңның сүзләрен. Акылсыз хатын ул. Аңа укытучы булырга түгел, терлекләр белән эш итәр өчен укырга кирәк булган, — диде.

Бу хатынның шушы сүзе җитә калды, Фәһимәнең күңеле тулып, елап җибәрде.

Ике атна дигәндә, Фәһимә, чыннан да, савыгып хастаханәдән чыкты.

Тагын бер айдан дәүләт имтиханнары башланды. Сәламәт-леге бик какшаган булса да, ул имтиханнарны җиңел бирде. Ел дәвамында яхшы укуы да аңа бу авыр сынауны җиңеп чыгарга ярдәм итте.

Училищены тәмамлаган илле укучы арасыннан иң яхшы алты егет һәм кызны мәктәп өчен математика укытучысы әзерли торган ике айлык курсларга Казанга җибәрделәр. Алар арасында Фәһимә дә бар иде.

***

Август. Фәһимә математиклар әзерли торган ике айлык курсларда булып, авылга кайтып төште. Озакламый мәгариф бүлегенә җибәрелгән юллама белән, кайсы авылга укытырга барырга тиешлеген ачыклаячак. Диплом кулда,

юллама бар. Аның киләчәге, бәхете шушы ике кәгазьдә, ул шулай дип уйлады. Озакламый сентябрь. Ә август — җәйнең соңгы, иң кадерле, иң ямьле ае. Ул муллык, байлык ае, җиләк-җимеш ае. Җәй иртәнге чыклары, ямь-яшел печәннәре, чиллә кызулары белән каядыр көньякка эре-эре адымнар ясый. Августта әле үләннәр ямь-яшел, чәчәкләр дә керфек кагалар, бакчаларда чия, алма җитешә. Алтындай басу-кырлар сүрәнләнеп баручы кояшка багалар, арыш, бодай исе, җитлеккән әрем исе борынны кытыклый.

Район үзәгеннән авылына кайтканда, Фәһимә шулай хозурланып атлады. Аны Аккүл дип аталган зур бер авылга математика-физика укытучысы итеп билгеләделәр. Ул иртән-иртүк юлга чыгачак. Аккүл алардан кырык чакрым ераклыкта.

Фәһимә таң алдыннан авыр бастырылып уянды.

Кап-караңгы төн, имеш. Күкнең бер кырыенда гына еракта ниндидер яктылык сирпелә. Яңгыр ява. Фәһимә яңгыр астында каядыр атлый, шәбәргән, калтырана. Кинәт шак-шок ат тояклары тавышы ишетелә башлый, аны кемдер атка атланып куа. Ул арада эт тавышлары якыная, этләр өрә, тешләрен шакылдата, ырылдый. Шулчак әллә каян кара күләгәләр аңа ябырыла. Ул хәлдән тая, бик нык йөгерә башлый, күрмәсеннәр, тотып алмасыннар. Шунда ул бер юан агачка килеп сарыла, агачны кочаклап, бармакларын аның кабыгына батыра.

— А-а-а!— Фәһимә ачы тавыш белән кычкырып, күзләрен ачып җибәрде.

Фу! Нәрсә бу? Нинди коточкыч ямьсез төш! Урын-җир көйсез булдымы? Мендәр катымы?

Шундый уйлар белән ул урыныннан торды. Юк, аның бу куанычларын беркем дә, бернинди яман төш тә, хәтта күк күкрәп каты яңгыр ява башласа да, юкка чыгара алмаячак.

Бик матур җиләс аяз иртә. Фәһимә олы юлга чыгып басты. Әнисе аны изге юллар теләп тагын озатып калды. Өстендә зәңгәр чәчәкле ак якалы яңа күлмәк, аның өстеннән куе зәңгәр йон кофта. Икмәк ташучы машиналар тыз да быз үтеп кенә торалар. Фәһимә кулын күтәреп бер машинаны туктатты.

— Кая?

— Аккүлгә.

— Әйдә, мин дә шунда.

Юл авыр булмады. Кырык чакрым сизелми дә калды. Бара торгач, сүз иярә сүз чыгып, Фәһимә үзенең быел гына педучилище тәмамлап, Аккүл авылы мәктәбенә математика укытучысы итеп билгеләгәннәрен әйтте.

— О-о! Безнең мәктәп директоры бик коры кеше, әмма яхшы тарих укытучысы. Абруй зур, атна саен лекция укый.

Фәһимәнең күз алдына зур кара кысалы күзлек кигән, чал чәчле, ни өчендер кәкре борынлы кеше килеп басты. Ул елмаеп куйды.

— Абруйлы, дисең инде, яхшы укытучы.

— Укытучыларны да ул сайлап кына ала, диләр. Укытучылар бездә бик модныйлар, биек үкчәле туфли киеп, керт-керт кенә атлыйлар. Элек безнең авыл район үзәге иде бит, шәһәрдән ким түгел, көн дә кино, клуб зур, мәктәп... Мәктәп зур, балалар бик күп.

Фәһимә утырган машинаның шоферы телгә бик оста, хәтта артык телчән булып чыкты, анекдотлар, кызык хәлләр сөйләде.

Фәһимә гаять күтәренке рух белән мәктәп янында машинадан төшеп калды. Мәктәп директоры күзлекле дә, зур кәкре борынлы да түгел, какча гәүдәле, тәбәнәк кенә, үткен кап-кара күзле, җитез хәрәкәтле, теле сакаурак, пеләш башлы, олы яшьтәге кеше иде. Ул иң элек Фәһимәнең аякларына күз төшерде, аның аякларындагы чүпрәк чүәкләрне күреп, чырае сытылды. Аннан күлмәгенә, ак якасына, аннан гына күзләренә туры карады. Гүя аның алдында дипломлы укытучы түгел, ә ул сатып алачак мал — тоякларын тикшерә, тешләрен саный.

Ярый әле метр алып буемны үлчәмәде, дип уйлады Фәһимә. Аңа әллә ничек бик оят булып китте, кечерәеп калгандай булды.

—Дипломыгыз, юлламагыз, — диде директор.

Фәһимәнең дипломын ул бик озак укыды. Дипломда билгеләр дә бик яхшы, бары берничә генә дүртле. Исем-фамилиясе дә матур гына икән. Галимова Фәһимә. Фәһемледәдер...

Ләкин Фәһимә директорга ошамады, кечкенә гәүдә, өзелеп китәрлек нечкә бил, башкорт якларыннан килгән кызларныкы кебек киңчәрәк бит, хәтта кызның өзелеп төшәргә торган карлыгандай кара күзләре дә аны җәлеп итмәде.

— Бездә математика укытучылары җитәрлек, сеңлем, яңа укытучы таләп ителми, — диде.

Алмады Фәһимәне эшкә мәктәп директоры.

Фәһимә таныш булмаган бу авыл урамыннан салмак кына олы юлга таба атлады. Сул якта зур ишекле кибет күреп, анда керде. Кулында подъемный акчасы бар иде. Әнисенә чуклы яшел шәльяулык, әтисенә ялтырап торган күн итек сатып алды. Бүләкләрне пөхтәләп чүпрәк сумкасына салып, авылдан читтәрәк үтүче күтәрелгән таш юлга чыгып басты.

Авыр йөкләр ташучы зур машинаның биек кабинасына кереп утыргач, Фәһимә тын калды. Юл сикәлтәләрендә селкенә-селкенә ул ничектер оеп киткәндәй булды, уйлары чуалды.

Машина руленә ике куллап ябышкан юантык гәүдәле, чигәләре чалара башлаган агай да ләм-лим берни дәшмәде. Фәһимә абзый кешенең борын төбеннән генә көй көйләп баруына да гаҗәпләнмәде. Юлда шулай ялгыз көйләү дә, җырлау да кирәктер. Бу абзыйның да юлдашы җыр икән, дип уйлады Фәһимә, әнисе дә һәрчак аңа, җыр йөрәккә ял ул, дия иде. Абзый җырлап җибәрде. Тавышы йомшак, көе таныш иде:

Байлар гына элә икән
Тәрәзәгә пәрдәне.
Юллар түгел, язмыш йөртә
Бу дөньяда бәндәне...

Агай җырлаган бу җыр Фәһимәне әллә нишләтте, миенә сарылды, йөрәген җилкетеп җибәрде. Көе генә нинди бит! Нинди моң! Фәһимәнең әнисе дә шушы көйгә җырларга ярата, сузып-сузып җырлый, Фәһимәнең үзенең дә абзый кешегә кушылып җырлап җибәрәсе килде. Тик аның халәте җырларлык түгел, еларлык иде. Шулай ук ул укытучы булып эшләрлек кеше түгелмени?! Ә диплом? Гел бишлеләрдән генә торган диплом аңа бу хокукны бирмимени?

Аккүл мәктәбе директоры аңа ышанмады. Фәһимә анның күз каршында: «Син, кызчык-чыпчык, тугызынчы, унынчы сыйныфтагы өрлектәй егетләрне тыңлата алмассың»,— дигән фикерне укыды. Директор, авыз чите белән генә елмайгандай итеп, йомшаграк тавыш белән хәтта «сеңлем» дип тә куйды. Еларсың да! Беренче адым бит! Зур планнар, өметләр челпәрәмә килде. Шулай уйлап бара торгач, әнисенең бер җыры исенә төште:

Тәрәзәгә карый-карый
Кистем бармагым,— каный.
Бүгенге авыр хәсрәттән
Үлмичә калсам ярый.

Җырламады, исенә генә төшерде. Бу җырны әнисе бик еш җырлый иде.

Хәсрәте күп шул анның әнисенең. Унике бала тапкан, бары икесе исән. Ә анның нинди хәсрәте бар соң? Балалары бер-бер артлы үлгәнме? Ятимме? Бу хәсрәтмени?!

Юк, юк! Фәһимә, башыңны имә! Алда бербөтен гомер, озын гомер. Баш иярга ярамый. Ярамый!

Ул уянып киткәндәй булды, туган авылына борыла торган таррак юлны күреп:

— Абый, җаным! Мин кайтып җиттем. Туктатыгыз машинаны. Сезгә бик зур рәхмәт,— дип, әллә кайчаннан кулында йомарлап килгән кәгазь акчаны аңа сузды.

— Акча алмыйм, сеңлем! Юлың уң булсын!

Машина кызу гына китеп тә барды.

Ул басу юлыннан атлады. Ашлыгы суктырып алынган салам өемнәре, кыркып алынган чәч кебек, тип-тигез тырпаеп торучы арыш камылы анның каршылыклы уйлар тулы күңелен әллә нишләтте. Икмәге җыелган буш кыр, сап-сары салам, сап-сары камыл... Сары төсне яратмый Фәһимә. Әнисе дә, кайгы-хәсрәт төсе ул — сары, ди.

Аккүл авылында укытырга калмавын белгәч, Фәһимәнең әти-әнисе бик куандылар.

— Үзебездә, Наратлы мәктәбендә генә укытырсың, кызым, Алла боерса,—диде әтисе, кызының фикерен беләсе килеп. — Наратлыда да шул ук балалар, мәктәбебез дә төшеп калганнардан түгел, дип беләм, Казанда да, Ижауда да укыйлар, укытучыларның йөзенә кызыллык китермиләр.

— Әйе, балам, үзебездә генә укытырсың, фатир эзлисе, ни ашыйм, ни эчим диясе булмас, инде фатирда яшәп тә туйгансыңдыр. Ничә ел күрмәгән кунак сыенда булырсың, Аллага шөкер, әле үз көчемдә бит,—диде әнисе Бибиәсма да.

Райүзәктән Фәһимә туган авылы мәктәбенә юллама алып кайтты.

***

Июль аеның кайнар кояшы кыздырды да кыздырды, кичкә таба бераз сүрәнләнгәч, таулар артына качарга җыенды.

— Бераз гына туктап тор!—дип дәште Агыйдел Кояшка. Мин бик күп сөйләдем, инде син, кайнар Кояш! — Син бу баланың якын юлдашы булдың, аны һәр көн иртән йокысыннан уяттың, яшәргә көч бирдең, аның һәр адымын күзәтеп тордың. Сөйлә! Ник качасың?!

— Качмыйм, Агыйделкәй!

Кояш бераз гына туктап торгандай булды, таулар артына тәгәрәргә теләмәде, салмак кына сүзен башлады.

— Кешегә,— диде Кояш уйчан гына,— әгәр ул җиргә нык басып торырга, күкләргә күтәрелергә теләсә, ике канат кирәк. Ул канатларның берсе — сәламәтлек, икенчесе — белем. Беренче канаты турында кеше яшьлегендә уйлап та карамый, җилдәй җитез йөгерә, арыса, барын онытып, йоклый, ләззәтле халәттә була, сызланмый, газапланмый. Чөнки ул яшь, яшь организм хәрәкәт тели, биетә, җырлата.

Ә белем... Ул кешегә бик кирәкле икенче канат үзеннәнүзе генә килми. Ул табигать бүләге генә түгел. Ул канатны һәр каурыен кадерләп, аз-азлап җыя-җыя үстерә белергә кирәк. Кешегә урта белем, ягъни көтек канат кына җитми, югары белем кирәк, карчыга канаты кирәк...

***

Фәһимә институтның урыс һәм татар теле факультетына укырга керде. Имтиханнарны да бик җиңел тапшырды.

Институт мохите Фәһимәне тулы килеш үз эченә алып кереп китте. Беренче курста ук аны группаның комсомол оешмасы секретаре итеп сайладылар. Бер сессиядән икенче

сессиягә кадәр баш күтәрми уку, язу, лекцияләр, коллоквиумнар, семинарлар һ.б...

Вакыт бик тиз узды. Ә үткәннәр үтә күренмәле томан эчендә югала баргандай булды. Үткәндәге матур көннәр кинәт-кинәт искә килеп китсә дә, аларны инде онытырга сүз бирде Фәһимә. Ләкин онытып бетерә алмады.

Тулай торак. Тимер караватлар. Бер бүлмәдә унике кыз, унике холык, унике гамәл. Күбесе авыл кызлары. Арада бер-икесе урыс кызлары, шәһәр балалары. Киемнәре, килеш-килбәтләре башкарак. Алар авыл баласы күрмәгән челтәрле эчке күлмәкләр, биек үкчәле нәфис туфли кияләр, көн дә кайдадыр күңел ачып кайталар.

Фәһимә дә ике ел авыл мәктәбендә укытып килде, аның да алмашка бер-ике күлмәге, гәүдәсенә бераз олырак кышкы пәлтәсе, бер халаты, аягына биек үкчәсез булса да, туфлие бар.

Фәһимә икенче курста укый иде. Дуслары, туганнары белән хат алышты. Хатларда авыл яңалыклары, күңел ачу кичәләре, концерт, спектакльләр турында яңалыкларны белешеп торды. Менә бер көнне ул берьюлы ике хат алды. Икесендә дә бер яңалык. Дусты Сәлимә хатында да, апасы Зәйнәпнекендә дә бер үк сүз. «Бөтен авылны шаккаттырып, көтмәгәндә Шәһит өйләнде. Энесе Вахит өйләнәм дип кайтып әйткәч, бу башын тотып, телсез калган, ди. Аннан күрше кызы Фагыйләгә димче җибәргән, ди, Фагыйлә риза булган, Шәһит белән Вахитның туйлары бергә булды»,— дип язган иде Сәлимә.

Фәһимә бу хатны салкын гына, бер дә исе китми генә укып чыкты. Өйләнгән икән, өйләнгән. Шулай булырга тиеш иде, чөнки Фәһимә институтка кергәч, Шәһиткә, безнең юллар аерылды, башка минем белән күрешү эзләмә, дигән иде. Шәһит нәрсә генә әйтсә дә, ул бу сүзләрнең катгыйлыгын, кире кагарга мөмкин түгеллеген белә иде.

Әмма... Фәһимә әллә нишләде. Хатны вак-вак кисәкләргә ерткалап ташлады да, йөзе белән мендәргә капланып, стенага таба әйләнеп ятты. Димәк, яратмаган, димәк, сүзләре ялган булган.

— Ни булды, Фәһимә?

— Әллә кайгылы хәбәр язганнармы?

Фәһимә бер сорауга да җавап бирмәде, гүя ул аларны ишетмәде.

Фәкать үткәндәге ниндидер тонык, онытылып бара торган хәтирәләр килеп, кайберләре менә-менә кичә генә булган хәлләр кебек күз алдына килеп бастылар.

***

Фәһимә педучилище тәмамлап авылда укыта башлады... Унсигез яшьлек җитез, матур кыз. Егетләр дә күз салмый калмады. Берсе килеп серен уртаклашырга омтылса, икенчесе бәйләнеп карады, өченчесе озата килде. Ләкин Фәһимә берсенә дә ачылмады, яратмады, берсен дә үз итә алмады.

Авылга икенче көзне диңгезчеләр формасы киеп, төз, күркәм гәүдәле, чибәр Шәһит кайтып төште. Авыл кызларының һушын алып, энесе Вахит белән пардан киенеп, кичләрен клубка киләләр, икесе дә гармунчы. Әле берсе, әле икенчесе уйный.

Бер кичне буй бирмәс Фәһимәне Шәһит озата кайтты. Аның күңелгә ятышлы сөйләшүе дә, яше белән үзеннән олырак булуы да, килеш-килбәте дә — барысы да Фәһимәне әсир итте. Ләкин ул, гадәттәгечә, артыгын ачылып китмәде, үзенең бер күрүдә ярата башлавын сиздермәде. Кышкы бураннарда аның белән урам таптау, кар яру ничектер күңелле дә, рәхәт тә иде. Яз җиткәч, Шәһит Фәһимәгә тәкъдим ясады.

— Фәһимә, — диде, — миңа өйләнергә вакыт, минем белән язмышыңны бәйләргә син ризамы?

Фәһимә дәшмәде. Ашыгып сөйләшү, хискә бирелеп китүләр аңа ят нәрсә иде.

— Әйт, ризамы?

Фәһимә үзе дә сизмәстән йомшак кына көлде дә:

— Юк, мин «Риза» түгел, минем исемем Фәһимә,— диде.

Фәһимәнең сүз уйнатуын аңлап, Шәһит тә көлде. Ләкин кызның аңа карата салкынлыгы, җитди булмавы, аның ихлас күңелдән әйтелгән сүзенә шаярып җавап бирүе аны гаҗәпкә калдырды. Бар иде Шәһитнең Фәһимәгә кадәр йөргән, озаткан кызлары! Ләкин алар бөтенләй башка иде. Бер-ике кич озату белән кочакта эреργә әзерләр иде. Ә

Фәһимә — башка. Ул тыйнак, сак һәм артык җитди. «Укыган кеше...» дип уйлады Шәһит. Күршесе Госман, туры килсә-килмәсә: «Укыган кеше — чукынган кеше, бер чиләк катыкны эчте дә бетерде»,— дип шаяртырга ярата.

Беркөнне гадәттән тыш сөйләшү булды. Шәһит бөтен җитдилеге белән сүз башлады.

— Уенга алма, Фәһимә, әйдә сөйләшенгән, әни хәерфатихасын бирде. Мин синсез яши алмыйм, син дә... мине яратасың... дип беләм. Чык миңа кияүгә, бир ризалыгыңны.

— Юк,—диде Фәһимә,— мин әле яшь, миңа үсәргә кирәк.

— Үсәргә? Күпме үсәргә тагын?

— Йолдызларга кадәр үсәргә,—диде Фәһимә һәм тагын көлеп җибәрде, үзе дә бу кыланышын ошатмады.

Әмма җитди итеп Шәһиткә җавап бирерлек хәлдә дә түгел иде. Ярата иде ул аны. Ләкин уку теләге, белем алу теләге барыннан да өстен иде.

— Кыланма, Фәһимә, әйдә, чын күңелдән сөйләшик.

— Чын күңелдән булса, шул: мин быел институтка укырга китәм.

— Укырга? Тагы күпме укырга?

— Укырга. Биш елга.

— Ярар алайса, биш елга мин түзәрмен.

— Түзәрсең? Юкны сөйләмә, Шәһит. Биш ел — бу бит синең кебек яше егерме биштән үткән кеше өчен тулы бер гомер.

— Мин бөтен гомер буе көтәргә әзер.

Фәһимә Шәһитнең җиңел генә итеп «көтәргә әзер» дигән купшы сүзенә ышанмады.

Һәм менә Шәһит өйләнгән. Дөрес иткән. Биш ел көтү үзе бер юләрлек булыр иде. Онытырга, онытырга. Бөтенләй хәтердән юк итәргә, сызып ташларга! Бу көннән соң Фәһимә бик нык үзгәрде. Кайвакыт чиктән тыш җитди, кайвакыт үтә дә шаян булырга тырышып, җырлый, көлә. Көлә-көлә дә, үзе дә сизмәстән, күзләренә яшь тыгыла. Андый минутлардан соң аның шомырт-кара күзләрен томан каплагандай була, йөзе моңсулана, ятим балага охшап кала, үз-үзен кочаклап, тын гына керфек какмый бер ноктага төбәлеп утыра.

— Нәрсә булды? Ник тын калдың? — ди дус кызы Нәҗибә.

— Юк, болай гына.

Фәһимә уянып киткәндәй була. Әмма серен чишәргә ашыкмый. Бу минутта аңа дус кызы да ят, чит кешегә әйләнә.

Беркөнне алар группа белән «Сөйлә безгә үзең турында» дип аталган «түгәрәк өстәл» сөйләшүе әзерләделәр, һәркем үзе турында, хисләре, мәхәббәте, табышлары, югалтулары турында сөйләде. Һәркемнең сер капчыгы кагылды. Фәһимә дә үзенең Шәһиткә булган мәхәббәте, Шәһитнең өйләнүе турында энәсеннән җебенә кадәр сөйләп бирде. Аңа ничектер җиңел булып китте. Җилкәсеннән ниндидер авыр йөк төшкәндәй булды. Дусларының да аңа ышанычы артты.

***

Гыйнвар ахыры. Көннәр суык тора. Әле буран чыгып юлларны калын кар каплый, әле бик көчле көньяк җиле яуган карны ялап алгандай каядыр алып китеп яр араларына, таллыкларга сылый, юллар ялтырап кала. Тагын болыт каплап, җилсез-нисез йомшак кар ява. Шундый көннәрнең берсендә гомер тәгәрмәче җитмешкә таба тәгәрәгән Гыймалелислам белән Бибиәсманың ягарга утыннары бетте. Карап торган бер кыска аяклы, озын мөгезле, ак маңгайлы коба мөгезбикәне җигеп, алар утынга барырга җыендылар. Бүген-иртәгәлек кисеп өелгән чыбык-чабык булса да, алар киңәш-табыш иттеләр.

— Йә иртәгә буран кубар, кортка,— диде Гыймалелислам, — каян беләсең, бүген суык булса да, бураны юк, җиле юк.

Күршеләрдән камыт-ыңгырчак алып, үрәчәле иске чанага сыерны җигеп, чананың төбенә бер кочак печән салып, карт белән карчык утынга киттеләр.

Утын дигәннәре — күл буенда үскән кәҗә талы. Сыер алдына печән салып, үткен балта белән Гыймалелислам карга бата-бата, тал кисте, Бибиәсма киселгән талны чана янына ташый торды. Чанага төяп, аркан белән аркылы-торкылы бәйләп, әгузе-бисмилла белән кайтыр юлга чыктылар. Сыерның бу беренче баруы түгел, ат булып чана тарту ул — аның яшьтән өйрәнгән һөнәре. Сыер карышмады, имчәкләрен ике якка селкетә-селкетә салмак кына иңрәеп, бар көчен җигеп авылга таба атлады да атлады. Гыймалелис-

лам йөк артыннан атлый-атлый бүрек колакчыны бавын ияк астына бәйләп, бозланган мыегын сыпырып алды, «Әйдә, малкай!» дип, сыерны әледән-әле куалады.

Бибиәсма да, чи тал ташып шакыраеп каткан бияләйләрен бер-берсенә шап та шоп бәргәләп, шәлен ияк астына әйбәтләп кыстырды. Ике кулын артка куеп, кар ябышып авырайган олтанлы каталарына күзен төбәп, әкрен генә кыштыр-кыштыр карты артыннан теркелдәде.

Сыер әледән-әле туктап ял иткәләде. Гыймалелислам юл читеннән көрт ерып, тиз-тиз атлап, чана кырыена килде. Утын бәйләгән арканнан эләктереп, чананы селкеткәләп, сыерга кузгалырга ярдәм итте: «На, малкай!»

Менә алар авылга якынлаштылар.

— Син, кортка, авылга менеп, тыкрыктан туры кайт, якынрак булыр, алдан кайтып, миңа капка ачып торырсың. Ә мин Ат тавыннан әйләнермен, анда юл яхшырак,— диде карт.

Карчык, аның сүзен җөпләп, башын селекте һәм, авыр аякларын көчкә сөйрәп, тыкрыкка күтәрелде.

Ике яклап кар көрте өелгән тар тыкрыкта трактор чанасына төялгән, фиргавен тавы чаклы печән йөге юлны бүлгән. Алда, усал үгез кебек пошкырып, трактор тырылдый, төтен белән пошкыра. Йөкнең ике ягында ирләр, кул болгый-болгый, нидер кычкыралар, акыралар, сызгыралар. Бибиәсма акрын гына атлап, печән йөге артына килеп туктады. Трактор бертуктаусыз үкерде, төтен чыгарды. Бу печән тавын үтеп китүдән өметен өзеп, әрле-бирле каранып торган арада, ямьсез чыелдык тавышлар чыгарып, печән йөге тырык-тырык селкенгәләп, кинәт артка чигенә башлады. Карчык каушап калды. Ни алга, ни артка атларга белми торган арада, аягы таеп, егылып китте, үрмәләде, торырга азапланды, тора алмады. Ә трактор чанасы коточкыч шыгырдап аның өстенә килеп менде. Бибиәсма чананың ике табаны арасында калды. Ә чана, гайрәт чәчеп, шыгыр-шыгыр чигенде дә чигенде, карчыкның чана астында калганын беркем дә күрмәде.

— Ай! Ай! Балалар! Беттем бит,— дип аваз салды карчык.— Коткарыгыз!— дип кычкырды, тавышы гына чыкмады.

Әҗәлем шушы икән, ачы язмышым, күрәчәгем шушындадыр, дип чытырдатып күзләрен йомды. Чананың аркылы агачы аны аягыннан эләктереп, алга таба сыдырды, аннан артка таба шудырды. Карчык:

— Лә-илаһа-иллаллаһы!— дип пышылдады. Шушы догасын кабатлады да кабатлады. Ә трактор аждаһадай чигенде дә чигенде, чана шыгырдады да шыгырдады.

— Фью!— дип ачы сызгырды кемдер. — Туктат тракторны!

— Нәрсә бар?

— Трактор белән чана арасында ниндидер аяк! Олтанлы киезката! Туктат тракторны!

Кемнәрдер йөгереште, кемдер кычкырды, кемдер сызгырды:

— Фью! Туктат! Туктат!!

Тракторчы педальгә басты:

— Нәрсә бар?

Трактор туктады.

— Һәй! Чана астында әллә берәрсе бармы? Кем бар анда? — дип кычкырды печән чанасы астына иелеп колхозчы Сабир.

Бибиәсма булган көчен җыеп:

— Мин, балакаем, мин монда!— дия алды.

Тракторны тагын бераз алга таба тарттырдылар. Чана астыннан бите кара кан, чәче, шәле кар белән укмашып каткан Бибиәсманың гәүдәсен тартып чыгардылар. Иске бишмәте телгәләнеп беткән, якасы умырылган, җиңе өзелгән, кул-аягы берни тоймый асылынып тора иде.

— Муллаҗиңги, син түгелме соң бу?

— Бибиәсма җиңги, ничек чана астына килеп кердең?

Бу хәлгә барысы хәйран калып, ис-акыллары китеп тордылар.

Каяндыр чана алып килеп, карчыкның ярымүлек гәүдәсен җирдән күтәреп алып чанага салдылар.

Бибиәсманы алып кайтканда, Гыймалелислам инде сыерын тугарып печәнгә кушкан, үзе утын бушатып ята иде.

Карчыгының канга баткан гәүдәсен күреп, Гыймалелислам катып калды.

— Нәрсә булды? Кайда болай булды ул?— дип илерде карт...

***

Фәһимә ул таңда бик иргә уянды. Таң сирпелеп кенә килә иде, бүлмә эче кап-караңгы. Тулай торакта яшәүче кызлар әллә кайчан инде каникулга таралдылар. Кемнедер ат белән, кайберләрен машина белән килеп алдылар. Ә Фәһимәнең туган авылына кадәр ике йөз чакрым юлны Ходай кулыннан төшеп калган очраклы транспортта, очраклы юлчылар белән үтәсе бар.

Ул уйланып, хафаланып бераз ятып торды. Әле бик иртә, юл хәвефле, кояш чыкмый юлга чыгарга ярамас.

Уйланып ята торгач, беренче төшен исенә төшерде. Нәрсә күрде соң әле ул? Нинди шомлы төш? Әйе, әйе. Үзләренең бәрәңге бакчасы. Бакча артындагы читәндә кап-кара карлыган тәлгәшләре. Берсеннән-берсе озын тәлгәшләр асылынып тора. Фәһимә җырлый-җырлый шул карлыганны җыя. Чиләгенә сала тора, ә куакларда карлыган һич кимеми, киресенчә, арта гына, карлыганнары кап-кара. Җыры да әнисе җырлый торган шул ук җыр:

Бүгенге авыр хәсрәттән

Үлмичә калсам ярый...

Фәһимә кинәт сикереп торды, көзгесенә күз салды. Күз төпләре бераз шешенгән. Саташып йоклаган, шуңа шешенгән. Ә карлыган ул — ризык. Ризыкка булсын, дияр иде әнисе. Юлга әзерләп куйган әйберләрен тагын бер мәртәбә барлап, киемнәрен киенде. Ашыкмый гына юынды, чәй кайнатып эчте. Ләкин ничек кенә тыныч булырга тырышса да, юлга чыгу шик-шөбһәсез, икеләнүләр, борчылуларсыз булмый. Ничек кайтып җитәр? Бик авыр кайткан чаклар була, юлда да төрле кеше очрый. Яхшысы, начары...

Фәһимә шәһәр читенә — олы юлга чыгып басты. Җир өстенә чыгып килүче кояш инде беренче нурларын озын-озын учмалар итеп мул сибә иде. Көн аяз, салкын. Олы юлның каткан карын чәрдәкләп-чәрдәкләп, зур чанасын өстерәп, чылбырлы трактор килгәне күренде. Фәһимә, трактор якынлашкач, кул күтәрде. Тирә-якны шау-гөргә

күмгән бу гигант кыз янында туктады. Кабина эченнән кара тун кигән тракторчы сузылып кына Фәһимәгә дәште:

— Кая барасың, сеңлем?

—Минзәлә ягына.

— Утыр әйдә, чананы сытмасаң,— дип, эре тешләрен күрсәтеп, киң итеп елмайды. Әллә Фәһимәнең җиңел сөякле булуына ишарә ясап, әллә киеме юкалыгын күреп шаяртты.

Фәһимә биек итеп төялгән трактор чанасына үрмәләде һәм толып якалары эченнән ялтыраган күзләр күреп елмайгандай итте. Кинәт трактор кузгалып куйды, кыз башта артка чайкалды, аннан җайсыз гына толыплылар арасына барып төште.

— Кил, кызым, минем толып чабуы арасына кер, өстең бик юка, туңарсың, бүген көн усалрак, чеметкәләр үзеңне,— диде олы яшьтәге абзый.

Фәһимә Минзәләгә кадәр шул агайның чабуына ышыкланып, йокымсырап кайтты.

Минзәләдән соң ул бераз җәяүләде, бераз атка утырды, тагын җәяүләде. Ул көнне авылына кайтып җитә алмады. Унике чакрым кала, Суыксу авылында, туганнарында кунды.

***

Ничә еллар инде Фәһимәне шушылай туган авылының Түбән Очында карт өянкеләр шаулашып каршы ала! Бүген алар иртүк бәйрәмчә киенгәннәр, ап-ак сыкыга төренгәннәр. Өянкеләрне үтеп, авылга күтәрелгәндә, кәефе күтәренке иде аның. Каршысында җаннан да кадерлерәк ягымлы өйләр, һәркайсының морҗасыннан күккә ашкан ак төтен чыга. Урам да аңа елмая, аны сәламли кебек.

Ул адымын тизләтте. Менә әнкәсе аңа каршы чыгар, табагач исе, карабодай тәбикмәге исе бөркеп, аңа ике кулын сузар.

«Кайттыңмы, бәбкәм, бик сагындык!»— дияр.

Фәһимә аның сөякчел бармакларын учларына алып күшеккән кулларын җылытыр, аннан әнкәсенең җыерчыклы яңагына үзенең кайнар иреннәрен тидерер...

Кары икегә аерып көрәлгән капка төбеннән ул үзләренең «урыс капка»сына якынлашты, сак кына киләсен күтәрде,

капка ачылып китте. Аңа гадәттәгечә карабодай тәбикмәге исе килгәндәй булып куйды. Ләкин ишегалдында да, өйалды баскычында да җан әсәре юк. Бүген аны әнисе каршыларга чыкмады. Ишегалды түрендә, утынлык янында яңа кайткан кәҗә талы өеме. Әтисе Гыймалелислам да утынлык янында күренмәде. Фәһимә йөгереп диярлек биек болдыр баскычына менде, шыгырдатып ишекне ачып җибәрде.

— Һәй, исәннәрме? Өйдә кем бар? — диде, кайтып җитүен белдереп, әнисенең ашыгып килеп чыгуын өмет итеп.

Ләкин беркем дә җавап бирмәде.

Фәһимә өй ишеген ачты, тупсаны атлап өйгә керде. Өй эче тып-тын. Карт әнисенең түшәк өстендә, ак бинт белән уралып беткән битен, кул-аякларын күреп, Фәһимә һушын җыя алмый, үз күзләренә ышанмый, бер мизгел катып торды. Аннан, кызу-кызу атлап, ялгыз яткан анасы янына килде:

— Ни булды? Нишләдең?—дип илерде һәм сак кына әнисенең иске күлмәге аша калкып, тырпаеп торган сөякчел ябык күкрәгенә маңгаен терәде, кичә генә күргән төше, кара карлыганнар исенә төште.

— Инәкәем, мине гафу ит! Мин синең ярдәмчең була алмадым,— диде һәм тагы да көчлерәк сулкылдап елап җибәрде.

— Елама, балам, буласы булган,— диде ана ыңгырашып, — мин күрәсен кеше күрмәс. Йөрәгеңне телгәләмә, мин карт инде. Ходай хөкеме шулай булгандыр. Заманасы шул: яшьләргә укырга, картларга үлгәнче дөнья куарга язган...

Ананың бу сүзләрендә Фәһимә бераз шелтәләү дә, үпкә дә, үз язмышына ачыну да сиземләде. Ананың да, баланың да бу мизгелдәге халәтен ачык кына аңлатыр өчен сүзләр генә көчсез иде.

Фәһимә алдында зур сорау туды: укуын дәвам итә алырмы? Хакы бармы аның ата-анасын бу авыр хәлдә ташлап китәргә? Бик озак сөйләшүләр, күз яшьләре, үкенүләр булды. Чиктән ашкан өметсезлек, чарасызлыкка каршы язмышның нинди генә каршылыкларына да баш имәскә, аек акыл белән һәр очракта дөрес юл табарга өйрәнгән, зур тормыш тәҗрибәсе булган ата кеше үзенең катгый жавабын ярып салды, төгәл сүзен әйтте:

— Без яшисен яшәгән, баланың язмышын кыл өстенә куярга минем хакым юк, укысын, белем алсын. Без ничек тә бу авыр хәлдән чыгарбыз, үз-үзебезне карарбыз.

— Без бар бит әле,—диде олы кызлары Зәйнәп. — Ташламабыз, ярдәм итәрбез, менә Равил дә кайтыр...

***

Кеше үзенең язмышына озын юллар аша килә. Туганда ук маңгайга язылган язмыш дисәләр дә, язмыш кешенең үз кулында. Кеше язмышын, үз бәхетен үзе кора, үзе юл сала.

Институтның соңгы курсында укыганда Фәһимә Әгъзәм исемле егет белән танышты...

Шимбә көн була торган танцыларга шәһәрдән яшьләр күп җыела. Шундый кичәләрнең берсендә табигате белән бик тыныч, базык гәүдәле бер егет Фәһимәне танцыга чакырды. Аның киң итеп ачылган ак якасы эчендә шома таза муены, яшьлек бөркеп торган юан беләкләре, киң маңгае өстендә күпереп торган шомырт-кара чәче һәм татар егетләрендә генә очрый торган ягымлы моңсу күзләре Фәһимәне әллә нишләтте.

Егет әрсезләнмәде, төчеләнмәде, күп сөйләшмәде. Үзенең бик оста биюче түгеллегеннән кыенсынып кына, кулын да кызның биленә тидерер-тидермәс, сак кына, ашыкмый-кабаланмый бөтерелде, үзе ни өчендер тирләп чыкты, йөзе алсуланды. Бу кадәр дә кызлар кебек оялчан, әдәпле егетне шәһәрдә беренче тапкыр очратты Фәһимә. Кем ул, авылдан-мы, шәһәрдә үскәнме, шул турыда уйлады. Әгъзәм бу кичәдә гел Фәһимә белән генә биеде, һәм исемен сорарга җөрьәт итте.

— Танышып кую яхшы булыр,— дип сүз башлады ул, өченче тапкыр танцыга чыккач. — Минем исемем — Әгъзәм.

— Ә мин — Фәһимә, соңгы курста укыйм.

— Димәк, соңгы елыгыз?

— Әйе, соңгы елым.

— Соңгы очрашу дияргә теләмисездер бит?

— Анысы сездән тора,—диде Фәһимә сүзенә бик тирән мәгънә салып.

Кыз, бу чибәр егеткә битарафлык күрсәтүне үзе өчен оятсызлык булыр иде, дип уйлады. Аңа мөмкин кадәр үзенең җылы карашын, ягымлы йөзен күрсәтергә тырышты, чөнки ул бу егеттә башка егетләргә хас булмаган сыйфатлар күрде. Моңарчы да Фәһимәгә күз атучылар булмады түгел, булды, хәтта кулын гына түгел, йөрәген тәкъдим итүчеләр табылды, ләкин аларда кыз үзенә таяныч булырлык җитдилек, эчкерсезлек тоймады. Фәкать аның алдынгы, абруйлы кыз булуыннан файдаланып калу нияте, су өстендә калыккан май табы кебек, ялтырап тора иде. Ә Әгъзәм — бөтенләй башка.

Фәһимә күрешү, очрашу, атнага бер була торган танцы кичәләрен көтеп җиткерә алмый иза чикте. Ләкин ул үзенең хисләрен бик тирән яшерде, лаф ормады, уфылдамады, беркемгә дә серен чишмәде. Ул яшьтән үк ахмаклыкны, шамакайлыкны гына түгел, артык беркатлылыкны да яратмады. Аның өчен кешенең табигыйлыгы, хәтта бераз гына кырыслыгы, туры сүзлелеге кыйммәт иде.

Әгъзәм исә Фәһимәнең башкалардан аерылып күзгә ташланган пөхтәлеген, гади җыйнаклыгын күреп алды. Кыз нәфис гәүдәсенә бик килешеп торган гади күлмәк кигән, чәчен авыл кызларыча үреп, баш артына җыеп куйган, бите чип-чиста, кара каләм, иннек-кершән төшмәгән. Табигать биргән сафлык бөркелә.

Менә шул гадилек, сафлык җәлеп итте егетне. Аңа инде унҗиде яшь түгел, аның ялтыравыклы гүзәлләр белән гыйшык-мыйшык уйнар чагы узган. Бәлки шушы кыз аның соңгы тукталышы, шушы гади кыз — аның язмышыдыр.

Әйе, алар икесе дә авыл балалары. Ике як кешеләре, ерак авыл, хәтта ерак район кешеләре иде. Бергә үсмәделәр, бергә уйнамадылар. Күрештеләр, очраштылар һәм берсе икенчесе өчен туган икәнен аңладылар.

***

Дәүләт имтиханнары җитте. Җиң сызганып сынауларга әзерләнү, чабышкы ат кебек соңгы киртәләрне сикереп чыгарга җыенган киеренке көннәр. Биш ел буе алган белемнәрне мәртәбәле комиссия алдында күрсәтәсе, хисап бирәсе.

Иртәгә сабан туе дигән көнне Фәһимә белән Әгъзәм

бәйрәмгә бергә барырга сүз куештылар. Өскә нәрсә, аякка нәрсә кияргә — барысы килешенде.

— Сәгать тугызларда килермен,—диде Әгъзәм.

Ул төнне Фәһимә әсәрләнеп, үзенең якты киләчәге турында хыялланды. Менә алар сөйгәне Әгъзәм белән киң юлдан икесе җитәкләшеп сабан туена баралар. Тирә-якта күпләр аларның матурлыгына сокланып карап калалар. Аларның бәхет канатлары — ялтыравык каурыйлар, җилдә җилфер-җилфер чәч җилферди, күзләр яна, алар әле көләләр, әле җырлыйлар, әле йөгерәләр, әле очалар.

Әйе, Фәһимә белән Әгъзәмнең бер-берсенең җылысын тоеп, җитәкләшеп, бер җан, бер тән булып олы гомер юлына чыгар көннәре җиткән. Фәһимә дә кавышырга, язылышырга каршы түгел. Барысы уйланган, килешенгән. Дәүләт имтиханнарын тапшырып, диплом алып, Фәһимә авылга кайтып китә, ә Әгъзәм берничә көннән аларга бара, йола буенча Фәһимәнең әти-әнисеннән хәер-фатиха бирүләрен сорый. Аннан язылышу, туйлар...

***

Тулай торак кызлары бик иртә торып, сабан туена барырга әзерләнделәр. Күлмәк үтүкләделәр, чәч бөдрәләттеләр, киенде-ясандылар, бизәнделәр.

Фәһимә дә ашыкмый гына әзерләнде, сәгатенә карый-карый Әгъзәмне көтте. Сәгать тугызларда кызлар барысы бергә гөрләшеп чыгып киттеләр.

— Син, Фәһимә, Әгъзәмне көтәсеңме?

— Әйе, тугызда килергә тиеш.

— Ярый, көт, бергә барырсыз, сезне көтеп торырбыз,— диде дус кызы Нәҗибә, егете Заһит килгәч.

Бүлмәдә Фәһимә берүзе генә калды. Сәгать тугыз тулып, ун минут, унбиш минут үтте. Әгъзәм һаман күренмәде. Фәһимә дулкынлана башлады. Нәрсә бу? Вәгъдәсезлекме? Алдаумы? Нәрсә? Ул үз-үзен кая куярга белмәде. Ун да тулды. Әгъзәм килмәде. Фәһимә ни еларга, ни көләргә белмәде. Бу кадәр ахмакларча алданганы юк иде әле аның... Менә шунда әнисенең: «Иделгә таянма, ирләргә ышанма»,— дигән сүзләре исенә төште. Иң ышанычлы, иң тәртипле, тыйнак Әгъзәм дә бөтен ирләр кебек ышанычсыз, затсыз

булыр микән? Юк, юк. Нәрсә дә булса булгандыр, йә юлда бер-бер хәвеф-хәтәр килеп чыккандыр. Ул килергә тиеш иде, шулкадәр ышанычлы итеп әйтте бит.

Фәһимәнең күңеленә әллә нинди шөбһәле уйлар килде. Бер караганда, ул Әгъзәмне хыянәттә гаепләде, бер караганда, аны яраланган, хәтта үлгән итеп күз алдына китерде. Килер иде, һичшиксез, килер иде!

Фәһимә, сабан туена барудан өметен өзеп, матур күлмәген салып, халатын киде, китапларын алып имтиханга әзерләнергә утырды. Өстәл артына утырып, китабын, лекцияләр дәфтәрен ачты, тик башына берни кермәде, ни бирелеп укый алмады, ни яза алмады. Башын, миен бары бер нәрсә борауллады — Әгъзәм ник килмәде? Ни булды?

Ике көннән соң, дүшәмбедә, кич Әгъзәм тулай торакка ялтырап килеп керде. Гүя берни булмаган. Фәһимә исә аның белән сүз алышырга, хәтта аңлашырга да теләмәде. Аның күңел көзгесе гүя шушы көндә тагын бер мәртәбә челпәрәмә килде, ватылды, фәкать истәлекләр булып кыйпылчыклар гына калды. Фәһимә Әгьзәмне үзенең язмышыннан сызып ташларга тиеш, мәңгегә онытырга һәм һичбер вакытта да искә алмаска.

Имтиханнарга да әзерләнерлек хәлдә түгел иде ул. Башын бер сүз яулап алды: хыянәт! хыянәт! Ә хыянәтне ул гафу итә алмый. Дәүләт имтиханнарында дуслары да, укытучылар да аны танымады: ул сулган, шиңгән чәчәкне хәтерләтте. Билгеләр дә түбәнәйде. Гел бишлегә генә тәмамларга, «кызыл диплом» алырга тиешле кыз ике фәннән дүртле билгесенә тапшырды. Нәрсәнедер бутады, кайдадыр ялгышты.

Фәһимәнең сөйләшергә теләмәвеннән гаҗиз булган Әгъзәм аңа хат язды. Ул анда үзенең килмәвенең сәбәбен аңлатты, гафу үтенде, яратуын, үлеп яратуын белдерде. Әллә кайлардан, Себер якларыннан мәрхүмә әнисенең энесе ике генә көнгә кайткан икән, кайтышлый үзе белән аны да алып киткән, Әгъзәм баш тарта алмаган.

Күңеле белән Фәһимә Әгъзәмне аңлады, хәтта кичерде. Ахмакланма, Фәһимә, акылыңа кил, бер Сабантуй күрмәгәннән әллә ни югалтмадың. Ә язмышың юлында очраган юлдашыңны югалтсаң, яманрак булыр, ялгыз калырсың,

дип фикер йөртте кыз, мәңге оныта алмассың, башканы үз итә, ярата алмасаң, нишләрсең?..

***

Гыймалелислам белән Бибиәсманы яшен суккандай көйдереп, хәлдән тайдырган тагын бер вакыйга булды. Институтта читтән торып укучы кияүләре Равил Зәйнәпкә хат юллаган.

«Фәһимә дәүләт имтиханнарын яхшы тапшыра, диплом алу белән тормышка чыгачак бугай, егете бар. Әгъзәм исемле. Болай яхшы кешегә охшаган. Әзер торыгыз, без икәү кайтачакбыз. Әби белән бабайга әйт, кыз бирергә әзерләнсеннәр».

Хатны уку белән Зәйнәп әнисе янына йөгерде. Әнисенә зур сөенче итеп, хатта ире әйткәннәрне сөйләп бирде.

— Сөенче, әни, Фәһимә озакламый кайта, диплом алып, кияү белән кайта, туйга әзерләнергә кирәк.

Ана телсез калды. «Ә» дияргә дә, «җә» дияргә дә белмәде. Күптән көткән көн килеп җитте, дигәндә, кызының бу сүзе аңа аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте.

— Нинди туй ул?—диде ана, ниһаять. — Бернинди туй булмаячак! Фәһимәне без җиде ятка бирер өчен укытмадык. Ул безне картаймыш көнебездә ташлап китәргә тиеш түгел! Ул безне карарга тиеш!

Аның тавышы гомер булмаганча катгый һәм кырыс иде. Яулыгы эченнән тузып чыккан чәчләрен җыештырып алды да, урындыкка утырып елый ук башлады.

— Картлык көнебездә бер караучысыз калырбыз микәнни?! Бәхетсез башкайларыбыз!

Ул арада Гыймалелислам кайтып керде. Уң кулын колагына якын китереп:

— Нәрсә бар? Ник елыйсың? Әллә суган әрчедеңме?— дип шаяртты.

Бибиәсма аның колагына ук якын килеп, кызы Зәйнәп сөйләгәннәрне түкми-чәчми сөйләп бирде.

— М-м... — диде карт.— Соң, кортка, моны ничек аңларга? Син бит Фәһимә кияүгә чыгарга җыенмый, укып бетергәч, безне карый, дип тәкрарлап килдең.

— Тәкрарлап, тәкрарлап! — дип үртәде карчык, ни

әйтергә белми.— Синең белән минем теләк — теләк түгел, имгәк булган ул. Әнә, сезне карыйм дигән иркә кызың тотакаба кияүгә чыга, ди. Бездән сорап та тормаган, ди.

— Кем әйтә?

— Кияү язган.

Зәйнәп, карт белән карчыкның сөйләшүләрен берсүзсез тыңлап торды да, үзенең катгый сүзен әйтергә булды.

Туктагыз әле, чыгырдан чыкмагыз! Мин дә сезгә бер генә сүз әйтим.

— Нәрсә? Нәрсә, син дә аның яклымы?

— Сез — карт юләрләр! Әллә кыз бала үз бәхетеннән баш тартып, яратам дип торучы барда, ялгыз бәбкәдәй каңгырап, буйдак булып калырга тиешме? Уйлап карагыз башыгыз белән! Үзегез ничә ел гомер иттегез, чөкердәшеп яшәдегез. Әллә аның балалар үстерәсе килмәсме? Кемнеңдер җылысына җылынасы килмәсме? Башыгыз олы, акылыгыз юк. Аңа инде егерме дүрт яшь. Сезгә терәк булырга без бар, киявегез бар. Ташламабыз.

Шулай да карт белән карчык аның сүзенә колак салырга, аның белән килешергә теләмәделәр.

Фәһимә берүзе генә кайтып төште. Карт белән карчык аны бик салкын каршы алды, кызым, балам, төпчегем дигән сүзләрне гүя алар онытканнар иде. Нәкъ бер атна аның белән сөйләшмәделәр. Фәһимә эти-әнисен танымады. Бу кадәр каты бәгырьлелеккә ул гаҗиз булды. Нәрсә булган? Нинди явыз көч аларны яңадан тудырган? Нинди давыл уйларын чуалткан, йөрәкләрен чәрдәкләгән? Фәһимә аңламады. Мәктәптә сәркатип булып эшләүче бертуган апасы Зәйнәп белән сөйләшергә уйлады. Зәйнәп бу хәлне аңа яхшылап аңлатып бирде.

— Сатып алынмаган биянең, тумаган колынның билен сындырырсың, дип чыккан тавыш икән бу, апа,—диде Фәһимә.

— Ник алай сөйләшәсең?

— Мин нык ышанып, ул һичшиксез киләчәк, дип әйтә алмаганга. Мин, яратса — килер, яратмаса — онытырмын, дип кайтып киттем.

— Озатмадымыни?

— Озатты, ничек кенә озатты әле! Вәгъдәләр бирде... Нишләр?..

— Ышанычлы кеше түгелмени?

— Хәзерге егетләргә ышансаң... Алар бит бүген сөям дисә, иртәгә хыянәт итә. Әни әнә һәрчак, ирләргә ышанма, Иделгә таянма, ди. Әнинең шул сүзе минем колагымда.

— Күптән танышмы?

— Ел чамасы. Соңгы курста. Чыгарылыш кичәсендә дуслар йөдәтеп бетерделәр, әйдәгез, бу мәҗлес сезнең туй булсын, диделәр.

— Мин риза, — ди Әгъзәм. — Фәһимә риза булса.

— Ә син ни диден?

— Әти-әни ризалыгыннан, хәер-фатихасыннан башка кияүгә чыгарга мин кәҗә бәрәне түгел, дидем.

— Дөрес әйткәнсең. Очсызлы булырга ярамый.

— Килерсең, сөйләшерсең, дидем. Кыз баланың кыйммәтле товар икәнен аңласын.

— Товар, дип, син бигрәк инде.

— Нигә? Товар булмый. Бирдем-алдым товарлар белән була инде. Бирсәләр, мине алалар бит инде, — Фәһимә кычкырып көлеп җибәрде. — Туу белән сатып алганнар. Иң кыйммәтле, затлы, карап торган бердәнбер күлмәгенә алышып алган түгелме соң әни мине? Шулай булгач, мин туу белән товар, хәзер дә — товар. Ләкин һиммәтле, затлы икәнемне мин бервакытта да онытмадым.

— Рәхмәт, сеңлем, сүзләрең дөрес. Әнә Габидулла кызы Сәхия ниндидер урыс егете ияртеп кайтып, әти-әнисенең һушын алды. Бу минем ирем, дигәч, Габидулла белән Маһи телсез калганнар, ди. Авыз ачып сүз әйтә алмаганнар, ди.

Бу сөйләшүдән соң берничә көн үтте. Фәһимә Әгъзәмнең киләчәгенә тәгаен генә ышанмаса да, беркая чыкмады, клубка бармады. Йөрәге белән көтте. Күңеле белән икеләнде.

— Кайттылар,— дип кычкырып ук җибәрде Бибиәсма беркөнне, урамда туктаган җиңел машинадан төшүче кияве белән ят кешене күреп.

Шул сүзне ишетү белән, каушауданмы, Фәһимәнең кулындагы чынаягы идәнгә төшеп китте, челпәрәмә килеп ватылды.

— Бәхеткә булсын,— дип пышылдады Фәһимә.

— Нинди бәхеткә?! Савыт-саба бәхетсезлеккә ватыла ул. Бәхетсез бала икәнсең,—дип ачыргаланды ана кеше һәм

яулык почмагы белән күзләрен сөртә-сөртә, кече якка атлады. Фәһимә, иелеп, чәчелгән керәч ватыкларын җыйды.

«Каргама, әнием, каргама,
Каргышың кабул булмас.
Минем бәхетем булмаса,
Синең дә җаның тынмас»,—

диясе килде Фәһимәнең. Тик ул күңелендәгесен әйтеп бетермәскә өйрәнеп бара иде инде.

***

Кыз ярәшү, кызның кулын сорау гадидән дә гади, көтмәгәнчә бик җиңел булды Әгъзәмгә.

Таныш түгел бу чибәр яшь егетнең кем икәнен Гыймалел-ислам тиз аңлады, күрү белән ни өчендер аны үз итте, аңа бу егет үз улы кебек якын, җаныннан аерылып төшкән баласы кебек кадерле булып китте.

— Әйдәгез, түрдән узыгыз, өстәл янына,— диде карт бераз каушый төшеп, өй тутырып ике яшь кеше тупсадан атлап килеп кергәч.

Үзе нәрсәгә тотынырга белми арлы-бирле килде, урындыкларны урыннарыннан этебрәк куйды, елмаеп, таныш булмаган егетнең киң маңгаена, акыллы күзләренә карап алды. Ниһаять, исенә килеп, кияве Равилгә кулын сузды:

— Күрешик, кияү, исән-сау кайтып җитүегез белән,— диде.

Ак ашъяулык ябылган өстәл өстенә тәлинкә белән берничә телем ипи куелды, чынаяк белән каймак, җамаяк белән катык кебек, көтелмәгән кунак килеп кергән очракта куела торган ризыклар өстәлдә урын алды.

Гыймаделислам, кунаклар хөрмәтенә, иелеп кенә, өйнең түрен икегә бүлеп торган шкафның аскы бүлегендә торган, күптән кузгатылмаган әче бал салынган графинны чыгарып өстәлгә куйды, стаканнар алып, аларга гәрәбәдәй сары әче бал койды. Күбекләре чәчрәп чемердәп торган әлеге бал күңелләрне күтәрде. Карт үзе дә сизмәстән:

— Яле, яшь кияү...— дип сүз башлаган иде, кече якта чаршау артыннан һәр сүзгә колак салып утыручы Бибиәсма, сөякчел кулын сузып, картның күлмәк чабуыннан тартты:

— Ни сөйлисең, карт! Нинди кияү әле ул? Кешенең кем икәнен белмәс борын!— дип үрсәләнде.

— Шаулама, кортка! Мин үзем беләм.

Ике кияү берьюлы көлеп җибәрделәр.

— Бер дә беләсе юк! Күрәм мин, төпчегемнең булачак кияве шушы, дип беләм. Килгән, рәхмәт төшкере, безне олылап килгән. Ата-баба йоласы белән кыз сорарга килгән. Рәхмәт аңа.

— Шулай, бабай, сүзең дөрес, — диде Әгъзәм, ниһаять, телгә килеп.

Ике көннән никах мәҗлесе билгеләнде. Яшьләрнең никах укытуга каршы төшүенә карамастан, Гыймаделислам белән Бибиәсма бертавыштан: «Никахсыз кыз бирмибез. Никах зинадан һәм хәрамнан саклый ул»,— дип нык тордылар. Җомга көн кич белән кунаклар һәм шаһитлар җыелды. Өйдә, югын бар итеп, табын әзерләнде. Никах хотбәсен укырга авыл мулласын дәштеләр.

— Никах булачак хатын белән ир өстенә бурычлар йөкли, никахны саклый белү, таркатмаска тырышу, тугрылыклы булу — бу ике яшьнең бердәй бурычы,—дип башлады мулла үзенең сүзен.

Никах ашыннан соң ана белән кыз арасында күптән түгел булган үпкә-ачулар юкка чыкты, онытылды. Алар тагын бер-берсенә бик якын, бик кадерле кешегә әйләнделәр.

— Кызым, Фәһимә, — диде Бибиәсма икесе генә калгач, — сине институтта нәрсәгә өйрәткәннәрдер, мин анысын белмим. Әниең буларак, тормышның ачысын да, тәмлесен дә бик күп татыган кеше буларак, сиңа әйтәсе сүзем күп. Бу сүзләрне сиңа миннән башка беркем дә әйтмәс. Яңа тормыш башлыйсың, сынаучылар, сөйләүчеләр күп булыр...

— Тыңлыйм, әнием, тыңлыйм. Синең киңәшләрең, сүзләрең һәрвакыт гомер юлдашым булды, юл күрсәтте, ялгыштан саклады. Тыңлыйм.

— Балам,— диде ана, дулкынлана төшеп, сүзен ерактан башлады.— Яшьләр хәзер бик тәкәббер. Үпкәләмә, синдә дә бу сыйфатны күрәм. Тәкәбберлек кешенең дусты түгел, дошманы. Тәкәббер булма. Яңа гаиләгә яңа кеше булып, килен булып барасың. Олыларны, биатаң белән бианаңны диюем, олылап, ихтирам итеп «әни», «әти» дип дәш. Тәмле телеңне кызганма. Аларны үзеңә буйсындырырга тырышма. Яшьләрнең иң зур хатасы шул — ирнең ата-анасын,

туганнарын үзенә буйсындырырга тырышу. Гомер иткән, тәҗрибә җыйган өлкәннәргә баш имәү — мин-минлек чире ул. Менә шунда башлана инде аңлашылмаучылык. Яңа гаиләгә керәсең, анда һәркем сине сынар, энә күзеннән үткәрер. Син аларның ихтирамын, ышанычын яуларга тырыш. Җиң сызганып эш эшлә, хезмәтеңне күрсәт. Эш эшләгәннән сөяк кәкрәйми, хезмәт күрсәтсәң, хөрмәтле булырсың. Кер юсаң, идән юсаң, чистарак итеп, агартыбрак юарга тырыш. Уңганлыгыңны күрсеннәр.

— Рәхмәт, әнием, киңәшең өчен зур рәхмәт.

— Әле бетмәде, балам. Әле әйтәсе сүзләрем күп. Ир башын бөксә дә, тезен чүкмәс, диләр. Шуны исеңдә тот: ирләр сүз белән түгел, кул белән аңлатырга яраталар. Ул теленә салынмый, яхшырак аңлату өчен кулын уйната. Шуны исеңнән чыгарма. Кияү болай бик акыллы, тыйнак күренә, ләкин бераз вакланучан булмагае дим, кием-салымы артык пөхтә, бу —вакланучанлык билгесе. Бәлки ялгыша торганмындыр, болай гына әйтүем. Ни генә булса да, чын ир була күрсен. Тәвәккәлләп язмышыңны аның белән бәйләгәнсең икән, аны ир итеп яшә, ихтирамлы, игътибарлы бул. Юкка-барга чәпчемә, күбрәк елмай. Хатын-кызның бер елмаюы ирләрне кар өстеннән ялан тәпи йөгертә ул. Иреңә киңәш итми эш эшләмә. Ир — ир булып калсын, бар эштә башлап йөрсен, дилбегә аның кулында булсын. Хатын-кызның тырышканы — ир кешенең корышканы, диләр.

— Ярар, әнием, бик зур рәхмәт.

— Юк әле, балам, бетмәде,— ана бераз гына уйланып торды. — Минекеләр, безнекеләр, дип мактана күрмә, ирләр аны яратмый. Синекеләр, минекеләр дип чәкәләшә башласаң, өйдән бәрәкәт кача. Арагызга салкынлык кермәсен, бер-берегезгә ышаныч кимемәсен. Мин һәрчак хәерфатихада булырмын. Намазларым саен теләкләр теләрмен, догалар җибәрермен. Сез дә безне кайгы-хәсрәткә салмагыз...

Икенче көнне капка төбенә читән тарантаска җигелгән ат килеп туктады. Кызы белән кияве пристаньга озату өчен Гыймалелислам җигеп алып кайткан ат иде бу. Тарантаска Зәйнәп зур гына одеял чыгарып җәйде. Капка төбенә тирә-күрше хатын-кызлар җыелды. Бибиәсма

тарантасның утыргычы астына зур гына сумка чыгарып куйды. Аннан яшьләр килеп чыктылар. Озатырга килүчеләргә Фәһимә юл хәере өләште, барысы белән кул биреп саубуллашты.

Һәркем Фәһимәгә үз сүзен әйтеп калырга ашыкты:

— Авылны онытып бетермә, кызым.

— Көзгә парлап кунакка кайтыгыз!

— Ак бәхетләр сезгә, Фәһимә!

Күрше Шәмсенур Фәһимәгә бик якын килеп, бик зур сер әйткәндәй:

— Артыңа борылып карый күрмә, җаныем, — дип пышылдады.

— Нигә, Шәмсенур апа?— дип гаҗәпләнде Фәһимә, ул турыда аның бер дә ишеткәне юк иде.

— Артка әйләнеп карасаң, кире кайтасың, әйләнеп карарга кушмыйлар,—диде һәм үзе елап җибәрә язды.

Шәмсенур моннан берничә ел элек күрше авылга кияүгә чыгып кайткан иде, үз тәҗрибәсеннән чыгып әйттеме, шундый ышану бармы? Шулай да Фәһимә артына борылып карамаска, түзәргә булды.

Менә Фәһимә тагын туган авылыннан чыгып бара, тагын шул олпат өянкеләр салмак кына җилдә аңа кул болгадылар: хуш, Фәһимә, безне дә онытма, кунакка кайтуыңны көтәбез...

Көн аяз иде. Яфрак селкетерлек тә җил юк. Фәһимәнең ишеткәне бар: язылышу, никах көне ничек булса, гомерең шундый була, имеш. Яңгыр булса, күз яшьле; суык, җилле булса, гомерең тынгысыз була; аяз, матур булса, тормышың бәхетле була. Фәһимә үзенең гомерен бик бәхетле итеп күз алдына китерде. Бүгенге көн кебек чалт-аяз, алар күңеле кебек чиста, саф.

Тарантасның алгы өлешендә утыргычка урнашып, Гыймалелислам дилбегәсен әле бер, әле икенче яктан каккалап атын куалады. Үшән ат юырткалап та, салмак атлап та барды. Көн аларныкы, беркем дә арттан кумый.

Әгъзәм егерме биш чакрымлы бу араны икенче тапкыр үтә. Җиңел машина белән элдергәндә, ул берни дә күрмәгән

икән. Нинди матур җирләр! Уң якта чәчәкләр тулы чабылмаган болын, сул якта төнбоеклы күл. Арба юлы күл буйлап, таллыклар күләгәсеннән сузыла. Менә ат сөзәк кенә үргә күтәрелә башлады. Алда кеше кулы белән өеп куелган төсле зур булмаган текә һәм биек тау. Ул эре яфраклы тәбәнәк куаклар белән капланган.

— Бу нинди тау, Фәһимә?

— Бу — Кирмәнчек дип атала. Алып шунда утырып чабатасын каккан. Шуның олтырагындагы туфрагы тау булып өелеп калган, диләр,—диде Фәһимә.

Аннан аның әби патша заманыннан калган нindидер корылма икәнен аңлатты.

Күлдә камыш арасында үрдәк кычкырды, берсе күл өстенә күтәрелеп, бер әйләнеп, кире камышлар арасына төште. Бер тургай озак кына юлда теркелдәгән атны озата барды, зәңгәр күктә югарыда-югарыда эленеп торгандай, ул бер менеп, бер түбәнәеп, җырлады да җырлады.

Яшьләр бер-берсенә сыенып, тургай җырын тыңладылар, гүя алар бер җан, бер тән булып гомернең озын юлында, гаҗәеп бер әкият юлында сихри Сәхраларда икәүдән-икәү калганнар.

— Җырла әле, Фәһимә. Синең тавышың бик матур,— ди Әгъзәм.

— Ә эткәй? Ул ни әйтер?

Фәһимә тирән итеп тын алды да, әкрен генә җырлый башлады, аның тавышы юл сикәлтәсендә сикереп-сикереп алды:

Ай-һай да гына дими көйләр килми,
Кайгылар гына күрми ир булмый...

Кинәт Фәһимә төртелеп калды, ютәлләп алды һәм алдагы ике юлны тирән күкрәк тавышы белән дәвам итте:

Ничек кенә мактап җырласаң да,
Чит-ят җирләр туган ил булмый...

Җыр Фәһимәнең йөрәк түреннән моң булып та, сагыш авазы да, туган җирдән аерылу ачысы да булып яңгырады. Кызның җыры карт атаның күңелен нечкәртте, ул яшьләргә күрсәтми генә күз яшьләрен сөртеп алды, ул яшьләр горурлык яшьләре дә иде бугай: менә бит аның кызы нинди!

Җырны ишетеп, Әгъзәм бик дулкынланды. Фәһимәнең

егет алдында беренче мәртәбә җырлавы түгел, шулай да бу кадәр дә үзәк өзгеч итеп җырлаганы юк иде әле.

Фәһимә җырлады да җырлады. Ат та, гүя җырны тыңлап, адымын акрынайтты. Тургай тынды, камышлар шаулаудан туктады.

Агыйделкәй буе гөлләр тулы,
Гөлләрендә сөмбелләр тулы.
Кулләрендә йөзә кыр казлары,
Талларында былбыллар тулы...

Фәһимә Әгъзәмнең җилкәсенә башын салып тынып калды. Карт дилбегәсен тарткалап атын куалады. Яшьләр шулай бер-берсенә елышып, тарантас белән бергә селкенеп тын гына бара бирделәр. Кояш каты кыздыра иде. Әгъзәм җилкәсендәге костюмын салып тезенә куйды, Фәһимәгә туры карап:

— Җырла әле тагын, Фәһимә. Бәхет турында, безнең турыда җырла, минем өчен җырла,—диде.

Кинәт Фәһимә Әгъзәмне кочаклап үбеп алды һәм тагын җырлап җибәрде:

Нигә, нигә синең шаян күзләр
Күзләремә болай багалар?
Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
Керфек очларыңнан тамалар?

***

Мин, Кояш, ничә гасырлар җир өстен күзәтеп, кешеләрне барлап, үсемлекләрне чәчәк аттырып, суларны җылытып, җир өстен яктыртып, моңарчы беркайчан да ул көнге кебек бәхетле парны күргәнемне хәтерләмим. Матурлар иде алар, йөзләре балкый, күзләре очкынлы, йөрәкләре дәртле сөю тулы.

Ә Фәһимә ул көнне гүзәлләрнең гүзәле иде. Ә ничек ул җырлады! Сайрар кошлар аны тын калып тыңлады. Аның тавышы саф чишмә чылтыравы, болындагы кыңгырау чәчәгенең чыңы кебек илаһи.

Фәһимәнең икегә бүленеп үрелгән авыр толымнары, киң маңгаен бераз яба төшкән чәче аның түгәрәк йөзенә бик килешле. Өстендәге зәңгәр чәчәкле күлмәге гәүдәсенә җыйнак итеп сыланып тора, биле нечкә.

Ул елмайганда коңгырт күзләре очкынлана. Мин ул көнне Фәһимәнең җырын үзем дә моңланып тыңладым. Ул бит туган йортыннан бу көнне мәңгегә аерыла, шуңа аның җыры аеруча моңлы иде. Дөресен әйтим, мин аны бераз кызгандым да. Юк, бу кызгану аны мескенгә санаудан түгел, аңа яңа бәхет, ак юл теләүдән аерылмады. Мин, Кояш, аңа моннан соң мәрхәмәтемне күбрәк салырмын, дип ант итәрдәй булдым. Тик мин үзем генә ни эшли алам соң?! Кайчак атналар буе җир йөзен кара болытлар каплап ала, мин Галәмнең иксез-чиксез киңлегендә салкын планеталар арасында, Җир-гүзәлемне күрүдән мәхрүм калам. Еш кына минем нурларымны, җылымны шәфкатьсез җилләр еракларга, әллә кайларга очырып алып китәләр, мин тагын чарасызлыктан газап чигәм. Мин, Кояш, җирдә кешене фәкать бәхетле итәргә телим, әмма миңа каршы көчләр дә зур куәткә ия. Фәһимәгә мин ак бәхет кенә телим. Ул шуңа лаек бала...

УРЛАНГАН БӘХЕТ

Бу әсәр каләмдәшем Рәис ага Кашаповның хәер-фатихасы белән язылды.

1

Янтирәк авылын нәкъ икегә бүлеп чип-чиста сулы инеш ага. Ул Корытау урманы уртасыннан башланып, күпсанлы чишмәләрнең суы белән тулылана. Авыл уртасында — инеш аркылы салынган таш күпер. Борынгы авылның борынгы күпере. Бабайлар, бабайларның бабалары үз куллары белән салган таш күпер ул. Нык күпер, мәңге ишелмәс һәм искермәс күпер.

Янтирәкнең көньягында таучыкларны әйләнеп үтә-үтә, сабыр гына, моңсу гына Сакман елгасы сузыла. Авыл аша үткән инеш шул Сакманга барып кушыла. Нәкъ шул инеш тамагында Кондызлы күл җәйрәп ята, сөйләп тә, язып та бетерә алмаслык ямьле, оҗмахтай почмак. Яз кояшы җирне иркәләп, урыны-урыны белән яшел җәймә булып ачыла башлау белән, Янтирәкнең яшь-җилкенчәге шул күл буена ашкына. Бөтен тирә-як гармун моңына, җырга күмелә.

Язның иң матур, кояшлы көне. Әле кыр эшләре башланмаган. Тау өсләре кипкән, ә тау итәгендә кар ята, шул яктан дымсу җиләс җил исеп ала. Үлән калкынган, агачлар яфрак яра башлаган вакыт.

Авылда: «Иртәгә — Карга боткасы!» — дигән хәбәр тарала. Малайлар учак өчен кичтән агач әзерлиләр.

Иртән иртүк карга боткасы пешәсе урынга чишмә суы китерелә, учак ягыла, казан асыла.

—Кайнап чыкты, балалар, уйный торыгыз, үзем кычкырырмын, — ди Хәдичә карчык.

— Сакка йөгерәбез!

— Сакка йөгерәбез!

Малайлар—кызлар парлашып сакка басалар.

— Сакка — Сок, йөгереп чык!—дип кычкыра ялгыз калган Ирек исемле малай.

— Тота алсаң — синеке, тоталмасаң — минеке, — диләр арттан сакка йөгерүчеләр. Сакка йөгерүчеләр — Нияз белән Гөлчирә. Алар Ирекка тоттырмыйча йөгереп барып «кавышырга» тиешләр.

Менә эре-эре атлап Нияз алга таба чыга һәм, кинәт ыргылып, Ирекне урап үтә, ә Гөлчирә аны тотып алырга ташланган Иректән читкәрәк йөгерә, үзе Ниязны күрә-күрә аңа таба омтыла.

— Гөлчирә! Тоттырма!

— Тоттырма!!

— Һай! Тота бит!— Урыннарында аларга куәт биреп, тыпырданып, дуслары тора.

Нияз белән Гөлчирә, Ирекне артта калдырып, кулларын сузып, бер-берсенең кочагына ташланалар. Их, ул кайнар кочак! Их, бу яңа өлгергән чор, сөю-сөелүнең бөтен матурлыгын, тәмен тоя башлаган көннәр! Нияз белән Гөлчирә җитәкләшеп, яшьләр янына килеп алга басалар. Тагын чират көтәләр.

—Балалар! Оланнар! Ботка пеште!

«Карга боткасы» уены башлана, һәркемнең кулында агач кашык. Боткалы казанны ике як колагыннан тотып, ике малай «урлап» алып китә. Башкалар казан артыннан чаба, куып җитеп бер кашык ботка эләктерә.

Аннан барысы җыелып тыныч кына ботка ашыйлар. Казанда йомырка пешә.

—Йомырка, йомырка! Байлык бир илгә, йортка! — дип йомырка тәгәрәтәләр. Аннан тагын уеннар башлана.

2

Янтирәкнең уртасында зур агач мәчет. Тик ул хәзер мәчет түгел — мәктәп. Алгы кечкенә бүлмәдә беренче сыйныф, ә зур бүлмәдә — җиденче. Унөч малай, ун кыз. Шаяннар. Кызлар малайларга серле караш ташлый, ә тегеләре кызларның үкчәсенә баса, кич аулакка серләшергә чакыра.

Шул шаяннар арасында моңсу кара күзле, озын толымлы, кыйгач кашлы, янып торган алсу йөзле, чия иренле Гөлчирә бар.

Гөлчирә — бу авылга иярә килгән кыз. Әнисе Бибилатифа күрше Сакман авылыннан Янтирәккә умартачы Минхәер картка кияүгә килгән.

Минхәернең ян бакчасында умарталар. Авылның яшекарты үз итеп, бал алырга аларга килә. Бибилатифаның җиз самавыры һәрчак өстәлдә. Килгән-киткәнне баллап

тәмле чәй белән сыйлый, һәркемгә җылы сүз, якты күз карашы бүләк итә.

Җомга көннәр — Гөлчирә өчен зур шатлык. Әнисе таңнан торып коймак пешерә.

—Тор, кызым, тор, матурым! Чәй эчкәч, кендек әбиеңә коймак илтерсең.

Әнисе кайнар коймакларны тәлинкәгә салып, чуптарлап сугылган ашъяулыкка төрә һәм Гөлчирәгә тоттыра. Кыз төенчек тотып, күрше авыл Сакманга, кендек әбисенә китә.

Мәликә әби берүзе генә яши.

— Һай, матур кызым икән, чәчен үргән, зәңгәр күлмәген кигән, күбәләктәй очып, минем янга килгән,—дип такмаклый кендек әби, Гөлчирәнең башыннан сыйпап.—Әниең Бибилатифа ни хәлдә? Минхәер картның аяклары сызламыймы? Мал-туарлар көтүгә йөриме?

Әби, Гөлчирәне олы кешегә тыңлап, хәл-әхвәл сораша. Килгән саен шул ук сораулар булса да, Гөлчирә тагын җавап бирә:

— Әнием иртүк торган, сыерны сауды, коймак пешерде. Әткәем намаз укыды, чәй эчеп калды. Аякларыннан зарланмады.

— Менә, кызым, сиңа дип кенә саклаган җиләк катым, бераз чикләвегем дә бар иде,—дип серле сандыгыннан күчтәнәчләрен чыгара.

Аннан, Гөлчирә белән кара-каршы утырып, чәй эчәләр. Чәй эчеп туйгач, кендек әбисе:

— Яле, кызым, мин өйрәткән доганы онытмадыңмы?— ди.

— Юк, әбием, онытмадым.

Алар икесе бергә ашны олылап дога кылалар.

Кай көннәрдә Гөлчирә кендек әбисенә куна бара, матур савыт белән юкә балы алып килә. Әбисе белән мәтрүшкәле чәй эчеп, ул тирән йокыга тала, матур-матур төшләр күрә...

3

Югары очта Гөлчирәнең классташы Нияз яши. Ниязга әле биш яшь тә тулмаган иде, әтисе Бөгелмә базарыннан бәләкәй гармун алып кайтты. Башта Нияз аның телләренә барлык бармаклары белән берьюлы басып, өй эчен шаушуга күмде, колакларны тондырганчы кычкыртты. Аның

күзләре ялтырый, нечкә беләкләре киеренке халәткә кереп, юанаеп киткәндәй була.

— Карале, әнисе, кимәленә китерә бит бу малай, каракара, чын гармунчы диярсең, — дип, соклануын яшерми, әтисе Галиәхмәт, мыекларын борып куя.

Ун яшьтә инде Ниязга әтисе чын гармун алып бирде — тальян гармун.

Ләкин Галиәхмәт бик иртә дөнья куйды: Нияз сигезенчедә укыганда, авариядә һәлак булды ул. Алар сеңлесе Зөһрә белән ятим калдылар, әтисез үстеләр.

Нияз — җор сүзле, шаян табигатьле, шат күңелле малай. Ул алтынчы сыйныфта укыганда ук Гөлчирәне үз итте. Әллә нәрсәсе тартып тора шул кызның, карап кына торасы, чәчләренә кагыласы, кулларын тотып карыйсы килә. Гөлчирәнең күзләренә карап көннәр буе утырырга риза Нияз, тик кыз гына, Нияз аңа караса, керфекләрен төшерә, әллә ояла, әллә яратмый. Нияз әрсезләнергә курка, читкәрәк китә дә Гөлчирәдән күзен алмый.

Ул Гөлчирә утырган парта янына килә. Гөлчирә исә, тамчы-тамчы керфекләрен түбән төшереп, тынып кала. Сүзе бармы? Йомышымы? Ник әйтми? Нияз кызның ике толым итеп үргән шома чәчләренә озак кына карап тора да кабат үз урынына барып утыра. Кызга борылып карый. Күзләрен күтәргәнме? Аңа таба карамыйммы?

... Алар тугызынчы сыйныфта укыйлар иде. Нияз чандыр гына егет. Аның белән очрашкан саен Гөлчирәнең йөрәге тукталып калгандай була.

Язгы ташу вакыты. Якшәмбе көн. Көн буе ташу карап, түгәрәк уен, сакка йөгерү кебек сабый чак уеннары уйнап туйгач, кайсы кая таралышты. Елга яры буенда алар икесе генә утырып калдылар. Гөлчирә Ниязның гармун уйнаганын тыңлый. «Беркем дә аның кебек матур итеп уйный алмый»,—дип уйлый кыз.

Текә яр астында тасма-тасма булып боз яргаланган, ярылган урыннары зәңгәрсу-яшел төстә. Су өстендә бертуктаусыз хәрәкәт итүче зур-зур бозлар шау-гөр килеп бәрелешәләр, берсе өстенә икенчесе килеп менә дә, вак кисәкләргә яргаланып, шыбырдап коела, юкка чыга. Язгы ташкын бозларны чүбе-ние белән каядыр куа.

Нияз гармунын җиргә куеп, Гөлчирәнең нәзек бармакларын үзенең учына алды. Кыз аңа күтәрелеп карамады, йөрәгенең кызу-кызу типкәнен генә сизде. Нияз кызның йөзенә якын килеп, кинәт кенә аның чия төсле кабарынкы иреннәреннән үбеп алды. Бу Гөлчирә өчен көтелмәгән хәл булды, ул кычкырып куйды һәм Ниязның аркасына сугып, сикереп торды да, авылга таба йөгерде.

4

Тире җыючы Халикның Ниязлар өенә урам аша каршы салынган йорты башкалардан йөз чөерүче тәкәббер кешене хәтерләтә, барлык өйләрдән калкурак, зуррак һәм матуррак.

Халик кызы Сәримә, тәпи йөри башлау белән, Ниязга тартылды. Әнисе яңа күлмәк тегеп кидерүгә була, Сәримә йөгереп Нияз янына килә:

—Матурмы күлмәгем? Күрәсеңме, нинди төймә такты әни! Матурмы? Матурмы?

—Матур, матур. Йә, аптыратма әле, Сәримә.

Никтер кечкенәдән үк Нияз аны яратмады. Иркә, кылтык, назлы булып үсте Сәримә, Нияз дип ут йотты. Үсә төшкәч, аны фәкать үзенеке генә итеп хис итте. Хыялларга бирелде: менә алар мәктәпне тәмамлыйлар, өйләнешәләр, яңа өй салалар, Нияз Сәримәнең әтисе кебек тире-йон җыя башлый, байыйлар, балалар үсә. Ниязны ул нәкъ әнисе әтисен биеткән кебек «биетеп» кенә тора. Нияз арт аякларында үрә басып торучы маэмай булып күз алдына килеп баса...

Сәримәнең әтисе юаш, бик сабыр холыклы кеше. Хатыны Маһибәдәр — холыксыз хатын. Халик түзә, дәшми.

Сәримәнең әнисе «кызның кырыгыннан» дип, «кыз бишектә — җиһаз сандыкта» дип, бирнә хәстәрен күрә торды. Кияү дигәнең Нияз кебек ярлы булса, кызы шыр ялангач өйгә килен булып төшсә... Бер караганда, үз бизмәне белән үлчәп, «бай кызга мең ия» дия-дия, әйбер җыйды. Авыл кызлары кебек алача палас, чуптарлы тастымал түгел, шәһәрчә, яңача асыл мал җыя торды. Ак чәчәкле зәңгәр төстәге карават җәймәсе, затлы челтәрләр, мендәр япмалары... Бөгелмәдән елык-елык килеп торган калай тышлы яшел сандык кайтартты, шул сандыкка шыплап чүпрәк-

чапрак тутырды. Сәримә генә сандыкны яратмады. Кем хәзер сандык төяп кияүгә чыга? Комод, шифоньер кирәк, яңача! Шәһәрчә!

... Сәримә җиденче сыйныфта укыганда ук кашларын йолкып, нәзек кенә калдырды, күз төпләренә сөрмә тартып, көзгедә мут яшькелт күзләрен күреп, үз-үзенә соклана, сыйныфта иң чибәр кыз — мин, дип уйлап йөри башлады. Йөзенә иннек сөртә, бит очына кара каләм белән миң төртә, маңгай чәчен кайчы белән кисеп, каш өстенә чәч тәлгәшләре төшерә. Иреннәр генә калынрак, тешләр сирәк. Аларны һич үзгәртеп булмый. Күзләр матур булгач, теш сирәклеге чүп кенә, авызны йомыбрак йөрергә туры килер, дип фикер йөртә кыз.

...Ул Ниязның Гөлчирә тирәсендә бөтерелгәнен сизә башлады. Аның күршесе, аңа гына булырга тиешле Нияз Гөлчирәдән күзен алмый.

Бер кичне Сәримә Ниязның Гөлчирәне озатып кайтканын үзләренең капка төбендә көтеп торды. Нияз таш күпер өстендә күренү белән кыз, эскәмиядән торып, урам аша җәһәт-җәһәт атлап, Ниязлар капка төбенә килеп басты.

— Менә сезгә кергән идем,—дигән булды.

— Нигә?

— Нигә дип, әниең белән сөйләшеп утырырга.

— Ярый, бар, өегезгә кер.

— Минем синең белән сөйләшәсе сүзем бар.

— Ә минеке — юк.

— Йә, нәрсә инде син, күрше, минем белән тупас.

— Тупас түгел, бөтенләй сөйләшер сүзем юк.

— Табарбыз. Әйдә, тегендәрәк китик, тыкрыкка.

— Юк, Сәримә, миңа әйтәсе сүзең булса, шушында гына әйт, тыңлыйм.

— Шул Гөлчирәнең нәрсәсе миннән артык соң?

— Синең сүзең Гөлчирә турында икән...

— Әйе, Гөлчирә турында. Шул йолкыш, хәерченең нәрсәсе сиңа ошыйдыр инде? Миннән кай җире белән артык соң ул? Чибәррәкме?

— Син, Сәримә, һичшиксез чибәр, кара инде, синең кыйгач кашларың, сөрмәле күзләрең генә ни тора, — диде Нияз сүзенә тирән мәгънә салып.

Мактау сүзләрен ишеткәч, Сәриманең зур авызы ерылып, сирәк тешләре күренде.

Нияз, аның көлүен күрмәскә теләп, күзләрен җиргә төбәде.

— Йә, булды, Сәримә, сөйләштек. Мин керим...

Әле Сәриманең моңарчы Нияз белән болай кыюланып сөйләшә алганы юк иде. Ниязны болай гына кулга алып, үзенә каратып булмаячагын кыз аңлады.

Сәримә укуда әллә ни өлгер булмаса да, һәр җирдә чәчрәп чыгып үзен күрсәтергә, Гөлчирәдән бер дә ким булмаска тырышты. Гөлчирә килмешәк, атасы да юк, киеме дә рәтле түгел. Чибәрлеккә мин аннан кимме әллә, дип фикер йөртте. Тора-бара Гөлчирәнең хак дошманына, көндәшенә әверелде. Араларын бозарга тырышты.

5

Әле сигезенче сыйныфта укыйлар иде. Февраль ае. Салкын. Гөлчирә көянтә-чиләк тотып, күрше Гапсаттарлар капка төбендәге чыгырлы коега су алырга чыкты. Кое буе ап-ак боз, кое авызы боз катып бәләкәй генә калган. Чылбырга эленгән кыршаулы чиләк тә бозланып ялтырап тора. Кемдер су алган да, төбендәге суын салып бетермичә, кое капкачына утыртып киткән. Гөлчирә бозга каткан авыр чиләкне күтәреп алып, кое капкачын бер кырыйга шудырды, сузылып кына кое эченә күз төшереп алды да, чиләкне коега төшереп җибәрде. Суга чупылдап барып төшкән чиләк, су белән тулып, чыгырны сөйрәде, коеның терсәкле тимер тоткычы зыр-зыр әйләнеп, коточкыч шау-шу куптарды.

— Су аласыңмы, Гөлчирә? Кая чиләгеңне үзем алыйм, тая күрмә.

Үтеп барышлый, Нияз кое буена туктаган иде.

— Юк, юк, үзем,—диде кыз, сер бирмәскә тырышып.

Ул арада Нияз тимер тотканы әйләндерә башлады. Сулы чиләк тар кое авызына килеп җиткәч, Гөлчирә аңа сузылды, әмма аягы таеп китеп, боз каткан кое бурасына күкрәге белән килеп төште, ә уң кулы сулы чиләкнең кыршавы белән кое читенә каткан боз арасында калды.

Нияз каушавыннан кое чыгырының тоткасын кулыннан ычкындырды, чылбырга тагылган сулы чиләк дулый-дулый

коега төшеп китте. Нияз ашыгып Гөлчирәгә таба омтылды, аның канга баткан кулыннан бияләен тартып алып, бармакларын учына алды һәм җылы тынын канлы бармакларга өрде. Кыз, кулы авыртуга чыдый алмый, үксеп-үксеп елый башлады.

Бу көннән соң кызның бармаклары кызыллы-зәңгәрле булып шешеп чыкты. Бик озак төзәлде. Гөлчирәнең чәнчә бармагы бөтенләй тырнаксыз калды. Ул аларга теге көндәге хәвеф-хәтәрне гел исләренә төшереп торды. Тырнаксыз бармак Гөлчирәнең тамгасына әверелде.

Ә Нияз кыз белән очрашкан саен:

— Я, ничек, бармагыңа тырнак үсмиме әле?—дип шаяртa торган булды.

— Оныт инде син аны, авыртмый да, сызламый да,— дия иде Гөлчирә.

6

Яз.

Гомер дә тоташ яз гына булыр төсле. Күңел моңарчы сизелмәгән, беленмәгән яшерен хисләрне ак өметләргә әйләндереп, ап-ак күлмәкләр кидерә, чәчәкләрнең бәхет, мәхәббәт теләгәннәрен эзли, сөю көтә. Яз вәгъдәләренә ышана кыз бала.

Үзе дә гөл сыман, яңгырның җылысы, җилнең назлысы, кичнең сандугачлысы, төннең йолдызлысы турында гына хыяллана.

Язлар уяткан хыялларның эссе җәйләрдә, яңгырлы көзләрдә, салкын кышларда барысы да чынга ашырмы? Юкмы?..

Менә хәзер барысы да артта, дәфтәргә соңгы нокта куелган. Имтиханда мәсьәлә дә бик җиңел иде.

— Синеке беттеме?—диде Гөлчирә, урыныннан торып.

— Ә синең барысы да дөресме?

— Дөрес, киттек.

Алар дәфтәрләрен тапшырдылар, бүлмәдән чыктылар.

Алар ун сыйныфны уңышлы тәмамладылар. Аттестатларында икесенең дә өчәр дүртле, калган фәннәрдән бишле иде.

...Чыгарылыш кичәсе. Күңелләрне куаныч һәм дәрт сарган көннәр.

Утлар балкыган зур залда озак кына җырлаган-биегәннән соң, Гөлчирә белән Нияз урамга чыктылар. Таң сызылып килә иде. Алар, аяк кайда әйди, шунда атладылар. Ә аяклар ялгыз каен аланына юл алды.

Алар алдында зур сорау: алга таба нишләргә? Гүя кайчандыр зур бер ишектән кергәннәр дә, ун ел буе шунда янып-көеп, алҗып-арып зур юл үткәннәр, бүген генә шул ишекне ябып бу дөньядан чыкканнар. Кулларында ишекнең зур ачкычы. Ә ул ачкыч тагын нинди ишекне ачып керергә ярдәм итәр? Ул яңа ишек кайда? Каян табарга аны? Анда кайсы сукмак, кайсы юл илтә? Уңдамы ул, әллә сулдамы?

Әйе, әле бүген генә алар кулларына аттестат алдылар. Мәктәп директоры аларны бик җылы тәбрик итте...

Ялгыз каен янында Нияз белән Гөлчирә бик озак сөйләштеләр.

Таң белән саубуллашучы йолдызлар күз кысыша-кысыша берәм-берәм сүнделәр, ә ялгыз каен аланы, яшел үлән, чәчәкләр, ачып куелган зур китапны хәтерләтеп, аларга колач җәйде. Ерактагы биек тау сыртыннан кояшның җирән сырты күренде, каршыдагы урман кояш нурларыннан ялтырады.

— Йә, ярый, көн туды, кояш чыкты, безнең өчен яңа тормыш башланды,—диде Гөлчирә уйчан гына.

— Яңа тормыш, яңа юллар,—диде Нияз.—Гөлчирә, ник син бүген бик күңелсез?

— Нияз, сиңа бер дә әйткәнем юк, син бит берни белмисең. Әни авырый минем. Шуңа бер дә күңелем үсми, табиблар бер дә өметле сүз әйтмиләр.

Гөлчирә кояш нурларыннан алсу төскә кергән каенны кочаклады һәм кулларын югарыга таба шудырды.

— Карале, Нияз, безнең каеныбызның кәүсәсенә нинди гөмбә ябышкан!

— Ул — мәшкә дип атала. Укыганым бар, бик күп авыруларга дәва икәне турында язалар.

— Минем әниемә ярдәм итмәс иде микән?

Нияз кулын сузып гөмбәне капшап карады.

— Кап-каты. Өзеп алыйммы?

— Юк, кирәкми, торсын.

Гөлчирә уйга калды. Бераз торгач, тирән сулыш алып, әкрен генә сөйләп китте:

— Каен ул — сагыш агачы, ялгызлык символы, ул һәрчак сагышлы, язларын елап күпме күз яшьләре түгә. Шул түгелгән каен яшьләре шушы каты гөмбә булып бергә җыелып оешкандыр. Ул гөмбә каенның бәгыредер, елый-елый каенның бәгыре каткандыр.

— Син әллә ниләр сөйлисең, Гөлчирә.

Гөлчирә дәшмәде, аның күңеле һаман авырудан шәмдәй сызып баручы әнисе белән иде...

Гөлчирәнең әнисе Бибилатифа, карты Минхәер үлеп биш ел үткәннән соң, алмалар җитешкәч, августның соңгы көнендә дөнья куйды. Унҗиде яшьлек Гөлчирә каңгырып япа-ялгыз калды. Ялан чаклы өйдә берьялгызы яши башлады.

7

Сәримә унынчы сыйныфта укыганда зур күкрәкле, тулы гәүдәле, җитлеккән кызга әйләнде. Карап торуга бер дә кеше карамаслык түгел, әмма ни өчендер башка кызлар кебек аны бер генә егет тә үз итмәде. Фәкать түбән оч саескан Фәрхиенең кайдадыр яшәп, хатын аерып кайткан малае Фатих кына берничә мәртәбә озата килде.

Таң атканчы кайдадыр олагып йөргән кызын Маһибәдәр берничә мәртәбә тыкрыклардан, бакча башларыннан, инеш буйларыннан чыгып эзләп йөрде.

— Сәримә! Сәримәү! — дип, югалган бәрәнен эзләгәндәй, кычкырып йөреп тә таба алмагач, күршеләрдән ишетеп, кызының кем белән бәйләнгәнен белде.

Сәримәнең кайтканын капка төбендә саклап торды да, кызы капка төбенә килеп җиткәч, яңагыннан ут чыгарып, чалтыратты. Урамда тавыш куптармады, кызын аркасыннан этә-төртә өйгә алып керде һәм, бар зәһәрен җигеп, авызыннан утлар чәчеп сүгә башлады:

— Син нәрсә? Хатын аерган зимагур белән йөри башладыңмы? Юкмы сиңа үзеңә бер егет? Ирлек тәмен тойган кеше синең битеңнән үбәр өчен генә озатып йөрмәс. Ике аягыңның берсен дә атлатмыйм. Клубка түгел, капка төбенә дә чыгармыйм. Итәгеңә салып бала алып кайтсын, дип үстердеммени мин сине?

Әнисе зимагур дип атаган Фатихны моңарчы егетләр назы күрмәгән Сәримә инде ярата башлаган иде.

Фатих матур гына киенә, читтә йөреп чарланган, теле телгә йокмый, ярату сүзләрен сибә генә. Сәримә бу ирне инде үзенең язмышы итеп күрә башлаган иде. Әмма Маһибәдәр катгый рәвештә кызының чыгар юлына йозак салды:

— Чыкмыйсың, бетте-китте, — дип кычкырды. — Әнә Нияз. Бергә үстегез, ярлы булса да, үз кеше. Тәртипле, акыллы. Сиңа башка кеше юк. Ишетсен колагың!

Ул да булмады, Фәрхи малае Фатих авылдан чыгып китте...

8

— Гөлчирә, — диде беркөнне Нияз бик җитди генә. — Мин уйладым-уйладым да, вербовка белән Кузбасска китәргә булдым. Авылда ни калган?! Безнең бит мәктәп тәмамлаганга кәгазь генә бар, ун ел буе укыдык, бер һөнәр алмадык. Алга таба укырга акча кирәк, әни дә: «Укыта алмам, улым, сеңлеңне үстерәсе бар, берәр кая китәрсең, өсбашыңны карарсың»,— ди.

Ниязның бу сүзләре Гөлчирәне уятып җибәргәндәй булды, аның күңеле әллә нишләде:

— Мине дә ал, Нияз, мин дә китәм синең белән, — диде.

— Гөлчирә, — диде Нияз, — вербовка белән егетләрне генә җыялар, мин укып һөнәр алыйм әле, эшләп карыйм, урнашыйм, сине чакырырмын яки кайтып алырмын.

— Нияз, минем бит беркемем дә юк, мин синнән башка нишләрмен? Ал мине дә, икәү китик.

Гөлчирә елый ук башлады.

— Мин сине бер елдан кайтып алырмын. Шушы ялгыз каен янында вәгъдә бирешик: тормышта кем генә очраса да, бер-беребезгә хыянәт итмәскә, ташлашмаска, мәңгегә бергә булырга. Вәгъдәме, Гөлчирә?

— Вәгъдә, Нияз, вәгъдә, — диде Гөлчирә тынычлана төшкәч. Кайчан китәсең? Кем белән?

— Иртәгә, Рәфис белән.

— Нәрсә белән китәсез?

— Поезд белән.

Гөлчирә белән Нияз утырган җирләреннән торып бастылар һәм, каен янына килеп, икесе ике яктан каенны кочаклап, кулга-кул тотындылар:

— Мине күтәрсеңме?
— Хатлар язарсыңмы?
— Күрәсеңме, каенның яшьләреннән оешкан гөмбә безгә дәшә, вәгъдәгезне ныгыттым, ди, күз яшьләре түкмәгез, ди, бер-берегезгә ышаныгыз, ди...

Алар каенны кочаклаган килеш, кулга-кул тотынышып озак кына тордылар...

Икенче көнне Нияз бик иртә уянды. Әнисе, улының уянганын күреп, ашыга-ашыга өстәлгә пар бөркеп торган самавырны китереп куйды.

— Көтү киттеме әле, әни?
— Юк әле, улым, иртә әле.
— Көтүгә кадәр юлга чыгарга кирәк, юкса, тузан басылганын көтәсе булыр.
— Әйдә, улым, юынып кер дә чәй эчәрбез, Аллага тапшырып, авылны чыкканчы озата барырмын.

Нияз кичә кич Гөлчирә белән саубуллашуын исенә төшерде. Вәгъдәләшүләр, Гөлчирәнең күз яшьләре... Менә шул күз яшьләре башка бервакытта да таммасын өчен Нияз әллә ниләр бирер иде.

Нияз, әтисеннән калган иске бишмәтне киеп, аркасына биштәр асып, урам буйлап атлады. Аны дусты Рәфис капка төбендә көтеп тора иде инде. Күк йөзе аллы-гөлле төсләр белән балкыган. Тиздән кояш та чыгачак. Кошлар тынып калган. Нияз эре-эре атлап Рәфис янына килеп туктады, елмаеп аңа кулын сузды:

— Сәлам!
— Сәлам! Киттек.

Алар Бөгелмә станциясенә сәгать унга барып җиттеләр. Малайларны клуб кебек бер зур бүлмәгә җыйдылар. Җыелу урыны дип атала икән. Беркемне дә чыгармыйлар. Озакламый комиссия булды. Нияз белән Рәфис тә каралдылар. Рәфисне комиссия яраксыз дип тапты.

— Мин, болай булгач, Нияз, авылга кире кайтам. Озата гына бардым, диярмен инде.

Бу фикер белән Нияз да килеште. Рәфис Ниязга бераз акча бирде, поездга дустын утыртып, кул болгап, озатып калды.

9

Өйдән чыгып киткәнгә ике атна дигәндә, Нияз Осинники станциясенә килеп төште. Тимер юлның уң ягында елга, суы кап-кара. Сул якта вокзал бинасы. Бу яклар безнең җирләргә бер да охшамаган икән. Бөтен җир өсте кап-кара. Елга да кап-кара, урамнарда да ниндидер кара су ага.

Вагоннардан аның кебек үк малайлар коелды. Аякларында чабата, өсләрендә иске, ямаулы фуфайка. Кайсы соры чикмән кигән, кайсы — кыска тун. Менә бик каты кычкырып команда бирделәр:

— Стройся!

Эреле-ваклы малайлар бер рәткә тезелеп бастылар. Команда биреп, аларны җәяүләтеп шәһәргә таба алып киттеләр.

Уң якта биек тау, тау буйлап йортлар тезелгән. Бер генә агач та юк. Җир дә кап-кара, йортлар да.

— Син кайдан?

— Әлмәттән.

— Ә син?

— Бөгелмәдән.

— Зәйдән...

Малайлар шулай шыбыр-шыбыр сөйләшеп баралар. Шлак түшәлгән юлдан атлап бару җиңел түгел, аякка каты. Аларга каршы кулларына ниндидер кораллар күтәргән бер төркем шахтерлар очрады. Битләре кап-кара, ком гарәбе дә алай ук кара түгелдер, күзләре генә ялтырый. Үзләре малайларның сәләмә киемен күреп, бармаклары белән төртеп күрсәтә-күрсәтә көлгән булалар. Тешләре генә апак. Алар көлгәндә бигрәк ямьсез икән.

Нияз күзенә күренгән һәр нәрсәне исендә калдырырга тырышты. Менә «Центральная» дип язылган биек каланча, аның артында, кара төтен бөркеп, коточкыч зур тау күренеп тора. Шахта дигәннәре шулдыр инде, дип уйлады Нияз.

Бара торгач, кирпечтән салынган зур, матур бина күренде. Анысы шахта идарәсе булыр, чиста кешеләр, начальниклар эшли торган җирдер инде.

Ул арада каяндыр бер төркем малай-шалай килеп чыкты. Чиста, матур киемле шәһәр малайлары. Шулчак берсе:

— Вон, японцев ведут! — дип сөрән салды.

Икенчесе тагын:

— Бей самураев! — дип, рәт белән матур гына, тәртипле генә атлап баручы малайларга күмер кисәкләре, ташлар ата башладылар. Малайларның кайсы кычкырып җибәреп, башын тотты, кемдер аксый башлады.

Аларны «ФЗО-17» дип язылган өч катлы бина каршысына китереп туктаттылар. Берничә группага бүлделәр. Яңа киемнәр өләштеләр. Мунчага озаттылар. Иске киемнәрне яндырдылар.

Әнисе юлга чыгар алдыннан Ниязга догалык-бөти биргән иде. Нияз аны иске бишмәтенең түш кесәсеннән эзләп алып учына йомарлады. Әнисе аңа:

— Шушы догалыклар сине хәвеф-хәтәрдән саклар, исән-сау өйгә алып кайтыр, — дип әйткән иде.

Укулар башланды. Уку дигәннәре — бер көн класс бүлмәсендә укытучының сөйләгәнен тыңлау, биш көн җир астына төшеп, тәҗрибәле шахтерлар күзәтүе астында забойда күмер чабу икән.

Нияз забойщиклар төркеменә эләкте. Аны төркемнең өлкәне итеп билгеләделәр.

Төркемнең мастеры — Тау техникумы тәмамлаган, чандыр гәүдәле, җитез хәрәкәтле, төскә-биткә чибәр егерме биш яшьләрдәге хохол Петр Иванович Перебейнос — яхшы, кешелекле егет булып чыкты. Урыс телен ипилек-тозлык кына белгән татар малайларын ул үз күреп, яратып, малайлар арасында зур абруй казанды.

Брезенттан тегелгән калын, авыр кием, аягына резин чуни, башына шахтер каскасы киеп алгач, Нияз гомере буе шахтада эшләгән кешегә охшады да куйды. Ул көлеп җибәрде. Их, Гөлчирә янына шушы киемнәр белән барып басарга! — дип уйлады егет. Бигрәк «матур» икән бу шахтер киемнәре!..

10

Сентябрь ае. Гөлчирә башка барлык авыл хатыннары белән бәрәңге алды, чөгендер казыды. Арып, эштән туктап, барысы бергә олы тирәк янына җыелдылар. Кем нәрсә алып килгән — бары уртак: кабыклы бәрәңге, кара ипи, әйрән,

катык. Гөлчирәнең күршесе Сәмигa никтер көндезләтеп кенә эшкә килде. Гөлчирәгә кесәсеннән алып конверт тоттырды.

— Ал, әҗерен сорамыйм. Биемәсәң, икенче кат тәтемәс, — дип шаяртты.

Үткен күзләр Сәмиганың Гөлчирәгә хат биргәнен күреп, аңа табарак елыштылар.

— Әйдә, ярар бу юлы биетеп торма инде...

— Хат дигән куаныч көн дә килеп тормый. Миңа язсыннар иде әле, хәлдән тайганчы биер идем.

— Ниязданмы?

— Нияздандыр. Кемнән булсын.

Гөлчирә читкәрәк китеп, ашыга-ашыга конвертны ачты. Таныш кул, түгәрәк-түгәрәк хәрефләр...

Кызлар барыбер Гөлчирәне уратып алдылар, җилкә аша сузылып, очлы күзләрен хатка төбәделәр.

— Кызлар, бәйләнмәгез әле!

— Ниләр яза, Гөлчирә? Без да укыйк әле.

— Адресын гына булса да күрсәт инде.

Сәримә Гөлчирәнең кулыннан конвертны алмакчы булды, Гөлчирә аның кулына сукты, кырт борылып китеп барды. Гөлчирә янына дусты Рәисә килде.

— Ник елыйсың, Гөлчирә?

— Үзем дә белмим, дустым.

Гөлчирә яшьле күзләрен сөртеп алды.

Хат озын иде. Нияз юлда ниләр булган, ничек барып урнашкан, укуы һәм эше турында бәйнә-бәйнә язган иде.

Хатының ахырында бер җыр да бар.

«Алтын пәкемне сындырдым
Гөл тамырын кискәндә.
Сәламнәремне җибәрәм
Кичке җилләр искәндә...»

Гөлчирә Ниязга шул көнне үк хат язып салды. «Нияз!— дип язды кыз,— син киткәннән бирле күңелем урынында түгел, авыр миңа, мин ялгыз. Ник син мине үзең белән алмадың? Ник ташлап киттең? Кемгә ташлап киттең? Минем бит беркемем дә юк.

Әнием үлгәннән бирле миңа өйгә керү дә бик авыр. Ярый әле Рәисә бар, аның белән бергә кунабыз, һәркөн диярлек төшләремдә сине күрәм, синең өчен бик борчылам, сак бул анда, шахта эше бик хәтәр, диләр бит.

Ялгыз каен янына ялгыз барасым килми. Сине бик сагындым, бик күрәсем килә, күзләреңә карыйсым, кулларыңны тотасым килә...

Минем хәлләремне белмисең бит. Бер генә туганым да юк бит минем. Сер сөйләр, сагышымны таратырга ярдәм итәрлек кешем юк.

Син киткәнгә менә бер ай булды. Мин инде сагынып үлә яздым. Бер ел сине күрми ничек түзәрмен? Ләкин мин өметемне өзмим. Алдагы бәхетле көннәрне уйлап елмаям. Бәхет ул — язларда язылган язмышның рәхәтен дә, михнәтен дә күреп, яшисе, кавышасы килү теләген җуймыйча, һаман матурлыкка, мәхәббәткә омтылудыр. Мин үземне бәхетсез димим, безнең бәхет әле алда, без һичшиксез бергә булачакбыз. Мин моңа ышанам.

Гөлчирә.»

11

— Шәлеңне сал, Рәисә, чишен. Ярый әле, дустым, син бар.

— Гөлчирә, алма исе килә, эм-м, әллә алмаң бармы? — Рәисә борынын җыера-җыера иснәнә башлады. — Хуш исе борынны яра, әллә мәтрүшкәң дә бар инде?

— Чоланнан әни белән җыйган мәтрүшкәләрне алып кердем, баздан алма алып мендем син килүгә. Әнием төсе, аның белән агачтан өзеп, кәгазьгә төргән идек. Кызым, кыш көне ашарбыз, Алла теләсә, дигән иде. Үзенә генә ризык булмаган, — дип сөйләнә-сөйләнә Гөлчирә өстәлгә алмалар куйды.

— Минем әни чәйгә дип кишер киптерә, кабак көйдерә. Туйдырды инде, — ди Рәисә.

— Мәтрүшкә чәе эчәрбез, дустым, баллап-тәмләп эчәрбез...

Мәтрүшкәле чәй эчеп, кызлар йокларга яттылар. Рәисә пышылдап кына сорап куйды:

— Нияз ниләр яза соң?

— Ниләр яза, дип... Берничә хаты килде дә, туктады, язмый. Нәрсә булгандыр...

— Әллә башканы тапты микән?..

Рәисә бик тиз йоклап китте. Ә Гөлчирәнең күзенә йокы

кермәде. Туңып киткәндәй булды. Өй дә суынып өлгерде, ахры...

Кыз таң алдыннан гына йокыга талды. Йокысы да тыныч булмады. Менә ул сап-салкын су эчендә. Туңа, калтырана. Судан чыгарга тели, булдыра алмый. Кулына ниндидер бау эләгә. Бау яр өстендәге ялгыз каенга бәйләнгән. Ә яр шундый биек — күккә тигән. Яр өстендә ялгыз каен җилдә уңга-сулга чайкала.

Әллә каян еpактан бер аваз килә:

— Ник суга ташландың?

— Мин үзем ташланмадым, мине ташладылар,—ди Гөлчирә.

— Кем ташлады?

— Белмим... Ниндидер явыз, кара көч.

— Кем чыгарыр икән сине бу судан?

— Минем бик яшисем килә! Каенкаем! Ярдәм ит!

Гөлчирә бауга ябыша, үрмәләргә тели. Бау дигәне бау түгел икән, ямь-яшел үлән. Өзелә! Өзелә! Тагын бераз гына! Бераз гына!

— Өзелә! Өзелә! — дип кычкырып уянды Гөлчирә.

Рәисә дә бу тавышка уянып китте.

— Нәрсә өзелә, Гөлчирә?

Гөлчирә авыр сулап, һушын җыеп, караватында утыра бирде. Дәшмәде. Аның кәефе юк иде.

12

Янтирәккә ел башында кайсыдыр бер районнан Арслангали исемле егет килеп төште. Ул ниндидер кыңгыр эшләре өчен теге районнан куылган. Лубян урман хуҗалыгы техникумын тәмамлагач, ул районда озак эшли алмаган, яңа җиргә — Янтирәккә күчкән.

Олы юлның ике ягындагы киң кырларны, урманнарны карап бара торгач, Янтирәккә керә торган чана юлын күреп, ул машинадан төшеп калды һәм авылга таба җәяү генә атлады. Аяклары туңа төшкән иде, чана юлыннан тая-тая атлый торгач, җылынып китте.

Биш чакрым араны ул бер сәгать үтте, ул бер сәгать Арслангалигә бер ел кебек тоелды. Ул үзенең үткәннәрен уйлады, алга планнар корды. Ул ышанычлы адымнар белән яңа урынга эшкә килә.

Арслангалине фатирга Сәримәләргә керттеләр. Сәримәнең әтисе Халик егетне бер күрү белән ошатты. Карчыганыкы кебек очлы күзләр, кавказлыларныкы кебек кәкре борын, киң җилкә. Үткен, җилле егеттер, эш сөя торган кешедер, дип уйлады Халик. Егетне өстәл янына чакырып, рюмкага аракы койды, үзе өстәлнең икенче ягына утырды:

— Әйдә, юлдан килгән кешегә әз генә чеметеп куйю ярый ул.

Арслангали икеләнеп калды: киң күңеллелекме бу, хәйләме?

— Әйдә, әйдә, җибәр әле, яхшырак йокларсың. Арыгансыңдыр.

Арслангали рюмкадагы аракының яртысын эчте дә, чыраен бик нык сытып, рюмкасын өстәлгә куйды. Халик исә рюмкасындагы аракының тамчысын да калдырмыйча авызына каплады, олы ләззәт кичергәндәй мыекларын сыпырды.

— Ачы каһәр. Ачы булса да, яхшы!

Халик бик тәфсилләп Арслангалинең кем икәнен сораштырды. Аракысының калганы өстенә тагын өстәде, тагын кыстады. Бер-ике рюмка җибәргәч, Арслангали сораштыруны көтеп тормады, үзе сөйли башлады.

— Лубян урман хуҗалыгы техникумын бик яхшы тәмамладым. Менә, иң алдынгы белгеч буларак, урманчылык эшләрен җайга салу өчен монда җибәрделәр.

— Гаиләң?

— Өйләнмәгән. Баулыда ялгыз әнием калды.

— Э-э. Өйләнмәгәнмени?..

Ул арада кичке уеннан Сәримә кайтып керде.

— Ай, кунак бар икән, — диде кыз Арслангалигә әрсез караш ташлап.

Аңа күз сирпеп бер карау җитте, барысын күреп алды: үткен караш, куе кара кашлар, кара-кучкыл йөз...

Хуҗа хатын да биләмнән кайтып керде. Маһибәдәрнең бөкрерәк какча гәүдәсе, иякккә таба очлаеп килгән саргылт йөзе Арслангалигә ошамады: усалдыр, явыздыр, дип уйлап алды.

— Менә, әнкәсе, безгә бу егетне фатирга керттеләр. Урманчы, бик олы кеше, — диде Халик.

Рюмкаларга тагын аракы агызды, салкын итне кунакка табарак этеп куйды, ипи кисте.

— Аша, энем, аша. Юлдан килгән кешегә кайнар аш куярга кирәк иде дә, соңрак килеп кердең шул.

Рюмканы каплагач, Халикнын теле тагын да ачылып китте.

— Күрдеңме кызыбызны. Берәү генә. Әнкәсе башка табарга теләмәде. Кызыбызның чибәрлеге дисеңме, характеры дисеңме, Аллага шөкер.

— Әти, дим, күп лыгырдыйсың, җиттеме, юкмы?

Кызның бу сүзләре бөтен нәрсәне юкка чыгарды. Атасының мактау сүзләре дә, Арслангалинең күңелендә секунд эчендә бөреләнеп алган планнары да, түбә кыегыннан ишелеп төшкән калын кар катламы кебек, җимерелделәр.

Атна-ун көн үтмәде, урман белгече, комсомол оешмасы белән килешеп, авыл клубында яшьләр өчен лекцияләр укый башлады. Агротехника, туфрак структурасы, агачларның төрләре...

Арслангали кечкенә блокнот тотып яшьләр каршында лекция укый. Уңга-сулга йөренгәли, ботинкасы атлаган саен шыгырдап китә, костюм эченнән зәңгәр күлмәк, шакмаклы галстук таккан. Ул үз-үзенә бик ошый, ул — интеллигент, башы тулы белем, гыйлем.

Гөлчирә башын бераз гына кырын салып, күзләрен күптән юылмаган идән такталарына төбәп тыңлаган булып утыра. Ә Рәисә утыра-утыра да кулы белән авызын каплап иснәп ала. Сәримә арткы рәттә яшерен генә көнбагыш чиртә, тырнаклары белән генә яра да, кабыгын эскәмия астына ата, төшен тиз генә авызына ыргыта.

Арслангали кызып-кызып сөйләвендә. Ике сүзнең берендә кызларга таныш түгел сүзләр кыстыра, каенны ул әллә нинди телдә атый, гүя ул ак каен түгел, әллә нәрсә — «ветула» дигән була. Сүзләре дә колакка тыгыла, аңларга комачаулый: «литосфера», «биомасса», «структура», тагын әлләниләр, һәрбер аңлашылмаган сүздән соң кызлар берберсенә карашып алалар, елмаялар, җилкә җыералар.

Лектор моны күрмәмешкә сабыша, сибә генә. Уңга таба атласа да, сулга атласа да, ул эскәмиянең нәкъ уртасында утырган Гөлчирәгә күз сала: нинди гүзәл кыз! Кашы —

карлыгач канаты, күзләре кара бөрлегән, бит очы — күзгә алма.

Лекция тәмам. Яшьләр сүзсез генә таралышалар.

— Ә сезне бер генә минутка мөмкинме? — Арслангали Гөлчирәнең беләгенә кагылды һәм күзләренә туры карады. — Сез бик аңлы кыз күренәсез, сезгә авыл хуҗалыгы академиясенә укырга керергә кирәк.

— Рәхмәт...

— Чынлап та, үзем сезгә ярдәм итәрмен.

Ләкин Гөлчирәнең бу кара тут йөзле егет белән сүз куертасы килмәде, бер сүз әйтми клуб ишегенә таба юнәлде. Аның уенда бары берәү — Нияз.

Кызның үзе белән салкын гына сөйләшүе Арслангалинең кәефен кырды. Бу кызыйга үзенең кем икәнен күрсәтер әле ул! Аның белән авыл кызлары түгел, Баулы кызлары да болай сөйләшми иде.

13

ФЗОда укыганда күп кенә егетләр сагынуга чыдый алмый кайтып киттеләр. Нияз кайту турында уйлап та карамады, ашау яхшы, өстә өр-яңа кием, акча төшә...

ФЗОны тәмамлагач, аны Прокопьевск шәһәрендәге Ворошилов исемендәге шахтага эшкә җибәрделәр. «Забойщик» дигән белгечлек документы булуына карамастан, аны проходчик итеп куйдылар. Проходчик — тау токымын тишеп, киң штрек (тоннель) куучы. Гаять авыр эш. Тамчылап торган салкын су астында токымны бораулап, штрекның түбәсен агач белән ныгытып, терәү салып куя. Еш кына лава баганаларны шыгырдатып кыса, бу кысуга чыдый алмый, токым кисәк-кисәк ярылып килеп төшә, забой дер селкенеп ала. Ниязның өстендә махсус кием, шулай да тәннең һәр күзәнәгенә салкын су үтә. Еш кына ул аягындагы резин итекне салып, суын түгә. Тузаны сулышны авырайта. Шушында инде шахтерлар күкрәк чире — силикоз алып инвалид булалар. Ничек кенә соң забойщик булып урнашырга? Нияз көн дә, төн дә шул турыда уйлый. Егетнең бер куанычы бар — кулга уч тутырып акча бирәләр. Беренче хезмәт хакыннан ул әнисенә биш йөз сум акча салып җибәрде, дүрт йөз сумга өр-яңа ялтырап торган тальян

гармун алды. Кичләрен, сменадан соң, шуның белән кайгы-сагышларын уртаклашты.

Ниязның бәхетенә шахтада яңа участок ачылды. Бу участокка эшчеләрдән икешәр-өчәр кеше күчерелде. Ниязны да шунда забойщик итеп алдылар. Монда коры һава, күмер катламы калын, өч метрдан алып алты метрга кадәр, катламнар текә, күмерне чабу җиңел, төяп җибәрү уңайлы. Лавада ике кеше эшли: берсе аста, лава эчендә, икенчесе өстә, штректа. Ниязның бергә эшли торган иптәше — зур тәҗрибәле шахтер Галимҗан Зелендинов, татар кешесе. Бик ярдәмчел, мәрхәмәтле кеше. Бер көнне ул Ниязга:

— Нияз энем, минем гаиләм белән танышасың киләме? Әйдә безгә, кунак булырсың, өй исе иснәрсең, — диде.

Бу гаилә белән танышу Нияз өчен бер куаныч булды. Ул үзенең кечкенә кайгысын онытып, бу гаиләнең кайгы-хәсрәтен үзенеке итеп кабул итте.

Яшь кенә авыл малае алар йортына килеп кергәч, Галимҗан аганың атасы Шәнгәрәй карт ун яшькә яшәргәндәй булды. Бик күп сөйләште, әле көлде, әле елап алды.

— Туган яклар бик сагындыра...

Картның ачынып әйткән бу сүзләре Ниязның халәтенә бик тәңгәл килә иде. Ул, уйчан күзләрен бер ноктага төбәп, Янтирәкне күз алдына китерде.

Шәнгәрәй гаиләсе белән егерменче еллар башында туган яктагы ачлыктан качып, Башкортстаннан, Туймазы якларыннан шахтага килгән. Йорт салган, балалар үстергән.

— Һай, улым, сугышка кадәр тормышлар бөтенләй башка иде. Татарлар күп. Мәктәпләрдә татарча укытылды, клублар ябылып тормады, театрлар уйныйлар иде. Сагынырга вакыт та юк иде. Акча күп алабыз, җәйләрен туган якка кайтабыз. Ә хәзер — бөтенләй башка. Кайтырга да оят. Мәктәпләр, балалар бакчалары урыс телендә. Балаларымның балалары татарча белми. Сугыштан соң татар мәктәпләре ябылды, клубларда урыс музыкасы гына. Как же! Урыс үзен җиңүче дип дөньяга танытты. Барысы да урысныкы! Башка халык — чүп! Гүя башка халык сугышта катнашмаган! Менә шулай, улым, без хәзер татар түгел, нацмен — аңлыйсыңмы? Национальное меньшинство!

Менә кая бара дөньялар! Бетте безнең татар, өч улымның берсе генә татарга өйләнде. Киленем — Арча кызы. Балалары барыбер урысча гына сөйләшәләр. Кызлар өчесе дә урыста.

Картның сүзләрен бик игътибар белән тыңлады Нияз. Түзмәде, үзе дә сорау бирде:

— Фамилиягез сезнең, ничектер, ни татарча, ни урысча түгел, димме?

— Аның тарихы да бик гыйбрәтле. Минем бабам Җәләлетдин булган. Балалары Җәләлетдиновлар, урысчалап әйтсәк, Залалетдиновлар иде. Элек бит биш ел саен паспорт алыштыру бар иде. Менә шул биш ел саен бер хәрефне төшереп калдыра торгач, әле Залетдинов, әле Залелдинов булып йөрдем. Инде менә урыс сүзенә якын Зелендинов булып калдык. Тел күтәреп каршы киленмәгән. Ярар, әйдә, дия торгач, балалар да Зелендиновлар булып киттеләр.

Ул арада өйгә кап-кара күзле, чәчрәп торган бер кызый килеп керде. Керде дә бабасына килеп сарылды, әле Ниязга, әле Шәнгәрәй картка карап, аларның сүзен аңламыйча, озын керфекләрен аска төбәп тын калды.

— Исемең ничек синең? — диде Нияз урысчалап.

Кыз күзен дә йоммады — тәтелдәде:

— Папа зовет — Рамиля, мама зовет — Римма, бабушка зовет — «Басурманка»,— диде.

Шәнгәрәй карт бу сүзләрне, бәлки, беренче тапкыр ишетмидер, шулай да ул шаркылдап көлеп җибәрде.

— Менә шулай, Нияз улым, безнең хәлләр — еласаң, гел елап торырлык, көлсәң, гел шаркылдап көлеп утырырлык, — диде, ташкүмер карасы сеңгән, кара тӧрткеләр тулы җыерчыклы битен җәеп елмаеп...

14

Район комсомол конференциясенә авылдан Арслангали белән Гөлчирәне делегат итеп сайладылар. Конференция озакка сузылды. Кич тынчу залда утырып, талчыгып, саф һавага чыккач, аллея буйлап барганда, Арслангали Гөлчирәне култыклап алды һәм, аңа таба иелә төшеп, пышылдады.

— Ниһаять, без бергә, икәүдән-икәү!

Гөлчирә кулын тартып алып, Арслангалидән читкәрәк тайпылды.

— Кыргый булма, мин бит болай гына, үз итеп, яратып кына, — диде Арслангали.

Гөлчирә баганадагы электр лампаларына карады, алар яктыртмыйлар, кып-кызыл булып эленеп торалар. Төнлә ай булса, яктырак булыр иде, дип уйлап алды кыз. Конференция делегатлары ашыгып-ашыгып таралыштылар.

Арслангали тагын кызның беләгенә килеп тотынды, аның беләген үзенә таба тартып:

— Әллә атны җигеп кайтып китәбезме? — диде.

— Төн бик караңгы бит.

— Ә безгә якты төн кирәкми дә, караңгыда кайту күңеллерәк булыр.

— Ай, юк! Юк!

— Ярар, алайса. Монда гына йокларбыз. Иртәгә иртән шәһәрдә тулганырбыз.

«Тулганырбыз». Нинди ямьсез сүз.

Гөлчирә эшсез, кирәкмәскә тулганып йөрүне бер дә яратмады. Шәһәргә килсә дә, йомышын тиз-тиз йомышлап, кайту ягын карый торган иде.

Аларны колхоз өенең хуҗасы, юан марҗа каршы алды. Арслангали Маня түтигә:

— Без монда кунып калырга булдык, — диде.

— Мин үземнең караватымны Чибәркәйгә бирермен, — диде тегесе.

— Юк, мин туганнарга барам, — диде Гөлчирә һәм ашыгып капкадан чыгып китте. Арслангали үҗәт кызны озата баруны кирәк тапмады.

Икенче көнне иртән Гөлчирә колхоз йортына килеп керде. Өстәл тулы пычрак савыт-саба, аракы шешәләре. Гөлчирәне күреп, карт марҗа сары тешләрен күрсәтеп, шаркылдап көлеп җибәрде, чәче-башы тузган, юынырга да өлгермәгән.

Гөлчирә кырт борылып, ишектән чыгып китте. Коедан су алып атны эчерде. Үзен-үзе кая куярга белми, ишегалдында йөренгәләде. Аннан ишекне ачып:

— Маня түти! Әйт әле теге кешегә, уянсын, авылга кайтып китәргә кирәк.

Шул арада нидер уйлап өстәде:

— Юк, юк, кирәкми, уятма, мин үзем генә кайтып китәм.

Гөлчирә атны йөгәненнән алып тәртә арасына кертте. Ул арада Арслангали уянып, кызның ат җигеп маташканын күреп, йөгереп чыкты.

— Тукта! Нишлисең? Хәзер үзем җигәм!

— Кагылма! Үзем, үзем.

Гөлчирәнең каршылык күрсәтүенә ачуы чыгып, Арслангали дуганы тартып алды һәм камыт бавына тыгып, турылады:

— Нинди килешле дуга. Шөлдер генә җитми, әллә кибеткә кереп шөлдер алып тагабызмы? — дип шаяртты.

— Почта алып кайтмыйбыз бит, нигә шөлдер?

— Минем сине уң ягыма утыртып, билеңнән кысып кочаклап, шөлдер чыңлатып, бар кешене шаккатырып, авылга кайтып керәсем килә. Күрсеннәр иде. Авылның иң чибәр кызы кемнең кочагында, янсын иде күзләре!

Гөлчирә аракы парыннан айнып җитмәгән бу егетнең сүзләренә ни дип тә җавап бирергә белмәде.

Алар тарантаска утырдылар. Арслангали дилбегәне үз кулына алырга теләгән иде, Гөлчирә кырт кисте:

— Юк! Дилбегәне үзем тотам...

15

Кемнәр генә эшләми шахтада! Кыргызлар, кытайлар, украиннар, татарлар. Төрлесендә төрле холык, төрле язмыш. Тормыш шундый катлаулы, каршылыклар белән тулы.

Монда яхшы күңелле Галимҗан ага кебекләр дә бик күп. Әмма кеше җанына кадалып, үртәп, үчекләп, усал сүз әйтеп кәеф җибәрүче, тәнгә кадалган шырпы яки аяк киеме эченә кергән таш кебек борчып торучылар да бар. Шундыйларның берсе — шахтада мастер булып эшләүче Сулейма Володя. Үзе чибәр, буй-сыны килгән, нык бәдәнле, ә менә холкы — яман. Бәйләнәсе килсә, кемнең кем булуы белән исәпләшми. Аның турында төрле сүзләр йөри, имеш, ул сугыш елларында немецларда полицай булган. Дөрестер дә, бу кадәр явыз булмас иде. Беркөнне ул Ниязга бәйләнде:

— Синең атаң колхозга кермәгән. Советка каршы булган, сез контра, шуңа сезне монда куганнар, — дип Ниязның канына тоз салды.

Нияз аның сүзләренә әлләни игътибар бирмәде, сөйли бирсен, дип уйлады.

Нияз эшли торган участокка ФЗО тәмамлап, тагын берничә егет эшкә килде. Аларны күргәч, Сулейма:

— Күрәсеңме, Батый ханнан тагын безгә пополнение килде, — дип, ачы көлеп, монголларның Киевне яулаулары турында тузга язмаган нәрсәләр сөйли башлады.

Аның мәсхәрәләп көлүенә, мыскыллавына түзә алмыйча, Нияз кулындагы кәйләсен читкә атып бәрде дә, тегенең якасыннан эләктереп алды һәм, үзе шәйләп алганчы, берничә мәртәбә башына кундырды. Тавышка лавадан Паша исемле шахтер килеп чыкты. Ул чагында Сулейма Ниязны егып салган иде, күзләрен тондырып Ниязга ташланырга торганда, Паша аны җилкәсеннән эләктереп, скважинага таба сөйрәде. Нияз сикереп торып, Пашага ярдәмгә ашыкты. Паша Бельц:

— Скважинага очырабыз, телеңне тыясыңмы, юкмы? Сүзләреңне кире ал! Гафу үтен, — дип кычкырды.

Егетләр шаярмыйлар — Володя моны аңлады.

— Братва! Мине гафу итегез! Башка бервакытта да алай эшләмәм!

— Кара аны, телеңне тиз кыскартырбыз.

Күп тә үтмәде, ниндидер карарлар нигезендә, Сулейманы мастерлыктан алдылар, ул гади шахтер булып эшли башлады.

Галимҗан ага ял иткән көнне Костя Шуруп исемле егет белән Нияз скважина шартлатып киңәйтү эшенә керештеләр. Өстәге штректан утыз метрлап аска төшеп, бораулап шартлаттылар. Әмма скважинадан газ чыкмады, күмер тыгылган иде. Костя штректа калды, Нияз баскыч буйлап аска төшеп китте. Кулындагы лом белән тыгылган күмерне тишкәләргә кереште. Ләкин күмер шул кадәр күп, тишекләр ясалмады, газ чыкмады. Ниязның күңеле болгана, башы авырта башлады. Өскә менеп китәр өчен баскычка тотынды, хәле бетте, гәүдәсен күтәрә алмады. Егылып төшеп китүдән куркып, ул бер кулын аркан баскычның арасына тыкты. Әллә каян еттактан:

— Чык тизрәк! Ник туктадың? — дигән тавыш ишетте.

Нияз һушын җуйды. Ниязның гәүдәсен ул тотынган

баскыч белән бергә скважинадан тартып алдылар. Штректа көчле һава агымы аны бераздан һушына китерде.

Эш ничек кенә авыр, хәвефле булмасын, Нияз өчен зур куаныч бар. Ул — Гөлчирәдән килгән хатлар.

Тик соңгы вакытта хатлар килми башлады. Тулай торакка почта килгән саен, ул йөгереп чыгып хатларны карый.

— Миңа тагын хат юк, — дип көрсенә.

— Язалар, язалар, — дип шаярта почта ташучы, — сиңа озын, би-ик озын хат язалар. Әле кәгазен сатып аласы бар, карасын ясыйсы, каләмен рәтлисе бар.

Ниязга бик күңелсез булып китә, аның шаян сүз тыңларга теләге юк. Аңа хат кирәк яки бер кечкенә открытка да ярап торыр иде. Шунда да бер генә сүз — «Гөлчирә» дип язылса, аңа шул җиткән. Әнисе хатларында бер дә Гөлчирә турында язмый. Сорап язарга Нияз кыенсына.

Ул бу кадерле исемне күмер тузаны кунган кара карга әллә ничә тапкыр язып куйды инде. Тик ул язган хәрефләрне шаян җил шундук бозып куя. Язганның эзе дә калмый.

Ә егетләр авылдан сөйгән кызыннан хат көткән Нияздан еш кына шаяртып-көлеп алалар.

— Монда кызлар кай яклары белән ошамый?

— Кара син Катяны яки Мотяны.

— Әнә Лиза — атаман. Аның белән яшәргә була. Акча күп ала.

Нияз түзми:

— Юк инде, егетләр, үзегезгә булсын кызларыгыз, хатыннарыгыз, — дип кулын селти.

Нияз өчен дөньяда бары тик Гөлчирә генә бар, бары ул гына! Гөлчирә генә! Ни өчен хат язмый? Әллә ташладымы? Башканы таптымы?

Беркөнне егетләр Ниязны кызлар барагына чакырдылар. Барак эче җылы, мичтә күмер яна. Кызлар берсен-берсе уздырып частушка сибәләр. Кәстрүл капкачлары кага-кага биилэр.

Берсе, Катя исемлесе, туфли үкчәләрен идәнгә бәрә-бәрә, Ниязга таба килә башлады. Йомры иңсәләрен чегән кызлары

кебек уйната-уйната тыпырдый. Нияз алдында озак кына селкенгәннән соң, ул сул аягы белән идән тактасына типте һәм артка чигенә башлады, гүя кулларын җәеп, егеткә йомшак келәм җәя, үзе белән биергә чакыра. Ә Нияз урыныннан кузгалмады, хатынга кырыс караш ташлап, борын астыннан гына мыгырдап алды:

— Бернинди бәйрәм түгел, нәрсә дип чашалар инде?

— Нәрсә, әллә миннән куркасыңмы? Ник биемисең? Һәй, бии белмисеңдер әле, татарин.

Катя, өметен өзеп, кулын болгады, тыпыр-тыпыр биюче ике кызны кочаклап алып, алар колагына нидер пышылдады.

Ниязга бик күңелсез булып китте. Их, үз авылларында булса, күрсәтер иде ул биеп! Авыл клубында ул биегәндә идән тakталары гүләп тора иде.

Катя кочагыннан аерылып, кызларның берсе Ниязга шундый итеп карады, Нияз аның түгәрәк йөзендәге, ул йөз өчен кечкенәрәк булып күренгән, өлгереп җиткән шомырт төсле чем-кара күзләренең очкынын күтәрә алмады, күзләрен алды һәм, баракка кайтырга кирәк, дип урыныннан кузгалды.

Ул арада теге Шомырт Күз аның янына ук килеп басты, егетнең күзләренә бәреп карады:

— Син татар егетемени?

— Булса соң, сиңа соң нәрсә?

Ниязның бу кыз белән дә сөйләшәсе килмәде. Бу да ут чәчрәп торган күзләре белән аңа ут төртергә, яндырырга тели, ахры, дип уйлады. Нияз кашын җыерды, чыраен сытты.

— Тукта, минем беләсем килә, син, чыннан да, татармы?

— Әйттем бит инде, мин — татар егете.

— Ә исемең? Николай диләр түгелме соң сине?

— Мин Николай түгел, Нияз. Ишетәсеңме, Нияз.

— Мин дә татар кызы, Әлфия, — диде кыз.

— Ярый, ярый, Аля, җитәр, телеңә салынма, ул минеке, мин аны үземнеке итәм. — Катя Нияз белән Әлфия арасына килеп басты һәм туп-туры, ашардай булып, комсызланып Ниязның күзләрен, иреннәрен, борынын, шашкан исерек күзләре белән ялап алгандай итте, кулларына ябышты.

Нияз Катяның кулыннан ычкынып, ишекне каты ябып коридорга чыкты. Коридорда тәрәзә буена чүгәләгән тәмәкечеләрнең борыныннан паровоз торбасыннан чыккан кебек бөркелгән куе зәңгәр төтен селкенеп-селкенеп тора иде.

17

Гөлчирә Арслангали белән булган күңелсез көнне искә алмаска тырышты. Корытау урманында зелпе тамыры казу башланды. Арслангали колхоз идарәсе аша һәр хуҗалыкка күпме тамыр җыярга план җиткерде.

Гөлчирә бер төркем яшьләр белән урманга китте. Арслангали аларга делянкалар бүлеп бирде, эшне оештырды.

Аны һаман бер уй борчый: ник Гөлчирә аңа бу кадәр битараф? Ничек кенә шул чибәрне үзенеке итәргә? Арслангали бер төпкә килеп утырды. Ара-тирә кызларның эше белән кызыксынды, сүз каткалады. Үзе һаман Гөлчирә турында уйлады: теге вакытта кыз белән кыюрак була алмады, тәвәккәлрәк, усалрак булырга, кунарга калдырырга иде. Нинди уңайлы вакыт иде бит! Йомшак баш! Пешмәгән! Хәзерге кызлар белән җебеп торсаң...

Ул Гөлчирәнең бер егетне уйлап саргайганын белә: шахтер диләрме, кайдадыр зимагур инде. Арслангали бит зимагур түгел, ул белемле, интеллигент кеше. Аңа булырга тиеш бу чибәр. Ну, ярар, тегенең кебек гармун уйный белми, ди, аның каравы — дәрәҗәсе бар. Гармунчы бит урамда гармун уйнаганда гына шәп, ә өйгә акча табучы кирәк. Өендә ул гармун уйнап утырмас бит, уйнаса да, Гөлчирә бит җырлап кына яшәмәс.

Урман эче тынчу иде, кинәт җиңелчә җил исеп куйды. Арслангали Гөлчирә ягына атлады. Кыз зелпе тамырларын бер өемгә өйгән, тырышып-тырышып тамыр йолкый. Арслангали кызның балчык белән пычранган кулларына карап сүз башлады:

— Гөлчирә, монда зелпе беткән инде. Мин сиңа куе зелпелекне күрсәтәм, телисеңме? — диде.

Гөлчирә тураеп басты да тир белән юешләнеп маңгаена төшкән чәчен яулык астына кертеп, яулыгын кысыбрак

бәйләп куйды. Маңгае кулындагы балчыктан пычранды. Арслангали моны күреп, алтынга пычрак кунмый, диләр, дөрес сүз, маңгаендагы пычрак та кызның матурлыгына зыян китерми, дип уйлап куйды.

— Әйдә, Гөлчирә, мин сиңа бер урын күрсәтәм, бер сәгать эчендә бер көнлек нормаң үтәлер. Анда зелпе менә моннан, — Арслангали кулын муенына тидереп алды.

— Башкаларга да әйт, алар барса, мин дә барырмын.

— Башкалар да барса, һәркемгә бер-ике агач кына тиячәк. Син үзең турында уйла, үзең башкалардан күбрәк җый. Әйдә, әйдә, моннан ерак түгел.

Нәрсә булды Гөлчирәгә, башын түбән иеп, Арслангали артыннан атлады. Куе урман үләне арасыннан сукмаксыз җирдән, кычытканнарны, кура җиләге үсентеләрен аралап, бер-бер артлы алар озак бардылар.

— Менә күрәсеңме? Ничаклы зелпе. Кил әйдә, икәү казыйбыз.

Арслангали кызның көрәген алып, кызу-кызу казый башлады.

— Әнә, тартып ал, нинди юаннар, озыннар. Берсе-берсе юан шиннар ясарлык каучук бирәчәк. Зелпедән алынган каучук — натураль каучук ул, безнең илдә резин әйберләр, галушлар, итекләр натураль каучуктан ясала,— дип сөйләнде.

Үзе шулай сөйләнде, үзе ничек кенә җаен китереп, бу кызны кочаклап алып җиргә егарга, дип план корды. Бу уйларыннан үзе шабыр тиргә батты.

— Гөлчирә, аны-моны уйламыйча, һаман зелпе тамырларын йолкуда булды.

... Сәримә Гөлчирәне бер генә минутка да күздән ычкындырмады: ни эшли, кем белән сөйләшә? Менә Арслангали Гөлчирә янына килде, туктап нидер сөйләште, аннан алар урманга таба атладылар. Сәримә көрәген атып бәрде дә кача-поса алар артыннан атлады.

Мәче кебек кенә, йомшак басып, алар ерып барган үсентеләр арасыннан берничә адым гына арттан атлады. Менә алар туктадылар. Арслангали казый башлады. Монда зелпе күп икән. Сәримә юан агач артына качып, тын да алмый аларны күзәтте.

Менә Арслангали көрәген ыргытты. Гөлчирәгә ташланды, биленнән кысып кочаклап, үзенә тартып китереп, кызның иреннәреннән үбә башлады. Гөлчирә бертуктаусыз чәбәләнде, Арслангалинең кулларыннан ычкынырга тырышты.

— Коткарыгыз! А-а-а! — дип кычкырды.

Сәримә шатлыгыннан ни эшләргә белми, кулларын уауа, тагын нәрсә булыр, дип тын да чыгармый карап торды.

Арслангали кесәсеннән кулъяулык алып, кызның авызына тыкты, аннан аны кинәт кенә җиргә егып салды да, үзе аның өстенә ауды, ашыга-ашшыга күлмәген күтәрә башлады. Гөлчирә тыпырчынды, тибенде, кычкыра алмады, бары җан ачысы белән ыңгыраšты гына.

Шул чак Сәримә, агач артыннан чыгып, аларга якынлашты:

— Менә сез кайда икән!—дип кычкырып җибәрде.

Арслангали көтелмәгән бу тавыштан сискәнеп, шашкан кеше кебек сикереп торды. Үз-үзен кулга алырга теләп, томан баскан күзләре белән Сәримәгә карады. Аңа Сәримә әллә ике, әллә өч булып күренде, ул башын чайкап алды һәм маңгаена төшкән юеш чәчләрен артка сыпырып куйды.

— Нәрсә, гыйшык-мыйшык уйнарга уңай урын эзләп монда килдегезме? Әйтәм аны, сезнең турыда авылда әллә ниләр сөйлиләр, юкка түгел икән.

— Тукта, Сәримә, син ни сөйлисең? — диде Арслангали.

— Кабахәтләр! Уйнашчылар! Гөлчирәнең уйнашчы икәнен белә идем. Ә менә сине... Сине мин юньле кеше дип уйлаган идем.

Гөлчирә суеп ташланган бәрән кебек, сүз ката да, кыймылдый да алмый шул халәтендә ята бирде.

— Тор, нәрсә ятасың? Төшер күлмәгеңне! Шакшы гаурәтең күренә!

Сәримә бөтен ачуын, бөтен үчен алып бетерергә теләгән кебек, Гөлчирәне төрле яман сүзләр белән мәсхәрәләвендә булды.

— Ниязны миннән тартып алдың, инде Арслангалигә тотындыңмы? Фәхишә!

Арслангали ни әйтергә дә белмәде.

— Менә шушында алып килде мине... Күрәсеңме? Мин гаепле түгел... Мин...

Сәримәгә шул гына кирәк иде.

Гөлчирә ашыкмый гына торып басты, күзләрен кысып, җирәнеп әле Арслангалигә, әле Сәримәгә карап алды. Йөзләренә төкерер иде, авыз эче коп-коры, башы чатный, куллары, бөтен тәне сыкрый, сызлый иде. Нинди кабахәтлек! Нинди вәхшилек! Түбәнлек. Җир ничек мондый бәндәләрне күтәреп йөри икән?

Еламады Гөлчирә, елый алмады. Аның бөтен барлыгын, моңарчы бервакытта да булмаганча ниндидер салкын нәфрәт биләп алды, ул кинәт калтыранып куйды, күлмәген, оекларын каккалады. Теге нәфрәт үсте, зурайды, күкрәгенең уртасын ташка әйләндерде. Ул бу халәттән котылырга теләп, тирән итеп сулыш алды, калтыранып көрсенде, бу ярсу, бу салкын нәфрәт аның күкрәгеннән кубып, йөзенә таба үрмәләде. Гөлчирә бит очларынын ут булып януын тойды, аннан шул ук нәфрәт рәнҗү булып, күзләренә менде. Күзләре бер мәлгә бик нык әчетеп куйды һәм кайнар яшьләр тәгәри башлады. Яшь тулы күзләре белән Гөлчирә кемнәндер ярдәм сорарга теләгәндәй, тирә-ягына каранды.

Аның янында Сәримә дә, Арслангали да юк иде. Ул кара урман уртасында, каһәрләнгән бу дөнья эчендә берүзе ялгыз калган икән бит! Шулчак ул әнисен, әнисенең түшәк өстендә яткан, сөяккә калган гәүдәсен күз алдына китерде.

Әнисе аңа үләр алдыннан:

— И, балам, ялгыз каласың бит. Ничекләр яшәрсең? Дөньяда явыз кешеләрдән саклана күр,—дигән иде.

Аның да әнисе күпне күргән, күп рәнҗетелгән булгандыр, бәгыре өзгәләнмәсә, баласына болай димәс иде.

18

«Тайженка» дип аталган зур участокка юл озын. Унынчы шахта коесыннан төшеп, җир асты поезды белән биш чакрым ара үткәч, юл ике тау арасында җир өстенә килеп чыга. Аннан яңадан коедан дүрт йөз метр җир астына төшеп эшлисе. Кайбер көннәрдә Нияз иптәшләре белән икенче сменадан соң поездга утырмыйча тау аша кайта. Агачлар, куаклар, яшел үлән, чәчәкләр... Шул җәяүләп үткән биш чакрым юл үзе бер бәйрәм була. Сагыну үзәкне өзә. Нияз шунда бер каен янына еш кына туктый, аны кочаклап ала,

яшьләрен тыймый. Гөлчирә белән соңгы мәртәбә ялгыз каен янында очрашу исенә төшә, йөрәге телгәләнә.

Их, Янтирәгем! Ник киттем синнән? Ник шунда гына калмадым,—дип әрни егет.

Тау өстендәге урман аланында егетләр шәфәкъ батканчы моңланып утыралар, һәркайсы үзенең үткәнен искә төшерә.

Беркөнне шул тау аша җәяүләп кайтканда алар каршысына бер төркем шәһәр яшьләре килеп чыкты. Күкрәк киереп, сөзәргә җыенган үгезләр кебек каш астыннан усал карап, җиң сызганып, егетләргә ташландылар. Ниязның кулында балта, башкаларда обушок, кәйлә. Сугыш куркыныч булачак. Шул арада мастер Перебейносның тавышы яңгырады:

— Татары, за мной! Бейте городских!

Шул чакыру авазы җитә калды, егетләр шәһәрнекеләрне тәпәләп ташладылар.

Икенче көнне Нияз белән берничә егетне шахта директоры үзенең кабинетына чакырды. Кабинетка мастер Перебейнос та чакырылган иде. Марля белән башлары бәйләнгән шәһәр егетләре берсен-берсе уздыра-уздыра:

— Мастер Перебейнос әмер бирде, шуңа болар безне кыйнадылар.

— Перебойное гаепле! — диделәр.

Нияз шунда тыныч кына:

— Без эштән кайта идек, мастер анда юк иде. Шәһәр егетләре үзләре безгә һөҗүм иттеләр,—диде.

— Әйе, әйе, безнең белән мастер юк иде, — диделәр егетләр беравыздан.

Тикшерүчеләр һәм шәһәр егетләре чыгып китте. Директор үзенең креслосына утырды да Ниязга елмайды. Аннан мастер Перебейноска карап:

— Яхшы егетләр эшли сездә. Мин күптәннән татарларның дус халык икәнен белә идем. Молодцы, егетләр,— диде.

19

Арслангали олы юлга чыкты һәм кызу-кызу авылга таба атлады. Ул башы чатнаудан, булып үткән күңелсез хәлләрдән исерек кебек чайкалды. Булмады, булмады. Булдыра алмады. Ул усаллыгына тәкать таба алмый җиргә каты-

каты басты. Аның авыр кирза итекләреннән җир дә ыңгырашкандай булды.

Кыланчык. Ныклап карасаң, әллә ние дә юк кебек, чибәр генә, күзе, кашы... Әллә кем диярсең. Сәримәнең сүзләре дөрес булса, инде әллә кайчан кулдан-кулга киткән икән үзе. Кыланган була. Керпе. Күзлут кебек үзе янып, кызыктырып тора, кагылсаң, энәсе кадала. Күзлут инде, нәкъ күзлут.

Кояш түбән төшә башлаган иде. Арслангали адымын бераз акрынайтты. Тагын ничек кенә күңеленә керергә соң каһәрнең? Башканы эзләргәме?

Артыннан кемдер ашыгып атлый. Аны куып җитәргә тели, ахры. Җиңел адым. Арслангали юри борылып карамады. Гөлчирә түгелме? Сәримәме?

Ашыгып атлаучы — Сәримә иде.

— Көтмәгән идеңме? Менә көчкә куып җиттем.

Арслангали папирос алып, авызына капты, шырпы сызды, папиросын кабызырга дип тукталды. Сәримә дә туктады.

— Бар, бар, мине көтмә, — диде Арслангали, авызын кыйгайтып төтенен өргәч.

Аның Сәримә белән сөйләшәсе бөтенләй килми иде.

— Ә минем ялгыз йөрисем килми, — диде Сәримә үҗәтләнеп.

Сәримә тирән итеп тын алды да Арслангалинең күзенә карап:

— Мин бүген күргәннәремне бөтен авылга сөйләячәкмен. Яңа лесник Гөлчирәне көчләргә теләде, мин генә аралап калдым, диячәкмен. Бәлки Гөлчирә сине судка бирер, ә мин шаһит булып барачакмын, — диде.

Арслангали бу көтелмәгән сүздән туктап, урынында катып калды.

— Син бит бая башкачарак сайраган идең, нәрсә булды сиңа? Нәрсә койрык болгыйсың?

— Койрык болгамыйм, дөресен әйтәм. Син Гөлчирәне...

— Җитте! — дип кычкырды Арслангали. — Җитте! Нәрсә, юк сүз сөйлисең? Мин аны үбәргә генә теләдем, үптерсен иде, карышмасын иде. Мин бит аны яратам.

— Яратам?! Үзеңне яратмаган кешене яратып буламыни?! Ул бит сине куралмый. Булдыра алса, атып үтерер иде. Син сукыр булма. Үзеңне яраткан кешене күрә бел.

— Әллә синеме?

— Әйе, мине.

Арслангали хәлнең кискенләшү мөмкинлеген чамалап, үзе дә Сәримәне кочарга, үбәргә торганда, кыз үзе сүзне җайга салды да куйды.

— Соң әллә кайчан шулай диләр аны. Мин бит сукыр, пешмәгән, юньсез, шуны күрмәдем, сизмәдем. Карале, Сәримә, ник соң син гел минем белән төртмә сүзләр белән генә сөйләшәсең? Нәрсә әйтсәм — ул ярамый, шырпыларыңны тырпайта башлыйсың.

— Син гел Гөлчирәгә генә карап, күзләреңне ата мачыныкы кебек яшелләндергәндә миңа ни кала?!

— Синдәй чибәр, яхшы кыз янымда гына булганын ничек итеп сизмәдем икән соң мин?

— Сизмәдең? Сиздең син, сиңа... Сиңа, беләсеңме, нинди кыз кирәк иде?

— Я, я, әйдә, әйтеп кара.

— Аның биек зур өе булсын, ялгыз булсын, чибәр булсын...

— Тагын, тагын...

— Тагынмы? Менә шул, мин бүгенге хәлне бөтен авылга чәчәм, сине авылдан кудырам, я төрмәгә яптырам.

— Син нәрсә, Сәримә, акылыңа кил. Син шундый чибәр, яхшы кыз, җитмәсә, мине яратасың икән әле. Мин, юләр, белмәгәнмен, мин дә бит сине күптән яратам. Тик син миңа карамассың, дип кенә сиңа сүз катмадым. Сәримә, дим, онытыйк, әйдә, теге хәлне онытыйк. Мин валлаһи сине яратам.

Арслангали Сәримәне сөякләрен сындырырдай итеп, бөтен көченә кысып, авызын зур ачып, калын иреннәрен капты да тешли-тешли суыра башлады. Сәримәнең буыннары бушады, хәле бетте. Арслангалинең кочагыннан котылырга теләсә дә, егет аны бик озак ычкындырмады, комсызланып, кыргыйларча тупас итеп кызның иреннәреннән чәчрәп кан чыгарлык итеп суырды да суырды.

Алар урман кырыенда икәүдән-икәү иде.

20

Бу көннән соң Сәримә Гөлчирә турында авылда уңлысуллы гайбәт чәчте. Максаты — Арслангалине үзенә карату иде.

Арслангали иртән торып, ишегалдындагы юынгыч янында баганага беркетелгән ватык көзгедән үзенең йончыган йөзенә карый-карый сакал-мыегын кыра, борын астыннан акрын гына җыр суза:

Кемгә сөйлим серләремне?

Йөрәгем ялкын кебек...

— Миңа сөйлә, Арслангали, миңа гына сөйлә, серләребез бер булсын, — диде күзен ертып яңа йокысыннан уянып чыккан Сәримә.

Сиңа сер сөйләсәң, кәтер китәрсең, дип уйлады Арслангали, сөйләрмен, тот капчыгыңны. Ә үзе:

— Һай, чибәрем, Сәримә, безнең серләр күптән бер бит инде, — дип пышылдады, үзе берәрсе ишетә күрмәсен дип, ялт итеп өй ишегенә карап алды.

— Тукта, Арслангали, чиста сөлге алып чыгыйм, бу сөлге юеш бугай.

— Алып чык, алып чык. Әйе, әйе.

Сәримә өйгә кереп китте, тиз генә йөгереп, юып үтүкләнгән чуклы зур сөлге алып чыкты.

— Тик... Түлисе булыр.

— Түләрмен, түләрмен, анысы миннән калмас.

Сәримә йөзен аңа таба сузып, күзләрен йомды, Арслангалинең үбеп алуын көтте.

Арслангали Сәримәне әләктереп алды да кырыныр өчен иягенә сылаган куе сабын күбеген аның иреннәренә сылап куйды, үзе каркылдап көлеп җибәрде.

Тфү! Тфү! Юньсез!

Сәримә юри генә ачуланган булды, әмма ул Арслангалинең шушы дорфа шаяруына да шат иде.

Гөлчирә, Арслангали белән очрашырга туры килгәндә, ләм-мим эндәшмичә, башын түбән иеп, җирәнеп һәм нәфрәтләнеп үтеп китү ягын карый. Бу хәл Арслангалинең күңеленә шом сала, әллә судка бирергә йөриме, дип хафалана егет.

Беркөнне Гөлчирә, урам буйлап уйланып килә торгач, Арслангалинең аңа каршы килүен абайламады.

— Гөлчирә, син мине, зинһар, гафу ит, мин синең белән тупас булдым, — диюгә, Гөлчирә башын күтәрде.

Бу кешене беренче мәртәбә күргәндәй, күзләрен киң ачып

аңа карады, ләкин карашы бушлыкта эленеп калгандай булды, кыз аны күрмәде, аның үз кайгысы кайгы иде. Күптәннән инде Нияздан хатлар килми.

— Гафу ит, Гөлчирә! — дип кабатлады тегесе.

Кыз эндәшмәде. Арслангали дәвам итте:

— Мин сине яратам, Гөлчирә, аңла шуны!

Гөлчирә кинәт уянып киткәндәй булып, җилкәләрен турайтты һәм егеткә ашардай булып каш астыннан карап:

— Кит юлымнан! Кит, дим, — дип кычкырды.

Кызның кара күзләреннән чәчелгән нәфрәт очкыны Арслангалине көйдергәндәй булды. Аның беркем алдында да болай каушап калганы юк иде. Ул бу күз карашыннан тетрәнеп куйды һәм, буйсынып, артка чигенде.

— Бәлки гафу итәрсең...

Бу аның күптән уйланган, әзерләнгән сүзләре иде.

Гөлчирә үз юлында булды. Арслангали тукталган җиреннән кузгалмады, кесәсеннән папирусын алып иреннәре арасына кыстырды да, җил уңаена борылып, шырпы сызды. Куллары калтыранды, бер сызды, ике сызды, папирусына ут ала алмый озак азапланды. Ут алгач, тирән итеп эченә төтен суырды, озак итеп өреп чыгарды. Әмма тәмәке төтене аның тынычлыгы төкәнгән күңелен баса алмады. Их, дип уйлады ул, нинди кыз бит! Нинди кыз! Ашыктым шул, алай кирәкмәс иде, иплəп, җайлап кына җанына үтәргә иде. Ә мин, тиле...

21

Маһибәдәрнең сеңлесе — почта таратучы. Сәримә күптән инде Ниязның хатларын үзе алып укып, аларны юкка чыгара барды. Гөлчирә язганнары да шулай юкка чыкты.

Ә бүген Сәримә Ниязга үзе хат язарга утырды. «Нияз!» дип язып куйды һәм уйга калды. Авыл хәлләрен, күршекүлән турында язаргамы, әллә турыдан-туры Гөлчирә турында гына язаргамы? Алай итсә, Нияз шикләнмәсме? Хат ярыйсы гына озак язылды. Сәримә авыл хәлләрен, үзләре белән укыганнардан кем кая киткән, ни белән шөгыльләнә — бәйнә-бәйнә язды. Хат җылы булсын, Ниязның күңеленә хуш килсен...

Ә Гөлчирә турында яза башлагач, никтер аның кулы

калтырый, хәрефләре кыек-мыек төшә башлады. Дәфтәр битенә хаталы сүзләр ятты. Аларны төзәтәм дип Сәримә язган хатын пычратып бетерде. Ачуы чыгып, урталай ертып ташлады. Ертыкларын җыеп, хатын башыннан ахырына кадәр күчереп язды. Бу юлы аның кулы тагын да ныграк калтыранды.

«...Гөлчирә Арслангали исемле лесничий белән типтерә. Авыл халкы инде күптән аларны ирле-хатынлы булып яшиләр, хәтта Гөлчирәнең авыры бар икән, дип тә сөйлиләр. Гөлчирәне күргән идем әле, битен тут баскан, ул бик үзгәргән, куәс чиләге кебек җәелгән, дөрестер, халык белми сөйләмәс. Менә шулай, Нияз, син мине чит иттең. Ә сөйгәнең сине онытты. Башкалар куенында. Ә мин сине һаман оныта алмыйм, көтәм. Кайчан кайтасың инде. Кайтсаң, бергә булыр идек...»

Хатын конвертка салып, Ниязның адресын язып куйды һәм почта ташучы апасы Маһисәүдәгә илтеп бирде.

—Апа, беркем белмәсен. Бу хат минем киләчәгемне хәл итәргә тиеш. Югала күрмәсен, — диде һәм Маһисәүдәгә исле сабын тоттырды.

22

— Үт, әйдә, үт, үт! Әйдә утыр, менә монда утыр. Гөлмәрьям ашыга-кабалана Гөлчирәгә урындык алып килеп бирде.

Ниязның әнисе Гөлчирәнең аларга килеп керүен көтмәгән иде. Ул күптән инде кыз турында авыл гайбәтләрен ишетеп, аптырап-йөдәп, ышанырга да, ышанмаска да белми яши иде, Гөлчирә аңа бик кайгылы күренде, йөзе саргайган, үзе тартылган, ябыгып киткән кебек тоелды.

Алар бераз сүзсез утырдылар. Гөлмәрьям кыздан хәлләрен сорашты, Гөлчирә елый ук башлады.

— И Гөлмәрьям апа, авыл тулды инде гайбәт белән. Авылда яшәрлегемне калдырмадылар. Китәрмен, ахры, авылны ташлап чыгып китәрмен. Өйне саттым, юлга акча бар.

— Кая китмәкче буласың соң, бала?

Гөлчирәнең түгелергә торган барлык кайгы-хәсрәтен, үзе белән соңгы көннәрдә булып алган күңелсезлекләрне түкми-

чәчми аның кайгысын аңлардай, хәленә керердәй берәүгә күптән инде сөйлисе килеп йөргән иде. Ул яшьләрен тыймады. Ниязның әнисен үз әнисе кебек якын итеп, киңәш сорап кыз аңа килгән иде. Ул гына ышаныр, аңлар, бәлки, киңәш бирер...

— Китәм, Гөлмәрьям апа, Пермь якларыннан әнинең туганнарыннан хат алдым, чакыралар, — дип алдады Гөлчирә бераз тынычлана төшкәч. — Монда бер көнгә дә кала алмыйм. Ул якларда урман эшендә акча эшләп була, ди, шунда китәм.

Гөлмәрьям пар бөркеп торган самавырын өстәлгә китереп утыртты.

—Ярый, Гөлчирә, сөйләштек, яшермичә барын да сөйләвең өчен рәхмәт. Башыңны имә, кызым, бирешмә, — диде Гөлмәрьям, ни дип сүз башларга белмичә. — Ниязның хатлары киләме соң?

— Юк, Гөлмәрьям апа, аның хатларын күптән алганым юк инде.

— Соң, җаным, ул бит миңа Гөлчирәгә дә хат яздым, дип яза. Ничек инде алмыйсың?

— Белмим, мина аның хатлары килгәне юк, язмый ул миңа.

Гөлчирә яшьле күзләрен сөртеп алды, ә яшьләре бертуктаусыз актылар да актылар.

Гөлмәрьям Гөлчирәне үз баласы кебек ике кулы белән кочаклап, басынкы тавыш белән юата башлады.

— Кирәкми, кызым, елама... Тынычлан...

Гөлмәрьям бу сөйләшүдән Нияз белән Гөлчирә арасында Сәриманең кулы уйнаганын аңлады. Ана улының стенадагы сурәтенә карады, күкрәгендә шундый ачы сыкрану кузгалды.

И бала, бала. Ярату, мәхәббәт дигән изге хисеңә кара куллар сузылган икән бит. Ничек кенә соң сине бу хәлдән йолып алырга?

Гөлчирә китәр алдыннан соңгы төнен Ниязлар өендә кунды. Гөлмәрьям аңа йомшак мендәрләрен салды, өстенә калын юрганын япты.

— Иртәнгә өй бик суына, салкын тия күрмәсен, — диде.

Гөлчирәне авылны чыкканчы озата барды.

— Хат яз, кызым, үземә атап хат яз! — диде һәм җәяүләп карлы юлдан җиңел-җиңел атлап киткән Гөлчирә артыннан бик озак карап торды.

23

Янтирәк белән Бөгелмә арасы ерак. Бераз юл үткәч, Гөлчирә авылга таба борылып карады, туган авылы булмаса да, Янтирәк аның өчен бик кадерле, якын иде.

— Хуш, Янтирәк! — диде Гөлчирә пышылдап. — Мин китәм инде, кайтырмынмы, юкмы, әйтеп булмый. Хуш! Хуш, яшьлегем үткән авыл, хуш, ялгыз каен!

Ул кызу-кызу алга атлады. Китәргә, китәргә, еракка-рак китәргә. Янтирәкнең бер генә кешесе дә булмаган ят җирләргә китәргә!

Көн әллә ни салкын түгел, җиле дә тымызык кына иде. Кинәт җил чыгып, буран күтәрелде. Ул көч-хәл белән Сакман тавын менеп җитте дә тирә-ягына каранды.

Буран. Кул җитеме арада берни күренми. Кире кайту турында уйларга да ярамый. Буран битне чеметә, салкын җанга үтә. Атларга, атларга...

Тездән кар ерып бара торгач, Гөлчирәнең колагына ат пошкырган тавыш ишетелде. Юлаучы утыртса, станциягә тиз барып җитәрмен, дип уйлап та өлгермәде...

— Һайт, юл бир, тапталасың!— дигән тавыш Гөлчирәнең колагын ярды, өмет дигән нәрсә юкка чыкты.

Ул юл кырыендагы тирән карга батты. Ат пыр тузып чабып үтеп китте. Кыз үксеп елап җибәрде.

Ничек итсә итте, буранга каршы атлап, Гөлчирә станциягә барып җитте. Аның яныннан ат белән узып китүчеләр — Сәримә һәм аның этисе, тире җыючы Халик булган икән. Станциядә Сәримә аның янына килеп басты:

— Гөлчирә? Кая киттең?

— Бәхет эзләп, — диде Гөлчирә, аңа күтәрелеп карамый гына.

— Яман исемеңнән качмакчы буласыңмы?

— Әйе, качмакчы булам.

— Кач, әйдә, кач. Яманаттан җәяүләп качу кирәк.

— Юк, яманаттан түгел. Яман кешеләрдән ераграк китмәкче булам, — диде Гөлчирә.

Гөлчирә поезд белән бик озак барды. Ак бәскә төренгән урманнар, торбалары туктаусыз төтенләп торган таныш булмаган шәһәрләр, ярымҗимерек авыллар күзгә чалыныш-чалынып үттеләр.

Аннан кыз йөк машинасының кабинасында бик озак селкенде. Машина кара урман эченнән тар гына юлдан барды. Урман, урман, шушы иксез-чиксез урманнардыр инде — аның алдагы язмышы.

Машина урман уртасында юан бүрәнәләрдән салынган озын шыксыз йортлардан торган бер җиргә килеп туктады. Авыл да түгел, шәһәр дә түгел.

— Килеп җиттек. Шушы инде Камский дигән поселок, — диде машина йөртүче.— Әнә тегендәрәк контора булыр, шунда барырсың.

Кайдадыр барлык тавышларны басып, колакны ярып түгәрәк пычкы чиный. Гөлчирәгә шул түгәрәк пычкы аның хәлен аңлап, аны кызганып елыйдыр кебек тоелды. Ул зур гына бер склад яныннан үтте, анда юан бүрәнәләрне зур-зур тырнаклар белән эләктереп, трактор чанасыннан склад янына бушаталар. Аның гомерендә дә бу кадәр күп, бу кадәр юан, озын бүрәнә күргәне юк иде. Кая китә икән бу кадәр агач? Саллар итеп агызуларын көтеп шушында өелеп ята инде болар, дип уйлады кыз.

Гөлчирә кадрлар бүлеген эзләп тапты һәм өстәл артында утыручы күзлекле кешегә документларын сузды.

— Ибраһимова Гөлчирә... — диде күзлекле ябык абзый аның паспортын кулына алып. — Гөлчирә инде алайса, татар баласы икәнсең.

— Әйе, татар кызы.

— Авыр эшкә килгәнсең, кызым, бездә эш тә, яшәү дә бик катлаулы. Нинди язмыш җилләре китереп ташлады сине бу якларга? Үзең бик яшь, үзең бик нәфис, дип әйтимме...

Абзый кешенең бу сүзләреннән Гөлчирә комачтай кызарды, ләкин аның нинди язмыш җилләре дигән соравына җавап бирергә теләмәде, кулындагы бияләен бертуктаусыз бөгәрләде, тарткалады. Юлда очраган һәр кешенең соравына үз язмышыңны сөйлиләрмени? Ләкин дәшми калу да мөмкин түгел иде:

— Дөнья күрәсем килде, — диде Гөлчирә.

Бу аның иң төгәл җавабы иде.

Күзлекле абзый бөтен йөзен җыерчыкларга күмеп, кызга туры карап, бик юмарт елмайды.

— Ярый, ярый. Дөнья күрергә теләү дә бик күркәм эш, — дип кенә куйды. — Ибраһимова, Ибраһимова... Ботак чабарга туры киләчәк, кызым, балта тотканың бармы?

— Булмаска, бар... Мин бит авыл баласы. Балта да тотканым бар, кирәк тә, пычкы да.

— О-о! Ябык кына булсаң да, бик кыю күренәсең.

Әллә инде күзлекле абзыйның Гөлчирә белән озаграк сөйләшәсе килде, әллә татарча сөйләшү аңа бик рәхәт булып китте, ул сораштырды да сораштырды. Атасы, анасы, белеме, авылы, хәтта сөйгән егете бармы, юкмы икәнен дә сорады. Гөлчирә агайның соңгы соравына бары бер сүз белән җавап бирде:

— Юк.

24

Иксез-чиксез тайга. Кая карама — шәм кебек төп-төз чыршылар. Төптә юаннар, ә очлары күккә тигән. Шул мәһабәт агач төпләрендә бик кечкенә кешеләр вак бөҗәкләр кебек мәш киләләр.

Менә Гөлчирә үзенә билгеләнгән пычкычы янына килеп басты.

— Ә, килдеңме? Ботак кисәргәме? — диде урыс кешесе, бүрегенең колакчын бавын өскә күтәреп бәйли-бәйли.— Яңа кыз бугай, беренче көнеңме?

Ничаклы сорау яуды кызга, ә ул дәшәргә ашыкмады.

— Исемең ничек?

— Гөлчирә.

— Ничек, ничек?

— Гөл-чи-рә.

— Ә-ә, бездә «гөл»ләр бик күп. Аларны белеп бетерәсең юк, телең сынар, барысы да Гуля. Син дә Гуля булырсың. Ә мин Иван Александрович.

— Иван Александрович,— дип кабатлады Гөлчирә.

Ә үзе мине Гуля ди, гүя мин унтугыз яшьлек җиткән кыз түгел, ә бер бөҗәк, теләсәң, исеме белән ата, теләмәсәң, бөҗәк кенә дип дәш. Кызга бик күңелсез булып китте.

— Юк, мин Гуля түгел, ә Гөлчирә. Гөлчирә диярсез. Мин бит сезгә зурлап исемегез һәм атагыз исеме белән дәшәргә тиеш, ә мине — бары Гуля. Юк инде, минем үземнең тулы исемем бар — Гөлчирә Ибраһимова. Ә этиемнең исеме Нургата иде.

— Димәк, Гөлчирә Нургатовна.

— Әйе.

— Телем сынар бит синең исемеңне әйткәндә, — Иван Александрович көлеп җибәрде.

— Бездә мәктәптә урыс теле укытучысының исеме Глафира Никандровна иде, беребезнең дә теле сынмады. Сезнеке дә сынмас, бәлки бераз гына йомшарыр. Мин сезгә Гөлчирә Нургатовна дип атагыз димим, мин яшь әле, Гөлчирә диярсез.

— Булды, таныштык, — диде урыс.

Үзе бик озак пычкысын кабыза алмый азапланды, әллә кызның кыюлыгы аны уйга калдырды. Чыннан да, башка кызлар берсе дә болай сөйләшмәделәр, Гуля дигәч, бик риза булалар иде. Шулай «Кудрявая Гуля», «Длинная Гуля». «Толстая Гуля»лар барлыкка килде. Ә бу — Гөлчирә, Гөлчирә, Гөлчирә.

— Онытмасам, Гөлчирә дип атармын, онытсам искә төшерерсең.

Урыс пычкысын кабызып җибәрде. Пычкының чылбыры бик каты сызгырып, тешләре арасына кысылып калган агач чүбен чәчеп җибәрде һәм җиңел генә агачның кутырлы кәүсәсенә барып та керде. Пычкы чүбе су чәчрәгән кебек сибелә башлады. Бераз шулай шау-гөр килеп агачның яртысына кереп җиткәч, пычкы туктап-туктап пошкырып та алды. Иван Александрович пычкыны тартып алды һәм шатор-шотыр килеп агачның икенче ягына чыкты. Тагын шау-шулы пычкы агачка керде. Пычкы ыңгырашты, улады, елады, сызгырды. Пычкы чүбе бөтерелеп-бөтерелеп очты, кар бураны кебек өермәләп-өермәләп сибелде.

Гөлчирә үзенең кайда икәнен дә онытып, аның эшләгәнен карап торды.

Агач кинәт дерелдәп алды, чайкалды, бер генә мизгелгә тынып калгандай булды һәм салмак кына бер якка авыша башлады. Киселеп бетмәгән агач үзәге ниндидер теш

камаштыра торган тавыш чыгарып, сынып чыкты. Иван Александрович кызның җиңеннән тотып, аны читкә әйдәде.

— Якын торырга ярамый, китереп бәрүе бар, —диде.

Агач коточкыч тавыш куптарып, вак-төяк агачларны сытып, кар өстенә ухылдап барып төште. Агач төшкән урында буран купты, кар көрте күккә омтылды һәм әкрен генә кире төшә башлады. Куе ботаклы мәһабәт агач күздән югалды, аны тоташ болыт пәрдәсе каплады. Аннан бер-бер артлы әле уңда, әле сулда шулай ук ухылдап агачлар ауганы ишетелде.

— Синең, Гөлчирә, ботак кискәнең бармы соң?

— Юк. Өйрәнермен әле.

— Кеше өйрәнмәгән эш булмас, тик менә көчең җитәр микән?

— Балтаңны менә болайрак тот, кәүсәгә якынрак чап, төп калдырма.

— Анысын гына белермен инде, — диде чая кыз, сер бирмәскә теләп.

— Ашыкма, алдан сөйләшмә, олыларны тыңла.

Чыршылар бик юан, куе ботаклы. Гөлчирә кисеп аударылган агачның янын башта яхшылап таптап чыга. Аннан, аскы иренен тешләп, бар көченә кизәнеп, ботакка чаба, бер-бер артлы ботакларны чукый башлады.

25

Шахтада тәмәке тартырга, шырпы кабызырга ярамаганны һәркем белә. Кайчакта электрдан чаткы чыгыш та шартлау очраклары булгалый.

Забой кайвакыт гүләп тора, андый көннәрдә забойга кермиләр, хәвефсезлек кагыйдәләре шуны таләп итә. Аварийщиклар штректа сынган кругларны алмаштыралар, бортны чистарталар, лава астындагы штрекның беркетмә кругларын сүтеп куялар, икенче смена килгәч, лаваны шартлатканда, аннан күмер бертуктаусыз агып торырлык булсын.

Шахтада эшчеләр күп: забойчылар, проходчылар, мастерлар, шартлатучылар, җилләткеч эшчеләре. Тик алар бербереен күрмиләр. Шахтада беркем дә юк кебек, һәркем үз урынында. Кечкенә поездлар тимер юл буйлап йөреп тора.

Беркөнне кинәт лавадан күмер ишелеп төшеп, Ниязны муенынннан ук күмеп куйды. Бәхетенә, аның өстенә коелган вак күмер озак каплап тормады, чокырга шуышты, агып китә башлады. Нияз тиз генә штрекка чигенде һәм Галимҗан аганы тартып чыгарды. Тагын лава җимерелә башлады, өстәге штректан лава җимерелүен ишетеп, мастер килеп җитте.

— Сез исәнме? Гомерегез озын булсын! — дип үзе елап ук җибәрде...

Арып-талчыгып кайтуга, Ниязны Сәримәдән килгән хат көтеп тора иде. Бу хат Ниязны пычаксыз суйды.

Гөлчирә язган хатларында авылга килгән яңа кеше турында хәбәр бирмәде. Ни өчен? Әллә чыннан да... Әллә Гөлчирә Ниязны алдап ятамы? Ышаныргамы Сәримәнең язганнарына? Булмас, булмас! Гөлчирә андый кыз түгел. Ул тагын Гөлчирәгә хат язып салды. Кем ул Арслангали? Нинди егет?..

Берничә атнадан Ниязга әнисе язган хат килеп җитте. Гөлмәрьям улына Гөлчирә белән булган хәлләрне бәйнә-бәйнә язган иде. Гөлчирәнең гел юкка рәнҗетелүе, Сәримәнең мәкерле эшләре, Арслангалинең явызлыклары, гаепсез кызның авылдан чыгып китәргә мәҗбүр булуы турында иде хат. Ана улын шелтәләп тә алган иде: «...хатлар язмагансың, синең хатларың булмаганга, Гөлчирә бик гарьләнде», — дип язган. Хатта язганнар Ниязның күзләрен ачты, менә ни өчен Гөлчирәдән хатлар килмәгән икән.

Күпмедер вакыттан соң Гөлмәрьям улына Гөлчирәнең адресын салып җибәрде.

Кыз белән егет арасында җылы хатлар йөри башлады. Алар отпуск алып авылга кайту турында планлаштырдылар. Нияз Гөлчирәне эшләгән урыныннан килеп алачагын язды...

26

Бәхетле бүген Сәримә. Ул көн саен Арслангали белән. Менә бүген дә кулындагы сәгатенә күз сала-сала аның яныннан Арслангали атлый. Сәримә аны култыклап алган, үзе кая басканын белми, аяк астында җирне сизми, күбәләк кебек җилпенә. Өстендә өрфиядәй җиңел күлмәк, аякларында шыгырдавыклы чүәкләр. Арттан көнче күзләр карап

калалар. Арслангали аның кулын беләге белән җиңелчә генә кысып куя: күрсеннәр!

Тик бу бәхетле көннәр озакка бармады: Сәриманең гәүдәсе үзгәрде, күкрәкләре авырта, күңеле болгана башлады.

Маһибәдәр, күпне күргән хатын, кызындагы үзгәрешләрне бик тиз сизде. Чарасын күрә башлады. Арслангали белән сөйләшеп уртак тел таба алмагач, ул колхоз рәисе аша эш йөртергә булды. Арслангали колхоз рәисе Хәсән Харисовка:

— Минем аның белән булганым юк, ул үзе теләсә кем белән ятып, мине кулга алмакчы була, — дип кырт кисте.

Арслангали бу сөйләшүдән соң озак тормады, документларны алып, моннан тизрәк таярга булды.

Арслангали кошевка чанада район үзәгенә документларын алырга бара. Карлы юлда чана салулаган саен ул күзләрен ача, аннан тагын күзләрен йомып, уйларына чума. Ә уйлары башыннан ашкан. Кайда гына эшләсә дә, шул ук бер нәрсә: аңа һәрчак җил каршы. Бу яңа урыннан тагын уңмады, урманчылык буенча әлләни майтармады, агач утырту буенча планны үти алмады. Ул бит зур планнар белән килгән иде, элеккеге мәхәббәт маҗараларын онытып, яңача эш һәм яңача тормыш башлау иде планы. Нияте — берәр чибәрне очратып, яратып һәм яраттырып өйләнеп җибәрү, йорт салу, балалар үстерү иде. Тагын бөтенесе җимерелде, тагын ялгышты, нәфес дигән явызны тыя алмады. Беткән баш инде, беткән баш! Дурак.

Ә ат салмак кына атлады да атлады.

«Койрыкка басканчы, тизрәк китәргә, — дип уйлады Арслангали. — Сәримә белән буталып беттем. Корсаклы, имеш, әллә кайчан, әллә кемнәр белән чуалган башы белән, син генә мине хур иттең, кеше күзенә күренерлегемне калдырмадың, дип елый, тиз көндә өйләнмәсәң, мин сине нишләтергә белермен, дип яный. Яхшы чакта таярга, таярга! Теләсә ни эшләсен. Минем койрыкны тота алмас ул. Китәм, Пермь якларына китәм. Эт белән дә эзләп таба алмас җиргә китәм...

27

Арслангали, поездга утыргач, ерак-ерак юл алып, ниһаять, ялгызлык рәхәтенә чумды. Шул вакыт вагонга беләгенә кызыл чүпрәк бәйләгән бер хатын килеп керде. Арслангали чакырылмаган бу хатынга сөенмәде, анын никтер ачуы килде, тик ул, табигате белән тиз аралашучан булганлыктан, үзенең халәтен сиздермәде, ирен читләре белән генә хатынга елмайды. Кечкенә гәүдәле, җитез хәрәкәтле бу хатынның Арслангали яшен билгеләргә тырышып карады, яшь кыз түгел, әмма картайган дип тә әйтеп булмый. Хатын-кыз шундый инде ул, дип уйлады Арслангали. Бер караганда, аңа утыз-утыз биш, икенче карасаң — егермене дә биреп булмый. Хамелеон кебек үзгәреп кенә торалар алар.

Бу хатын белән Арслангали арасында ниндидер күзгә күренмәгән җеп сузылгандай булды, алар бер-берсенең күзләренә карашып бик тиз аңлаштылар.

Хатын тиз-тиз генә соры чүпрәге белән тузаннар сөрткән булды, аннан Арслангали белән сөйләшәсе килүен сиздереп, кушеткага утырды.

Арслангали бу хатынның кечкенә гәүдәсенә бер дә килешмәгән олы күкрәкләренә игътибар итте. Тимер юлчылар формасы эченә тыгызлап тутырылган булса да, ике якта ике баш чаклы булып тыҗраеп торган тыгыз күкрәкләр Арслангалинең күңелен әллә нишләтте. Аларны капшап карыйсы килде, хәтта иреннәрен тидерәсе килеп китте.

— Кая юл тотасыз? — диде хатын тупас, ирләрчә калын тавыш белән.

— Курортка.

— Себердә нинди курорт, ди?

— Миңа дигәнен салып куйганнар, — дип көлде Арслангали.

Хатынның йөзенә нәфрәт күләгәсе ятты: сөйләшүен кара, мактанчык, франт. Үзен әллә кем дип белә, ахры, әллә кая түгел — тайгага, урман эшенәдер әле. Авыл эте. Авылында яшәрлеге калмаган шалапайлар урманга кача. Бу да шуларның берсе инде, дип уйлады хатын. Шулай да, үзен тиз кулга алды. Мондый таза чибәр егетләрне ул аз күрмәде, җылы сүзгә теләсә нинди туң йөрәк тә эреп төшә.

Арслангали хатынның күз төпләрендәге җыерчык-ларына, ирен тирәли сибелгән ачы язмышка үпкә билгесе булган беленер-беленмәс сырларга күз төшерде һәм ул хатынның бөтен үткәнен күз алдына китерде: мәктәптә озак укымаган, бик яшьли эшли башлаган, иргә иртә чыккан, уңмаган, хәзер ялгыз, ни өе, ни баласы юк...

Арслангалинең бу хатын өстендәге кысан кительне ычкындырып җибәрәсе килде. Аңа вагон һавасы тынчу булып тоелды һәм ул тәрәзәгә таба шуышты, куллары бу хатынга сузылмасын дип, кечкенә өстәлгә бармакларын җәеп куйды. Ул тагын үзенең кыргый хисләренең баш күтәрүеннән куркып калды.

Ул кырын күзе белән хатынга карап алды: сизенмиме? Күрмиме?

Хатын аңа ышанучан караш ташлап елмая иде. Вагон бик каты селкенеп куйды. Арслангали тәрәзәгә күз салды: поезд ике состав арасында тар гына урынга керә иде, тәгәрмәчләр шыкылдавы сирәгәйгәннән-сирәгәя, поезд туктарга җыена иде. Проводница хатын вагоннан ашыгып чыгып китте.

28

Көн буе эшләп, арып, кәүсә өстери торган каты юлдан Гөлчирә олы юлга таба атлады. Юлга чыгып җиткәч, киез итекләрен кардан чистартып, сырган чалбарына ябышкан бозларны бәреп-бәреп төшерде. Кайдадыр бик еракта урман яңгыратып, радио тавышы ишетелә. Поселокка чаклы ике чакрым атлыйсы. Шулай инде, дип уйлады Гөлчирә, карлы юлдан шыгыр-шыгыр атлаганда, кемдер радио тыңлап җылы өйдә утыра, кемдер балта һәм пычкы белән акча эшли. Тормыш шулай бик катлаулы.

Арттан ат тоягы тавышы ишетелде. Гөлчирә сөенеп куйды: баракка кадәр бер чакрым булса да ул атка утырып кайтыр. Кәүсә ташучылар шулай еш кына аны утыртып алып кайталар. Җигүле ат аның янына ук килеп туктады.

— Һәй, утыр, кызый! — дип кычкырды кемдер. — Утыр!

Гөлчирә ат тоткан кешегә карады һәм үз күзләренә ышанмады, өнеме, төшеме? Чана өстендә Арслангали иде. Гөлчирә таныса да, танымагандай:

— Утырмыйм, үтеп кит! — диде аңа карамый гына, үзе чана янынннан атлый бирде.

— Нәрсә? Тешләмәм, — дип шаяртты Арслангали. — Икәүләп тизрәк барып җитәрбез. Җылынырбыз.

— Күземнән олак! — дип кычкырды Гөлчирә үзен-үзе белештерми.

Монда да эзләп тапкан, каян белгән ул минем монда икәнне? Гөлчирәнең арыган гәүдәсе тагын да авырайды. Ул бу минутта, булдыра алса, бу бәндәне чәйнәп атар иде.

Делянкада әле һаман эш кайный, җиргә агач ухылдап ава, балта тавышлары яңгырап тора.

— Тапмас дип уйлаган идеңме? Озак эзләдем. Мин бит синнән башка яши алмыйм, Гөлчирә, — диде Арслангали.

29

Туң ишекне шыгырдатып ачып, Гөлчирә эчкә үтте. Кызлар мичкә якканнар, берсе мичкә якын утырган, бит алмалары уттай яна. Өстәл өстендәге керосин лампасы томан эчендә булып күренә — бүлмә эче төтен.

Эштән соң бик арыган булса да, Гөлчирәнең баракка кайтасы бер дә килми. Хатыннар арасында аңа бик читен, нинди генә сүзләр, нинди генә яман хәлләр турында сөйләшмиләр алар. Гөлчирәнең дә кем икәнен беләселәре килеп сорашалар. Гөлчирә сорауларга ачык кына җавап бирми. Бу йомылып яшәү аңа шундый авыр. Кичләрен алар кайсы кая китә, Гөлчирә берүзе кала. Еш кына урамда ялгыз йөреп керә. Янтирәкне, су буйларын, ялгыз каенны, Ниязны искә төшереп, тәкатьсездән күзләренә яшь килә. Ә Арслангали белән очрашудан уттан курыккан кебек курка.

Арслангали исә һаман да Гөлчирә белән аңлашуга исәп тота, тәкәббер кыз монда юашлангандыр, ачуы басылгандыр, сагынгандыр, дип фикер йөртә. Ничек кенә булса да, ул Гөлчирәнең күңелендә үзенә карата ышаныч, ихтирам хисе уятырга тиеш. Нинди сүзләр табарга? Нинди бүләк бирергә? Ничек итеп ул боз йөрәкне эретергә? Бер әйбер дә алмаса?..

Юк, ул аны барыбер үзенеке итәргә тиеш. Нинди генә юллар белән булса да. Монда кемне кем белә? Кем күрә? Күрсә дә, сөйләми. Ә ул әллә кая китә алмас.

Менә ул, тыкрыклар буйлап үтеп, Гөлчирә яшәгән барак

янына якынлашты. Соңгы көннәрдә ул кич саен шушы барак тирәсендә таптанды, очратыр, сөйләшер кебек тоелды. Ләкин Гөлчирә чыкмады. Менә ул тәрәзә рамына якын килде, тәрәзә пыяласының туңмаган бер почмагыннан барак эченә күз салды. Өстәл янында Гөлчирә нидер эшләп утыра, битенә лампадан тоныккына яктылык төшкән, бу яктылыкта ул бигрәк чибәр булып күренә.

Арслангали барак эченә керергә җөрьәт итмәде, урам буйлап китеп барды.

Күпмедер вакыттан Гөлчирә белән яшәүче кызлар шаугөр килеп урамга чыктылар һәм клубка таба киттеләр. Арслангали кире әйләнеп килде һәм тәрәзә пыяласы аша тагын бүлмә эченә күз салды. Гөлчирә һаман баягыча утыра, әллә чигү чигә, әллә төймә тага.

Арслангали, бар кыюлыгын җигеп, бүлмә ишеген ачты һәм үзе белән салкын ияртеп, итекләренә кунган карны да какмыйча, бүлмә эченә атлады.

— Саумы, Гөлчирә? Әллә үзең генәме?

Гөлчирә, сискәнеп, башын күтәрде һәм куркынган күзләрен Арслангалигә текәде.

— Сиңа ни кирәк?

— Ярар, ярар. Тыныч кына. Ашамам. Ул ашыкмый гына тунын, итекләрен салып ишек төбенә куйды, аннан Гөлчирә янына урындыкка утырды.

— Чигү чигәбезме?

Кыз нәрсә уйларга, нәрсә әйтергә белми югалып калды. Шул минутта Арслангали Гөлчирәне җайсыз гына үзенә таба тартып, кысып кочаклады һәм иреннәренә үрелде. Гөлчирә башын артка ташлап:

— Коткарыгыз! Каравыл! — дип кычкырды.

— Юләр! Кычкырма! Барыбер беркем дә ишетмәс.

Гөлчирә аның беләген тешләп алды. Арслангали, авыртуга түзә алмыйча, аны кочагыннан ычкындырды. Ә Гөлчирә йөгереп кенә мич яныннан утын агачы алды, аның күзләреннән зәһәр очкын очты:

— Якын килмә! Якын килмә! Башыңа бирәм! Үтерәм! — дип кычкырды кыз һәм чөйдән пәлтәсен алып, ишектән чыгып йөгерде...

30

Соңгы вакытларда Нияз үз-үзен белештермичә, бәхеттән канатланып, очынып-очынып йөрде. Гүя ул җир кешесе түгел, йолдызлар арасында. Алдагы матур тормыш турындагы хыяллар аңа канатлар куйды. Тиздән алар авылга кайтырлар, никах укытырлар, дусларын җыеп, туй ясарлар. Аннан... Аннан...

Нияз соңгы сменасына эшкә килде. Лавага төшәр алдыннан, зәңгәр күккә сокланып карап торды. Аннан соң Галимҗан ага артыннан атлады. Соңгы тапкыр, соңгы тапкыр, дип уйлады Нияз, аннан отпуск, Гөлчирә, авыл...

Нияз шулкадәр җилкенде, гүя аның кулында авыр көрәк түгел, ханым-туташлар җилпенә торган япон веером, ташкүмер дә гүя күмер түгел, бодай кибәге. Җилләткеч тә тузанны яхшы суыра.

Ара-тирә Галимҗан белән Нияз сөйләшеп тә алалар.

— Ну, егет, авылга, ялга, дисең инде син? — диде Галимҗан, тешләрен ялтыратып елмаеп.

— Әйе, Галимҗан абый, иң элек Гөлчирә янына барам, аның белән авылга китәбез.

— Кайчан юлга?

— Иртәгә кичке алтыга билет алдым, каршы ал, дип телеграмма бирдем. Өч көннән анда булам.

— Яхшы, яхшы. Тимерне кызуында сугарга кирәк.

Эш дәвам итте. Бүген алар аеруча тырышып эшләделәр. Смена бетә дигәндә забойда кинәт чыбыркы шартлаган тавышлар килә башлады, ныгытма баганалары басымга түзә алмый шыгыр-шыгыр килделәр, өстән токым ишелә башлады. Галимҗан белән Нияз штрекка таба омтылдылар, тик гөрселдәп лава ишелде һәм икесе дә басылып калдылар.

Коткаручылар отряды озак көттермәде. Башта Ниязны казып алдылар. Аның башыннан кан саркып күзләрен каплаган, йөзе танырлык түгел иде.

— Пульс бар, тын ала, — диде шәфкать туташы.

— Ипләп, ипләп, башын тотыгыз.

Аннан Галимҗанның күмер астында сытылып изелгән үле гәүдәсен казып алдылар. Ниязны «ашыгыч ярдәм» машинасы хастаханәгә алып китте.

Нияз ике тәүлектән соң гына аңына килде. Башы чатнап

ярыла, күзләре тәрәзә яктылыгын томан аша гына шәйли. Башы марля белән бәйләнгән. Бетте, бары да бетте, дип уйлады Нияз, ял да очты, Гөлчирә дә. Ә Гөлчирә аны каршыларга килер, көтәр-көтәр дә ни уйларга белми кайтып китәр. Инде ни эшләргә?..

Ниязга өч ай буе урыныннан кузгалырга ярамый, диделәр. Хәле бик җитди, мие бик каты селкенгән, күзләренең бик күп нервылары өзелгән. Сукыр калу ихтималы зур, диделәр.

31

Тимер юл станциясендә халык күп түгел. Нияз утырган поезд килеп җитәргә ярты сәгать вакыт бар. Гөлчирә бераз утырып та торды. Түзмәде, йөреп килде. Дулкынланудан йөрәк түзми, хәрәкәт сорый. Ул буфетка да кереп чыкты. Нияз поездан төшкәч, монда кереп чәй эчәргә кирәк булыр, өч көн буе юлда арып, йончып килер. Гөлчирәнең үзенең дә тамагы кипте. Буфетта кыздырылган балык, пирожкилар исе тамакны кытыклады. Кемнәрдер өстәл тирәли басып кына колбаса чәйни, чәй эчә, сүз куерта.

Гөлчирә буфетта озак тормады, чыгып тагын урынына барып утырды. Поезд килер вакыт җитте. Ул перронга чыкты. Йөк ташучылар уңга-сулга чабуладылар. Вокзалдан кызыл фуражка кигән дежурный чыкты, шул арада аны көтеп кенә торган кебек борылышта паровоз кычкыртып җибәрде. Перронга халык агылды. Паровоз, аждаһадай үкереп, Гөлчирәгә куе пар бөркеп, чажлап үтеп китте, вагоннар әкренәя төште, тормозлары чыелдады.

Гөлчирә әле уңга, әле сулга башын бора-бора вагоннарны озатты. Нияз тәрәзәдән аны күрер, кул болгар, кычкырыр, дип уйлады кыз.

Кемдер ашыгып чабып үтте, аны бәреп ега язды. Буферларын шыгырдатып, состав туктап калды.

Вагоннарның ишекләре ачылып китте, зур-зур чемоданнар, төеннәр тотып, кешеләр төшә башлады.

Гөлчирә муенын сузып кешеләр арасыннан Ниязны эзләде. Вагон тәрәзәләренә күз салды. Түзмәде, кешеләрне этә-төртә әле алга, әле арткы вагоннарга таба чапты. Ләкин бер җирдә дә Нияз юк иде.

Әллә йоклап калдымы? Әллә поездга соңга калды микән? Әллә бөтенләй башка поездда киләме икән? Кыз нәрсә уйларга да белмәде.

Гөлчирә бер вагон янына килеп, ишектә басып торган про-водницадан:

— Бу Новосибирск — Мәскәү поездымы? — дип сорады.

— Әйе, шул, шул, — диде хатын.

— Чынлапмы? — диде кыз аптырап.

Ул арада поезд кузгалып та китте.

Арслангали станциядә Гөлчирәне читтән генә күзәтеп торды. Гөлчирә аны күрмәде. Кызның вагоннар буйлап йөгерүен, каршыласы кешесенең төшмәвен, килмәгәнен аңлап, поезд китеп, перрон тынып калгач, ул әкрен генә кызга таба атлады.

Гөлчирә рәнҗеп, чарасызлыктан ни уйларга, үзен-үзе кая куярга белми, башын иеп перронда берничә минут басып торды. Килмәде... Килмәде... Кесәсеннән телеграммасын алып кабат-кабат килер көнен, сәгатен укыды. Барысы да дөрес. Нәрсә соң бу?

Арслангали өчен моннан да уңайлырак вакытның булуы мөмкин түгел иде. Гөлчирә аныкы! Фәкать аныкы! Киләсе кешесе килмәде. Ул аңа кайгысын сөйләр, елар, Арслангалинең җилкәсенә башын салыр, кочаклатыр, дип хыялланды.

Ул Гөлчирәнең уң ягына килеп басты.

— Каядыр китәргәме әллә, Гөлчирә? — диде бик ясалма, йомшак тавыш белән.

Гөлчирә сискәнеп китте, аңа таба борылды. Каршысында торган Арслангалине күреп, куркып калды.

— Беркая да китмим. Китәр җирем юк, — диде коры гына.

— Поселокка кайтасыңмы? Мин матай белән, алып кайтам. Әйдә, әйдә, киреләнмә.

Ул Гөлчирәне култыклап өстери үк башлады. Гөлчирә аякларын терәп каршы торды һәм бик озак тарткалашты.

Зур гәүдәле, егерме биш яшьләрдәге бер егет бу тамашаны күреп, битараф кала алмады. Аларга таба йөгереп килде.

— Җибәрегез кызны!

— Кыз түгел, ул минем хатын.

— Алдашма! — дип кычкырды Гөлчирә.

— Җибәр, егет, яхшы чакта!

— Ә син кем? Нәрсә? Күптән борының канаганы юкмы эллә?— дип җикерде Арслангали.

— Үзеңнеке канамасын!

Егет Арслангалинең якасына барып ябышты.

— Ярый, ярый, егетләр! Сугыша күрмәгез! Җитте! Булды! — дип Гөлчирә икесенең уртасына басты.

Арслангали тупас итекләре белән лап-лап атлап, алпан-тилпән матае янына китте. Матаен бик озак тырылдатып, әче төтен исе таратып, поселокка таба китеп барды.

— Сез кем? — дип сорады Гөлчирә, ниһаять, таныш түгел бу миһербанлы егеттән.

— Исемем Хәмит. Тракторчы. Отпускыдан килүем. Ә син кем?

— Гөлчирә исемле мин. Камский поселогыннан. Ботак чабучы булып эшлим.

Хәмит кызның җыйнак гәүдәсенә, сабыйларча саф йөзенә, ихлас карашлы күзләренә кызганып карап торды. Бу нәфис кызга авыл мәктәбендә укытучы яки китапханәче булып кына эшләргә иде. Ә ул монда тупас балта тотып, ботак чаба...

— Бик авыр түгелме соң?

— Авыр иде, күнегәм.

— Ә бу кеше кем?

— Бу бер «сагыз», «сагыз»ның да куркынычы, оятсызы, комсызы.

Хәмит барысын да аңлады. Кызны торган җиренә кадәр илтеп куярга кирәк, дип уйлады.

— Мин Дубровкадан, Камский аша кайтырмын, сине кертеп куярмын, — диде.

— Бик зур рәхмәт, Хәмит абый. Сез булмасагыз, мин беткән идем, — диде Гөлчирә Хәмиткә, барак янында машинадан төшкәч.

Хәмит аның белән җылы саубуллашып, китеп барды.

32

Нияз килмәде. Шикләнеп, икеләнеп торасы юк, ул үч ала, мыскыл итә, көлә, мәсхәрәли, дип уйлады Гөлчирә. Шул

көнне үк кич бик озын хат язды. Барысын язды. Рәнҗешләрен, үпкәсен, үзенең аны гына, фәкать аны гына яратуын... Елый-елый, күз яшьләрен тамыза-тамыза язды кыз хатын. Ләкин бу хат Нияз кулына эләкмәде. Хат баракта бүлмәдән бүләмгә, кулдан кулга күчеп, таушалып бетте, әмма аны Ниязга алып барып бирүче табылмады. Авыр хәлдә, хастаханә койкасында үлем белән тартышып ятучы Ниязга аның хәлен тагын да кискенләндерер, дипме, әллә башка сәбәпләр беләнме, ул хатны тапшырмадылар...

33

Урман һавасы күкрәкләрне сафландыра, әмма Гөлчирәнең эче тулы әрнеш. Ул әле һаман Ниязның алдавын кичерә алмый, аңлый алмый. Бүлмәдәш кызлары Гөлчирәнең бу хәсрәтен, егетенең килмәвен, вәгъдәсезлеген бердәм булып үз хәсрәтләре кебек кабул иттеләр.

— Гөлчирә, син бик яшь әле. Бер Нияз гына димәгән. Менә дигән егетләр очрар әле.

— Бәлки башканы сөядер, — диде берсе.

— Мин аны моның өчен үлгәндә дә гафу итмәячәкмен, — диде Гөлчирә тирән көрсенеп.

— Бәлки хат язар әле...

— Нәрсә дип акланыр икән?

Галя исемле чуаш кызы Гөлчирә янына килеп утырды, аны җилкәсеннән кочып алды.

— Елама, Гөлчирә, күз яшьләре ярдәм итмәс, нык пул. Мин дә яратып парган ирем пелән мәңгегә аерылдым,— диде.

Ул үзенең язмышын, тарихын берничә сүз белән әйтеп бирде.

— Яшь идем. Алдандым. Авырлы пулдым. Әни үтергәнче кыйнады да әпигә алып барды. Төшерттерде. Аннан... Аннан кияүгә чыктым... Яратып чыктым. Пала пулмады. Санням пер көнне пуып алды да, дөресен әйт, опорт ясаттыңмы? — дип кысты. Түзә алмадым, сөйләдем. Аерды. Миңа кысыр хатын кирәкми, — диде. Авылдан чыгып киттем. Их, капат унҗиде яшемә кайтып пулса, пелер идем, — дип көрсенде Галя.

Кызлар барысы да тын гына Галяны тыңладылар, һәркайсының күңелендә үз язмышы, хәсрәте күзләрендә сөрем булып селкенеп торгандай тоелды.

— Мин, кызлар, моннан китәм, башка участокка күчәм, — диде Гөлчирә. — Сезнең белән иялэшкән, дуслашкан идек. Минем әле тагын бер борчуым бар.

— Нинди борчу тагын?

— Монда мин күрә алмаган, явыз, кара эчле, куркыныч берәү авылдан мине эзләп килгән. Кая барсам, шунда ул, эзәрлекләвенә түзәр хәлем калмады.

— Кем ул, кем?

— Мастер Махиянов Арслангали.

Кызлар барысы да авызларын ачып, беравыздан: «Абау!» — диделәр.

34

Гөлчирә яңа участокта эшли башлагач, леспромхоз идарәсендә җыелыш булды.

Җыелыш шау-шулы үтте. Озакка сузылды. Бертуктаусыз тәмәке тарттылар, залда төтен селкенеп-селкенеп торды. Бер генә таныш йөз дә юк. Барысы ят, күбесе ирләр. Кинәт Гөлчирә үзеннән уң якта берничә кеше аша гына, алгы эскәмиядә таныш йөз күреп алды. Кем соң ул? Кайда күрде ул аны?

Гөлчирә хәтеренең бөтен почмакларын барлап чыкты һәм, ниһаять, моннан бер генә ай чамасы элек тимер юл станциясендә очраклы рәвештә танышкан, үзен Арслангалидән коткарып, Камскигача озата килгән Хәмитне таныды.

Гөлчирәнең сул ягында утыручы ике татар кычкырып-кычкырып сөйләшәләр.

— Әле эшеңне алыштырмадыңмы?

— Юк әле.

— Кара аны, акча күп килә торган җиргә керергә тырыш. Эшләргә эше булсын. Монда безнең братны өнәп бетермиләр, алдыйлар, кысалар. Алдыңны-артыңны карап йөр. Төп башына утыртмасыннар.

Икенчесе сүзсез генә аны тыңлый, башын каккалап куя. Яңа килгән кешедер, ахры.

Тәнәфес игълан иттеләр. Кешеләр тоташ агым булып тышка агылды. Гөлчирә дә саф һавага ашыкты. Тышка чыккач, бер кырыйга барып басты. Шулчак ул, кешеләрне аралап, әллә каян елмаеп, ашыгып аңа таба килүче Хәмитне күрде. Мәрхәмәтле Хәмит, изге күңелле Хәмит абый.

Хәмиткә дә Гөлчирә бик кадерле, бик якын булып тоелды, ул әллә кайчангы танышын очраткан кебек:

— Саумы, Гөлчирә!— дип елмайды.

Яңа гына явып үткән яңгырдан үләннәр юеш иде, җылы пар күтәрелеп, күңелләрне иркәли, агач яфракларыннан төшеп өлгермәгән яңгыр тамчылары сирәк кенә тамып куя.

Хәмиткә Гөлчирә белән сөйләшеп китү бик җиңел булыр сыман иде. Ләкин бер дә алай булмады. Шаярып сөйләшсә, килешмәс, әле кызның күңелендә теге көндә булган күңелсезлекләр җәрәхәт булып сыкрап торадыр кебек, артык җитди сөйләшсә, кыз ничек кабул итәр?

— Җыелышта утырасың бик киләме? — диде Хәмит.

— Юк, — диде Гөлчирә.

— Әйдә, читкәрәк китәбез. Сөйлә, син Дубровкага каян килеп чыктың? Син бит Камскида идең.

Алар яңгырдан соң ялтырап күренгән бер агачка таба атладылар. Сулыш алганың да яңгырап китәр төсле тын урамда кычкырып сөйләшү җиңел түгел иде. Гөлчирә, Хәмит белән янәшә, юешләнгән туфлиләренә карап, башын бер яккарак кыйгайтып атлады да атлады, биргән соравына җавап бирергә ашыкмады. Хәмит үрелеп бер агач ботагын тартып куйды, шыбырдап алар өстенә салкын тамчылар коелды. Гөлчирә көтелмәгән бу салкын тамчылардан нәзек кенә тавыш белән кычкырып куйды һәм матур итеп кеткелдәп көлеп җибәрде. Аның көлүендә әле чәчәк атып кына килүче гүзәл яшьлек авазы яңгырады. Хәмит тагын соравын кабатлады:

— Каян безгә килеп чыктың соң син, Гөлчирә?

— Теге кешедән качып киттем.

Хәмит барысын да аңлады, бу сүзне кабат яңартмады.

— Борылмыйбызмы? Туңмыйсыңмы?

— Юк, туңмыйм, нишләп туңыйм?

Соңгы көннәрдә Гөлчирәнең бәгырен телгәләп күңелендә бер теләк кабынды: аңа әнисе кебек үк якын, ышанырлык бер кеше кирәк икән. Сер сыярлык, күңел җылысын

тоярлык. Аның беркеме дә калмады. Нияз оятсызларча хыянәт итте, алдады, Арслангали куркыныч, ул аның тормышында очраган куркыныч бер кара көч, ул көчле һәм явыз.

Гөлчирә кичләрен Хәмит белән очраша башлады. Хәмит бер дә әрсезләнмәде, кызда ниндидер тирән сагыш, моң-зар, олы кайгы сизеп, рәнҗетүдән курыкты. Кызны күрү белән Хәмитнең күңеле күтәрелә, арыганы онытыла. Тик ул үзе дә еш кына моңсуланып кала, аны күңелсез уйлар биләп ала. Яхшы кыз очрату, аны ярату — бер нәрсә, ә аны бәхетле итә алу-алмау — бөтенләй икенче. Ул бу матур, яшь кызны бәхетле итә алырмы? Кыз аны ярата алырмы? Алар сөю, мәхәббәт турында бөтенләй сөйләшмәделәр. Туган як, туган авыл, ата-ана, дуслар, мәктәп...

Хәмит Казан артындагы бер районның Көтмәс дигән авылыннан икән. Отпускада булып килгән, шуңадыр, Гөлчирәгә гел үзенең туган авылы турында, кызлар, кечке уеннар турында сөйләде. Сагынуын яшермәде. Ул Көтмәснең табигате, урманы, чишмәләренең матурлыгы турында сәгатьләр буе сөйләргә әзер иде... Әти-әнисе колхозчылар, энесе һәм сеңлесе бар икән.

Хәмит кичләрен кызлар яшәгән баракка килә, киң күкрәкле, озын буйлы, бөтен барлыгы белән сәламәтлек, көч бөркеп торган егет — кызлар арасында күп сөйләшми генә, телчән кызларның шаян, төртмәле сүзләренә елмаеп, кызарып бераз утыра да, Гөлчирәгә карап күз кыса. Гөлчирә урамга чыгарга әзерләнә. Кичләр салкынча булганга, ул җылы кофтасын кия. Башына юка капрон яулыгын чөя. Урамга чыккач, Хәмит Гөлчирәне, бармакларын аның җылы тәненә тидерер-тидермәс сак кына биленнән кочаклап ала. Аның кызга бик матур сүзләр әйтәсе, тантаналы итеп аны ратуын белдерәсе килә, ләкин һич кенә дә кирәкле сүзләр таба алмый.

Менә алар бараклар буйлап киттеләр... Әйтер сүзләр генә әллә кайда йөри. Кая соң аның егетләр белән сөйләшкәндәге кыюлыгы? Бераз баргач, Хәмит Гөлчирәне ике куллап кочаклап алды, йөзенә үк якын килеп:

— Гөлчирә, мин сине яратам, — диде һәм суырып иреннәреннән үбеп алды. Гөлчирә дә тартылмады, сүз әйтмәде. Шушы минутта Гөлчирә бу ят, чит җирдә үзенең япа-

ялгыз түгеллегенә ышанды. Бәлки шушы аз сүзле, көчле, үзеннән берничә яшькә олы егет бүген генә түгел, аның иртәгәсе, алдагы еллары өчен бергә тормыш юлы үтәрлек, ышанычлы иң якын кешесе булыр, хыянәт итмәс, алдамас дусты булып чыгар... Кыз егетнең җилкәсенә башын салды...

35

Кызлар тәрәзә аша Арслангалинең баракка якынлашуын күрделәр.

— Кызлар! Арслан килә, Арслан...

— Килсен, килсен, без аны йолкынган әтәч итәрбез.

Арслангали кызлар бүлмәсенә килеп керде, исәнләште, башыннан кепкасын салып, кадакка элеп куйды. Бармак очлары белән генә куе кара чәчен артка сыпырып җибәрде. Кызлар урыннарыннан кузгалмадылар, бары да аңа таба карап, елмаймый-көлми, якты йөз күрсәтми, сүзсез калдылар.

— Ә кая соң минем чибәрем? — диде Арслангали беркемгә дә карамый гына.

— Чибәреңме? Чибәрең сәлам хатлар җибәрәм, дип кайтып китте.

— Кайтып китте?! Аның кайтыр җире юк. Кая кайтсын ул? Өен сатты. Егете ташлады.

— Кызларның дүрт ягы — кыйбла, бәлки берәр күз күргәне булгандыр. Җир йөзендә син генәмени?

— Мин генә. Ул минеке генә... Булырга тиеш.

— Ой-ой-ой! Мактанчык. Мактанчыкның арты ачык. Мин — мастер, дигәч тә...

Кызлар берсеннән-берсе арттырып, Арслангалидән көлделәр.

Ул бүлмәдән саубуллашмый да чыгып китте. Кызларның кайтып китте дигән сүзенә ышанмады, билгеле. Урамда йөрде, клубка кагылды. Гөлчирә беркайда да юк иде. Арслангали бу баш бирмәс Гөлчирәдән үч алырга уйлады.

Күптән түгел кайсыдыр участокта урманда ботак чабуда эшләүче Гөләндәм Ибраһимова исемле кызны агач басып үтергән иде. Аның гәүдәсен туганнары килеп авылына алып

кайтып киттеләр. Озак та үтмәде, урман хуҗалыгында чыга торган аз тиражлы «Лесоруб» гәҗитендә бер мәкалә басылды.

Мәкаләдә урман хуҗалыгы җитәкчеләре, мастерлар гаепләнеп, аларга каршы җинаять эше кузгатылу турында язылган иде. «Г.Ибраһимованың фаҗигале үлемендә мастер И.Шмарев һәм К.Саянов гаепле» дип язылган иде.

Арслангали бу мәкаләне кисеп алды да, Гөлчирә урманда агачка басылып үлде, дип авылга хат язды. Хат янына шушы мәкаләне дә тыгып җибәрде. Айлар буе шушы хәбәр авыл халкының теленнән төшмәде. Ә Ниязның әнисе Гөлмәрьям хастаханәдә ятучы улына бу хәбәрне хат аша җибәрми булдыра алмады.

«Улым, — дип язды ул, — авыр булса да язам, язмый булдыра алмыйм. Гөлчирә, мескенем, агачка басылып үлгән икән бит. Гәҗиттә хәбәре дә килде, авыл халкы бик кызганды. Кешеләр телендә гел Гөлчирә. Туганнары бар дигән иде, шунда гына җирләгәннәрдер инде...»

36

Әнисеннән килгән бу кара хәбәр Ниязга аяз көнне яшен суккан кебек тәэсир итте, кулларын пешерде. Хатны ул кабат укырга теләмәде, ертып атты һәм гомерендә беренче тапкыр үксеп-үксеп елады. Авариягә эләккәч, ул Гөлчирәгә хатлар язды, килә алмавы өчен гафу үтенде, ләкин Гөлчирәдән җавап хаты булмады. Сәбәбе — шул һәлакәт икән, дип уйлады.

Нияз көн саен Гөлчирәне төшләрендә күрә. Гөлчирә, мәктәптә укыган вакыттагы кебек, аңа карап елмая. Кызның шомырт кара күзләрен ул аерым-ачык күрә. Ә ул күзләр әллә кайчан йомылганнар, әллә кайчан аның Гөлчирәсе җир куенында ята икән.

Ул, уйланып ята торгач, Гөлчирәсенә багышлап шигырь дә чыгарды:

«Ялгыз каен... Ялгыз каен яннары Яшел чирәм. Сине мәңгегә югалттым. Мин гаепле, Гөлчирәм...»

Ниязның бу көннәрдә хәле бик авырайды, күзләрен томан каплады, тәрәзәләр дә кечерәеп, нидер элеп куйгандай булып калдылар. Палатада ятучылар да аның авыр хәлен

аңлап, артыгын сорашмадылар, ярасын яңартмадылар.

— Авылга кайтам, Гөлчирәм белән йөргән сукмакларда йөрү өчен авылга кайтам, дип уйлап ятты Нияз...

37

Җәй иртәсеннән дә матуррак вакыт бар микән? Үлән өстендә чык тамчылары ялтырый. Урман эченнән җиләс һава бөркелә. Куакларда бертуктаусыз кошлар чыркылдаша, көнне сәламли.

Хәмит бу көнне бик иртә уянды. Барактан чыгып, мускулларын уйнатып, гимнастика ясады, берничә мәртәбә баракны йөгереп әйләнеп чыкты.

Сүз кибәк түгел, җилгә очырып булмый, дип уйлады егет: Гөлчирә белән кушылырга. Кыз каршы түгел, тагын ни кирәк? Чибәр, уйчан, тыйнак, кирәк чакта кыю, чая. Сузарга ярамый.

Бераз тәнен язгач, ул барак янында җайланган юынгыч янына килде, кушучлап битенә салкын су сипте, биленә бәйләнгән иске сөлге белән муенын, беләкләрен ышкыды.

Башка егетләр дә чыктылар, көлешә-көлешә йөгерешеп алдылар.

— Ник иртә тордың? Әллә бер-бер хәл булдымы?

— Юыныгыз, егетләр.

Хәмит сүзне башкага борды. Алдан кычкырган күкенең башы авырта, егетләргә Гөлчирә белән корган планнар турында ул бер сүз дә әйтмәде.

Иртәнге ашны ашап, Хәмит тракторын кабызды һәм урманга таба юл алды.

Бер дә көн бозылыр, яңгыр булыр төсле түгел иде, кинәт кенә урман артыннан кара болыт килеп чыкты, үсте, киңәйде һәм ярты күкне биләп алды. Җирне-күкне тоташтырып, яшен яшьнәде һәм җир селкетеп, күк күкрәде.

Хәмит, шуңа да карамастан, эшкә керешге. Яшен дип, яңгыр дип тормады. Үзе авылда үткән балачагын исенә төшерде. Яңгырны ул кечкенәдән ярата. Урамда яңгыр явып күлләвекләрдә тамчылардан куыклар кабара башлау белән ялантәпи урамга йөгереп чыга да, шул куыкларга баса-баса: «Яңгыркаем, яу, яу, майлы ботка бирермен!» — дип такмаклый. Менә бүген дә егерме алты яшьлек егетнең,

балачактагы кебек, яңгыр астында шәбәрәсе, юеш үләндә чабулыйсы килеп китте. Аның куанычы эченә сыймый, җырлыйсы, шаярасы килә.

Тиз башланган яңгыр озакламый туктады. Урман юлы буйлап балта, пычкылар тоткан эшчеләр килгәне күренде.

Әнә кызлар белән көлешә-көлешә аның Гөлчирәсе атлый. Зәңгәр комбинизоны да, ак яулыгы да шундый килешә, ул гүя урман кисәргә, ботак чабарга бармый, танцыга ашыга. Гөлчирә аны күреп елмайды. Хәмиткә ничектер ул: «Нихәл, кияү егете!» — дия төсле тоелды. Гөлчирә түбән карап, юеш үләнне таптап трактор яныннан салмак кына атлап үтеп китте.

Алар бу атнаның шимбәсендә язылышырга барачаклар. Туйлар ясап түгел, бик гади генә, тыйнак кына, дуслар белән утырачаклар. Хәмит урман хуҗалыгыннан аерым бүлмә сораячак. Алар шулай килештеләр.

38

Нияз өч ай хастаханә койкасында аунап, терелеп, аякка басты.

Монда көн тудымы — авариягә эләгеп кулы сынган, аягы өзелгән, башы ярылган шахта эшчеләре. Кемнәр белән генә сөйләшмәде, аралашмады Нияз.

Менә аягы бот төбеннән өзелгән Касыйм исемле урта яшьләрдәге абый. Ул Нияз белән еш кына сөйләшә:

— Минем әти дә, әни дә шахтерлар иде,—дип башлады ул беркөнне сүзен. — Үзем унике ел шахтер булдым. Бик авыр, хәвефле эш. Ничәмә-ничә кешенең гомере өзелде монда. Мин үзем унике ел буе сменага чыгып киткән саен балаларымны, хатынымны кочаклап үбеп, кайтмасам, бәхил булыгыз, дип китә торган идем. Ходай гомерне алмады — алуын, ну аяксыз калдым. Бер аяк белән яшәргә туры киләчәк.

— Галимҗан абый шахтада гомер буе эшләп, карт атасын калдырып китеп барды, — диде Нияз авыр көрсенеп.

— Терелеп чыксаң, шахта эшенә кайтырга уйлыйсыңмы соң, Нияз? — диде Касыйм.

— Ике аягымның берсен дә атламыйм, терелим генә! Авылыма кайтып китәм.

— Авылны сагындым, дисең инде син?

— Әйе, авылымны бик сагындым. Әни ялгыз минем, безне ялгыз үстерде. Мин авыл өчен яратылган, иген үстерәчәкмен. Агроном буласым килә минем.

— Әниеңә акча җибәрә алдыңмы соң?

— Ай саен сала идем. Мин әни алдында зур бурычлы.

— Менә бит, кемгә нәрсә... Син авылыңны оныта алмыйсың, ә миңа шахта якын. Минем туган җирем шушы.

Нияз авылда озак тормады.

Сагынып кайтты, әмма авылның су буйларында, урманнарында була алмады. Шулай да, Гөлчирә белән килә торган ялгыз каен янына бармый булдыра алмады. Каенның кәүсәсен сыйпады, кара гөмбә һаман да урынында икән. Ялгыз каен Ниязга ничектер бик моңсу булып күренде. Инде монда башкалар килмидер, тирә-ягы яшел чирәм, тапталмаган. Нияз үзе дә сизмәстән, Гөлчирәгә багышланган шигырен җыр итеп җырлап җибәрде:

Ялгыз каен... Ялгыз каен яннары
Яшел чирәм.
Сине мәңгегә югалттым,
Мин гаепле, Гөлчирәм...

Җыр туды, моңлы яңа җыр туды. Ул аны өйгә кайту белән гармунында уйнап җырлап утырды:

Ялгыз каен һаман шулай —
Тирә-ягы гел чирәм.
Вәгъдә бирешкән көннәрне
Оныталмам, Гөлчирәм...

Ике көннән Нияз Казанга имтиханнар тапшырырга китте.

39

Гаиләнең үзәге — ир, өйнең яме — хатын. Хәмит белән Гөлчирә матур гына гаилә корып җибәрделәр. Кечкенә булса да, тәрәзәләре белән кояшка карап торган барак бүлмәсе алар өчен изге оҗмах булып тоелды. Иртән йокыдан уянуларына тәрәзәдән бөркелеп кояш нурлары керде, җилләр искәндә агачлар шаулавы, кошлар сайравы аларның күңелен күтәрде, гүя алар өчен генә табигать концерт куя, җыр җырлый. Күңелләре күтәренке, кәефләре шәп иде. Эшләре әйбәт

барды, авыр булса да, арытмады, ялкытмады. Дуслары күбәйде. Алар үзләрен табигатьнең бер кисәге, бәхет өчен яратылган җаннар итеп хис иттеләр.

Икесенең дә хисләре, кичерешләре тәңгәл, һәр сулышы, һәр күзәнәге — табигать биргән байлык. Тормышларында тулы гармония, бердәмлек, үзара аңлашып яшәү бәхет китерде.

Бу — беренче елны да, икенче елны да шулай булды. Әмма өченче елда инде алар яшәү яме балада икәнен аңлап, бәхетнең бер ягы китек икәнен сизә башладылар. Өч ел яшәп, балалары юк. Хәмит еш кына эчә башлады, көйсезләнде. Гаиләдә эчкән ир булуның олы бәхетсезлек икәнен Гөлчирә үз җилкәсендә татыды. Менә шулай матур башланган гаилә тормышы һәр икесе өчен аңлаешсыз газапка әйләнде.

...Хәмит көч-хәл белән барак янына кайтып җитте. Барак почмагына таянып, селкенгәләп бераз басып торды да, авырткан башын болгап алып, җиргә таба иелде, коса башлады.

Гөлчирә, аны күреп, йөгереп чыкты.

— Әйдә өйгә, Хәмит, әйдә, әйдә!

— Хатын!

Аягы белән җиргә тибүе булды, Хәмит кыйгаеп, яны белән барып төште.

— Әй, Ходаем! Пычранып бетәсең бит! Әйдә инде өйгә, кеше көлдермә, — дип Гөлчирә Хәмиткә торып басарга ярдәм итте.

Хәмит аякларына баса алмады, тезләнгән килеш Гөлчирәнең аякларын кочаклап елый башлады.

— Мин болай яши алмыйм, барыбер асылынып үләм, Гөлчирә! Кит син миннән, мин сине бәхетле итә алмадым, — дип үкерде исерек ир.

— Хәмит, дим, әйдә кеше көлдермә, әйдә, җаным, кер өйгә, исергәнсең, ни сөйләгәнеңне үзең белмисең...

— Беләм, бик беләм мин ни сөйләгәнемне. Бүген үк китәр идем тегендә. Сине җәллим, Гөлчирәм!

Хәмит торып баса алмый азапланды. Гөлчирә иренең олы гәүдәсен ничек кенә тырышса да, күтәрә алмады.

Ул арада, бераз салып алган ике кеше килеп, Хәмиткә басарга ярдәм иттеләр.

— Бирешмә, Хәмит, аягыңда нык тор! — диде берсе. — Без әле синең белән дөнья җимертеп эшлисе кешеләр.

Хәмит, аягына баскач, теге ирләр белән кочаклашып, бер урында аякларын тыпырдатып, биегән булып кыланды.

Тегеләр үз юлларын дәвам иттеләр. Ә Хәмит, чайкалып китеп, Гөлчирәнең җилкәсенә барып асылынды.

— Әйдә, әйдә, атла, Хәмит.

Хәмит авыз эченнән нидер мыгырданып, ниһаять, барак эченә атлады.

Гөлчирә Хәмитне сабый бала кебек хәйләли-хәйләли күлмәк-ыштаннарын салдырып, чиста кием кидертеп, урынга яткырды. Җылы урынга яткач, Хәмит, үкереп-үкереп, елап җибәрде.

Гөлчирә су җылытып Хәмитнең пычрак киемнәрен юып элде. Үзенең күзләреннән бертуктаусыз яшь акты:

— Кая соң ул — миңа дигән бәхет? Инде таптым дигәч, булмады, бәхет түгел, бәхетсезлек бит бу. Болай ничек яшәргә кирәк?

Хәмит айныгач, ул бик җитди итеп Пермьгә барып табибларга күренергә кирәклеге турында сөйләшергә булды. Ярдәм итәрләр, дәваларлар...

40

Казан урамында Нияз бер төркем кызлар арасында Сәримәне танып алды. Ул? Нишли ул монда?

Сәримә дә аны күрде, үзе комачтай кызарды һәм ничектер каушап калгандай булды, кызлар белән карашып алды да, шул минутта әрсезлеген җиеп, Ниязга таба атлады. Аңа кулын сузды:

— Исәнме? — диде.

— Бу минем авылдаш, — диде кызларга.

Нияз теләр-теләмәс кенә аның сузган кулын кысты. Ләкин текә күкрәкле, шәһәрчә киенгән, хатыннарча тупасланган бу кызда ул элекке Сәримәне күрмәде. Ул бик нык үзгәргән: киеме дә, прическасы да, хәтта гәүдәсе дә. Ул элеккедән озынрак та, калынрак та.

Сәримә үзеннән-үзе бик канәгать булды: Нияз аңа кызыгып, хәтта сокланып карый дип уйлады. Бер мизгелгә аларның күзләре очрашты. Ә менә кызның туп-туры сөзеп карый торган күзләре — гел элекке Сәриманеке иде.

— Ник туктап торабыз. Әйдә безнең белән.

Сәримә Ниязны култыклап алды. Кызлар шаркылдап көлеп җибәрделәр.

Нияз Сәримә турында берни дә белми иде. Ул хәзер Казанда пединститутта укый икән. Алар барысы бергә Сәримә яши торган тулай торакка керделәр.

— Чәй эчәбезме?

— Юк.

— Бездә шундый гадәт: эчәм дисәң, эчерәбез, эчмим, дисең икән — кыстамыйбыз.

Кызлар тагын көлештеләр.

— Мин озакка кермәдем, күреп кенә чыгыйм, дидем.

Нияз урыныннан торып ишеккә таба юнәлде.

— Мин синең белән,—диде Сәримә.

Алар урам буйлап озак кына сөйләшеп бардылар. Урам тулы халык, этә-төртә йөгереп үтәләр, каядыр ашыгалар. Сәримә, никтер, авызына су капкандай, иреннәрен кыскан.

Нияз беренче булып сүз башлады:

— Син чын шәһәр кызы булгансың, карале, сиңа бик күпләр күз төшерәләр.

— Алар сиңа карыйлар, — диде Сәримә.

— Нишләп миңа?

— Авыл кешесе монда әллә каян күзгә ташлана.

Нияз Сәримәнең үкчәле туфлиләре белән керт-керт атлавына туры китереп вак атларга тырышмады. Эре-эре атлап барды. Алар гүя бергә түгел, ә аерым-аерым каядыр атлыйлар.

— Ә син монда нигә килдең?

— Мин авыл хуҗалыгы институтында укыйм.

— Ә-ә, — Сәримә иреннәрен генә кыйгайтып мәсхәрәле елмаеп куйды.

— Әйдә, бу бакчага кереп утырыйк.

Алар бер бакчага кереп, эскәмиягә утырдылар. Монда Сәримә ничектер авыл кызлары кебек гадирәк булып калды.

— Менә без дә үсеп җиттек, акыл утырттык, — диде Нияз ни әйтергә, нәрсә турында сөйләшергә белмичә.

Сәримә көлеп җибәрде.

— Укытучы булып авылга кайтырсың инде.

— Белмим әле.

— Нәрсәсен беләсең аның? Авылда укытучылар кирәк, көтә торганнардыр.

Сәримә иреннәрен тешләде, туфли үкчәләре белән саргайган каен яфракларын изгәләде, йөзендә уйчанлык сирпелеп алды.

— Минем монда бер таныш лейтенантым бар. Кияүгә сорый... Ничек уйлыйсың, чыгыйммы?

— Чык...

41

Табиб күзлек өстеннән генә ишектә күренгән таза, чибәр егеткә күз салды. Бер дә авыру кешегә охшамаган, нинди хәсрәт китергән аны монда, дип уйлап алды.

Гөлчирә табибларда булды. Бары да яхшы, бала табачаксыз, бернинди дә патология юк, диделәр. Гөлчирә табиб бүлмәсеннән куанып чыкты, киләчәк көнгә зур өметләр туды. Ул ана булачак! Бары да яхшы!

Хәмиткә табиб белән сөйләшү җиңел булмады. Эшнең нидәлеген аңлаткач, табиб аңа бик күп сорау бирде.

— Күп эчәсеңме? Тартасыңмы?

— Бераз була инде.

— Агуланганың юкмы?

— Юк, бервакытта да агуланганым исемдә юк.

— Кайда хезмәт иттең? Нинди частьта? Менә шушы сорау Хәмитне айнытып җибәргәндәй итте.

— Тоцкий полигонында. Оренбург өлкәсендә, — диде Хәмит.

Сорашу-тикшерүләрдән соң, анализлар ачыклангач, табиб бик тыныч булырга тырышып:

— Хатыныгызны чакырыгыз! — диде.

Гөлчирә кереп Хәмит янына утырды.

Табиб бик күп сөйләде, күп сүзләре аларга аңлашылмады. Радиация, диде, ионнар, гамма, диде.

Ләкин Хәмит тә, Гөлчирә дә табибның сүзләрен ишетмиләр иде, алар ул сүзләрне ишетер дә, аңлар да хәлдә түгел иде. Һәм, ниһаять, табиб тирән сулыш алып, йомгаклап куйды:

— Аяныч, бик аяныч, сезне тынычландырыр сүз әйтә алмыйм. Балагыз булмаячак, кадерлеләрем, — диде аларга туры карамыйча гына.

Хәмит тетрәнеп куйды. Гөлчирәнең күзләреннән өзлексез яшь коелды.

Ир белән хатын утырган җирләреннән торып, әкрен генә ишеккә юнәлделәр. Табиб, башын күтәреп, алар артыннан карап калды. Алар аңа бик нык кечерәеп калган сыман тоелдылар. Кеше бит кояшка үрмәләгән агачтай үсәргә, өскә үрләргә омтыла. Ә болар көчсезлектән, гаҗизлектән, үткән гомерләре, язмышлары өчен күңелләрендә ургып торган рәнҗүдән бөкшәеп, бөрешеп калганнар иде...

42

Алар балалар йортыннан тәрбиягә бала алырга булдылар.

Балалар йорты. Киң генә бүлмә. Түрдә зур-зур өч тәрәзә. Идәндә түсе уңа башлаган зур палас. Палас өстендә кайсы утырган, кайсы мүкәләп йөрүче балалар уен белән мәш киләләр.

Балалар йорты хуҗасы Хәмит белән Гөлчирәне кисәтеп куйды: «Берсен дә кулыгызга алмагыз». Тик монда килеп керүгә аларга төбәлгән нәни күзләр аларны битараф калдыра алмады. Әнә берсе зәп-зәңгәр зур күзләрен мөлдерәмә тутырып карап тора, әнә икенчесе утырган урыныннан сикереп торып, кулын сузып алар янына ук килеп басты, әнә өченчесе «мама! папа!» дип елап ук җибәрде. Гөлчирә үзенә таба сузылган бу сөякчел ябык кулга сузылмый булдыра алмады.

— Син минем әниемме? — диде күбәләктәй очып аның янына килеп баскан кызчык. — Син мине алырга килдеңме?

Гөлчирәнең сузылган кулына сабый чытырдап ябышты да, аякларын күтәргәләп, кулга алуын үтенде.

— Йә, ярый, Лена! Синең хәлеңне белешергә килгән апа бу. Ә әниең башка көнне килер.

Ул арада җиде-сигез бала Гөлчирә белән Хәмитне урап алдылар.

— Минем әниемме син?

— Син минем әниемме?

Балаларның һәркайсы аларны үз әнисе, үз әтисе итәргә теләде.

— Мине дә күтәр әле, — диде Хәмит янында бөтерелгән сары чәчле малай.

— Ә мине! Ә мине! — дип үрсәләнә башладылар балалар.

Телләре яңа ачылып килә торган бу сабыйлар язмышларының ачылыгын бөтен тулылыгы белән аңлап бетермәсәләр дә, әти-әни назыннан мәхрүм икәнлекләрен сизеналәр иде бугай. Илереп-илереп бу ят апа белән абыйга карап торганнан соң, бер-икесе инде кабат үз урыннарына барып утырдылар һәм нәүмизләнеп уенчыклары белән уйный ук башладылар.

Гөлчирә белән Хәмиткә балалар йортыннан бала алу өчен бик күп кәгазьләр тутырырга, раслатырга туры килде, шулай да, алар зур түземлелек белән ул кәгазьләрне тутырып, зәп-зәңгәр күзле, өч яшьлек бер нәни малайны үзләренә балалыкка алдылар. Арада иң ошаганы шул булды. Хәмит кебек үк зәңгәр күзле, коңгырт-сары чәчле бу малай — Саша Якушев иде. Хәмит баланың документларын алды, Александр Якушев — Атлас Якупов булыр, дип уйлады. Бик матур чагы, теле ачылып бетә язган. Бала шатлыклы күзләрен ялтыратып Гөлчирә белән Хәмитне йөгереп килеп икесен берьюлы кочаклап алды да әле берсенә, әле икенчесенә карап:

— Папа! Мама! — дип кычкырды.

Алар өендә моңарчы булмаган, булганы да сүнә барган җылылык, яктылык, нур артты. Гөлчирә баласы булган көннән эшкә чыкмады, расчет алды. Хәмит тә:

— Эшләмәссең, баланы кеше итеп үстерергә кирәк,— диде.

Эштән кайту белән Хәмит улын кулына алып:

— Әти, диген, әти, диген, әти, әти,—дип аның белән әңгәмә кора.

Бала:

— Әти, әни,—диде.

Урыс һәм татар сүзләрен буташтырып, сөйләшеп аларны куандырды...

43

Гөлчирә белән Хәмитнең бәхетле көннәре озакка бармады. Хәмит көн дә эштән хәлсезләнеп кайтып егыла, күзгә күренеп сула барды. Ашаган азыгының тәмен тоймый, ашаганы үтми, коры сөяккә калды, күзләре начар күрә башлады.

Табиблар радиация галәмәте, нурланыш чире, диделәр, катаракта дигән диагноз куйдылар.

Озакламый аның буыннары шеште, аяклары йөрмәс булды.

Табиблар Подольск шәһәрендәге фәнни-тикшерену институтына юллама бирделәр. Гөлчирә улы Атлас белән Хәмит янына Подольскига күчеп килде. Фатир табып, тегү фабрикасына эшкә урнашты. Көн саен Хәмит янына йөрде.

— Саумы, Хәмит!

— Саумы, Гөлчирә.

Хәмитнең зураеп калган сукыр күзләрендә җан өшеткеч томан. Атлас, әтисенең кулын тотып, аларның сөйләшүен тыңлап утыра. Хәмит бертуктаусыз улының чәчләреннән сыйпый.

— Син мине, Гөлчирә, гафу ит инде. Мин сине бәхетле итә алмадым...

— Мин бик бәхетле синең белән, Хәмит. Бу уйларыңны оныт, минем өчен борчылма. Сина терелү кирәк, терел генә...

— Күпме җәфалар күрдең син минем белән, Гөлчирә! Күпме хурлыклар. Ни кадәр түземлек, сабырлык кирәк иде сиңа! Мин синең язмышыңны харап иттем.

— Юкны, сөйләмә, Хәмит! Без синең белән әле матур итеп яшәрбез, — дип юата Гөлчирә, үзенең күзләреннән чишмә булып яшь ага.

Ул көнне Хәмит көн уртасына кадәр һушында иде, кулын Гөлчирәгә суздылда хырылдый башлады һәм тынсыз калды.

— Хәмит! Хәмит! Ни булды сиңа? Үлмә! Үлмә!..

44

Гөлчирә белән Атлас зираттан соң гына кайттылар. Тәрәзәгә кояшның алтын нурлары төшкән, бүлмә эчендә барлык нәрсә кызгылт булып күренә. Гөлчирә бүген ятимлек һәм ялгызлыкның чын мәгънәсен аңлады. Ул улы Атласны кочаклап алды һәм күкрәгенә кысты. Шулай кочаклашып алар озак кына утырдылар.

Гөлчирә соңгы өч ай вакытны күз алдына китерде. Өч ай элек ул Хәмитне бу институтка озата килгән иде. Ак халатлы табиб аның күңеленә өмет чаткылары кабызган

иде. Бәлки табиб нидер эшләп җиткермәгәндер, ниндидер кыйммәтле дару табылмагандыр. Ул аны, бәлки, юри генә юаткандыр, чөнки Гөлчирә белән сөйләшкәндә аның аскы ирене калтырап-калтырап ала иде.

Гөлчирә хастаханәгә килгән саен аңа шикәр кебек ап-ак халат бирәләр иде. Хәмит аны күргәч, күгәргән ираннәре белән елмая, кулларында кан тамырлары зәп-зәңгәр, бармаклары нечкә, йөзе балавыз кебек сап-сары иде.

— Син шәфкать туташы булсаң, мин күптән терелгән булыр идем, — дип шаярта Хәмит.

— Терелерсең, болай да терелерсең, — ди Гөлчирә.

Ә Хәмит кайнар, коры иреннәре белән аның яңагыннан үбеп ала. Гөлчирә аны китәр алдыннан үбә:

— Сау бул, иртәгә мин килгәндә терелгән бул, — дип елмая.

Хәмит аларны тәрәзәдән карап озатып кала.

Инде хәзер Гөлчирә зиратка йөри, көн дә бара, Атласны җитәкләп бара.

Бүген дә алар Хәмитнең кабере янына килделәр. Озак басып тордылар. Зират өстендә зур тилгән әйләнә, канатларын селкетми, гүя ул очмый, ә тын гына канат җәеп су өстендә йөзә. Ә җир астында Хәмит ята. Гөлчирә аны күз алдына китерергә тырыша.

...Алар кояш түбәнәйгәч кайтырга кузгалдылар.

— Хуш, Хәмит, без киттек, — ди Гөлчирә.

— Хуш, әти, без киттек, — дип кабатлый Атлас.

Алга таба ничек яшәргә? Авылга кайтыр иде, өе юк, элекке эшенә урманга кайтырга теләмәде. Гөлчирә шушы Подольскида яшәргә калды. Монда Хәмитнең кабере, аны да ялгыз калдыру ярамас. Эше дә авыр түгел, хатын-кыз эше. Тора-бара, бәлки, улы белән икесенә фатир бирерләр.

Атласны йокларга салгач, Гөлчирә тәрәзә янына килде, утырды, ике кулы белән яңакларын учлап, шәһәргә күз салды. Төн караңгы, шәһәр урамнарында утлар, еракта зур заводлар, кайдадыр паровоз сызгырта.

Шулай уйга талып утырганда, ул үзенең җилкәсенә улының кулы кагылганын тойды һәм колак янында аның пышылдаганын ишетте:

— Әни, әни!

— Нәрсә, улым, ник йокламыйсың?

Гөлчирә аны кочаклап алды, тезләренә утыртты. Улының ябык гәүдәсе бүген бигрәк тә җиңел кебек тоелды.

— Әни, син мине кире балалар йортына илтеп бирмисеңме?

Гөлчирә соңгы көннәрдә, кайгысына күнегә барып, еламый башлаган иде. Улының сүзләрен ишеткәч, түзмәде, үксеп елап җибәрде. Баланын да олы кайгысы бар икән бит! Балалар йортына кире бирмәссеңме, ди. Гөлчирә яшьләрен тиз генә сөртеп алды һәм якты елмаеп:

— Юк, улым, мин сине беркемгә дә бирмим. Син бит минем бердәнбер юанычым, — диде һәм Атласны тагын да ныграк кочаклады, чәчләреннән үбеп алды. — Аңлыйсыңмы, балам, минем синнән башка беркемем дә юк...

— Минем дә беркемем юк, әни, — дип пышылдады сабый һәм борылып Гөлчирәнең муенына сарылды. Ул да елый иде.

Гөлчирәгә һәр тиенне санап тотарга туры килде, фатирга түлисе, Атлас өчен балалар бакчасына. Әмма Гөлчирә акча дип тормады, Хәмитнең кечкенә сурәтеннән зур гына портрет ясатты. Портрет бик матур чыкты. Хәмитнең солдатта хезмәт иткән чагы, күзләре шаян ялтырыйлар, иреннәрендә елмаю, гүя ул үлмәгән, менә шушы рәсемнән чыгып, алар белән сөйләшә, көлешә башлар сыман. Портретны Гөлчирә караватъ янына, стенага элде. Тар бүлмә киңәеп, яктырып киткәндәй булды. Тора-бара ачы кайгы бераз чигенә башлады.

45

Нияз институтның өченче курсында укый иде. Институттан бик арып, хәлдән таеп кайтып керде. Тулай торак бүлмәсенең ишеген ачып керү белән ишектә кемдер күренде.

— Һәй, кайсыгыз анда зачет биреп кайтты?

Бу күрше бүлмәдән Ниязның курсташы Илгиз иде.

— Мин, — диде Нияз. — Мин агрономиядән зачет бирдем. Имтиханнарны алдан биреп, кайтып китәргә җыенам.

— Синнән булыр! Син бит төн йокламыйсың, китап кимерәсең. Күз яшьләре түгеп, Нияз, Нияз, дип авыз суы корытучы кызларны да күрмисең. Авылда сөйгәнең көтәдер. Укытучымы? Табибәме?

— Бәйләнмә әле, Илгиз, беркемем дә юк минем.

— Йә, йә! Алдашма, ышаныр, дисеңме?

— Миңа дигән фәрештәдәй кыз, мине ялгыз калдырып, кара гүрдә ята.

— Ничек, ничек? Кара гүрдә?

— Әйе!

— Башкалары сине сагынып көтеп, тезелешеп торалардыр әле.

— Җитте, Илгиз, башым авыртып тора.

Нияз караватына ауды, башы әйләнгәндәй булды, әллә Илгиз белән бу тузга язмаган сөйләшүдән, әллә арудан аның күз аллары караңгыланып китте.

Ул арада шау-гөр килеп бүлмәдә яшәүче егетләр кайтып керде. Берсен-берсе уздыра-уздыра урамда, институтта булган вак-төяк хәлләр турында зурдан кубып сөйләшә башладылар. Яшьләр, яшелләр, тормышның каймагын гына җыярга өйрәнгән кавем, дип уйлады Нияз, аларның сүзләрен тыңламады. Урамга чыгып йөреп керергә уйласа да, ул уеннан кире кайтты, башы әйләнде, күзен ниндидер кара пәрдә каплагандай тоелды.

Ул төне буе саташып йоклады. Забойга төшкән, имеш, кап-караңгы, маңгаендагы лампасы сүнгән, әллә каян тычкан күзе кебек кенә ут сирпелә. Караңгылык эченнән Гөлчирә килеп чыга. Ул, Ниязга үпкәле караш ташлап, алдадың, оныттың, ә мин сине көткән идем. Ник килмәдең? Ник килмәдең? — дип кычкыра.

Нияз бастырылып уянып китте, башы чатнап ярыла. Ул күзләрен ачты, тәрәзәдән сирпелеп кергән якты аның күзләрен авырттыра. Нәрсә соң бу? Новосибирскида табиблар: «Егет, терелдең — терелүен, әмма сак булу кирәк, бигрәк тә күзләреңә көч китермә, сукыраюың бар. Баш мие травмасы белән шаярырга ярамый», — дигәннәр иде. Әллә башланамы? Әллә чыннан да көч китердемме, дип уйлады Нияз.

Торып басмакчы булды, башы әйләнеп, ава ук башлады, күз алды караңгыланды. Ул маңгаена кулын куйды, температурасы юк. Нәрсә соң бу?

— Егетләр, торыгыз, зинһар, миңа әллә нәрсә булды, — диде Нияз егетләргә.

Шул арада аның караваты янына егетләр килеп бастылар.

— Нәрсә булды, Нияз? Нәрсә булды?

— Бер күзем бөтенләй күрми, башым әйләнә.

— Дамир, бар «ашыгыч ярдәм» чакыр, — диде Хәлим исемле егет.

Берничә минуттан «ашыгыч ярдәм» машинасы Ниязны хастаханәгә алып китте.

Бетте, очты, юкка чыкты бөтен планнар, дип уйлады Нияз. Ник соң бу дөнья гел аңа кире? Ник аның тормышы алдында сынаулар килеп баса? Ник гел үтеп чыкмаслык киртәләр?

Ниязны берничә көннән Мәскәүдәге Н.Н.Бурденко исемендәге нейрохирургия үзәгенә озаттылар.

Анда Ниязның баш миенә бик катлаулы операция ясадылар.

Июнь аенда Ниязны Мәскәү өлкәсенең Подольск шәһәрендәге фәнни-тикшерену институтына күчерделәр.

46

— Якупова! Сине телефонга!

Гөлчирә нәрсә уйларга да белми телефонга йөгерде. — Кем бу? — Якупова кирәк. — Мин тыңлыйм.

— Тиз генә балалар бакчасына килеп җитегез. Улыгыз авырый.

— Нәрсә булган?

Гөлчирә балалар бакчасына йөгереп килеп җитте. Атлас йокы бүлмәсендә караватта чалкан ята. Күзләре йомык. Кечкенә ябык бите сулган, карарга кызганыч.

— Ни булды минем балама? «Ашыгыч ярдәм» чакырдыгызмы?

Ул арада ак халатлы шәфкать туташы килеп керде. Ашыкмады, кабаланмады.

— Нәрсә булды балага?

Тәрбияче, ике кулының бармакларын бер-берсенә аралаштырып күкрәгенә куеп, сөйли башлады:

— Иртән берни дә юк иде, көндезгә таба битләре кыпкызыл булды, үлчим — температурасы утыз сигездән артык.

— Чәй калагы бирегез!

Шәфкать туташы Атласның авызын җай гына ачып, тамак төбен карады һәм башын селкеп:

— Балада дифтерия, хастаханәгә озатыгыз, — диде.

— Мин анда бармыйм, — дип ыңгырашты Атлас.

— Без анда сине тиз генә терелтәбез. Бер атна дигәндә йөгереп йөрерсең, — диде шәфкать туташы аңа бик ягымлы итеп.

— Кирәкми, мин анда бармыйм. Минем әтием дә хастаханәдә үлде, минем үләсем килми.

— Улым, алай карышма, табиблар сине бик тиз терелтерләр, әйдә, үзем озата барам, — дип пышылдады Гөлчирә.

Атласны фәнни-тикшеренү институтының балалар бүлегенә салдылар.

47

Нияз, хәле җиңеләйгәч, көн дә төшке аштан соң хастаханә аллеясындагы бер эскәмиягә чыгып утыра торган булды. Мондагы юкә агачлары исе аңа зур ләззәт бирә, күзләре күрсә, ул бакчадагы матурлык белән хозурланыр иде. Шулай да, юкә исеннән ул исереп киткәндәй була. Җәйге талгын җилдә яфраклар шыбырдашуын тыңлап утыра. Кинәт аның борынына каен яфрагы исе килеп киткәндәй булды, каен да бардыр, ахры, монда, дип уйлады Нияз.

Аның янына фәнни-тикшеренү институтының баш табибы профессор Рәшит Гәрәевич Сабиров килеп туктады.

— Сез монда көн да чыгасыз бугай, — диде профессор, һәм Нияз янына утырды.

Профессор Нияз белән аның монда күчерелүенең беренче көненнән үк танышты. Татар егете, нинди җилләр монда ташлаган? Кем ул? Барысын да сораштырды. Нияз барын да яшерми сөйләде. Гөлчирә турында да, шахтер булуы, авыл хуҗалыгы институтында укуын да. Ә профессор үзе турында сөйләде.

Сабиров Татарстанның бер районында туган, Казан медицина институтын тәмамлап, Әлмәттә хастаханәдә эшләгән, аннан соң ординатураны Мәскәүдә үтеп, галим дәрәҗәсенә күтәрелгән. Җаны һәм рухы белән татар булып калган. Татарстаннан татар телендә гәҗит-журналлар алдыра, халыкның тормышы, язмышы өчен янып-көеп, уңышларына сөенеп яши. Бер ел элек сөйгән хатыны каты авырудан вафат булган.

Профессор саф татарча сүз башлады:

— Үзебезнең тәмле, матур телебездә сөйләшик әле, Нияз, — диде.

— Яман хәбәр әйтергә җыенмыйсыздыр бит, — диде Нияз хафалана төшеп.

— Мине синең үзеңне нык тотуың сокландыра. Көчле рух — ул кешенең канаты. Шул рухи канат булганда, кеше бөтен авырлыкларны җиңеп чыга. Кайгы-хәсрәткә дә, авыруларга да баш бирми.

— Бераз баш авыртып тора.

— Баш авыртуыгыз озакламый бетәчәк. Ә менә күзләр... Күзләргә ярдәм итеп булмый, бу өлкәдә әле медицина көчсез. Безнең илдә генә түгел, алга киткән Көнбатыш илләрендә дә дарулар, нерв күзәнәкләрен алмаштыру ысуллары табылмаган.

Алар озак кына сүзсез утырдылар, һәркайсының үз уйлары, үз хәсрәте алып ашкан иде.

— Рәшит абый, гафу итегез, минем сезгә бер соравым бар. Туган якка кайту турында уйлаганыгыз юкмы? Татарстанда да сезнең кебек галимнәр кирәк бит.

Бу яшь кешенең күзгә бәреп әйтелгән соравы Рәшит Гәрәевичны уйга калдырды. Әйе, анда да, монда да галимнәр кирәк.

— Син минем иң авырткан җиремә кагылдың, Нияз энекәш. Мин бу турыда күптән баш ватам инде, бигрәк тә иптәшем Галия вафат булганнан соң.

— Бу бакчада юкә генә үсәме? Каен агачы да бармы?

— Юкә генә.

— Миңа каен исе килгән кебек тоелды.

— Әйе, бер генә каен бар. Карт каен. Институт бинасын төзегәндә ул могҗиза булып берүзе исән калган.

— Шул каен янына мине алып бармассызмы?

Рәшит Гәрәевич Ниязны җитәкләп каен янына алып килде.

— Менә сиңа исен җибәреп торган каен. Кил, кулларың белән тотып кара.

Нияз ике куллап каенга тотынды һәм аның кәүсәсен капшый башлады, күзләренә яшь, тамагына каты төер тыгылды. Ул акрын гына кулларын агач буйлап шудырды. Бу каен аңа әллә кайчаннан танышы сыман тоелды.

— Я, энем, мин киттем, син үзең юлны табарсыңмы?

— Табармын, Рәшит абый.

Нияз кулларын тагын да өскәрәк шудырды һәм шулчак кулы кәүсәгә ябышып үскән гөмбәгә барып төртелде. Мәшкә! Гөлчирә аны каенның күз яшьләреннән барлыкка килгән гөмбә дип атаган иде. Бу каен, бу гөмбә Гөлчирә белән бара торган яландагы ялгыз каенны искә төшерде.

— Бу нинди могҗиза соң? Әллә мин саташаммы? Бу бит нәкъ шул агач бугай.

Нияз каенны кочаклап алды, аның шома тузына иреннәрен тидерде, иснәде, ялап карады. Дулкынланудан йөрәге еш-еш типте, күзләреннән яшьләр акты.

— Каенкай! Әллә син безнең авылдагы Гөлчирә белән минем мәхәббәтемнең шаһиты булган карт каенның игезәгеме? Әллә шул каен үзе монда күчеп утырганмы? Могҗизамы бу, Ходай кодрәтеме? Син миңа үткәннәремне, Гөлчирәмне искә төшерү өчен монда күчендеңме? Әйт, каеным! Син беләсеңме, минем Гөлчирәм күптән җир куенында. Сезнең икегез алдында да мин гаепле. Авылымны ташлап киттем. Сине дә, каеным, Гөлчирәне дә ялгыз иттем. Мин гаепле, мин гаепле.

Нияз акылдан язган кеше шикелле үзалдына сөйләнә-сөйләнә каенны сыпырды, аннан кулларын акрын гына аска таба шудырды. Башы әйләнеп китеп, борын өстендәге кара күзлеге җиргә төшеп китте. Ул җиргә иелеп, озак кына капшанып, күзлеген табып алды. Кесәсеннән Гөлчирә чиккән кульяулык алып, күзлеген сөрткәләде. Кульяулыкка төрелгән, әнисе биргән догалык-бөтиен сак кына төреп кесәсенә кире салып куйды.

48

Гөлчирә көн дә көндезләтеп Атлас янына килә. Баласының тамагында дифтерия түгел, үлекле ангина булган икән, ул инде терелеп килә. Алар хастаханә бакчасындагы эскәмиягә килеп утыралар. Эсседән качып, юкә күләгәсендә

бик озак сөйләшәләр. Бала әнисенең муенынннан кочып ике як битеннән үбә, иркәләнә. Ана да, үз чиратында, кадерлесен назлый:

— Терел, тизрәк, улым. Менә сиңа нинди тәмле җир җиләге сатып алдым. Витаминнар сиңа бик кирәк.

Гөлчирә юып, әле суы да саркып бетмәгән җиләкләрне улына каптыра.

Шунда ул аллеянең каршы ягында эскәмиядә ялгыз утыручы кара күзлекле яшь кешегә игътибар итте. Бу кеше нәрсәсе беләндер Гөлчирәгә Ниязны хәтерләтте. Бер карады, икенче мәртәбә тагын борылып карады. Ара ерак, шулай да, чәче дә, авызы, ияге дә нәкъ Ниязныкы кебек, дип уйлады Гөлчирә. Азмыни дөньяда охшаш кешеләр?

Каян килеп чыксын бу урыс шәһәренә Нияз? Ул якка бүтән карамаска, яшьлектәге үткән авыр кичерешләрне яңартмаска булды. Ләкин борылып карамый булдыра алмады. Инде кабат караганда, аның янына ак халатлы табиб килеп утырган иде. Алар әкрен генә нидер сөйләшәләр. Ара ерак булганга, Гөлчирә аларның сүзен ишетмәде.

Ул Атласны хастаханәнең ишегенә кадәр озатты һәм, битләреннән үбеп, ишектән кертеп җибәрде.

— Улым, иртәгә шушы вакытта тагын килермен, көт, — диде.

49

Июльнең кызу көне. Юкә агачлары шау чәчәктә, алар гүя юкә түгел, сары чәчәкле мимоза тавы. Ачык тәрәзәдән кергән бал исенә башлар әйләнә. Нияз бүген дәвалану процедураларын иртәрәк алып бетерде дә бакчага ашыкты. Бүген аңа нindидер могҗиза булыр төсле. Рәшит Гәрәевич аңа гәҗитләр һәм тальян гармун алып килергә вәгъдә иткән иде. Тальян гармун! Аның телләренә басып, бер сыздырып җибәрсә, үткән якты кайгысыз көннәре кайткандай булыр иде. Кайда калды соң аның болытсыз, гел кояштан гына торган көннәре? Менә нәкъ бүгенге җылы көн кебек иде ул чаклар. Авыл, мәктәп, Гөлчирә, ялгыз каен. Их!..

Нияз көн дә утыра торган эскәмиягә килеп утырды. Тыптын, юкә яфраклары бүген шыбырдамый, фәкать тирә-якка

бал исе бөркелә. Бал кортлары дуены. Юкә агачы үзенә күрә бер көй чыгарып бертуктаусыз зеңләп тора. Һәй, җан-кисәкләрем! Ашыгыгыз, ашыгыгыз! Соңга калмагыз! Җыегыз табигать биргән байлыкны, ләззәтләнегез, куан-дырыгыз кешеләрне, дип уйлады Нияз.

Ул арада профессор килеп аңа сәлам бирде:

— Саумы, баһадир! Бал исе исертмәсен үзеңне.

— Һай, Рәшит абый, исерсәң дә гөнаһ түгел мондый көндә.

— Әйе, Нияз, көннәр бик матур тора. Йә, гәҗит укыйммы сиңа, әллә гармун уйныйсыңмы?

— Гармун, гармун, Рәшит абый. Сагындым гармун тавышын, бармакларым гына мукләнмәгән булса. Бирегез тизрәк.

Рәшит Ниязга гармунны тоттырды, җилкәсе аша каешын кидереп куйды.

— Их!..

Нияз бармакларын берничә мәртәбә гармун телләрендә биеткәләп алды да, кыска-кыска аккордлар биреп, үзе яраткан көйләрне уйнап алды. Бакчада бары Нияз уйнаган гармун тавышы гына калды, бары да тынды. Кошлар да, бал кортлары да, кычкырыш-кычкырып сөйләшүче авырулар да. Аннан Нияз үзе чыгарган көйне башлады:

Ялгыз каен,
Ялгыз каен,
Яннарында гел чирәм.
Сине мәңгегә югалттым,
Мин гаепле, Гөлчирәм...

Гөлчирә, улы белән кочаклашып утырган җиреннән, җыр тавышы ишетеп, сагаеп калды, татарча җыр, тальян гармун.

— Утырып тор, улым, мин хәзер, — дип, улын калдырып, җыр агылган эскәмия янына килеп басты — аның каршында кара күзлекле Нияз иде.

— Нияз! Синме соң бу?

Бу тавышка Нияз утырган җиреннән кинәт сикереп торды, кулындагы гармуны уфылдап җиргә таба сузылып төште.

— Кем сез? Кем тавышы?

— Мин бу, Гөлчирә!

— Кем, кем? Кайсы Гөлчирә?

— Авылдашың, классташың Гөлчирә.

—Уятыгыз мине! Мин саташам бугай, — диде Нияз ачыргаланып.

— Юк, Нияз, син саташмыйсың. Синең алдыңда бик чибәр яшь хатын басып тора. Ул үзен Гөлчирә дип атый, — диде профессор.

— Гөлчирә үлгән, ул юк. Ә минем Гөлчирә исемле башка танышым юк.

— Я, ярый, аңлашыгыз, сөйләшегез, мин киттем, — диде Рәшит Гәрәевич.

Гөлчирә Ниязны кочаклап алды.

— Ни булды сиңа, Нияз?

Нияз да Гөлчирәне кочаклады.

— Гөлчирәм, Гөлчирәм. Сине бит мин күптән бу дөньядан киткән, дип беләм. Юк, юк, ышанмыйм, үтерсәгез дә ышанмыйм.

Нияз Гөлчирәнең чәчен, маңгаен капшады, битенә кулын тидерде.

— Ышанмыйм, кемдер мине шаярта. Сәримә түгелме? Сәримә тагын бутап йөрмиме мине?

— Юк, Нияз, бу мин — синең беренче мәхәббәтең — Гөлчирә.

— Синең үлемең турында гәҗиттә дә язганнар иде бит.

— Ялгышлык булгандыр. Ышанмасаң, минем ышандырыр дәлилем бар. Исеңдәме? Тугызынчы сыйныф. Кое буе. Исеңдәме? Минем тырнаксыз калган бармак...

Нияз Гөлчирәнең кулын үз кулларына алды, бармакларын берәм-берәм тотып, аның тырнаксыз чәнчә бармагына җитте.

— Гөлчирә! Гөлчирәм! Бу нәрсә бу? Каргышмы? Ялгышмы, язмышмы? Нәрсә бу?

Гөлчирә улы Атласны чакырып алды. Шушы тымызык матур көндә, туып-үскән җирдән меңләгән чакрымнар еракта, ике йөрәк, ике күңел җил-давылда куптарылган диңгез дулкыннарын хәтерләтте. Күпме хатирәләр, күпме истәлекләр диңгез төбеннән кубарылып өскә калыкты...

САБЫРЛЫК

1979 елның җәе иде. Май ахырлары. Эшли торган урыныннан Хәмдүнәгә ниндидер «яна» торган юллама тәкъдим иттеләр. Курортка, Кырым ярымутравына. Бакча эшләре, дип бераз икеләнеп торса да, йөрәгенең күптән инде туктап-туктап тибүенә, сулкылдавына гаҗиз булган Хәмдүнә барырга булды. Балалары, ире белән киңәште. Ире дә, Кырым дигәннәрен күреп кайтырсың, ил күрү — үзе бик зур нәрсә, диебрәк, Хәмдүнәнең бу сәфәренә хәер-фатихасын бирде. Юллама С. дип аталган, йөрәк-кан тамырлары авыруларын дәвалый торган бөтен илгә танылган мәшһүр санаторий иде.

Хәмдүнә иң элек Казанга очты, аннан Мәскәүгә, аннан Кырымга. Мәскәүдән самолет иртәнге биштә күтәрелә икәнен белешеп, Хәмдүнә билетын компостировать итте, аннан халык тулы аэропортның ялан зурлыгындагы көтү залындагы, бер урынга барып утырды. Бераздан төнге кафега кереп кайнар чәй эчте, ике сумса ашады. Төн бик озын, ыгы-зыгы, шау-шу шулкадәр көчле иде, инде ул ник чыкканына мең тапкыр үкенде. Хәерле булсын, акчасы түләнгән, билет алынган, берни эшләр хәлең юк, барысына түзәргә, сабыр итәргә, дип уйлады. Олылар юкка гына, юл газабы — гүр газабы, димәгәннәрдер. Чемоданына башын куеп, черем иткәләде. Башы авырайды, үзеннән-үзе күзе йомылды. Ул арада, соңга калмыйм дип тәшвишләнеп, күзен ачып, залның биек диварына элеңгән җиз табак чаклы сәгатькә карап-карап алды. Ниһаять, вакыт җитте...

Самолет шулкадәр югарыдан очты, күк йөзе зәп-зәңгәр, яңа гына чыгып килүче кояш самолет астындагы кабарынкы болытларны әллә нинди сихри төсләргә манчыган. Хәмдүнә, иллюминаторга башын терәп, шул сихри болытлар арасыннан җирне күзәтә. Йә, Хода! Нинди хозурлык!

Гүя аска, җир өстенә, ул кайчандыр география фәненнән өйрәнгән физик картаны җәеп салганнар. Әнә озын-озын елгалар, урманнар, шәһәрләр, бормалы юллар. Нинди манзара! Моны кайчан күрер идем әле, дип куанды Хәмдүнә.

Күп тә үтмәде, самолет иге-чиге күренмәгән зур диңгез өстеннән оча башлады. Хәмдүнә бертуктаусыз күзәтте. Әнә кораблар, пароходлар дулкыннарны яра-яра каядыр баралар. Чү! Бусы нәрсә? Диңгез өстендә гаять зур кара тап.

Түп-түгәрәк, шомлы-ямьсез тап. Ул дулкыннарда чайкалып-чайкалып тора.

Берничә минуттан кара тап та артта калды. Ниһаять, самолет урманнар белән капланган диңгез яры буйлап оча башлады.

— Кырым, Кырым, — диеште самолеттагылар.

***

Самолеттан төшү белән, зур автобуска утырып, Хәмдүнә С. курортына килеп җитте. Автобустагылар барысы да шунда килүчеләр икән, алар, зур бер агым булып, искиткеч матур чәчәкләр үсеп утырган аллеялар буйлап тоташ пыяладан торган бер гүзәл бина янына килделәр. Хәмдүнә дә бина эченә кереп, курортка теркәлер өчен паспортын, юлламасын алып сабыр гына чират көтә башлады.

Менә икесе дә чал чәчле ирле-хатынлы бик мөлаем кешеләр язылды һәм Хәмдүнәгә чират җитте.

Ул язып утыручы ханымга документларын сузды, кып-кызыл иннек сөрткән калын иренле, алтын тешле бу ханым Хәмдүнәнең исем-фамилиясен хәрефләп диярлек язып куйды, юлламадан тагын нәрсәләрдер язды. Аннан паспортның бер ноктасына усал күзләрен акайтып текәлде. Тынып калды. Кулындагы каләмен журнал өстенә ташлады һәм Хәмдүнәгә чекрәйде:

— Сез татаркамы?

— Әйе, мин татар хатыны.

— Кайдан килдегез? — диде ханым, тагын да дорфарак тавыш белән.

— Мин Татарстаннан, А. шәһәреннән.

— Кайда тудыгыз? Кайда яшәдегез?

Ул тагын нидер әйтергә теләп, алтын тешле авызын ачты, тик башка сорау бирмәде.

— Күчеп утырыгыз, әнә тегендәрәк, тегендәрәк! Ачыкларбыз, тикшерербез, — дип читтәге бер урындыкны күрсәтте.

Нишләсен, Хәмдүнә теләр-теләмәс кенә ул күрсәткән урынга күчте.

Килүчеләр бик күп иде. Ханым, йөзенә ясалма елмаю чыгарып, тәртип белән һәркайсын язды, нindидер кәгазьләр бирде, яхшы ял теләде, чәй бүлмәсенә кереп чәй эчәргә тәкъдим ясады.

Бу церемония бик озакка сузылды. Йокысыз төннәр, ачлы-туклы озын юл үткән Хәмдүнә үзендә чигенә җитәр дәрәҗәдә талчыгу тойды, тамагы кипте, теле аңкавына ябышты. Бер генә чынаяк чәй эчеп алса, хәл керер иде, тик аңа карата бу кунакчыллыкны күрсәтүче, аның хәленә керүче булмады. «Ни өчен мине болай тоткарлый бу ханым? Нинди гаебем бар соң минем? Берәр кәгазем ялгыш язылды микәни?» — дигән уйлар буталды аның авырайган, ачыгудан чынлап кысылып авырта башлаган башында. Шулай да сабыр итте.

Ниһаять, көн кичкә авышкач кына, килүчеләр сирәгәйде, язылучылар бетте. Кызыл авызлы ханым Хәмдүнәне янына чакырды. Ул каршысында басып торган бу кечкенә гәүдәле, коңгырт күзле, урта яшьләрдәге хатынга күзен йоммыйча, сөзеп, бик озак карап торды, карашы аның саен караңгылана барды.

— Татармы син?

— Әйттем бит инде, мин татар хатыны, ирем, өч балам бар. Татарстаннан. А. шәһәрендә, нефтьчеләрдә оператор булып эшлим. Менә шул.

— Туган җирегез кайда?

— Тууым да Татарстанда.

— Кайда соң ул Татарстан? Үзбәкстан янындамы?

— Нинди Үзбәкстан янында булсын?! Идел буенда.

— Татарлар хәзер Үзбәкстанда яшиләр бит. Сатлык халык. Кырымны немецларга саттылар. Сезнең аркада немецлар Кырымны басып алдылар.

— Сез ни сөйлисез? Мин Кырым дигәннәрен дә беренче тапкыр күрәм. «Янган» юллама булмаса, гомеремдә аяк басасым юк иде. Ник кенә килдем?! Ник кенә ул каһәр суккан юлламаны алдым?— дип ачыргаланды Хәмдүнә.

— Я, ярый, карарбыз. Менә сезгә талоннар, бүлмә алыгыз. Урнашу белән тулы килеш автобиографиягезне язып миңа китерегез. Сак булыгыз, бер генә адымыгызны да күздән яздырмабыз. Бу җирләргә килеп урнашу турында уйлап та карамагыз. Хыялларыгызны онытыгыз. Кырымда сезгә урын юк! — диде ханым күзләреннән очкыннар уйнатып, төкрек чәчә-чәчә.

Хәмдүнә өчен бу сөйләшү — башына авыр таяк белән суккан кебек булды. Әйе, ишеткәне дә, укыганы да бар иде аның бу фаҗига турында. Сугыш елларында бөтен бер

халыкның туган җирләреннән көчләп Урта Азия далаларына сөрелүе турында ул белә иде. Әмма үз язмышында аның шаукымы булыр дип башына да китермәде. Нәкъ менә шушы сөйләшүдән соң бөтен тирәнлеге белән бу каһәрләү аның күз алдына килеп басты.

Халкы куып җибәрелгәч, бушап калган йөзләгән авыллар, шәһәрләр... Ата-бабаларының изге каберләре. Хуҗасыз калган этләр, мәчеләр...

***

Хәмдүнә, ишекне сак кына ачып, бүлмәгә килеп керде. Стеналар буйлап дүрт караватъ. Берсе — тәрәзә буендагысы — аны көтә булыр. Яшел җәймәсе бик яхшылап шомартылып куелган, өстендә кечкенә мендәр. Өч караватта юлдан соң талчыккан ханымнар ял итәргә ятканнар. Берсе аягындагы кара туфлиен дә салырга онытткан. Икенчесе яткан килеш кенә чемоданыннан аллы-гөлле күлмәкләрен урындык аркасына элә.

— Каһәр генә икән, йомарланып беткәннәр. Үтүк берерләрме икән?

Аның соравы җавапсыз калды. Хәмдүнә өч хатынның сынаулы карашы астында сабыр гына тәрәзә буендагы караватъ янына үтте. Чемоданын идәнгә куеп, урындыкка утырды. Аның шушы минутта ук караватка сузылып ятасы килде. Ләкин аның әле автобиография язасы бар.

Ул уйга калды. Нигә кирәк булды икән аның тәрҗемәи хәле? Аның тормышында бернинди дә кара таплар юк бит. Авыл кызы, колхозчы баласы. Ун сыйныф бетергәч, башлангыч мәктәптә укытты, ә А. шәһәренә күчеп килгәч, оператор булып урнашты. Ире, өч бәгырь кисәге — балалары бар. Ул сабыйларын күз алдына китерде...

Бераз утырганнан соң, кәгазь алып яза башлады...

***

Кич белән, көтмәгәндә, бик көчле яңгыр яуды. Күз ачып йомганчы бар җирдә болганчык шарлавыклар хасил булды. Текә ярлардан ташлар тәгәрәде. Диңгез яры гүләп торды, шашкан дулкыннар ярга бәрелүдән меңәрләгән биниһая зур су көлтәләре булып һавага омтылдылар һәм, кабат ыңгырашып, акылдан язган диңгезгә килеп төштеләр.

Яр буенда тимер троска бәйләнгән катерлар, көймәләр бер-берсенә бәрелеп шыгырдашты, ыңгырашты.

Бу кара тавыштан, моңарчы беркайчан да ишетмәгән бу үкерүдән Хәмдүнә йокысыннан уянып китте, куркынып, шомланып, йоклап китә алмый бик озак ятты. Болганчык яңгыр суы белән төссезләнгән тәрәзә аша бүлмәне яктырткан яшен аңа бигрәк тә куркыныч, күзен ачып тәрәзәгә караса, асылынып-асылынып торган кара болытлар күңеленә аеруча көчле шом салды. Йөрәге ярсып-ярсып типте, күкрәген ярып чыгардай булып сулкылдады.

Күрше караватта йоклаучы юан ханым йокы аралаш тешләрен шыгырдата, нидер мыгырданып ала да, авыр ыңгырашып, икенче якка борылып ята. Аның өчен табигатьтәге бу мәхшәр бармы да юкмы, ул ишетми. Йокысы каты.

Бераздан яңгыр туктагандай итте, яшен дә сирәгәйде, ерактарак күк күкрәде, әмма диңгез өстендә эленеп торган кара болытлар озын йонлы юеш толып кебек бөтен күкне каплап тора иде...

***

Хәмдүнә таң алдыннан гына йокыга талды. Ул уянып күзен ачканда, болытлар таралган, күк йөзе чалт аяз, ялтырап кояш чыккан иде. Ул аякларына җиңел чүәген элеп, зәңгәр халатын киеп алды да, башкалар уянмасын, дип әкрен генә ишекне ачып, коридорга чыкты, аннан чәчәкле аллеялар буйлап диңгезгә таба атлады. Диңгез тынган, йөгерек дулкыннар гына яр буендагы комны юа. Хәмдүнә үзенә бер әсәрләнү белән күз карашын еракка-еракка төбәде. Менә нинди икән ул — диңгез дигәннәре!

— Саумы, зәңгәр диңгез! Саумы-ы-ы!—дип аваз салды.

Кычкырмады, ә якын сердәшенә, беренче күрүдә үк күңеленә хуш килгән берәүгә дәшкән кебек, хисләнеп, чын күңелдән күкрәк тутырып, елмаеп әйтте ул бу гади генә сәламләү сүзләрен. Чүәкләрен салып җылы комга басты, диңгезгә якын ук килде, уң аягының бармакларын гына суга тигезеп карады. Нинди талгын, җылымса су! Аннан ике аягы белән дә тубыктан суга кереп басты. Иелеп, кушучлап су алды һәм кинәт кенә йөзенә сипте. Аның моңа кадәр бервакытта да мондый хозурлыкны, рәхәтлекне татыганы юк иде бугай. Кичәге ямьсез уйлар да әллә кая юкка чыкты. Аның диңгездә йөзәсе, чумасы килеп китте. Тик ялгызы, тиле кеше кебек, бик иртә монда килүенә бераз кыенсынып та куйды.

Ни өчен бу чиста сулы зәп-зәңгәр диңгезне Кара диңгез дип атаганнар соң? Кем беренче тапкыр аны кара итеп күргән икән? Ул кеше нинди халәттә иде икән? Әллә бик рәнҗетелгән иде микән?

Ул әкрен генә иң яраткан җырын җырлап җибәрде:

Зәңгәр диңгез,

Зәңгәр һава

Зәңгәрләтә диңгезне...

Һай, диңгез дигәннәре матур да икән соң! Бу көй үзе дә, сүзләре дә җанга сары май булып ята. Мөгаен, бу җырны Хәмдүнә кебек беренче тапкыр диңгез күргән тирән хисле, гүзәл яшь кыз җырлагандыр. Безнең халык шундый инде: Идел буена барса, Иделкәем, дип, урманга керсә, урман турында, чишмә буена килсә, чишмәне мактап җырларга ярата.

Хәмдүнә дә бик нечкә зәвыклы, җырлы, моңлы ханым. Бу хозурлыкка җырламый түзә алмады.

***

Ханымнар бик тиз танышып өлгерделәр.

— Мин — Архангельскидан,—диде яшь кенә чибәр ханым. — Исемем — Нина.

— Ә мин — Шура, Александра Христофоровна, Курскидан. Ишеткәнегез бармы? Безне «Курск сандугачлары» дип атыйлар. Бездә җырчы халык яши.

Ул җырлап та күрсәтте. Җырчы, янәсе.

— Мин Кама буйларыннан. Исемем — Хәмдүнә. Оператор булып эшлим.

— Хам-хам-хам, — ничек, ничек? — диде Шура кашларын күтәреп.

— Хәмдүнә.

— Хамдуна, — ха-ха-ха,—дип шаркылдады тагын Шура дигәне.

— Хам-дуня! Без сине Дуня дип атарбыз, — диде, елмая төшеп өченчесе.

Өченче дигәне, бик ябык, кыркылган кыска чәчле, йолка-йолка нечкәреп беткән кашлы, бик юка иренле ханым үзен:

— Мин Мәскәүнең үзеннән. Исемем Элеонора,—дип таныштырды.

Хәмдүнәгә ул бик сөйкемсез булып күренде.

Бу ханымны Хәмдүнә бүлмәдә бик сирәк очратты. Ул

курортка килү белән үзенә иш тапкан һәм шул бәндә белән көн-төн бергә булып, бик сирәк кенә күзгә чалынды.

Шулай итеп, Хәмдүнә Дуня исеме алып, курорт мохитендә яши башлады. Яңа исемгә ул ияләшә алмады, шулай да сабыр итте, түзде. Эндәшсәләр, еш кына ишетмәде. Үз исеме белән ничә еллар гомер иткән кеше ничек яңа исемгә тиз генә ияләшсен.

Көн буе җай гына төрле дәвалау бүлмәләренә йөрде. Кичләрен бүлмәдә үз уйларына бирелә торган булды.

Үзе генә калганда җырлар җырлады. Сагынганда җыр да күңел түреннән әллә ничек моңлырак та, матуррак та булып чыга икән.

Хәмдүнә шушы хакыйкатьне беренче мәртәбә биредә аңлады. Чөнки ул курорт дигәннәрендә беренче тапкыр иде. Курорт тормышы тоташ сагыштан, төрле-төрле күңелсез эпизодлардан тора икәнен аңлады.

***

Беркөнне хатыннар барысы да бүлмәдә сөйләшеп утырдылар. Кемдер үзенең балалары, кемдер эше турында сөйләде.

— Син милләтең белән кем соң? — диде юан Шура Хәмдүнәгә.

— Мин — татар хатыны.

— Татар? Кем соң ул — татар? Далада яшиме? Урмандамы? — диде Элеонора.

— Сез юрталарда яшисездер бит? — диде Шура.

— Юрталар?! Нинди юрталар?! — диде Хәмдүнә, гаҗәпләнүен яшерә алмый, сабырлыгын җуеп.

—Кыргый халыклар — казахлар, кыргызлар, татарлар — барысы да ком чүлләрендә киездән ясалган тирмәләрдә яшиләр икән бит.

— Юкны сөйләмә! Татар халкы Идел-Чулман буенда яши. Урман эчендә дә, чүлдә дә түгел. Менә дигән уңдырышлы җирдә, Татарстанда! — диде Хәмдүнә.

Ул инде бераз кызып китә язды. Күңеленнән «кызма, сабыр, сабыр, Хәмдүнә!» — дип уйлады.

— Лыгырдама! Идел ул урыс елгасы! Великая русская река, — диде Шура.

— Әйе, урыслар татарларны куып, Идел ярына үзләренең шәһәрләрен салганнар, чиркәүләр җиткергәннәр. Ә ул җирләр ничә гасырлар безнең бабаларыбыз җире булган.

— Лыгырдама! Нинди ахмаклык! Татар җире, имеш! Татарлар алар — сатлык халык. Әнә, Кырымда да татарлар яшәгән. Немецларга сатылганнар.

— Ялгышасың, Шура ханым, — диде Хәмдүнә сабыр булырга тырышып, — татарлар сатлык халык түгел, ә герой халык.

— Герой! Тот капчыгыңны! Ни өчен Кырымнан татарларны куганнар? Ә?! Белмисеңме? Сатлык булганга куганнар!

— Юк, юк. Урыска җәннәт кебек җирләр кирәк булган. Шуңа куып җибәргәннәр. Ә урыста сатлыклар аз булганмы? Власов кем? Татармы? Бандерачылар — кем? Татарлармы? Берничә кеше сатлык булган, бөтен халыкка пычрак атарга, аны эзәрлекләргә кем хокук биргән? Халык сатлык була алмый!

Сүз озак дәвам итте. Хәмдүнә бөтен акылын, бөтен сабырлыгын җыеп, үз халкын яклады. Геройлар исемнәрен атады.

— Герой-шагыйрь Муса Җәлилне бөтен Җир шары белә.

— Муса Җәлил, — диде Шура, — ул, беләсең килсә, еврей, ә, юк, грузин! Шуңа ул герой.

— Юк, җан кисәгем, ул еврей да, грузин да түгел, ул — татар.

— Юкны сөйләмә, лыгырдык. Джалили — грузин фамилиясе. Яңгырашын гына ишет — Джалили! Грузиннар — герой халык алар!

Хәмдүнә йокларга яткач та озак кына тынычлана алмады. Шураның тузган чәче, бәбәгеннән тәгәрәп төшәм-төшәм дип киерелгән сыек зәңгәр күзләре аның күз алдыннан китмәде. Аның ажгырып кабат-кабат әйткән «лыгырдама!» дигән сүзе колагында яңгырады. Я, Ходам! Нинди дорфа хатын, нинди усал.

— Сабырлыклар бир, сабырлыклар, — дип кабатлады Хәмдүнә.

Ул бит, бу халыкны ихтирам итеп, телен өйрәнде. Әйе, гыйбрәт алу өчен монда килергә кирәк булган икән аңа. Ул сукыр булган икән. Татарны күралмыйлар икән ләбаса.

***

Беркөнне Хәмдүнә Нина исемле хатын белән ялгыз иде, икәүдән-икәү генә. Әллә ни сөйләшер сүз дә юк, эш тә юк. Тегеләр кичке танцыга киттеләр. Нина тыйнак хатын, алай артык мактанмый, күп сөйләшми. Танцыларга йөрми. Ирен, балаларын сагына, еш кына йөрәге авырта.

— Дуня, — диде ул, Хәмдүнәгә туры карап. Син Шураның сүзләрен игътибарга алма. Ул акылга сайрак, әрепләшергә ярата торган, буш хатын. Сөйләгән сүзенең рәте юк.

— Юк, мин аңа үпкәләмимим, ул, чыннан да, узынган хатын.

— Әйе, әйе. Менә минем өчен сезнең фикерләрегез бик кызык тоелды, дөресрәге — ышанычлы, мәгънәле. Сез үзегезне татар дидегез.

— Җитте, Нина, мин бу темага башка сөйләшергә теләмимим.

— Юк, юк, мин чыннан да сезнең халык турында бик аз беләм, гафу ит. Әйдә, минем белән чын күңелдән сөйләш әле. Мин җәнҗал куптарырга теләмимим. Я инде! Сезнең чыннан да шәһәрләрегез, мәдәниятегез, әдәбиятыгыз, җырларыгыз бармы?

Хәмдүнә озак кына дәшмәде. Сабырлык бир, диде күңеленнән.

Урыныннан торып басты, төнге тәрәзәдән йолдызларны күзәтте. Нина исә соравын тагын кабатлады:

— Җырларыгыз, җырларыгыз да бармы?

— Нинди генә әле, нинди генә! — диде Хәмдүнә әсәрләнеп, өзгәләнеп...

Ничек кенә бу самими яшь ханымга үзенең бөек халкы турында аның күңеленә, йөрәгенә барып җитәрлек итеп, кызмый гына, сабыр гына сөйләп бирергә соң? — дип уйлады.

— Җырлап күрсәтимме?

— Җырла, җырла!

Бүген көн буе үзе яшәгән шәһәрен, Чулманын, ирен, балаларын юксынудан Хәмдүнәнең йөрәге сулкылдап-сулкылдап сагыну хисе белән тулган иде. Инде килгәненә дә ун көн, сагынырга вакыт. Ул кинәт күкрәген тутырып, тирән итеп тын алды да, моңарчы һич булмаганча көчле һәм моңлы итеп, нәфис күкрәк тавышы белән, көньякның чая йолдызларына күзен текәп, җырлап җибәрде:

Китми күңлемнән минем һич
Шул сөекле илкәем.
Анда минем сөйгән халкым,
Анда сөйгән әнкәем.
Анда таңнар — җәйге диңгез...

Ул җырны дәвам итә алмады, күзеннән атылып яше чыкты, тамак төбенә нindидер каты төер килеп тыгылды, тавышы кысылды. Ул бу минутта үткән көннәрдә булып алган авыр сөйләшүләр, аңа шикләнеп, чит итеп караучы-

ларга рәнҗеп, үз җирен, үз илен сагынып, бөялеп торган барлык кичерешләреннән, әрнешләреннән ыргылып тышка чыгуын сизде, караваты янына килеп, мендәренә ауды һәм тын гына сулкылдады.

Танцы мәйданчыгында яңгыраган «Виновата ли я? Виновата ли я?» дигән шашкын җыр, тәрәзә аша кереп, бүлмәне тутырды. Нина исә Хәмдүнәне юатып та карады, сораулар да бирде. Ләкин ул дәшә алмады, теләмәде. Аның күңеле каткан, уйлары чуалган иде.

Халыклар дуслыгы символы булган бу бөек илдә аның газиз халкына чүп итеп карыйлар, аны белмиләр икән. Җитмәсә, җае чыккан саен кыерсытырга, түбәнсетергә генә торалар икән. Югары белемлесе дә, чеп-чи наданы да, дип уйлады Хәмдүнә.

***

Бу якларда көчле яшенле яңгырлар сирәк түгел икән, әмма шунысы яхшы: коточкыч көчле яңгыр явып үтә дә ялт итеп кояш чыга, гүя бер дә яңгыр да яумаган, болыт та булмаган. Беркөнне тагын күк йөзен болыт каплап алды. Хатыннар, дәвалану тәмамлангач, күңелсезләнеп үз бүлмәләрендә утырдылар. Хәмдүнә үзе белән кул эше алып килмәвенә үкенеп бетә алмады. Бәйләм энәләре белән берәр йомгак җеп тыккан булса соң, авыр да түгел бит югыйсә, дип уйлады эченнән.

Сүз иярә сүз китте, һәркем үзенең үткәнен, кызык хәлләр сөйләде, ир белән хатын мөнәсәбәтләре уртага салып җилгәрелде.

— Һи, — диде Элеонора, — ирләрне үзеңә карату ике тиен бер акча ул. Менә мин үзем беренче иремне бик оста каптырдым.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Тын калып, барысы да аны тыңлады. Ул очынып-очынып сөйли башлады.

— Яшь чак, матур чак. Арттан йөрүчеләрнең исәбе юк, тик берсе генә дә минем зәвыкта түгел. Кайсының буе, кайсының йөзе-бите. Киң җилкәле, куе кара кашлы сөлектәй бер егет ошый, әмма ул миңа күз дә сирпеми. Ә минем аңа сүз кушасым, күзләренә туры карыйсым килә. Очратсам, үз-үземне белештермәс дәрәҗәдә аңа омтылам, ләкин ул мине күрми. Икебез дә тулай торакта яшибез. Ул икенче катта, ә мин өченчедә. Ул укый, мин эшлим. Барыбер мин сине кулга төшерәм, дим, үҗәтләнә башладым. Төрле-төрле планнар корып карадым, юлларына каршы чыга торган

чакларым булды. Тик юкка. Беркөнне ул вахтада дежур тора. Әһә, мин әйтәм, булды бу. Хәйлә уйлап таптым. Соң гына, төнге уникеләр тирәсендә, ашыга-ашыга өченче каттан төшеп киләм. Ул күрде дә:

— Кая киттең соңлап, Эля? — ди бу.

— Менә, дим, тәрәзәдән ридикюлемнең чүп-чарын каккан идем, ялгыш сәгатем төшеп китте, дим, шуны эзләргә чыгам.

— Соң бит инде, — ди бу, — ялгызыңа куркыныч бит. Әйдә мин дә эзләшим, ди.

Әһә, дип уйлыйм, эләктерәм моны кармакка! Эләктерәм!

Урамга чыктык, эзләгән булдык. Сәгатьне тапмадык. Ярар, мәйтәм, берәрсе табып алгандыр. Тулай торакка кердек. Мин алдан, ә ул минем арттан. Ах, ул чагында минем тантана итүләремне белсәгез иде! Мин аңа туры карап елмаям. Күрде, кызлар, күрде, ул да миңа карап шундый елмайды!

Сәгать уникене сукты, аның вахтадан китәр вакыты җитте.

— Әйдә, дим, минем бүлмәгә керик, вахтадан соң чәй эчәсең киләдер, яңа таңны бергә каршылыйк. Риза булды, кызлар, артымнан ияреп бүлмәмә керде. Шул көннән соң көн дә минем бүлмәдә таңнарны бергә каршылый башладык. Ул минем бүлмәмә күчте.

Элеонора бик ямьсез итеп көлә башлады. Ул озак көлде. Башкалар берсе дә көлмәде. Ул сүзен тагын дәвам итте.

— Озак яши алмадык, аерылыштык. Син мине үзеңә көчләп өйләндердең, дип җанымны ашады. Эчә башлады, минем янга сирәк кайтты, башканы тапты.

— Башка кияүгә чыкмадыңмы? — диде Нина.

— Һи-и, юләр, ирләремнең инде санын онытып барам.

Бу ямьсез сөйләшүдән соң Хәмдүнә Элеонорага туры карарга, аның белән сөйләшергә чирканды.

Ул үзенең яшьлеген, ире Ралиф белән танышу көннәрен исенә төшерде. Ул аңа ничә көннәр ялындырып йөрде. Ялынсын, кадерне белергә әйбәт булыр, дип уйлый иде. Әнә бит кайберәүләр ничек кылана. Гыйбрәтләр алу өчен чит җирләргә чыгып йөрергә кирәк икән, дип уйлады Хәмдүнә тагын бер тапкыр. Бу аның өчен бер яңа ачыш иде. Гыйбрәтләр алу өчен...

***

Бүлмәдә ялга, дәваланырга килгән бу ханымнар арасында

көн саен ниндидер каршылыклы сөйләшү булып ала һәм торган саен мөнәсәбәтләр киеренкеләнә барды. Хәмдүнә һәр иртәне шомланып, кәефсезләнеп каршы алды. Дәвалануның да уңай нәтиҗәләрен сизмәде. Ул төннәрен дә начар йоклый башлады. Көн саен берничә мәртәбә «Бу җәһәннәм астына ник кенә килдем?» — дип уйлый иде. Аллы-гөлле чәчәкләре дә, диңгезнең гүзәллеге дә күзенә күренмәде. Ул инде дәвалану көннәренең яртысы җитү белән, кайтып китү турында уйлый башлады. Уйлап кына калмады, чемоданына әйберләрен тутырып та куйды.

Җир тетри торган урыннарда яшәүчеләрнең һәрчак «тревога чемоданнары» әзер тора икән, дип ишеткәне бар иде Хәмдүнәнең. Ул үзенең бу көннәрдәге халәтен шуңа охшатты.

Бердән, балаларын сагыну, икенчедән, килү белән туган бу киеренке мохит аның җанына, бәгыренә бер генә минутка да тынычлык бирмәде. Никадәр генә Ходайдан сабырлык сорап, сабыр булырга тырышмасын, аның эчендә нәрсәдер кымырҗып авырта башлады. Кайтып китәргә! Тизрәк моннан китәргә! Китәргә! Ул һәрвакыт шушы уй белән янды.

Көннәрнең берендә тагын гадәттән тыш хәл булып алды.

Хәмдүнәнең үз итеп өлгергән Нинасы беркөнне кош тоткандай, ялтырап кайтып керде.

— Кызлар, бүген минем туган көн, өйдән телеграмма алдым, шул шатлыктан әрмән коньягы алып кайттым, эчәбез, җырлыйбыз, утырышыгыз, — дип, өстәлгә колбаса турап куйды.

— Дуня, Дуня, өстәл янына!

Хәмдүнә дә өстәл янына килеп утырды. Нина курорт стаканнарына коньяк койды. Хатыннар аны котладылар, матур-матур тостлар әйттеләр. Шакылдатып сырлы стаканнарын бәреп алдылар һәм эчеп тә җибәрделәр. Хәмдүнә генә савытка кагылмады.

— Дуня! — диде Нина авызын бүлтәйтеп, — син нәрсә? Мине котларга теләмисеңмени?

— Котлыйм, Нина, чын күңелемнән сиңа бәхет телим, син бик яхшы кеше, мин сине яраттым. Әмма, гафу ит, минем бу нәрсәне беркайчан да эчкәнем юк, — дип Хәмдүнә стаканны этеп куйды.

— За компанию и жид удавился, — диде Элеонора.

Юан Шура да үз дәрәҗәсен белеп кенә кайчандыр, кемнәндер ишеткән сүзен әйтергә булды:

— Шекспирча әйтсәк, «Син монда чакта, без сине эчәргә

өйрәтербез!» Ха-ха-ха!

— Нәрсә генә әйтсәгез дә, эчә алмыйм, кызлар, гафу итегез, эчкәнем юк.

Бераз утлы су да йоткач, хатыннарның авызлары ябылуны, телләре талчыгуны белмәде, төрле тавышлар чыгарып җыр суздылар.

Хәмдүнә сабыр гына аларның кыланышларын карап утырды. Сабыр ит, Хәмдүнә, күп калмады, дип юатты ул үзен.

***

Ике көннән ул, тәвәккәлләп, кире кайту юлына самолетка билет алды. Җитте, бу мәхшәрдә нинди дәва булсын да, нинди ял булсын. Үземнең бакчамда эшләрмен, балаларымны кочармын, дип, өч көннән кайтып та китте. Аэропортка кадәр аны Нина озата килде.

— Син мине, Дуня, гафу ит, мин дә, бәлки, сине рәнҗеткәнмендер, син миңа үпкәләмә, бәлки игътибарым җитмәгәндер, — диде Нина самолет көтеп утырганда.

— Юк, Нина, минем килү беләп канатымны сындырдылар, сабыр канатыма зыян килде, сына язды минем сабырлыгым. Мин бер нәрсә аңладым: бездә байлык бар, матур да яшибез. Ял итү өчен җәннәт кебек матур җирләргә, курортларга йөрибез. Кием-салым да, Аллага шөкер, күп. Әнә бит Шура ничаклы кием, ничаклы алтыннар белән килгән. Ашый-эчә, туйганчы йоклый. Хәсрәте юк, бернидә аның гаме юк. Ә бит уйланыр нәрсәләр күп икән: баерга тырышу, муллык, бөтенлек бездәге иң кадерле нәрсәне юкка чыгарган. Ул — кешелеклелек. Кешегә, ягъни башка кешегә, башка халыкларга ихтирам.

— Әйе, Дуня, син хаклы, моны «кешелеклелек дефициты» дип атыйлар. Чыннан да, бездә кешелеклелек юкка чыгып бара бугай, — дип килеште Нина да.

Самолет кузгалып китте. Хәмдүнә тагын иллюминаторга башын терәп аска карап бара башлады. Кара диңгезнең меңнәрчә чакрымнарга сузылган сары комлы пляжларында кызынып, аунап-тәгәрәп ятучы гәүдәләр аңа чәчеп ташланган бәрәңгеләрне хәтерләтте.

Тизрәк, тизрәк, үз ягыма, үз өемә, үз җиремә! — дип уйлады Хәмдүнә.

ЫШАНЫЧ

Кайвакыт ирем Камилнең киң җилкәләре, тыгыз тәне, зур-зур кулларына карап мин хәйран калам. Каян килгән соң бер карауга тупас, шыксыз булып күренгән кешедә шундый да хисле, нәзакәтле йөрәк?!

Ул еш кына сөякчел тезләренә башын салып, уйга калып диванда утыра. Аның озынча йөзе, туры борыны, кысылган иреннәре, акыллы күзләре аның язмышын сөйли кебек. Ни өчен яраттым икән мин аны? Нинди сыйфаты мине үзенә җәлеп итте соң? Ничә еллар бергә яшәсәк тә, мин бу сорауларга җавап таба алмыйм. Инде балалар үсеп җиттеләр. Ничек бу кадәр матур пар булып бер-берегезне таптыгыз? — дип сораучылар да бар. Ничек табыштык та, ничек кавыштык соң без?

Хәтердә. Ул көннәрдә һәр атлаган адымым хәтеремдә. Аларны онытып буламы?!

19... елның август башлары иде. Институтның икенче курсын тәмамлап, мин бик матур күл буенда урашкан пионер лагеренда вожатый булып эшләдем. Лагерьның соңгы көннәре иде. Көннәр кызу тора, коры. Беркөнне балаларны көндезге йокыга яткырып, су коенырга ялгызым гына күл буена килдем. Беркем юк, әкрен генә чишендем, тал төбенә, күләгәгә сарафанымны ташлап, җылы ком өстеннән күлгә таба атладым.

Кинәт артымда кемдер миңа текәлеп карап тора сыман тоелып, сискәнеп, артыма борылдым. Чыннан да, тал төбендә, минем сарафаным янында үзебезнең күрше, заводта абый белән бергә эшләүче Камил миңа карап тора иде. Мин суга кермәдем, борылып, никтер аңа таба атладым. Ул арада Камил аякларын сузып комга утырды, ә мин аның янына килеп чүгәләдем, күрше бит.

— Син каян килеп чыктың, Камил?

— Менә сине күрергә килгән идем.

Ниндидер тынлык урнашты. Мин бер сүз дә дәшмәдем, нигә, дип сорамадым. Камил дә сүзен дәвам итмәде, бары ап-ак, җылы коры комны әкрен генә бер учыннан икенче учына агызды да агызды. Мин дә нәкъ аныңча учымнан учыма ком коя башладым. Без гүя телсезләр идек.

Камил утырган җиреннән кинәт кенә сикереп торды да, тиз генә чишенеп, суга таба йөгерде. Киң җилкәсе әле уңга,

әле сулга чайкалып, атлаган саен кояшта янган мускуллары уйнады. Кулларын киң җәеп ул суга сикерде һәм колач салып кызу-кызу йөзә башлады.

Аның әтисе юк, кайчандыр һәлак булган, әнисе аны ялгыз гына үстерде. Яхшы укыса да, Камил укуын дәвам итә алмады, заводка эшкә керде.

Ул озак йөзмәде. Судан чыгып киенде дә:

— Иртәгә шушы вакытта тагын килермен, көт, яме, — дип агачлар арасыннан олы юлга таба китеп барды.

Шул көннән соң мин берничә мәртәбә күрше егете Камил килер дип бу урынга килгәләдем, әмма ул күренмәде. Минем тагын шулай табигать кочагында аның белән янәшә утырып, берсүзсез учтан учка ком коясым, шул коры комның җылысын учымда тоясым килде бугай.

Ә ул башка килмәде. Шулай вәгъдәсез булалармы?! Ул бит үзем килермен, син дә кил, дигән иде, катгый һәм бик ышанычлы итеп әйткән иде. Су буендагы таллар шаһит.

Ник соң ул килми? Бу шөбһә минем бөтен барлыгымны яулады, күңелемне биләп алды. Егетләр шулай вәгъдәсез, ялганчы була икән, дигән шикле, ямьсез уйлар борчыды.

Әллә мин аны яратаммы соң? Үземнең күңелемне тыңлап карыйм. Аны күрәсем, сөйләшәсем, елмаясым, аңа үпкәлисем, ялындырасым, аннан җылы сүзләр ишетәсем килә башлады.

Моңа кадәр Камилгә карата мондый хисләрем уянганы юк иде. Көн дә диярлек бер-беребезне күрә идек, ул безгә кергәли иде. Гап-гади күрше егете, мөлаем, җитди, азсүзле, оялчан.

Ә менә ни өчендер минем лагерьда ничек яшәвем белән кызыксынган. Килгән.

Мин аның йөзен, кояшта янган тәнен күз алдына китердем. «Мин иртәгә килермен!», — дигәндәге шат тавышы колагымда яңгырады.

Юк, ул комлыкка бүтән килмәде. Нигә килмәгәндер, белмим.

Менә соңгы көн. Саубуллашу учагы кара август төнен урталай ярып, ялкынын, очкыннарын күккә чөя. Учак яны чыр-чу, көчле көлү тавышы белән тулы. Әле урысча, әле татарча җырлар яңгырый.

Ә иртән соңгы линейка, соңгы рапорт. Лагерь булган мәйданчыкта үләне тапталган түгәрәкләр, соңгы учак күмерләре генә калды.

Мин үзебезнең өй янына килеп җиткәч, баскычтан үзебезнең катка менгәндә үк өйдә әнинең тавышын ишеттем. Ишекне киң ачып, алгы бүлмәгә утүгә әни каршы чыкты.

— Ай-һай, балам, кояшта булу сиңа килешә дә соң! Көньяк гүзәлләренә охшап калгансың. Сине күпләр танымас та инде, ә күзләрең... ә күзләрең!.. — дип, миңа соклануын яшермәде.

Мин дә ишек төбенә эленгән көзгедә үземне беренче кат күргән кебек бик озак карап тордым. Йөзем ябыграк та, җитдирәк тә кебек тоелды. Куе кара кашларым бераз өскә күтәрелгән, кара каләм белән сызган кебек ясалмарак. Керфекләрем генә бераз кояшта уңган, күзләремнең ялтыравын яшерә алмый иде.

Үземә үзем ошап куйдым. Йә, Ходаем, нинди чибәрлек! Йөземдә моңарчы булмаган нindидер яңалыклар ачтым, күземнең тирән бер җиреннән яктылык сирпелә, күңелем скрипка кылы кебек киеренке, гүя кемнеңдер кулы кагылу белән җырлап җибәрермен кебек. Ә әни үзенең үткен күзләре белән миндәге бу үзгәрешләрне җил-җил атлап өй янына якынаюымнан ук сизгән, күрәмсең, каршысына килеп басканчы ук шау-шу куптарып, соклануын тыя алмады.

Берничә минуттан әни өстәл әзерләде. Мин үзебезнең өстәлне, чәй тәлинкәләрен, иске чәйнекне сагынганмын, бертуктаусыз сабынлап юудан буявы төссезләнгән өстәл җәймәсен сыпырам. Әни дә үзенең сагынуын яшерми, миннән күзен дә алмый, әтинең эшендәге уңышлары, бакчадагы җимешләр, кемнәрдән хат килгән, кемнәр кунакта булып киткән, барысын, барысын бәйнә-бәйнә сөйли, үзе бер көлә, бер сабыр гына күз яшьләрен сөртеп ала. Әти командировкада, озакка, берничә айга каядыр җибәрелгән. Мин лагерьда шуны да белми яшәгәнмен.

Абыем Мизхәт үзенең уңышлары турында сөйли. Заводта аңа бишенче разряд биргәннәр. Ә энем Шәүкәт никтер кымырҗый. Бер кузгалып, бер утырып азапланганнан соң, ул өстәл яныннан кузгалды да:

— Рәхмәт, әни. Абый, мин малайлар янына... Мөмкинме? — диде.

Ул һәрчак әти өйдә юкта абыйдан рөхсәт сорый, чөнки абый бервакыт та аның соравын кире какмый. Ләкин бүген бөтенләй киресе булды:

— Утыр әле! — диде абый, кашын җыера төшеп. Мин аның бу кыяфәтен күптән күргәнем юк иде. — Сиңа бик җитди сүз бар. Менә Мөслимәнең кайтуын бәйрәм иттек, сөенештек. Булды. Инде сүз синең турыда, җитдирәк һәм күңелсезрәк.

— Нәрсә булган, улым? — дип, әни чынаяк юган җиреннән туктап калды.

— Булган, әни, булган. Улың Шәүкәт чак кына төрмәгә эләкми калган. Ә Камилне кулга алганнар. Бүген заводта ишеттем.

—Камилне?! — дидем мин үз-үземне тыя алмыйча.

Тамак төбенә нидер килеп тыгылды, телем аңкавыма ябышты. Башка бер генә сүз дә әйтә алмадым. Урынымнан торып, дулкынлануымны, йөземнең януын күрсәтмәс өчен тәрәзә янына килдем. Мине күз яшьләре буа башлады. Менә ни өчен ул минем янга комлыкка килүдән туктаган икән. Төрмәгә эләккән, дигәнен ничек аңларга?

Өстәл янында сөйләшү дәвам итте.

— Беркая да бармыйсың, Шәүкәт.

— Ярар, абый, бармам.

— Син ничек ул шайкага барып эләктең?

— Эләкмәдем, абый, аларның тәрәзә алып өй эченә керүләрен күзәтеп кенә тордым. Мин үзем генә түгел, әнә егерменче йорттан Сашка белән икәү идек.

Мин тәрәзә янында артык озак торуымны сизенеп, борылдым. Үз-үземне кулга алдым.

Абый Шәүкәттән сорау алуын дәвам итте.

— Ә Камил кем белән иде?

— Алар өчәү иде, Камил, Баров Вася һәм Шустов Коля.

— Камил шул әтрәк-әләмнәргә ияргәнме?

— Ияргән инде, мин дә аның белән идем.

— Камил дә тәрәзәдән өй эченә кердеме?

— Юк ул кермәде, тәрәзә төбендә калды. Ә без Сашка белән куак төбендә яшеренеп тордык. Милиционерлар килгәч...

Мин шунда телгә килдем.

— Абый, Камил бит карак, өй басучы түгел, аңа ярдәм итәргә кирәк.

— Ничек, Мөслимә? Камилнең ул юлга басуына мин дә ышанмыйм.

Мин абыйның Камил турында әйткән бу сүзләре өчен рәхмәт әйтергә теләдем. Әйе, беркатлылык, артык ышанучанлык аркасында нindидер ялгыш адым ясалган. Камилне чыгарырлар, акларлар. Ул бит бернинди шайкага да кушылмады, әнисе ялгыз, тәртипле хатын. Камил дә тыйнак, азсүзле булып үсте. Менә тиздән солдат хезмәтенә алынырга тиеш. Эчми, тартмый.

Ә Вася белән Коляның кем икәннәрен мин бик яхшы беләм. Камил төрмәдә. Мин аны су буенда комлыкта янәшә утырып сүзсез генә бер учтан икенче учка ком коярга теләп ничә көн рәттән анда бардым. Ә ул калын стеналы, тәрәзәләре рәшәткәләр белән капланган теге каһәр суккан йорт эчендә икән. Ул йорт эче кабер эче кебектер, андагы кешеләр дә үлекләр кебек җансыз, төссез, сап-сары, нурсыздыр. Анда бер тавыш юктыр, кабер тынлыгыдыр. Шунда Камил. Ул, мөгаен, аны бөтен кеше оныткан, дип уйлыйдыр.

Мин ул төнне керем дә итмәдем. Пионер лагерендагы шау-гөр килеп үткән ямьле, якты көннәрне менә шундый йокысыз төн алыштырды.

Иртән, якты кояш нурлары тәрәзәгә төшкәч, өйдә хәрәкәт башланды. Әни торып тиз генә юынып алды да чәй кайнатты, аннан абый торып кырына башлады. Торырга кирәк, күзне йомып ята торгач, арып беттем. Тордым, киендем, юындым.

— Нәрсә булды сиңа, Мөслимә, син бүген үзеңә, кечәге пионерочка-тәрбиячегә бөтенләй охшамагансың, — диде абый мине күреп, нindидер ясалма күтәренке тавыш белән. — Әллә син йокламадыңмы? Күзең шешенгән, йөзең суырылган.

Юк, мин көзгегә карамадым. Әмма карамасам да беләм, мин бүген инде үзем түгел. Абыйның үткен күзләреннән минем кичерешләрне яшереп буламы соң? Әни дә мине күреп аһ итте.

— Ни булды, балам? Әллә авырыйсыңмы?

Минем кыяфәтем гомере буе балаларының сәламәтлеге, исәнлеге өчен үзенең сәламәтлеген бирергә әзер торучы әнине аягыннан ега язды.

Ул кулларын күкрәк алдында кушырып, миңа карап башын чайкап, ни уйларга белми карап тора бирде.

Мин карашымны идәнгә төбәп:

— Мин Камилнең карак, өй басучы икәненә ышанмыйм, — дидем.

Әни, күрәмсең, барын да аңлады.

— Я, ярар, балам, мин дә ышанмыйм. Денсез, имансыз бала түгел, ничә ел күрше булып яшәп, аның кем икәнен яхшы беләбез. Абынгандыр, ялгышкандыр, күрәмсең.

Әнинең «күрәмсең» дигән сүзе миңа аның тулы килеш бу сүзләрен ихластан әйтмәве кебек тоелды.

— Мин, әни, аңа ярдәм итәргә тиеш.

— Ничек? Нәрсә белән?

— Мин аның янына барам.

Абый моңа гаҗәпләнмәде. Ул минем бу сүзләрнең озак уйлап, төне буе газап чигеп туган фикер икәнен аңлады, ахыры. Аның йөзе яктырып китте. Әйе, ул минем ныклы карарым, катгый сүзем, чын кешеләрчә эшләргә тиеш гамәлем икәнен аңлады.

— Әйе, әйбер алып барырга онытма, передача,—дип куйды.

— Әйбер дә алып барырга, аңа ышанучылар, аны яратучылар бар икәнен әйтергә кирәк,—диде әни дә.

Абый эшкә китте. Чыгып китәр алдыннан, ишекне ачкан килеш, ул ни өчендер миңа серле итеп күз кысты,

Минем төрмә дип аталган вак-вак тәрәзәле биек ак йорт яныннан узып йөргәнем бар. Яныннан узганда мин ул йортка карарга да курка идем, әллә ничек шикләнә идем. Ә бүген шул йортның ишеген ачып эченә керергә җыенам. Ә ничек керергә? Кемгә мөрәҗәгать итәргә? Мин берни белмим. Әмма бүген үк барырга, мөмкин булса, күрергә, җылы сүз әйтергә тиеш мин.

— Нәрсә алып барырсың микән, кызым,—диде әни. — Помидор бар, йомырка да бар, әнә бакчадан алмалар алып кайттым.

Шул вакыт энем Шәүкәт тә уянып, аш бүлмәсенә чыгып басты.

— Син кая?

— Камил янына.

— Син нәрсә, кыз башың белән... Мин үзем аның янына барам.

— Син?! Син егет була алмагансың, качкансың... Ә мин менә кыз башым белән аңа ярдәмгә ашыгам.

— Син акылыңдамы, Мөслимә? Үзеңне кулга алсалар...

— Мине беркем дә кулга ала алмый. Мин аның гаепле түгеллегенә ышанам.

Күптән түгел генә утыртылган паркның яшь агачлары арасында юл буендагы зәңгәр эскәмиягә утырып, бераз төрмә тәрәзәләренә карап тордым да, үземнең бирегә килүем дөресме, ялгышмы дип уйлана башладым. Дөрес! Дөрес! Тик менә кайсы яктан керәсе икән? Кемгә мөрәҗәгать итәсе? Шушы сораулар минем миемне борауллады. Ниһаять, шикләнеп торуым өчен үз-үземне битәрләп, урынымнан торып бастым һәм ныклы адымнар белән төрмәгә таба атладым. Кулымдагы камыш сумканы кысып тоткан килеш, берничә метрлы бу араны мин бик озак үттем бугай, ул юл миңа бик озын тоелды. Төрмә капкасы төбендә үрә басып торучы яшь кенә милиционер янына барып туктадым. Ул исә минем сумка эчендәге кызыл помидорлар, алмаларны күреп, кулын тиз генә козырегына тидереп алды да, елмаеп:

— Передача китердеңме әллә, чибәркәй? — диде.

Мин түбән карап, башымны селектем, ә ул каян керергә, ничек сөйләшергә кирәклеген кыска җөмләләр белән аңлатып бирде. Мин теш арасыннан гына рәхмәт әйттем, тавышымны үзем дә ишетмәдем. Яшь милиционер өйрәткәнчә атладым да атладым. Беркемне күрмәдем, каршы очраучыларга күтәрелеп карамадым. Минем кем янына килүемне дә, кем булуымны да бөтен кеше беләдер, кайсы кызганып, кайсы гаҗәпләнеп, кайсы көлеп миңа карыйдыр кебек тоелды. Ниһаять, төрмәнең ишек төбенә якынлаштым. Гадәтемчә, тәрәзәләренә күземне күтәреп карамадым. Бәлки шул тәрәзәләрнең берсендә Камил мине күреп алгандыр, миңа кул болгыйдыр, мине күреп гаҗәпләнгәндер. Авырдыр аңа монда утыру, бик авырдыр. Мин бу газаплы юлның

тизрәк бетүен теләдем, әмма нәкъ шушы юлдан тагын әллә ничә тапкыр үтәргә туры киләчәген аңлыйм, бернинди икеләнүсез, үкенүсез үтәргә әзер идем.

Ишекне ачып кердем. Ишектән керү белән — түбән төшә торган баскыч, ә аста, киң подвалда, тәрәзә янында, озын чират сузылган. Кулларына төенчек тоткан чытык йөзле хатын-кызлар бер-бер артлы басып катып калганнар. Беркем дә сөйләшми, бер-берсенә карамый, һәркайсының үз кайгысы, үз язмышы.

Мин иң соңгы булып баскан чал чәчле, бите җыерчыклар белән ергаланып беткән хатын янына килеп туктадым. Ул миңа таба борылып:

— Ә гариза яздыңмы соң? — дип сорады.

— Юк, нәрсә, гаризага да язаргамыни?

— А как же. Ике экземплярда, дежурныйга тапшырырга.

Минем гаризамны алып укыгач, кизү милиционер язу өстенә нидер сызды да, бер зур амбар кенәгәсен бик озак актарганнан соң:

— Бар андый кеше, рөхсәт, — диде.

Мин теге чал чәчле апа янына кабат барып бастым. Хатын тагын миңа таба борылды.

— Синең кемең?

Мин дәшмәдем.

—Атаң?

— Юк.

— Ирең?

— Юк ла.

— Егетең?

Мин уйга калдым. Ул бит миңа беркем дә түгел. Ярый әле кизү милиционер мондый сорау алу үткәрмәде. Нәрсә дияр идем?

— Ә минем ирем монда, — диде хатын. — Инде дүртенче елын утыра.

Подвал эче тынчу. Кайнар бәрәңге, алма, ипи, тозлы балык исе килә. Менә мин дә тәрәзә янына килеп җиттем. Камыш сумкамны кабул итүчегә сузган идем, ә ул яньчелеп беткән киң поднос төртте:

— Сал шунда, нәрсәң бар!

Аннан стена аша: «Кулга алынган Галиәкбәров Камилгә», — дип кычкырды.

— Следующая!

Мин подвалдан өскә күтәрелдем, урамга чыктым, колагымда һаман «кулга алынган» дигән сүз яңгырады, бит очлары чәнчеп-чәнчеп кызышты. Күңелемдә авыр, изә торган хурлык тойгысы таш булып тоелды. Мин Камилне күз алдына китердем. Теге юан кеше Камил утырган камераның ишеген ачар да:

— Тоткын Галиәкбәров! Передача! — дип кычкырыр.

— Миңамыни? — дип гаҗәпләнер Камил, яткан җиреннән сикереп торып.

— Сиңа, сиңа. Кемнән көткәң идең? Әниең түгел, чибәр кыздан!

— Булмас, минем бернинди чибәр кызым да юк, — дияр Камил.

Ул мине күптән оныткандыр, тал төбен дә, ап-ак җылы комны да — барысын да оныткандыр.

— Бар инде, бар, — дияр юан абзый. — Ал әйдә, ал, алып килгәннәр бит, — дияр.

Камил алыр да, уйга калыр. Кем булыр? Кыз кеше? Аның бит әнисеннән башка беркеме дә юк, апасы да, сеңлесе дә. Кинәт ул мине исенә төшерер. Мөслимә! Мөслимә!

Берничә көннән мин тагын төрмә капкасы төбенә барып бастым. Бу юлы мин Камил белән очрашу таләп итеп, көрәшү өчен, сөйләшү өчен килдем. Абый суд булганын, Камилгә ике ел ярым срок биргәннәрен әйткән иде. Акылым белән һәрбер гаеп эш җәзасын алырга тиеш икәнен аңласам да, җаным белән, йөрәгем белән Камилгә бирелгән бу җәза срогын дөрес дип һич кабул итә алмадым. Ә ничек итәсең? «Камил—әйбәт егет, дип кычкырып, «дөрес түгел, дөрес түгел!»—дип тәкрарлап кына хөкемдарларны йомшарта алсаң иде дә ул. Камил белән нәрсә турында сөйләшермен соң мин? Сүзләр, фикерләр күп, әмма алар ниндидер хаос хәлендә, тәртипсез, чуалчык. Ә чуалган фикерләрне җеп кебек җайлап суырып кына чыгарып, нәфис тә, нәзек тә, өзелмәслек тә итеп булырмы?

Мин капка төбендә бик озак тордым. Иртәнге йомшак җил әле бер ягымнан, әле икенче ягымнан бәргәләде, агачларның сирәк-сирәк кенә саргая башлаган яфраклары җил иркендә асфальт буйлап әрле-бирле йөгерештеләр. Көрәшү

көтеп, уңга-сулга үтеп-сүтеп торучы хатыннарны берәм-берәм төрмә капкасына уеп тишелгән тәрәзәдән чакырып алдылар.

— Хәсәнова Мөслимә!

Мин йөгерә-атлый капкадагы тәрәзәгә килдем һәм рөхсәт язуын суздым.

— Үтегез!

Кечкенә капка эченә үттем. Ниндидер гаҗәеп көчле дулкынлану бөтен гәүдәмне яулап алды, эчемдә нидер дер-дер калтыранды, аякларым кыйгаеп-кыйгаеп китқәләде. Бу таш диварлар эчендә мин югалып калдым. Аннан бер ишеккә керттеләр, ике мәртәбә паспортымны һәм пропускны тикшерделәр. Озын коридор башында бер кечкенә бүлмәгә килеп җиткәч, кизү:

— Утырыгыз, бераз көтегез, — диде.

Кизү — олы яшьләрдәге абзый, күп кайгылар, язмышлар, күп күз яшьләре шаһиты булырга тиеш, үз эшенә күнегеп беткән, хәрәкәтләре салмак, ул миңа бар нәрсәгә битараф кебек тоелды. Ул арада бер ишек ачылып, кемдер эчтән:

— Рәхим итегез, — диде.

Мин тимер рәшәткәләр белән бүлгәләнеп беткән бер бүлмә эченә кердем. Рәшәткәнең теге ягында яшь кенә сержант бер урында катып калган. Мин егылып китүдән куркыпмы, бу төш кебек мәхшәрдән тәмам арыпмы, тыңлаусыз бармакларым белән рәшәткәнең салкын тимеренә чытырдапябыштым, тын алырга, тирә-ягыма карарга куркып, катып калдым. Озын коридорның теге башында ишек ачыла башлады, тимергә тимер ышкылып, ямьсез чыгырдавык тавыш чыгарды. Йа Хода! Шул ишектән Камил килеп чыкты. Ишек тагын ямьсез тавыш чыгарып тиз генә ябылды. Камил миңа таба атлады. Аның иреннәре нәрсәдер пышылдады, ахры, селкенеп алдылар һәм ул миңа якын килеп, куллары белән тимер рәшәткәгә ябышты, ә мин аңа карап, гүя телсез калдым: мин аны танымадым. Бите җир төсендә күм-күк, иреннәре зәңгәр, коңгырт күзләре генә шул килеш нурлы, зуп-зурлар. Күзләрендә моңсулык түгел, ә хаксызлыкка рәнҗеп монда очрашуы өчен миннән гафу үтенү кебегрәк бер ят очкын чагылып китте. Ул елмаерга теләде бугай, иреннәре кыймылдап алды, аннан тораташтай

катып калган сержантка таба карап алды да, миңа текәлде. Минем йөздә, карашымда нидер эзләде бугай: кызгану, гаепләү, үпкәләү, инанмау... Юк, юк! Тик берсе дә миндә юк иде. Үземнең аңа ышануымны, гаепләмәвемне, хәтта яратуымны менә шушында, тимер рәшәткәләр эчендә әйтергә тиеш. Ничек соң ул сүзләрне әйтергә?! Нинди сүзләр табарга?

Безнең сүзсез карашып торуыбыз озакка сузылды. Тик шул сүзсез карашып тору барысын да әйтте бугай.

Передачаларны... Мизхәт абый кушкандыр инде... — диде Камил нидән сүз башларга белми.

— Юк, мин үзем...

Без тагын берничә юк-бар сүз алыштык. Янында өченче кеше басып торганда нәрсә сөйләшергә мөмкин соң?! Бигрәк тә моңарчы уртак берние дә булмаган ике юләр арасында.

— Миңа ике ел ярым...

— Кирәкми, беләм...

— Алар... мин бит белмәдем...

Әйе, Вася белән Коля бу көнне теге йортка өченче тапкыр килгән булганнар, ә Камил очраклы рәвештә аларга ияргән, һәм нәкъ шул көнне тегеләрне эләктергәннәр. Камилне бу эштә бергә катнашкан дип, тыңлап та тормаганнар.

Сержант баскан урынында бераз таптанып алды да:

— Вакытыгыз бетә, өч минут калды, — диде.

Без бит әле берни дә сөйләшмәдек, мин аңа бер генә җылы сүз дә әйтә алмадым, ярты сәгать үткән дә киткән.

— Мөслимә, — диде Камил кабаланып. — Мине син гаеплисеңдер, мин синең алдыңда, завод, Мизхәт абый алдында бик зур гаепле.

— Юк, — дидем мин, тик үз тавышымны үзем танымадым. Юк! — Сүзем коридор буйлап яңгырап китте. — Бервакытта да мин сине гаепләмәдем һәм гаепләмәм. Мин монда килер идеммени?!

— Рәхмәт. Син минем кешеләргә ышануымны арттырдың. Рәхмәт, Мөслимә.

— Сине беркем дә гаепләми, абый әйтә, заводта сине бик кызганалар, ди.

— Ике ел ярым күп түгел, үтәр, кайтырмын, Алла теләсә, гаепсезлегемне эшем белән күрсәтермен.

— Ә мин сине көтәрмен.

— Мөслимә...

Бу сүзләр ничек минем телемә килгәндер, белмим. Камил аларны ишеттеме, юкмы, белмим, аның рәшәткәгә чытырдап ябышкан бармаклары кысып тотудан кызарып беткәннәр иде. Минем ул бармакларны үз кулыма алып, җылы тыным белән өреп җылытасым килде. Мин аның күзләренә карадым; аның күзләрендә ике тамчы яшь бөртеге күреп, күзләремне алырга ашыктым... Шул мизгелдә миңа илереп караган яшьле күзләре соңыннан минем төшемә кереп җәфалады.

— Күрешү тәмам, — диде сержант, сәгатенә карап.

Шулай ике ел ярым буе Камилем белән тимер рәшәткәләр аша карашлар, хисләр алыштык. Сүзләребез күп булмады, белмим, ул миңа яратам дип әйттеме, юкмы, мин үзем дә ул илаһи сүзне әйтмәдем бугай.

Безнең өйдә Камил турында сөйләшү күп булды. Еш кына Камилнең энисенең яшьле күзләре белән очраша идем. Ул миңа рәхмәтләр әйтә, Камил турында бик күп нәрсә сөйли иде.

Институтта Камил белән булган хәлне, аның янына төрмәгә баруларым, очрашуларымны мин изге бер сер итеп сакладым, очрашырга, мине озатырга теләүче егетләрне үземнән биздерү дә җиңел булмады, әмма нык тордым, көттем. Камилнең котылып чыгуын түземсезлек белән көттем.

Кайчан кайтасын, көнен, сәгатен ул миңа әйтмәде.

— Юк, кирәкми, каршылама, — диде соңгы күрешүдә.

Аны энисе каршылаган. Бу авыр да, куанычлы да, тетрәндергеч тә минутларны ул фәкать энисе белән генә уртаклашырга теләгән, күрәмсең.

Соңгы курс тәмамланып килә. Язгы зачетлар, экзаменнар, ниһаять, дәүләт экзаменнары. Иң җаваплы, киеренке көннәр, һәр минут, һәр сәгать исәптә, мин өйдә ялгыз гына зачетка хәзерләнеп утырам. Кинәт ишек шакыганга сискәнеп киттем.

— Керегез! Кем анда шакып азаплана?

Мин дәфтәрләрем, китапларым арасында күмелеп дигәндәй утырган җиремнән, нидер сизенеп, аягүрә бастым. Ишек һаман ачылмый, һаман шакыйлар. Ишеккә бардым. Ачып җибәрсәм, Камил!

— Син? — дип кычкырып җибәрдем.

Көтелмәгән бу хәлдән мин артыма ава яздым, күз алдымда Камил ниндидер томан арасына югалгандай булды, мин

чайкалдым бугай, Камил минем кулларымнан тотып алды. Йа Хода! Бу көннәрне дә күрер минутлар килеп җитте. Без беренче мәртәбә кулларыбызны берләштереп, бер-беребезгә карап торабыз. Тагын телләр көрмәлде, тагын телсез калдык.

Ниһаять, мин беренче булып телгә килдем:

— Утыр, Камил.

Камил өстәлгә якынлашты, дәфтәрләргә, китапларга күз йөртеп:

— Мин сине эшеңнән бүлдем бугай, Мөслимә, — диде.

Ә мин ни өчендер йөгереп икенче бүлмәгә чыгып киттем, башымны ике кулым белән кысып, көзгегә карадым, тынычланырга тырыштым. Нәрсә булды миңа? Нишләргә? Камил белән рәшәткәләр арасында сөйләшкәндә сүзләр ничектер җиңелрәк әйтелә иде, ә монда, үз өебездә, Камил белән икәүдән-икәү калгач, телсез калдым. Ниһаять, бераз тынычланып, мин Камил янына чыктым. Ул урындыкта тын гына утыра, йөзе караңгы. Мин үземнең юләрлегем, аның янынннан чыгып китүем өчен үземне битәрләп, аның муенына ташландым. Каян килде миңа бу әрсезлек, хәзер дә аңлый алмыйм. Ә Камил минем билемнән кочаклап алды да, беренче тапкыр, кайнар тыны белән бөтен йөземне куырып, иреннәремнән үпте.

Әйе, мәхәббәттә сүзләр күп кирәкми икән. Сүз күп булган саен хисләр саегаядыр, мөгаен.

Мин ни өчендер елап җибәрдем. Бу һич тә хурлык яшьләре, кайгы яшьләре түгел, сөенү яшьләре иде.

— Мөслимә, — диде Камил, кайнар пышылдап, — син булмасаң, син минем янга килмәсәң, миңа ышануыңны белдермәсәң, мин инде, мин булмас идем, йә сынган, йә изелгән яки...

Мин аңа әйтеп бетерергә бирмәдем.

— Җитте, Камил! Без бергә, мин синең кем икәнеңне беләм.

— Миңа башка берни дә кирәкми, Мөслимә.

Аның күзләреннән ике генә яшь бөртеге тәгәрәп төште. Ул күз яшьләрен күрсәтмәскә теләп, башын читкә борды. Ә мин ул яшьләрнең саф икәненә шикләнми идем.

СИКӘЛТӘЛЕ ЮЛЛАР ҮТКӘНДӘ

I

Алар яңа ел кичәсендә поселок клубында таныштылар. Сәхилә ире Павел белән бәйрәмгә килгән иде. Үзенә бик килешеп торган яңа күлмәге, лаклап кабартылган бөдрә чәчләре аны яшь кызлардай сылу, нәфис иткән. Ул үзеннән бик канәгать иде: шаярды, көлде, күңел ачты. Яңа елда ниндидер үзгәрешләр көткән күңеле җилкенде, җилбәзәкләнде. Озак кына вальсларда бөтерелеп, тирләгән битен, муенын кулъяулыгы белән җилләндереп басып торганда, кинәт ул ерактан үзенә төбәлгән зур зәңгәр күзләрне күреп, сискәнеп китте, карашын түбән төшерде. Күзләрен күтәрсә, теге күзләр тагын да әрсезрәк, ашардай булып аңа төбәлгәннәр иде.

Яңа вальс яңгырый башлау белән, куе бөдрә чәчле, зур зәңгәр күзле бу кеше, кызу-кызу атлап, алар янына килеп басты.

— Мөмкинме?

Шуны гына көтеп торган кебек, Сәхилә, иренә борылып та карамыйча, кулларын ят кешенең җилкәсенә сузды. Алар бөтерелә башладылар. Сәхилә бу ирдән күпкә тәбәнәк иде, шуңа күрә, аның йөзен карау өчен башын арткарак җибәреп, ачык кызыл иннек сыланган иреннәрен бүлтәйтә төшеп, ул тегенең сорауларына җавап биргәләде... Ә чибәр кеше бик елгыр һәм күп сүзле булып чыкты. Сәхиләне уң кулы белән үзенә таба кыса төшеп, әллә нинди сораулар яудырды, ә Сәхилә бөгелә-сыгыла көлде, ят кешегә сөрмәләре эченнән серле карашлар ташлады. Музыка туктагач, теге аны култыклап алып, ире янына китереп куйды.

— Рәхмәт, миңа сезнең белән бик приятно булды, — диде Сәхилә аңа туры карап.

Чибәр кеше залның икенче ягына китеп, кемнәр беләндер көлешә-көлешә сөйләшә башлады. Музыка уйный башлагач, Сәхилә тагын тегенең аны биергә чакыруын көтте, үзе көтмәгәндәй кыланды.

— Рөхсәт итегез! Бу юлы чибәр кеше Павелга мөрәҗәгать итте.

— Ә-ә, бу тагын сезмени? — дигән булды Сәхилә.

— Киттек! Алар бөтерелә-бөтерелә Яңа ел кичәсенә

җыелган чуар киемле яшьләр, маскарад костюмнары арасына кереп югалдылар.

— Ә мин сезне көткән идем, — дип сүз башлады Сәхилә, бераз сүзсез генә бөтерелгәннән соң.

— Танышырга вакыттыр, сезгә кем дип дәшим?

— Сәхилә яки Сима.

— Аh, Сима! Можно Саня яки Соня.

— Ярый ничек тә: Соня ни, Саня ни, Сима ни. Ничек атасагыз да ярый.

— Аңладым. Ә мин — Николай. Коля дияргә дә ярый.

Николай шаркылдап көлеп җибәрде. Алар бераз тын гына, сөйләшми генә селкенгәләп тордылар. Ирнең кулы Сәхиләнең билен йомшак кына кысып, үзенә тартты, ә сул кулы хатынның йомшак бармакларын кыскалады, ул аны сыный, эч серен белергә тели иде бугай.

Көтмәгәндә чибәр кеше телгә килде. Сәхиләнең колагына иелә төшеп:

— Сезнең белән тагын кайда очрашырбыз? — дип пышылдады ул турыдан-туры.

Ул инде Сәхиләнең уен аңлап алган иде. Сәхилә исә башын артка ташлап, кычкырып көлеп җибәрде, тирә-якта бөтен кеше көлә иде, җырлый иде, шаяра иде. Беркем дә аның көлгәнен ишетмәде, чөнки мукләнеп бара торган күңелләрне дә шаштыра торган сихри, экияти Яңа ел мизгелләре бик якын иде. Николайның кайнар учы эчендә Сәхиләнең симез бармаклары тирләп чыкты.

Сәхиләнең ире Павел исә баскан җиреннән кузгалмады. Ул Сәхиләнең дәртлелеген дә, көлүен дә аның яшьлегеннән, үзе белән бик бәхетле яшәвеннән дип юрады. Күңеленнән ул, ярый әле килгәнбез, югыйсә, ничә ел инде, әле өй салабыз, әле балалар яшь дип, Яңа елны түгел, башка бәйрәмнәрне, хәтта туган көннәрне дә оныта башладык бугай, дип уйлады. Ул Сәхиләсенең матур итеп биюенә, чибәрлегенә, нәзакәтлелегенә сокланып, елмаеп торды. Үз-үзенә: юк, Пашка, хатыныңны күңел ачулардан читләштермә, әле картаеп өйдә утырырга иртә, ул бәхетле булса, син дә бәхетле, диде. Сәхиләне ул яңа өйләнешкән көндәгечә олы ярату белән ярата иде.

Сәгать унике туларга берничә минут кала Сәхилә белән Павел балалар һәм Сәгыйдә түти янына ашыктылар. Аларны да Яңа ел белән тәбрик итәргә кирәк. Сәхилә, Павелны култыклап, балалары янына ашыга, үзе Николай-ның тәкъдиме турында уйлый. Аның тормышында үзгәреш булачак! Кызык! Үзе тагын акылына килгәндәй булып: «Юләр син, Сәхилә, Яңа ел төнендә бераз салып алган чит ирнең вәгъдәсенә ышанып буламыни?!»—дип уйлый. Ул адымнарын тизләтә төшеп, Павелдан алгарак китә. «Мөмкин, мөмкин! Ышанырга мөмкин!»—ди үз-үзенә. Аннан тагын: «Ә Павел? Ә балалар? О, юк, бу мөмкин түгел...» «Мөмкин! Мөмкин!..»

II

Алар дүрт бала ятим үстеләр. Әтиләре Гыйлемдар сугыштан кайтмады, аның истәлеге булып өчпочмаклы хатлары һәм «похоронка» гына калды. Әниләре Сәгыйдә берсеннән-берсе кечкенә дүрт баланы ничек итсә итте, үстерде, ачмы, ялангачмы, ил белән килгән авырлык, дип түзде. Көн эшләде, төн эшләде. Авыр тормыш аны тупас, холыксыз хатынга әйләндерде. Ачлык-ялангачлыкка чыдый алмый бар ачуын балаларыннан алды. Әллә шуңа, балалары да аякка баса башлау белән бәхет эзләп, кайсы кая, чит-ят җирләргә китү ягын карадылар. Төпчеге Сәхилә дә, унсигез яшькә җиткәч, читтән киенеп-ясанып кайткан таныш-белешләренә кызыгып, беркөнне аңа:

— Әни, әллә мин дә Пермь, Березники якларына барып, эшләп кайтыйм микән, — диде.

— Әй, балам, абыең да чыгып китте дә хат-хәбәре юк, апаң Салисә әллә кайда урыс җирләрендә карт урыска кияүгә чыгып калды, кайтканы да юк. Фәрит әллә кайда югалды. Инде син... Җанымны ашама, беркая да җибәрмим, — дип кырт кисте.

Ул яулыгын башыннан тартып алды да, күз яшьләрен дә, борынын да сөртә-сөртә елап, тутыгып беткән иске тимер караватына ауды. Караватның пружинасы аның авырлыгыннан идәнгә тия язып, шыгыр-шыгыр килде. Сәгыйдә, күз яшьләренә манчылып, мендәргә капланды.

Анасының ялыну, каргауларына карамастан, Сәхилә берничә көннән төнге пароходка утырып, Пермь якларына юл алды. Ике көн пароход идәнендә аунаганнан соң, төш житкәндәрәк бер зур булмаган пристаньда төшеп калды. Урыс поселогында үскән кызга кыюлык тансык нәрсә түгел, шартлатып урысчасын сөйләшә, чибәрлеге күпләрне көнләштерерлек, кайчан гына, кайда гына булмасын, аның сөрмәле кара күзләренә, энжедәй вак кына тешләрен күрсәтеп елмаюына чит-ят бәндәләр дә эреп китә, йомышын үтәргә, ярдәм итәргә ашыга.

Сәхилә бер урман хуҗалыгына эшкә урнашты. Билгеле, урман эше авыр, пристаньда савыт-саба юу гына түгел. Эше авыр, өйрәсе сыек булса да, акчаны яхшы алды Сәхилә. Бер-ике ай эшләү белән өс-башын рәтләде. Челтәрле якалы яшел күлмәк, туфли алып җибәрде. Кызлар белән танцыга йөри башлады. Матур күлмәген киеп алгач, ул күзгә ташланырлык тулы гына күкрәкле, елмайса, егетләрнең һушын ала торган гүзәл булды да куйды һәм урман эшенә төрле яклардан килгән егетләрнең игътибарын бик тиз яулады. Аны танцыга чакырып, сөрмәле күзләренә карап, иркә сүзләр әйтергә, озата барырга, кочаклап үбәргә хыялланучылар күбәйде, егетләр арасында аның өчен әтәчләнеп алулар да булгалады.

Менә киң җилкәле, куе кара кашлы, калын иренле, җир җимертеп эшләргә, кирәк икән, егетләрнең теләсә кайсысын егып, сыртына салырга да күп сорамаучы керәшен егете Павел Петров Сәхиләне озата башлады. Павел яшь кыздан җавап мәхәббәте табуны өмет тә итмәде, сеңлесе кебек итеп, тупас сүзгә урын калдырмыйча, кызга беркемне дә якын җибәрмәү, яклау, саклау өчен озатты. Кочарга, үбәргә омтылмады. Ул Сәхиләгә авылда калган әти-әнисе, яраткан бердәнбер сеңлесе булуы турында һәркөн яңача, китап сөйләгәндәй кызык итеп сөйләде дә сөйләде. Сәхилә исә бу тупасрак керәшен егете янында булганда, бернинди хәтәр хәлләр дә булмаячагына ышанып, аның сөйләгәннәрен тыңлап, рәхәтләнеп көлә торган булды.

Көз җитте. Сәхилә салкын тидереп бик каты авырып китте. Тулай торакта дус кызы аңа мәтрүшкә кайнатып

әчерде. Ә Павел, кызның хәле авырлыгын күреп, аның караваты янына, идәнгә матрас салып, бушлатын ябынып төннәрен йокылы-уяулы үткәрде.

— Паша, синең эшкә барасың бар бит. Бар, тынычлап үз бүлмәңдә йокла.

— Юк, Сәхилә, сине калдырып китә алмыйм...

Павел Сәхиләне моңарчы очрашкан, кочкан һәм үпкән кызлары кебек түгел, бөтенләй башкача, яңа гына мыек төрткән малайларча, шашарлык булып яратты. Әллә үзе яше белән зуррак булганга, әллә авыр эштән тупасланган авыл малаеның килеш-килбәте кызга ошамас, мәхәббәтен кире кагар дип, куркып, эчке хисләрен тыярга тырышты. Әмма ничек кенә йөгәнләргә тырышмасын, кайнар мәхәббәт беркөнне, каты җир кабыгын бәреп чыккан вулкан кебек, йөрәк түреннән ургылып чыкты.

— Яратам мин сине, Сәхилә! —диде Павел. Синсез яши алмыйм, чык миңа кияүгә. Җил-яңгыр тидермәм, өрмәгән урынга утыртмам, рәнҗетмәм.

Сәхилә аның сүзләренең ихлас икәнен аңлады, риза булды.

III

Алар Зәй буйларына, Павелның туган авылына кайтып киттеләр. Сазап бара торган улларының башлы-күзле булуына ата-ана бик куанды.

— Әйдә, килен, төкле аягың белән! — диде Кәти түти, куанычын яшерә алмыйча.

— Әни, синең бер кызың бар, ә Сәхилә сиңа икенче кызың булыр, килен түгел, кызым, диярсең, — диде Павел башка сүзгә урын калдырмыйча.

Икенче көнне алар Зәй буйлап сузылган авыл аша узып, елга ярыннан тар гына сукмак буйлап, әллә канларга бардылар, йомшак әңгер-меңгердә болыннарда, көмеш яфраклы тирәклекләр арасында йөрделәр. Кинәт кенә болытлар кабара башлады, җир өстенә әллә ничек кинәт кенә караңгылык төште. Алар йөгерә-йөгерә авылга кайттылар.

Авыл тып-тын. Фәкыйрь авыл, карга оялары, салам

белән япкан сыер абзарлары, тавык кетәкләре, тәрәзәләрдә сирәк-мирәк кенә тоныкс лампа уты кабынган. Сәхиләгә авыл ошамады.

— Юк, Павел,— диде Сәхилә, — безнең поселокка кайтыйк. Анда электр, пароходлар, зур клуб, ресторан. Без бит әле яшь.

Авылда бераз кунак булганнан соң, алар Сәхиләнең туган җиренә, Данышкага киттеләр. Павел пристаньда төрле эшләрдә эшли башлады, Сәхилә элек үзе эшләгән пристань ресторанына официантка булып урнашты.

Ике елдан искергән өй урынына яңа йорт салып чыктылар. Кияү кеше йорт-җирне бик яхшылап төзәтте, искергән каралты-кура калдырмады. Куллары алтын иде Павелның. Ни тотса — шуны гөл итте, өй эченә яңа шкафлар, урындыклар, агач караватлар аның кулы белән ясалды. Йорт җанлы кеше, нәрсә эшлим, дип сорап тормый. Павел иртүк торып, колонкадан су ташый, мал астын чистарта, капка төпләрен кардан чистартып, эшенә ашыга.

Сәгыйдә исә киявен бер күрүдә үк ошатмады.

— Каян таптың бу тасланмаган утын бүкәнен? —диде кызына, киявен күрү белән.

Җае килгән саен Сәхиләнең колагына ысылдый торды:

— Кара урман карачкысыдыр бу, кулы кул түгел, карашы караш түгел. И Ходаем, бар икән күрәселәрем!

Ул, Павел капка ясаса, кыек җирен эзләде, койма койса, сирәклегеннән зарланды.

— Утынны бигрәк эре итеп яргансың, Паша, үзең кебек тупаслар, — дип кимсетте.

Сәгыйдә түти, урамга чыкса, юкны бар итеп киявен хурлады.

— Яратмый Сәхиләм, яратыр җире бармыни аның?!

Үзенең Павелны яратмавын уңаен китереп көн дә Сәхиләгә әйтә торды.

— Әни, — диде Сәхилә беркөнне. — Нинди генә булса да — ул минем ирем, аның күңеле яхшы, ул акыллы.

— Кит инде! Керәшеннең акылы...

Шуңа да карамастан, Павел белән Сәхилә бик тату яшәделәр. Павел, мин керәшен, дип тормады, нәкъ мөселманча

итеп бисмилласын әйтте, амин тотты, Сәхиләнең якын һәм ерак туганнарын үз итте, туган итте. Ярата, бик ярата иде ул Сәхиләне. Гаиләдә бер-бер артлы өч малай туды. Сәхилә кадерле хатын булып, тагын да чибәрләнде, зифалыгын җуймады. Чәчен кисеп бөдрәләтте, көн дә эшкә матур күлмәк, ап-ак челтәр алъяпкыч, крахмалланган калфак киде. Тышкы кыяфәт, матур кием аның чиренә әверелде.

IV

Яңа ел кичәсеннән соң Сәхилә бик үзгәрде. Тагын да матуррак киенергә, бизәнергә, ак калфагын, алъяпкычын тәфсилләбрәк үтүкләргә тырышты. Николай! Николай! Коля! Кем ул? Ул бит җир астыннан булса да эзләп табармын, диде. Ул бит поселок кешесе түгел. Кем ул?

Бизәкле подносын тотып, су өстендә зифа аккош йөзгән кебек хуш исле чәчәк бөтерелгән кебек җитез һәм җиңел генә Сәхилә өстәлләр арасында заказлар алып йөри иде, ресторанның пыяла ишеге киң итеп ачылып та китте, ишектән, горур атлап, затлы костюм кигән, мәһабәт гәүдәле Николай килеп керде. Ул?! Сәхиләнең бармаклары өстендә генә тоткан подносы чайкалып китте, үзе әллә абынды, әллә сөртенде, кыйгаеп китеп, якындагы бер буш урындыкка утырды. Шәраблы подносын җайсыз гына өстәл өстенә куеп, учлары белән битен каплады. Аның тыны кысылды, йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Йөзеннән кулларын алганда, аның янына официанткалар җыелган һәм Николай басып тора иде.

— Николай Васильевич, Симага әллә ни булды, — диде өлкән яшьтәге официантка Валя.

— Симочка! Симочка! Сиңа ни булды? — диештеләр башкалар.

— Берни дә...

Сәхилә экрен генә урыныннан торды, Николайга карамаска тырышып, өстәлләр арасында йөри башлады, заказлар алды.

Николай Сәхиләнең җитез хәрәкәтләренә, матур калфагы, кечкенә алъяпкычына сокланып, бераз басып торды. Сәхиләне ул Яңа ел кичәсенә кадәр үк ресторанда өстәлләр арасында күреп, гүзәллегенә кызыгып, озак кына карап

торган иде. Сәхилә генә эше белән мавыгып, аны күрмәде. Николай Сәхиләнең бу халәтен бик тиз аңлап алды. Башы әйләнеп китүе — аны күреп каушап калуы икәнен аңлап, тизрәк чыгып китү ягын карады. Тәэсир көчле булган, дип кулларын уды.

Ул бик хәйләкәр, хатыннарның игътибарын яулап ала белә. Бу кошчык кына түгел, мәһабәт аккошларның да муенын борган карчыга ул. Ул белә: хатын-кызга күзеңне майландырып, озаграк карап торсаң, бер-ике мактау сүзе әйтсәң, ул, сихерләнгән кебек, җеби дә төшә, калганына әллә ни зур тырышлык кирәкми. Тик әлегә әрсезләнергә ярамый. Ул үз максатына якын: кошчык аның кулында.

Николай үзенең май кебек йомшак тәнле, искиткеч серле карашлы яшь хатын өстеннән чикләнмәгән хакимлеген, тәэсир көчен сизеп ләззәтләнде.

— Кызлар, кем иде ул — кергән теге кеше? — дип сорады Сәхилә бераздан официанткалардан.

— Николай Васильевич — ресторанның яңа директоры, каяндыр күчеп килгән.

— Ә-ә-ә...

Сәхилә моңа битараф калган булып кыланды, ә үзе бертуктаусыз «аны» уйлады. Ул, чыннан да, җилбәзәк кызларча гашыйк иде.

Кинәт ресторан эче Сәхиләгә гадәттәгедән дә яктырак, матуррак булып тоелды, түшәмдә бәллүр люстралар җем-җем итә, алар, аз гына кагылсаң да, чыңлап матур җыр башлар, илаһи аһәңнәрдән торган оркестрга әйләнер дә бөтен зал Яңа ел кичәсендәге кебек биер, әйләнә башлар кебек тоелды.

V

Берничә көн яңа директор ресторан эченә кермәде, күренмәде. Сагынсын, кабат күрәсе килсен, кошчыкның күзенә чалынырга ярамый. Чыннан да, Сәхилә инде сагына башлады. Ресторанның пыяла ишеге ачылган саен ул ялт итеп ишеккә карады, аны көтте, күрәсе килү бәгырьне телгәләде. Керсә иде! Тагын бер генә күрәсе иде! Ул бүтән һушыннан язмас иде, рюмкалар чайпалмас иде! Яңа ел

алдыннан «аның» белән вальс әйләнүе исенә төшсә, йөрәге чеметеп-чеметеп куя. Ул «аның» көчле, шундый көяз ирләргә генә хас нәфис һәм йомшак кулның дымсу җылысын әле дә үз кулында тоя.

Беркөнне кич смена бетәр алдыннан официантка Валя Сәхиләгә:

— Сине директор үзенең кабинетына чакыра, — диде.

Сәхиләнең йөрәге тагын чеметеп алды. Әйе! Ул Сәхиләне көтә, күрергә тели, ярата.

— Мөмкинме? — Сәхилә кабинетның калын ишеген ачып, бүлмәгә керде. — Чакырдыгызмы?

Ул ап-ак вак тешләрен ялтыратып елмайды һәм әллә кайчангы танышы, әшнәсе янына килгән кебек әрсезләнеп, Николайга таба атлады. Ул инде оят, әдәп дигәннәренә — барысына төкергән иде. Аңа унҗиде яшь түгел. Аның шушы чибәр кешене шашып сөясе һәм сөеләсе килә. Ә Николай аны кабып йотардай булып, хатынга текәлде, теленә, тешләренә сыланган селәгәен йотып җибәрде. Нинди гүзәл кошчык! Ул Сәхиләнең шәрә беләкләрен тотып карыйсы килеп, утырган урынында кыбырсынып алды. Сәхиләнең тулы балтырларын күзләре белән ялмады, аннан карашын өскәрәк юнәлдереп, ак челтәр алъяпкыч астындагы иң ләззәтле урынын күз алдына китерде, күлмәк якасыннан күренер-күренмәс үртәп торучы ап-ак күкрәкләрен, муенын тикшереп, ерткыч үзенең корбанын егып салгач, кайсы җиреннән ашый башларга дип уйлап торган кебек, ач күзләрен ялтыратып, йотлыгып, аскы иреннәрен теле белән ялап алды.

— Саумысыз! Сезне кабат күрүемә мин бик шат, — диде, ниһаять, аңына килеп.

— Ник чакырдыгыз? — диде Сәхилә йомшаграк тавыш белән, чытлыкланып.

— Белмим, — диде директор һәм, башын артка ташлап, эре тешләрен ыржайтып, шаркылдап көлеп җибәрде. Ул көлеп бетергәч тә бик озак шыңгырдап, яңгырап торды. Николай Васильевич Сәхиләнең бу минутта чиксез шат, башын югалтыр дәрәҗәдә бәхетле икәнен бик яхшы аңлый иде.

— Белмим, үзем дә белмим, сине күрәсем, сөйләшәсем килеп чакырдым, — диде ул «син» гә күчеп.

Урыныннан торып, ишек янына килде һәм ябыкмыюкмы икәнен тикшереп, аны этеп куйды. Сәхилә исә аннан матуррак сүзләр, кыюрак адымнар көтте. Бу минутта ул, әгәр Николай, утка ташлан, дисә, сөенә-сөенә ташланырга әзер иде. Директор кабинетының тәрәзәләре зур, биек, якякта урындыклар, өстәлләр елык-елык ялтырап тора, чипчиста. Тәрәзәләрдә кыш бизәкләре, әллә нинди сихри әкият сурәтләре, кышның салкын кояшы күзне чагылдыра, өзекөзек болытлар астыннан чыгып, җирне күзли, бер балкып, бер тоникланып тәрәзәдә шаяра. Шул арада Николай Сәхиләнең ап-ак йомшак беләгеннән эләктереп, башын аңа таба ия төшеп, сул яктагы ишеккә барырга әйдәде.

— Менә монда минем «турецкий сундук», — дип, матур бизәлгән кечкенә бүлмәгә алып керде.

Ап-ак челтәрләр, калын бәрхет пәрдәләр белән җиһазланган бу бүлмәдә бер тәбәнәк журнал өстәле һәм бәрхет белән тышланган кәнәфи тора. Өстәл өстендә озын тәпиле бәллүр фужерлар һәм төрле-төрле төстәге чуар шәраб шешәләре. Сәхиләнең карашы бераз шул шешәләрдә тукталып торды.

— Кайсы ошый? Кайсын ачыйм?

Сәхилә бу «төрек сандыгы»нда эчмичә дә исерек иде, ул көлде дә көлде. Бераздан Николай Васильевич үзенең монда яңа кеше булуын, Г. шәһәреннән күчерелүен, анда зур гына особнягы калуын сөйләде.

— Ә менә җаныма, зәвыгыма туры килерлек хатыным юк, —диде.

Бу көнне Сәхилә өенә бик соң кайтты.

VI

«Төрек сандыгы»нда очрашулар ешайды. Алар өчен бу очрашулар ихтыяҗга әйләнде. Сәхилә өйдәгеләрне башта алдады: сменада кемдер авырып киткән, аны икенче сменага калдырганнар. Әмма без капчыкта ятмый. Бу яшерен очрашулар кеше телендә төрле бизәкләр белән баетылып, күпертелеп йөри бирде. Павелның колагына гына килеп җитми торды.

Сәгыйдә түти бу яңалыкны ишетеп, көенергә дә, сөенергә дә белмәде. Сөенде: сөймәс сөяк киявеннән котылыр, көенде: ире — мәрхүм Гыйлемдарга охшатып ярата торган оныклары нишләр? Ничек үсәр? Кемгә калыр Наиле? Бик акыллы, эшчән Фәнил белән Рәмиле бик дуслар. Ул алардан башка ничек яшәр? Пашканы өеннән куар, ә балаларга моны ничек аңлатыр? Шушы уйлар күңелен алгысытты, башын авырттырды.

Беркөнне Сәгыйдә түти көзге каршында үзенә-үзе сокланып, көязләнеп боргаланучы кызына сүз башлады:

— Чибәр инде, чибәр, атаң мәрхүмгә охшап, бик чибәр булдың, Аллага шөкер. Тик менә кем өчен бу кадәр сырпаланасың?

— Берәү өчен! — диде Сәхилә күз дә йоммыйча һәм чыркылдап көлеп җибәрде.

— Хак сүз сөйлиләр икән...

— Хак сүз, хак сүз! — диде Сәхилә, куанычын анасыннан яшермәде.

— Кем соң ул урыс? — диде ана бераз пошынып. — Безнең илдә урыс-керәшеннән башка кеше беткәндер шул. Апаң карт урыска чыкты, син керәшенгә чыгып мине утка салдың. Инде бусы — урыс! Ни җитми соң сиңа? Татар беткәнмени соң бу дөньяда?

— Беткән әни, беткән. Пашка — татар бит, керәшен татар түгелмени? Кемгә кирәк ул сөя дә, үбә дә белми торган татар?! Әнә безнең эштә татар хатыннары ирләренең издеваться итүләрен сөйләп бетерә алмыйлар. Эштән кайталар да гыргыр йоклыйлар. Йоклау өчен яшимени соң кеше?! Кочаклый да, назлый да белмәгән ир ирмени ул?! Аның ирлеге корысын.

— И бала, Пашка аз кочаклыймыни үзеңне? Син дип үлә язып тора бит. Сиңа тагын нинди ярату кирәк соң? Аны да сөйми, яратмый, дисәң...

— Син, әни, берни аңламыйсың.

— Кая инде миңа аңларга? Мин ирләр назы күреп яшәмәдем. Тормыш мине кыйнады гына. Сөешеп кенә яшәр елларымда сугыш башланды. Сезне ач-ялангач итмим, дип мин ниләр генә күрмәдем. Миңа да иргә чыгарга була иде, сорап та килгәннәр иде. Сезне кызгандым, ятим булмасыннар, кеше күзенә карап тилмермәсеннәр, дидем.

Сәгыйдә түти тагын күз яшьләренә төелде.

Бераз тынычлангач, ул тагын сүзен дәвам итте:

— Павел килү белән җиде ел бик тату яшәдегез бит, балаларны кызган, һич булмаса, аны кызган!

— Пашка белән җиде ел яшим, Николайның бер төндә назлаган, бер төндә әйткән иркәләү сүзләренең яртысын да ишетмәдем мин! Син бит берни дә белмисең!

Сәхилә һәр сүзгә басым ясый-ясый, елардай булып әйтте бу сүзләрне.

Әйе, Николай назлый белә. Бәллүр фужерларны чыңлатып, чит ил шәрабларыннан иреннәр баллангач, тел — тел түгел, гүя ефәк тасмага әйләнә. Ул хатыннарның башын әйләндерергә маһир кеше. Ничә хатын аның белән очрашудан язмышларын челпәрәмә китереп атты — саны юк. Сәхилә дә кечкенә кәнәри кебек, үзе аның тозагына килеп эләкте. Эләкте дә ычкына алмады. Катлаулы, бик тә катлаулы булып китте аның тормышы. Хатын уртасы җитеп килүче Сәхиләнең мәхәббәте мәхәббәтме, ялгышмы, азгынлыкмы, әллә язмышмы — ул моны үзе дә аңлый алмый иде. Ул бер генә нәрсәне ачык аңлый: ул сөя! Аны сөяләр!

VII

Ямьле яз җитте. Пароходлар йөри башлады. Гашыйклар бу көннәрне күптән көтә иде. Май ахырларында Сәхилә белән Николай Васильевич, кеше күзенә чалынмас өчен, качып-посып, төнге пароходка утырдылар. Аларны беркем дә озатмады. Икесенә ике кечкенә чемодан, бер кул сумкасы — аларның бар әйберләре шул иде.

— Г. да алырбыз, мин сине тутый кош кебек итеп киендерермен. Г. шәһәре Данышка түгел инде, андагы кибетләр! — диде Николай.

Г. шәһәрендә аның чыннан да алты почмаклы үз йорты бар иде. Ул шәһәрдән ерак түгел иске бер бистәдә, Идел ярында. Хатыны аерылып киткәч, өенең тәрәзәләрен такта белән кадаклап, ул Идел пароходчылыгы хуҗалары белән килешеп, Данышкага ресторан директоры итеп күчерелгән иде.

VIII

Павел дөнья куды, бил бөкте, булсын-булсын, диде, күз күтәрми эшләде дә эшләде. Сәхиләнең соң кайтулары аны борчый, күп эшли, көн буе аяк өстендә, арый, талчыга, вакытыннан иртә картаер, дип борчылып та куя. Сәхиләнең сукмаклары болай буталыр, чуалыр, хатыны хыянәт юлына басар, дип башына да китермәде.

Кеше гомере сикәлтәле юл, диләр, дөрес сүз. Шул сикәлтәле юллар гомер арбасының тәгәрмәчләрен югалтмый, тәртәләрен сындырмый үтүләр бик җиңел түгел икән шул.

Иртән Сәхиләсен урынында күрмәгәч, Павел аптырап калды. Төнгә куна калган, эше күп булгандыр, дип уйлады. Балалар иртән торып, әниләрен сорый башлагач, Сәгыйдә түти:

— Әниегез ерак китте, моннан күренми! — дип акырды.

— Кая китте? Кая ерак китте? — диде Павел, гаҗәпләнеп.

— Син утын пүләне белән яшәмәс бит инде! Китте! Кияүгә чыгып китте!

— Кияүгә? Нинди кияүгә? Ә мин? Ә балалар?

— Үсәрләр, үлмәсләр. Ә син үз юлыңны үзең карарсың, атаң-анаң бар, кайтып китәрсең.

— Ышанмыйм, булмас! Сәхилә мине ташламас! Ул мине ярата!

— Ярата! Ярата! Арт ягына карата! — диде карчык шашынып.

Өрлектәй зур гәүдәле, көрәктәй куллы, киң җилкәле Павел, кечкенә бала кебек, үксеп елап җибәрде.

— Сәхилә! Сәхилә! Мине шушылай хур итү өчен, төн йокыларымны калдырып, сине башкалардан сакладыммыни мин?!

Гүя аның алдында Сәхилә утыра, ул аңа мөрәҗәгать иткәндәй, такмаклап, елады да елады.

— Җаным кебек күргән, атам-анамнан артык күреп яраткан Сәхиләм, син нишләдең? Ничек ялгыштың? Мине бәхетсез, балаларны ятим иттең!

— Балалар өчен борчылма, үтермәм, үстерермен. Синнән яхшырак тәрбияләрмен. Синең кемгә кирәгең бар? Карачкы! Синең белән Сәхилә түгел, энә кылый Марҗый да яшәмәс.

Икенче көнне Сәгыйдә, Павел эштән кайтуга, аның әйберләрен бер иске чемоданга тутырып, ишек төбенә үк чыгарып куйды.

— Әнә әйберләрең, дүрт ягың кыйбла, чыгып кит, күземә күренмә, — диде ул Павел капкадан күренү белән.

— Ә өй? Хуҗалык? — дип карады Павел.

— Нинди өй? Нинди хуҗалык? Менә сиңа өй, менә сиңа хуҗалык, — дип, Сәгыйдә ике кулы белән кәҗә тоягы ясап, Павелның йөзе алдында боргалады.

Павел китте. Балалары хакына, суд каршына барырга да, дәгъва белән йөрергә дә теләмәде.

Озак яшәмәде Павел, аны паралич бәрде. Калтыравык куллары белән авызына ризык та каба алмагач, бер рус хатынына өйдәш булып кереп карады. Ул хатын аны кулдан туйдырудан җиксенеп, хастаханәгә озатты, аннан Павел Нәгыймә исемле әбигә күчте. Әби, савабы булыр, дип аны тәрбияләде, авырсынмады. Көз җиткәндә Павел дөнья куйды. Аны якындагы татар авылы зиратына җирләделәр.

Ә Сәгыйдә тутинең элек тә борчый торган тын юллары кысылуы көчәйгәннән-көчәйде. Ул, озак-озак капка төбендәге эскәмиягә утырып горык-горык ютәлли, тыны бетеп, тәмам хәлдән тая. Кечкенә оныклары кайсы кая, алар кем белән нәрсә ашый, Сәгыйдәнең кайгысы юк. Аның үз кайгысы кайгы. Балаларының берсеннән — бер хәбәр юк. Сәхиләсе дә, китте дә, суга баткандай юкка чыкты. Хат та язмады.

IX

Сәхилә өчен яңа тормыш башланды. Бистәгә кайту белән Николай зур гәүдәле, озын мөгезле бер сыер, каз-үрдәк сатып алды. Үзе каядыр эшкә урнашты. Ә Сәхилә авыл өендә йорт эшләренә чумды, өстенә кара халат киеп куя, бау белән бәйләп сыерны көтүгә куа, каз-үрдәккә тугым болгата, ире кайтуга ашау пешерә. Николай исә эшеннән кайтып, өс-башын алыштыра да каядыр чыгып китә. Аңа тегесе ярамый, монысы килешми, ваклана, чәүчәләк, усал. Сәхилә кайчандыр йомшак куллы, шаян сүзле Николайны танымый.

— Син кем соң?! Татарка! Онытма үзеңнең Чыңгыз хан токымы икәнеңне!

Сәхилә еш кына илереп елый башлый.

— Елама, — дип кычкыра Николай.— Елап кемне ышандырмакчы буласың? Пашкаңны сагындыңмы әллә? Бар, ычкын! Отчаливай! Миңа синең кирәгең шул кадәр генә.

Беркөнне Сәхилә токмачлы аш пешерде.

— Мин токмачлы аш ашамыйм, —дип, ир тәлинкәне читкә этте. — Син мине каткан татар дип белдеңме?! Миңа борщ, рассольник пешер, кәтлит кыздыр! Мин урыс өстәле яратам.

— Коленька, — дип ялынды Сәхилә. — Иртәгә борщ та пешерермен, кәтлит тә кыздырырмын, бүгенгә шуны аша инде.

Сәхилә иртүк тора, ире сүз әйтмәсен, дип йөгергәли башлый. Су ташый, сыер сава, аны көтүгә куа, базардан ашау-эчү алып кайта, алҗып-арып тәмам шәлперәеп кала. Хәзер аның исеме — «татарка».

— Татарка, кайчан син чын борщ пешерергә өйрәнәсең соң? Кәтлитең янган, авызга алырлык түгел.

— Татарка, миңа иртән урыннан торганчы ук җылы сөт бир. Миңа яхшы ир булу өчен ач карынга җылы сөт эчәргә кирәк.

X

Николайның бу кыланышларына түзә алмый Сәхилә еш кына үз ягына, туган җиренә талпынды, ләкин юлга акча каян алсын! Билет бәяләре кыйммәт. Ни күзе белән ул ире Павелга күренсен? Ул, бәлки, гафу да итәр, Сәхиләне ярата иде бит. Ничек поселок урамыннан үтәр?! Кешеләр күзенә ничек күренер?! Урамнан узганда артыңнан төкереп калырлар. Ләгънәт укырлар. Әйе артка юл ябык.

Шулай да бер елдан соң, җәйләр җиткәч, ничек итсә итте, Сәхилә юлга акча юнәтеп, әнисе, балалары, Павел янына кайтырга ниятләде.

Пароход Данышкага төнлә килеп төште. Төн караңгысында аның өенә кайтканын берәү дә күрмәде, качып-посып йөрисе булмады. Ул өй янына килде, капкага кагылды,

капка бикле, тәрәзәләр караңгы. Тәрәзәләрдә пристаньның неон лампалары уты чагылган. Ул яшәгән ярымҗимерек бистәдән соң үзенең поселогы аңа искиткеч матур булып күренде. Ул кече капкадан сикереп кенә керде дә тәрәзәгә каракларча гына бер-ике шакыды. Тыңлап торды. Ник бер тавыш, ник бер хәрәкәт булсын, тагын шакыды. Эчтән:

— Кайсы котырганы төнлә борчып йөри? — дип кычкырды әнисе өй ишеген ачып, горык-горык ютәлли-ютәлли сүзен тагын кабатлады:

— Төнлә кем йөри?

— Мин, әни, Сәхиләң бу.

Шәүләләренә озак кына карап тордылар.

— Кая ирең? — Сәгыйдә түтинең беренче сәламләү сүзе шул булды.

— Я, әни, исәнме, саумы? Күрешик, аннан сөйләшербез.

Сүзләр күп булмады. Сәгыйдә бер сүз әйтте дә ютәлләде, тагын әйтте дә буыла-буыла коркылдады.

— Мин озак яшәмәм инде, балаларыңны алып китәрсең, — диде ана.

— Кая алып китим? Үзең сыясыңмы, дип сора. Павел гафу итәр әле, мин бөтенләйгә кайттым.

— Павел?! Павелның теге дөньяга китүенә... — ана бармакларын бөгә-бөгә санап алды, — тагын бер айдан ел тула.

— Ничек?! Әллә... үзенә... кул салдымы?

— Ю-у-к.

Сәгыйдә башын түбән иде. Павелның нинди хәлләрдә яшәве, ничек үлүе турында сөйләде. Таң ата башлады. Ана белән кыз, бер-берсеннән ераклашкан, кайчандыр үпкәләшеп, инде дуслашырга ниятләгән, чит кешеләр кебек коры гына, тын гына ел буена булган хәлләрне сөйләштеләр. Ана тагын беренче җөмләсен кабатлады:

— Ирең кая соң?

— Ир ир түгел, деспот, явызлыкның чигенә чыккан, куркыныч кеше, юха елан булды ул, әни. Сорама, сөйлисем дә килми. Исемен әйтәсем дә килми. Павлик кызганыч... Ул миңа рәнҗеп үлгәндер... ул изге кеше иде, әллә аның рәнҗеше төште микән миңа?

Сәхилә үзен-үзе белештерми чәчләрен йолка-йолка елый башлады.

Ана эндәшмәде, аның әйтер сүзе юк иде.

БӘХЕТ

Аяз ел да җәй көннәрен әби-бабасында авылда кунакта үткәрә. Авыл малайлары белән сай инештә болганчык суда туйганчы чупырдый, җәйге кояшта ком гарәбе кебек карачутыр булып каралып көзгә таба гына әтисе-әнисе белән шәһәргә кайтып китә.

Ә быел ул җәйге каникулга кайтты, чөнки ул, беренче сыйныфны тәмамлап, икенчегә күчте. Инде хәзер аның өчен бу җәй каникул дип атала. Бабасы белән әбисе дә укучы оныкларының кунакка кайтуына куанып:

— Һо, улым Аяз каникулга кайткан!

— Нинди зур үсеп, ябыгып, авылга тазарырга кайткан, — диештеләр.

Җитмәсә, әбисе былтыр җәй аның буен ишек яңагына билгеләп — пычак белән киртекләп куйган иде.

— Бабасы! Бабасы, улың бер сөямгә үскән бит быел. Мәктәптә әллә колагыңнан тартып үстерделәрме сине? — диде әбисе Аязның аркасыннан сөеп.

Көннәр бик эссе, иртәдән кичкә кадәр һава зыңлап тора. Аяз икенче көннән үк малайлар белән су коенырга, кармак салырга йөри башлады. Көн дә иртән әбисе аңа бер стакан кәҗә сөте бирә:

—Эч, улым, күзеңне йом да эчеп җибәр. Кәҗә сөте бөтен тәнгә шифа ул.

Аны эчкәндә Аяз тын алмый, күзен чытырдатып йома. Әнисе дә шулай кушты. Бабасы белән әбисе яши торган авыл бик матур күлләр, урманнар янында, һәр көн иртән Аязның бабасы эре-эре балыклар, төнбоеклар алып кайта. Аяз йокысыннан торуга, әбисе бик тәмле итеп балык кыздырып куя. Ерак күлдән, Сөтлә күленнән алып кайта шул бабасы ул эре балыкларны. Аяз тоткан бармак башы чаклы чабак маймычлары түгел инде. Их, барасы иде шул ерак Сөтлә күленә, күрәсе иде тере балыкларны! Өзәсе иде күл өстендә үскән ап-ак төнбоекларны! Шәһәрдә боларның берсе дә юк бит. Су буендагы тумпак башлы камышлар да, елык-елык килеп торган вак балыклар да. Шәһәрдә кая карама таш җәелгән урам, биек-биек таш йортлар, таш баганалар, таш эскәмияләр, таш сыннар... Анда җәен бөркү, күңелсез... Менә ичмасам авылда рәхәт.

Аяз беркөнне бабасы алып кайткан балыкларын

чистартып яткан чагында йокысыннан уянды. Ишегалдына йөгереп чыкты. Инде кара тәпиле ала песи дә, ак түшле Актүш тә бабасы янында сырпаланалар иде.

— Бабкай! — диде ул бераз ялыныбрак, — алып бар әле мине дә шулерактагы Сөтлә күленә! Минем дә бит бик күрәсем килә шул күлне, тере балыклар күрәсем килә.

— Ярар соң, улым, балай ук ялынгач, алып бармый да булмас. Әнә бит быел ничек зур үсеп кайткансың. Көймәдә йөрергә дә курыкмыйсыңдыр инде.

— Курыкмыйм, бабкай, курыкмыйм! Мин көймәнең читенә чытырдап ябышырмын.

Йокладымы Аяз ул төнне, юкмы, әмма ул бик иртә уянып, күзләрен ачты, сикереп торып утырды. Бабасы йоклаган караватка күз төшерде. Бабасы урында юк иде. Алдаган, бабасы, уятмаган, үзе генә киткән!

Ул йөгереп ишегалдына чыкты. Ә бабасы ишек төбендә биштәрен рәтләп, көсмәненә элеп маташа иде.

— Әллә китәсеңме, бабкай? — диде Аяз ачыргаланып.

— Юк, улым, менә сине уятыйм, дип кенә тора идем.

Алар өйгә керделәр. Идәндә сап-сары җиз самавыр гөжләп утыра.

Әбисе кәҗә саварга чыгып киткән. Өй эче чыгып килүче кояшның якты нурлары белән тулган.

Аяз тиз генә аягына кроссовкаларын, зәңгәр спорт костюмын киеп алды:

— Киттек, бабай, әйдә!

— Юк, улым, син әле кәҗә сөте эчәрсең, әбиең коймак пешергән. Коймак белән чәй эчәрбез. Әле бик иртә. Күрәсеңме, кояш та җир өстенә бер генә адым атлаган.

— Бабакаем, мин йокламадым, миннән башка гына китәрсең, дип курыктым.

— Синсез китәмме соң? Кичтән сөйләштек бит. Бабаң сине кайчан алдаганы бар?

— Юк та...

— Соң шулай булгач...

Аяз, өстәл артына утырып, әбисенең сөтле чәй ясаганын көтә башлады. Әбисе аңа бер стакан җылы сөт сузды. Күзләрен йомып, Аяз, бер тын белән сөтен эчеп куйды да авыз читен кулы белән генә сөртеп алды.

— Тәмлеме, улым?

— Тәмле, әбкәем, рәхмәт.

Ул арада кайнар коймакларны майга манчый-манчый, шикәрне алгы теше белән керт итеп китеп алып бабасы да чәй эчә башлады. Ул бүген чәен өрә-өрә озак-озак эчми, бер-ике коймак белән бер генә чынаяк чәй эчте дә, тиз генә амин тотып, чынаягын этеп куйды.

— Кузгалдык, улым, хәерле сәгатьтә.

— Бабкай, песине алабызмы?

— Юк, улым, песигә балыкны кайткач бирербез. Ул әбиең белән өйдә калсын.

— Актүшне?

— Актүш алсаң — алмасаң да, калмас ул.

Аязның бабасы Кадыйр ишкәгенә биштәрен асып җилкәсенә салды, ә Аязга бер җиңел такта кисәге тоттырды. Кузгалдылар. Актүш туктап нидер иснәнә-иснәнә алдан чапты, һава җиләс, салкынча. Алар башта тыкрыктан бардылар, дусты өен уздылар. Аяз аларның тәрәзәсенә карап алды. Айдар әле йоклап ятадыр, ә менә ул бабасы белән ерак Сөтлә күленә балыкка бара. Әле көтүчеләр дә уянмаган, чыбыркы шартлаткан тавыш та ишетелми. Капка төпләрендә сыер сауган тавыш:

— Тз-тз-тз.

— Тз-тз-тз.

Бәләкәй урамны узып, Ат тавыннан күл буе яланына төштеләр. Күл өстендә ап-ак томан эленеп тора. Күләгәләр бик озын, килбәтсез. Актүшнең колаклары да самавыр торбасы чаклы.

— Улым, сукмактан гына атла, аягың чыланмасын.

Ямь-яшел үлән өстеннән чык кояш яктысында җем-җем җемелди. Аязның бабасы балык тотарга ярата. Ул балык тоту коралларын да үзе ясый. Кышларын ау үрә, питил бәйли, кышка кармак салу өчен селекмә әзерли, кургаштан «ялган балыклар» коя. Яз көне тал чыбыктан мурда үрә. Аяз юл буе бабасының иң оста балыкчы булуын, дөньяда иң яхшы бабай булуын уйлап тын гына аның артыннан сукмактан атлый.

— Бабкай, дим, сине кем шулай балык тотарга өйрәтте?

— Дөнья өйрәтте, улым, дөнья.

— Ничек инде — дөнья? Бөтен кешене дә өйрәтмимени дөнья?

— Теләгән кешене өйрәтә ул, өйрәтә.

— Күрше Сәләхетдин бабай балык тотмый бит, аны өйрәтмәгәнмени?

— Сәләхетдин бабаңны дөнья өйләр салырга, бура бурарга өйрәткән. Ул бит балта остасы.

— Ә Галимәрдән бабайны?

— Галимәрдән бабаңны дөнья мичләр чыгарырга өйрәткән. Безнең авыл өйләре Галимәрдән бабаң чыгарган мичләр белән җылына. Әйе, улым, дөнья шулай ул, берәүләрне тегү тегәргә, икенче берәүләрне машина йөртергә өйрәтә. Менә хәзер күпләрне сату итәргә өйрәтеп килә.

— Ә-ә-ә. Бабакай, синнән дә оста балыкчы юк инде, әйеме.

— Бар улым, миннән дә осталар бар. Әнә Билал бабаң миннән күпкә оста.

— Билал бабай синнән остаракмыни?

— Оста, улым, оста.

Алар шулай иртәнге тын һаваны яңгыратып сөйләшә-сөйләшә таллар белән әйләндереп алынган күл буена килеп җиттеләр. Куе томан әкрен генә эреп юкка чыкты. Тал яфраклары суга коенган кебек юеш, кояшта елык-елык килеп, әкрен генә селкенгәлиләр. Күл уртасында чулт-чулт чабак уйный. Яр буенда яшел чирәмлеккә эреле-ваклы көймәләр каплап куелган. Кадыйр чыклы үләннән эре-эре атлап, үзенең каегы янына килеп, иплән кенә бер ягыннан күтәреп, сыртына төшерде. Аяздан тактаны алып, җайлап утыргыч итеп куды, ишкәген салды, аннан каекны җирдән сөйрәп, күлгә таба алып китте.

Үткән җәйдә Аязның бабасы бу уенчык кебек кенә кечкенә каекны үзе ясады. Аяз аларда кунакта иде. Ишегалдында аунап яткан бик юан агачны бабасы аягы белән типкәләп-типкәләп тирә-ягында бераз йөреде дә, кулына балта алып, учына лач итеп төкереп, әгузе-бисмилласын әйтеп бик каты кизәнеп, балтасын сыртына батырды. Аннан сабына суккалый-суккалый агачтан каерып алган иде зур бер йомычка купты, аннан тагын кизәнде, тагын каерды. Аяз, бабасы селтәнгән саен, күзен йомып алды. Бераздан ишегалды йомычка белән тулды. Бабасы шулай берничә

көн балта белән чапканнан соң, чүмеч кебегрәк балта белән чапты. Күзгә күренеп менә дигән ап-ак көймә хасил булды. Аяз аның эченә дә кереп утыргалады. Берничә көн күләгәдә торганнан соң, бабасы каегын кап-кара сумала белән майлады, тагын киптерде. Ә быел каек инде күл буенда ята. Бабасы ишкәген дә үзе юнды. Ул нәкъ камыр болгата торган калак кебек, әмма зур, сабы бик озын.

— Бабакай, син каегыңны имән агачыннан ясадыңмы?

—Юк, улым, имән агачы бик каты ул, авыр. Каекны мин юкә агачыннан чаптым.

Каекны суга төшергәч, иң алдан Актүш сикерде, аннан Аяз. Ә бабасы кирза итеге белән су эченнән бераз этеп барганнан соң, каекның койрыгына җайлап утырды, ишкәге белән су төбенә терәп этә-этә каекны камышлар арасыннан күл эченә чыгарды. Кояш нурында җем-җем иткән вак-вак йөгерек дулкыннарга бәрелә-бәрелә, каек күл буйлап җиңел генә йөзә башлады. Аяз, үзе күтәреп килгән тактага утырып, ике кулы белән каекның читенә тотынып тын калды. Аңа бик кызык иде. Бабасының ишкәк белән суны ишеп баруы да, көймәнең борынында тын гына утырган Актүш тә, кояшта ялтыраган дулкыннар да, әкрен генә артка чигенгән таллар да, алар белән бергә суда йөзгән кояш та. Ә төнбоеклар! Алар балавыздан әвәләп ясалган шарлар кебек түп-түгәрәк, сап-сары, ә яфраклары аш тәлинкәсе чаклы, җәелеп су өстенә ятканнар. Күлнең суы топ-тонык. Аяз муенын суза төшеп каек читеннән су эченә күз сала.

Күл төбендә ямь-яшел тасмалар, әле бер, әле икенче якка тирбәлеп кояшта ефәк кебек ялтырый, җилферди. Шундый кызык. Ә каекны Аязның бабасы уенчык кебек кенә йөртә, ул гүя чәй тәлинкәсе, җиңел, җитез, элдерә генә.

— Бабакай, су төбендә дә үлән үсә икән, әйеме?

— Үсә, улым, үсә.

— Төнбоеклар нинди матур, ничек күп!

— Сары төнбоеклар әле ачылып җитмәгән. Әнә, ак төнбоеклар ачылган.

— Ах, ак төнбоеклар нинди гүзәл!

— Төнбоеклар алар иң чиста суда гына шулай матур булып, күп булып үсәләр.

— Чиста түгел суда үсмиләрмени?

— Пычрак суда берни дә үсми. Шакшы кушылса, күлләр черирләр, балыклар тончыгалар, төнбоеклар шиңәләр.

Аяз уйга калды. Ничек соң күлләрне, елгаларны шакшыдан сакларга? Тиздән ул бу күңелсез уйларын онытты, каек читеннән чәчрәп-чәчрәп торучы дулкыннарга бармакларын тыкты, аларны су агымы аергалый, селкетә, бармаклар дерелдиләр. И кызык! Су җылы, яңа сауган сөт кебек.

Озак кына төнбоеклар, таллыклар арасыннан йөзә торгач, каек текә ярлы зур күлгә килеп чыкты. Менә шунда инде Аяз үзенең чигенә җиткән куанычын, шатлануын яшерә алмый:

— Бабкаем! Нинди зур диңгез! — дип кычкырып җибәрде.

— Диңгез түгел, улым, күл бу. Менә шушы инде безнең Сөтлә күле. Балыклы, бай күл.

— Шушымыни?

Аязның күзләре ялтырый, аның моңа кадәр беркайчан да бу чаклы да матурлыкны, гүзәллекне күргәне юк. Тар гына тирән, тамактан соң бу киң мәһабәт зур күл өстендә кояш та аңа бөтенләй башкача, биегрәк тә, яктырак та тоелды. Иге-чиге күренмәгән зәңгәр күл өсте, андагы эрелевваклы меңләгән дулкыннарда чагылган кояш күл өстен тоташ шадра көзгегә әйләндергән. Аязның күзләре чагылды. Ә каек Актүшне, Аязны һәм бабасын су өстендә талгын гына тибрәтә.

— Бабкаем, ә балыклар ничек сикерешәләр!

Ул арада камышлар арасыннан берничә үрдәк күккә күтәрелде.

— Чү, улым, әкренрәк. Кычкырып сөйләп, үрдәкләрне өркеттең әнә, күкәй сала торган ояларыннан кузгалдылар.

Каекның борынына леп-леп итеп дулкыннар бәрелә, аның саен су тамчылары көмештәй ялтырап, Аязның да беләкләренә чәчри.

— Бабкай, күрәсеңме, көймә борынында салават күпере!

— Әйе, улым, вак кына су тамчылары кояшта шулай төрле төсләр белән балкыйлар.

— Кызык та соң!

— Чү, улым, балыкларны качырырсың, бик шаулама. Табигать ул тынычлыкны ярата.

Аязның күл өстен яңгыратып кычкырасы, көләсе, җырлыйсы килә. Ул арада Сөтлә ярыннан җил исеп җибәрде, дулкыннар да зураеп каекка лап-лап итеп бәрелә башлады.

— Җил кузгалып тора, яңгыр булмагае,—ди Аязның бабасы үз-үзенә сөйләнгән кебек, чабак та уйнамый башлады, көн бозылмый торсын иде инде.

— Бозылма-ас!— ди Аяз бу кадәр хозурлыктан, яңалыктан шатлануын тыя алмыйча.

Менә Кадыйр агай Сөтлә күленең сөзәгрәк яры буена зур агач янына каегын китереп терәде.

— Актүш! Марш!

Шуны гына көткәндәй, эт җиргә сикерде.

— Аяз улым, Актүш белән шушында гына торыгыз, мин тиз генә мурдаларны карап киләм, — дип Кадыйр агай ишкәге белән тиз-тиз ишә-ишә, яр буйлап китеп барды. Аяз Актүш белән куе печән арасында аунаклашып уйнады, күбәләк куалады, кигәвен тотты.

Тиздән Аязның бабасы каегы белән камышларны аралап ярга кабат килеп туктады. Ә көймәдә! Көймә төбендә эре-эре балыклар, җанлы балыклар чап та чоп бәргәләнәләр иде.

— Тере балыклар! — дип кычкырып җибәрде Аяз.

— Тере балыклар күрәсең килгән иде, әнә, кара инде, улым.

Актүш, бәргәләнүче балыкларга карап, алгы аяклары белән терәлеп, һау-һаулап өреп тә алды.

Берсе, балта сабы озынлыгы, ул очлы тешләрен күрсәтеп, авызын бер ача, бер йома, койрыгын күтәрә, әле дуга кебек бөгелә, атыла, бәрелә.

Монысы чуртан улым.

— Ул мине тешләмәсме?

— Тешләмәс, тешләмәс. Ә менә бу — карабалык, бик тәмле балык, чирләгән кеше аны ашаса, чиреннән терелә, савыга. Ә менә бу зурысы корбан, бик симез, тәмле балык.

Корбан балык дигәне коймак пешерә торган таба чаклы, күзләре кызыл, койрыгы, канатлары бик зур. Карабалык дигәне ала-тилә.

— Нигә, бабакай, чуар ул, ала-тилә?

— Кара балык камыш төбендә кояштан качып ята, яшеренә, шуңа ул чуар.

— Шәһәрдә йөри торган ОМОНнар киеме төсле, әйеме, бабакай.

— Әйе, улым, шулайдыр.

Кадыйр агай каегыннан чыгып, җиргә утырды, һавага карап бераз чалкан ятып торды, аннан оныгына болай диде:

—Бу балыклар, Аяз улым, синең бәхеткә эләккәннәр. Син бик бәхетле булырсың Алла теләсә, яхшы укысаң, тәүфыйклы булсаң, атаң кебек ерак китәрсең, зур кеше булырсың. Кичә мурдаларны синең исемгә атап салган идем. Икесенә дә балык кергән. Менә бит хикмәт нәрсәдә.

Аязны әбисе дә бәхетле булгыры, тәүфыйклы булгыры, дип сөя.

Нәрсә ул бәхет, нәрсә ул тәүфыйк, Аяз моны белми.

— Бабкай, нәрсә ул бәхет?

— Бәхетме? Бәхет ул әтиең-әниең булу, — ди бабасы озак уйлап тормый.

— Тагын, бабкай, тагын?

— Тагынмы? Тагын менә шушындый матур җылы көндә тыныч күл өстендә көймәдә йөзү, балык тоту.

— Тагын?

— Тыныч тормышта, яшәүнең ләззәтен тоеп сөенеп, куанып яшәү, чәчәкләрнең тәмле исен иснәү, кошлар сайравын тыңлау. Тыңла әле, әнә камышлыкта үрдәк кычкыра, ул күкәен салып куана, балаларын чыгара, әнә балыклар чума, күрәсеңме, болар барысы бәхет.

— Кызык! Бәхет ул тыныч тормыш инде бабай, әйеме.

— Әйе, балам, нәкъ өстенә бастың, мин әйтә алмаганны әйтеп бирдең.

Аязның бабасы җирдән торып, киемнәрен какты.

— Булды, улым, әйдә кайта башлыйк, балыклар бозылмасын. Актүш! Көймәгә!

Алар тагын сихри күл өстендә әкрен генә яр буйлап Сөтләдән тамакка якынлаштылар. Балыклар да әкренләп тынды. Актүш акыллы гына әле бер колагын, әле икенче колагын шомрайтып, балыкларны күзәтә.

— Аяз! Беләсеңме, бүген кичкә синең әтиең белән әниең кайтырга тиеш.

— Ур-ра!—Аяз көймәдә аягүрә басты.

— Чү, балам, әкрен, көймә янтаймасын, тыныч кына утыр, кыймылдама.

Бераз баргач Аяз тагын бабасына сорау бирде.

—Бабкай, тәүфыйк нәрсә ул?

— Анысын, улым, әбиеңнән сорарсың инде. Ул бик яхшы аңлатыр.

Сөтләдән тирән тобага кергән урында ак төнбоеклар бик күп. Кадыйр каегын шунда борды. Ишкәгеи көймә эченә салып, берничә ак төнбоек өзеп алды.

— Әбиеңә бүләк итәрсең, һай, ярата әбиең ак чәчәкләрне,— дип Аязга чәчәкләрне сузды.

Алар авылга кайтып җиткәндә кояш хәтсез генә күтәрелгән иде.

КАЙТТЫМ СИҢА, ГАЗИЗ ТУГАН ҖИРЕМ

(Әдәби очерк)

Бу бәян Бөек Ватан сугышы ветераны, «Сәламәтлек саклау отличнигы», югары категорияле хирург, Мәскәү өлкәсе табиблар җәмгыятенең хөрмәтле әгъзасы, галим, медицина фәннәре кандидаты, Германиянең Магдебург шәһәре Медицина Академиясе гыйльми советының хөрмәтле әгъзасы, Милевско шәһәренең Почетлы гражданины, мәшһүр хирург Бәдретдинов Рәшит Заһретдин улының гыйбрәтле тормыш юлы турында.

Монда бәян ителгән хәлләр, вакыйгалар Рәшит аганың көндәлек дәфтәрләренә, документларга, хатларга таянып, дуслары һәм гаилә әгъзалары сөйләве буенча үзе исән чагында ук языла башлаган иде. Кулъязманың күп өлешен ул үзе укып, кирәк урында төзәтмәләр ясады.

Үзе инде бакыйга күченде. Урыны оҗмах-та булсын!

ЕЛЛАР, ЮЛЛАР, УЙЛАР

Безнең гомер уен түгел, бәйрәм түгел,
Бер кайгысыз кеше булса, адәм түгел.

Г.Тукай

Бүген әллә ниткән каршылыклы уйлар, хисләр, уфтану, бетмәс-төкәнмәс үкенү биләп алды Рәшит Бәдретдиновны. Ямьле, нурлы кояшлы яз. Ул, эштән кайтып, өс-башын алыштырып, тамак ялгап алды да шәфәкъ нуры белән өртелгән түрьяк тәрәзә янына килеп утырды. Ни укыйсы, ни телевизор карыйсы килми иде аның. Тәрәзәсе алдындагы ямь-яшел яфракларга күмелгән бөдрә каен аның күңелен алгысытып җибәрде, яшьлеген исенә төшерде. Ул үзе дә сизмәстән, бөтен күкрәген тутырып, сулыш алды. «Үтте дә китте яшьлегем...» дигән җырның көе колагында яңгырагандай булды. «Үтсә соң!» — дигән тискәре тойгы миенә сукты. «Үтсә соң! Дөнья йөзендәге дистәләр, йөзләр, меңнәрнең гомере минеке кебек бай, эчтәлекле, катлаулы һәм куанычлы булсын иде әле!» — дип уйлады ул.

Ике бүлмәле, иң кирәкле җиһазлар гына урнашкан фатирында ул менә ничәнче язны берүзе каршылый. Берүзе, әмма ялгыз түгел. Киләләр. Дуслары, яшьтәшләре, якташлары, хезмәттәшләре килә. Хатын-кыз затыннан да аның ялгыз тормышын ямьләргә теләүчеләр бар. Әмма алар инде беренчеләр түгел, алар инде болай гына.

Шөһрәтле, данлыклы, табибчылыкның могҗизасына, даһиена әверелгән, җитмеш яшен инде күп еллар элек билгеләп үткән хирург, галим ул Рәшит Бәдретдинов.

Акылны да, уңганлыкны да, зиһенне дә, күңел байлыгын да табигать бер дә кызганмый, мул итеп биргән аңа. Шулай да ул бервакытта да үзен күрсәтергә, көч-гайрәтен файдаланып, халык теленә, тарихына кереп калырга теләүче-ләрдән булмады. Ул бервакытта да кыйбласын алмаш-тырмады, кайда гына яшәсә дә, кемнәр белән аралашса да, үзен чын татар, чын мөселман итеп тотты, шуның белән горурланды, сөенде. Адашмады, бозылмады, имансыз булмады.

Шулай да ул, үзенең үткәнен исенә төшереп, бик күп гамәлләре өчен гомере буе үкенү хисе белән янды. Үкенечләр, үкенечләр...

Ул көн дә берничә җөмлә язып куя торган дәфтәрен кулына алды һәм болай дип язып куйды:

«Әллә, мин әйтәм, кеше тормышы гел генә үкенүләрдән, ялгышлардан гына тора микән, дип уйлаганнарым күп булды минем. Ул ялгышларым, үкенүләрем хронологик тәртиптә язылыр әле, Алла теләсә, дим.»

ҮКЕНЕЧЛЕ ХАТИРӘ

Әллә ничә еллар элек... Ничәнче ел иде соң әле ул? Рәшит уйга калды, санады, санады һәм, ниһаять, очына чыкты.

1944 ел. Август. Һөҗүм башланды, Полтаваны үтеп, Днепрны кичтеләр. Әйе, әйе. Украина җирен үтеп, Польша җиренә барып керделәр. Бу Польшаның Висла елгасы буенда Сандомир дип аталган җир иде. «Сандомир плацдармы» дип аталып, тарихка да кереп калды ул. Анда 593 нче аерым рота дүрт-биш ай буе бер урында оборонада торды.

Арада берсеннән-берсе чибәр өч кыз да бар иде. Полянская Антонина, Ермакова Екатерина һәм Мятка Мария.

Шуларның берсе — Антонина исемлесе бик тиз яшь фельдшер Рәшитнең игътибарын җәлеп итте. Үзе дә сизмәстән, егет белән ниндидер бер могҗиза булды. Кызның шомырт кара чәче, сөрмәле коңгырт күзләре аның һушын алды. «Беренче очрашу ничек булды соң әле?» дип уйланып утырды Рәшит, батып баручы кояшка карап. Ә, ә... Әйе. Сирәк кенә булса да авыл яланында кичләрен танцылар була иде. Шул кичләрнең берсендә егет Антонинаны биергә чакырды.

— Киттек! — диде кыз чая гына, күзләрендә очкын уйнатып һәм кулын егетнең иңенә салды.

Зифа буйлы, матур сынлы кыз Рәшиттән аз гына тәбәнәк иде һәм егет белән сөйләшү, аның йөзенә карау өчен ул башын артка ташлый һәм шулчак чиядәй пешкән иреннәре бераз гына ачылып, ап-ак тешләре күренеп китә. Кырыс сугыш шартларында аз сөйләшергә гадәтләнгән Рәшит бу көнне беренче тапкыр күп сөйләште һәм үзенең килбәтсезлегеннән кыенсыныпмы, бер сәбәпсез көлеп-көлеп җибәргәләде.

— Рәхмәт! Сезнең белән бик күңелле булды, — диде кыз, музыка тынгач.

— Миңа да, — дип елмайды Рәшит кыюсыз гына.

— Мине тагын биюгә чакырыгыз, — диде кыю кыз.

Бию башланганчы бераз тынлык урнашты. Бүгенгедәй хәтерендә, мәңге онытылмаска истә калган: Рәшит Катя һәм Мария белән шаяртып сөйләшергә теләп, алар янына килде, ләкин аның шаян сүзләре кызларның йөзен ачмады. Колгадай озын офицер кызлар янына килеп, нидер сөйли башлаган иде, кызлар башларын артка ташлап, кычкырып-кычкырып көлделәр, чыркылдаштылар. Рәшит моңа бик рәнҗеде.

Антонина, чыннан да, Рәшитнең чакыруын көтте.

— Рөхсәтме? — Рәшитнең тавышы дулкынлануданмы, бик тоныкчыкты.

— Ә, әйе, киттек. Мин сезне көттем, — диде шаян тавыш белән Антонина һәм сүзсез генә, дәртле итеп, җилкенеп-җилкенеп вальска бөтерелде.

Рәшитнең гомерендә дә мондый халәтне тойганы юк иде бугай. Ул бик оста биемәсә дә, бөтен барлыгын биреп, шат елмаеп, кызны кочагына кысып, ашкынып-ашкынып биеде. Ул бу минутта беркемне дә күрми иде, гүя, алар бу чибәр кыз белән бөтен Җир шарында икәүдән-икәү калганнар да гүзәл күбәләкләр кебек һава дулкыннарында канат кагыналар, бер-берсен үлеп яраталар.

— Без тагын очрашырбызмы?

— Һичшиксез, — дип кыз көлеп җибәрде. Рәшит аны култыклап алды һәм алар, бер-берсенә сыенып диярлек, кыз яшәгән блиндажга таба атладылар. Алар икәү иде, гүя, кайдадыр урманнар артында гына туплар шартламый, гомерләр өзелми, йортлар җимерелми, җил дә исми, һава да салкынча түгел. Бу кичтә Рәшиттән дә бәхетлерәк кеше юк иде. Нинди гүзәл кыз Антонина! Алар һәркөн кичләрен кыска гына вакытка очраша башладылар.

— Сәлам! Сине күрүгә мин бик шат, — дип елмая Антонина. — Кая барабыз?

— Белмим, — ди егет кыюсыз гына.

— Әнә теге агач төбенә,— ди кыз кулын сузып.

— Әйдә, — ди Рәшит. Ул инде бу чая кыз белән бергә утка да, суга да ташланырга әзер.

Беркөнне Рәшит кызлар яши торган блиндажга килде. Ишекне шакыды. Ишекне Антонина ачты.

— Үт, әйдә, чишен, утыр.

— Ә кызлар кая?

— Каядыр киткәннәр.

— Ә син?

— Мин сине көттем. Алар мине ят итәләр... — диде кыз. Аның тавышында моңсулык, хәсрәт, уфтану да, хәтта ачу да яңгырап алгандай булды.

Кыз егетнең каршысына ук килеп, җылы кулларын аның муенына тыкты, битеннән үпте, аннан үзенең янып торган битен егетнең иреннәренә якын китерде. Рәшит кинәт кыю гына аның биленнән кочып алды, күкрәгенә кысты, кызның кайнар күкрәкләрен йөрәк турысында тоеп, әллә нишләде...

— Әйдә, чәй эчәбез, — диде кыз аның кочагыннан чыгып.

Рәшит ыргылып диярлек, тагын бер мәртәбә кызның нечкә биленнән кочып алды һәм үзенә таба тартты.

Көтмәгәндә Антонина аның кулларын көч белән үзенең биленнән суырып алды һәм:

— Ашкынма, егет. Ашыккан ашка төшкән, диләр бит. Күпләр ашыгып, үз бәхетләреннән колак кагалар, шуны беләсеңме? — диде.

Салкын гына, уйчан тыйнаклык белән әйтелгән бу сүзләр егетне таңга калдырды. Яшь кенә, сабыйларча эчкерсез, шат, мөлаем 18 яшьлек кызга каян килгән бу кадәрле тирән фикер, дип уйлады Рәшит. Бәлки, аның язмышы катлаулы, кыска гына гомере гыйбрәтле, ә бәхет дигәне әллә кайда ерактадыр. Ни генә булса да, кыз хаклы иде.

Яхшы, дип уйлады егет, ашыкмам. Әмма бу чиядәй янып, ымсындырып торган иреннәрне ничек үпми түзәргә соң?! Ул үзен тынычландырды, ашыкмаска, гомер буе аның ризалыгын көтәргә, аны җәберләмәскә уйлады.

Егеткә озак көтәргә туры килмәде. Кыз, көтмәгәндә, аны үзе килеп кочаклады, башын егетнең күкрәгенә салды, аннан кинәт кенә йолкынып, иреннәреннән суырып үпте.

Моңарчы беркайчан да мондый чын бәхеткә ирешә алмаган егет бу утлы өермәдән башын югалтырдай булып иләсләнде. Ул бу чибәрне бүген, иртәгә, гомергә үзенеке итәргә теләде, шул мизгелдә аның башына да әллә нинди сихри планнар туды.

— Син кем соң? Кай яклардан? — дип сорады Антонина беркөнне егеттән.

— Минме? Мин... — Рәшит тулы җавап бирергә ашыкмады.

— Я, я, син инде, син, — дип ашыктырды кыз.

— Мин — авыл малае, татар авылының зур, күп балалы гаиләсендә туган малай.

— Син татармыни?

— Әйе, мин чеп-чи татар. Әткәй белән әнкәйнең тугызынчы баласы.

— Тугызынчы?! — дип кычкырып җибәрде кыз.

— Әйе, без тугыз бала булганбыз. Иң олы абый гомерсез булган, чәчәк авыруыннан вафат булган. Аннан соң бер кыз туып, ул да озак яшәмәгән. Калганнары исән.

Антонина, кулларын күкрәгенә кушырып, күзләрен

киереп ачып, шаккатып Рәшитнең туганнарын санаганын тыңлап торды. Дәшмәде, туктатмады.

— Ә мин, — диде Рәшит, 1924 елның уникенче июлендә соңгы бала булып дөньяга килгәнмен.

Шул сүзләрдән соң Рәшит бераз тын торды, кызның күзләренә карады, ә ул күзләр мөлдерәмә тулы яшь, ике бите буйлап агып, яшел гимнастеркасына тама иде.

— Сиңа ни булды, Тоня? Ник елыйсың? Мин сине әллә рәнҗеттемме? — диде Рәшит.

— Юк, һич юк. Рәнҗетмәдең. Мин... Мин бик бәхетсез бала, — диде кыз сулкылдап-сулкылдап. — Минем беркемем дә юк. Хәтта әтием дә...

Рәшит бу сүзләрне ачыкларга теләп сораулар бирмәде. Тоня сүзен дәвам итте:

— Мине әнием ирсез килеш тапкан. Әйе, мин җилдән туган бала.

Шунда егет кызның теге көнне әйткән сүзләренең тирән эчтәлеген тулы килеш аңлады.

1945 елның Җиңү тантанасын да Рәшит Антонина белән бергә Германия җирендә каршылады. Ә июль аенда Антонина Дмитриевна Полянская демобилизацияләнеп, туган ягына, әнисе янына Саратов өлкәсенә кайтып китте. Сугыштан соң Рәшит аңа адреслап хатлар язып карады, үкенечкә каршы, ул сөеклесеннән, бердәнбер яраткан кешесеннән җавап хаты алмады, ул аны мәңгегә югалтты.

Иң үкенечлесе шул: Рәшит аңа өйләнергә, гомергә бергә булырга дип сүз дә катмакчы булды, кыз да каршы килмәс иде, әмма ул урысча бер кәлимә сүз белмәүче әнисе, туганнары янына бу чит кавем баласын, бер сүз дә татарча белмәгән кызны алып кайтырга кыймады. Менә шушы курку, шикләнү аның гафу итмәслек ялгышы булды. Яшьлектәге әнә шул мәхәббәт, шул эчкерсез саф җан аның йөрәгенең иң нечкә, иң тирән җирендә әле дә булса бер нур булып балкып тора. Менә шул ялгыш Рәшитнең язмышын да билгеләде, ул башка берәүне дә Антонинаны яраткан кебек чын ярату белән ярата алмады.

Шушы үкенечле язмыш, шушы ачы ялгыш аның җанын озак еллар тырнап тынгылык бирмәде.

ЙОМРЫ БАШ

Тамырлары нык агачның кәүсәсе дә таза була, диләр бит. Рәшитнең нәселе көчле, укымышлы, тырыш һәм шуңа күрә авылда бик абруйлы иде. Аларны Әмир нәселе дип атыйлар. Әмирдән Баһаветдин, ә аңардан Рәшитнең бабасы Бәдретдин дөньяга килә. Бәдретдин соң гына өйләнә. Җәмәгате Хәерлебәдрия бик чибәр кыз була. Менә шушы Бәдретдин белән Хәерлебәдриядән Гәрәй, Заһретдин һәм Шәмсекамәр туа.

Заһретдин Нәдер авылында мәдрәсәдә укыганда мулла кызы Сәрбиҗинан белән күрешеп, яратышып, 1899 елда гаилә корып җибәрә. Аларның җиде баласы үсә. Тормышны алып бару, гаиләне туйдыру өчен Заһретдин чит җирләргә китеп тә йөри. Петроград шәһәрендә берничә ел ипи пешерүче булып эшли. Аннан авылга кайтып, умарта булдырып, мал-туар асрап яши башлый. Берничә ел коймак оны тарттырып, сәүдә эше белән дә мавыгып ала. Авыр ачлык елларында да балаларын ач-ялангач итми. Күмәк хуҗалыкка кучкәч, ул ипи пешерүче булып эшли, халыкны бик тәмле ипи, күмәч белән тәэмин итә. Аның шул кадәр тәмле ипи камырын кул белән басуына ышанмыйча: «Заһретдин, ыштан балакларын сызганып, ипи камырын аяклары белән баса икән», — дип шаярталар.

Аның эш кораллары да бик чиста һәм үткен, һәрчак куллануга әзер тора. Авыл халкы бик үткен пычак яки балта турында: «Заһретдин чалгысы булган бу», — ди торган була.

Рәшит төпчек булып гаиләдә бик иркә үсте. Абыйлары, апалары аны кулдан төшермәделәр. Үзе матур, зирәк һәм телгә оста булды. Җитәкләп мәктәпкә озаттылар, кайтканда каршы алдылар. Рәшит дүрт ел үз авылларында белем алганнан соң, күрше Мәмәттә укыды. Йөреп укыды, авыллар арасы өч кенә чакрым. Аякта чабата, өстә иске бишмәт. Китап тутырылган букчаны иңсәгә аркылы асып, җиде сыйныф тәмамлады малай. Яхшы укыды.

Әтисе Заһретдин йомры «башлы» малаеның керпе энәләре кебек тырпаеп торган куе чәчен сыйпап: «Улым, маладца, яхшы укый, аны җиде сыйныф белән генә калдырып булмас, үзем ипи ашамасам ашамам, улымны укытырмын», — диде.

Чоры өчен яхшы гына гыйлемле Заһретдин дәүләт сәясәтен, тормыш тегермәненең кай якка әйләнгәнен аңлап, урыс телен яхшырак өйрәнсен өчен, аны урыс мәктәбенә укырга бирде. Урыс мәктәбе алар авылыннан унике чакрымераклыкта иде. Татар мәктәбендә укыган малайны урысча начар белә, дип сигезенче сыйныфка түгел, ә бәлки бишенче сыйныфка утырттылар.

Инде егет булып килүче, гәүдәле, унбиш яшьлек Рәшит ыбыр-чыбыр, вак-төяк малай-шалай, чәрелдек кызчыклар белән парта арасында утырырга теләмәсә дә, ата сүзе аңа закон иде. Әмма аңа озак укырга туры килмәде, күрше авыл мәктәбендә сигезенче сыйныф ачылды, Рәшит шунда күчте. Ул «кечке комсомоллар мәктәбе» дип атала иде.

Укуның беренче көненнән үк Рәшит бу уку формасын яратмады. Ул кичке дип аталса да, кичке түгел, төнге мәктәп иде. Укулар кичке биштә-алтыда башлана. Сыйныф бүлмәләре караңгы, матчада эленеп торган бердәнбер җиделе лампаның уты бик тонык. Үз язганыңны үзең күрмисең, китап хәрефләре биешә башлый. Уку түгел, җан җәфалау булып тоелды бу Рәшиткә.

Төнге унда, унберләрдә иске чабата, тула оек белән язынкөзен пычрак ярып өйгә кайту — сират күпере кичү белән бер. Кыш көне декабрь, гыйнвар суыкларында, февраль, март бураннарында катып-калчаеп укырга, белем алырга тырышып утыру үзе бер газап иде.

Укыды Рәшит, тырышты. Үҗәтлеге дә, алга омтылышы да зур иде, әтисенең сүзләре дә аңа көч өстәде.

***

Дүшәмбе көн иде. Рәшитнең сабакташы Гәрәйша гадәтенчә кичке сәгать өчтә аларның ишеген шакып килеп керде.

— Киттекме? — диде букчасын бер иңеннән икенче иңенә күчерә-күчерә. — Минем алгебра чыкмады бит, малай. Шунда барып мәсьәләнең чишелешен күчереп аласы бар. Бирерсең бит.

— Бирермен, күчерерсең.

Кичкә авышкан кояш нурлары астында кар күзләрне чагылдырып, елык-елык килә. Суык. Алар кызу-кызу атлап, олы урам аша үтеп, дуслары Мөгаммәр урамына керделәр һәм өчәү, кызу-кызу атлап, барыр юлга чыктылар.

Бу кичне укулар ничектер тиз үткәндәй тоелды. Сәгать төнге ун тулып, унберенчедә малайлар кайтыр юлга чыктылар.

Авылны чыгып, Заһит чокырына җитүгә, ай яктырткан тауда ап-ак кар өстендә ниндидер кара шәүләләр пәйда булды. Ерак та түгел — биш данә. Мәмәт урманыннан чыкканнар.

— Бүреләр, — диде Рәшит көч-хәл белән тавышын тыеп, елап җибәргәндәй булып.

Малайлар шып туктады. Бүреләр әкрен генә аларга таба килә башлады.

— Малайлар, ятыгыз! — диде Мөгаммәр.

Алар карга егылдылар. Ә бүреләр, рәткә басып, берсе артыннан берсе һаман килә. Якынлашалар. Моны күреп каушаган малайлар, бер командага буйсынган солдатлар кебек, дәррәү сикереп тордылар. Ә бүреләр һаман килә. Мөгаммәр кирегә йөгерә үк башлады.

— Тукта, йөгермә! — диде агарынган Рәшит.

— Беттек, малайлар, үләбез! — диде Мөгаммәр.

Малайлар бер-берсенә сыенып, бүреләрдән күз алмыйча, басып тора бирделәр.

«Нәрсә булыр? Өскә ташланырлармы? Кайсыбызны башта ботарларлар?» — дигән коточкыч уй Рәшитнең башын яндырып үтте. Нишләргә? Артка таба чапсаң, алар куып җитәчәк...

— Безнең бит «пистолет» бар, малайлар, — дип пышылдады Рәшит.

Ул дүртенче сыйныфта укый иде, каяндыр тимер көпшә табып, җайлап кына кап куйды, эченә дары, дары өстенә вак кисәкләргә вакланган тимерчыбык тутырып, «пистолет» ясады. Мөгаммәр белән аларның лапасындагы саламга төшкән бер өер чыпчыкка атып карадылар. Чыпчыклар пыр тузып очып киттеләр. Шуларның берсе, мескен, очып китә алмады, салам өстенә аркасы белән төште. Рәшит аны кулына алды. Бер тимерчыбык кисәге чыпчыкның ике канат арасына кадалган, шуннан мескен кошның каны сыркып, йоны буйлап ага иде. Рәшит чыпчыкны бик кызганды. «Нигә генә аттым? Бу кадәр кансыз гамәл нигә кирәк?» — дип, үзенең бу ерткычлыгы, вәхшилеге өчен бик үкенгән иде. Әмма шул «пистолетны» ул һәрчак үзе белән йөртә иде.

Бүреләр салмак кына атлап аларга таба якынлаша. Курку, каушауның чигенә җиткән Мөгаммәр ни дип тә кычкырырга белмичә:

— Үтерәләр! — дип, бөтен көченә кычкырып җибәрде, җан ачысы белән чыккан бу тавышка башкалар да кушылды:

— Үтерәләр! Бүре бар!

Ә бу вакытта Рәшит калтыраган, каушаган куллары белән шырпы кабызды да «пистолеты»на ут төртте. Озак көтәргә туры килмәде, бик каты шартлау яңгырады, ут көлтәсе бөркелде һәм тирә-як төтенгә күмелде. Ә малайлар җир яңгыратып: «Бүре бар! Бүре бар!» — дип акырдылар.

Бүреләр, бераз туктап тордылар да, Заһит чокырына таба борылдылар.

ҮКЕНЕЧЛӘР, ҮКЕНЕЧЛӘР...

Залдагы зур стена сәгате җидене сукты. Бүлмәдә салкынча. Урамда шыбыр-шыбыр көчле яңгыр ява, тәрәзә рамнары аша бүлмәгә салкынча дымлы һава керә.

Рәшит Заһретдин улы урыныннан җәһәт кенә торды да йокы бүлмәсеннән залга чыкты, җылы йон джемперын аркасына салып, аягына йомшак башмакларын киде. Өстәл янына килеп утырды һәм тиз-тиз нидер яза башлады.

Менә хәзер, иртә таңда, әле кояш та чыкмаган, көн тумаган сәгатьтә аны шулай каләмгә тотынырга нәрсә мәҗбүр иткән соң?

Еракта калган, юләр яшьлектә булган кызыклы вакыйгалар еш кына искә төшә. Гүя алар йөрәкнең кайсыдыр почмагында бик озак йоклап яталар да, беркөн килеп, бер сәбәпсез, йә иртә таңда, йә шәфәкъ кызыллыгы сүнгәндә, эңгер-меңгердә йөрәген чеметеп-чеметеп, я тәмле-тәмле, я ачы күз яшьләренә сәбәп булалар. Юк, ул яшьләр йөрәкне ярсытмыйлар, киресенчә, шул хатирәләрдән соң Рәшит үзенең күңелендә җиңеллек, сафлык артуын тоя. Ул бүген дә татлы да, сагышлы да уйларга бирелде, хатирәләрнең ахыры-чиге юк иде.

***

Рәшит, авыл баласы булгангамы, күп балалы гаиләдә үскәнгәме, телгә бай, сөйләшергә яратучан, укуда алдынгы

булды. Бик күп мәкаль-әйтемнәрне ул әтисе һәм әнисеннән ишетеп белә иде. Шул мәкальләрдән бигрәк тә «атып калганчы, атып кал» яки «калган эшкә кар ява» дигәннәрен һич тә исеннән чыгармады, ә инде «иелгән башны кылыч кисмәс» дигәнен һич кенә дә сөймәде, яратмады. Ничек инде башыңны иеп, тезләнеп яшисең, башыңны күтәреп якты дөньяны күрмә, кол булып яшә, дип фикер йөртте ул. Ә менә «калган эшкә кар ява» дигәне тирән мәгънәле. Бүген эшләнергә тиешле эшне беркайчан да иртәгәгә калдырмады ул. Ә анысына, ягъни эшләнергә тиешле эшне вакытында башкарырга кирәклегенә тормыш аны үзе өйрәтте.

Рәшиткә тугыз-ун яшьләр иде бугай. Беркөнне әнисе аңа: «Улым, безнең чуар тавык үзенә яшереп оя ясап, унлап күкәй салган, — диде. Кулым буш түгел иде, алып керә алмадым». Әнисе әйткән урынга барып, Рәшит тавыкның яшерен күкәйләрен күрде, тавык та шул тирәдә йөри иде. Әйдә, диде ул, саласы күкәен салсын инде, аларны иртәгә алып керермен, дип дуслары янына уйнарга чыгып китте.

Икенче көнне чуар тавыкның яшереп салган күкәйләрен алырга барса, юк, җилләр искән, бер күкәй дә калмаган. Оя да пыр тузган булып чыкты. Бу әле аның тормышында ясаган ялгышларның беренчесе, бик кечкенәсе, бик вагы булып исендә калды.

Зурраклары менә хәзер — олыгайгач кына исенә төште. Тормыш һәрвакыт кеше алдына бик күп сынаулар, бик күп сораулар куя. Сынауларны җиңеп чыгарга, сорауларга җавап табарга күп күргән, күп йөргән, озак яшәгән олы яшьтәге кешеләр ярдәм итәр иде. Ләкин алар дөньядан киткәннәр, аларны югалткан саен кешелекнең рухи байлыгы саега икән. Терсәкне тешләргә телисең, тешләп булмый. Ата-анадан, әби-бабайдан алдагы буыннар турында, аларның кем булуы, ничек яшәве, нинди эш белән шөгыльләнүләре турында бәйнә-бәйнә сорашасы, белешәсе калган. Ә бит алар үзара сөйләшкәннәрдер, ә Рәшит аларга колак салмаган. Нинди кызганыч, хәтта оят. Ул бары әтисенең әтисе Бәдретдин турында гына ишетеп белә, аның атасы Баһаветдин булган. Ә әнисе ягыннан бабасы һәм әбисенең хәтта исемнәрен генә дә белми калган бит ул.

Бәдретдин бабасы турында да ул бик аз белә. Ул 1919 елда вафат булган, ә туган елы билгесез. Урта хәлле крестьян

булган, иген иккән, мал асраган, авыл халкыннан йомырка җыеп та сәүдә иткән. Мәчеттә мөәзин булган, кышларын мәчетне утын ягып җылыткан. Өч баласы булган. Аның турында Рәшит менә шуларны гына белә алган. Калган эшкә кар яуган, барысы онытылган. Вакытында кәгазь алып, барысы турында сорашып язып алып, шәҗәрә төзисе калган.

Салкынча өйдә кәгазьгә иелеп, үткәннәре турында яза башлагач, оятыннан һәм тирән үкенеченнән аның маңгае вак-вак тир белән капланды. Җыерчыклар белән телгәләнгән муены җилкәсе эченә җыерылды. Я, Хода! Нинди үкенеч, нинди төзәлмәслек ялгыш, хата! — дип уйлады ул. Эш калган, кар яуган!

ЮЛ БАШЫ

Кичке комсомол мәктәбе бер генә ел эшләде дә, нининдидер сәбәпләр аркасында, ябылып та куйды. Белемгә омтылган яшьләр тагын җиде юл чатында, билгесезлек алдында аптырап калдылар. Рәшит кая барып бәрелергә белми йөрдейөрде дә «Чулпан» колхозында тракторга ягу өчен җәй буе «чүрәкә» ваклап торды. Авыр эш түгел, агачны түгәрәк циркуляр пычкы белән кисте, балта белән ваклап өемнәргә өйде. Өч айлык хезмәт хакына кара төстәге кәчтүм алып киде, гомерендә беренче мәртәбә өстенә адәм рәтле кием эләкте. Шул киемне киеп, егет булып, Уфага укырга китте.

Заһретдин абзый йомры башлы малаен кая гына алып барып, белем оясына илтеп тыгарга инде, дип аптырап торганда, 1939 елның җәендә Уфада яшәүче олы кызы Дөрлиҗинан, кияве Нургали белән авылга кунакка кайтып төште.

Анда-монда сугылып, кулына эш, башына гыйлем эзләп тинтерәүче унбиш яшьлек Рәшит шәһәрдән кайткан туганнарына кызыгып карады. Аларның киемнәре дә, сөйләшүләре дә башка. Хәтта апасының яулык бәйләве дә аңа бик ошады. Үзгәргән апасы, чибәрләнгән, балалары гына юк.

— Я, кайнеш, — диде җизнәсе Нургали Рәшиткә, — эшләр кай якка тәгәри? Гыйлем эстәү, белем алу безнең заманда бик кирәк. Кем булырга ниятең? Мәктәпне тәмамлагач, кая барасың?

— Мәктәп тәмам инде, җизни, — диде Рәшит сүлпән генә.

— Ничек тәмам? Син инде унны бетердеңмени?

— Нинди унны? Сигезне генә бетердем. Ә җәйгә ябып та куйдылар.

— Нишләп яптылар? Әллә тәртип игы чамалы булдымы?

— Юк ла, нишләп ябылганын кем белә инде аның. Яптылар, бетте китте.

— Кайгырма, кайнеш, җаен табарбыз.

Шул көнне Нургали белән Дөрлиҗинан киңәштеләр, сөйләштеләр дә, бер карарга килеп, ата кешегә сүз каттылар.

— Әткәй, — диде Дөрлиҗинан эштән кайтып, атын тугарып, өйгә килеп кергән Заһретдингә. — Рәшитнең мәктәбе ябылган икән, укуын кайда дәвам иттерергә уйлыйсыз соң?

Заһретдин бераз дәшми торды, аннан чыбыркысын мич артындагы чөйгә элеп:

— Без өйләнгәч, төн кыскарды, дигәндәй, төпчегемне укытып, кеше итәрмен, дип уйлаган идем, үзе дә укырга бик хирыс иде, дөньясы әллә нишләде шунда, бүгенге закун иртәгәгә ярамый, ай бирде, кояш күпсенде, бер сәбәпсез мәктәбен яптылар. Авылда гына, колхузда эшләр инде. Алма агачыннан ерак тәгәри алмас. Кая барсын?! — дип, җилкә чокырын кашып алды.

— Бик кайгырма әле, әткәй, берәр нәрсә уйлап чыгарырбыз. Бездә, Уфада, бер техникум бар, бездән ерак түгел. Фельдшерлар әзерли торган техникум. Яшьләр җидееллык белем белән шунда укыйлар.

— Һәй, кая инде безгә Уфага укырга бару?!

— Алабыз да китәбез үзебез белән. Урнаштырабыз, укытабыз, бездә яшәр, Аллаһы боерса. Бер баланы гына туйдырып торырга хәлебез җитәр, Аллага шөкер. Күләгәдә таш та мүкләнә, диләр бит, әткәй, укысын, кеше булсын!

Дөрлиҗинан белән Нургали бик тыйнак хезмәт кешеләре, фатирлары да зур түгел. Шулай итеп, Рәшит Уфада медицина техникумында укый башлады. Яхшы укыды, яратып укыды. Гүя ул шушы профессиягә күптән әзерлән-гән, гүя ул тумыштан ук кешеләрне дәвалар өчен яралган иде.

Ике курс тәмамланды. Имтиханнар бетте. 21 июнь көнне барлык студентларны Актлар залына җыйдылар. Яшьләр урыннарга урнашкач, башын түбән иеп, салмак атлап,

техникум директоры килеп керде. Ул яшьләргә таба карарга кыймыйча, тәрәзәгә төбәлеп, сүзен башлады.

— Бүген... — дип, бик озак сүзсез торганнан соң, — бүген Мәскәү радиосы бик зур кайгы хәбәр итте, балалар. Зур кайгы. Сугыш башланган. Германия безнең чикләрне үтеп, бик күп шәһәрләргә бомба ташлаган.

Бу тышкы яктан бик кырыс кешенең яшьләнгән күзләрен күрү яшьләргә бик авыр иде. Кемдер шунда елап җибәрде, кемдер йөзен куллары белән каплады.

— Сугыш... Сугыш башланган.

Аннан директор гражданлык бурычы, намус, табиблык бурычы турында сөйләде һәм, бераз туктап торганнан соң, укучыларга туры карап, кычкырып һәм тантаналы рәвештә:

— Халыкка һәм илгә хезмәт итәргә ант итәбез! — диде. Шау-гөр килеп яшьләр урыннарыннан тордылар һәм барысы дәррәү бертавыштан:

— Халыкка һәм илгә хезмәт итәргә ант итәбез! — диделәр.

1941 нче елның октябрендә уку срогы кыскартылу сәбәпле, техникум дипломы тоттырып, Рәшитне Башкортстанның Мәчетле районына санитар-табибның ярдәмчесе итеп эшкә җибәрделәр. Анда алты ай эшләгәннән соң, ул сугышка алыначагын белеп, туган авылына кайтты.

Юлда ул гел үзенең туган авылы, әти-әнисе, туганнары турында уйлады. Аңа әтисе әле дә, аны озаткандагы кебек, авыл читендә ялгыз тирәк янында басып торадыр кебек тоелды.

Март аеның җан өшеткеч бер җепшек болытлы көне иде. Район үзәгеннән авылына җәяүләп, җепшек карны ера-ера, арып-талып кичкә кайтып җитте. Элек шау-гөр килеп торган авыл аңа буп-буш, җансыз кебек тоелды. Ул урам буйлап атлады, беркем очрамады, хәтта этләр дә өрми, тынып калганнар. Бөтенесен каһәр суккан сугыш, фронтлардан килгән хәбәрләр, «кара кәгаз»ьләр аяктан еккан.

Рәшит авыр уйлары белән тын урам буйлап төште, башын түбән иеп, арыган аякларын көч-хәл белән сөйрәп, туган өенә таба атлады. Урамның уң ягында кемнеңдер шыгырдатып урыс капканы ачуы ишетелде. Рәшит шул якка башын борды, әмма капка ничек тиз ачылган булса,

шулай бик тиз ябылып та куйды. Беркемнең дә беркемне күрәсе, сөйләшәсе, хәтта исәнлек-саулык сорашасы килми, ахры. Кайгылар баштан ашкан. Авыл мәет чыккан йортны хәтерләтә.

ЯҢА ФЕЛЬДШЕР

1942 елның маеннан августка кадәр, ягъни хәрби комиссариаттан чакыру килгәнчегә кадәр, Рәшит Миңлебай авылында фельдшер булып эшләде. Авылда моңарчы медпункт та, фельдшер да булмаган. Аңа, шул дүрт ай эчендә медпункт ачып, кирәкле дарулар, медицина кирәк-яраклары белән җиһазлау эше йөкләнде. Тырышты егет, алны-ялны белмәде. Белем җитәрлек, дәрт-дәрман бар.

Яшь фельдшерны эшли башлавының икенче көнендә үк кинәт кенә авырый башлаган бер ир янына чакырдылар. Авыруның хәле мөшкел: иреннәре күгәргән, йөзе көл төсле, үзе эченең авыртуына чыдый алмый ыңгыраша, бәргәләнә, эче тау кебек кабарган, көч-хәл белән тын ала.

«Эчәкләре чуалган» дигән нәтиҗә ясады яшь фельдшер. Барлы-юклы медицина кораллары белән ул авыруның туры эчәгенә җылы су җибәрде, эчәк юллары ачылып, авыруның авызына кадәр эчәк сулары килә башлады. Байтак газаплардан соң авыру күзләрен ачты, тирән итеп сулыш алды, хәле җиңеләйде.

Шушы вакыйгадан соң яшь фельдшерның абруе күтәрелде. Район сәламәтлек саклау бүлеге баш мөдире Сабо Серафима Йосифовна да Рәшитнең бу батырлыгына югары бәя бирде. Шушы вакыйга байтак еллар авыл халкының теленнән төшмәде, егетнең абруе бермә-бер күтәрелде.

***

Туган йортның капка төбенә халык җыелган, кемдер гармун уйный, кемдер җырлый, кемдер елый. Рәшит тарантастан сикереп кенә төште дә гармун көенә биегәндәй итә башлады. Аның башы һаман аңгы-миңге, ни әтисе, ни әнисе, ни аны сагынып көтеп торган туганнары аның күзенә чалынмады.

Әлмәт хәрби комиссариатында Рәшиткә мөһер сугылган зур гына пакет бирделәр. Рәшит пакетның тышына язылган язуны бик җентекләп, кабат-кабат укыды: «Мәскәү шәһәре,

Осипенко урамы, Бурденко исемендәге госпиталь» дип язылган иде. Бу мөһерле пакет аңа документ та, юллама да, юл үтү өчен акча хезмәтен дә үтәде.

Бөгелмәгә, станциягә кадәр Рәшитне аның олы апасы Дәрлиҗинан озата барырга булды. Колхозның калтыр-калтыр, җимерелергә торган арбасына арык ат җигелгән. Шул арбага, салам өстенә утырып, Бөгелмәгә чаклы озын юл үтәсе бар. Аны иң якын дусты, сердәше Фарукшин Һади да озатырга булды. Ат авылдан чыккач, Миңлебай тавына көч-хәл белән күтәрелде. Тауга таба җәяүләп, арба артыннан атладылар. Төш җиткәндә генә Миңлебайга килеп җиттеләр. Анда Рәшитнең дуслары: колхозның табельчы-кассиры Мөдәррис һәм йөргән кызы Разия Каюмова биш күз белән көтеп торалар иде. Гармун уйнап, урам әйләнеп, авыл халкы зурлап, хөрмәтләп аны күрше авылга кадәр озата барды. Разия Рәшитнең учына кәгазьгә төрелгән бер нәрсә салды:

— Бу миннән истәлек, — диде.

— Мин аны саклап тотармын, — диде Рәшит.

Бөгелмәгә барып җитә алмадылар. Ат арыды, хәлдән тайды. Тайсуган авылыннан ерак түгел инеш янында туктадылар, атны печәнгә җибәрделәр. Үзләре белән алган коры-сарыны ашап, куна калдылар.

Юлда барганда Рәшит, озаткан чакта Разия биргән төргәкне сүтеп, кулъяулыкны әйләндереп-әйләндереп карады, чигешенең матурлыгына сокланып барды. Бу вәгъдә кулъяулыгын сөйгәненең оста куллары аның өчен чиккән, аны ярату билгесе итеп бүләк иткән иде.

СУГЫШ ЮЛЛАРЫ

Поезд һәр станциядә сәгатьләр буе тукталып-тукталып барган җиреннән, кичкә таба зур гына бер станциядә бөтенләйгә туктап калды. Алда юл юк, немец самолетлары тимер юлны бомбага тоткан, Мәскәүгә йөз егерме чакрым калды дип сөйләшүләр Рәшитнең колагына чалынды. Халыкны вагоннардан төшерделәр. Зур-зур чемоданнар сөйрәп, хатын-кызлар, бала-чагалар вокзал эченә тулдылар. Рәшит тә, этелә-төртелә эчкә узып, үзенә урын карады, әмма бер генә утырыр урын да тапмады. Ары-бире килеп, вокзалның бер почмагына барып шунда урнашырга булды. Аркасындагы биштәрен салып, аякларын сузып, таш идәнгә

утырды. Аркасын стенага терәп утыра торгач, йокымсырап китте. Күпме йоклагандыр, күзләрен ачты һәм уң ягында фанердан ясалган кечкенә чемодан өстендә сап-сары чәчле башын түбән иеп йокыга талган бер кызны күрде. Кыз ак чәчәкле зәңгәр күлмәге өстеннән буйлы-буйлы аклы-сарылы джемпер кигән, аякларында җиңел чүәкләр.

Бераздан кыз, башын күтәреп, күзләрен ачты, маңгаена төшкән чәчләрен артка җилпеп җибәрде дә Рәшиткә карап, бик мөлаем елмайды. Алсуланып торган ике бит очында мәхәббәт чокырлары пәйда булды. Ә күзләре... күзләре кыр чәчәкләре төсле зәп-зәңгәр иде. Кызның шундый да матур күзләреннәнме, бу гүзәллекнең аның янында гына булуыннан кыенсыныпмы, Рәшит күзләрен ачарга куркып утырды. Шулай утыра торгач, тагын йокыга киткәнен сизми дә калды. Ниндидер шау-шуга, ыгы-зыгы тавышларга ул уянып китте, ләкин күзләрен ачмады, теге гүзәл зат һаман аңа таба карап утырадыр кебек тоелды. Рәшит үзенең кулы өстендә кызның кул җылысын тойды, ә җылы кул аның саен авырайды. Ул күзләрен аз гына ачып, керфекләре арасыннан шул якка күз ташлады: кыз үзенең кулын егетнең кулы өстенә куеп, башын стенага терәп, йокыга киткән иде. Рәшит тын алырга да, кыймылдарга да куркып, озак кына утырды. Бертөрле халәттән оеган аякларын кыймылдаткан иде, кыз уянып китте, күзләрен ачып алды, ләкин уянып бетмәде, күрәмсең, шунда аның башы егетнең җилкәсенә авып төште. Рәшит үзенең комачтай кызаруын сизде, бит очлары янды, колаклары кызышты. Шунда ул үзенең колагына якын ук пышылдаган тавыш ишетте, күзләрен ачмады, сүзләрне аңламады. Аннан кыз бик ачык һәм бик аңлаешлы итеп тагын кабатлады: «Давай, уйдем отсюда!» Рәшит, пружинадай кысылып, урыныннан кузгала алмый, тораташтай катып калды. Өнеме бу, төшеме? Кыз аңа сүз ката. Урысча. Каядыр чакыра. Нишләргә? Ул, күзләрен ачып, кызга карады. Кыз исә баягыдан да матуррак елмаеп, аңа: «Пошли, не стесняйся!» — ди.

Кызның «пошли» дигән сүзен аңлап, Рәшит бик авырлык белән урыныннан торып басты, ташта утырып, аяклары каткан, бөгелмиләр, җилкәсе суык тарткан иде.

— Әйдә, әйдә, кыенсынма, китик моннан, — диде кыз.

Рәшит ашыкмый гына биштәр бауларын иңнәренә киде: «Кая барырга өнди бу кыз? Белмәгән-күрмәгән, пәри кызыдай чибәр бу кыз, ымсындырып кая алып бармакчы?» — дип уйлады, егет. Шулай да кызның боеруына буйсынып, башын түбән иеп, салмак кына аның артыннан атлады. Идәнгә ятып йоклаган кешеләр аша атлап чыга-чыга, алар вокзал ишегенә җиттеләр, кыз кызу гына ишектән тышка омтылды. Айлы төн иде. Сентябрь күгендә йолдызлар чекрәеп тора.

— Давай, давай, шагай! — дип боерды кыз һәм җил-җил атлап, агачлар арасына кереп китте. Рәшит аның артыннан атлады. Алар станция яны бакчасының кеше йөрми торган аулак почмагындагы бер эскәмия янына килеп туктадылар. Шул арада кыз чемоданын җиргә куйды да, Рәшитнең кулларын күкрәгенә таба күтәрде һәм авызына якын ук китереп, егетнең кулларын җылытырга теләгәндәй, кайнар тынын өрде, ашыга-ашыга аларны үбә башлады. Рәшит, бу кызның ни кыланганын аңламыйча, тәмам мәлҗерәп төште. Җебегән малай-шалай кебек, ул бу сихерче кызга ни бер сүз әйтерлек, ни бер хәрәкәт ясарлык хәлдә түгел иде. Ул, кызлар белән мәхәббәт уртаклашкан, яратышкан егет, нининдидер нечкә генә, сары чәчле марҗа кызы алдында җебеп төште. Кыз исә, Рәшитнең оялчанлыгын, кыюсызлыгын күреп, үзенең дәртле сүзләрен такмаклый башлады һәм, ниһаять, егетнең күзләренә керердәй булып: «Я тебя люблю! Я тебя хочу!» — дип, аңа кайнар тынын өрде, кочаклап алды, аны кочагында яндырырга теләде.

— Миннән курыкма син! Мин чирле түгел, мин әле кыз кеше. Сине күрмәгән булсам, мин бу турыда уйламас та идем. Син миңа бик ошадың, мин сине яраттым. Анда немецлар. Минем аларга үземнең сафлыгымны калдырасым килми. Ал мине! Ал! Ал! Менә шушында ал! — дип өзгәләнде кыз.

— Юк, кирәкми! — дип, Рәшит кызны этеп җибәрде.

«Мин китәрмен дә югалырмын, ихтимал, фронтта һәлак булырмын, ә бу өрфиядәй нәфис, чәчәктәй матур кыз баланы бозып, әрәм итеп калдыра алмыйм, гөнаһлы буласым килми», — дип уйлады Рәшит һәм капчыгын сулъяк иңсәсенә элеп, караңгы почмактан кызны җитәкләп алып чыкты. Алар вокзалга таба атладылар.

Иртәнге якта бу станциягә товар вагоннарында солдатлар,

атлар, танклар төялгән зур состав килеп туктады. Рәшит, вагон ишекләре янына килеп, кертүләрен, вагонга алуларын үтенде.

Җавап фәкать бер иде:

— Ярамый!

Состав кузгала башлады. Егет түш кесәсеннән сургучлы пакетын тартып чыгарды да, ачыргаланып, пакетын болгый-болгый инәлде:

— Алыгыз мине! Миңа Мәскәүгә барып җитәргә кирәк! — дип кычкыра-кычкыра, әкрен генә үтеп китүче вагоннар артыннан бик озак йөгерде. Көтмәгәндә, соңгы вагон ишегеннән аңа таба озын бер кул сузылды һәм Рәшит аңа чытырдап ябышты, теге кул аны сөйрәп диярлек вагон эченә менгезде. Вагон эче солдатлар белән шыгрым тулы иде. Рәшит вагон эченә атылып килеп кергәч, солдатлар, комедия караучы тамашачылар кебек, шаркылдап көлеп, кул чаба башладылар. Ә бераздан «магарыч» дип күчтәнәч таләп иттеләр. Рәшит аларны бик теләп биштәрендәге сохарилары белән сыйлады.

КОМАНДИР

Пакетта язылган адрес буенча Рәшит Осипенко урамын озак эзләде. «Справочное бюро» дигән язу күреп, аның алдында бераз чират торды да, аңа кечкенә тәрәзә аша кәгазь суздылар. Анда Осипенко урамына баруның иң уңайлы юллары язылган иде. Метро, трамвай, автобус. Ике сәгать дигәндә ул Осипенко урамындагы госпитальгә килеп җитеп, пакетны комендатурага тапшырды. Дүрт катлы йортның бер бүлмәсеннән урын бирделәр. Бу Көньяк-көнбатыш фронтның медицина хезмәткәрләрен резервта тоту идарәсе иде. Бөтен Союздан табиблар, фельдшерлар, шәфкать туташларын җыеп, төрле фронтларга җибәрә торган идарә иде. Егерме көн хәрби хәзерлек үткәннән соң, Серпухов шәһәрендә яңа оешып килүче полкның беренче батальонына военфельдшер Рәшит Бәдретдиновны санвзвод командиры итеп билгеләделәр. Өр-яңа форманың якасындагы күксел тасмага ике шакмак беркеткәч, Рәшит урта комсостав булып алды. Кирза итекләр бирделәр. Берничә ел гына элек тимер көпшәгә дары тутырып, чыпчык атып йөргән чабаталы

малайның биленә портупеяга, ягъни корал тагып йөри торган калын каешка елык-елык килеп торган күн кобура эченә салынган «ТТ» пистолеты тактылар.

848 нче полк Серпухов урнашкан. Медицина хезмәте структурасында дүрт санинструктор, уналты санитар булып, алар барысы да командир Бәдретдиновка караганда күпкә өлкәнрәк иде. Аларга яшь командир сугыш кырында яраланган сугышчыга ничек ярдәм күрсәтергә кирәклеген өйрәтә башлады. Элемтә һәм санитар взводлар солдатлар белән тулылана башлады. Кече комсоставны һәм солдатларны ашату өчен ашханә оештырды. Полк зурайганнан-зурайды. Клубның санузеллары, бәдрәфләре җитми башлады. Шул хаҗәт өчен клубтан читтәрәк, кырда зур-зур канаулар казыттылар. Солдатлар шул канауларга бәдрәфкә йөрделәр. Менә шул канау янында Рәшит беркөнне авылдашы Хәйрулла агайны очратты. Аны Чупайда Птиен Хәйрулла дип йөртәләр иде.

— Бәррәч, — диде Хәйрулла, Рәшитне танып, — Заһретдин абзыйның төпчеге түгелме соң син?

— Әйе, мин бу, Хәйрулла абзый, Рәшит булам.

Алар, бер-берсенә якын үк килеп, ике куллап күрештеләр, туганнарча кочаклаштылар.

— Менә бит язмыш кайларда очраштыра, энекәш. Тау белән тау гына очрашмый, диләрме?

Шул көннән алар, очрашып, озак-озак сөйләшә, өйдән килгән хатларны бергә укый торган булдылар. Хәйрулла бик тәмле һәм бик күп ашарга ярата торган кеше булып чыкты. Солдат ашы гына аңа җитми иде. Ә Рәшит авылдашына батальон кухнясыннан йә аш, йә ботка алып кайта торган булды, чөнки ул, санвзвод командиры буларак, ашханәдә аш-суның сыйфатын тикшерүче дә, аның «алласы да, мулласы да», дигәндәй, үзе хуҗа, аш-суны күпме алырга, кемгә бирергә теләсә, аның үз кулында иде.

Беркөнне Рәшит Хәйрулла абзыйга бик тәмле майлы ботка алып килде. Хәйрулла ботканы ашый башлагач, авылда булган бер вакыйганы исенә төшереп, Рәшит сүз башлады:

— Мин Хәйрулла агай, синең хатыныңа сине сугыштан исән-сау алып кайтырга вәгъдә биреп киттем бит, — диде.

— Ничек? Ничек? — диде авылдашы, эчендәге кызыксыну кортын тыя алмыйча.

— Кайчан сине сугышка алдылар?

— Июнь аенда.

— Менә, менә, шул июнь ае иде инде, — дип сөйли башлады Рәшит. — Сезгә кайсыдыр авылдан кунак кызларын күзләргә килдек. Ишек шакыдык. Миңнури апа ишекне ачты. «Сездә кунак кызлары бар, керик әле», — дибез. «Юк, юк, — ди бу, — кертмим, йөрмәгез дә, сорамагыз да, кертмим булгач, кертмим, — ди. — Кәефем юк, сезне күрәсем килеп тормый әле, ди, кичә генә Хәйрулла абзагызны сугышка озаттым, кайгылы чагым», — ди. «Алайса, кызларны безнең янга чыгар», — дибез. «Юк», — ди бу. Ә без ялманабыз, үтенәбез. Юк, нихәтле зинһарлап, үтенеп сорап карадык, кызларны да чыгармады, безне дә өйгә кертмәде.

— Кертмәс, энекәш, кертмәс. Минем карчык бик акыллы, тыйнак хатын ул, — дип, Хәйрулла хатынын мактап алды. Рәшит сүзен дәвам итте:

— Миңнури җиңги, — дим, — мине дә бер-ике көннән армиягә алалар, — дим, безне кызлар янына кертсәң, Хәйрулла абзыйны үзем белән саклап кына йөртермен, кайтканда алып кайтырмын, дим. Бу сүзләрем дә ярдәм итмәде, тәки кызлар янына безне кертмәде.

Хәйрулла мыегын боргалап, хәйләкәр елмаеп, егетнең сүзләреннән үзенчә тәм табып, кеткелдәп көлеп утырды.

СТАЛИНГРАДКА!

1942 елның ноябрендә 848 нче полкны Дон фронтына Сталинград юнәлешенә җибәрделәр. (Дон фронты соңрак Сталинград фронты белән берләштерелде.)

Вагонның каты сәкесенә сузылып яткан егетнең муенын шинель якасы кырды, тәненә җылы кермәде. Ничаклы гына күзен йомып ятса да, йоклый алмады. Вагон эче салкын, түбәдә нидер шалтыр-шолтыр килә, тәрәзә ишек-тошыкларыннан салкын җил бертуктаусыз сызгыра. Паровоз төнге кыр буйлап, кыргый үкереп, алга ыргыла.

— Сталинградка барабыз дисең инде син, авылдаш, — диде Хәйрулла. — Анда турыйлар инде безнекеләрне! Курыкмыйсыңмы?

— Барып җиткәч, күрербез инде, Хәйрулла абзый. Ә син соң, син, әллә бик куркасыңмы?

— Үтереп кенә куйсалар, ярый ла, үләрсең дә күмәрләр. Ә менә плингә эләксәң, Ходай сакласын, — диде карт солдат.

— Хурлыгы ни тора! Синең ярый балаларың юк, атаң-анаң гына. Алар алдында да оят.

Хәйрулла Рәшиттән егерме яшьләр тирәсе өлкән, взводта да иң өлкән кеше. Әмма Рәшитнең шинель якасындагы ике шакмак яшь егетне аңардан өстенрәк итә иде.

Вагон селкенүдән, уңга-сулга чайкала-чайкала, Хәйрулла ишеккә таба юнәлде.

— Йокла, әйдә, — диде.

Вагонда йокыга киткән солдатларның гырлау тавышы һәм борын сызгыртканы гына тынлыкны бозды. Ә паровоз, дәһшәтле үкереп, тукталышларсыз, төн караңгысын ярып, алга таба элдерә.

Кинәт каяндыр ерактан дәһшәтле гөрелдәү — немец очкычларының үкерүе ишетелде. Берсе эшелон өстеннән ыжгырып үтеп китте. Берничә секундтан бик көчле шартлау тавышы яңгырады. Немец бомбасы паровозны челпәрәмә китерде. Рәшит бу коточкыч шартлау тавышыннан сикереп торды, вагоннар ямьсез чыгырдады, бер-берсенә бәреләбәреләәкренәеп туктадылар. «Бөтен эшелонны юкка чыгармыйча китмәсләр инде», — дип уйлады ул. Кайсыдыр вагонга ут капкан булып чыкты, чыр-чу, кычкырыш, кемнәрдер яраланган, кемнәрдер үлгән.

Ярымҗимерек вагоннар, шартлатылган паровоз, яраланган солдатлар япа-ялан кыр уртасында калды. Санитарлар яралыларга ярдәмгә ашыкты.

Рәшиттә ниндидер зәһәр ачу, каргыш, авыр әрнү хисе уянды, көчсезлек, үлем алдында каушап калу хисе аның җанын айкады.

— Кешеләрне барларга! — дигән команда яңгырады.

— Взвод командирлары! Расчетларны тезәргә!

— Санвзвод! Тезелергә!

***

Ноябрьнең кояшлы салкын бер көне. Гүя шартлау да, кычкырыш, ыңгырашулар да, үлем дә юк. Вак кына кар йолдызчыклары кояшта елык-елык килеп җемелдиләр иде.

Исән калганнарны җимерелмәгән, янмаган вагоннарга төяп, икенче бер паровозга эләктерделәр дә, берничә сәгатьтән алар тагын фронтка таба юлны дәвам иттеләр.

Бутуриновка станциясенә җиткәч, состав туктап калды. Вагоннардан төшәргә дигән команда булды. Алга таба

җәяүләп үтәсе юл әле бик озын иде. Атлар җигелде, йөкләр төялде. Солдатлар аркаларына биштәрләрен киделәр, котелокларын астылар, колоннага тезелеп, фронтка таба юл алдылар. Нәрсә көтә? Үлемме? Яшәүме?

Көн кичкә авышты. Җепшек кар яуган юлдан ал-ялсыз атладылар да атладылар. Рәшитнең аяклары тәмам хәлсезләнде, ул бервакыт аягүрә йокыга китте, уң ягындагы берәүгә таба авып китеп, сискәнеп уянды.

Рәшитнең аркасы тирләде, бик нык ашыйсы килә башлады, авыз эче корып, теле аңкавына ябышты. Ул тагын йокымсырады, авып китә башлагач, тагын сискәнеп уянды.

Таң атты, кояш күтәрелде, кояшта ялтыраган кардан егетнең күзләре яшьләнде. Күңеленә шом салып, сискәндереп, кайдадыр гөрселдәү тавышлары ишетелде. Фронт кайда? Колонна кая бара? Рәшитнең күңеленә, ирексездән, шундый уйлар килә. «Ничә көннәр, атналар буе поездда бардык, инде җәяүләп никадәр юл үтәбез. Исән-сау калып булса, сугыштан соң туган якка, Чупайга ничек кайтып җитәрмен микән?» — дип уйланды Рәшит. Башта төрле уйлар. Эчпошыргыч бу күңелсез юлда егетнең күңеленә авылы, тирәк төбендә сагышланып, күз яшәләрен сөртә-сөртә аны озатып калган чибәр кыз Разия егетнең күз алдына килә.

Эх, менә хәзер түш кесәсеннән алып, Разия бүләк иткән кульяулык белән күзләрен сөртеп алыр иде. Нинди матур кульяулык иде! Чигеше генә нинди иде! Рәшит аны егетләргә күрсәтеп мактана, горурлана иде: түш кесәсеннән әкрен генә тартып чыгара, бөтен матурлыгын җәеп сала иде. Кызыкмаган, тел шартлатмаган кеше калмый иде. Яңадан иpләп кенә, җайлап кына дүрткә бөкләп, тагын уң як түш кесәсенә салып куя иде. Әмма ул юк инде. Беркөнне ул Серпуховта керләнгән гимнастеркасын чистага алыштырды, кесәсендәге истәлек кульяулыкны алып калырга оныткан. Менә шулай үкенечле булды истәлек кульяулыкның язмышы.

Күзләр яшьләнә, авыз кибә. Рәшит юеш карны авызына ала, ләкин ул хәлне җиңеләйтми, сусауны басмый.

Арыган, талчыккан солдатларның барган саен адымнары акрыная. Колонна озынайганнан-озыная. Төркем-төркем булып та, аерым-аерым да сөйләшми генә, тупас бер үҗәтлек белән, һәр адымны санап диярлек, авыр итеп атлыйлар да атлыйлар.

— Артка калмаска!

Шулай көндезләрен яшеренеп торып, аннан төннәр буе бертуктаусыз җәяү бара торгач, колонна Дон елгасы буендагы бер станицага килеп җитте.

— Привал! — дигән команда яңгырады.

Укчыларның күбесе шунда ук җиргә егылды. Станица урамында — автомашиналар, «Катюша»лар, йортларда, келәтләрдә — хәрбиләр. Авыл халкы каядыр китеп беткән.

Турыдан-туры урамда привал солдатларга көч тә, ышаныч та өстәмәде. Суык, көнбатыштан бик көчле җил исә, өстәвенә карын ач, эч буш. Рәшит көч-хәл белән аягында басып калды. Юеш җиргә утырырга да, ятарга да теләмәде, тик шинель якасын күтәреп, битен салкын җилдән ышыклады.

ДОН

Озакламый бу тирәдә бик каты бәрелеш булачак икән. Донның көнчыгыш яры сөзәк, сап-сары комлы, ә көнбатыш яры текә. Шул якта ун-унбиш чакрым ераклыкта немец һәм мадьяр гаскәрләре тупланган. Елга бик киң, туңмаган, елга өстендә дәһшәтле дулкыннар.

Озакламый полк һөҗүмгә әзерләнә башлады. Аның өчен Донны кичәргә кирәк. Көнбатыш ярга чыгу өчен әзерләнергә: бүрәнә, такта яки башка нәрсә табарга фәрман булды. Һәр солдат үзе өчен ышанычлы әйбер эзли башлады. Сарайлар ватылды, хәтта искерәк өйләрнең бүрәнәләре алынды. Әмма ике көннән бик каты суытып җибәрде. Төнлә Дон калын боз белән капланды. Иртән Рәшит кичә кич кенә дулап торган елганы танымады. Су өсте шоп-шома боз, ялтырап тора, җил ап-ак карны әрле-бирле очыртып йөртә. Иртәнге суык тәнне куыра, тынга каплана, кашларны, керфекләрне бәс каплый.

Солдатлар, елганы шул боз өстеннән шуышып үтеп, аргы якта һөҗүмгә ташланырга тиешләр. Менә тоташ агым булып, боз өстеннән шуышу башланды, боз өсте солдатлар белән капланды.

Кинәт бөтен горизонтны дер селкетеп, дәррәү кузгалган көчле орудиеләр телгә килде. Гүләү көчәйгәннән-көчәя барды, җир белән күк тоташкандай булды.

«Башланды, — дип уйлады Рәшит, — самолетлармы бу, танклармы?»

Командалар яңгырап-яңгырап алды. Ашыктылар, кабаландылар.

Дошман туктаусыз ут яудырды. Боз өстендә якын ук гранаталар шартлады, ядрәләр сызгырды, әле анда, әле монда бомбалар ярылды, боз өстен төтен, сөрем каплады. Яргаланган боз кешеләрне күтәреп тора алмады. Елга өсте кып-кызыл кан булды.

Кичкә таба көчле җил исте, иртәнгә Дон елгасының өсте үлгән гәүдәләр белән бергә шатырдап туңды. Икенче көнне иртән полк таңнан тагын һөҗүмгә күчте, әмма тагын шул ук хәл кабатланды.

Ә өченче көнне гаять күп югалтулар белән 848 нче укчы полк дошманны куып җитте.

Рәшитнең санвзводы яралы солдатларны, командирларны сугыш кырыннан алып чыгып, беренче ярдәм күрсәтте, госпитальләргә озатты. Аның үзенә дә, еш кына корал тотып, ут эченә керергә туры килде. Шундый бәрелешләрнең берсендә ул каты яраланды, контузия алды.

КОНТУЗИЯ

Санвзвод әле боз өстенә кереп өлгермәгән иде. Күз алдында утлы зилзилә бөтерелә. Солдатлар, төбеннән кисеп аударылган агачлар кебек, тәгәрәп-тәгәрәп китәләр. Менә Рәшиткә якын гына берәү, табигый булмаган хәрәкәтләр ясап, тезләренә төште һәм акбур кебек агарган йөзе белән комга капланды, теткәләнгән киеме астыннан куе кызыл кан саркыды. Шул арада кинәт Рәшитне ниндидер бер көчле дулкын күтәреп алды һәм җиргә ыргытты. Колагы тонды, ярылырдай булып башы шаулады. Косасы килде, ләкин коса алмады. Башыннан яшен тизлеге белән «Мин исән!» дигән уй үтеп китте һәм шунда ул авыз эченә тозлы сыеклык җыелганын сизде. «Кан!» — дип уйлады Рәшит, — мине яраладылар бугай». Ул җылы сыекчаны төкереп, башын күтәрде, тирә-ягында йөзләре белән комга төртелеп, хәрәкәтсез ятучыларны күрде. Авыз эченә тагын тулган тозлы сыекчаны авырлык белән йотып җибәрде һәм санитарларга кычкыргандай итте, әмма аның тавышы чыкмады. «Тизрәк! Тизрәк! Яралыларга ярдәм кирәк!» — дип ыңгырашты ул пышылдап. Ул, үзен-үзе белештерми торып басты, косасы килде, күзләре чыгардай булып, башы

авыртты. Әллә саташты, әллә акылдан язды, бертуктаусыз: «Тизрәк! Тизрәк!» — дип пышылдады һәм ниндидер бер эчке иңрәү белән җиргә капланды. Шул мизгелдән башлап ул берни дә күрмәде, берни дә ишетмәде.

***

Рәшит үзенең һушын югалтып күпме ятуын хәтерләми. Ул күзләрен ачты. Зур бүлмә, түшәме биек, тәрәзәләр зур, кемнәрдер сөйләшә.

— Уянды, уянды, күзен ачты, — дип пышылдады аның янында урындыкта утырган ак халатлы таныш түгел ханым.

Рәшитнең йөрәге сыкрап-сыкрап алды: яраланган, һуштан язган, госпитальгә эләккән. Ул күзләрен йомды. Аның күз алдына үле гәүдәләр, яралылар белән быгырдап торган бозлы Дон суы килеп басты. Бераздан Рәшит бик авырлык белән күзләрен ачты, янында утыручы шәфкать туташы аның күзләренә карап бик мөлаем елмайды һәм:

— Хәлең ничек, герой? — диде, сабыйга эндәшкән кебек.

Рәшиткә бүгеннән үзенең гомере икегә бүленгән кебек тоелды. Унсигез яшенә кадәр, ягъни сугышка киткәнче ул үзе кешеләргә ярдәм кулы сузды, хәтта үлемнән алып калган чаклары да булды, ә хәзер аның язмышы кешеләр кулында, табиблар яхшы булса, ул аякка баса, булмаса — юк.

Кояш палатаның тәрәзәләренә туры карый, пыяла бозланган, аллы-гөлле төсләр белән аңа елмая. Ләкин туп-туры төшкән кояш нурларыннан аның мие кайный кебек, ул башын яшерергә теләп, әле уңга, әле сулга каерыла. Эх, тәрәзәләргә пәрдә элсәләр... Эшләре күптер шул...

Палатада кемнәрдер кычкырып-кычкырып сөйләшә, терелеп килүчеләрдер инде. «Сөйләшмәгезче! Туктагызчы! — дип дәшәсе килә, ярамый, килешмәс. Килеп кермәс борын, үзенә буйсындыра, диярләр. Бәлки, алар яраларның сызлавын, газапларын басар өчен, онытып тору өчен сөйләшәләрдер. Ниһаять, сөйләшүләр тына, кемдер гырлап йокыга китә.

Рәшит түшәмгә карап, уйларына чумып озак ятты, керфекләренә йокы эленде. Ул кинәт сискәнеп китте: күзләре йомылып, башка беркайчан да ачылмаса?.. Әмма күзләр ирексездән йомылалар, ул тагын сискәнеп китә.

Аның ятагы яныннан бертуктаусыз кемнәрдер үтә, берәүләр керә, икенчеләре чыга. Алар Рәшиткә атлап түгел, шуышып йөриләр кебек тоела. Ул саташа башлый. Юк, юк. Ул саташмый, ап-ачык ишетә: кемдер янында гына бик каты ыңгыраша. Ыңгыраша... Ул үзе ыңгыраша түгелме соң?!

Аның күзләренә йокы эленә, әмма йоклый алмый. Гырылдау, ыңгырашу, саташу тавышлары комачаулый. Кинәт кемдер кычкырып җибәрә. «А-а-а!» Рәшит бер мизгелдә йокыга китеп, каядыр упкынга оча, әмма ул шул секундта ниндидер гөрселдәү тавышыннан уянып китә. Кич җитә. Палатада тынлык урнаша, почмактан тычкан утыдай гына яктылык сирпелә. Гөрселдәү тавышы ул саташу гына икән.

Менә шул авыр яралы, хәлсез көннәрендә аның бәгырен үткен пычак белән кискән тагын бер хәл булды.

Ул уянып күзләрен ачты, аның караваты янындагы тумбочка өстендә бер кәгазь ята. Хат, дип уйлады егет, күптән көткән хат! Ул тамагына утырган каты төерне йотарга теләде. Булдыра алмады. Гап-гади өчпочмакның тышына хәрби часть саны язылган, Рәшит Бәдретдиновка диелгән, ә аста Чупайдан Бәдретдиновлардан дип язылган. Рәшит калтыранган хәлсез куллары белән өчпочмаклы хатны ачты да, яткан җиреннән, тәрәзәдән төшкән яктыга туры китереп, укый башлады. Авылдан күптән хат-хәбәр булмый торды. Хатны җиңгәсе Миңзифа язган, аның кулы.

«Кадерле энем Рәшит, — дип башланган иде хат, — сиңа күп кайнар сәламнәр озатабыз, исән-имин сугышлардан әйләнеп кайтуыңны көтәбез. Авыр булса да, түз, иркәм, кайгылы хәбәр җибәрәбез: әткәй вафат булды. Ноябрьнең 11ендә җирләдек. Әнкәй елый да елый, бик борчыла... Карәметдин белән Кәшифнең «кара кәгазь»ләре килде.»

Рәшит хатны укуын дәвам итә алмады, әлеге каты төер аның күкрәген яндырып, ачы күз яшьләре булып бәреп чыкты. Ул үзенең фронтка киткән чакта ялгыз агач янында моңаеп, күз яшьләрен сөртеп басып калган әткәсен һәм әнкәсен күз алдына китерде. Менә ни гомерләр инде ул аларны уйлый, ул бит алар белән кешечә саубуллашмады да. Үлгән бит! Үлгән бит! Авыр көрсенеп, сабыйларча үксеп-үксеп елап җибәрде.

Рәшит Бәдретдинов башта Мичуринск шәһәрендә, аннан Борисоглебск һәм соңыннан Скопин шәһәрендә госпитальләрдә авыр яраларыннан өч ай буе дәваланды.

ЯҢА УРЫНДА

Госпитальдән соң тәмам савыккач, аңа тагын Мәскәүгә медицина кадрлары буенча баш идарәгә юллама бирделәр. Анда Рәшитнең урман эчендә урнашкан яңа оеша башлаган «Гороховец лагере»на — танкларга каршы торучы 1322 нче аерым полкка өлкән хәрби фельдшер итеп билгеләделәр. Аның медицина пункты штатында бер табиб, бер фельдшер, аптека мөдире һәм берничә санитар бар иде.

1943 елның җәендә 1322 нче полк Орел-Курск ягына юнәлде. Фронт сызыгына барып җиткәч, медицина пункты Курск өлкәсенең Иске Оскол районы, Салтыково авылында урнашты. Авыл читендә зур гына палатка корылды. Медсанчастьнең бөтен мөлкәте шунда урнаштырылып, такта-фанерлар өстенә печән, салам җәеп, яралыларны яткыру өчен урын әзерләнде.

Кайдадыр урман эчендә яшеренгән 593 нче ротаны Рәшит бик озак эзләде. Аркада авыр биштәр, көч-хәл белән ялгызы урманнар, ялан-кырлар аша җәяүләп үтте. Еракта-еракта ату тавышлары, самолетлар гөрелтесе ишетелде. Урман эчендә тынлык, шомлы һәм куркыныч тынлык. Җилдә агач башлары әкрен генә кыймылдый, кояш нурлары белән агачлар арасыннан җиргә терәлгән сыек томан дерелди, гөлҗимеш тәлгәшләре күзне кызыктыра. Төнлә булып үткән яңгырдан яшелләнеп, яшәреп киткән урман эчләтеп барганда Рәшит үзе дә сизмәстән:

— Ходаем! Нинди илаһи гүзәллек, — дип куйды.

Ләкин бу сүзләр сөенү сүзләре түгел, ә йөрәктән чыккан сыкрану иде. Ул әле дә булса үткән сугышта алган тән һәм җан яраларыннан айнып җитә алмый. Никадәр кеше гомере өзелде. Хәйрулла абыйның хәле ничек икән? Исәнме? Әллә ул да шул бозлы комга борыны белән капланып калдымы?

Аның юллары совет армиясе солдатларын һәм командирларын ауларга ниятләнеп йөрүче немец разведчик-лары күп булуы билгеле. Алар кулына эләкмәү өчен зур тәвәккәллек, үткенлек һәм уяу булу кирәк иде. Ул төш вакытына ротага килеп җитте. Анда аны бик яхшы каршы алдылар. Бу рота 5 нче гвардияче Укчылар армиясе составында, ә армия генерал-лейтенант С.М.Жадов командалыгында иде.

Рәшит, рота командиры янына кереп, килеп җитүе турында хәбәр итте.

— Бик яхшы, — диде рота командиры капитан Тиктинский, — күптән медиклар көтәбез. Яралылар, авырулар бар, ярдәм юк.

— Ә дарулар бармы соң? — дип сорады өлкән хәрби фельдшер Рәшит Бәдретдинов.

— Дарулар да аз. Сез юлдан килеп арыгансыз, ачыккансыздыр, — дип, кемнәргәдер хәстәрен күрү өчен әмер бирде.

Ул яралылар яткан блиндажга кергәч, барысы да тынып калды, ыңгырашучылар тешен кысып түзде, идәнгә җәелгән салам кыштырдавы да тынып калгандай булды. Күзләр яшь фельдшерга төбәлде, хәле булганнар хәтта торып утырды. Аның монда булуы да аларда өмет уятты: димәк, яшибез, димәк, ярдәм итәчәкләр.

«Алар миннән бик күп нәрсә көтә инде, — дип уйлады Рәшит, — үзем дә белмим, кайчан дарулар, бинтлар булыр».

Ул идәндә салам өстендә яткан бер яшь кенә солдат янына чүгәләде, аның чәченнән сыйпады һәм яраланып госпитальгә эләккәч, беренче тапкыр үзенә мөрәҗәгать иткән шәфкать туташының сүзләрен исенә төшерде һәм үзе дә бу егеткә сабыйларга эндәшкән кебек:

— Хәлләр ничек, батыр? — диде.

— Көлмәгез инде, нинди батыр булыйм мин?!

— Ник, батыр булмый. Батыр ярасыз булмас, дигән сүзне син әллә белмисеңмени?

— Мин алгы сызыкта булырга, немецның бер генә танкын булса да җимерергә хыялланган идем, булмады, менә монда аунап ятам, — диде егет күңелсез генә.

— Әле син берне түгел, унны җимерерсең, — диде Рәшит, егеткә күз кысып.

— Әйе, — дип кушылды янында ятучы олы яшьләрдәге солдат, — госпитальдә үзеңне дәваларлар, немецның барлык танкларын кырырсың әле.

— Я, ярый, барыгызны да медсанчастька озатырга кирәк, — диде Рәшит, аңа төбәлгән сагышлы, өметле күз карашларын тоеп. Әмма аның күңелендә кешеләрдә өмет чаткылары .уятырлык башка бер генә сүз дә юк иде әле.

***

Бу тирәдәге барлык армияләр, корпуслар, дивизияләр, барлык төр гаскәрләр Дала фронты дип атала иде. Ул фронт

белән генерал-полковник С.И.Конев командалык итте. Частьләрдә киеренкелек. Менә-менә каты бәрелешләр булачак. Алда ни көтә? Рәшит булачак бәрелешләрне күзал-ларга тырышты. Шушы сугышта ул бу кешеләр белән булачак, кайберләрен үлем тырнагыннан йолкып алачак, кайберләренең үле гәүдәсе өстендә баш киемен салачак. Солдатларның йөзләрендә яшерен салкын битарафлык, алар инде үлемнәрне дә күп күргәннәр. Рәшиткә алар барысы да бер төсле булып күренделәр.

5 нче июль таңында дошман Орел һәм Белгород шәһәрләре ягыннан Курск юнәлешендә һөҗүм башлады. Әмма 7 нче һәм 10 нчы июльләрдә аның һөҗүме туктатыл-ды, дошман оборонага күчте. Озакламый немец-фашист гаскәрләре көнбатышка таба чигенә башладылар.

КӨНБАТЫШКА

Туган җир, туган авыл, ата-ана йорты, туганнар, дуслар — алардан ерагайган саен, Рәшитнең йөрәген пычак белән телгәләгән кебек өздереп-өздереп исенә төшә, төшләренә керә. Шулай да ул туган ягын уйлаганда үзен бәхетлерәк хис итә, шушы сугыш дулаган җир өстендә дә җәйнең баллы тынлыгы аның үзәген өзә.

Көнбатышка юл урау-чурау һәм бик авыр булды. Шәһәр артыннан шәһәр алынды, тирән сулы зур-зур елгалар, үтеп-сүтеп чыга алмаслык сазлыклар кичелде, һәрчак һәлакәт, газап, үлем һәм яшәү бер-берсенә үрелеп барды. Күпме танышлар ятып калды. Кайберәүләргә фронтта медикның һәм элемтәчеләрнең эше хәвефсезрәк кебек күренәдер. Чынлыкта исә бөтенләй киресенчә. Кыр шартларында, оборонада торганда санитарларның эше аеруча хәвефле, солдат окопта дошманга күренми, ә медикның һәм элемтәченең окопка сикереп төшеп утырырга хакы юк. Ул һәрчак шуыша яки йөгерә. Яралы солдат: «Санитар!» — дигән хафалы аваз салу белән, санитар аның янына ашыга, ә элемтәче элемтәне барларга, өзелгән урынны шуышып барып ялгарга тиеш. Алар һөҗүм итүче часть артыннан атламый, ә бәлки шул гаскәр арасында була.

Җәйнең иң гүзәл көннәре. Күзләрне чагылдыручы зәпзәңгәр чалт-аяз күк йөзе, кайнар кояш, күктә сирәк кенә сибелгән каурый болытлар... Шушы манзараны бозып,

күңелләргә шом салып, ярылып яткан танк чылбыры эзләре, тузан, эссегә көйгән, тапталган соргылт үлән... Бертуктаусыз атыш тавышлары...

Яшь егетнең күңеле әллә нишләде. Ул Чупай тау буйларын, елга ярларын, чәчәкле болыннарны күз алдына китерде. Бездә дә шушылай ук кызу микән? Авыл халкы печәндәдер инде... Уракка төшәр вакыт җитә...

Юл тауга таба иде, сугыш үткән җирдә янган авылларның кызганыч манзарасына карап, Рәшитнең тамагына ачы төер килеп тыгылды, күзләренә кайнар яшь килде. Сугыш... Сугыш... Сугыш аяусыз нәрсә, рәхимсез. Утлы корал — ул үлем. Рәшит моны яхшы белә. Кеше заты биләүдән ук явыз. Рәшитнең үзенең дә, металл көпшәдән ясалма ут коралы ясап, гөнаһсыз җаннарны кыйганы булды.

Сугышта ике як та үзен хаклы саный, берсе дә мин явызлык эшлим, дими. Кеше үтергән өчен мактыйлар, орден, медаль бирәләр. Ә бит ике як та гаепле, алар сәясәт кораллары.

Уйлары бик тирәнгә китте Рәшитнең. Нәкъ менә шушы минутта, бервакытта да булмаганча, аның яшәү теләге көчле иде.

Фронт юлы ничек кенә озын, ничек кенә авыр булмасын, Рәшитнең башыннан тыныч тормыш турында уйлар бер генә минутка да чыгып тормады. «Һичшиксез хирург булачакмын!» — дип план корды яшь военфельдшер Рәшит Бәдретдинов.

***

Кемдер әйткән бит: үткәннәргә без тау өстенә басып, аста калган чәчәкле аланга караган кебек карыйбыз, якын үткән ачыграк, ә ерагы томан эчендә. Меңнәрчә көннәр, чакрымнар аерым-ачык күз алдыннан үтә, колакта ядрә сызгыруы, бомба шартлавы ишетелә, төшләргә кереп сискәндерә. Рәшит менә шул үткән юлларны бер җепкә тезеп, бербөтен итеп күз алдына китерә башлады. Җиңү хакына утка тотылып, җимерелеп калган җирләр, илләр: Иске Оскол... Богодухов... Харьков... Ахтырка... Полтава... Кременчуг... Кировоград... Знаменка... Молдавия... Румыния... Бу озын юл Рәшит өчен кемнәрнеңдер өзелгән аягы, кулы, актарылган эче, ватылган башы, сызлану, сыкранулар юлы иде.

Бу авыр, озын юлда Антонина Рәшит белән һәрчак бергә булды. Аның белән бергә ярдәм сорау, ыңгырашу, саташуларны күреп, тешен кысып түзде, үлүчеләрнең соңгы сулышына шаһит булды.

Рәшит аның матур, мөлаем йөзен, арыган кыяфәтен, моңлы, сагышлы күзләрен һәрчак күреп, тоеп яшәде. Егеткә бу яшь сылу кыз йөз еллар аша аңа таба атлаган, аның бәхетенә туган кебек тоела иде. Алар күп сөйләшмиләр, шулай да менә шул дәшмәү, бер-берсенә күз тутырып, томырылып карау барысы турында да сөйли иде. Бик сирәк кенә алар авырулардан читтә, күзгә-күз карашып, бер-берсенең кочагына ташланалар, Рәшит кызны суырып үбеп ала, ә кыз комачтай кызара һәм егетнең күзләренә туры карап:

— Мин сине яратам, — ди.

— Эх, сугыш булмаса... — ди егет, ә бу сүзләрдә тирән мәгънә ята.

Сугыш булмаса, ул бу мөлаем, нәфис кызны үзенең туган иленә алып китәр иде, беркайчан да үз яныннан җибәрмәс иде.

— Әгәр сугыш булмаса, без синең белән очрашмаган булыр идек, — ди кыз.

— Әйе, — дип килешә аның сүзләре белән Рәшит тә. Ул кызның чәчләренә сак кына кагылып ала, назлап кына шул йомшак чәчләрне сыйпый. Аннан, берсүзсез, ике кулы белән кызны биленнән ала, үзенә таба тартып, күкрәгенә кыса, кыз да аның кайнар күкрәгенә башын салып, күзләрен йома. Икесендә дә гомер буе шушылай бер-берсенә бик якын һәм бик кадерле булып, бер дә аерылмый яшисе килү хисе уяна.

Рәшит бервакытта да ялгыз булмады, дуслары һәм иптәшләре балачагыннан ук күп иде, алар гел янәшә булдылар, ләкин алар дуслар гына иде. Ә хәзер аның ярты җаны кебек кешесе бар. Бу зур бәхет һәм шатлык, әмма һич тә тынгылык бирмәүче борчылу. Нишләргә? Ничек булырга?

ЧИТ ИЛЛӘРДӘ

Җиңү артыннан җиңү килде. 5 нче гвардия Укчылар армиясе Польша аша үтеп, Германиягә барып керде, Брестславль, Бриг кебек кечкенә шәһәрләрдән соң искиткеч матур Дрезден шәһәренә килеп җитте. Рәшит шәһәрне

күзәтте. Урамнар төп-төз, матур, чиста. Чит шәһәр, серле шәһәр. Кибетләрнең барысы да диярлек ачык, урамда кеше аз. Аңлашылмый, монда сугыш булганмы, юкмы? Машинада барганда моны белү авыр, билгеле. Җиргә төшәргә, урамнарда йөрергә кирәк. Шунда гына бу шәһәрнең ни белән яшәвен аңларга була.

Дрезден аша Эльба елгасы үтә, аның тармакларында күпсанлы күперләр, киң төзек юллар, әлләни биек булмаган, бер-берсенә бер дә охшамаган күркәм йортлар. Аннан Чехословакия чигендәге Теплице-Шанов шәһәрен алып, Литомиржице, Хомутово аша армия гүзәл Прагага килеп җитте. Җиңүче, азат итүче булып үтте. Праганы азат иткәннән соң кыска гына вакытка Лидице дип аталган чех авылы янында озак көтеп алынган «Привал!» командасы яңгырады. Озын юл үтеп арыган, талчыккан солдатлар ис-акыл китешле күренешкә тап булдылар. Кайчандыр монда авыл булган, әмма аның урыны гына калган, аны фашистлар тәмам яндырганнар. Бу, күрәмсең, Чехословакиядә оешкан оккупантларга каршы милли көрәш фронт юлы булган. Авыл урынында өелеп көл калган, күмерләнгән агачлар аунап ята, ямьсез мич морҗалары, зираттагы кабер ташлары кебек, шом таратып, серәеп торалар. Кайбер урында әле дә булса аксыл төтен күтәрелә, күңел болгаткыч ис аңкый.

Кеше дигән зат ныклыкка сынау үтте, кеше дигән зат тимер һәм корычтан ныграк булуын раслады. Көннәр, төннәр буталды, илләр буталды.

Апрель башында Америка, Англия гаскәрләре Эльбага таба хәрәкәт итте, Җиңү көне якынлашуы көн кебек ачык иде. «Сез кайда булдыгыз соң безнекеләр Сталинградта канга коенганда? — дип уйлады Рәшит. — Ә хәзер Җиңү көне җиткәч, зуррак калҗа эләктерергә омтыласыз».

Совет гаскәрләре Берлинны камап алды, бөтен дөнья җиңү тантанасын көтә башлады.

5 нче армиянең алдынгы частьләре Эльба ярларына чыгып, Торгоу шәһәре янында 25 апрельдә Американың 1 нче армиясе белән очраштылар. Ике ил гаскәрләре озак көтелгән Җиңү көнен якынайттылар. Өч көн, өч төн шул очрашуны билгеләп, автоматлардан һавага атып, «ура!» кычкырып, ракеталар очырып, иң затлы шәраблар эчтеләр. Кем ак тәнле, кем кара, кем офицер, кем генерал, кем гади солдат, гади фельдшер — барысы бергә җиңү тантанасын билгеләде.

Шулай итеп, 1945 елда Европада барган канлы сугыш тәмам булды. 9 май — Җиңү бәйрәме, бөтенхалык тантанасы көне итеп билгеләнде.

1945 елның июлендә Антонина демобилизацияләнеп үзенең туган ягына, әнисе янына кайтып китте. Рәшит аны поездга озатты.

Поезд әкрен генә кузгалып, тартылып алды һәм тәгәрмәчләр салмак кына тәгәри башладылар. Вагон тәрәзәсенә куллары белән ябышып, Антонина соңгы тапкыр Рәшиткә карады. Рәшит аның йөзен, чәчләрен, күзләрен мәңгегә исендә калдыру өчен аңа төбәлде һәм вагон яныннан атлап:

— Хуш! Сау бу-ул! Без әле очрашырбыз! — дип кычкырды.

АВСТРИЯ

1946 елның сентябрендә аларның частен Австриянең Санкт-Пельтен шәһәренә, аннан озакламый Альп таулары итәгенә урнашкан бик матур крепостька күчерделәр. Ул «Замок Голдэк» дип атала иде. Замокның иң аскы катының диварлары дүрт-биш метрлы. Анда часть җиде ай булды. Аннан тагын күченделәр. Монысы инде Эггендорф дигән авыл иде. Йортлар барысы да кирпечтән, таштан салынган, түбәләр кызыл чирәп белән ябылган, электр, радио кертелгән. Өйләр җимеш агачларына күмелеп утыра. Әллә авыл, әллә шәһәр...

Бу авылга килеп урнашкач, Рәшит туган авылы Чупайны бу авыл белән чагыштырды. Чупай да зур гына авыл, урамнары да киң, ләкин яңгыр яуса — баткак. Ә монда урамнарга ап-ак таш җәелгән. Чупайда өйләр агачтан, күбесенең түбәсе салам, ике тәрәзәсе белән урамга моңаеп, күз яшьләре белән караган кебек күз алдына килде. Лапас артларында дистәләгән сутый бәрәңге бакчасы, ишегалларына җил капка ачыла, сирәк кенә урыс капка.

Австрия. 1938 елда бу чәчәк атучы ил фашистлар Германиясе тарафыннан яулап алына. Фашистлар изүе астында үткән еллар — Австрия халкының иң авыр, иң караңгы еллары. Ул Германиянең хокуксыз провинциясенә әверелә. Аның меңләгән гражданнары фашист терроры корбаннары була. Алдынгы кешеләре Германиянең изүенә каршы көрәшә һәм, ниһаять, 1945 елның 13 апрелендә авыр сугышлар аша Совет Армиясе Австрия башкаласы Венаны азат итә.

Эггендорф авылында Совет Армиясен азатлык армиясе буларак кабул иттеләр. Рәшит исә олыгаеп баручы пенсионерлар йортына урнашты. Аларның өч бүлмәле үз өйләре. Калын-калын идән паласлары, ялтыравыклы шкафларда бәллүр савытлар, рюмкалар, матур бизәкле чынаяклар, көмеш кашыклар. Әмма өйдә таныш түгел ис, тынчу. Йорт тирәли рәт-рәт тезелгән түгәрәкләп формалаштырылган юкә агачлары.

Өй хуҗасы гомере буе кәгазь фабрикасында бухгалтер булып эшләгән. Карт та, карчык та Рәшитне үз балалары кебек яраттылар, аерым бүлмә бирделәр. Ап-ак урын җир, мамык юрган, ягымлы җылы караш — болар барысы да егетнең күңеленә хуш килде.

Медицина хезмәте лейтенанты буларак, аңа ашау-эчү бирелә, ә хуҗабикә төрледән-төрле тәмләткечләр өстәп, өч мәртәбә аны ашата.

Беркөнне күрше кызы, Рәшитне урамда очратып, бик матур итеп елмайды. Аның куе зәңгәр күзләре Рәшиткә төпсез зәңгәрлек булып тоелды. Ә кашлары нәкъ карлыгач канатлары, ә иреннәре пешкән чия диярсең. Кызның гәүдәсе яшь кызларга гына хас нәзек һәм нәфис иде.

Рәшит комачтай кызарды.

— Гильда, — дип кыз аңа кулын сузды.

Рәшитнең йөрәге еш-еш тибә башлады, ләкин бу халәт берничә минутка гына сузылды. Шушы көннән Гильда Рәшитнең эштән кайтканын көтеп тора торган булды. Алар еш кына шулай очраша башладылар.

— Син миңа ошыйсың, — диде Рәшит кызга.

— Мин дә сине беренче күрү белән үк яраттым, — диде Гильда һәм яңагы белән Рәшитнең җилкәсенә сыенды. Шунда егет кызның чәчләренең исерткеч исен иснәде, бу ис — аңа әллә кайчаннан таныш мәтрүшкә исе, коры печән исе, алма исе.

Тагын Рәшит үзенең үсмер елларын исенә төшерде, гүя ул үзен шул малай чагында итеп хис итте. Ул көннәр тыныч көннәр иде. Сугыш дигәннәре телгә дә кергәне юк, авыр еллар булса да, ата-ана белән бергә. Өстә ситсы күлмәк, юка гына сатин чалбар. Аларның бер келәтләре бар иде. Рәшит еш кына шунда йоклый, анда һәрвакыт җиләс, мәтрүшкә исе, алма исе. Алмалары күп иде аларның. Көз җиттеме, идән тулы алма, кәрҗиннәрдә, чиләкләрдә алма.

Рәшит шул җиләс ярымкараңгы келәт эчендә юка җәймә ябынып, шул тәмле истән эреп йоклап китә иде.

Кинәт кыз белән басып торганда Рәшитне каршылыклы хисләр яулап алды. Аның бу кыз белән очрашуын белеп алсалар...

— Ник син эндәшмисең? — диде кыз.

— Мин синең хакта уйлыйм, — диде Рәшит үзенең эчке уйларын яшереп, әгәр кемдер күреп, КГБга хәбәр бирсә, һичшиксез, чиннан төшерәләр яки дәрәҗәсен түбәнәйтәләр. Солдатларның үз-үзләрен тотышын күзәтеп торучы оешмага дөресен әйтергә карар кылды Рәшит.

Озакламый Рәшит хезмәт итә торган частьне Карлштеттен исемле авылга күчерделәр.

ЯКТАШЛАР

Яңа авылга кичкырын, кояш баеп, ут алыр вакыт җиткәч күченделәр. Әйберләрне, җиһазларны җайлап урнаштырдылар. Тагын яңа урын, әмма шул ук эш, яралылар, авырулар. Лазаретның стеналары буйлап койкалар тезелгән, һәркайсында озак терелә алмый яткан авырулар. Күп төрле күченүләр күргән һәм күченгәннән соң яңа урынга тиз ияләшә алмый торган Рәшит монда да бик тиз үз кеше булып китте. Авыруларның документлары һәм карточкалары белән танышты. Яралылар арасында татарлар булуын белеп, шул ук көнне алар белән танышырга булды.

— Ибраһимов Зыятдин сезме? — дип татарчалап дәште Рәшит сары йөзле, ябык урта яшьләрдәге яралыга.

Зыятдин, татарча сүз ишетеп, үзенең яралы булуын, хәле авыр булуын да онытып, урыныннан калкына ук башлады.

— Юк, юк, ярамый, кузгалма, яраң ачылыр, — диде Рәшит йомшак кына. — Кайсы яклардан син, абзый кеше?

— Мин Татарстаннан, Әлмәт районы, Бигәш авылыннан булам. Ишеткәнең бармы, лейтенант?

— Минем якташым икәнсең бит син, минем кадерле яралым, мин дә Әлмәт районыннан, Чупайдан.

— Әнә теге ятакта Нәгыймов Фоат ята, ул Мактамадан.

— Менә бит, тау белән тау гына очрашмый, диләр. Австрия җирендә, әллә кайда, җәһәннәм тишегендә ... дип башыма да килмәгән иде.

Зыятдин елый ук башлады:

— Туган җирләргә кайта алырбызмы, энекәш, юкмы?

— Һи, якташ, күр дә тор. Ай да үтмәс, мин сезне аякка бастырырмын, бергә-бергә үзебезнең Әлмәтебезгә кайтып китәрбез. Кайтып, әле җир җимертеп эшләрбез, яшәрбез.

Һәр көнне, Рәшит алар янына килгән саен, озак-озак туган яклар турында сөйләштеләр. Рәшитнең куллары шифалы булдымы, очрашу куанычыннан дәртләнепме, аларда яшәүгә өмет уянды, яралары күзгә күренеп төзәлде.

ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ

1947 ел якынлашты. Офицерлар Яңа елны шушы авылның клубында каршыларга булдылар. Европада Яңа елны ничек каршылыйлар икән? Рәшит шундый уй белән клубка килде.

Ул килгәндә түбәсендә зәңгәр-яшел-кызыл утлар балкыган биек зур бина тирәсе шау-гөр килә иде. Аны битлек кигән яшьләр ишек төбендә каршы алды.

— Офицер! Офицер! Хуш киләсез!

— Рәхим итегез Яңа елга! — дип кычкырдылар.

Рәшит баскыч буйлап югарыга, икенче катка күтәрелде. Иркен зур залның уртасында мәһабәт, куе яшел пихта — ак чыршы утлы тау кебек янып тора, әкрен генә әйләнә, уенчыклар, гирляндалар елык-елык килеп, күзнең явын ала. Уенчыклар арасында алма, конфетлар күзгә ташлана.

Мондый матурлыкны күптән күрмәгән Рәшит югалып калгандай, кечерәеп киткәндәй булды. Ул үзләрендә Чупайда үтә торган Яңа елларны искә төшерергә тырышты. Иске мәктәпнең тар гына бүлмәсенә утыртылган тәбәнәк чыршыга кәгазьдән ясалган уенчыклар элеп, шуның тирәсендә әйлән-бәйлән уйнаучы бала-чага аның күз алдына килеп басты.

Ә монда — бу авылда нинди зур тантана! Киң залның түрендә оркестр. Аккордеон, саксофон һәм флейта тоткан, кара фрак кигән яшь егетләр уен коралларын көйләп, төрле тавышлар чыгаралар, тантананың ачылуын көтәләр.

Менә Яңа ел җитүен хәбәр иттеләр. Төрледән-төрле битлек кигән кешеләр белән зал тулды. Һәркайсы бәйрәмчә киенгән.

Залны шау-шуга күмеп, оркестр уйный башлады, аккордеон «елмайды», флейта «көлде», барабан вальс ритмын җайга салды. Битлек кигән егетләр, хатын-кызлар янына килеп, ипле генә баш иеп, аларны биергә чакыралар. Бөтен зал бөтерелә. Офицерлар бераз гәпләшеп, музыкада белемнәрен тикшереп алдылар.

— Бу — Иоганн Штраус, кечесе — улы, — диде кемдер.

— Бу нинди вальс?

— Бумы? Бу «Вена урманы әкиятләре» дип атала.

Шул арада алар янына да битлекле кызлар килеп басты.

Менә Рәшит янына бик матур бөрмәләр белән бизәлгән юка гына зәңгәр күлмәкле, маскасына «Jog mich lieb!», ягъни «Мине ярат!» дип язылган кыз килеп басты. Рәшит әллә каушады, әллә уңайсызланды, йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Юк, ул сөенде, чөнки, ниһаять, аны да игътибарсыз калдырмадылар. Кыз ике кулы белән Рәшитнең кулларыннан алды һәм үзенә таба тартып, сул кулын аның җилкәсенә куйды. Рәшит тә югалып калмады, аны биленнән тотты. Кыз бик җиңел бөтерелеп, очына-очына егетне залның уртасына ук алып китте. Бу көтелмәгән дәртле биюдән Рәшит тирләп чыкты. Аh, бу кызның йөзен, күзләрен күрергә иде дип уйлады. Ярамый. Монда шундый тәртип: битлекне ачу — әдәпсезлек, культурасызлык. Рәшит, кызны сак кына биленнән тотып, урынына илтеп куйды. Әсәрләнгән, дәртләнгән офицерлар кызып-кызып сөйләштеләр, көлештеләр. Бераздан оркестр яңа вальс уйный башлады. Бу юлы Рәшит янына битлегенә «Ewig nur deine!» дип язылган кыз килеп басты һәм тыйнак кына аның җилкәсенә сул кулын куйды. Вальс артыннан вальс кабатланды. Кызлар әллә сүз куешканнар, әллә башка сәбәп белән, әле берсе, әле икенчесе алмаш-тилмәш Рәшитне биергә чакырды.

Бу карнавал-маскарад Австрия халкының нинди культуралы, зәвыклы, җыр-бию сөючән, шаян халык икәнен күрсәтте. Сугыштан соңгы җимереклек, авырлыкларга карамастан, халык тантана итте.

ТУГАН ҖИРГӘ

1947 елның 27 апрелендә Рәшитне хәрби хезмәттән азат иттеләр. Австриянең Баден шәһәрендә тимер юл станциясендә хәрби хезмәттән азат ителгән солдатлар, офицерлар җыелган. Оркестр уйный, чәчәкләр.

Вагон ишегенә керәм дип торганда Рәшит әллә кайдан ерактан чәчрәп йөгереп килүче Гильданы танып алды.

— Рәшит! — дип кычкырды Гильда, кешеләрне этә-төртә аңа якынлашты һәм егетнең муенына сарылды. — Ал мине үзең белән! Ал, ал!

Рәшит белән Гильданың икесенең арасына каяндыр зур гына чәчәк бәйләме килеп төште. Рәшит тирә-ягына каранып алды, башкалар да елый-елый озатышалар.

«Минем кайчан һәм кайдан китүемне бу кыз каян белгән? Эггендорф авылы моннан илле чакрым ераклыкта бит. Ул монда ничек килеп чыккан? Гаскәрләрнең бер урыннан икенче урынга күчүләре, килү-китүләре бик тирән хәрби сер ләбаса. Каян белгән?» — дигән уйлар Рәшитнең фикерләрен чуалтты.

Гильда исә җылы тынын Рәшитнең битенә өрә-өрә: «Ал мине дә үзең белән! Ал!» — дип ялынды. Егеттән җавап ишетмәгәч, ул бөтен гәүдәсе белән аңа елышты, гүя ул шушы якынлыкны мәңгегә исендә калдырырга теләде. Рәшит аның җилкәсеннән кочып, җәйге күл төсле куе зәңгәр күзләренә карады, нәфис, сөякчел кыз аңа бик бәләкәй кебек тоелды.

— Я, булды, Гильда! Җибәр! Хуш, — диде Рәшит һәм вагонга менде.

Поезд алга ыргылды. Тирә-якта кызыл чирәп түбәле авыллар кояшта янып, Австриянең зур-зур тәрәзәләре көзгедәй ялтырап, артта калдылар. Чит-ят җирләрдә йөреп, күпне күреп, күпләр белән аралашып тәэсирләнгән, купкан күңел әкренләп урынына утыра төште. Австриянең таш җәелгән урамнары, очы күкләргә ашкан манаралары, чибәр кызлары хәтердән югала барды. Советлар иленең җимерек капкалары аша, иске вагоннарда шыгыр-шыгыр кайту бик авыр булса да, үз җирең — үз җирең инде. Кайда туган, шунда яшәргә тиеш кеше.

САУМЫ, ӘНКӘЙ!

Рәшиткә юл бик озак, озын, ялыктыргыч тоелды. Бер яктан, юл буе чәчелгән җимерек, күмергә әйләнгән авыллар, таш өемнәрен хәтерләткән шәһәрләр, елаудан уңып, төссезләнеп беткән хатын-кыз күзләрен күрү күңелне гасабиласа, икенче яктан, барысыннан да өстен, куаныч биргән җиңү, өмет, хәзер барысы да ал да гөл булыр дигән уй иләсләндерде.

Рәшит туган авылына җәяүләп кенә кайтып керде, аркасындагы биштәрендә яшь тамчылары кебек чиста намус һәм җиңү шатлыгы иде. Биш елга якын чит җирдә, чит кешеләр арасында, сугыш зилзиләсендә йөрү, аны, авылдан чыгып киткәндә унсигез яшен генә тутырган авыл малаен, бүген егет булып буй сузган, солдатларча җилкә калынайткан, авырлыкларны җиңгән ир-егеткә әйләндергән. Үткән юлы аның авыр һәм гыйбрәтле булды, әмма беркайда да абынмады, аек акыл аны ташламады, шуңа да ул авылдашларының, туганнарының йөзенә, күзенә туры карый ала. Шул уйлар белән ул адымын кызулатты, юлны йөгереп диярлек үтте. Менә Мөгаммәрләр өе, Мидхәтләр капкасы. Авыл үзгәргән, йортлар искергән, агачлар киселгән, капкалар кыйшайган, читәннәр ауган.

Кечү елгасы гына, берни булмагандай, салмак кына ага да ага, ярларына сыярга теләми ярсый. Шул әллә ни үзгәрмәгән, элеккечә үк шаулап аккан елганы күреп, ул бераз тынычлангандай булды. Ни генә булса да, алда аны ни генә көтсә дә, аңа барыбер — ул туган җирендә, туган йортында. Чит илләрдәге таш пулатлар, асфальт юллар аның күзенә дә күренмәде, ул шушы үзенең сукыр тәрәзәле кечкенә өен сагынды.

Бусаганы атлап керү белән аның йөзенә туган өенең таныш җылысы бөркелде. Ул үзләренең шушы дүрт почмаклы, зур мичле кечкенә өен сагынган иде. Өй эче бик тар, түшәм тәбәнәк, тәрәзәләр мөлдерәгән яшьле күзләр кебек күренде Рәшиткә. Аның кадерле әткәсе инде якты дөньядан киткән, әнкәсе ялгыз тормыш итеп ятадыр.

«Кая киткән соң әнкәй?» — дип уйлады Рәшит һәм ашыгып ишегалдына чыкты. Ярымҗимерек лапастан бер кулы белән алъяпкычын йомарлап тоткан әнкәсе аңа таба атлады.

— Әнкәй! — дип кычкырды да, Рәшит әнисенә каршы йөгереп барып, аны кочаклап алды.

Ананың алъяпкычындагы йомыркалар җиргә төшеп ватылдылар.

— Һай, Ходаем! Улым! Синме соң бу? — ана йомыркаларның төшеп ватылуларына игътибар да итмәде, улының бик килешле хәрби киемен, күкрәгендәге медальләрен сыйпады.

— Кайгырма, әнкәй, тагын салырлар, — диде Рәшит, җирдә сап-сары булып җәелгән ватык йомыркаларга ишарәләп.

— Ризык булмагандыр, — дип куйды Сәрбиҗинан.

Рәшит әнисен алдан җибәреп, аның артыннан атлады. Әнисе бөкрәйгән, тәбәнәкләнгән, аякларын авыр атлый, кайгы-хәсрәт, ярлылык баскан. Өйгә керделәр. Рәшит һәрбер әйберне, өстәлне, урындыкларны, әнисенең өстәлгә куйган Коръән китабын капшап-капшап алды. Аннан мич каршысына килеп аны ике кулы белән кочаклагандай итте. Мич сап-салкын иде. Күптән инде ипи пешерелмәгән.

Шул арада, каян ишеткәннәрдер, туганнары җыелды, һәркайсы Рәшитне кочаклады, үпте, сөйде.

Иң беренче булып капкада Дөрлиҗинан апасы күренде, ашыгудан аның башындагы ак яулык әллә ничек салынып төшкән, чәчләре яулык астыннан бүселеп чыккан. Ишектән атылып килеп керде дә үксеп елый-елый Рәшитнең муенына ташланды.

— Кайттыңмы, җанкисәгем! Кадерлем, чибәрем, Нургалием генә кайтмады, чит-ят җирләрдә ятып калды, — дип әрнеп күз яшьләрен түкте.

Рәшит, аны кочаклап, җылы сүзләр белән юатырга тырышты. Гади сүзләр генә ачыргаланган йөрәккә дәва була аламы соң?!

Шул арада Миңзифа җиңгәсе белән Рәфикъ килеп керде. Миңзифа:

— Рәшит иркәм, кайттыңмы? Син исәнме? — дип Рәшитнең яңакларын, җилкәләрен капшады, — гомерләре булганнар кайта... менә минем Карәметдинем генә якты дөньяда юк.

Күз яшьләре, елау-сыктаулар бик күп булды. Рәшитнең яшьтәшләре, кордашлары Габделхак, Гәрәйша, Хәмидулла сугыш кырларында калганнар. Иң якын дусты Мөгаммәрнең Җиңү бәйрәме көнендә үлгән хәбәре килгән.

Бу сөйләшүләр, бу хәбәрләр Рәшитнең йөрәгенә сугыш яраларыннан да ачырак сызлау салдылар.

Беренче көнне Рәшит әтәч кычкырган тавышка уянып китте. Бу тыныч тормыш тавышы иде.

УКЫРГА, БЕЛЕМ АЛЫРГА

Хәрби киемнәрен салгач, тыныч тормышта яшәүне ничек дәвам итәргә? Ул шул турыда озак уйланып ятты. Укырга! Белем алырга!

Иң беренче эш итеп ул Антонина биргән адреска Самара өлкәсенә хат язып салды. Хаты ничектер коры, рәсми булып чыкты. Хисләр төссез, буталчык иде. Үзе язарга теләгәннәрне ул барысын да хатка сыйдыра алмады. Язып бетерде дә бер кат укып чыкты. Хат әлләни җылы һәм шома түгел иде, коры-коры җөмләләр һәм өзек-өзек фикерләр. Шулай да ул хатны ертмады, конверт тышына матурлап адрес язып, почта тартмасына илтеп салды. Әмма, никадәр генә көтсә дә, Рәшит Антонинадан бер генә хат та алмады, хат артыннан хат язды, кызны сагынудан һәм хат көтүдән озак кына үзенә урын таба алмады.

Рәшит август аенда Уфа медицина институтына имтиханнар тапшырып, шунда укый башлады. Бу белем йорты, чыннан да, аның чын үз урыны, ул шул медицина өчен туган, теләк зур, тәҗрибә бар, төпле теоретик белем кирәк иде егеткә.

Имтиханнар вакытында яшь кызлар һәм егетләр офицер киеме кигән яшь егетне аеруча зур игътибар һәм ихтирам белән күзәттеләр. Аңа яңа гына өлгергәнлек аттестаты алган яшьләр белән тартышу җиңел булмады. Әмма кичәге фронтовикның имтихан кенәгәсенә «Дәвалау факультетына кабул итәргә», дип язып куйдылар. Ул яшьләр арасында үзенең җитдилеге белән генә түгел, ә укуга җаваплы карашы белән дә аерылып торды, кичләрен уку залларыннан иң соңгы кеше булып китә, дәресләргә иң беренче булып килеп утыра иде. Галимнәр дә аның төпле егет икәнен, кызыксынучанлыгын һәм белемгә омтылуын сизеп алдылар.

Институт ректораты сугыш юлын үткән лейтенант Бәдретдиновның Октябрь бәйрәмендә яшьләргә берничә сүз әйтүен үтенде.

— Мин, — дип ашыкмый гына Рәшит сүз башлады, — үткән юлларымда, узган елларымда менә нәкъ шушы минутларны күрү турында хыялландым. Парта арасына утырып, тыныч тормышта белем алу минем иң зур хыялым иде. Мин күп мәртәбәләр үлем белән очраштым, күпләрне аның тырнагыннан тартып алдым, кызганычка каршы, бик

күпләрне җирләргә туры килде. Менә шул чакта мин үземә сүз бирдем: белем, тирән белем алырга, беркемне дә аяусыз үлем тырнагына тапшырмаска. Кеше өчен сәламәтлектән дә кадерлерәк, яшәүдән дә татлырак берни дә юк, — диде егет.

АЛИЯ

Алия белән алар Уфа педагогия институтының бию залында очраштылар. Рәшит кызны биюгә чакырды, һәм алар бер сүз дә алышмый гына көчле музыка астында дәртләнеп-дәртләнеп биеделәр. Биегәндә Рәшит кызның алсу йөзенә, озын керфекләренә күз салгалады, әмма сүз катарга, туры карарга кыймады. Матур, гүзәл, тыйнак кыз дип фикер йөртте.

— Сезнең исемегез ничек? — дип сорады Рәшит кыздан урысчалап, кабат танцыга чакырып чыгаргач. Ул аның урыс кызымы, татармы икәнен белми иде әле.

— Алия. Минем исемем Алия, — диде чибәр кыз, йомшак тавыш белән.

— Бигрәк матур, үзегез төсле икән, — диде егет, кыюлана төшеп. Алар моннан соң татарча гына сөйләштеләр. Озак тормады Алия, каядыр юкка чыкты. Рәшит тә, кәефе кырылып, кайтып китте. Беренче очрашу менә шулай тәмамланды.

Берничә атнадан Май бәйрәме җитте. Рәшит бәйрәмгә Чупайга кайтмаска булды. Пединститутка барам, бәлки анда тагын Алияне очратырмын дип уйлады ул. Һәм шулай булды да. Ул юып киптерелгән гимнастеркасын бик озак үтүкләде, туфлиләрен майлады, ялтыратты һәм кичке җиделәргә пединститутның биюләр залына килде. Зал шаугөр килә. Алия килмәгән булса? — дип, икеләнә-икеләнә, як-ягына каранып, һәр басманы санагандай, җай гына баскычтан күтәрелде. Алия күренмәде. Рәшит залга килеп керде. Әнә! Залның уң як ерак почмагында ялгыз гына Алия басып тора. Рәшит Зөһрә йолдызга сокланган кебек озак кына карап торды да аңа таба атлады.

— Алия! Саумы! — диде ул якын килеп. Алия уянып киткәндәй булды, моңсу йөзенә бераз гына алсулык йөгерде, елмайды. Рәшит исә, кызны күрүенә чиксез шатланып, аның кулларына үрелде, кыз кулларын тартып алмады.

— Бәйрәм белән! — диде Рәшит, май кояшыдай балкып, — биибезме?

Алия җавап бирмәде.

— Биибезме? — диде Рәшит кабат, тавышын бераз күтәрә төшеп, һәм кызның куе керфек арасына яшеренгән зәңгәр күзләренең төбенә төшәрдәй булып, туп-туры карады, ә кыз аның артык кыюлыгыннан оялыпмы, тирә-ягына каранып алды һәм керфекләрен түбән төшерде. Рәшит, тагын әрсезләнә төшеп, аны үзенә таба тартты һәм музыкага уңга-сулга аякларын авыштырып, уң кулы белән кызның биленнән алды. Алар бии-бии кешеләр арасына кереп киттеләр. Рәшит бертуктаусыз кызның аз гына елмаю сирпелгән куе зәңгәр күзләренә карады, ул бүген үзен бик бәхетле сизде, җиңел биеде, сүзләре дә матур чыкты.

— Бәлки якыннанрак танышырбыз, Алия! — диде ул биюдән тукталгач, кызны залның тынычрак урынына әйдәп. Алиянең кәефе яхшы түгел иде, күрәсең. Ул Рәшитнең сорауларына теләр-теләмәс, ым белән генә җавап биргәләде. Бигрәк тә оялчан инде безнең татар кызлары, дип уйлады егет. Аның күңеленә каршылыклы уйлар килеп борчыды. Шундый да нәфис, чибәр кыз, үзе үзсүзле. Ник? Ни өчен? Шатлык, өмет, ярату егетнең йөрәгендә мөлдерәмә, чайпалып, түгелеп тора лабаса. Ул аны яшерми дә. Ә кыз сөйләшми. Кем соң ул? Этисе? Әнисе? Аны ничек сорарга?

Бар бит дөньяда шундый дә әдәпле, чибәр, чәчрәп тормый торган татар кызлары.

Моңарчы Рәшит кызларның ниндиләрен генә күрмәде?! Үзләре аның муенына асылындылар, башларын югалтырдай булып гашыйк булдылар. Алар инде онытылып бара. Ә миңа нәкъ менә шушындый әдәпле, оялчан татар кызы кирәк, дип уйлады Рәшит. Алия, Алия. Ул намуслы, саф күңелле, беркем дә, беркайчан да аның нәфис кулларына кагылмагандыр, күзләренең серен беркем дә алмагандыр. Шушы уйлар Рәшитне бөтереп алды. Аның тормышы үзгәрәчәк! Ул тиздән диплом алачак! Өйләнәчәк! Фәкать Алиягә өйләнәчәк! Алия аның Ходай биргән насыйбы.

Тик аңа бер нәрсә тынгылык бирмәде: солдат киемнәрен дә салып ташлый алмаган авыл малаен кыз үз итәрме? Аның мәхәббәтен аңлармы? Бәлки аның яхшы киемле егете бардыр. Читтән күзәтеп торадыр. Рәшит тирә-ягына каранды.

Шулчак аңа дистәләгән күзләр аларга төбәлгән кебек тоелды. Кайсысы аныкы? Әнә, кара костюм, ап-ак күлмәк кигән, галстук таккан озын егетнең күзләре гел Алиядә. Кая инде Рәшиткә аның белән тартышырга. Ул хәтта тешләрен шыгырдатып алды һәм Алиягә борылып карады. Кызның керфекләре түбән төшкән, ул беркемне дә күзәтми, беркем белән дә карашлар алышмый. Рәшит тынычланды, аның шик-шөбһәләре озакка бармады. Алар тагын биеделәр. Шул кичтән соң очрашулар, күрешүләр башланды.

Рәшит озакламый Алияне әнисе белән таныштырырга булды, ул кызны үзләренә кунакка чакырды.

Кыз әнисенә бик ошады. Авыл кызы, гади, тыйнак, күп сөйләшми, дип уйлады ана.

— Бу кыз сине ярата, улым. Син нәрсә, күрмисеңме әллә? Ярата белү зур бәхет ул, — диде күпне күргән ана. — Ә син үзең яратасыңмы соң? Яратсаң, кыюрак бул, аны бәхетле итәргә тырыш.

Ананың бу сүзләрен тыңлаганда Рәшит болайрак фикер йөртте: «Эх, минем кадерле әнкәем, син үз улыңны иң чибәр, иң акыллы кызга өйләнергә тиеш дип уйлыйсың. Синең улың авыл баласы, авыл тәрбиясе алган, гади, бәлки тупасрак та, игътибарсызрактыр да. Без бер-беребезгә туры киләбезме соң?»

Әйе, алар икесе дә бер тирә, бер чама, яшь аермалары гына бар. Рәшит Алиядән җиде яшькә зур иде. Ул ятимә кыз, ә Рәшит солдат киемен дә алыштырырга хәле булмаган ярлы авыл малае. Алар икесе дә бу очрашуның язмыш, өметле, якты язмыш икәнен, ике ачы язмышның бер төенгә бәйләнгән икәнен аңладылар. Алия генералга чыкмады, гапгади Рәшитне сайлады. Ике ел буе хатлар алыштылар, өйләнештеләр. Бервакытта да, бер генә көнгә дә берберсеннән аерылышмаска дип күңелләренә беркетеп куйдылар. Ә мәхәббәт? Мәхәббәт акчасыз да тормышны бакча итә, диләр бит. Чәчәкле бакча булды аларның тормышы. Алия, моңа кадәр беркемне дә чын ярату белән яратмаган яшь кыз, үз-үзен онытырдай булып гашыйк иде. Ул Рәшитнең аны яратуы, яратмавы белән кызыксынмады, сорамады. Әмма егетнең игътибарлылыгы, ихтирамлы, нәзакәтле булуыннан үзенең аңа кирәк икәнен аңлый иде.

Яшь табиб Рәшит Бәдретдиновны Әлмәт район хастаханәсенә хирург итеп билгеләделәр. Алар язылыш-тылар,

зурлап туй ясадылар. Алия юллама белән Әлмәткә укытучы булып кайтты. Яшь гаиләгә фатир бирделәр, көянтә-чиләк белән су ташып, утын ягып яшәделәр. Тормыш җиңел булмады. Шул кечкенә фатирга тугызынчы сыйныф-та укырга Алиянең сеңлесе, сигезенче сыйныфка Рәшитнең туганының кызы килде, бүлмәләр кысанланды, түзделәр. Бер елдан кызлары Гүзәл туды. Уңайлыклары булган ике бүлмәле фатир алдылар.

Язмыш Рәшиткә зур бәхет тоттырды. Өйдә һәрвакыт җыйнаклык, чисталык булды, һәрчак ризык әзер, кием юылган, үтүкләнгән. Хатының уңганлыгына да, тулып торган алсу түгәрәк йөзенә, куе кара чәчләренә карап алу гына да Рәшиткә чиксез ләззәт бирә иде. Алия үзе дә еш кына көзгегә карап, эчтән генә үз-үзенә сокланып куя, моңарчы бервакытта да булмаганча бәхетле елмая. Ә ятимлек, күз яшьләре, сабый чаклары әллә кайда еракта, томан артында калгандай булып тоела.

Авыр тормыш юлы узган Алия үзенең сизгер күңелен, нечкә хисләрен тормыш зилзиләләрендә дә, язмыш җилләрендә дә тоныкландырмыйча, бүгенге көнгә кадәр саф килеш саклый алган. Мәхәббәт, ярату дип аталган илаһи хисләр аның күңеленең серле сандыгына биклән куелган. Ә үткәннәрне, яшьлекне сагыну, юксыну, газаплану хисләрен ул йөрәгенең иң тирән бер җирендә саклый. Әмма аның туган авылым, туган җирем дип атардай урыны юк. Ата-ана җәбер-золым елларында очраклы рәвештә барып чыккан Мәскәүме ул? Ятимлектә, якты чырай күрергә тилмереп яшәгән Салаватмы ул? Бабаларының туган, торган җире Яңавылмы? Ул бу сораулар алдында көчсез? Аның нәсел-нәсәбе, кыргый ерткыч пыр туздырган асыл кош оясы кебек, таралган, туганнары, кош каурыйлары кебек, кайсы кая җиргә төшеп, урын тапкан, күбесе төрле җирдә, төрле зиратларда ята.

ҮРЛӘР ЯУЛАУ

Сугышның соңгы гөрелтесе туктагач, анда күргәннәр гомергә дә онытылмас кебек иде. Тик еллар үткән саен яңа вакыйгалар туып тора, яңа кешеләр очрый, ул еллар ничектер күләгәдә кала бирә, бик сирәк искә төшә. Шулай да кеше йөрәгендә гомере буе «Мин — җиңүче!» дигән горур

кыңгырау чаң кагып тора. Бу җиңүдә аның да кан тамчысы, газаплары бар. Аларны кеше ничек онытсын?! Тормышта булган яки булуы мөмкин булган бер генә хәсрәт тә, бер генә сынау да аның белән чагыштырыла, рәттән куела алмый.

Әлмәтнең шәһәр булып яңа күтәрелеп килгән еллары. Төрле җилкуар, әтрәк-әләм, эчкече, хулиган, «төрмә сандугачы», илнең төрле почмакларыннан җылы урын эзләп, монда җыелган еллар. Сугыш, үтерешләр. Көн-төн кеше тормышы өчен көрәш бара. Хастаханәгә көн-төн канга баткан, ярымүлек гәүдәләр китерелә. Хирург бертуктаусыз эштә. Нәкъ фронттагыча Рәшит Бәдретдинов иң элек авыр яралыларны карый. Ашыгыч эш башлана.

Операция — кеше гомере өчен көрәш: Хастаханәдә бертуктаусыз киеренкелек. Операция буласы бүлмәнең ишеге өстендә кызыл ут яна: «Тынлык! Операция бара!»

Хирургның кулында юка перчаткалар, ак халатының җиңнәре сызганылган, авыз һәм борынында марлядан ясалган битлек. Бүлмәдә бик көчле лампочкалар яна. Ә биек өстәл өстендә, канлы гәүдә. Бүлмәдә тынлык, барысы да урынында, инструментлар, аппаратлар. Аның каршысында өстәлнең икенче ягында ассистент, аның янында шәфкать туташы. Операция башлана.

Рәшит институтта бик яхшы укыды. Хирург өчен иң кирәкле сыйфатларны ул үзендә сугыш юлларында булдырды: тәвәккәллек, салкын канлылык, үз-үзенә тирән ышаныч.

***

Рәшит Бәдретдинов исеме Әлмәттә генә түгел, республика күләмендә еш искә алынды, матбугат битләрендә аның хезмәте турында язмалар күренә башлады. Аның турында «иң кыю», «новатор хирург» дигән сүзләр йөрде. Медицина хезмәткәрләре алдында ясаган чыгышлары бик югары бәяләнде.

Табибларның гомуми җыелышында, эше күп икәнен сәбәп итеп, ничек кенә баш тартырга теләсә дә, Рәшит Бәдретдиновны, яшь кенә булуына карамастан, район һәм шәһәр Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәттеләр.

Менә шул еллардан ук аның хезмәт юлы, иҗаты, новаторлыгы көчле локомотив кебек бертуктаусыз алга ыргылды.

Рәшит Бәдретдинов 1956 елда «Әлмәтнефть» идарәсенең яңа төзелгән һәм оешып килүче медсанчастенең беренче баш табибы итеп билгеләнде. Аңа хастаханә комплексының төзелеш эшләрен тәмамлау, кадрлар туплау, дәвалау учреждениесенең эш режимын җайга салу йөкләнде. Шулай итеп, ул нефть чыккан мәшһүр якларның, хезмәт сөючән халкының сәламәтлеген саклау, халыкка медицина хезмәте күрсәтү эшенең башында булды.

Гаилә ишәйде. Гүзәлдән соң улы Рөстәм дөньяга килде.

Беркөнне Рәшит хатыны Алиягә:

— Син сизәсеңме, миңа алга таба укырга кирәк, мин аспирантурада белемемне күтәрергә тиеш, бүгенге көн белән яшәргә ярамый, — диде.

— Тагын күпме укырга? Сиңа ирешкән уңышларың җитмиме? — диде Алия.

Бу сөйләшү бик авыр һәм катлаулы булды. Алия елап та алды. Ул балалар белән берүзе нишләр? Алар икәү бит. Рәшит үзенең тәҗрибәләре, ачышлары турында язмалар теркәлгән катыргы тышларны кулына алды:

— Менә бу папкалар, материаллар — минем тәҗрибә җимешләре. Алар фән өчен кирәк, Алия! Мин кешеләргә, медицинага, җәмәгатьчелеккә белемнәремне, ачышларымны җиткерергә тиеш, аңлыйсыңмы? Аларны тузанга батырып яткырырга ярамый. Шул ачышларны системага салу өчен укырга тиеш мин, Алия!

Рәшит Бәдретдинов 1956 елда Мәскәү шәһәрендә А.Н.Бакулев исемендәге күкрәк хирургиясе институтында, гаиләсеннән еракта өч ел аспирантурада укыды.

Чупай авылы егете үз халкына, кешеләргә хезмәт итү өчен тагын да югарырак күтәрелде, тагын да серлерәк белем ачкычларын алды. Ул кайчандыр бу турыда уйлый ала идемени? Әмма бүген инде ул үзен артта калган кеше итеп күз алдына китерә алмый. Баш иеп, башын саклап, иелгән башны кылыч кисмәс, дигән принцип белән яши алмый. Юк, юк! Аның тормышында, хезмәт юлында төрле кешеләр очрады, көнләшүчеләр, астан эш йөртүчеләр дә табылды. Әмма юкка гына халык: «Беләге юан берне ега, белеме зур

меңне ега», — дип әйтмәгәндер. Ул сугышта явыз дошман алдында баш имәде, инде фән гыйлемен дә үзенә баш идерде, дошманнарын җинде. Ул һәрчак җиңүче булды. Шундый очракларда һәрвакыт күптән булып үткән бер хәл аның исенә төшә. Сугыш вакыты. 1944 ел. Польша җире. Ул берүзе алгы сызыкка таба урман буеннан атлый. Якында гына бер зур кара елан шуыша иде. Елан кинәт кенә башын күтәрде. Рәшит шундук кобурадан парабеллумын (немец офицерлары пистолеты) тартып чыгарды һәм еланның башына төбәп атып та җибәрде. Башсыз елан гәүдәсе боргалана-боргалана шунда ятып калды.

ДИССЕРТАЦИЯ

Авыруны үлем тырнагыннан йолкып алып, яшәү шатлыгын тоярга ярдәм иткән табибтан да бәхетлерәк кеше юктыр дөньяда. Ул да изге аналар кебек кешене яңадан тудыра, аңа яшәү көче бирә. Кеше яңадан яши башлый.

Рәшит Бәдретдинов диссертациясен әзерләгәндә бик күп мәртәбәләр гаять авыр, катлаулы операцияләрне уңышлы башкарып чыкты. Һәрбер операциядән соң ул күңелендә зур куаныч, чиксез илһам һәм иҗади үсеш хис итте. Шуңа күрә еш кына, яшь чаклардагы киеренке мизгелләрдәге кебек, тамак төбенә кайнар төер утырып, күз кырыйларына бер генә бөртек яшь бәреп чыга иде, сөенеч, канәгатьлек, шатлык яшьләре иде ул. Ул яшь кенә кыз балаларның йөрәгенә, үпкәсенә операцияләр ясады. Ничә мәртәбәләр ул шул кыз балаларның бәхеттән ялтыраган күзләрен, кайчандыр күгән кебек булган иреннәренең операциядән соң озак та тормый пешкән чия төсле кып-кызыл булып янып торганын күреп куанды.

«Клиника и лечение бронхиальных свищей после радикальных операций на легких» дигән темага ул диссертация язды.

Җәй көне кичке шәфәкъ бик озак сүнә, көннәр озын, төннәр кыска. Кыска гына булса да, төн иртәгесе көнгә көч, кодрәт җыю өчен кирәк. Рәшитнең иртәгә бик җаваплы көне, бераз ял итәргә кирәк. Ләкин ул тиз генә йоклап китә алмады, чалкан яткан килеш диссертациясен башыннан ахырына кадәр исенә төшерде. Ул урыннан торды, ут яндырмый гына тәрәзә янына килеп басты. Сихри-әкияти

дөнья булып Мәскәү балкый, мәһабәт биналар хан сарайлары кебек күзнең явын алып торалар. Автобуслар, троллейбуслар шау-гөр килеп үтеп китәләр. Тагын беразга гына тынлык урнаша. Рәшит тагын урынына барып ята, күзләрен йома, әмма күзенә йокы керми.

Институт бинасына килгәндә аның авыр ишекләреннән дистәләгән кешеләр бер-бер артлы керәләр иде инде. Рәшит тә эчкә үтте. Ул, бөтен дөньяга исемнәре танылган галимнәрне күреп, үзендә бераз каушау сизде. Бу галимнәр турында ул фәкать журнал битләреннән укып яки институтта профессорларның лекцияләреннән генә ишетеп белә иде. Менә алар аны тыңларга килгәннәр. Юк, каушамаска, нык булырга!

Диссертацияне ул уңышлы яклады, бертавыштан аңа «Медицина фәннәре кандидаты» дигән исем бирделәр.

ПОДОЛЬСК

1963 елда фәннәр кандидаты, яшь галим Рәшит Заһретдин улы Бәдретдиновны Мәскәү өлкәсе төбәк хастаханәсенә — Подольск шәһәренә баш хирург итеп билгеләделәр. Һәрвакыттагыча яңа урын, яңа кешеләр белән очрашу аны бик дулкынландырды.

Менә юкә агачларына күмелеп утырган күп катлы хастаханә. Андагы табиблар, хезмәткәрләр ничек каршылар?

Тиздән аны яңа вазыйфалар, яңа мәшәкатьләр урап алды. Гаиләне күчерәсе, балаларны алып киләсе — бу уйлар аның йөрәгенә якты шатлык бирде.

Рәшит Бәдретдинов бик тиз арада кирәкле кеше булып китте. Һәркөнне аңа табиблар, шәфкать туташлары алдында чыгышлар ясарга туры килде. Аңа шушы елда ук «Югары категорияле хирург» дигән исем бирелде. Бер елдан шул ук хастаханәнең баш табибы да булды.

Авырулар белән күзгә-күз очрашканда ул һәрвакыт дулкынлану хисләре кичерә. «Ник дулкынланасың? Син бит бик стажлы медик», — дия иде ул үз-үзенә. Ә шулай да дулкынлана. Дулкынлану ул кешене хөрмәт иткәннән була торган халәт икәнен ул бик яхшы белә.

Кичләрен уйланып утыра торгач, ул йокыга тала, әмма йокысы тыныч булмый. Ул йоклар-йокламас ята яки йокы

аралаш үзенең көндез башкарган эшләрен күңеленнән кичерә. Әгәр инде тирән итеп йоклый алса, бу бәхетле төннән соң аның кәефе бик яхшы була, башы да авыртмый, тәнен дә бик җиңел хис итә.

Табиб иң элек башкалар өчен яши. Аның тормышының бөтен эчтәлеге — авыруларны терелтү. Ялгызмы ул, сагынамы, кайгысы бармы, ни генә булса да, аның сыгылып төшәргә хакы юк.

Подольск — элек-электән тегү машиналары белән дан тоткан шәһәр. Ә бу кечкенә шәһәргә егерме еллар элек, халык өстенә җәфа булып, зур индустрия ишелеп төште. Нинди генә завод- фабрикалар төзелмәде биредә шул еллар эчендә. Чималны китертү һәм әзер продукцияне алып китү уңай булсын өчен ул заводлар тимер юл буйлап төзелделәр, аннан соң күп катлы йортлар калкып чыкты. Шул заводлар шәһәр үзәген тәшкил иттеләр. Дөрес, скверлар булдырылды. Әмма завод-фабрикалар белән чагыштырганда алар бик аз. Ике йөзгә якын предприятиенең зарарлы газларын йотарга алар гына җитми.

Менә шуңа күрә дә халык бу шәһәрдә начар һавага бәйле авыруларның чуар «букеты» белән интегә. Күз һәм тын юллары авырулары караганда Подольскида илдәгедән өч мәртәбә күбрәк. Аккумуляторлар заводы гына да ни тора! Ул халык сәламәтлегенә бик зур зыян сала. Аның җитештергән продукциясе башка бер җирдә дә җитештерелми. Кара кургаш участогы да бик сирәк очрый торган производство. Кара кургаш сәламәтлек өчен зарарлылык ягыннан беренче урында тора. Аның кислород белән кушылмасы туфракта туплана. Шуларга машиналар, поездлар калдырган пычрак өстәлә. Шәһәрдә еш кына төннәрен хлорлы водород исе аңкып тора. Химия-металлургия комбинаты цистерналарын юа, пычрагын атмосферага ташлый — беркем дә күрми бит. Менә шушы индустриянең ялкынлы учагы булган шәһәрдә Рәшит Бәдретдинов баш табиб, фтизиатр-хирург булып эшли башлады.

Берничә айдан, ниһаять, ул гаиләсен Подольскига алып килде. Алия дә шул ук елны эшкә урнашты — эшче яшьләр мәктәбендә математика укыта башлады.

ГАИЛӘ БӘХЕТЕ

Рәшит кибеттән яңа костюм алып, тротуар буйлап әкрен генә атлап өйләренә якынлашты. Кичке аш әзердер, Алия өстәл әзерлидер. Ул аш-суга бик оста, өстәлне һәрчак матур итеп җиһазлый. Кунаклар чакырырга ярата. Аларның аш бүлмәсе зур түгел, әмма бик чиста, җылы һәм бик якты, операция бүлмәсендәге кебек. Тик тегендәге стерильлек ул саргылт, дару, йод таплары белән «бизәлгән» стирильлек, ул бөтенләй башка. Ә Алиянең сөлгеләре шикәрдәй, яңа яуган кардай ап-ак, зәңгәрсу. Өстәл җәймәсе крахмалланган, газ плитәсе көзге кебек ялтырап тора. Су краннары кояшта елык-елык килә. Тәрәзә төбендә чәчәкле гөлләр. Өйдә бар ашамлык тәмле, татлы, сәламәт һәм күңелне күтәрә.

Ул сөзек баскычтан фатирына күтәрелде, үз ачкычы белән ишекне ачып керде. Алиягә күз ташлады. Алиянең йөзе тулган ай төсле якты: ул аның юлга чыгасын белгән икән. Каян белгән? Чыбыксыз телефоннармы, чыбыклыларымы хәбәрне җиткергәннәр.

— Хәерле кич, — диде Рәшит киң елмаеп.

— Хәерле, — дип җавап бирде Алия, — мин сине көтәм дә көтәм, ә син юк.

— Кибеттә озаграк булдым, костюм сайладым.

— Кая, нинди костюм алдың?

— Ярыйсы, хакы да безнеңчә.

— Яхшы, бик яхшы. Чит илләргә матуррак киенеп барырга кирәк.

— Әйе шул, сынатырга ярамый. — Рәшит көлеп җибәрде, җиңелчә генә хәрәкәт белән хатынын үзенә таба тартып китерде һәм алсу колагы яныннан муенын үбеп алды.

— Бүләкләр дә аласың калган.

— Кемгә?

— Дусларыңа.

Рәшит, кулларын юып, өстәл янына килеп утырды. Сак кына, бик җитди эш эшләгән кебек тәлинкәдәге ит кисәгенә чәнечкесен батырды. Сүз дәвам итте.

— Синең анда таныш кызың булган бит, — диде Алия тыныч кына.

— Әйе, бар иде, — диде Рәшит һәм уйга калды, ул көннәрдән соң дистәләрчә еллар үтте.

— Матур идеме?

— Матур иде, — Рәшит кычкырып көлеп җибәрде.

— Ничә яшьтә иде?

— Нишләп сине ул кызыксындырды әле?

— Мин аңа да бүләк алырга кирәк иде дип уйлыйм.

— Булган беткән, җилгә очкан, — диде Рәшит бик җитди генә. — Рәхмәт, бик тәмле булды. — Ул челтәр белән капланган тәрәзә янына килде.

Алия аның янына килеп басты:

— Ут яндырыйммы?

— Яндырма әле.

Алар озак кына ерак-еракка, сүнеп баручы кызгылт шәфәкъка карап тордылар.

Рәшит моннан ничә еллар элек булган хатирәләр әсирлегендә иде. ... Әйе, Австрия... Эггендорф... Гильда...

Беркөнне зәңгәр күзле Гильда аны үзләренең бакчасына чакырды.

— Белсәң иде, сине ничек яратканымны! Мин сине беренче күрү белән үк яраттым. Күзләреңне, чәчеңне, иреннәреңне яраттым, — дип, кайнар учы белән Рәшитнең ике яңагыннан алды, аннан маңгаена, кашларына кулын тидереп алды. — Мин бик бәхетле, бик бәхетле.

Рәшит кызның йомшак, нәфис кулларын учына алып, иреннәренә якын китерде һәм озак кына шул кулларга тынын өрде.

— Без өйләнешербезме? — диде кыз.

Шулчак аяк тавышлары ишетелде.

— Бу мин, әти, без, — диде Гильда.

— Кул фонареннан ут көлтәсе аларга таба төбәлде.

Ир озак кына сүзсез торды, аннан Рәшиткә таба бармак янап:

— Кара аны, егет, бездә һәр өйдә күзләр һәм колаклар бар, — дип пышылдады.

Әйе, бу яшьлек елларыннан соң бик күп сулар акты. Кайда икән хәзер ул кыз, әллә кайчан оныткандыр инде, кияүдәдер, балалары бардыр.

— Ярый, әйдә ут яндырыйк, — диде Рәшит, баскан җиреннән кузгалып.

Алия дә Рәшитнең үткәннәрен, аның яшьлектә булган маҗараларын белә, әмма алар аңа комачауламый, ул аны үткәндәге гашыйкларына көнләми.

Сылу гәүдәле, мөлаем йөзле, чибәр Алия үз дәрәҗәсен белә. Рәшит тә Алиядә үз әнисенең чалымнарын таба. Әнисе дә күп сүзле түгел иде, төчеләнмәде, иркәләмәде, тыйнак кына ярата иде. Алия дә шундый. Ә Рәшит көне-төне эш дип чаба, эше өчен яна, мең проблема, мең уй аның башында. Өенә, Алиясе, балалары янына кайткач кына җанына тынычлык таба, рәхәтләнеп, онытылып ял итә.

Эшенә муеннан чумган Рәшит чәчәкләр, бүләкләр биреп Алияне артык узындырмады. Бүләкләр, чәчәкләрне Алия күбесенчә үзенә ала иде. Ул ирен юк-бар белән борчымады, ул аңа таяныч булырга тырышты.

ЭШ ТӘ ЭШ

Хастаханәдә көн-төн эш кайный. Таң алдыннан, иртәнге сәгатьләрдә генә бераз тынлык хөкем сөрә. Баш табиб Рәшит Заһретдин улы эшкә бик иртә килә, чөнки персонал җыелып беткәнче үк беренче чиратта эшләнәсе эшләр дә килеп чыга. Баш табиб барысы өчен дә җаваплы, аны хастаханәнең барлык мәшәкатьләре дә борчый, хасталарның терелү дәрәҗәсе генә түгел, пешә торган ризыкларның сыйфаты, санүзәкнең төзеклеге һәм чисталыгы...

Хастаханәнең киң капкалары ачып куелган. Корпуслар куе ябалдашлы юкә агачларына күмелеп утыра. Ничә еллар шушы капкадан кереп, аллеялар буйлап үткәндә шул юкәләрнең исенә исерә Рәшит Заһретдин улы. Шушы хуш ис, ямьле яшел агачлар арасында никадәр зар, никадәр шатлык күргәндер бу борынгы соры биналар.

Дежур шәфкать туташы баш табибны бик илтифатлы, мөлаем елмаеп каршы ала. Менә күзләре елаудан кызарып, шешенеп беткән бер ханым аңа таба якынлашты:

— Доктор! Зинһар әйтегез, минем иремнең хәле ничек? Операция булачакмы?

— Бу мәсьәлә берничә сәгатьтән ачыкланыр, кадерлем.

— Гафу итегез, мин күтәргә әзер.

— Күтәрсез, кадерлем. Бер дә дулкынланмагыз, бездә хирурглар бик яхшы, дарулар җитәрлек, кирәк булса, кан да бар.

Сүз иң элек кизү торган табиб һәм шәфкать туташына бирелә, баш табиб һәрбер сүзне каләм очына ала, сораулар бирә.

Көн дә менә шулай, эшне җайга салу, көндәлек планнар, авыруларның хәле белән танышу, операцияләр билгеләү...

Яше, тәҗрибәсе, күпьеллык хирурглык хезмәте Бәдретдиновның исемен бик популярлаштырды. Ул ясаган операцияләрнең җиңел үтүе, кулының, хәтта тынының шифалы булуы турында төрледән-төрле хикәятләр йөрде, хәтта җырлар җырланды. Табиб елмая һәм шул җырның истә калган берничә генә сүзен кабатлап ала: «У Рашида легкая рука, смело подставляй ему бока!» Һе, «смело подставляй!» Яхшы әйтелгән.

Әмма... Операция... Күп кеше бу сүзнең нинди киеренкелекне эченә алуын аңлап та җиткермидер. Пычак астында ятмаган бәндәләр минутлар, секундларның нинди көч һәм ихтыяр, түземлек һәм тәвәккәллек таләп иткәнен аңламыйлардыр дип уйлады ул.

Рәшит Бәдретдинов һәрвакыт бүген һәм иртәгә нәрсә эшләргә тиешлеген яхшы белә. Җитәкче эшенең төп кануны шул: эшең эшләнмәгән килеш, ял итәргә, тугарылырга хакы юк. Максаты — коллективта һәрвакыт тәртип булырга тиеш.

ТОРМЫШ БИТ УЛ АКЛЫ-КАРАЛЫ

Кешеләр арасында — хезмәттәшләрме ул, гаилә әгъзаларымы, ир белән хатынмы — карашлар, мөнәсәбәтләр, хәтта мәхәббәттә дә кайчак чатнап ярылу булып ала. Шул чатнау, ярылу озакка китсә, бу инде фаҗига. Ул зурая, киңәя, кешеләрнең аралары мәңгегә якынаймас, кушылмас була.

Рәшит белән Алия арасында да ярык, чатнау барлыкка килде. Көтмәгәндә уйламаганда беркөнне хатыны Алия Рәшиткә коры гына:

— Мин иртәгә абортка керәм, — диде.

Рәшит торшердан төшкән ут яктысында китап укып утыра иде. Ул китаптан башын күтәрде, Алиянең әйткән сүзләрен аңлап җитмәде, аңа таба борылды:

— Ничек? Нәрсә дидең? Абортка?

— Абортка! — диде Алия гадәтенчә ачык күкрәк тавышы белән.

— Син ни сөйлисең, Алия! Нинди аборт ул! Ике бөртек бала белән калабызмыни? Шул да гаилә буламы? Ике бөртек бала!

— Сиңа ничәү кирәк тагын? Унмы?

— Рәшит китабын ябып куйды, һушына килә алмый, ни әйтергә белми бераз тын утырды. Ачуы чыкса да, үз-үзен кулга алырга тырышты. «Таякны тоткан җиреннән сындырырга ярамас», — дип уйлады һәм хатынына бик җылы елмаеп, аңа тәэсир итәргә теләде:

— Ике баланы яхшы кеше итеп тәрбияләве авыр, Алия, дип куйды.

— Күп баланы җиңелме?

— Кара инде безнең Гүзәл һәм Рөстәмне. Көн туса, алар тарткалаша. Ашый башласалар, күз кырые белән бер-берсенең савытына карый: аңа күбрәк, миңа азрак, имеш. Сиңа, миңа... Бу эшме инде? Без җидәү үстек, бер-беребезне үлеп ярата идек, һәр нәрсәне җидегә бүлә идек, көнчелек дигән нәрсәне белмәдек...

Алия ирен тыңламый иде инде. Рәшитнең сүзләре аңа тәэсир итмәде. Бераздан Рәшит, хатыны янына ук килеп, аның биленә кулын салды:

— Күптән әйтергә җыенып йөри идем, Алия, минем бала сөясем килә башлады, — дигән булды.

— Сөй, әнә улың Рөстәмне алдыңа утырт та «үчти, үчти» диген.

— Юк, минем нәни бала, тәмле сөт исе килә торган нарасый сөясем килә, — диде Рәшит.

— Юк инде булмас, тормышка ашмас синең бу хыялың. Мин башка бер бала да тапмаячакмын, җитте, — диде Алия катгый төстә.

— Ник? Ни өчен?

— Синең кайтып кергәнең дә юк. Әле командировка, әле срочная операция. Көн юк, төн юк, җитте, гарык мин бу тормыштан.

Алиянең бу сүзләреннән Рәшит уянып, айнып киткәндәй булды. Аның өстәлгә сугып: «Юк, абортка җибәрмим. Баланы табачаксың!» — диясе килде. Әмма мөнәсәбәтләрне киеренкеләтүдән ни файда?

— Алия! — диде Рәшит бик гасабыйланып, — син ни сөйлисең? Эшем күплеккә мин гаеплемени?

— Минем үзем өчен яшисем килә, миңа тынычлык кирәк, ниһаять, миңа да үз сәламәтлегем турында кайгырырга вакыт.

— Сәламәтлек? Бала табу сәламәтлек түгелмени? Аборт ясату синең сәламәтлегеңне какшатачак, Алия! Мастопатия

китереп чыгаруы бар, ниһаять, яман шеш. Аборт күп кенә хатыннарда катлаулы депрессиягә сәбәп була, — дип ир хатынын куркытып та карады.

Алия дәшмәде. Аның дәшмәве Рәшитне тагын да чыгырыннан чыгарды. Ул дулкынлану, борчылудан ишекле-түрле йөри башлады.

— Син мине сөймисең, — дип, ул соңгы чиккә җиткәч әйтә торган сүзне башлады, — син мине яратмыйсың, шуңа күрә син кан тамырларында минем каным аккан, геннарым белән яшәргә тиешле минем баламны үтерергә әзер. Син минем баламны түгел, иң яхшысы минем үземне үтер! — дип кычкырды Рәшит. Бераз тынычлана төшкәч, тагын сүзен дәвам итте. — Мин бит синнән ничә еллар инде җылы сүз, җылы караш күрергә тилмереп яшим. Без бит синең белән башкалар кебек култыклашып та йөргәнебез булмады, син мине култыкларга ояла идең. Син баланы да мине яратмаганга табарга теләмисең, акылы камил ана үз баласын үтерәмени? Ярый, мин аңлыйм, кемнеңдер тормышы авыр, күп бала үстерергә мөмкинлекләре юк, матди хәлләре начар. Безнең бит менә дигән фатирыбыз бар, хезмәт хакыбыз яхшы.

— Акчадамыни соң эш?!

— Нәрсәдә соң? Аңлат! Нәрсәдә?

Хатын дәшмәде. Гүя ул «сөйлә, сөйлә, тагын нинди матур сүзләрең бар? Мин барыбер үз уемнан кайтмаячак-мын», дип иреннән эчтән генә көлә иде. Аның йөзе үзгәрмәде, гадәтенчә коры, салкын, барысына да битараф булып калды.

Рәшит ярсып хатынына соңгы сүзен әйтте:

— Мин сине гомеремдә дә гафу итмәячәкмен. Син... Син, беләсеңме, кем? Син — кеше үтерүче.

Хатын тыныч кына урынында утыра бирде.

Рәшит ярымпышылдап сүзен тагын дәвам итте.

— Син бит татар канлы, татар җанлы, әбиең, әниең кебек үк шәфкатькә ия мөселман баласы! Акылыңа кил! Җан кыйма!

Бу сөйләшүдән соң Рәшитнең йөрәгенә гүя кан сауды, ул хатыны әйткән сүзләрдән айный алмый интекте.

Беркөнне шушы сөйләшү турында уйланып, үткәннәрне хәтерләп утырганда Рәшит хастаханә тәрәзәсеннән зәвык белән пөхтә киенгән, бала җитәкләгән бер ананы күреп,

аларга бик озак сокланып карап торды. Ана баласы белән нидер сөйләшә, аңа таба иелеп-иелеп ниндидер сүзләр әйтә, ә сабый ихлас көлә.

Бала — сөю җимеше, дип уйлады Рәшит Заһретдин улы, ул ананың сүзләреннән, уй-тойгыларыннан азык ала, дөньяны танырга өйрәнә, үзендә исә вөҗдан, башкаларга ихтирам, мәрхәмәт кебек илаһи сыйфатлар булдыра. Ике бала баламыни ул, дип тә уйлады ул. Халык юкка гына, икене бер дип, берне юк дип уйла, димәгәндер. Ул үзенең сабый чакларын, апалары, абыйлары белән уйнап-тәгәрәп үскән чакларын, кайгы-хәсрәтсез вакытларын исенә төшерде. Ишле гаиләдә бала бөтенләй башка тәрбия ала, туганлык, дуслыкны бөтенләй башкача аңлый. Ә бердәнбер яки ике генә балалы гаиләдә кеше үзен генә сөя торган, көнчел, хөсетле, башкаларны яратмый торган булып үсә.

Әллә соң бу мәхәббәт дип аталган галәмәт юк нәрсә микән? — дип уйлый еш кына Рәшит, китапларда гына, язучылар тарафыннан гына уйлап чыгарылган, бизәкләнгән нәрсәдер ул бәлки. Мәхәббәт дигәннәре, мөгаен, вакытлыча гына җан һәм тәннең дулкынлануы, дәртләнүедер. Вакытлыча гына, вакытлыча гына! Шулай булмаса, күпләр бер күрүдә гашыйк булып, гомер буе эт белән мәче кебек яшәр идемени? Эче саф, күңеле күркәм кешеләр генә бер-берсен якын итеп, иләшеп, яратышып яшиләрдер.

Менә шундый авыр, газаплы уйлар белән көннәр, еллар үтә торды. Алия башка туачак сабыйларын да юкка чыгара барды.

ҖИРСҮ

Кеше ничә еллар чит җирләрдә, чит шәһәрләрдә яшәсә дә, күз алдыннан китми икән аның туган җире. Кайткан саен никтер кечерәеп, җыйнакланып баручы туган йорты, һәр күрешкән саен якынрак, кадерлерәк тоелган нәсел-ыру, борчу-үкенечләрне искә төшереп, сагышка сәбәп булган урамнар, су буйлары...

Яшьлек хыялларына уралып, әллә кайларга китеп барса да, кешене бөтенләйгә җибәрми икән ул туган җир. Аның күзгә күренмәс тарту көче бар икән. Язмыш җилләре килеп кагылган саен ул җирсүгә әйләнә икән. Җирсү, җирсү... Белә аның ни икәнен Рәшит Бәдретдинов. Кайтса да, китсә дә, ак теләкләр теләп калучы карт анасы, туган ягы, туган авылы һәрчак аның күз алдында булды.

Бу юлы ул поезд белән кайтты. Никтер ул төне буе йоклый алмады. Нервлар шаярамы, кан басымы күтәрелдеме? Юк, йоклый алмады, төн ката күзен йомып ята бирде Рәшит. Ни әйтсәң дә, иң яхшысы — самолет дип уйлады ул. Керәсең, утырасың, берничә бит китап укырга өлгермисең — инде самолет түбәнәя башлый, җиргә төшә... Ә поездда йокысызлык, эшсезлектән хәлдән таясың.

Рәшит таң алдыннан гына йокыга китте, дөресрәге, берничә минутка онытылып алды. Купеда бик тынчу иде, башка әллә ниләр кереп йөдәтте: нидер эшләнмәгән, кайдадыр ялгышылган, үкенечләр, үкенечләр... Соңгы вакытта гаиләдә дә аңлашылмаучылык үзен сиздерә.

Рәшитне беркем дә каршы алмады, үзе хәбәр бирмәде. Маршрут автобусына утырып, Әлмәтнең төз, матур урамнарын күзәтте, тәрәзәдән кибет язуларын, кинотеатр рекламаларын, плакатларны күздән кичерде.

Аклы-зәңгәрле томанга өртелгән таулары, кырлары, эреле-ваклы йортлары белән каршы алды аны Чупай. Сагынды туган авылын Рәшит. Чит шәһәрдә затлы фатирында утырганда ул туган җирнең җылысын, тауларын бер генә минутка да исеннән чыгармады.

Менә бүген дә, озын, ялыктыргыч юл үтеп, туганнары белән очрашып, хәл-әхвәл белешкәннән соң уйларының очына чыга алмыйча йөдәп, йөрәген әрнетеп торган авыр тойгылардан котыласы килеп, ул ташлы тау буена китте. Күлмәк изүләрен ачып җибәрде, тау өстенә менгәч карашын еракларга төбәп уйга калды. Күңеленең шулай тетрәнгән чакларында ул сабый вакытындагы хатирәләренә әйләнеп кайта. Авылы өстенә карап ул хәйран калып, озак кына әсәрләнеп, кинәнеп торды. Аның күңеле күтәрелеп китте, күзләреннән сөрем юылып төште, моңарчы күзендәге сөрем аша дөнья кыек-мыек күренә кебек иде. Шул сөрем Алия белән ике араны каплап тора иде бугай. Ул ашыга-ашыга яшьлегендә йөргән сукмактан атлый башлады, кулын күтәреп, канатлар кебек ике якка җәеп йөгерергә үк тотынды.

Ул бу юлы да Сабантуйга кайтты. Чупай сабан туе, Әлмәт сабан туе...

Сабантуйлар туган якта гөлләр чәчәк аткан, кошлар бертуктаусыз сайрап торган, күк йөзе каурый болытлар белән генә бизәлгән көннәрдә була.

Рәшит иртүк торып урамга чыгып басты. Бу — Чупай сабан туе иртәсе. Һәр татарның җанына якын милли бәйрәм иртәсе. Кай арада сыер сауган, көтү куган, кай арада капка төбен ялт итеп себереп куйган җиңгәсе. Авыл өстендә таба исе аңкып тора, кайдадыр тальян чыңы яңгырый.

Рәшит капка төбендәге эскәмиядә барысын онытып, шушы иртә белән хозурланып утырды. Һәркайсы аны олылап сәламләде, зурлап кул биреп күреште. Ашкынды сабан туе иртәсендә Рәшитнең күңеле.

Ишегалдына туганнар җыелды, күршеләр керде, киң күңелле туганнарының йөзләре балкый. Апасы Шакирә Рәшит алып кайткан кәшемир яулыкны ничек итеп бәйләргә белми. Рәшит аның янына килеп, ягымлы сүзләрен әйтә-әйтә, апасының башына яулык яба.

Шулай Рәшит Бәдретдинов Подольскида эшли башлагач, ел саен әле поезд белән, әле самолет белән туган ягына ашыга. Ә машина алып җибәргәч, ел саен үзенең машинасында кайта башлады.

Сабантуйларда ул яшь тай кебек баскан җирендә тыныч кына тора алмый, көрәшчеләр өчен җан ата, йөгерешчеләр өчен җилкенә, җырчылар белән бергә моңланып күз яшьләрен коя. Безнең татарның җырлары гына ни тора бит! Алар туган як җилләредәй саф, чишмәләрнең салкын суларыдай татлы. Йөрәкнең әллә кайсы төшләрендә сагыну инәләрен кыймылдатып-кыймылдатып куя торган гаҗәеп могҗиза ул җыр.

Чупай — Әлмәт районында исеме төрле якларга таралган шөһрәтле зур авыл. Чупай ташыннан шәһәрләр үсеп чыккан. Анда нинди эшкә алынса да, шуны булдыра торган, гайбрәт-көчкә ия ир-егетләр, оста-эшчән кыз-кыркыннар яши. Чупай ил тоткасын тотардай ирләр үстереп биргән, аларның даны тирә-якка таралган.

ЧИТ ИЛЛӘРДӘ ЙӨРЕП

1972 ел. Подольск шәһәре делегациясе составында табиб Рәшит Бәдретдинов Чехословакиядә булды. Анда ул партия эшлекклеләре һәм халык белән очрашты, хатирәләре яңарды. Кладно районы партия комитеты секретаре Ярослав Патера белән үзе 1945 елда фельдшер булып эшләгән Милевско шәһәрендә булды, үзе йөргән сукмаклардан тагын бер мәр-

тәбә атлады. Егерме алты ел эчендә шәһәр бик нык үзгәргән, гигант завод-фабрикалар калкып чыккан. Ә кешеләре әле дә Рәшит Бәдретдиновны хәтерли икән. Аеруча дулкынландыргыч очрашу Зденек Нейдли белән булды. Ул чакта ул яшь кенә егет иде, үпкәсе ялкынсынган, тәне ут кебек яна. Рәшит аның өенә барды. Яшь фельдшер аңа дөрес диагноз куеп, берничә көн эчендә аякка бастырды.

Бу шәһәрдә бик күпләр азатлык алып килүче Совет Армиясе турында сөйләделәр, туганнарча кунак иттеләр.

Бөек Җиңүнең 35 еллыгы якынлашу көннәрендә Рәшит Бәдретдинов Чехословакиянең Милевско шәһәрендә нәшер ителүче «Звезда» газетасына хат юллады. Ул анда үзенең сугышчан юлы турында бәйнә-бәйнә язып, Милевско шәһәрендә үткәргән көннәре һәм 1972 елда булган истәлекле очрашу турында язды һәм фотосурәтләр җибәрде.

«Чехлар һәм словакларның дуслыгын һәм шатлыклы йөзләрен һичкайчан оныта алмам. Безнең солдатлар һәм офицерлар белән җирле халык арасында яхшы дуслык урнашты. Миңа, медик буларак, ярдәм сорап бөтен тирәяктан киләләр иде.

Күптән түгел, 1972 елның сентябрендә мин Подольск шәһәре делегациясе белән Чехословакиядә булдым, шул исәптән, минем өчен бик истәлекле Милевско шәһәрендә. Минем белән Кладно райкомы секретаре Ярослав Патера булды. Шәһәрдә мине белүчеләр әле исән. Мин Зден Нейдлине очраттым. 1945 ел. Мин аларның өенә бардым. Ул авыр хәлдә ята иде. Мин аны терелттем. Утыз елдан соң очрашу безне бик дулкынландырды.»

Рәшит Бәдретдиновның бу хатына тиз көндә җавап хаты килде. Аны «Искра» газетасының җаваплы секретаре Гана Кложукова язган иде.

«Хөрмәтле иптәш Рәшит Заһретдинович!

Сезгә хатирәләрегез һәм фотосурәтләрегез өчен бик зур рәхмәт.

Мин сезнең хатирәләрне газетада бастырдым. Безнең газета битләрендә 1945 елның маен күз алдына китереп, алар Җиңүнең 35 еллыгын лаеклы каршыларга ярдәм итәрләр. Сезгә әдәби хезмәттәшлек һәм киң күңеллелек өчен зур рәхмәт. Мондый хезмәттәшлек әле соңгысы булмас дип ышанам.

Минем өчен сезнең белән очрашу бик күңелле булыр иде.

Сезгә газетабызның басма нөсхәсен һәм фотосурәт-

ләрегезне кире җибәрәм. Шул ук вакытта шәһәр комитетының котлавын юллыйм.

Тирән ихтирам белән, Гана Кложукова.»

1980 елның сентябрендә Рәшит Бәдретдинов Чехословакиядән тагын бер хат алды.

«Хөрмәтле иптәш Рәшит!

Милевско шәһәреннән, аның халкыннан һәм шәһәребезнең милли комитеты әгъзаларыннан кайнар сәлам.

Язган хатыгыз өчен зур рәхмәт.

Иң элек шуны хәбәр итәбез, кадерле иптәш, 1980 елның 28 апрелендә халык комитетының пленар утырышы булды, анда шәһәрнең барлык гражданнары исеменнән Сезгә Милевско шәһәренең шәрәфле гражданины дигән исем бирелде. Без Сезне бу исем бирелү уңаеннан котлыйбыз, тормышыгызда уңышлар, ныклы сәламәтлек һәм гаилә тынычлыгы телибез.

Май аенда фашизмнан азат ителүгә 35 ел тулу көнендә Сезне һәм 1945 елда безнең шәһәр халкына медицина ярдәме күрсәтүегезне искә төшердек. Без Сезне яратабыз, Сезнең фидакарь хезмәтегезне чиксез бәялибез. Ярдәмегез өчен зур рәхмәт.

Хушыгыз, кадерле иптәш Рәшит — Милевско шәһәренең шәрәфле гражданины! Без Сезне үзебезнең шәһәрдә көтәбез.

Иптәшләрчә сәлам белән,

Милевско шәһәренең милли комитеты Вацлав Воржишек.»

Бу хатны алгач, Рәшит Бәдретдиновның күзләре яшьләнде, ул бик дулкынланды һәм аның күңелендә әллә нинди күптән булып үткән хәлләр, хатирәләр яңарды.

1945 елның язы иде. Милевско шәһәренең күгендә таң сызылды. Язгы дымлы һавада команда тавышлары ераклар-га яңгырап тора, озак көттергән Җиңү бик якын икәнен һәркем белә. Озак авыр юлларның азагы якын икәнен тою шатлыгы көчле.

1980 елның май аенда Милевско шәһәрендә нәшер ителә торган атналык «Искра» газетасы Рәшит Бәдретдиновка багышланган «Май көннәре хатирәләре» дип аталган зур мәкалә бастырды.

---

* Хат рус телендә язылган, тәрҗемә ителеп бирелә.

БАЛАЛАР ГАМЕ

Балалар яхшы укыдылар, Гүзәл бигрәк тә. Рәшит Заһретдин улы аны, һичшиксез, киләчәктә югары белемле табиб, хәтта үзе кебек фәннәр кандидаты, галим итеп кенә күз алдына китерде, ул кызына өметен беркемнән дә яшермәде.

Ун сыйныфны тәмамлап, Гүзәл Мәскәү медицина институтына имтиханнар тапшырды, әмма конкурстан үтмәде. Рәшит Заһретдин улының өметләре һәм хыяллары июль күгендәге каурый болытлар кебек эреп таралдылар.

— Син дәрәҗәле, күренекле табиб, хирург, кемгә дә булса шалтырат, тыңламый калмаслар, — диде Алия ханым.

— Кемгә? Министргамы? — диде, ачуы кабарган Рәшит Заһретдин улы.

Хатын төрле чагыштырулар белән ирен үзсүзле, киребеткән булуда гаепләде. Ир бер сүз дә әйтмәде, киенде дә чыгып китте. Ул өч сәгатьләп вакыт үткәч, өенә кайтты, беркемгә бер кәлимә сүз әйтми, үз бүлмәсенә кереп китте. Алия, сүз күпкә китәр дип, аның янына керергә ашыкмады. Бераздан түзмәде:

— Син берәрсен күрдеңме? Сөйләштеңме? — дип янына керде.

— Мине генә көтеп торалар инде! — Мин кем? Мине әллә Алла дип белдеңме?

— Эгоист син, үзең турында гына уйлыйсың! Берданбер кызыңның язмышы сине борчымый.

Рәшит Заһретдин улы Гүзәлне Подольскидан ерак түгел Поливаново авылына балалар бакчасына музыкаль хезмәткәр итеп урнаштырды.

Икенче елны да Гүзәл конкурстан үтмәде. Ә өченче елны Алия ханым аны Казанга алып китте. Анда имтиханнарны уңышлы биреп, Гүзәл медицина институтының стоматология факультетына укырга керде. Рәшит Заһретдин улы Казанга килеп, аны тулай торакка урнаштырды, ә ике курс тәмамлагач, Гүзәл Мәскәү институтына күчте. Аны уңышлы тәмамлап, теш табибы булды. Берничә елдан аспирантура тәмамлап, диссертация яклады. Мәскәү медицина-стоматология университетында «Балалар стоматологиясе терапиясе» дигән фән укыта ул хәзер.

Рөстәм дә, ун сыйныф тәмамлагач, бер ел эшләде дә, бик нык әзерләнеп, имтиханнар тапшырып, институтка керде һәм теш табибы булды.

Балалар шулай үсеп җитәләр дә тормыш мәгънәсен эзли башлыйлар, табигать үзенекен итә, сөю, ярату чорына җитәләр. Әмма алар ата-ананың һәр киңәшен акыл өйрәтү дип кабул итәләр икән. Имеш, һәр буын үз юлы белән бара. Ә син аларга буш урында берни дә үсмәгәнен аңлатып кара! Һәр нәрсәнең башлангычы һәм дәвамы бар. Алдагы буыннар тәҗрибәсен уллар үстерә һәм үз нәүбәтендә балаларына тапшыра. Буыннарның дәвамчанлыгында бөек мәгънә бар. Менә шушы хакыйкатьне ничек кенә балаларга аңлатырга? — дип баш ватты Рәшит Заһретдин улы.

Ул үзенең яшьлек еллары, өйләнгән көннәрен күз алдына китерде. Әле генә институт тәмамлаган, сугышларда катнашып, тормышның ачысын-төчесен күп күргән кешегә ул үзенә күрә бәхетле көннәр иде. Әле аларның тормыш юлы яңа башлана, эшләгән ашарга җитми, фатир юк, кием юк. Ә хәзер... Хәзер аның бар нәрсәсе бар: дүрт бүлмәле фатир, дәртләнеп, тәм табып эшли торган эше, даны, дәрәҗәсе, җәмәгате, балалары. Ныклы, ышанычлы тормыш. Яшьлек кенә артта калган. Ә менә яшьләр, балалар өчен хафалану көчле: әнә бит Гүзәл, күз дә йоммый, урыс егетен яратам, ди. Шундый чибәр, югары белемле кызын Рәшитнең урыска бер дә бирәсе килми. Аның рәхәтләнеп, ләззәтләнеп кемгәдер «кияү», «кода-кодагый» дип әйтәсе килә.

Кызы Гүзәл җыйнак гәүдәле чибәр кыз булып үсеп җитте, яшьләрнең күзенә чалына башлады. Ул татар кызы булуы белән гүзәл иде, куе зәңгәр күзләр, кыйгач каш, төз борын, куе коңгырт чәчләр аны Шәрык чибәре итте. Шәһәр мохите, Мәскәүдә уку аның зәвыгын үстерде, ул бик матур киенде.

Игорь Сальков аның чибәрлеген тиз күреп алды. Ә Гүзәл аңа башын югалтыр дәрәҗәдә гашыйк булды. Шулай кызлар бик тиз мавыгалар һәм еш кына ялгышалар, сайлаганының кимчелекле якларын күрмәс дәрәҗәдә сукыр булалар. Гүзәл дә Игорьны егетләр арасында иң намуслы, иң игътибарлы, иң чибәр, иң акыллы дип санады. Ул аның ясалмалылыгын күрмәде, күрергә теләмәде. Өйләнештеләр. Ата киңәшенә колак салмады Гүзәл. Ике елдан улы Ефим туды. Озак яшәмәделәр, гаилә таркалды, Игорь башкага өйләнде.

Рәшит улы Рөстәмнең дә үзе-үзен тотышына бик борчыла иде. Ул йөрәге сызлар дәрәҗәдә улы алдында үзенең көчсез икәнлеген тойды. Рөстәм әле ун-унбиш яшьләрдә үк үзенә мөстәкыйльлек таләп итә башлаган иде. Тора-бара бу сыйфат аның характерына әйләнде. Үзсүзлелек, мөстәкыйльлек, хәтта бәйсезлек. Бу — Алия тәрбиясенең нәтиҗәсе. Ул һәрвакыт, баланың ихтыярын чикләмәскә кирәк, дия иде. Әйе, Рөстәм — әнисенең улы. Аны күбесенчә әнисе тәрбияләде, аның белән урысча гына сөйләште. Тышкы кыяфәте белән генә ул миңа охшаган, дип уйлады Рәшит.

Ничектер беркөнне улы Рөстәм этисе белән гәп куертканнан соң аңа болай диде:

— Син нәрсә, эти, безне Казан ханлыгына кайтырга өндисеңме әллә?

— Нишләп минем фикеремне син шулай ваклыйсың? — диде ата кеше, ачуы чыгып.

Бу сөйләшүдә Рәшит улына тарихны белмичә, киләчәкне төзеп булмый икәнен аңлата алмады. Кеше буш урында тумый, ул алдагы буыннарның тәҗрибәсен өйрәнеп, нәрсә яхшы, нәрсә начар икәнен аера белергә тиеш. Шуннан башка булмый. Кеше нәрсә изге икәнен аңларга тиеш. Югыйсә, тимерне тутык ашаган кебек, аның җанын рухи хәерчелек ашаячак.

Безнең бабайларның бай үткәне, дөньяга таныткан һөнәрләре булган. Төрле сугышлар, афәтләр, янгыннар, төрле чикләүләр бабайларның тормышын агуласа да, үсешен тоткарласа да, алар иң яхшы рухи байлыкны — Коръәнне, динне, иманны, иң яхшы кешелек сыйфатларын саклап калганнар. Тыйнаклык, әдәплелек, пакьлек, сабырлык, кешелеклелек, ата-анага һәм өлкәннәргә ихтирам һ.б. бик күп күркәм гореф-гадәтләр безгә дә килеп җиткәннәр. Гаиләдә дистәләрчә бала үстергәннәр, тәрбия биргәннәр, рухларына иман өргәннәр.

Менә шушы рухи байлыкны ул үзенең балаларында булдыра алмаган! Ничек аяныч! Дингә өйрәтсә, ата-анага ихтирам хисе тәрбияли алган булса, улы Рөстәм шулай тупас, дорфа сөйләшер идемени? — дип уйлады Рәшит. Аның балалары Гүзәл дә, Рөстәме дә, үзләре тиен дә акча тапмаган хәлдә, яхшы киенделәр, магнитофон, алтын алка... әйе шул... Тәмле ашап, матур киенеп, имәндәй буй үстергәч, ата-ана бик көчсез булып кала икән ул.

Атасыннан киңәш, тәҗрибә алу урынына көннәрнең берендә улы Рөстәм, бу турыда берничә сүз әйткәч: «Мин сездән мине тудырыгыз дип сорамадым», — диде. Нинди тупаслык, нинди шәфкатьсезлек! Гарьлеге ни тора бит!

Бердәнбер улының бу дорфалыгын ул үзенең гомер буе башына төшкән таш, олы җәрәхәт, йөрәк ярасы итеп саклар инде. Онытa алмас.

Рәшит Заһретдин улы кайвакыт балаларның шундый булуында үзен гаепләп, тәрбия бирә алмаганмын, эш-эш дип балаларга игътибарым да аз булгандыр, дип уйлый. Теләге булган кеше вакытын да, җаен да таба торгандыр. Яшьләрне аңлау өчен теләк кенә түгел, ә бик зур ярату, аларны аңлау һәм мәрхәмәтлелек кирәк шул. Ни генә әйтсәң дә, яшьләр үз мөстәкыйльлекләрен алга куя. Менә шунда аталар һәм балалар проблемасы туа икән.

Дөрес, аның тормышы, эше ыгы-зыгылы, катлаулы, җаваплы булды. Балалар аны көнозын күрмәделәр. Балаларга ата тәрбиясе, атаның каты кулы кирәк булгандыр.

Ә Алия исә тыныч, сабыр хатын, берникадәр ваемсыз булып күренсә дә, аның күңелендә гомер буе каршылыклы хисләр, давыл, ятларга сер бирмәслек көч, кызы белән улының әтиләренә якынлыгын сүндермәслек акыл бар иде. Ул татар хатыны, буыннардан — буыннарга килгән күркәм сабырлык, мәрхәмәтле йөрәк, киң күңеллелек аның төп сыйфатлары иде.

ТАГЫН КАРА ЕЛАН

Еллар яхшы, илдә иминлек. Хирург Рәшит Заһретдин улының да, укытучы Алиянең дә хезмәт хаклары яхшы. Алар озак еллар буе арткан акчаларын саклык кассасына сала бардылар. Бераз гына дуслардан әҗәткә акча алып, кайсыдыр елны «Жигули» маркалы машина алып куйдылар. Шәһәрдә җилдереп йөрергә дә, урман, су буйларына барырга да машинаң булу бик яхшы. Ә машинада туган ягыңа кайтып төшү — анысы инде ләззәт, шатлык, горурлык, дәрәҗә. Үз куллары белән гараж да төзеп куйганнар иде. 1981 елда, модага ияреп, бакча өчен җир алып җибәрделәр, агач төпләделәр, җире начар булганлыктан, җир ташыдылар. Рәшит шунда бер сарай да ясап куйды. Бөтен

гаиләләре белән җиң сызганып җирдә эшләделәр, агачлар, куаклар утырттылар. Тавык кетәге ясап, тавыклар алып җибәрделәр.

Рәшит кайсыдыр елны «Волга» машинасы сатып алды. Машинаның борын өстендәге очып китәргә әзерләнгән болан сыны аның күңелен күтәрә, ул машинасында күкрәк киереп, дәртләнеп алга ыргыла.

Көтмәгәндә, уйламаганда шул гомерлек хыялы «Волга» аның язмышына кара күләгә төшерде. Уңышлар булгач, көнчеләр күбәя бит. Теге Польша җирендә шуышкан кара елан монда да бар икән. Кайсыдыр мәкерле, хөсетле бәндә аның өстеннән ОБХССка шикаять язып җибәргән. Каян акча алган? Нинди акчага «Волга» алган? ОБХСС бик төпченә торгач, партия линиясе буенча «каты шелтә» чәпеделәр. Баема! Ярамый! Мәскәү өлкәсе Сәламәтлек министрлыгына чакырдылар. Рәшит Зәһретдин улына һәр урында су буе аңлатма язарга туры килде.

Бер генә ставкага түгел, ставка ярым эшләве, югары категорияле хирург буларак та, фәннәр кандидаты булганы өчен дә өстәмә эш хакы алуы, күп еллар фтизиатр, үпкә туберкулезы белән авыручы кешеләргә операция ясап, зарарлы шартларда эшләгәне өчен хезмәт хакына 25 процент өстәмә акча алуын да бәйнә-бәйнә язарга туры килде аңа. Ул урламады, алдашмады, ришвәт тә алмады. «Волга» машинасы аның хәләл хезмәтенә тапкан бәхете иде. Тикшерүчеләр аның тузан бөртеге чаклы да гаебен тапмадылар. Әмма бу җәберләүләр йөрәкне җәрәхәтләде.

ТУГАН ЯГЫМ — ИЗГЕ БИШЕГЕМ

Мәскәү өлкәсенең Подольск шәһәрендә туберкулез хастаханәсендә Рәшит Бәдретдинов утыз ел эшләде. Аякка басу, өлгергәнлек, чәчәк ату, дәрәҗәгә күтәрелү — бөтенесе шунда үтте. Кызык, әгәр тормышны яңадан кабатларга кушсалар, дип уйлады ул, мин ни эшләр идем икән? Кабатлар идемме? Шул ук ялгышларны кабатлар идемме икән? Әллә тагын да катлаулырак, тагын да тормышын төрләндеребрәк, азрак югалтулар белән яшәр идеме? Ә кирәкме икән? Тормыш бит шунысы белән кадерле — аны һич тә кабатлап булмый. Иң куркынычы — буш, максатсыз яшәүдер. Кеше бит икеләнсә, юкка да янса-көйсә, берниһгә

дә ирешә алмый. Кеше максат куя, максатына ирешә, кызыклы, эчтәлекле тормыш үтә. Менә инде Бәдретдинов та олыгаеп бара. Аның яшь чагын белгән кешеләрнең исендә: Подольскига килеп урнашкан елларда ул солдатларча төз гәүдәле, чибәр, куе чәчле, очкынлы зәңгәр күзле, җиңел аяклы иде. Ә хәзер аяклары җиргә ышкылып-ышкылып атлый, җилкәләр төшенке, чәчләр сирәгәйгән.

Гомер буе Рәшит Бәдретдинов үзенең туган ягы белән элемтәне өзмәде. Подольскига Татарстанда чыга торган газета-журналларны яздырып алды. Аларны башыннан ахырына кадәр укып, илдәге хәлләрдән хәбәрдар булып яшәде. Байый Татарстан, көче, куәте арта, мөстәкыйльлек өчен көрәшә, татар телле мәктәпләр, балалар бакчалары ачыла. Шул яңалыклар белән ул һәрчак Алияне, балаларын да таныштырырга, аларның җаннарында татарлыкны сакларга, рухларын үзгәртергә тырышты. Журнал, газеталарда язылганнарны укып-укып күрсәтте, ләкин һәрчак битарафлык тойды һәм күңеленә ятышсыз сүзләр ишетте:

— Тыңла әле, Алия, нәрсә язалар: «Әлмәттә яңа көнкүреш хезмәте күрсәтү йорты ачылды. Анда дистәдән артык төрле хезмәт күрсәтелә, заказлар кабул итәләр, кофталар, күлмәкләр...»

Әмма Алия аны тыңларга теләмәде:

— Шул газеталарда язган юк-барга ышанып гомереӊ үтте инде, әллә бездә юкмы андый яңалыклар?!

— Алия, — диде Рәшит беркөнне, минем күптәнге хыялым бар. Туган-үскән җиргә кайтып төпләнәсе, соңгы көннәрне шунда үткәрәсе иде. Без бит татарлар, мөселманнар. Картаябыз. Минем, гомеремнең ахырында булса да, туган ягымда яшисем килә, яшьлегем үткән юлларда йөрисем, сабый чакларда чыпырдаган инештә аягымны гына булса да юасым, татарча сөйләшәсем, «Туган тел» җырын җырлыйсым килә. Быел булмаса, киләсе елга, тотыйк та күченик без минем туган ягым Әлмәткә яки Чупайга. Анда хәзер искиткеч үзгәрешләр, муллык, байлык.

— Балалар ни әйтер икән бит, — диде Алия салкын гына.

— Балалар, балалар....

— Бүгенге яшьләр авылда яшәргә теләрме соң?

— Ә үзең соң? Үзең?

— Мин дә беркая да кузгалырга ашкынып тормыйм.

Берничә көн үткәч, Алия үзе иренә сүз башлады. Ул озак уйлады, үткән гомерен исенә төшерде, киләчәген күз алдына китерергә тырышты.

— Рәшит, — диде ул, — мин синең «туган як, туган як» дип авыз суын корытуыңны һич аңлый алмыйм. Нәрсә бар соң анда? Монда дуслар, дача, гараж... Күченә башласаң, барын пыран-заран китерергә, яртысын ташлап калдырырга, яки бушка таратырга кирәк булачак. Мин сиңа ул уеңнан кире кайтырга киңәш итәр идем.

— Кире кайтырга? Юк инде, Алия. Мин хәзер дөнья малы өчен җанын фида кылучы түгел, минем күземә берни күренми. Мине туган ягым, туган җирем тарта, атам-анам, бабаларым яшәгән Чупаем, аның урамнары, таулары тарта. Мин соңгы көннәремне шул изге җирдә үткәрергә телим минем тәнем туган җирем куенында булырга тиеш.

— Син теләсә ни эшлә, мин беркая да кузгалмыйм. Минем соңгы сүзем шушы, — диде Алия.

Мондый ук яман күңелсез көнне һәм дөньяның дәррәү шыксызланып калуын Рәшит моңарчы тормышында һич кенә дә белми, ничаклы уйласа да, исенә төшерә алмады. Тирә-юнь аңа искәрмәстән караңгыланып калгандай тоелды.

Бу сөйләшүдән соң Алиягә әллә ни булды. Моңарчы да, Рәшит фикеренчә, ирем, дип үлеп тормаган хатынның сүзләре дорфаланды, иренең ни сүзе, ни гамәле аңа ошамады. Беркөнне хатынын акылга утыртып булмасмы, гаилә бөтенлеге турында уйламасмы, дип Рәшит иң соңгы, иң тәвәккәл, иң кискен сүзен әйтергә булды:

— Алайса, Алия, мин туган ягыма берүзем кайтып китәм, — диде.

— Теләсә ни эшлә, ихтыярың, — диде хатын салкын гына.

Рәшитнең гүя башына суктылар.

Соң аңладым ялгышымны, дип уйлады Рәшит Заһретдин улы. Минем өйләнүем үзе үк ялгыш булган икән ләбаса. Әгәр мин үз авылым кызына өйләнгән булсам, ул минем белән шулай сөйләшер идеме? Нәрсә ди бит: «Теләсә ни эшлә! Ихтыярың!». Туган җирең ни аңа, туган телең ни! Һай, хәзерге акылым булса! Тормыш кору өчен, гаиләң бөтен булсын өчен әллә кайдан, чит җирдән өйләнмә икән! Чит җирдә гомер итмәсәм, бәлки, балаларым татар кызлары,

егетләре белән гаилә корырлар иде. Хәзер нәрсә? Безнең татар өчен иң зур фаҗига — катнаш никах. Милләтебез бетә баруның төп сәбәбе — шул катнаш никах. Минем генә түгел, туганнарның балалары да башка дин, башка милләт кешеләре белән кушылып, үз йөзләрен югалттылар, үз нәсел тамырларына балта чаптылар. Кызым, Гүзәл галим, медицина фәннәре кандидаты. Улым Рөстәм — теш табибы, урыслар белән гаилә корып карадылар. Ни гаилә юк, ни оныклар. Бердәнбер оныгым — урыс. Сальков Ефим Игоревич.

СОҢГЫ СӨЙЛӘШҮ

Бәдретдиновлар гаиләсе, башка күпләр кебек, яздан алып салкын көзгә кадәр үзләренең шәһәр читендәге дачаларында яши. Эшкә дә шуннан баралар. Көннәр матур тора. Пахра елгасы буенда көзгә таба кешеләр да азая. Көн саен елга үзенең матурлыкларын ача, анда бервакытта да күңелсез булмый, язын да, көзен дә ул аларның кәефен күтәрә, уйландыра. Елга кешеләр күңеле кебек серле, һәрвакыт яңача. Шул елга гына беразга туган якларны оныттырып тора.

Ул менә шушы утыз ел эчендә бертуктаусыз Чупай белән Подольск арасында, үткәне белән киләчәге арасында йөрде, бәргәләнде. Менә инде соңгы көннәрдә аның сагынуы, җирсүе гади җирсү генә түгел, ә аның җирсүе халкына, туган ягына ярдәм итәргә теләү белән үрелеп үсте. Ул газеталардан укып, анда барган сәяси көрәш, сайлаулар, мөстәкыйльлек турында бик күп мәгълүмат алды. Рәшит Заһретдин улы үзенең бәхетен туган җиренең, туган халкының язмышы хәл ителгән елларда шул язмышның авырлыгын күтәрергә теләүдә күрде. Язмышлар кыл өстендә торганда җиңү, җиңүче булып алу бәхетеннән дә зуррак бәхет була аламы? — дип уйлады Рәшит Заһретдин улы Бәдретдинов.

1991 ел, май башы.

Бу көнне дачада алар икесе генә иде. Тагын шул туган якка кайту-кайтмау турында сүз куерды.

— Син бүген минем сүземне тыңламасаң, минем киңәшне кабул итмәсәң, мин түзәрмен, түзәрмен дә катгый карарга килермен. Иртәме-соңмы син мине аңларга тырышырсың,

әмма мине тапмассың, — диде Рәшит Алиягә, бик күптән күңеленә тулган үпкәсен ачып. Алия эндәшмәде. Аның эндәшмәве — риза булмау, киреләнү икәнен белә иде Бәдретдинов.

Алия чәч толымнарын үрә-үрә тәрәзә аша ерак болытларга карап торды. Аннан һәр сөйләшүдә әйтелә торган бер үк сүзне кабатлады. Аннары сабыр гына, салкын гына, катгый карарын әйтте:

— Юк, мин беркая да кузгалмыйм.

Алар дачада кундылар. Төне буе утлы кылыч булып күкне яшен телгәләде. Төне буе бер дә тынмый, калын стеналарны дер селкетеп, күк күкрәде. Рәшитнең күзенә йокы кермәде. Әйе, күңелләр төрле, максатлар төрле, кичерешләр, уйлар башка. Шулай итеп юллар аерылырмы?

Таң алдыннан тагын коеп яңгыр яуды. Алия бик иртә уянды, юынды, киенде. Алар бер-берсенә бер кәлимә сүз әйтмәделәр. Рәшитнең күңелендә әллә үч уяныпмы, әллә хәтере калып, ничә еллар бергә яшәгән, балалар анасы булган горур һәм салкын Алияне онытырга ант эчте.

Менә шулай икенче тапкыр, алар арасында яшен чаткысыдай чатнап ярылган ярык киңәйде, зурайды.

Алар икесе ике бүлмәдә калдылар. Рәшит бераз газета укып алырга булды, юлга чыгарга иртә иде әле. Әмма аның күзләре берни күрмәде. Ник Алия бу кадәр үзсүзле? Ник ул аның туган ягына кайтырга теләми? Туганнарын якын итми? Гомер буе шулай. Ә бит ул Рәшитнең хезмәт җимешләре белән яши. Кара инде — өйдә затлы җиһаз, машина, дача, матур киемнәр... Алиянең эш хакы белән боларны алып булмас иде. Ә киләчәк? Ә безнең татарлык? Мөселманлык? Үлә-нитә калсаң, безне монда кая куярлар? Менә шулай ярату, мәхәббәт белән бер рәттән ярсу һәм йөрәгенең тирән бер җирендә, кечкенә агулы елан кебек, шәфкатьсезлек оялады.

БЕР ТАЛПЫНГАЧ...

Берничә көннән Рәшит Бәдретдинов Әлмәт шәһәре халык депутатларының башкарма комитетына үзенең хатын юллады. Бер-ике атнадан ул хатына җавап алды.

«Хөрмәтле Рәшит Заһретдин улы!

Сезне эшкә урнаштыру һәм фатир белән тәэмин итү мәсьәләсе хәл ителә. Сезгә июнь башларында килеп, барысын

ачыкларга туры киләчәк. Сезнең хатны алуга мин бик шат булдым.

Ихтирам белән Н.Рәхмәтуллин.

15 май, 1991 ел.»

Бу көн килде. Рәшит Бәдретдинов иң кирәкле әйберләрен генә алып, туган ягы Әлмәткә кайтып китте. Булды рәнҗү, булды үпкә, әмма бу көн — аерылу сәгате иде. Китте гайбәт, китте гаепләүләр. Кем гаепле? Кем усал? Кем үҗәт? Кем? Кем?..

Дөньясына кул селтәде Рәшит Бәдретдинов. Эшен, өен, машинасын ташлап китте. Туган җиренә ашкынды. Бер караганда ул үзен зинданга салды, ялгызлык зинданына. Әмма үкенергә уйламады да.

САУМЫ, ТУГАН ҖИР

Такси алга ыргый. Сөзәк калкулыктан күтәрелеп, Әлмәткә җитәрәк, Рәшитнең каршысында ут диңгезе хасил булды. Төнге Әлмәт! Туган җир, газиз җир!

Рәшит Бәдретдинов озын юлда озак уйланды, аның күңеле, мие тулы уйлар иде. «Юк, — дип фикер йөртте ул, — кешелек алдында үз бурычымны мин соңгы сулышыма кадәр үтәячәкмен, әле көч бар, акыл камил, баш эшли, куллар калтырамый. Эшләргә! Чыннан да, ул үзенә сүз бирде: гомеренең соңгы минутына кадәр халкына, иленә, кешеләргә хезмәт итәргә! Аның исеме Подольскида гына түгел, Мәскәүдә һәм чит илләрдә күренекле галимнәр белән рәттән яңгырады. Ул зур-зур дәрәҗәләр, исемнәр алды. Ул «Сәламәтлек саклау отличнигы», югары категорияле табиб, Мәскәү өлкәсе табиблары җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы, Германиянең Магдебург шәһәре медицина академиясе гыйльми советының почетлы әгъзасы, Чехословакиядәге Милевско шәһәренең шәрәфле гражданины. Ниһаять, ул күп еллар күренекле җәмәгать һәм дәүләт хезмәткәре булды, төрле киңәшмәләр, конференцияләр, халыкара конгрессларда чыгышлар ясады, газета-журналларга фәнни мәкаләләр язды.

Җизнәсе Ямалетдинов Таҗи һәм аның хатыны Хәдичә — Рәшитнең якын туганнары Әлмәтнең Невский урамында

зур булмаган йортта үз хуҗалыклары белән яшиләр. Рәшит шуларда тукталырга булды. Өйдә искиткеч чисталык, идәннәр ялт иткән, тәрәзә өлгеләре крахмалланган. Таҗи белән Хәдичә Рәшитне җылы каршыладылар, хәлләрен сораштылар.

— Менә туган як тартты, — диде ул, сорауларга җавап биреп.

Тәрәзә төпләрен тутырып шау чәчәктә утырган гөлләргә бер күз ташлауга, Рәшитнең үзәген өзеп, моннан күп еллар элек вафат булган әнкәсе исенә төште. Әнкәсенең яраннары, тамчы гөлләре, кыналары тәрәзә аша урамга нур сибә иде бит. Тугыз балага гомер бүләк иткән ананың куллары да шифалы булгандыр, аларның кечкенә өендә дә гөлләр күкрәп үсә иде.

Көннәр матур тора. Рәшит Заһретдин улы еш кына Әлмәт урамнарында йөрергә чыга, таныш йөзләр, дуслар очрый, матур-матур киенгән хатын-кызлар. Гүя ул моннан беркая да китмәгән, гүя сагыш та юк, моннан аерылып яшәү дә булмаган. Әлмәт матур, чиста, урамнар тулы машина.

Урамнарда йөрсә дә, кайда гына булса да, Рәшит Бәдретдинов тиз генә җанына тынычлык таба алмады.

Аны «Татнефть»нең Әлмәт шәһәр бораулау идарәсенең шифаханәсенә эшкә чакырдылар. Ул авыруларны энә белән, лазер белән дәвалады, аюрведо терапия, Су-Джок терапия ысулларын кулланды. Гаилә белән элемтә телефон һәм хатлар аша гына булды.

АРАЛАРДА ХАТЛАР ЙӨРДЕ

1991 елның ноябрендә Алиядән хат килде. Конвертны кулына алгач, Рәшит тәне буйлап ниндидер «дулкын» үтеп китүен сизде, башын нидер кыскан кебек булды, колаклары шаулап алды. Алия хаты! Конвертның ул әле адреслы ягын, әле мөһер суккан ягын әйләндереп карады, мөһердәге язуларны укыды. Хат 13 ноябрьдә салынган, 21 ноябрьдә Әлмәткә килеп җиткән. Рәшит сак кына конвертны ачты, хатны укый башлады. Бер генә минутка Рәшитнең күз алдыннан Әлмәт юкка чыкты, ноябрь бураннары, төтеннәре белән Подольск һәм Алия, балалары күз алдына килеп басты.

«Рәшит! Сиңа сагынычлы күп сәлам! Үзебез исәнбез, бер көе торып ятабыз. Балалар эшли, Фәһим укый. Мин өйдә. Ремонт бетә язды.

Рабига апа җиденче ноябрьдә үлде. Син киткәч, Хаймович үлде. Сине чакырып, берничә мәртәбә шалтыраттылар. Хәзер күрше Паша Тихомиров чирли. Шеше башында, эше бик начар. Мин сиңа берничә мәртәбә шалтыратып карадым. Мәскәү бирми, диләр. Квартир көтеп йөрисең икән. Гөлчирә шалтыратты, шул яңалыкны белдем. Бакчадан өч капчык бәрәңге алдык. Мин барганчы казып алып киткәннәр. Биш капчык бәрәңге сатып алдым, капчыгын 100 әр сумнан. Магазиннар шып-шыр. Син кайчан кайтасың? Бик авыр булмаса, шалтырат, яисә хат яз. Алия».

Алия язган хат шулкадәр кыска һәм коры иде, кемнәрдер үлгән, кемдер авырый, кемдер килгән... Рәшит кат-кат хаттагы сүзләр арасыннан җылырак сүзләр эзләде, ләкин ни гаҗәп, хат бик салкын язылган иде. Ул бу хатка бик озак җавап яза алмый йөрде. Кулы күтәрелмәде. Нәрсә язарга? Күңел тулы үпкә, йөрәк тулы сагыш. Сагынды ул, бик сагынды Алияне. Балаларын, оныгын сагынды.

Алдагы хатларында Алия Подольскидагы хаклар турында, яшәүнең бик авырлашуы турында хәбәр итте. Һәр хатында ул: «Кайт! Кайчан кайтасың?» дип үтенде. Ә Рәшит аларны Әлмәткә, Чупайга чакырып язды. «Кайту» дигән сүзнең мәгънәсен аңлатты. Мин үз туган җиремә кайттым инде, минем башка кайтыр җирем юк, ә Подольскига мин бара гына алам. Анда мин эшләдем, бераз яшәдем генә, шуңа күрә сезне дә монда кайтырга чакырам, дип язды ул хатларында.

1992 ел, 28 октябрь. Алиянең хаты.

«Бакчада кыяр, җиләк, помидор күп булды. Бәрәңге җитәрлек әзерләдек, аптырап яшәмибез. Магазиннарда шикәр юк. Паша Тихомировның гаражының стенасын җимереп, машинасын алып киткәннәр.

Ятим булып йөрмә мин исән чакта. Квартираңны приватизировать ит тә кайт. Ятим булырга өлгерерсең әле. Туганнарыңның берсенә дә кирәк түгелсең, һәркайсының үз балалары.»

1992 ел, 11 декабрь.

«Сиңа кайтырга кирәк, чеклар алырга. Монда шикәр юк, мөмкинлек булса шикәр, песок алып кайт. Монда килосы 135 сум, ул хакка да юк.»

1992 ел, 26 декабрь.

«Магазиннарда шып-шыр, талоннарга да бернәрсә алып булмый.»

1993 ел, 23 апрель.

«Син миңа ультиматум куйгансың, 15 майга кадәр Әлмәткә килергә. Мин бик күп уйладым, монда балалар. Минем шатлык — шул балалар. Үзең беләсең, мин алардан аерылып тормадым, беркая да аларны ташлап китмәдем. Әлмәттә минем беркемем дә юк. Өч атна буе анда булдым, беркемгә дә кирәгем булмады. Чирләсәм, анда караучы да булмаячак. Монда үзең кайт.

Син берүзеңә кыен дигәнсең, син бит бөтенләйгә китәм дип китмәдең, бар нәрсәне шыпырт кына эшлисең. Кайт монда. Күп эшләдең инде, җитәр, монда да эшләп була.»

1993 ел, 5 май.

Рәшит Заһретдиновичның оныгы Фәһимгә хаты.

«Саумы, минем кадерле, мәрхәмәтле оныгым һәм дустым Фәһим!

Сиңа чын йөрәктән сәлам һәм дөньядагы иң яхшы теләкләр! Хатыңны һәм фотосурәтеңне алдым, бик зур рәхмәт.

Турысын әйтәм, яшермим, синең фотосурәтеңне кулыма алдым да бик игътибар белән карадым һәм түзмәдем, елап җибәрдем. Мин бит сине бик сагындым.

Хәзер синең соравыңа җавап бирәм. Син: «Сездә атлар бармы? Атта йөрисем килә», — дип язгансың. Безнең якларда атлар бар, әмма алар авылларда, ә мин шәһәрдә яшим (Әлмәттә), шуңа күрә сиңа ат турында катгый вәгъдә итә алмыйм, чөнки Әлмәттә ипподром юк әле, киләчәктә булыр, диләр.

Ат вәгъдә итмәсәм дә, син бит минем янга килерсең һәм миңа бәхетле минутлар бүләк итәрсең.

Ә синең дәү әниең, әтиең һәм Рөстәм абыең бөтен гомерем буе миңа шатлыклы, бәхетле, җылы көннәр бүләк итмәделәр.

Хуш, минем иң якын, иң кадерле дустым Фәһим!

Синең дәү әтиең.»

1993 ел, 23 май. Фәһимнең бабасына язган хаты.

«Кадерле дәү әти!

Мин синең хатыңны алдым, бик зур рәхмәт!

Уку елы тәмамланып килә, мин имтиханнар тапшырам. 21 майда математикадан 4 ле алдым, 23 майда сочинение яздык, билгесен белмим. 14 майда — инглиз теленнән имтихан.

Син мине анда чакырасың. Дөресен әйткәндә, безнең акча ягы такыр, үзең беләсең. Рөстәм абый ярдәм иткәли. Син үзең безгә акча җибәр, әни белән Әлмәткә барырбыз. Иң яхшысы — үзең кайт.

Хуш. Синең оныгың Ефим.»

1993 ел, 7 октябрь. Алиянең хаты.

«Бәрәңге әзерләдем. Сумка белән дүрт капчык бәрәңге ташыдым, килосын 100-120 сумнан. Тормыш бик авырайды. Әлмәткә бара алмыйбыз. Рөстәм укый. Бакчага да фатирны калдырып китеп булмый, безнең өйдә ике фатирны бастылар инде».

1993 ел, 25 октябрь.

«Нигә Рөстәм укырга керде, дигәнсең, киңәшми. Син бит белеп киттең, ныклап әйтергә идең. Син ике баланы ташлап киткән идең бит әле, ул беркемне дә калдырмады. Син укырга киткәч, миңа беркем дә ярдәм итмәде, бер литр сөт кенә бирүче дә булмады, ә син, туганнар, дисең. Мин фатирны ташлап китә алмыйм, кайтса, Рөстәм берүзе кайтыр.»

1993 ел, 7 декабрь.

«Әлмәткә Рөстәмне берничек тә алып барып булмый, аның белән сөйләшеп булмый, укудан җибәрмиләр, ди. Гел үзенчә эшли бит ул. Теге марҗага өйләнгәндә дә мин риза булыр идеммени? Гүзәлне җитәкчесе җибәрми, Гүзәл диссертация яза.

Рәшит! Яңа елга син үзең кайт. Юл расходын Гүзәл күтәрер, озакка кайт, ныклап сөйләшербез.»

1994 ел, 2 гыйнвар. Рәшитнең улы Рөстәмгә язган хаты.

«Өченче ел инде мин ялгыз яшим. Ялгыз яшәү бик авыр. Минем кадерле кешеләрем күп түгел: әниең, син, Гүзәл, Фәһим. Мин бөтен гомерем буе сезне кайгыртып яшәдем, яхшы булсын дип тырыштым. Бәлки, мин үрнәк ата һәм бабай булмаганмындыр. Миңа билгеле булмаган сәбәпләр аркасында сез икегез дә, Гүзәл һәм син, минем киңәшләремә колак салмадыгыз, минем белән киңәшләшмәдегез, барысын да үз белдегегез белән эшләдегез, минем тырышлыкларымны искә алмадыгыз. Моның сәбәбен миңа ихтирамыгыз булмаудандыр дип уйлыйм. Ә бит мин үземнең максатчанлыгым, тырышлыгым, хезмәт сөюем белән ихтирам яулаган кеше идем. Мин бит тормышта үзем өчен, сезнең өчен һәм гаилә, җәмгыять өчен бик күп эшләдем. Мин, урыс телен белмәгән авыл малае, Чупай малае идем. Сезнең белән минем арада зур аерма бар.

Миңа хәзер озакламый җитмеш яшь, әниегезгә дә аз түгел. Гүзәлнең тормышы рәтле түгел. Ә синең тормышыңның рәте булмаганга син үзең генә гаепле, әниеңне һәм мине тыңламадың. Әлмәткә кил, сиңа бик туры килә торган, безгә килен булырлык кыз бар, киләчәгеңне әйбәт итеп үзгәртә аласың.»

1994 ел, 9 февраль. Алия хаты.

«Әлмәткә кайтып булмый, чөнки Гүзәл авырый. Мәскәүдә хастаханәдә ятып чыкты. Ниндидер уколдан аллергия булган. Бавыр, бөер, йөрәк эшләмәс булган, кан басымы төшкән. Рөстәм ординатурага йөри, эш тапмады.

Фәһим яхшы гына укый, әнисе авыргач, бик боекты, уйнарга да чыкмады. Күз тимәсен, чаңгыда бик яхшы йөри.»

1994 ел, 21 февраль, Рөстәм хаты.

«Миңа хат язуың өчен рәхмәт. Тиз генә хат язмавым өчен гафу ит. Соңгы ике атнада грипп белән авырдым, авырсам да, институтка йөрдем, хатыңа җавап яза алмадым. Үземә эш эзләп тә йөрим, хәзергә Гүзәл акчасына яшибез. Ординатурага керүемә үкенмим, ничек эшләргә кирәк икәнен өйрәнәм. Конкуренция көчәя. Минем

планнарым шундыйрак: Әлмәткә күченеп яшәү, фатирны Ефим белән Гүзәлгә калдыру.

Безгә хат язуың өчен зур рәхмәт. Мин майда, акча эшли алсам, Әлмәткә барырга тырышырмын.

Рөстәм.»

1994 ел, 30 май. Алия хаты.

«Гүзәл безгә билет алып кайтты. Фәһим белән икәү Әлмәткә кайтабыз. Поезд — 256. 16 июньдә 13 сәгать 17 минутта китә. Вагон 7. Син үзеңнең машинаң белән каршы ала алмасаң, автобус белән генә бар Бөгелмәгә. Вакытың булмаса, квартир ачкычын күршегә калдыр. Без үзебез барып җитәрбез.

Сәлам белән Алия.»

Рәшит Бәдретдиновның эпистоляр хәзинәсе бик зур, хатлар, открыткалар, котлаулар... Ул соңгы елларда үзенең фронтташ дусларын эзләде, бик күпләрен табып, алар белән дә җылы хатлар алышты.

Күңеле моңланып китсә дә, нидәндер хәвефләнеп, эче пошып алса да, Рәшит хатлар салган тартманы ача. Ача да берәм-берәм һәркайсын укып чыга. Гаилә альбомын актарып, җанына якын кешеләрнең рәсемнәрен сыйпап-сыйпап ала, аннан телефон трубкасына тотынып, Подольскидагы таныш саннарны җыя. Күңеле булганчы, эче бушаганчы Алиясе, Гүзәле, Рөстәме белән сөйләшә. Аннан Фәһимгә чират җитә. Дау ати, дип урысчалатып әйтсә дә, оныгының йомшак матур тавышы аның күңелен күтәрә. Соңгы елларда гаилә белән элемтә гел телефон ярдәмендә генә булды, сагыштан җәфаланган, олыгайган кешегә шуннан да уңайлысы юк, язасы юк, почтадан конверт эзлисе юк, телефоннан саннар җый да күңелең булганчы сөйләш.

ГОМЕР БӘЙРӘМЕ

12 июль, 1994 ел. Көн шундый матур булып туды, якшәмбе иде. Бу Рәшит Бәдретдиновның туган көне, аңа 70 яшь. Ул иртәннән саф һавада Әлмәтнең яшеллеккә төренгән урамнарында йөрде. Шәһәрнең һавасы да аңа башка булып тоелды. Җиңел, җылы һава җанын назлап, төреп алды да аны әкрен генә тибрәтте, изрәтте. Аннан көне

буе аның күңеле әллә нинди гыйшкый халәттә булды. Ул 70 яшен туган җире, туган туфрагында каршылый.

Истәлекләр, уйлар аның җанын талкыды, берсен исенә төшерә дә ул елмаеп куя, икенчесен уйлый башласа, кәефе кырыла, елыйсы килә, аннан фикер очы югала да куя. Ул менә шушында тормышның аклы-каралы якларыннан бигрәк, сөенечле якларын алга сөрә-сөрә, гомеренең шактый арасын яши... Исәпли белгән кешегә бу аз түгел. Ә аның илле елга якыны читтә узган: сугыш, институт, аспирантура, Подольск. Ә татар арасында татарча сөйләшеп, татарча уйлап, чын татарча ул бары тик егерме ел тирәсе генә яшәгән. Ләкин шунысына да ул ихлас күңеленнән шатлана, хезмәтнең изге юлдан баруын аңлап горурлана. Әнкәсе карыныннан төшүенә җитмеш көн генә үткәндер кебек тоелса да, җитмеш ел вакыт узган икән бит. Әйе, аның кайчандыр илле яшен, алтмыш яшен бәйрәм иткән көннәре булды, башка шартларда, башка урында. Ә бүген... ул көннәрен түгел, ә сабый чакларын, чыклы үлән өстеннән яланаяк йөгереп үткән балачагын сагына. Әмма аның ашкынулы хезмәте айлар-еллар узганын сиздермәгән. Гомер арбасы аның холкын чарлаган, еш кына һавалардан җиргә төшереп бастырган. Шул гомер арбасында ул чынбарлыкның бөтен йөген сөйрәгән. Шул юлда ул гаҗәеп шәхесләр, искиткеч язмышлар белән очрашкан, ничәмә-ничә кара еланга юлыккан...

Менә ул озак кына йөреп өенә кайтты. Никтер үзе яши торган күп катлы йорт та, урам да, анда үскән агачлар да аңа ят булып күренделәр. Ни өчен икәнен ул үзе дә аңламады. Әллә нинди сәер уйлар аның башын бутады.

Бәлки хәбәр итми генә җитмеш яшенә якыннары кайтып төшәр? Бу хыялдагы өмет аның күкрәген җылытты. Килерләр, килерләр, җитмеш яшь бит! Ул фатирының ишек төбенә килеп басты, кесәсеннән ачкычын алды. Ах, ул ишек ачканда эчтә аның кадерлеләре елмаешып карап торсалар! Ләкин андый көтелмәгән сөенечләр аңа бервакытта да тәтемәде шул. Ул ишеген ачты, ялгыз ир яшәгән бүлмә буш, караңгы, күңелсез иде.

Телеграмма килер, зур матур открыткага матур сүзләр язылган булыр Почта тартмасын ачып карады — тартма буш, әле килеп җитмәгән дип уйлады ул.

Озакламый зур гаилә булып туганнары килеп керде. Бүлмә кинәт яктырып киткәндәй булды. Туганнарының

тыны да, аларның назлы тавышы да Рәшиткә һәрвакыт бик кадерле, бик газиз.

Туганнары шау-гөр килеп, өстәл тирәли урнаштылар. Аңа алып килгән күчтәнәчләр, бүләкләр өстәлгә тезелде. Котладылар, үптеләр.

Рәшит Заһретдин улы туганнарын озатканда инде кич иде, Әлмәтне иңләп-буйлап дигәндәй, җылы яңгыр сибәли. Ул озак кына яңгыр астында йөрде. Өенә кайткач, почта тартмасын тагын ачып карады. Анда берни дә юк иде. Йөрәге сулык-сулык сыкрап алды. Балалары да, Алия дә аның гомер бәйрәмен исләренә төшермәгәннәр.

13 июль, 1994 ел. Иртән Рәшит Заһретдин улы көндәлегенә урысчалап болай дип язып куйды:

«Мин хәзер тәмам ышандым, мин сезнең өчен яшәмим һәм берни дә тормыйм икән.

Мин дә сезне онытырга тырышачакмын.

P.S. Болай булгач, үлсәм дә, сезгә хәбәр итмәскә кушачакмын.»

Соңлап кына, ике-өч көннән соң котлау телеграммасын алып килделәр, әмма ул инде Рәшитнең җанын җылытмады.

ЯЛКЫНЛЫ СҮЗ

Әлмәткә кайту белән Рәшит Бәдретдинов дәртләнеп, илһамланып, шәһәр һәм район, республикада бара торган иҗтимагый тормышны өйрәнде, күзәтте, үзенең уй-фикерләрен туплады. Еш кына районда нәшер ителүче «Әлмәт таңнары», «Знамя труда» һәм республикада чыга торган «Ватаным Татарстан» гәзитләрендә ялкынлы мәкаләләр бастырды. Табибның үзе турында да бик күп яздылар. Рәшит Заһретдин улы Әлмәт татар иҗтимагый үзәгенең утырышларында актив катнашты, милли мәсьәләләр, тел турында үзенең фикерләрен ачып салды. Әйтергә теләгән уйлары, күрәмсең, аның тынын буа, йөрәген кыса, тизрәк бушанасы килеп, ул һәрчак каләмгә тотына һәм мәкаләләр яза. Менә аларның кайберләре.

1992 ел, 16 май. «Әлмәт таңнары». Рәшит Бәдретдиновның бу санда «Татар тәмәке тартмаган» исемле мәкаләсе басылып чыкты.

«Тәмәке тарту безнең ислам динендәге татар халкы өчен гомер-гомергә килешми торган, гөнаһлы, хурлыклы начар гадәт булып саналган. Тартырга гадәтләнгән кеше дә үз

гамәлен кешедән яшереп, курка-өркә генә башкарган. Аны гаепләп кенә калмаганнар, бәддога укыганнар...» — дип яза табиб һәм тәмәке тартуның зарары, аны дәвалау ысуллары турында бәян итә.

1992 ел, 19 май. «Әлмәт таңнары».

Табибны һәр нәрсә борчый, тирә-якта булган хәлләргә ул битараф кала алмый. «Әлмәт таңнары» гәзитендә мөхәррир Ә.Сәләховның «Хәлебез мөшкел, нәрсә кылыйк?» дигән баш астында мәкаләсе чыккач, Рәшит Заһретдин улы гәзитнең хәлен җиңеләйтү теләге белән үзенең эшләп алган хәләл акчасыннан зур гына сумма акча китереп бирә.

«Тормыш ничек кенә авыр булмасын, газетаны чыгарудан туктамагыз, аны Әлмәт халкының чын-чынлап милли тормышы көзгесе дәрәҗәсенә күтәрергә кирәк», — ди.

1994 елның 9 август һәм 13 сентябрь саннарында «Әлмәт таңнары» гәзите Рәшит Бәдретдиновның бер үк темага багышланган ике мәкаләсен бастырып чыгарды: «Һәр сандугач үз талын мактап җырлый» һәм «Тирәнтен уйланмаган ниятләр турында».

Рәшит Бәдретдинов бу язмаларда үзенең табигать турында борчылуларын бәян итә. Җир-ананы рәнҗетерлек эшләргә юл куймаска чакыра. Табигать кайгысын үз кайгысы итеп кабул итә. Шулай Ватан, милләт, табигать, халык өчен сызлану, сыкрану белән яшәде табиб.

1995 ел. Җиңүнең 50 еллыгы. Рәшит Заһретдин улы ул көнне үзенең дәфтәренә мондый сүзләр язып куя:

«Күңелемне борчыган, тынгы бирмичә, йокысыз калдырган уйларым күп. Сугыш тәмамланганга 50 ел. Җиңүгә иң зур өлеш керткән баһадирларыбызның күбесе бу фани дөньядан китеп барды. Үз-үзләрен аямыйча утка ыргылганнарның газиз гомерләре чит-ят җирләрдә өзелде. Минем 1917 елда туган Кәшиф абыем әсирлектә калып, немец фашистлары тарафыннан җәзалап үтерелгән. 1914 елда туган Карәметдин абыем хәбәрсез югалган, якынча 1942 елда Сталинград фронтында җирләнгән булырга тиеш. Аның кабере билгеле түгел. Нинди аяныч хәл. Бик күпләрнең сөякләре җир өстендә аунап ята. Цивилизацияле илләрдә моңа һич тә юл куелмый. Анда шәһитләрне зурлап җир куенына салалар. Россия әле һаман сугыша. Үз халкы белән сугыша. Чечня мәхшәре әле күпме кешенең гомерен өзәр.»

1995 ел, 19 декабрь.

Рәшит Бәдретдиновның «Ватаным Татарстан» һәм «Әлмәт таңнары» гәзитләрендә зур күләмле «Тәкъдимнәрем бар» дип аталган мәкаләсе басылып чыкты. Мәкалә икетеллелек мәсьәләләренә багышланган. Автор болай дип фикер йөртә:

«Урыс тотар да бервакыт татарча сөйләшә башлар, дигән уйның булуы да мөмкин түгел. Чөнки закон кабул итү белән генә эш төгәлләнми бит әле. Бүген татар теле эш урыннарында кирәкле дәрәҗәгә күтәрелмәгән, ул һаман да аш бүлмәсе, кухняда ызгыш теле дәрәҗәсендә генә кала бирә.»

БӘЙРӘМ

2000 ел. Май. Җиңүнең 55 еллыгы. Олы, изге бәйрәм. Бәйрәм көннәрендә ветеранны бертуктаусыз телефон аша кунакка, очрашуларга чакыралар. Чыгыш ясагыз, сөйләгез, диләр.

Әлмәттә бу бәйрәмгә аеруча нык әзерләнәләр. Урамнарны чистарталар, өйләрне бизиләр, мәйданнарны тәртипкә китерәләр.

9 Май көнне Рәшит Бәдретдинов та Мәңгелек ут янына ашыкты. Урам буйлап атлаганда ни өчендер 1943 елның кышы күз алдына килеп басты, бәлки кыш сугышның иң авыр чагы булгандыр. Урамда чәчәкле май, ә ветеранның күз алдында буранлы кыш. Яралыны киеменнән әләктереп, аның коралын муенына асып, салкын кар өстеннән шуышуы бик авыр була иде. Авыр кышкы кием, маска халат хәрәкәтне авырлаштыра, салкын тынны куыра, берничә метр җир очсыз-кырыйсыз булып тоела.

Әкрен генә атлап, үз уйларына бирелеп, ул мәйданга килеп җитте. Баш өстендә югарыда-югарыда чыркылдашып бер төркем кош очып үтте. Аңа хөрмәтләп урын күрсәттеләр.

Менә трибунага шәһәрнең күренекле кешеләре, күкрәкләре орден-медальләр белән бизәлгән ветераннар күтәрелде. Тынлык урнашты һәм оркестр тантаналы марш уйнап җибәрде.

Ул еш кына мондый тантаналарда кешеләрнең күзләрен, йөзләрен күзәтә. Кайвакыт халык ниндидер сүзләр, өндәмәләрне җылы кабул итә, сүзнең бетүен дә көтми, дәррәү кул чаба башлый, ә кайвакыт битараф кала, ул сүзләрне тыңлар-

га теләми, хәтта авызын кулы белән каплап та тормый, зур ачып, исни башлый. Андый вакытта Рәшитнең ачуы кабара. Бүген дә шулай булды. Ул баш өстендә очкан кошларны күзәтте. Аның уйлары да бик еракта иде. Бәйрәмдә сөйләүчеләрнең чыгышлары аны канәгатьләндермәде, ул урыныннан кузгалып, тантана тәмамлануын көтмичә, кайтып китте.

Икенче көнне ул үзенең дәфтәренә болай дип язып куйды:

«9 май, 2000 ел. Җиңүнең 55 еллыгына багышланган тантанада булдым. Анда мин нидер әйтергә тиеш идем, әйтә алмадым, бик үкендем, хафаландым. Тантанадан соң үзүземне сүгеп җәяү генә кайттым. Анда әйтергә тиеш сүзләрем болайрак иде: «Хакимият башлыгы Татарстаныбызның дәүләт телендә бары тик ике сүз әйтте. Ветераннар Советы рәисе татарча бер генә сүз дә әйтмәде. Ул гынамы, үзләренең чыгышларында Татарстанның суверенлыгына кире мөнәсәбәт тә ишетелде. Мин бу хәлгә протест йөзеннән, бу тантананы ташлап киттем.»

ФАТЫЙМА

Рәшит Бәдретдинов эшеннән соңлап кына кайтып керде. Бүлмә буш. Утны яндырып җибәрсә дә, аңа ничектер өйдә караңгы һәм салкын булып тоелды. Өенә ялгыз гына кайтып керүе аңа бик күңелсез була. Гадәтенчә, ул тиз генә чишенеп, киемен элде дә тәрәзә янына килде, саргая башлаган каен яфраклары арасыннан күренгән баеп баручы кызгылт кояшка бик озак карап торды. Ул үзе дә шушы кояш кебек түгелме соң? Аның да соңгы нурлары гына. Алар йөрәкне дәртләндерми, киресенчә моңландыра, мәңге бетмәс үкенечләр тулы хисләр тудыра. Ул тәрәзә яныннан китеп, аш бүлмәсенә таба атлады, анда юылмаган савытлар аның кәефен кырды. Җиң сызганып, аларны юа башлады. Бу ялгызлык, бу савыт-саба... Ул ихтыярсыз үзенең якыннары турында уйлый башлады. Нәрсә эшлиләр икән? Алия дачададыр, анда хәзер аңа эш күп. Гүзәл Мәскәүдә я театрда, я дусларындадыр, ә Рөстәм? Ул кайда икән? Кинәт аның башына нидер суккандай булды. Ә нәрсә дип мин алар турында уйлыйм әле? Мине бит алар оныттылар, хат та язмыйлар хәтта. Юк, юк! Алар турында уйламаска! Өзелгән — беткән! Онытырга!

Менә ничә еллар инде алар кыска гына язылган салкын хатлар яки телефон аша сөйләшеп кенә аралашалар. Шулай тамчылап-тамчылап дигәндәй, җылылык, мәхәббәт тә, томан булып таралган чык бөртекләре кебек, юкка чыгып бара.

Бәлки өр-яңадан яңа тормыш башларгадыр? Алия генә димәгән. Кайтмый бит, минем белән яшәргә теләми. Дөрес, Рәшит Заһретдин улы күптән инде ялкынлы, дәртле, тупырдап торган егет түгел. Аңа тиздән җитмеш биш. Бу гомернең соңгы чиге түгелме соң? Юк, һич юк, мең мәртәбә юк! Аның әле кемгәдер иркәләнәсе, бу ялгызлыктан, бу җелекләргә үткән ялгызлык суыгыннан котыласы килә. Ул кемнедер аңа бик якын булуын бөтен акылы, хыялы, тәне белән тели башлады.

Рәшит газ плитәсе янына килде, чәйнеккә су агызып, аны ут өстенә утыртты. Нидер пешерергә кирәк. Нәрсә пешерә белә соң ул? Ул бит бу эштән бик ерак булды, гомеренең яртысын диярлек, көн дә, юка җилем перчаткалар кигән кулларын алга таба сузып, бармакларын тырпайтып, операция өстәле янына атлады, канга бата-бата кешеләрнең гомере өчен көрәште. Ә аш, ботка пешерү, ит кыздыру башкалар эше иде.

Ул бәрәңге пешерергә булды. Алай итте, болай итте, берничә бәрәңге әрчеп, суга салды һәм пешкәнен көтә башлады.

Шул вакыт ишектә кыңгырау чылтырады. Ул, кем килүен сорап тормыйча гына, ишекне ачты. Бу — ветераннар Советыннан килгән ике ханым — Мәрьям белән Фатыйма иде. Рәшит каушап калды:

— Гафу итегез, үтегез, мин — ялгыз кеше, тәртип юк инде, бигайбә! — диде.

Алар бу көнне өчәүләп бик озак сөйләштеләр, якыннанрак таныштылар.

— Мәрьям белән без күптәнге танышлар, без аның белән бергә эшләдек, сезне, Фатыйма ханым, мин әле бик аз беләм, — диде ветеран.

Тиз генә өстәл әзерләнде, пар чыгып торган бәрәңге өстәлгә килеп утырды. Аны бик тәмләп ашадылар, чәй эчтеләр. Сөйләшә торгач, Фатыйманың да сугышта катнашканы беленде.

— Мин зенитчица идем, яктырткыч бомбаларны, бомбардировщикларны юк итә идек. Житомир, Овруч

шәһәрләрен, күперләрне саклыдык. Украина, Польша, Белоруссия җирләре, — дип сөйләп китте ул. — 1945 елда сугышка кадәр йөргән егетем белән өйлә-нештек, 1946 елда улыбыз Дамир туды. Ирем Нәҗип 1996 елда вафат булды. Күптән пенсиядә инде.

Фатыйма һәм Мәрьям белән сөйләшү Рәшит Заһретдиновичның фронт юлларын күз алдына китереп, сугышта алган яраларын кабат кузгаткан кебек булды.

Хатыннар соңлап кына киттеләр, әмма Рәшит атналар буе айный алмый, шушы сөйләшү тәэсирендә йөрде. Бик ошатты ул Фатыйманы. Карашы нурлы, сүзләре төпле, дип уйлады ул.

Моңа кадәр дә ветеранның өен җылытырга, керләрен юып үтүкләргә, ризык алып кайтырга, ашау хәстәрен күрергә килеп йөрүче ханымнар булды-булуын, әмма берсе дә болай күңелгә якынаеп китмәде,

Фатыйма йә дус хатыны Мәрьям, йә башка хатыннар белән еш килде. Ялгыз гына килүне ничектер артык әрсезлек дип санады. Ялгыз килгән очракта да эшен тәмамлагач, тиз генә кайтып китә торган булды.

Беркөнне ветеран бөтен кыюлыгын җыеп, Фатыймага болай дип сүз башлады:

— Дөнья йөзендә бер генә нәрсә дә так яратылмаган. Бөтен кеше парлы-парлы, синең белән без генә моңлы-зарлы. Фатыйма, әйдә язмышларны үзгәртеп, бергә яши башлыйк.

— Булмас, Рәшит, — диде Фатыйма, — бер күңелгә ике дәрт сыймас, синең хатының исән, минем ирем үлгәнгә берничә генә ел әле, аннан күңелем суынмаган.

Бу катгый карар иде. Моның өчен Рәшит бик борчылды, хәтта Фатыймага үпкәләде. Берничә мәртәбә телефон аша үзенең үпкәсен белдерде, һаман да үзенең фәкать аның белән генә бергә булырга теләвен әйтте.

Бу сөйләшүдән соң Фатыйма да күп уйланды. Нишләргә? Ничек аны үпкәләтми генә барысын аңлатырга? Ул иренең әле дә булса шкафта эленеп торган костюмы һәм җәйге плащын кулына алды, аларны озак кына сыйпап утырды. Илле ел бергә гомер иткән ирен, аның көчле яшь чакларын, мәһабәт күркәм кыяфәтен күз алдына китерде. Кеше белән сөйләшкән кебек, ире Нәҗипнең киемнәре белән сөйләшә башлады.

Мин бит сезне беркемгә дә бирмәдем, сатмадым. Сездән аерылсам, Нәҗип белән минем арада булган мәхәббәт юкка чыгар кебек тоелды. Ә бүген... бүген мин чишә алмаслык катлаулы һәм четерекле мәсьәлә алдында калдым. Нәҗип, сиңа булган гомерлек мәхәббәтем бу мәсьәләнең бер ягы, ә икенче ягы — бу ярдәмсез, хатыны тарафыннан читкә кагылган ялгызак ир. Мин сине дә оныта алмыйм, аңа да изгелек эшлисем, ярдәм кулы сузасым килә, аны тормыш авырлыкларыннан саклыйсым килә. Нишлим? Әйт, Нәҗип?!

Бик катлаулы тормыш мәсьәләсен этисе янына Әлмәткә кунакка, берничә көнгә килгән Гүзәл чиште.

— Фатыйма апа, — диде Гүзәл, син дә, эти дә ялгыз. Килеп кенә тор инде син аның янына. Үзеңә дә җиңелрәк булыр.

— Әниең ни дияр, Гүзәл? Ул бар бит.

— Әни барыбер кайтмый, ул Рөстәмне ташламаячак.

ЯҢА ТОРМЫШ

Шушы көннән башлап алар яңа тормыш белән бик матур яши башладылар. Рәшит Заһретдин улының дөньяга булган үпкәсе, авыр уйлары, ялгызлыкта җәфа чигүләре, бөтен үткәне әллә кайда еракта, томан эчендә калгандай булды. Бу көннәрдә үзен биләп алган тантаналы хисләр аларны каядыр читкә җибәрде. Ул яшәреп китте, адымнары яшьләрчә ышанычлы, эше гел уңышлы булды. Ул яшәячәк, чөнки аның янында үзен ихтирам итә торган Фатыйма бар. Фатыйма шушы җанга якын газиз җирдә аны көтеп торган. Рәшит көн дә иртә-кич аның йомшак тавышын ишетә, сөеп, якын итеп караган моңсу күзләрен күрә. Ул барлык уйлары белән эшендә дә, юлда да гел Фатыйма белән.

ӘЙТЕЛМӘГӘН СҮЗЛӘР

Ничәмә көннәр, ничәмә-ничә йокысыз төннәр уйланып ята торгач, телефон аша барын да әйтеп бетереп булмый, дип, Рәшит Заһретдин улы ап-ак кәгазьгә беренче сүзен язып куйды: «Сәлам хат!» Ул бу кәгазьгә язылачак җылы сүзләрне, иң кирәкле фикерләрне әллә кайчаннан туплый-туплый өч көн язды, хат башыннан ахырына кадәр теләк һәм өмет, киңәш һәм васыятьләр булсын дип уйлады. Бу хатның һәр җөмләсен, фикерен үзенә буйсындыручы бер

нәрсә бар, ул да булса инде онытырга теләп тә, оныта һәм күңеленнән җуя алмаган олы мәхәббәте иде.

Ә БУ ЮЛЫ МОГҖИЗА БУЛМАДЫ

Табибны соңгы вакытта бер нәрсә борчый: аның эшен кемнәр дәвам итәр? Ул еш кына үз-үзенә: «Картаясың, картлач!» дияргә ярата, үзенең тормыш юлына, гомер агышына нәтиҗә ясый. Шулай да юкка гына яшәмәгән Рәшит Бәдретдинов. Ул балаларына да һәрчак: «Гомерегезне бушка уздырмагыз, дөньяда гомерем заяга узды, максатыма ирешә алмадым дип зарланудан да ямьсезрәк нәрсә юк», — дия иде. Ул хатларында да аларга бик еш шул турыда язды.

Соңгы айларда ул үзенең сәламәтлеге йомшаруын сизә башлады: бер-ике көн яхшы гына, өченче көнне инде никтер бик авыр була. Әмма бернигә дә карамый ул үз өендә авыруларны дәвалый. Кайвакыт шундый хәлсезлек килеп, кайсыдыр тамырга баса — төн буе хәлсезләнеп ятасы гына килә.

Кешенең табигате шундый: ул һәрчак нәрсәгәдер ышанып яши. Иң кискен вакытларда, инде бетте, берни дә ярдәм итмәс диясе урында ул: «Ә бәлки!» — диярге ярата. Менә шул могҗизага ышанасы килә кешенең.

Әмма бу юлы да могҗиза булмады.

Рәшит Бәдретдинов табиб бүлмәсеннән сукыр һәм чукрак кеше кебек капшана-капшана чыгып китте. Аңа коточкыч диагноз куелган: яман шеш. Күптәнге танышы, коллегасы алдый да, икейөзлеләнә дә алмады, дөресен әйтте: операция кирәк.

— Мине Казанга җибәрәсезме? — дип сорады Рәшит Бәдретдинов.

— Юк, сез Казанда беркем дә түгел, сез үзебезнең кеше, безгә ышансагыз, операцияне үзебез ясарбыз.

КОРЫГАН АЛМАГАЧ

Хезмәт, эш кешене бәхетле итә. Әйе, әйе. Студентлар арасында, шау-гөр килеп торучы аудиторияләрдә Гүзәл дә бик бәхетле. Аны ихтирам итәләр, яраталар, ул шәкертләренең кечкенә генә уңышына да куана, тыйнак, әдәпле — ул шундый тәрбия алган. Гүзәл Мәскәүдә медицина-стома-

тология университетында балалар стоматологиясе терапиясе дигән фәнне укыта.

Менә Гүзәл стоматология университетының биек, зур ишекләрен ачып, урамга чыкты һәм язгы көннең күзләрне чагылдыручы кояшына киң итеп елмайды, күзләрен йомды. Арылган. Лекцияләр күп булды. Ул салмак кына метрога таба атлады. Аның зур куанычы бар: улы Фәһим өченче курсны тәмамлап килә, чибәр, акыллы. Коммуналь квартирада алар улы белән егерме өч квадрат метрлы бүлмә-дә яшиләр. Йорт бик иске, кояшлы көннәрдә дә фатирда үтә-күренмәле эңгер-меңгер. Мәскәүдә фатир ягы бик авыр, үтә четерекле.

Метрода өенә кайтканда Гүзәл утырган җирендә күзләрен йомып, тирән уйга чумды. Әтисе аның исеннән бер генә минутка да чыгып тормый. Бүген дә шулай булды, ул бала чакларын исенә төшерде. Әтисе белән әнисе бик матур, тату яшәделәр. Әнисе ял көннәрендә тәмле-тәмле ризыклар пешерә иде. Әтиләре һәрчак балалар белән нинди дә булса уен оештыра, өй тулы бала-чага була: Гүзәлнең дуслары, Рөстәмнең иптәшләре килә, әтисе үзе дә балага әйләнә, һәм алар белән шау-гөр килә.

Балаларын кеше итү өчен ата белән ана барысын да эшләделәр. Укыттылар, төрле сәяхәтләргә алып чыктылар. «Курск дугасы»на бару, юлда очраган һәр шәһәрнең тарихи истәлекле урыннарын карау, Балтыйк буе, Азов диңгезе, Уфага, Әлмәткә туганнарга кайту, Чупайга, Бузатка машина белән бару... Никадәр истәлекләр!

Гүзәл институтның дүртенче курсын тәмамлагач, Рөстәм белән икесе Чехословакиядә, Милевско шәһәре музеенда әтиләренең рәсемен күреп куандылар. Никадәр хатирә! Онытып буламы соң боларны?!

Гүзәл кибетләргә сугыла-сугыла соң гына бүлмәсенә кайтып керде. Фәһим әле кайтмаган иде.

Сәгать җидедә телефон чылтырады. Әнисе икән. Ул гадәттәгечә балаларыныю хәлен сорашты, дачада булып кайтуы турында сөйләде.

— Гүзәл, беләсеңме, нәрсә булган. Теге зур алмагач, әтиең утырткан алмагач корыган. Хәтерлисеңме, бакча уртасында, зур ябалдашлы нинди мәһабәт агач иде, алмаларын җыеп бетереп булмый иде. Башкалары бары да чәчәккә бөреләнгән, ә ул — юк, корыган.

Бу хәбәрдән Гүзәл өнсез калды. Ул бер сүз дә дәшә алма-

ды. Күз алдына ботаклары белән тырпаеп торган алмагач килеп басты. Шул шыксыз ботаклар ниндидер хатирәләр булып, аның тәне буйлап шуышкандай булды, муенына үрмәләде. Гүзәлнең кинәт тыны кысылды, аяк-куллары калтырый башлады, аның күюелен коточкыч шом биләп алды.

— Кадерле әнием, — диде Гүзәл, — бу бер дә яхшыга түгел. Бу — ниндидер яман билге. Әти ни хәлдә икән?

Алия сүзен дәвам итте:

— Әллә тычкан, әллә башка җанвар агачны бик нык кимергән, төпләргә туры килер инде.

Алия белән Гүзәл салкын гына хушлаштылар.

Бүлмә эче кинәт караңгыланып киткәндәй булды. Гүзәлнең йөрәге сулкылдап-сулкылдап куйды: анда әтисе ни хәлдә икән? Ул арада улы Фәһим дә кайтып керде. Ул әнисенең күзләрендәге борчылу әлпәсен бик тиз күреп алды:

— Әни, нәрсә булды? Нигә борчылдың?

Гүзәл, Фәһимне янына утыртып, Подольскидагы дачада мәһабәт алмагачның коруы турында сөйләде.

— Ул әти утырткан агач иде, — диде Гүзәл, тәне буйлап тагын бала йоны кабарды, калтыранып куйды, туңа башлады.

Гүзәл бу төнне йокысыз үткәрде, төн караңгысы аңа хәвеф-хәтәр якынлашуын белдергән кебек, ниндидер кыштырдаулар, шомлы тавышлар белән җанына тиде. Ул әллә ничә тапкыр урыныннан торып, сәгатькә карады: сәгать ике... өч... дүрт...

Менә күк йөзе яктыргандай булып, бүлмәнең зур тәрәзәләреннән үтәкүренмәле эңгер-меңгер килеп керде. Гүзәл урынына бүтән ятмаска дип, салкын идәнгә аякларын төшерде, торып басты. Сәгать җиденче ярты. Әлмәткә шалтыратырга кирәк, дип уйлады. Әти, бәлки, йокламыйдыр. Бераз икеләнеп торганнан соң, җәһәт кенә телефон трубкасын алып, таныш саннарны җыйды. Әтисе шундук җавап бирде, әллә телефон янында көтеп торган тагы. Алар бик озак сөйләштеләр, ата кеше үзенең авыруы турында, табибларның диагнозы хакында бер сүз дә әйтмәде. Әле белмәссең, дип фикер йөртте ул, медицина бик еш ялгыша, бик еш анализлар бутала, көтелмәгән могҗизалар булып кала. Алдан борчылырга, чаң сугарга ярамый.

Бу сөйләшүдән соң Гүзәл тынычланып калды. Әтисе исән,

аның тавышы көр, Фатыйма апа аның янында, авылга Сабантуйга машина белән кайтырга җыеналар... Барысы да әйбәт.

СОҢГЫ САБАНТУЙ

Рәшит Бәдретдинов кебек машина яратучы тагын берәр кеше бармы икән? Юктыр, мөгаен. Ул үз гомерендә төрле маркалы машиналарда йөрде. «Ока», «Жигули-5», «Жигули-7», «Волга» һәм менә, ниһаять, өр-яңа «ВАЗ-2111» — иң соңгы модель, модалы гүзәл юртак.

Машина эченә кереп утырып, руленә ябышу белән, аның күңелен шушы гүзәл белән идарә итү, хакимлек хисе биләп ала да, йөрәге еш-еш тибә башлый, күзләре очкынлана. Гүзәл юртак аның ихтыярына буйсына, тимер йөрәге Рәшит Заһретдин улының кайнар йөрәге белән бергә тибә башлый. Алар гүя бербөтен, бер җан, бер тән. Машина моторының гүләве дә аның күңелендәге дәртле җыр булып ишетелә, дәрте арта, җырлыйсы килә башлый.

Бүген дә шулайрак булды. Сигезенче июнь, 2002 ел. Ул барысын онытып, Фатыйма белән туган авылы Чупайга кайтып бара. Ә тимер юртак аның хисләрен аңлый, асфальт юлдан җилдәй җилдерә, коштай оча, ашкына. Сабантуйга! Чупайга! Рәшит яшьлек елларындагы кебек дәртле, авырусырхаулары гүя юкка чыккан, онытылган. Шунда ул кайчандыр укыган һәм гомерлеккә хәтерендә калган сүзләрне кабатлады: «И син, татар кешесе, кайда гына яшәсәң дә, шуны бел, килер бер көн, син үзеңнең туган җиреңә кайтырсың». Әйе, ул туган авылына, газиз туган җиренә кайта! Ашкынып кайта.

Чупай. Әнә әллә кайдан нур чәчеп мәчет күренеп тора. Ул авыл халкының кәгъбәсе, куанычы. Аны булдыру өчен Рәшит Заһретдин улы аз көч куймады, кемнәрнең генә ишеген шакымады.

Ул машинасын халык җыелган Сабантуй мәйданына китереп туктатты. Төсләр, бизәкләр, таныш йөзләр, яшьтәшләр, гармун тавышы. Очрашулар, күрешүләр, сөйләшүләр.

Рәшит үзенең җәрәхәтле җанын, яралы йөрәк сыкрануларын беркемгә дә күрсәтмәде, хәсрәтен сиздермәде, һәркем белән кул биреп күреште, елмайды, көлде.

Көн шулкадәр якты, күңелле, гүя аның алдында зур

тәрәзә ачылып куелган да анда аңа карап йөзләгән таныш йөзләр балкый. Әмма ул бик нык дулкынланды, кояшка күзе чагылды, авызы кипте.

ОПЕРАЦИЯ

13 июнь көнне өлкән табибны «Люкс»ка салдылар. Операциягә әзерлек башланды.

Бу төнне Рәшит Заһретдин улы йокысыз үткәрде, керфек тә какмады. Ул үткәннәре турында уйлады: гомере буе ашыкты, эшләде, өлгерергә тырышты, дулкынланды. Ә нәтиҗә? Каламы соң эзе җир йөзендә? Башына әллә нинди уйлар килде. «Язмыштан узмыш юктыр, ахры», — дип көрсенде.

Әйе, риваятьләргә әверелгән шомлы бер сүз бар — «язмыш». Иң авыр вакытларда кеше шул сүз белән үзен-үзе юата, кайгысын җиңеләйтә. Рәшит тә шул уйлар белән җәфаланды. Язмыш... Аның да бит гомере вакыт бизмәненә салынган.

Аннан кайнар күз яшьләрен тыя алмыйча, гаиләсе турында уйлый башлады, әллә ниләр күз алдына килде. Озын гомеренең еллары түгел, минутлары, секундлары исенә төште. Алия өйдә булганда өй ничектер яктырак, җылырак, күңеллерәк була иде. Ә Рәшит кухняда, Алиянең аш-су хәстәрләгәнен күзәтә-күзәтә, Татарстаннан килгән гәзит, журналларны укый. Сөенә-сөенә укый, яңалыклар, үзгәрешләр, югары үңыш. И-и, бу туган илнең йөрәккә якынлыгы! И-и, бу туган телнең матурлыгы! Алия залга чыгып утырырга куша, ә ул аны тыңламый.

Рәшит яткан җирендә күз яшьләре аша елмаеп куя. Аннан ул балалары турында, улы Рөстәм, оныгы Фәһим турында уйлый башлый. Фәһим чибәр егет булып үсеп җитте. Рөстәм, Рөстәм! Атаның бәгырен өзгәләгән бердәнбер улы, аның нәсел тамырын дәвам иттерүчесе. Ул аны да укытты, канатлар куйды, ә тамырларын саклау өчен чара күрә алмады. Аһ! Без үзебезнең балаларыбызга милли аң бирү турында бик аз кайгыртабыз шул. Эш тә эш. Өлкән апам Шакирәнең киңәшен тыңламадым, дөресрәге, колак салмадым. Аның киңәше бик вакытлы иде. Ул бит миңа: «Менә, иркәм, фәлән кешенең кызын Рөстәмгә димлик,

килен итеп алыйк», — диде. Ул бит гомере буе Чупайда яшәде, кешеләрне яхшы белә. Ул кыз чибәр, диде, уңган, диде. Ни үгетләде, ни үгетләде, ә мин шуны төптәнрәк уйлап карамадым. Рөстәмне шул кыз белән кавыштырырга акыл җитмәде. Хәер, ул минем киңәшемне тыңлар идеме икән? Аның тискәрелеге җитәрлек, дип уйлады Рәшит. Әйе, Рөстәмнең язмышы шулдыр: балалы хатынга, марҗага өйләнде. Бөтен тапканын шул хатынга бирде, яши генә алмады. Ни хатыны, ни баласы юк хәзер. Ул бүгенге көндә буйдак, дуадак каз кебек ялгыз. Бу да, бәлки, язмыштыр.

Рәшит Заһретдин улының төн буе йоклый алмый ятуын күреп, аңа таң алдыннан кирәкле чарасын күрделәр. Аннан ул иртәнге сигезгә кадәр тирән йокыда булды. Операциягә әзерлек өч көнгә сузылды.

Операция дүрт сәгать ярым барды. Әлмәтнең иң яхшы хирурглары бөтен белемнәрен эшкә җиктеләр, операция уңышлы чыкты.

Алты көн реанимациядә ятканнан соң аны ике урынлы якты палатага чыгардылар. Бер урында Рәшит, ә икенче урын аны тәрбияләүче, якты күңелле Фатыймага бирелде. Ике кәнәфи һәм өстәл, аның өстендә кайнаган су салынган графин, тәрәзә пәрдәләре ничектер бу палатаны үз фатирларына охшатып җибәргән иде. Алар хастаханәдәге катгый кануннарны онытып торырга ярдәм итте. Рәшит бик тыныч һәм озак кына йоклап ала, Фатыйма чисталык, тынычлык саклый. Ул аны кашыктан ашата, ярасын бәйли.

— Син булмасаң, мин ни эшләр идем, Фатыйма? — дип ул кайнар куллары белән Фатыйманың кулларын тота, — без зәхмәтне җиңәрбез, Фатыйма, без — герой! — дип шаярта.

Фатыйма көн димәде, төн димәде, ялны, йокыны онытты, аны карады, янында булды. Ята-ята Рәшит бер сүзне кабатлый:

— Минем янда син булмасаң, мин әллә кайчан аяк суза идем бит, рәхмәт сиңа, Фатыйма!

Рәшит әкрен генә басып йөри башлады. Аннары өйгә чыгардылар.

ТУГАН КӨН

Уникенче июль — Рәшит Бәдретдиновның туган көне. Гүзәл белән Фәһим аның туган көненә һәм хәлен белергә кайттылар. Алар кайтып кергәндә соң иде инде. Җәйнең кыска төне. Шәһәр урамында таш баганалар өстендә сөт төсле электр шарлары томан эчендә көмеш йөгертелгән сихри шарлар булып балкыйлар.

Фатир эчендә хаста ята торган өйләргә генә хас тынлык. Алар пышылдап кына исәнлек-саулык сүзләре белән эчкә уздылар. Залда зур тәрәзәдән уң якта диван өстендә урын-җир. Ап-ак җәймә ябынып, Гүзәлнең әтисе Заһретдин улы ята. Ул, кемнеңдер керүен ишетеп, урыныннан калкынды һәм йомшак тавыш белән:

— Кем бар анда? — дип сорады.

— Без, әти, Гүзәл белән Фәһим.

Авыр уйларыннан арынып, ата аз гына елмайгандай итте һәм аларга якын килергә кушты.

Фатыйма идәнгә сак кына басып, тавышсыз гына Рәшит янына килде һәм балаларга карап алды. Аның бу карашында, гүя: «Зинһар өчен, бик кычкырып сөйләшмәгез!» — дигән ялвару бар иде.

Гүзәл атасы яткан диван янына килеп, идәнгә тезләнде һәм аның сөякчел кулларын үзенең җылы учына алды. Ә ата Гүзәлдән читтәрәк басып торучы оныгыннан күзләрен ала алмады. Фәһим ап-ак тешләрен ялтыратып, аңа карап елмая. Оныгының малайларга гына хас кабарынкы иреннәре, кыска борыны, матур түгәрәк ияге, җитлегеп килүче егетнең саф гүзәллеге Рәшитнең күңелен эретеп җибәрде, ул күзләрен аңардан ала алмады. Кулларын Гүзәлнең учыннан алып, Фәһимгә сузды:

— Менә бит нинди минем оныгым, кадерлем, бербөртегем! — дип елап җибәрде.

— Туган көнең белән, бабакаем! — диде Фәһим, ниһаять, бу сулган йөздә үзенең бабасын шәйләп:

— Рәхмәт, балалар, шатлыгымны арттырдыгыз, тормышымны ямьләдегез, рәхмәт сезгә!

— Менә без терeләбез инде, — диде Фатыйма, бераз сүзсез генә аларны күзәтеп торганнан соң.

Өстәл өстендә бәллүр ваза эчендә зур-зур ак шарлар — чит-ят җирләрдән безнең якларга кайтарылган затлы чәчәкләр — хризантемалар өйне бизәп тора. Гүзәл аларны кайтып керү белән үк күреп алды һәм Фатыйма апа игъ-

тибарлы, әтине туган көне белән котлаган, дип уйлап, бу ханымга карата аның күңелендә рәхмәт хисләре көчәйде.

Тиздән Фатыйма өстәл әзерләде, өйдәге сый-хөрмәт белән янәшә Мәскәү кучтәнәчләре дә өстәлгә тезелде.

Шул арада шау-гөр килеп Рәшитнең якын туганнары килеп керде. Котлаулар, тәбрик сүзләре, теләкләр бик күп булды.

... Ә иртәнгә ап-ак хризантемалар башларын салындырып, шиңеп утыралар иде. Фатыйма, бу хәлне күреп, кулларын кушырып, катып калды һәм Рәшит күрә күрмәсен дип, ашыга-ашыга бәллүр савыты белән чәчәкләрне аш бүлмәсенә алып чыгып да суын түкте, савытка яңа су салып, тәрәзә төбенә челтәр артына яшерде.

Юк, барыбер чәчәкләр кабат калкынмадылар. Ләкин аларга игътибар бирүче булмады. Ярый әле кеше күргәнче алып куйдым, дип сөенде Фатыйма.

Рәшит икенче көнне бик иртә уянды. Әле балалар йоклый иде. Өйдә гадәти тынлык, Фатыйма гына аш бүлмәсендә нидер хәстәрли, тәмле исләр чыгара.

Кайтканнар, онытмаганнар, рәхмәт төшкерләре, дип уйлады Рәшит, ә оныгым, оныгым нинди бит! Менә кем минем эшемне дәвам итәчәк! — дип куанды ул.

Фәһим, әнисеннән дә алда уянып, тиз генә юынды да бабасы янына килде, аның диваны янына тезләнде. Ә бабасы үзенең кәгазь кебек коры, кайнар иреннәрен аның ике битенә тидереп алды. Аннан, оныгының зәңгәр күзләренә карап, пышылдады:

— Рәхмәт, балам! Тормышымны ямьләдегез, яшәүгә өмет уяттыгыз, рәхмәт! Бәхетле бул. Әниеңне сакла, ул да ялгыз бит. Ә мин, улым, терелэм. Сез мине терелттегез. Сез минем дөньяда иң кадерле кешеләрем бит.

Аның күзләрендә тагын яшьләр күренде.

Балалар озак тормадылар. Өч көннән юлга әзерләнделәр. Аларны озатканда Рәшит икесен дә бик озак, кабат-кабат үпте. Күз яшьләрен тыймады.

— Кайтыгыз, тагын кайтыгыз, мин терелгәч, Алияне — әниегезне алып кайтыгыз. Чупайга барырбыз, тауларга менәрбез, — диде.

Ә балалар һәм аларны озатырга китүче Фатыйма артыннан ишек ябылгач, аңа ялгызына бик моңсу, ямансу булып китте, ул озак кына тәрәзәгә карап, зәңгәр күк йөзен күзәтте.

Иртәнге илаһи нурлар аның күңелен күтәреп җибәргәндәй булды.

Тик берничә көннән кинәт аның хәле начарланды. Аны кабат хастаханәгә салдылар. Хәле начарлана башлагач, Рәшит Заһретдин улы Фатыймадан Мәскәүгә Гүзәл исеменә, Подольскига Рөстәм исеменә ике телеграмма бирүен үтенде. Телеграмманың текстын үзе әйтеп яздырды: «Состояние папы ухудшается».

Аның хәле гаять авыр булды, бөтен гәүдәсен салкын тир баса, Фатыйма аның маңгаеннан тирен сөртеп, киемнәрен алыштырып, яраларын чистартып тора.

— Авыртуга түзәр идем, Фатыйма, тын алуы бик авыр, — ди көч-хәл белән.

МИН СИНЕ ЯРАТАМ, АЛИЯ!

Телеграмманы алгач, Гүзәл Әлмәт белән телефон аша сөйләшеп алды.

— Фатыйма апа! Хәлләр ничек?

— Хәләр яхшы түгел, Гүзәл. Табиблар Рәшитнең үпкәсе тыңламый, диләр.

Табиб буларак, Гүзәл хәлнең начар булуын бик тиз аңлады һәм юлга әзерләнде. Ул Подольскига кайтып җитте һәм әнисенә хәлне аңлатты. Алия сүзен әйтә алмый озак кына торганнан соң:

— Самолетны белешегез, мин дә Әлмәткә барам, атагызны соңгы юлга мин дә озатырга тиеш, бу минем изге вазыйфам, — диде.

— Син нәрсә, әни? — диде Рөстәм. — Синең кан басымың югары, диабет, ишемия, синең үзеңнең хәлең бик начар. Безгә берьюлы ике кайгы кирәкми. Син беркая да бармыйсың, монда каласың.

— Балалар! — дип елап җибәрде Алия. — Миңа Рәшитнең бәхиллеге кирәк, мин тормышымда бик күп ялгышлар җибәрдем. Мин, аның күзләренә карап, бәхиллеген сорарга тиеш.

Әмма балалар катгый булдылар.

Рәшит, авыртуга көч-хәл белән чыдап, тешләрен кысып, күзләрен йомып ята иде, койкасы янына кемнеңдер якынаюын сизеп, күзләрен ачты.

Ул янында Гүзәлне күреп, гаҗәпләнмәде дә, сөенмәде дә.

— Саумы, әти! Бу мин. — Гүзәл әтисен танымады, ул инде танырлык түгел иде.

— Бу мин, әти, — дип кабатлады Гүзәл, ул ике кулы белән үзенең чигәләрен тотты, аннан үзен-үзе кулга алып, атасының төк баскан ябык яңагын үбеп алды.

— Кайттыгызмы? — дип пышылдады Рәшит Заһретдин улы һәм терсәгенә таянып, сак кына мендәреннән күтәрелде. — Кая Фәһим, Рөстәм? Алия?

— Әнинең кан басымы бик югары, ул юлга чыга алмады. — Рәшитнең күзләреннән яшь бәреп чыкты, ул хәлсез куллары белән күз яшьләрен сөртеп алды.

— Я сөйлә,ниләр бар ул якларда?

Гүзәл күбрәк Алиянең хәле турында сөйләде. Кызын озак кына тыңлап утырганнан соң, Рәшит Заһретдин улы һава җитмәүдән газаплана-газаплана:

— Ярар, Алия кайта алмаган, язмыш шулайдыр. Әгәр Әлмәт халкы, авылдашларым илтифат итеп мине искә алса, онытмаса, миңа шул җиткән, — диде.

Менә шушы авыр минутларда Рәшит шуны аңлады: ул балаларының анасы Алияне үлеп ярата икән. Алар бергә булырга тиеш, теге дөньяда булса да. Бер урын җирдә, бер түшәктә яткан кебек, кул җитәрлек кенә якын арада алар бергә ятарга тиеш. Кешеләрнең ничәдер проценты мәхәббәтнең татлы назын, газабын татымый гына яшиләр, имеш. Бардыр, бардыр, дип уйлады Рәшит Заһретдин улы. Алар шулай бәхетнең нәрсә икәнен белми теге дөньяга китеп баралар. Ул кара язмыш аның өчен түгел, юк. Бәхет, сәгадәт, мәхәббәт турында уйлар аның башына менә шушы авыр, газаплы минутларда килде. Алия аны гомере буе сөйгәндер. Ул бит бер кемгә дә ачу тота белмәде, тәмсез сүз әйтмәде. Алия аны эчтән генә яраткандыр. Менә шушы минутта Рәшит мәңге бетмәс ярату, бергә яшәгән чакларны сагыну, юксыну белән бергә көнчелек шул кадәр үк әрнү, сызлану, дөньяга, язмышка рәнҗү сизде. Әмма... Әмма... Нигә шул ярату хакында алар бер дә сөйләшмәделәр икән соң? Бер-берләренә: «Мин сине яратам», — дип әйтмәделәр икән? Ә? Әллә икесе дә артык тәкәббер, горур булдыларммы?

Менә хәзер газаплар эчендә ятканда мең чакрымнар еракта калган газиз кешесенә, хатыны Алиягә, ул эченнән

генә, ыңгыраша-ыңгыраша, кычкыргандай итте: «А-а-а! Мин сине яратам, сине генә, Алиям! Син минем белән бергә, бер туфракта ятарга тиеш!»

СОҢГЫ ЮЛ

Өй тулы кеше. Бүлмәләрдә, балконда, коридорда энә төртер җир юк. Ә халык һаман агыла да агыла. Хезмәттәшләре, ветераннар, туганнар, күршеләр. Соңгы елларын гаиләсеннән читтә, дөресрәге, аерым яшәгән, ялгыз гомер сөргән олы яшьтәге кешенең шул кадәрле дуслары булыр дип күз алдына да китерү читен.

Рәшит Заһретдин улы чәчәкләр ярата иде. Ул аларны өзәргә ашыкмый, чәчәкләр дә кешеләр кебек, туалар, үсәләр, үләләр. Алар шиңмәсеннәр, өзмәгез, дия иде.

Бүген аның җәсәде чәчәкләргә күмелде. Һәркем хөрмәтле табибка чәчәкләр алып килүне үз бурычы итеп санаган.

Хәзер инде аңа нигә кирәк чәчәк? Нигә кирәк бу кадәрле хуш ис, төс, бизәк? Күзләре инде аның мәңгегә йомылган.

Яңаклары эчкә баткан, ябык йөзен әҗәл газаплары әлләни үзгәртмәгән, тыныч, әмма ул йөздә аңа гына хас самими елмаю юк иде. Киң маңгаенда җыерчыклар тирәнәйгән, аерым-аерым ярылып яталар. Ул тирән җыерчыкларда аның озын гомер юлы киртләнеп калган.

Рәшит Бәдретдинов яшәгән йорт янындагы мәйданда матәм митингы. Урам, тыкрыклар халык белән тулы. Тын гына, шым гына, тынычлыкны бозмас өчен ярымпышылдап сөйләшеп торалар. Танышлар, таныш булмаганнар, хезмәттәшләре, табиблар, каяндыр еракларлардан кайткан якын кешеләре аның белән соңгы мәртәбә хушлашырга килгәннәр. Сәгать унбер. Кояшлы җылы август.

Зиратка юл — дөньяда иң озын юл. Вакыт бу юлда үзенең үлчәмен, санын югалта. Ул вакыт минутлар яки үтелгән метр, чакрымнар белән саналмый, ә мәрхүмнең якыннарының күңелендә җәрәхәтнең авырлыгы, йөрәкләрдә яраның тирәнлеге белән санала.

Кеше китә, әмма аның эзләре җир йөзендә озак саклана. Кеше никадәр яктырак һәм юмартрак яшәсә, аның эзләре шул кадәр тирәнрәк һәм җуелмаслык булып кала.

Эчтәлек

Повестьлар
Рәйхан. 5
Буранлы юллар 75
Урланган бәхет 149

Хикәяләр
Сабырлык 229
Ышаныч 243
Сикәлтәле юллар үткәндә 257
Бәхет 275

Кайттым сиңа, газиз туган җирем *(очерк)* 285

Литературно-художественное издание

Дибязя Каюмова
Вьюжные дороги

Художественное оформление и
верстка Р.Хасаншин
Корректор Р.Салахиева

Формат 84х108/32. Бумага офсетная.
Гарнитура Школьная.
Печать офсетная. Печатных листов 12.
Тираж 500 экз. Зак. № Э-835

Отпечатано в ГУП ПИК «Идел-Пресс».
420066, г.Казань, ул. Декабристов, 2.